
# КАЗАН УТЛАРЫ

12.1999





НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ

1899—1992

# Казан утлары
# Qazan utları

*1999*

# 12

**(926)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

／# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Яңа меңьеллыкка—яңа имла белән ... 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр ... 9
Әнәс ГАЛИЕВ. Чигенгәндә. Повесть *(А. Гыйләҗевнең кереш сүзе белән)* ... 17
Роберт ӘХМӘТҖАН. Юлдагы кешеләр ... 59
Мансур ВӘЛИ. Мәхәббәт мажаралары. *Новеллалар* ... 65
Сафуан МУЛЛА ГАЛИ. Үткәннәр белән сөйләшеп ... 125

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ. Гасыр бусагасын атлаганда ... 127

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Сәгыйть ХАФИЗОВ. Туксанынчы еллар әдәбияты ... 144
Редакциядән ... 147

**НӘКЫЙ ИСӘНБӘТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Нәкый ИСӘНБӘТ. Мәкальләребез турында ... 149

**ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Дини тәрбияне кем бирер? ... 165

**ДӘРДМӘНДНЕҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ**

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. «Танылмыйдыр кеше тышыннан» ... 172

**СӘНГАТЬ**

Хәлим ҖӘЛӘЛОВ. Сагындырып искә төшә һаман *(Г. Шамуковның туууына 90 ел)* ... 181

1999 елда журналда чыккан әсәрләр исемлеге ... 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Колонка редактора»: «В новое тысячелетие—с новым алфавитом».
«Проза и поэзия»: стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Роб. АХМЕТЗЯНОВА, С. МУЛЛА ГАЛИ; повесть А. ГАЛИЕВА «Отступление», новеллы М. ВАЛИЕВА «Любовные приключения».
«Публицистика»: статья А. ФАЙЗРАХМАНОВА «На пороге века».
«Литературная критика»: статья С. Хафизова «Литература 90-х годов».
«К 100-летию Наки Исанбета»: статья выдающегося писателя и ученого-фольклориста «О пословицах» *(окончание)*.
«Актуальная проблема»: статья Ф. БАЙРАМОВОЙ «О духовном воспитании детей».
«К 140-летию великого татарского поэта Дэрдменда»: статья Л. ХАМИДУЛЛИНА «Души прекрасные порывы».
«Искусство»: статья Х. ЗАЛЯЛОВА к 90-летию Г. Шамукова «Помним, гордимся, грустим».
Список произведений, опубликованных в журнале в 1999 г.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зимнее мгновение—фотоэтюд; поэт Разим Валиуллин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

“Column of editor”: «In new millennium - with new alphabet».
“Prose and Poetry”: the verses of R. FAIZULLIN, Rob. AKHMETZIANOV, S. MULLA GALI; the story of A. GALIEV «The retreat», the novels of M. VALIEV «Love adventures».
“Publicism”: article of A. FAIZRAKHMANOV «On threshold century».
“Literary criticism“: «Tatar literature of 90 th years»— article S. KHAFIZOV.
“Commemorating the 100 Anniversary of N. Isanbat”: article remarkable writer and scientific - folclorman «About proverbs» (finishing).
“The actual problem”: article of F. BAIRAMOVA «About spiritual education of children».
“To 140th years great tatar poet Derdmand”: article of L. KHAMIDULLIN «The beautiful outbursts of soul».
“Art”: article of KH. ZALYLOV to 90 th years G. Shamukov «Remember, take pride, melancholy».
List works, publication in magazine in 1999 year.
The diary of social and cultural life.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 29.11.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8029 Заказ 3-613
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.

*Мөхәррир сүзе*

**Флүс Латыйфи**

# ЯҢА МЕҢЬЕЛЛЫККА—ЯҢА ИМЛА БЕЛӘН

Егерменче гасыр азагы татар халкының сәяси, мәдәни һәм, гомумән, иҗтимагый тормышында гаять мөһим, яшәешебезне билгеләүдәге әһәмияте белән тулы бер гасырларны колачларлык борылышлар чоры булды. Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итүдән башланган бу процессның җимешләре ике меңенче елга кереп килгәндә тагын да мулрак, үтемлерәк булып күз алдыбызга килеп баса. Әле моннан дистә еллар элек хыялда гына йөргән казанышларга без шул хәтле күнектек, гадәти бер хәл итеп кабул итә башладык ки, хәтта еш кына чын әһәмиятен аңлап та житкермибез шикелле тоела. Ләкин, ничек кенә булмасын, алар бар, алар елдан ел арта. Ә инде бу үзгәреш-яңалыкларны шулай булырга тиеш дип кабул итү, халык үзаңының яңа баскычка күтәрелүе, татар милләтенең дөньядагы цивилизацияле халыкларга хас зыялы һәм мәдәни яктан гадәти тормышка керә баруы турында сөйлидер.

Шушы казанышлар арасында иң мөһиме, минемчә, заманында хаксызга рәнҗетелгән, тапталган, изелгән, кыерсытылган газиз туган телебезнең, ниһаять, егерменче еллардан соң яңадан дәүләт статусы алуы, аның акрынлап булса да киң кулланышка—фән һәм икътисадка, мәгарифкә һәм югары уку йортларына, рәсми кәгазьләргә үтеп керүе. Тел—милләтне милләт итүче төп сыйфат, төп шарт. Телсез милләт булмаган кебек, телсез дәүләт тә була алмый. Татарстан суверен дәүләт икән, димәк, аның суверен тел сәясәте, төп милләт телен саклауны, яклауны һәм үсешен тәэмин итүче кануннары да булырга тиеш. Шул кануннарның катгый үтәлүе исә халкыбызны яңарышка алып баручы төп шартлардан санала.

Нәрсәләргә ирештек, ике меңенче ел бусагасын атлаганда куанып сөйләрлек ниләребез бар соң? Бармакларны бөгә башлыйк әле. Бердән, шәһәрләрдә татар балалар бакчалары барлыкка килде. Икенчедән, Татарстан башкаласы Казанда, Чаллыда, Түбән Камада, Әлмәттә генә түгел, халкыбыз тупланып яши торган Ижау, Ульян, Оренбург кебек зур шәһәрләрдә дә татар мәктәпләре, гимназияләр, туган телдә белем бирүче сыйныфлар ачылды, төрек-татар лицейлары, колледжлары, татар-инглиз мәктәпләре эшли башлады. Моннан ун-унбиш еллар элек кенә әле татар балаларының нибары 7 проценты урта белемне татар телендә алган булса, хәзер ул сан, Татарстан Мәгариф министрлыгы мәгълүматларына караганда, 47 процентка житте. Татар теле предмет буларак республиканың барлык мәктәпләрендә урыс теле белән бер дәрәжәдә өйрәнелә. Өченчедән, татар теле югары уку йортларында торган саен киңрәк тамыр җәя. Әле моннан ун ел элек кенә татар теле фән буларак бары тик Казан дәүләт университетының һәм педагогия институтларының филология факультетларында гына өйрәнелә иде. Ә хәзер Казан төзүче инженерлар академиясендә, авыл хуҗалыгы институтында, дәүләт консерваториясендә, ветеринария медицинасы академиясендә, югары техник уку йортларында татар телендә белем бирүче аерым төркемнәр, факультетлар бар, Казанда гуманитар институт эшли, Татар милли университеты ачылу көненә дә күп калмады кебек. Дүртенчедән, Ижау, Төмән, Ульян һәм башка шәһәрләрнең педагогия институларында татар филологлары әзерләүче төркемнәр ачылды, алар инде беренче чыгарылышларын да ясады. Бишенчедән, аспирантурада уку, диссертация яклауны да Казанның үзендә, туган

телдә башкару мөмкинлекләре тудырылды. Болары—белем алу, яшь буынга туган телдә белем бирү өлкәсендә. Татарча укып, югары белем алып чыккан яшьләребез арткан саен, алар фәнгә һәм халык хуҗалыгына күбрәк килгән саен, туган телебезнең дә абруе, кулланыш даирәсе дә шуларга нисбәтән арта һәм киңәя барачак. Болары—киләчәк эше, инде якын киләчәк эше.

Анык беләм, барлык казанышларны санап чыгу өчен кул бармаклары гына җитмәячәк. Инде алтынчыдан, җиденчедән, дип санап тормый гына тагын бераз йомгак ясыйк әле. Казанда "Курай" һәм "Дулкын" радиолары тәүлек буе туган телдә сөйләп тора, андыйлар республиканың башка шәһәрләрендә дә байтак хәзер. Татарстан радиосы авазлары кыска дулкыннарда дөньяның барлык кыйтгаларына тарала, Прагада "Азатлык" радиосы сөйләп утыра, Төркия дәүләт радиосында да татарча тапшырулар башланды.

Инде килеп, матбугат өлкәсенә күз салыйк. "Мәгариф" нәшрияты, матди кыенлыклар заманасы булуга карамастан, полиграфик эшләнеше, бизәлеше ягыннан да, эчтәлеге һәм фәнни кыйммәте ягыннан да иң югары кимәлдәге таләпләргә җавап бирүче зәвыкълы китапларны елдан-ел күбрәк бастырып чыгара. Инде танылып өлгергән яңа басмалар—"Идел", "Мирас"ларны санап тормыйча, әлегә киң катлау укучыларга артык таныш булмаган, әмма әһәмияте ягыннан бәяләп бетергесез берничә яңа мәҗмуганы да күрсәтү мөһим эш булыр. Күптән түгел генә Казанда "Фән һәм тел" журналын укучыларга тәкъдим иту булды. Бу инде гуманитар фәннәр белгечләренең генә түгел, ә җисми фәннәр галимнәренең туган телгә йөз белән борылуын раслучы яңа бер дәлил. Журналның беренче санында ук татарның күренекле математиклары, биологлары, медиклары, физиклары һәм башка галимнәре чиста татар телендә фәннең теге яки бу тармагындагы яңалыклар, югары уку йортларында ана телендә укыту проблемалары турында фикер уртаклашалар. Боларга өстәп Татарстан Фәннәр Академиясенең тарих институты чыгара башлаган "Татар археологиясе" журналын әйтми калу мөмкин түгел. Аерым мәкаләләре урыс, татар, инглиз телләрендә басылучы бу яңа басма да халкыбыз тарихын өйрәнүдә яңа баскычны тәшкил итә. Инде килеп, ноябрь башларында Казанда тагын бер чын мәгънәсендә тарихи вакыйга булды: киң катлам укучыларга "Татар энциклопедик сүзлеге" тәкъдим ителде. Татар энциклопедиясе институты галимнәре ун ел дәвамында төзегән бу киң колачлы белешмәлектә татар тарихы, аның бүгенгесе, теле һәм әдәбияты, матди һәм рухи культурасы, күренекле шәхесләре хакында иң тулы мәгълүматлар тупланган. Татар тарихында әле мондый колачлы басманың булганы юк иде.

1999 ел халкыбыз тарихына тагын бер мөһим вакыйга белән дә кереп калыр. 15 сентябрьдә Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев "Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында" Татарстан Республикасы Законына кул куйды. "Бу Закон латин графикасы нигезендә татар алфавитын тагын да камилләштерүгә һәм аның дөнья коммуникация системасына керүе өчен уңай шартлар булдыруга юнәлдерелә,—диелә Законда.—2011 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасында бер үк вакытта ике алфавит: латин графикасы нигезендәге һәм кириллица гамәлдә була". Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2001 елның 1 мартына кадәр латин графикасы нигезендә татар алфавитын кертү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына кертү бурычы йөкләнде. 2001 елның 1 сентябреннән беренче сыйныфка укырга кергән балалар әлифбаны яңа имлада укый башлаячак.

İnde az ğına tarixqa küz təşerik. Bez ni əçen urıs xəreflərenə küçkən, dəresrəge, məcbüri küçerelgən idek? Ul omtılış qayçan başlanğan? Ul soraularga cawapnı bik yıraqtan, ütkən ğasırlardan uq ezlərgə turı kilə. Əye, tatarlarnı urıs xərefenə küçerergə mataşu inde XVIII ğasır azaqlarında başlana həm XIX ğasırda tağın da kiŋrək qolaç ala. Tatar dəülətləren yaulap alğannan soŋ qoral kəçe belən genə tatar xalqın çuqındıru həm urıslaştıru barıp çıqmağaç, urıs patşaları həm missionerlar aldau yulına basalar: uqımışlı həm kitaplı, kitap süzen izge sanauçı xalıqnı yuldan yazdıru əçen kirillitsa xərefləre belən tatarça kitap çığaru eşenə kereşələr. Əlbəttə, berençe çiratta Alla süze—İncil həm Bibliə tərcemə itelə. Aldawıç sıyfatında isə tərle kalendar'lar, tərle beleşmələklər çığarıla. Alarda nasara (xristian) dineneŋ əstenlege, urıs xalqınıŋ ayırım missiəgə iə bəyek xalıq ikənlege təkrarlana. Əmma bay mədəni traditsiələre,

borın-borınnan sınalğan ğөref-ğədətlərе həm yolaları, əxlaqıy qanunnarı yəşəp kilgən xalıq aldanmıy.

Berniçə gasır dəwamında patşa xөkümətе həm ің yawız qara missionerlar eşli almağannı isə sovet xөkümətе berniçə yıl eçendə xəl itte də quydı. Xalıq meң ğasırlıq yazma ədəbi həm fənni mirasınnan, ruxi xəzinəsennən ayırıldı. Din belən kөrəş sıltawı astında ğərəp imlasında basılğan meңnərçə, distə meңnərçə dөnyawi kitaplar yandırıldı, yөz yıllar buyı tuplangan aң-belem çığanagı, xalıq təcribəse yuqqa çığarıldı, ğərəp xəreflərе belən yazılğan kitaplarnı saqlagan өçen genə də distələrçə meң uqımışlı keşe tөrmələrdə çeretelde.

Dөres, totalitar rejim, üze belepme, əllə belmiçəme, yalgışlıq cibərde. Nigezdə, tatarnı millət bularaq saqlap, yaqlap, üzanın oyıştırıp kilüçe islam dinennən ayıru өçen, anı mirasınnan məxrüm itü өçen eşləngən bu adım—1929 yılda barlıq tөrki xalıqlarnı latin xəreflərenə küçerü—bөtenləy kөtelməgən nəticə birde. Tipografiə eşe өçen uңaylı, yazılışı belən matur həm tatar teleneң awazlar sistemasına tulayım təngəl kilüçe latin xəreflərе qullanışta yөrgən qısqa ğına arada da çit il həm urıs klassiklarınıң iң yaxşı əsərlərе basılıp çıqtı, hər rayonda tipografiələr barlıqqa kilde. SSSRnıң tatar yəşi torğan hər tөbəgendə diərlek tatarça kitap həm gəzit-jurnal çığaru cayğa salındı. Latin xəreflərе, şulay itep, imperiə tırnagınnan qotıldım dip uylagan xalıqnıң tərəqqiət dөnyasına ırğılıp kilep keruenə səbəp buldı. Ləkin... busı, xərbi tel belən əytkəndə, aldawiç manevr ğına bulganmı, əllə totalitar rejim üzeneң xatasın bik tiz aңlap aldımı, ul tağın da qurqınıçraq, tağın da afətlerək yaңa udar əzerləgən ikən. Həm kommunistlar xakimiəte patşa türələrе həm missionerlar yөz yıllar buyı xıyallangan maqsatnı tormışqa aşıruğa kereşte. Tatar xalqın dinsez qaldıru belən bergə, anı ruxi çuqındıru—urıs xəreflərenə küçerü başlandı. XVIII gasırdan uq kilüçe astırtın həm məkerle eş üzeneң logik axırına kiterep cıtkerelde.

Urıs imlasınıң tatar həm, ğomumən, tөrki tellərgə yabışmağanlığı küplərgə məğlüm. Bu tellərdə ber ük tamğa belən kürsətelgən xərefləmeң əyteleşe bөtenləy başqaça yangırıy. Ber ük xəreflər belən yazılğan süzlər, məsələn, urısça ber, tatarça ikençe tөrle uqıla. Misallar bik küp: əytik, он—*он*, сука—*сука*, койка—***койка...*** Ə inde kirillitsa xəreflərе belən tatarça yazarga tırışqan süzlərdən bөtenləy məğnəsez nərsələr kilep çığu da ser tügel. Urısnıң "Что делать", yəgni "Nərsə eşlərgə" digən sorawına cawap bulıp yaңgırauçı *Тәлгать, Сибгать, Рифгать* kebek isemnər, ***канәгать, сәгать*** kebek süzlər yazılışı h. b. h. b. İmla berlegennən kilep çıqqan mondıy ğayre tabiği, dөnyanıң ber genə telendə də bulmagan məğnəsezleklərne bik küp sanap bulır ide. Xəyer, bezneң maqsatıbız ul tügel. Qızıqsıngan uquçılar yaxşı xəterlider, gəzit-jurnal bitlərendə latinğa qaytu məs'ələlərе buyınça fiker alışularda andıy misallar xətsez küp kiterelgən ide inde.

Ниһаять, ун елга якын сузылган бәхәсләргә чик куелды, латин имласына кайту дәүләткүләм дәрәҗәдә хәл ителде. Әйе, бәхәс каты барды, озакка сузылды. Әмма татарның алга карый белүче фикер ияләре И. Таһиров, Ә. Кәримуллин, М. Зәкиев, Х. Курбатов, В. Хаков, И. Надиров, яшь буыннан Мөдәррис Вәлиев, Р. Хәкимов, Римзил Вәлиев, Ж. Сөләйманов, инде мәрхүм Ф. Зөлкарнәй кебек галимнәре вә җәмәгать эшлеклеләре, каләм осталары латин имласына кайтуны яклап кин хәрәкәт җәелдереп җибәрделәр. "Ватан" җәмгыяте "Яңалиф" имласында халыкара "Dөnja" гәзитен чыгара башлады, "Мәгариф" нәшриятында В. Хаковның "Telen belgən il acar" дигән китабы, уку һәм язу күнекмәләре басылып чыкты, латинның уртак төрки вариантында "Идегәй" дастаны һәм "Кыйссаи Йосыф" поэмалары дөнья күрде. Һәм горурланып әйтә алабыз, бу өлкәдә "Казан утлары" журналы тотрыклы һәм эзлекле тел сәясәтен алып барды: вак бәхәсләргә катнашмыйча гына дистә елга якын үз битләрендә латин имласының төрле вариантларында борынгы һәм бүгенге әдәбият үрнәкләрен бастырып укучыларга тәкъдим итә торды. Төп бәхәс исә латинга кайту-кайтмауда түгел, бөтенләй башка, беренче карашка бик гади тоелган икенче бер мәсьәләдә—төгә яки бу хәрефнең язылышында иде. Галим-голәмә арасында кабул ителгән имлада аларны әле дә хуплап бетермәүчеләр бардыр. Аның тәгаен шулай икәнен дә беләм. Ләкин хикмәт анда түгел. Иң мөһиме—татар теле, ниһаять, аваз системасына тулаем тәңгәл киләторган имлага ия булды. Әле I Бөтендөнья татар конгрессында ук Төркиядән килгән күренекле тәрҗемәче, галим кеше Мостафа Өнәр болай дигән иде: "Иске классик төрки телләрнең элемтәсе нык иде. Казанда чыккан

китапны рәхәтләнеп укый ала идек. Латин имласы шул мөмкинлекне кире кайтарачак. Әйдәгез, тагын бер булыйк, бергә булыйк. Ильминскийдан калган мирастан котылырга вакыт". Бу сүзләр бәхәсләргә нокта кую булып та, киләчәккә өмет булып та яңгырый кебек миңа.

Тарих һәм чор татар халкына тагын бер мөмкинлек тудырды. Латин хәрефләренә кайту белән бәйле вакытлы кыенлыклар үтәр дә китәр. Ә татар теле үзенең мең еллык традицияләрен саклаган хәлдә яңа меңьеллыкка аяк басар. Яңа имла телебезгә бирелгән яңа мөмкинлекләр, аның тагын да камилләшүенә юл ачу дигән сүз дә ул.

*Түбәндә яңа имладагы хәрефләрнең язылыш үрнәкләре тәкъдим ителә:*

| № | БАСМА | ЯЗМА | ӘЙТЕЛЕШЕ | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ЛАТИНИЦА | КИРИЛЛИЦА |
| 1 | A, a | *A. a* | a | а |
| 2 | Ə, ə | *Ə. ə* | ə | ә |
| 3 | B, b | *B. b* | be | бе |
| 4 | C, c | *C. c* | ce | же |
| 5 | Ç, ç | *Ç. ç* | çe | че |
| 6 | D, d | *D. d* | de | де |
| 7 | E, e | *E. e* | e | е |
| 8 | F, f | *F. f* | ef | эф |
| 9 | G, g | *G. g* | ge | ге |
| 10 | Ğ, ğ | *Ğ. ğ* | ğı | гъ |
| 11 | H, h | *H. h* | he | һе |
| 12 | I, ı | *I. ı* | ı | ы |
| 13 | İ, i | *İ. i* | i | и |
| 14 | J, j | *J. j* | j | җе |
| 15 | K, k | *K. k* | ke | ке |
| 16 | Q, q | *Q. q* | qa | къ |
| 17 | L, l | *L. l* | el | эл |
| 18 | M, m | *M. m* | em | эм |
| 19 | N, n | *N. n* | en | эн |
| 20 | Ņ, ņ | *Ņ. ņ* | eņ | эң |
| 21 | O, o | *O. o* | o | о |
| 22 | Ɵ, ɵ | *Ɵ. ɵ* | ɵ | ө |
| 23 | P, p | *P. p* | pe | пе |
| 24 | R, r | *R. r* | er | эр |
| 25 | S, s | *S. s* | es | эс |
| 26 | Ş, ş | *Ş. ş* | şa | ша |
| 27 | T, t | *T. t* | te | те |
| 28 | U, u | *U. u* | u | у |
| 29 | Ü, ü | *Ü. ü* | ü | ү |
| 30 | V, v | *V. v* | ve | ве |
| 31 | W, w | *W. w* | wı | в (у) |
| 32 | X, x | *X. x* | xa | ха |
| 33 | Y, y | *Y. y* | y | й |
| 34 | Z, z | *Z. z* | ze | зе |

# ШИГЪРИЯТ



## Равил Фәйзуллин

### ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

*

Кавтау. Сугыш. Ташлар егълый...
Бомба ява халыкка.
Таулардан да биек булып
Үлмәс Нәфрәт калка.

Яна илләр. Вәйран булды
Әфган, Ичкер, Таустан...
Кылыч һәм Гөл булып шытыр
сабыйлардан аккан кан.

*

Уч тулы үч.

Нишләтергә моны?

Чәйгә салып болгатыргамы?
Сибәргәме Тегенең артына?
Пистолетның газы урынына
тутырыргамы шушы әчене?
Йотаргамы буар елан күк?

... Түктем ялан тәпиләремә.
Гөнаһлы аяк кичерер.

... Кулны юып,
Әнием рухына
дога кылдым
белер-белмәс
дога белән.

*

Канда—басып алу, талау.
Канда—канга батыру.
Юлбасарлыкта, угрылыкта
басмач «туган» батыр ул.

Читләрдән акча теләнер,
ракет базалар корыр.
Башкисәрләр тәрбияләп,
«азатлык» урнаштырыр.

Иген игеп азанланмас,
күп җире кысыр калыр.
Тарих чүплегендә «империя»
исемен алып калыр.

Һич булмаса, указлатып,
үз халкын ачта тотар.

Галәм нәфесле царьларның
беркөн үзен Җир йотар.

*

«Теге бөекнең тамыры
татар каныннан икән!
Төгән шәхеснең әбисе
Казан ягыннан икән!
Тәхет күргән ди фәләннең
бабасының бабасы—
чукынганчы ул бабаның
әтисенең бабасы...
Елъязмалар тузаныннан
их, исемен табасы!..

Наполеон да әйткән, имеш:
«Урысны игәүләп кара—
асылына төшкән саен,
татары торып кала».

Менә шундый безнең халык!
Бөекләрне мул биргән!
Дөньясында андый юктыр,—
безнең татар «Во!» дигән».

... И, кардәшем, сабыйланма,
горурлыгың—кабердә.
Ул бөекләр синекен дә
ашап киткән кавемнәр!
Бүген сине кол иткәннең
фәлән кемдер бабасы...
Әнә кырда чөгендерең,
эшлә, татар баласы!

## Мәдхия

*Флерага*

Нәселебез бәхетенә
туган кыз бала Син!
Кама ярына куярлык
һәйкәл—Ана Син.

Күпмебезгә—һәр гамәлең
рух-көч өстәде.
Шәфкать фәрештәсе булса,
ул—Синең төстәдер.

Синең мәрхәмәтеңне
үзем дә күп тойдым.
Изгедер бу! дип күңелемә
исемеңне уйдым.

Әрвахлардан—изге рух,
исәннәрдән—дога.
Бөек дигән тәгъбир бар бит,—
лаеклы Син шуңа!

*

Бүләкләрме?

Алгаладык.

Һәрбер бүләк—
алды саулык.
Булса да ул
бер кулъяулык...

... Арттан килгән
ат булмадык!

*

Шундый чак килә:
Җанга вәхи-хат иңә—
теләмә теләүләрен дә,
телефон челтерәвен дә,
ишек шакуларын да,
тәрәзгә кар атуларын да,
почта әрҗәсендәге чакыруларын да...

Һәй, Дөнья! Яшисе килә!
Көтәсең солы... борчак килә!

... Таң алдыннан,
күз алдыма,
гөнаһларны яндырып,
киләчәктә балкыр
Учак килә!

Чын хак килә.

## Оялма!

**Яшеңнән дә,**
**яшәвеңнең**
**рәвешеннән дә!**

**Таңда торгач,**
**чыкка төшкән**
**яшеңнән дә!**

**Эшең өскә чыккан!**
**Бу дөньяда**
**ни чинамас**
**сөткә төшкән тычкан!**

**Сират-кичүгә**
**кем нәрсә илтә!**
**Тыныч булсын төнең,**
**тыныч булсын иртәң!**

*

**Әче хәсрәт... Төче хәсрәт...**
**Татлы хәсрәт—синдер ул!**
**Гомерлек җандашка сусау—**
**Ялгызлыкка—синдром.**

**Тәүбәгә килгәнсең, имеш...**
**Тәүбә эчендә ни ята?**

**Түрдә янә таныш хата**
**ыржаеп көлеп ята.**

*

*«Аккош күле» циклыннан*

**Тәрәзәдә Синеңме сулыш?**
**Күбәләк икән...**

**Тәрәзәдә Синекеме кул?**
**Яфрак икән...**

**Саңгырау итәр яшен орды!**
**Бу—тәгаен Син!**

**Имән төбендәге күлдә**
**шыткан бер гөл!**
**Монсы... ахры, мин.**

*

**Авырыйсың?—димәк гөнаһың бар.**
**Җәза итеп Тәңре җибәргән.**
**«Череп кат!» диюче үзе корый,**
**үз каргышын алып бер бәндә.**

Өч сүгенеп, бер бисмилла әйтеп,
зина уйда укып бер «намаз»,
Ике Дөньялыкның бер чите дә
андый җанга җәннәт булалмас.

## Бала теләү

Көлеп килә Төн!
Карынындагы
Таң белән килә!

... Гаҗәп төш күрдем:
Диңгез-дулкында
тирбәлә силә!

*

«Хәзер—матур. Тиздән гүзәл булыр!
Ярда—чәчәк, тауда—кар исе!
Яз гөлләрен икәү бергә-бергә
Җыяр идек!.. Бездә кал!» дисең.

Бездә Кырымнан да яхшырак дип,
әйтә алмыйм сиңа, Гөлчәчәк...
Беләм: хәтта сәлви күләгәсе
ак юл булып төшкә керәчәк.

Күк Түбәләр Иле ят итмәде,
үз улыдай горур көн кичтем.
Маңгаемнан сөеп дулкын юды,
яшем чыкса, сөртеп җил исте.

«Ни җан белән китеп барасың син,
мин һәм миндаль чәчәк чагында?..»
... Сиңа түгел,
Аны сагынып өчен
килдем бит мин Диңгез ярына.

*

Козгын кунган киртәгә!..
Бүген—чебеш... Иртәгә?

Баскын тубы киртәдә!..
Бүген—чечен... Иртәгә?

Атмас диеп кем әйтә ала
канлы таңнар иртәңә?

## Триптих

*

Кавказ дәрьялары—кан елгасы.
Тау бозлары яшькә манчылган.
Каргыш болытларын сөйрәп йөри
күген җуйган бөркет-лачыннар.

*

Төннең—ае, көннең—кояшы юк...
Шомлы бер өн: иңри «ах-вах!..»лар...
«Җирдә нинди мәшһәр түе?» диеп
кубарылып баскан әрвахлар...

*

*Юктырсың ла, Алла...*
М. Г.

Язмыш итеп, вәхшиләргә—җиңү,
ватандарга—үлем язасың?..
Җәннәт җирен тәмуг ясаганнар
нигә алмый Күкнең җәзасын?

## *Кыска шигырьләрдән*

### Хәер бирмәгән чакларда...

Чәнчеп бозлы яңгыр явадыр күк
ләхет аша Әни йөзенә.

### Үземнеке!

Икәү фотога төшкәнсез.
Син—барыбер уртада!

*

Сәрхүш илнең кайгысы юк.
Халкының айныйсы юк.

*

Күк исеменнән кемдер кисә кебек
Миңа тигән Бәхет юрганын.

### Көтүче

Йокысызлык дигән каравылчы
саклап тора Еллар көтүен.

### Тагын бер мәртәбә Сиңа

Картайсаң да, яшәрсәң дә
матур булуың ошый!

### Хыянәт

Төенләнә-төенләнә ап-ак таңда
кара кан косты.

*

Утыз биштә. Өйләнмәгән. Алкоголик. Теләге юк.
Алма пешкән. Өзелеп төшкән. Череп ята. Кирәге юк.
Шигырь яза. Тамак туймый. Ил укымый. Тереге юк.
Дөнья кайный. Эре-вак бергә. Аерып булмый. Иләге юк.

*

Яхшылык эшлә дә,
яманлык көт!
Акмы, карамы—
эт—барыбер эт!

*

Җир сөрмәде. Нигъмәт күрде.
Илдән бизде. Дөнья гизде.
Этлек итте. Рәхәт чикте.
Кадер белән гүргә керде.
Имди...

*

Иясез шатлык түгел хәзер.
Ияле шатлык булдым:
Хыялым пирамидасына
бер шөпшә килеп кунды.

*

*«Их, милай!» дип әйтә иде Дәүәнием.*

Минем өчен борчылма Син!
Аңа хакың булу кирәк!
... Җисми тәгәрәшү бер хәл,
рухан туган булу кирәк.

## Гәрәмәчкә солы кырында

Язган чакта каләм тиеп алды:
бәллүр савыт—төнге бер зеңләү!

... Рәшә булып Икәү тибрәнгәндә
балкорт торды өстә безелдәп!..

*

*М. Хәсәневне уйлап*

Ятам ромашкалар диңгезендә
кулларымны җәеп чалкан!
... Ничекләр икән Алып Мәхмүткә
корт та үтмәс цинк табутта?..

## Ул төннәр истәлеге

Син чәпәгән черки эзе—
рамларлык сурәт!
Мәхәббәтнең сукырлыгына
тагын бер гыйбрәт.

## 99 яшьлек карт

Ни әйтсәм дә хәзер, барсы дөрес...

Бар яшьтәшләр—замандашлар барсы гүрдә...
Гөнаһларыма шаһит бер адәм юк.

... Янган морҗа булып Дөньялыкта
ялгыз мин калдым.

*


Күңелдә иман булмаса—
мәчет ни дә, азан ни!
Җәһаләт белән сәрхүшлек
безне әле озак җәзалар...

*

Кадерсездән—кадерсезгә...
Кара көздән—ай юлына.
Калам, ахры, «җан дуслар»дан
Киләчәкнең ак кулына.

*1998-1999*

## Чәчмә әсәрләр



# Әнәс Галиев

# ЧИГЕНГӘНДӘ...

ПОВЕСТЬ

*Әнәс Галиевнең архивы зур түгел. Гомере буе властьлар тарафыннан изелгән, кимсетелгән, куркытылган, утә намуслы кеше көндәлекләр алып бармаган. Язган хатларының копиясен сакламаган, үзенә килгән хатларны да яндыра барган...*

*Безнең танышып китү кызык кына булды. Моннан егерме еллар элек ул миңа «Коерыклы йолдыз» исемле повестен алып килде. Үзенең каһәрләнгән язмышы, бәхетсез кичерешләре—шул кульязмага нигез булган иде. Кульязма миңа бер дә ошамады. Автор үзе дә күңелгә җиңел генә кереп урнаша торганнардан түгел иде. Кырыс, төксе чырай, елмаюны күптән оныткан күзләр, җимерек кашлар... кульязмадагы фикерләр дә, ирен арасыннан кысылып чыккан кырыс сүзләр дә авторның йогышсыз язмышына баш бирә башлавын исбатлыйлар иде. Без салкын гына хушлаштык.*

*Яши-яши минем әдәбияттагы урыным ныгыды. Әсирлек һәм Сталин төрмәләрен узкән авторларга шәфкатьлерәк күз белән карарга тотындым. Байтак иптәшләрнең китаплары минем булышлыгым белән дөнья күрде. Әнәс Галиев минем янга тагын килеп чыкты, бу юлы ул «Намус кушканча» исемле повестен алып килгән иде. Укыдым да сөенеп куйдым: бу инде тоташ зарланулардан, файдасызга күз яше түгүләрдән торган беренче кульязма түгел иде! Тормыштагы ачы хакыйкатьне таныган, хак белән хаксызны җете күз белән аера алган талантлы замандашыбызның татар әдәбиятына алып килгән яңа сүзе иде бу. Үзе дә финансист, совет финанс системасын әтәм торып өйрәнгән Әнәс Галиев моңарчы без белмәгән, белә дә алмаган хакыйкатьне батырларча ачып салган иде. Бераздан бу әсәрә «Тугрылык сагында» кушылып китте, озакламый «Авылдашлар» романы басылып чыкты.*

*Әнәснең әсәрләрен укучы үз күреп, яратып кабул итте. Гадәттә яңа исемнәргә авыр күтәрелә торган тәнкыйтьче агайлар да, ниһаять, аның китапларына игътибар итә башладылар. Соңгы ун-унбиш ел эчендә Әнәс үзе дә тынмады, язмышына бик күп кыенлыклар өстәгән әсирлек елларына борылып*

*кайтуты һәм эмоциональ көчкә ия булган роман-повестьлар язып татар әдәбиятында батырлык эшләде. Ватан сугышының караңгы архивларына гына беркетелгән ачы дәреслеген татар укучысына җиткерде.*

*«Чигенгәндә...»—аның сиксәненче елларда язылган әсәре. Кызларының рөхсәте белән мин аны архивыннан алдым, гадәтемчә, редакцияләп, ул әйтеп бетермәгән кайбер фикерләрен ачыклап, журналга тәкъдим итәм.*

*Гомере буе нужа камытын салмаган, эштән бүтәнне белмәгән якын дустым үзенең 76 яшькә кадәр яши алуына чиксез гаҗәпләнгән иде... Ул 1996 нчы елның августында вафат булды. Язганнары күп булмаса да, аларның яшәргә тулы хокукы бар. Чөнки Әнәс Галиев «тугрылык сагында» торып, «намус кушканча» яшәгән чын татар, татарның да затлысы, чын кеше иде.*

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.**
*Зәй шәһәре.*

* * *

**... 1941** нче елга кердек. Көн туса, өзек-өзек хәбәрләр колакка килеп ирешә, ләкин без—авыл кабартмалары—хәбәрләрне җыеп, укмаштырып, акыллы бер нәтиҗә генә ясый алмаганбыз. Сугыш үзебезнең борын төбенә килеп җитә дигәндә дә без томана сарыклар идек әле. Мин хезмәт итә торган 268 нче КАПны (корпуснын артиллерия полкы) Краснодардан Кировоградка күчерделәр. Хәзер тарихчылар: сугыш башында безнең армия ярым-йорты гына коралланган иде, дип язалар. Безнең полк исә шул заманча бик яхшы коралландырылган иде. Яна гына модернизацияләнгән озын көпшәле, 122 мм лы, еракка ата торган гаубицаларны көчле тракторлар тарта. Ә сугышчылар бар да әрҗәләре махсус көйләнгән автомашиналарга утырып йөри. Пехотаның күзен кызыктырып!

Кировоградка полкны берничә эшелонга төяп алып килделәр. Яшьлек өчен һәр юл күңелле. Вагоннарда гармун тавышы яңгырый, күмәкләшеп җыр сузабыз, кысан булса да кемнәрдер тыпырдатып биеп тә җибәрә. Шәһәрдә туктатып та тормадылар, эшелоннарны вокзал артындагы аулак юлга кертеп бушаттылар да, кискен командалар биреп, каядыр алып киттеләр. 4-5 чакрым үткәч, куе агачлык эченә яшеренгән лагерьга алып барып туктаттылар.

Шулай итеп, без палаткаларда яши башладык. Кар эреп беткән булса да әле салкын иде. Кичләрен өсне чишенеп юрган астына кергәндә, яки иртән торып физзарядкага басканда тешкә-теш бәреләә.

Краснодардагы рәхәттән соң мондагы режимга күнегү кыен булды. Анда чакта еш кына шәһәргә чыгып, иркенләп йөри идек. Мин татар клубына бара идем. Әйе, әйе Краснодарда татар клубы бар иде. Ул үзәк урамда—Краснаяда, зур йортның беренче катына урнашкан иде.

Шәһәрдә татарлар шактый күп икән. Алар бар да дип әйтерлек Пенза ягыннан күчеп килгән мишәрләр. Күпчелеге, шәһәрнең сәүдә оешмаларында эшли. Шәһәрнең төрле почмакларында яшәгәнлектән, очрашу өчен буш вакытларында бергә җыелалар. Клуб кичләрен халык белән тулы була. Китапханәләренә Казаннан яна китапларны гел алдырып торалар икән. Драмтүгәрәк эшли. Бер мәртәбә «Галиябану»ның репетициясенә туры килдем. Үзешчән артистларның уеннарына бик яратып карап утырдым.

Яшь вакыт, яшь вакыт инде ул! Чибәр генә бер татар кызы белән танышып, мәхәббәт утында да яна башлаган идем әле...

Менә шундый иркенлектән соң монда, Кировоград янында, лагерьда ябылып яту бик авыр тоелды, әлбәттә. Өстәвенә занятиеләр бик каты. Еш кына төннәрен сугышчан тревога була. Ут капкан төсле кыланып, тәмле йокыдан уятып алып чыгып китәләр дә, уннарча чакрым жир йөгертеп, тәмам маэмай ясагач, кире лагерьга алып кайталар. Йөгерү генә булса бер хәл иде, бертуктаусыз окоп казыталар. Берсен казып өлгермисен, икенче жиргә куалар. Ә көндезләрен, гадәттәгечә, расписание буенча билгеләнгән өйрәнүләр була.

Мин топография взводында исәпләүче-санаучы булып хезмәт итә идем. Безнен исәпләүчеләр отделениесенә югары һәм урта белемле егетләр тупланган. Ә отделение командиры—өч класс белемле Зорин фамилияле сержант. Фамилиясе урысча булса да, ул үзе милләте буенча украинлы иде. Хохолларга хас нык акцент белән сөйләшә. Сверхсрочник, ягъни хезмәт срогын тутырганнан сон үзе теләп армиядә калган. Шулкадәр теләп хезмәт итә: анын өчен гүя солдат хезмәтеннән дә изге башка бер эш тә юктыр кебек! Хужалар алдында чәче белән жир себерергә әзер. Үз-үзен карап, бик чиста йөри, кирза итеге көзге кебек ялтыратылган, гимнастерка якасындагы ак бүз материяне көненә ике-өч мәртәбә алмаштырып тегә.

Артиллериядә исәпләүче-санаучы вазифасы ул вакытта ук инде ин кимендә урта белем таләп итә иде. Чөнки ут ача торган ноктаны батарея белән бәйләр өчен шактый катлаулы исәпләүләр ясарга кирәк була. Безнең сержант әзер формулалар белән эш йөртә. Ул аларны бик тырышып яттан бикләп алган, һәр сугышчыдан шуны таләп итә. Шул формулалардан башка ясалган исәпләүләрнең берсен дә санга сукмый. Аларны бүтән юллар белән дә исәпләү мөмкин булуын һич башына сыйдыра алмый иде.

Отделениедә Мороз фамилияле Ростов егете бар иде. Ул—белгечлеге буенча геодезист. Яна гына институт бетергән. Шуна күрәдерме, надан сержант белән бик санашасы килми, ана кимсетеп карый һәм күнегүләр вакытында батареяга ут ачарга кирәк булган ысулларны бөтенләй башка юллар белән исәпләп чыгара. Мона сержантның бик нык ачуы чыга һәм шушы нигездә алар гел әләгешергә әзер торалар иде.

Сержант мине дә бик үк өнәп бетермәде. Эш шунда, аз гына буш вакыт булдымы, мин шигырь язарга тотына идем. Анын нәрсә язуым турында бик беләсе килә. Ә мин, үз чиратымда, ана үземнең нәрсә белән шөгыльләнүемне белдерергә теләмим.

Краснодарда чагында ук бер поэма тәмамлап, Казанга—Язучылар союзына жибәргән идем. Озак көтәргә туры килмәде, Муса Жәлил имзасы белән жавап та килгән иде. Анда: «Поэмагыз ошады, альманах чыгарырга жыенабыз. Әсәрегезне шул альманахка тәкъдим итәргә уйлыйбыз. Ләкин исемен алмаштырырга туры килер, «Сайрый тургай» ничектер килешеп бетми», дип язылган иде. Поэманың шуннан сонгы язмышы мина билгесез. Кульязмасы үземдә калмады. Альманах чыккандырмы-юктырмы, бүгенгәчә кызыксынганым булмады. Поэма дигәнем кып-кызыл итеп язылган, дилбегәдәй озын бер шигырь иде. Вакыты шундый, нәрсә генә эшләсәк тә бөтенесен Сталин исеме белән бәйли идек. Танылган шагыйрьләр «ул исем—балаларның тел ачкычы» дип өзмәс тәкърарлаганда, безнең кебек малай-шалайга нишләргә кирәк иде сон?!

Бераз читкәрәк киттем бугай, укучым гафу ит инде! Хәер, алдарак та андый «тайпылышлар» булыр әле.

Тора-бара шигырь язу белән шөгыльләнүем өчен сержант Зорин мине бөтенләй үк эзәрлекли башлады. Беркөнне миндәр астыннан кульязмаларымны алган. Алар латин хәрефләре белән язылган иде. Чөнки кириллица нигезендә төзелгән алфавит безгә, татарларга, яна гына кереп килә иде әле. Безне мәктәптә латин графикасы нигезендә укыттылар. Шуна күрә күпчелек, шул исәптән мин дә, иске гадәт буенча үземә кирәкле язу-сызуны латин хәрефләре белән язуны дәвам итә идем.

Минем латин хәрефләре белән язылган кульязма сак һәм куркак сержант күңелендә шик тудырган. Ул мине ниндидер ярамаган эш белән шөгыльләнүдә гаепләргә чамалый башлады. Миңа үземнең нәрсә язуымны әйтүдән башка чара калмады. Моны тел белән генә әйтеп ышандырып булачак түгел иде. Миңа үземнең Казанда, дәүләт китап нәшриятында басылып чыккан шигырь җыентыгымны күрсәтергә туры килде. Бу вакытта минем ике шигырь җыентыгым бар иде. Дөресрәге, бер ярым җыентык. Беренче җыентык 1938 нче елда яңалиф белән басылып чыккан иде. Бу җыентыкның беренче яртысында Әгъзам Камал, икенче яртысында минем шигырьләр булды.

Ул елларны вакытлы матбугатта, «Совет әдәбияты» журналында минем шигырьләр еш диярлек күренә иде. Шулай ук Әгъзам Камал да шигырьләре белән матбугатта шактый актив катнашты. Ул тиз арада бер җыентык әзерләп нәшриятка илтеп биргән. Чүлмәкчедән күрмәкче, мин дә нәни генә бер җыентык илтеп тапшырдым. Ул вакытта редактор булып эшләгән Зәкия Садыйкова, ни өчендер, аны Әгъзам Камал җыентыгына кушып, бер китап итеп чыгарды. Җыентыкта Әгъзам Камалның «Җилфердә, байрак» дигән бер шигыре бар иде. Китапка да шул исемне куштылар.

Әгъзам Камал белән Казан финанс-экономика техникумында укыганда таныштык, соңра якын дуслар идек. Ул техникумны миннән ике ел алда бетерде. Аны кайсыдыр бер районның финанс бүлегенә эшкә билгеләсәләр дә, анда китмәде. Чын-чыннан шагыйрь булырга исәпләп Казанда калды. Шактый вакыт эшсез тинтерәп йөрде. Торырга урыны булмаганлыктан мин аны техникум тулай торагында үз янымда яшереп тоттым. Бер елга якын икәү бер түшәктә йокладык. Беркайчан да тормыш авырлыгыннан зарланмады. Читен вакытта: «чыда Камал, чыда, синең язмышың шундый—шагыйрьләр авылда туалар, шәһәрдә үләләр», дия торган иде Бальзак сүзләрен бераз үзгәртеп. Казанда Камалның житеш тормышта яшәгән туганнары да бар иде. Арада Альхан Камал атлы укымышлы, хәтерем алдамаса, заманында яхшы ук мәшһүр врач та бар иде бугай. Берсенә дә ярдәм сорап бармады. Йөри торгач «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә эшкә урнашты. Мин армиягә киткәндә шунда эшләп калган иде. Сугыштан кайткач, аның фронтта һәлак булганын ишеттем.

Минем икенче шигырь җыентыгым «Сөю» урыс графикасы нигезендә төзелгән яңа алфавит белән 1940 нчы елда чыкты.

Армиягә киткәндә мин бөтен әйберемне, китапларымны да үзем белән алып киттем. Хәер, олы итеп, әйбер дип әйтерлек нәрсә дә юк иде. Бар булганы бер-ике пар күлмәк-ыштан белән сөлге. Тагын кульязмалар, төрле вак-төяк китаплар—һәммәсен бергә җыйгач, тактадан эшләнгән кечкенә генә чемоданның яртысына сыеп бетә иде. Техникум бетергәнлегемне раслаучы кызыл катыргы аттестат та шушы чемоданда иде.

Мин Казанда бер ялгызым яши идем. Әти-әни авылда. Аларга үземнең армиягә алынуымны әйтеп тормадым. Акком асты урамындагы үзем яшәгән фатир хуҗасы белән исәп-хисапны өздем дә, чемоданымны күтәреп туп-туры военкоматка киттем. Бары да, ничектер, күршегә кереп чыгу кебек кенә итеп хәл ителде. Беркемгә дә мине озатып, мәшәкатьләнеп йөрергә туры килмәде.

Казаннан безне товар вагоннарына утыртып алып киттеләр. Бу минем үз гомеремдә беренче мәртәбә шундый ерак сәфәргә чыгуым иде әле. Шунадырмы, юлда бик ямансу булды. Өстәвенә, билгесезлек эчне пошырды. Кая, нинди частька баруыбызны әйтмәделәр. Поезд бик әкрен барды. Пенза, Балашов, Ростов шәһәрләрен узып Төньяк Кавказга килеп кердек. Ниһаять, Краснодарга килеп туктадык. Матур, бай шәһәр, барыннан да бигрәк андагы яшеллек безне таң калдырды. Бу вакытта 1940 нчы елның июнь азагы иде.

Мин яшем буенча армиягә 1939 нчы елның көзендә алынырга тиеш идем. Чираттагы чакырылыш вакытында мине калдырып тордылар. Никадәр ялынсам да алмадылар. Военком сөйләшергә дә теләмәде. «Мулла семьясында тугансың, андыйларның Кызыл Армиядә хезмәт итәргә хаклары юк!» дип кырт кисте. Мина ул вакытта бик авыр булган иде. Шуннан соң ярты елдан аз гына артыграк вакыт үтте. Әтиемнең кем булуын сорап та тормадылар, армиягә озаттылар. Соңыннан гына белдем, бу чакырылышта бары да дип әйтерлек минем кебекләр җыелган иде. Кайсы кулак малае, кайсының әтисен, яки берәр туганын халык дошманы итеп ясап, утыз җиденче елны төрмәгә утыртканнар. Ни сәбәпле безнең язмышлар үзгәрде, ул чакта боларын уйлап та тормаганбыз... Безнең арада танылып килә торган яшь рәссам Родионов та бар иде. Ул озак хезмәт итмәде. Ни өчендер, демобилизацияләнде. Бер-ике ай да узмады бугай, Казанга, өенә кайтып китте. Бу да ачылмаган сер булып калды.

Без хезмәт итәргә тиешле часть Краснодар шәһәрендә урнашкан иде. Ул, шәһәрдән бераз читтәрәк, әрмән зираты янындагы хәрби шәһәрчектә. Шәһәрчек территориясе чиста итеп җыештырылган. Бөтен җирдә тәртип. Юлларга ком сибелгән. Юл буйлап чәчәк түтәлләре тезелеп киткән.

Безне баракларга кертеп, һәркайсыбызга урын-җир, кызылармеец киеме бирделәр. Бараклагы ике катлы сәкеләр мина бик сәер булып күренде. Чөнки андый сәкеләрне беренче мәртәбә күрүем иде. Шул сәкеләрдән урын сайлап йөргән арада бөтенебезгә бер кисәтү булды: «Карагыз, киемнәрегезне яхшылап җыйнагыз, хезмәт срогын тутыргач алар кирәк булыр. Яна закон буенча, демобилизацияләнгәч, хәрби формалар кире алына һәм частьтә кала», диделәр. Бик киеренке еллар иде шул.

Һич көтмәгәндә, минем алда бөтен кискенлеге белән сержант Зорин каршында үземне аклау мәсьәләсе килеп басты. Шул исәп белән кызылармеецларның шәхси әйберләре саклана торган складка киттем. Башта склад начальнигы сөйләшергә дә теләмәде. Бик ялына торгач, ризалашты тагын. Шулай итеп мин китапларымны сержант Зоринга алып кайтып күрсәттем. Шуннан соң гына ул мина бәйләнүен ташлады, хәтта без аның белән дуслашып та киттек. Ул мине «шигырь язарга өйрәт» дип йөдәтә башлады. Мин аннан «урысча яза белмим» дип котыла идем.

Лагерьда занятиеләр көннән-көн кызып, кырык беренче елның апрель ае узганын сизми дә калдык. Беренче май көнне бөтен коралларыбыз белән Кировоградка, хәрби парадка алып чыктылар. Беренче мәртәбә шәһәрне шунда күрдек. Шәһәр артык зур түгел икән. Ярты өлеше калкулыкта, икенче яртысы инкү җиргә урнашкан. Бер юнәлештә генә йөри торган трамвае бар. Калкулыкка менә дә, аннан шул юл белән кире алып төшә. Революциягә кадәр шәһәрнең исеме Елизаветадармы, Елизаветаградмы булган—патша исеме. Сугыш алдындагы елларда бу шәһәрдә телгә алып сөйләрлек промышленность предприятиеләре дә юк кебек иде. Чәчү машиналары эшләп чыгара торган завод бар, исеме «Звезда» иде бугай. Без парадка чыгар алдыннан шул завод янында сафка тезелдек. Аннан безне шәһәр уртасындагы мәйданга алып киттеләр. Мәйдан ничек дип аталгандыр, исемдә калмаган. Без шул мәйдан аша строевой адым белән үттек. Трибунада күбрәк хәрбиләр иде. Иң зур чинлысы—полковник. Аны корпус командиры Малиновский диделәр. Имеш, ул монда Кировоградка күптән түгел генә килгән. Ана кадәр Мәскәүдәме, Ленинградтамы, кайсыдыр бер хәрби академиядә укыткан. Бу имеш-мимеш хәбәрләр дөрес булгандырмы-юкмы, анысын өзеп әйтә алмыйм. Шушы төптән юан чыккан, кара кучкыл йөзле, таза кешене мина тагын бер мәртәбә очратырга туры килде. Ул хакта бераз соңрак язып үтәрмен. Бөек Ватан сугышында дан казанган, булачак маршал Малиновский иде ул кеше.

Парадтан соң без туп-туры лагерьга кайттык һәм ул көнне тугарылып

ял иттек. Май бәйрәменнән соң занятиеләр тагын да катыланды. Шуңадырмы, көннәр бик авыр үтә, атна арасы бер ел кебек озак тоела иде.

Безгә аена ун сум акча түлиләр иде. Шул акчаны алган атна бик күңелле үтә иде. Мин үзем якшәмбе көн военторг кибетенә барып, шул ун сум акчаны бетереп кайтудан аеруча ямь таба идем.

Сүз уңаенда шуны әйтеп үтәргә кирәк, Бөек Октябрь революциясеннән соң озак вакыт, төгәлрәге, 1943 нче елга кадәр, безнең армиядә «солдат», «офицер» дигән сүзләр юкка чыгып торды. Погоннар да такмадылар. Хәрби хезмәткәрләр бер-берсенә «иптәш командир», «иптәш кызылармеец» дип мөрәҗәгать итәләр иде.

Ял көннәрендә иртән подъем булмый. Әмма өйрәнелгән гадәт буенча, шул подъем була торган вакытта уяныла. Яшь чагында йокыдан уянгач, юрган астыннан башны чыгарып, ялкаулыкны симертеп ятудан рәхәтрәк нәрсә бармы икән?

Подъем иртәнге сәгать биштә була торган иде. Мәскәү радиосы да тапшыруларны иртәнге сәгать биштә башлап җибәрә. Лагерьдагы бер репродуктор без яшәгән палатка янындагы агачка, безнең баш очына эленгән иде.

1941 нче елның 22 нче июне, якшәмбе көн. Мин иртәнге сәгать биштә, палатка янындагы репродуктордан «Коминтерн исемендәге радиостанция сөйли» дигән сүзләрне ишетеп йокыдан уянып киттем. Һәм ял көне булудан файдаланып, бик иркенләп соңгы хәбәрләр тынларга җыендым. Мине барыннан да элек Казан, Татарстан хәбәрләре кызыксындыра иде. Ул көннәрдә Казанда, Казанда гына түгел, бөтен Татарстанда Мәскәүдә уздырылачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлек алып барылды. Бу әзерлекнең барышы турында Мәскәү радиосы да бик еш хәбәр итеп тора иде. Мин ашкынып, бүген дә шул булачак декадага әзерлек турында берәр хәбәр булмасмы дип, радио тынларга тотындым. Тапшыруларның бик буталчык башлануы мине гаҗәпкә калдырды. Татар әдәбияты һәм сәнгате турында берәр хәбәр булгандырмы-юктырмы, анысын хәтерләмим, берничә минуттан кинәт тапшыруларны өзеп, көндезге сәгать уңдамы, уникедәме, төгәл әйтә алмыйм, тышкы эшләр халык комиссары Молотов радиодан чыгыш ясаячак дип әйттеләр. Аннан тагын соңгы хәбәрләргә күчтеләр. Алай да булмады, тоташтан аңлаешсыз музыка башланды.

Башка ял көннәрендә иртәнге ашка кадәр урыннан торасы килми ятыла торган иде. Әле ачык бернәрсә дә билгеле булмаса да, мин торып тиз-тиз киендем дә, палатка кырыена чыгып утырдым. Күрше палаткалардан да берәм-берәм чыга башладылар. Берәүнең дә күңеле тыныч түгел, барысы да нәрсәдәндер шикләнә. Хәтта, аяз күктән җиргә сибелгән иртәнге кояш нурлары да шомлы булып тоела, йөрәктә ниндидер билгесез курку хисе уяна.

Иртәнге аш вакытында сугышчан тревога булды. Безне, батареяда хезмәт итүчеләрне, стройга тезеп шәһәргә алып киттеләр. Без шәһәр хәрби комиссариаты янына килеп туктаганда, анда урам халык белән кырмыска оясы кебек мыжлап тора иде. Безне хәрби комиссариат ишеге алдына алып керделәр дә, һәркайсыбызның кулына бер кочак повестка тоттырдылар. Аларны кичкә кадәр таратып бетереп, корешокларын кире китерергә кирәк иде. Шулай итеп мин көннең көн буе повестка таратып йөрдем. Кая килеп кермә—җылау, сыкрау, күз яше ага, озату мәҗлесе. Ишек ачып бусаганы атларга өлгермисең, кулга рюмка китереп тоттыралар. Мин үземне чамалап сагайдым: кыстаганны кабул итеп аракы эчә башласам, бик тиз аяктан егылачак идем. Повесткаларны таратып бетерү турында әйтеп тә торасы юк. Җитмәсә винтовка да үзем белән. Әгәр исереп егылсам, ул чит кеше кулына эләгәчәк. Аннан ревтрибунал каршына басып җавап бирәсеңне көт тә тор!

Үзем повесткалар таратып йөрсәм дә мин һаман сугыш башланганын

ачык белеп бетерми идем әле. Бүтенгедәй хәтеремдә, Овчаренко фамилияле бер кешегә повестка тапшырырга кергәндә, анда җыелышып радиодан Молотов чыгышын тыңлыйлар иде. Мин аның соңгы сүзләрен генә ишетеп калдым. «Наше дело правое, враг будет разбит, победа будет за нами.»

Шушы сүзләр тәэсирендәдерме, бераз күнелем күтәрелде. Овчаренконың әнисе тәкъдим иткән бер рюмка аракыны йотып куеп, бик тәмле, өреле кайнар борщ ашадым. Югыйсә бик арыган идем, шуннан соң хәл кереп китте.

Повесткаларны мин кичкырын гына таратып бетердем. Корешокларны кайтарып, шәһәр хәрби комиссариатыннан чыкканда көн каранғыланып килә иде инде. Шәһәрдән үзебезнең полк урнашкан лагерьга бер үзем, ялгыз гына кайттым. Башкаларны да берәм-берәм кайтарып җибәргәннәр. Мина шактый араны урман аша узарга кирәк иде. Авыр уйлар төяп, ашыкмыйча гына алга атладым. Тирә-юньдә җан иясенең барлыгы сизелми иде. Шулай тыныч кына алга барганда ачыргаланып кычкырган тавыш ишетелде—хатын-кыз тавышы. Күп тә үтмәде, кычкырган хатын үзе дә күренде. Ул бөтен көченә мина таба йөгерә иде. Минем янга килеп тә җитте, егылды да. Аны ниндидер ирләр куып килә иделәр. Мин ирексездән инемә аскан винтовканы кулыма алдым. Затвор шалтыраганны ишетеп булса кирәк, кызны куып килүчеләр тиз генә агач арасына кереп юкка чыктылар. Кыз тынын да чыгармый җирдә ятуын дәвам итте. Торырга куштым, җавап бирмәде. Мин аны кулыннан тотып аягына бастырдым. Аның озын, сары чәчләре чуалып иңбашына төшкән. Зур күкрәге ачылып тора. Өстендә ак кофта белән кара юбка. Таза, озын гәүдәле булса да, йөзеннән балалык кыяфәте китеп бетмәгән. Авызыннан бер чакрымга аракы исе анкып тора. Ул кинәт бөтен гәүдәсе белән мина елышты.

—Нәрсә теләсәң, шуны эшлә—мин синеке!—диде.

Бер минутка аптырап калдым. Бу вакытта мин үз-үземә хуҗа түгел идем инде. Шулай да акылымны югалтмадым.

—Әйдәгез, мин сезне урманны чыкканчы озатып куям. Адресыгызны әйтегез, башка вакытта шәһәргә чыгарга туры килсә яныгызга керермен.

Ул мине тыңлап вакыт уздырмады, кулын селтәде дә, тиз генә шәһәргә таба элдерде.

Мин лагерьга кайтып кергәндә төн уртасы авышкан иде инде. Лагерь халык белән шыгрым. Мин шәһәрдә повесткалар таратып йөргән арада монда яңа кешеләр китереп тутырганнар. Безнең палатка янында да бер төркем халык җыелып тора. Аларга сержант Зорин хәрби киемнәр өләшә. Ул мина да өр-яңа күлмәк-ыштан, аяк чолгавы һәм кызылармеец формасы тоттырды.

—Хәзер үк чишенеп, киен!—диде.

Бераздан тагын шуны белдем: монда, лагерьда безнең 268 нче КАПның дүртенче дивизионы гына калган икән. Өч дивизион һәм полк штабы көндез үк моннан киткән. Дүртенче дивизионга запастан чакырылган кешеләрне өстәп яңа полк оештырганнар. Шулай итеп мин үземнең яңа, 374 нче КАПка күчүемне сизми дә калдым.

Бу полкта бөтенесе яңа иде. Туплар, аларны өстерәп йөрүче тракторлар, автомашиналар, барысы да яңа. Хәтта, безнең винтовкаларны да алмаштырдылар. Рус винтовкаларын җыеп, Беренче бөтендөнья сугышы вакытында трофей итеп алынган Австрия мылтыкларын өләштеләр. Шунысы кызык, хәзергә сезгә коралның әллә ни кирәге булмас дип ике кешегә бер мылтык бирделәр. Австрия мылтыклары бик авыр һәм бик җайсызлар иде. Шуңа күрә күпчелек сугышчы аны күтәреп йөрмәскә тырыша, теге яки бу сәбәп табып машина әрҗәсендә тота торган иде.

Безне, ягъни кадровикларны, запастан килгән кызылармеецлар белән аралаштырдылар. Мин полк штабына, штаб батареясенең топография взводына күчтем. Топовзвод командиры итеп запастан килгән инженер-

капитан Голумба тәгаенләнде. Ул югары белемле, яше кырыклар тирәсендәге җайлы гына яһүд иде. Бик чиста киенеп йөри. Кигәннәре төптән юан чыккан гәүдәсенә сыланып тора. Чәче дегет кебек кап-кара, чигәсенә сыек кына чал йөгергән.

Сержант Зорин белән безгә аерылырга туры килде. Ул теләгенә ирешә. Аны дивизионда калдырдылар һәм взвод командиры ярдәмчесе итеп күтәрделәр. Безгә отделение командиры итеп үзем белән бергә хезмәт иткән Иван Башкировны куйдылар. Ул бик күңелле егет иде. Җырларга ярата. Утесов репертуарындагы җырларны бик яратып җырлый. Ул үзе Үзбәкстанда, Кәттәкурганда туып үскән, үзбәкчә яхшы белә. Әгәр, кешедән яшерен сүзе булса, минем белән үзбәкчә сөйләшә торган иде.

Ниһаять, бер тәүлек дигәндә безнең полк фронтка китәргә әзер хәлгә килде. Полкны майор Макс Соломонович Киселев кабул итеп алды. Ул кадровый офицер иде. Гражданнар сугышында катнашкан, яше илле тирәсендә, сабыр холыклы, чәче ап-ак, сакал-мыек кырылган.

Нәрсәм белән ошаганмындыр, беренче көннән үк майор Кисилев мине үз итте. Картада, планшетта берәр эш башкарырга туры килсә гел миңа гына тапшыра торган иде.

Полкның комиссары Лысовой фамилияле иде. Исемен, атасының исемен хәтерләмим. Петлицасында ике шпал йөртә. Каяндыр, запастан килде бугай. Миңа аның белән бервакытта да аралашырга туры килмәде. Ул үзе белән машинасында бер хатын йөртә иде. Аның матурлыгына бар да сокланып бетә алмыйлар. Бер дә килешмәгән җире юк иде хатынның. Нәфис гәүдә, житен төсле сары озын чәч, зәп-зәңгәр күзләр. Гүзәллеген тел белән әйтеп бетерә торган түгел. Кайберәүләр аны кызы диде. Усал телләр сөяркәсе дип гайбәт тараттылар. Ахыры ничек булып беткәндер, алар соңгы көнгә кадәр бергә булдылар.

24 нче июньдә, таң белән, Кировоградка барып эшелонга төялдек. Эшелонга төялгән арада берничә мәртәбә һава тревогасы булды. Ләкин самолетлар Кировоград өстендә тукталып тормадылар, безнең котны алып каядыр арырак уздылар.

Каушадык, частьләр буталышып бетте, анда да, монда да буталчык командалар яңгырады. Без юлга кузгалганда төш вакыты узган иде инде. Поезд бик акрын барды. Һәрбер полустанка саен озак-озак тукталып торды. Без туктап торган арада узып киткән эшелоннарның исәбе-хисабы юк иде. Күрәсең, безнең тукталып тору шул эшелоннарны алга уздырып җибәрү өчен кирәк булган.

Шулай тыныч кына юлны дәвам иттек, вакыттан файдаланып мин бер шигырь дә язып ташладым. Ләкин, патриотик хисләр белән һаваланып язылган ул шигырьгә дөнья күрергә насыйп булмады. Мин аны Казанга «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә җибәргән идем, шунда юкка чыкты. Соңарып булса да редакциядән җавап килде. «Хәзер газета ике генә битле, шигырьләр урнаштыра алмыйбыз, официаль хәбәрләр генә басабыз» диелгән иде.

Кичкырын безнең поезд япан кырда туктап калды. Тирә-юньдә станция дә, авыллар да күренми иде. Ул арада бөтенебезгә дә вагоннардан төшәргә приказ булды. Колактан-колакка «дошман десант ташлаган» дигән шомлы хәбәр таралды. Җанны өшетеп кайдадыр, еракта мылтыктан аткан тавышлар ишетелде. Безне, бер төркем сугышчыларны, шул атыш тавышлары ишетелгән якка алып киттеләр. Башкалар эшелонны саклап калды.

Безнең отрядның башында полк командиры майор Киселев үзе бара иде. Ул безгә 268 нче КАП тан ук яхшы таныш кеше. Кадровый сугышчылар аның гражданнар сугышында катнашканын, тәҗрибәле командир икәнлеген яхшы беләләр иде.

Иген кырлары буйлап байтак буталып йөри торгач, бер калкулыкта ниндидер кешеләр күренде. Макс Соломонович аларны бинокльдән күзәтеп торды да, бөтенебезгә җиргә ятарга, аның рөхсәтеннән башка берни дә эшләмәскә кушты. Иң элек ул разведка оештырды. Разведкага үзе белән

ике сугышчы алып старшина Усик китте.

Разведчиклар китеп бераз вакыт үткәч, без күзәткән шикле кешеләр туп-туры безгә таба килә башладылар. Минем белән янәшә яткан Гуменюк фамилияле сугышчы кабыргама төртте: «Әзерлән, хәзер сугыш башлана», диде. Ләкин беребезгә дә мылтыктан атарга туры килмәде. Безгә каршы килүче кешеләр 268 нче КАП ныкы булып чыктылар. Алар да безнең кебек дошман десанты эзләп йөриләр икән. Старшина Усик әйләнгеч юллар белән алар янына барып чыккан һәм эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлатып биргән. Шулай итеп беренче «сугыш» уңышлы тәмамланды. Күңелемә: «Частьләр арасында элемтә юк микәнни?» дигән шик кереп калды.

Барыбыз да вагоннарга менеп урнашкач поезд куркып кына урыныннан кузгалды. Таң алдыннан Днестр елгасын кичеп Молдавиягә барып кердек.

Безне Румыния чигенә алып баралар икән. Ләкин чик буена ук барып житәргә туры килмәде. Бельцы дигән шәһәр янында эшелоннан бушаттылар. Монда бер погранотряд оборонада тора икән, без дә шуларга килеп кушылдык.

Без килер алдыннан гына шәһәрне немец самолетлары бомбага тотып киткән. Берничә урында янгын чыккан, йортлар дөрләп янып утырсалар да сүндерүчеләр күренми. Бер-ике йорт тирәсендә генә өс-башлары янып каралып беткән бала-чагалар жылашып, әнкәләрен йолыккалыйлар, тимер юл станциясе ярым жимерек, тәрәзәләрдә пыяла заты калмаган. Шәһәр читендәге азык-төлек складына да бомба эләккән. Анда шактый он калган булган, аларны жирле халыкка өләшәләр иде. Кайсы инбашына күтәреп, кайсы кечкенә арба белән капчык-капчык он ташый, талашалар, якалашалар.

Тирә-юньдәге вакыйгалардан әз-мәз хәбәрдар булу белән сугышчан позиция сайлап, ут сызыгына окоп казырга тотындык. Шәһәрнең уң як кырыенда, калку урында блиндаж корып, полк командирына күзәтү урыны эшләдек. Дивизионнарга, батареяларга элемтә үткәрелде. Тракторларны, машиналарны бакчаларга кертеп агачлар астына яшердек.

Шулвакыт немецлар еракка ата торган туплардан ут ачтылар. Снарядлар шактый еракта ярылсалар да бик куркыныч булып тоелды. Чөнки бу әле безнең беренче мәртәбә шундый көчле ут астында калуыбыз иде.

Сугышчылар яшен тизлегендә окопларга төшеп постылар. Полк командиры майор Кисилев та окопка төште. Ул мине стереотруба белән үзе янына утыртты. Минем икенче ягыма полкның разведка начальнигы өлкән лейтенант Кухарь утырды. Ул йомры гәүдәле, шомырт кара күзле, кара бөдрә чәчле, утыз яшьләр тирәсендәге бик тере яһүд егете иде.

Берничә залп бирделәр дә атуны кинәт туктаттылар. Бераздан безнең тирәдә миналар ярыла башлады. Кечкенә калибрлы миноменттан аталар иде. Миналар безнең окопка йә килеп житми, яисә узып китә.

—Засекли сволочи,—диде майор Киселев,—хәзер мина туп-туры безнең окопка килеп төшәчәк.

Ул шулай дип әйтеп кенә өлгерде, өлкән лейтенант Кухарь окоптан атылып чыкты һәм алга таба йөгерә башлады. Мина шартлаган тавышны ишетеп без окоп төбенә сыландык. Башыбызны күтәреп караганда окоптан 20-30 метр ераклыкта өлкән лейтенант Кухарьның гәүдәсеннән өзгәләнгән кисәкләр генә аунап ята иде инде. Без соңыннан гына аңладык: ул кызулык белән окоптан чыгып алга таба йөгергән, һәм мина аңа туп-туры эләккән икән.

Кичкә таба безнекеләргә дә жан керде. Бездән артта, шактый еракта урнашкан батареялар тәртипсез атарга тотынды. Снарядлар безнең баш түбәсеннән очып узалар һәм йөрәктә ашкыну катыш курку хисе уяталар.

Атыш бер сәгатькә якын дәвам итте.

Караңгы төшкәч ике яктан да атышулар туктап калды. Көньяктан

искән жил ямьсез, кара болытлар куып китерде. Һәм яңгыр ява башлады. Полк командиры янына дивизия штабыннан связной килде. Ул чигенергә приказ алып килгән иде. Уң якта немецлар безнең оборонаны өзгәннәр һәм без яртылаш чолганышта калганбыз икән. Дошманның мотомехчастьләре Одесса юнәлешендә, Днестр елгасы буенда һөҗүм алып баралар дигән хәбәрләр таралды. Без Бельцы шәһәрен ашык-пошык ташлап китәргә мәҗбүр булдык.

Шушы көннән, төннән дисән дөресрәк булыр, менә кадәр тиңе күрелмәгән авыр чигенүләр башланды. Авыл юллары буйлап көн-төн артка тәгәрәдек. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, өзмәс яңгырлар коя торды. Молдавиянең уңдырышлы кара туфрагы тәмам җебеде. Автомашиналар җиргә чумалар да кыймылдый да алмыйлар. Безгә аларны көнтөн, бертуктаусыз иңбашы белән этәргә туры килә иде. Болай гына булса бер хәл иде: бер минут тынгылык юк, әле самолетлар, әле танклар ут яңгыры яудыра.

Немец танклары туп-туры безгә каршы килә алмыйлар. Чөнки туплардан туры төзәп атып тетмәләрен тетәбез. Шуна күрә читләтеп үтеп, арт яктан һөҗүм итәләр һәм чып-чын мәхшәр башлана. Иң үзәккә үткәне—самолетлар. Аларга каршы торырга бер коралыбыз да юк иде. Соңга таба бер зенитный пулемет бирделәр, ул турыда бераз түбәндәрәк әйтеп үтәрмен әле.

Миңа гына шулай тоелгандырмы, безнең полк һәрвакыт ялгыз, үзе генә чигенде, тирәбездә башка частьләр барлыгы беленмми иде.

Без чигенгән юл буенда авыллар бик еш утырган иде. Һәр хуҗалыкның җиләк-җимеш бакчасы бар. Андагы чикләвек, груша агачлары шундый озыннар һәм куе яфраклы, астына юклы-барлы янгыр да үтми. Алар минем хәтердә шулай уелып калган. Һава һөҗүме вакытында без шул агачлар астына кереп кача торган идек.

Молдавиянең башка җирендә ничектер, белмим, әмма без чигенгән юл өстендәге авыллар бик зурлар иде. Төрек тәэсире булса кирәк, төзелешләре белән татар авылларына охшаганнар. Йортларның тәрәзәләре ишегалдына караган. Барысында да дип әйтерлек капка, койма корылган.

Кешеләр бик чиста киенеп йөриләр иде. Шунысы гаҗәпләндерде: олысы-кечесе—барысы да яланаяктан.

Молдавиянең СССР составына керүенә яңа гына бер ел тулып килә иде. Шуңадырмы, мондагы халык безне бик өнәп бетермәде. Үз күзем белән күрмәдем, әмма аерылып калган кызылармеецларга һөҗүм итәләр дип сөйлиләр иде.

Бер-ике атна узгандырмы, чигенә торгач Днестр буена да килеп җиттек. Днестр каты ага торган тар гына елга икән. Без килеп җиткән урында сул як яры бик биек гранит кыялардан тора иде. Бессарабия безгә кушылганчы, моннан илнең иске чиге узган. Шул иске чик сызыгындагы тимер-бетоннан коеп эшләнгән ДОТларны күргәч шатлыгыбыз эчкә сыймады. «Димәк, без башка бер адым да артка чигенәчәк түгелбез» дип уйладык. Гомумән, чигенүне без беребез дә башыбызга сыйдыра алмый идек. Чөнки, балачактан ук, әгәр дә мәгәр, сугыш була калса, дошманны үз җирендә тукмаячакбыз дип туктаусыз колакка тукып тордылар. Кызыл Армиянең дөньяда иң югары тәртипле, иң яхшы корал белән коралланган алдынгы армия булуына бөтенебез дә чын күнелдән ышана идек. Буденныйлар, Ворошиловлар бар ич бездә! Сталин бар! Аннан тагын шунысы: бөтен дөньяның эшче сыйныфы безнең яклы, алар безгә каршы атачак түгел дип тәрбияләндек. Ә чынбарлык башкача иде. Молдавия кадәр Молдавияне берничә көн эчендә калдырып чыгып, үзебезнең бер самолетны, бер танкны күрмәү сугышчыларны бөтенләй акылдан язарлык хәлгә җиткерә иде. Ике кешегә—бер мылтык!

Халык төрлечә юрап карый иде. Безнең самолетлар, танклар кайдадыр, ерак тылда, Себер ягында тупланган, шуннан килеп җитә алмыйлар булса кирәк дип уйлыйлар иде. Үзебезне, «менә алар озакламый

килеп житәрләр, менә шунда инде немецлар күрерләр күрмәгәннәрен», дип тынычландырырга тырыша идек. Ләкин безнең хыяллар хыял гына булып кала бирде, алар челпәрәмә килеп, бер-бер артлы юкка чыга иде.

Днестрны кичәргә өлгермәдек, безгә тагын чигенергә приказ булды. Башта Одесса янына күчерәләр икән дип сөйләделәр. Ләкин анда эләгә алмадык. Немецлар күптән инде безне читләтеп узган булганнар. Анда чигенергә юл калмаган иде инде.

Хәзер без Украина жирендә идек. Кызу урак өсте. Ашлык гажәп яхшы уңган иде ул елны. Кырларда тау-тау гәрәбә кебек бодай көшелләре тезелеп киткән. Урасы жирләр дә бик күп иде әле. Аларны ут төртеп яндыралар. Хәер, бер бодай кырларын гына түгел, бөтенесен яндыралар. Жирле халык тылга кача. Элеваторларны, тимер юл станцияләрен шартлаталар. Юллар качучылар белән тулган. Жигүле үгезләр, атлар, машиналар бар да бергә буталып, хәрәкәтне туктаталар. Гигант «бөкеләр» барлыкка килә. Немец самолетлары махсус шул «бөкеләр»не эзләп кенә йөриләр дә иде инде.

Бер яңгырлы көнне безгә кыска гына вакытка бер авылда тукталып торырга туры килде. Ул төзелеше белән мондагы авыллардан аерылып тора иде. Халкы китеп беткәнме, берәү дә күренми иде. Инеш буенда кызыл кирпечтән салынган бина бар иде. Мин буш вакыттан файдаланып, шул бинаны караштырып йөрергә тотындым. Бу бина мәктәп булып чыкты. Эче парталар белән тулы иде. Бер бүлмәдә бик күп китаплар өелеп тора. Мин шул бүлмәгә кердем. Һәм китапларны күргәч күземә ышанмадым. Анда яңалиф-латин хәрефләре белән басылган татарча уку китаплары өелгән! Актара торгач, шактый гына матур әдәбият китаплары да табылды. Мин Галимжан Ибраһимовның утызынчы елларның урталарында Таттосиздатта чыгарылган биш томлыгын табып алдым. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, утыз жиденче елда бу китапларны Татарстанда китапханәләрдән жыеп алдылар һәм аларны уку тыела иде. Мин бу биш томны үзем өчен зур табыш итеп санадым һәм капчыгымның төбенә үк салып куйдым.

Бик аптырап, китаплар актарып йөргәндә бүлмәгә шактый олы яшьтәге бер хатын килеп керде. Ул өстенә озын итәкле, киң күлмәк кигән, яулыгын алдан бәйләгән. Аның мондый кыяфәтен күргәч, татар хатыны булуында шигем калмады. Шулай да ничек сүз башларга кыймыйча бер-беребезгә күзләребезне текәп аптырап тордык. Ниһаять, мин татарчалатып: «Ничек монда килеп чыктыгыз?» дип сорадым. Минем сүзләремне ишеткәч ул жанланып китте һәм ягымлы тавыш белән:

—Әй, үзебезнең кеше икәнсез, ләбаса,—диде.—Малаема ияреп килгән идем, башым харап булды, кайта алмый калдым...

—Бу нинди китаплар?—дип сорадым мин аны бүлдереп.

—Мәктәп китаплары...

—Монда ничек килеп эләккән алар, татарча аңлаучы бармыни?

—Нишләп булмасын, татар авылы ла бу...

Монда, Украинада, татар авылы бардыр дип башыма да китермәгән идем. Хатынның сөйләвенә караганда, аларны егерменче елларның азагында монда, Киев өлкәсенә, Татарстанның Буа ягыннан күчереп китергәннәр. Халыкны болай туган-үскән иленнән аерып, күчереп йөртү нигә кирәк булгандыр, бу сорауга әлегә кадәр жавап таба алганым юк. Украинаның уңдырышлы жире кызыксындырганмы, әллә көчләп китергәннәрме, анысын әйтүе кыен. Ничек кенә булмасын, алар ата-бабаның гореф-гадәтен саклап татарча яшәгәннәр, мәктәптә укулар татар телендә алып барылган.

Бу татар авылында миңа башка беркем белән дә сөйләшергә туры килмәде. Авылга нинди тизлек белән килеп кергән булсак, шундый ук тизлек белән чыгып китәргә мәжбүр булдык. Гомумән, безгә бер жирдә дә озак тукталып торырга ирек бирмиләр иде. Кайсы көнне немецлар безне йөзәр километрга узып китәләр иде. Шуннан инде менә башлана:

дошман олы юл буйлап һөҗүм итә, ә без аның артыннан иген кырлары аша чигенәбез.

Бер көнне иртә белән, Николаев шәһәреннән ерак түгел, бик матур урынга урнашкан Лилиенталь дигән немец колониясенә килеп туктадык. Авылда беркем дә юк, халыкны каядыр Себер ягынамы, Казахстангамы күчергәннәр. Колония шактый зур булган. Мондагы йортлар украинлылар яши торган авыллардагы кебек балчыктан түгел, таштан, кирпечтән эшләнгәннәр. Бөтен җирдә пөхтәлек, тәртип күзгә бәрелеп тора.

Авылга кереп өлгермәдек, безне немец танклары чолгап алдылар. Генерал фельдмаршал фон Клейстның танк гаскәрләре һөҗүм итә дип сөйләделәр.

Бу авылда бездән башка тагын мин элегерәк хезмәт иткән 268 нче КАП һәм составында без булган корпус штабы да бар иде. Корпус командиры генерал-майор Малиновский да шушында иде. Мин аны күрү белән таныдым. Бу шул—Беренче Май бәйрәмендә, Кировоградта без катнашкан парадны кабул иткән хәрби иде, тик чины гына үзгәргән.

Сугыш хәрәкәтләре белән генерал үзе җитәкчелек итте. Безнең полкның батареяләрен Лилиентальнең көнчыгыш ягына, калкулык артына туплады, ә 268 нче КАП ныкыларны безнең полк штабыннан ерак түгел, көнбатыштан килә торган олы юл буена урнаштырды. Шунда мин үзем белән бергә кадровый хезмәткә алынган Татарстан егетләре—Гаптери, Әсәт һәм Могыйн атлы иптәшләрне күреп сөйләштем. Алар өчесе дә бер батареядә наводчик-төзәүче булып хезмәт итәләр иде. Мине күргәч якын туганнарын очраткан кебек булдылар.

Авыл кырыенда шактый калку урын бар иде. Шунда тиз генә тирән окоп казытып, күзәтү пункты оештырдылар. Миңа стереотруба белән шушы окопның нәкъ урта бер җирендә утырырга туры килде. Полк командиры, һәрвакыттагыча, мине үз янынннан беркая да җибәрмәде.

Ниһаять, олы юлда дошман танклары күренде. Алар коточкыч тавыш белән үкереп, туп-туры авылга таба юл тотты. 268 нче КАП батареяләре аларны шактый якын җибәреп, давыллы ут ачты. Бернәрсә белән исәпләшмәстән танклар һаман алга үрмәләделәр. Кайбер батареяләрдә танкларга туптан туры төзәп атарга мәҗбүр булды. Ераккка ата торган 122 миллиметрлы гаубицалардан туры төзәп ату ансат эш түгел иде, әлбәттә.

Дошманның һөҗүме минут саен кискенләште. Алар 268 нче КАПның батареяләрен танклар белән таптатып йөри башладылар, күп кенә тупларын юк итеп авыл урамына килеп керделәр. Шул вакыт 374 нче КАП батареяләре ут ачтылар. Авылдагы йортларга дөрләп ут капты. Йортлар белән бергә урамдагы танклар да шырпы тартмасы кебек дөрләп яна башлады. Бу дошман өчен көтелмәгән хәл булып чыкты шикелле. Мөгаен, алар безнең полк батареяләренең засадада торуын абайламый калды булса кирәк. Югыйсә, шундый күп техниканы бергә җыеп тозакка, ут астына китереп кертмәсләр иде.

Майор Киселев окопта утырып тора алмады, өскә күтәрелде. Аның янына снарядлар килеп төшә башлады. Танктан аткан бу бронебойный снарядларның кыйпылчыклары юк иде. Алар чыжлап җиргә кереп китәләр дә юкка чыгалар. Шулай да полк командирын ялгыз калдырырга ярамый иде. Чөнки снарядның туры килеп эләгүе бар. Без взвод командиры инженер-капитан Голумба белән аның янына чыгып бастык. Дөресен әйтим, үземнән «егетлегемә» үкенеп куйдым. Тез буыннарым калтырый башлады. Голумбаның да йөзе агарып китте. Майор Киселев әллә безнең курыкканны сизеп алды инде, окопка төшәргә боерды. Без аңа күзебезне текәп таш кебек катып калдык. Бары ул җиде катлап сүгенә башлагач кына аңыбызга килдек. Макс Соломонович окопка төште, аның артыннан без дә шунда сикердек. Ул окопка төшү белән дивизион командирлары белән элемтәгә керде һәм боерыкларын бирергә тотынды.

Безнең батареяләрнең уты көчәйгәннән-көчәйде. Исән калган танклар кире борылдылар. Соңыннан сөйләүләренә караганда, безгә каршы кырыкка якын танк һөҗүм иткән булган. Булса да булгандыр, авылда утырып калган танкларның исәбе-хисабы юк иде! Мина бу сугышта беренче мәртәбә туптан туры төзәп аткан снарядларның танкка эләгүен күрергә туры килде. Бу шундый күренеш, тел белән әйтеп аңлата торган түгел! Снаряд килеп эләгү белән танк коймакка әйләнә.

Кичкә таба бөтен дөнья тынып калды. Каты сугыштан соң урнашкан бу тынлык ничектер сәер булып тоела иде. Ул арада караңгы да төшеп өлгерде. Украин төне шундый караңгы, күзгә төртсәләр дә бернәрсә күренә торган түгел.

Безгә хәзер чигенергә юл ачык. Николаев шәһәренә чигенергә боерык булды. Полк командиры мине авыл башына регулировщик итеп куйды. Аның әйтүе буенча, чолганыштан иң элек үзенең штабы белән генерал Малиновский чыгып китәргә тиеш. Генерал артыннан 263 нче КАП кузгалачак. Аларның яртыдан артык туплары һәм сугышчылары шушы бәрелештә юк ителгәннәр. Иң ахырдан безнең полк юлга чыга. Колонна башында полк командиры майор Киселев үзе барачак. Бөтенесен озатып бетергәч, азактан полкның штаб начальнигы подполковник Тарасенко кузгалачак, имеш.

—Тарасенко сине үзе белән алыр, ул килеп житмичә баскан урыныңнан кузгалма!—дип боерды полк командиры.

Подполковник Тарасенко тәбәнәк буйлы, чепи күзле, кыяфәтсез бер бәндә иде. Күбесенчә исерек, шунадырмы, чөгендер кебек зур борыны һәрвакыт кып-кызыл була. Бик ачы телле, сөйләшкәндә һәр сүз арасына сүгенү ымлыкларын өстәп жибәрә.

Менә калдык-постык машиналар хәрәкәткә килделәр. Колонналар полк командиры әйткән тәртиптә уза башладылар. Иң элек үзенең утыздан артык машинасы белән генерал-майор Малиновский командалыгындагы корпус штабы чыгып китте. Яралы сугышчылар төялгән санитар машиналар да аларга ияргән иде. Алардан соң калганнар юлга чыкты. Майор Киселев белән бергә авыр тупларны өстерәгән тракторлар узгач, шактый вакыт юлда беркем дә күренмәде. Мин шикләнә башладым. Чөнки Тарасенкога ышаныч шулкадәр генә. Ә постны ташлап китәргә ярамый. Чөнки аны күрмичә китсәң, полк командирының приказы үтәлми кала.

Ниһаять, зарыгып көтә торган газик табышы ишетелде. Мин аны тавышыннан таныйм, ул безнең полк штабы урнашкан машина. Газик килеп житәрәк мин кулымдагы Австрия мылтыгын юлга аркылы суздым. Машина туктагач, шофер янында утырган подполковник Тарасенко кабина тәрәзәсендәге пыяланы түбән төшереп башын тышка чыгарды. Мин пулеметтан аткан кебек кызу-кызу сүз башладым:

—Иптәш подполковник, хужа сезгә мине, үзегез белән алырга боерды...

Тарасенко мине тыңлап бетермәде, авызны-борынны майлап сүгенде дә, ут капкан кебек китеп тә барды. Мин нишләргә белми аптырап калдым. Ачудан чәчем үрә торырлык булды. Үземнең нишләгәнемне белмичә, машина киткән якка мылтыктан ата башладым. Шулвакыт миннән берничә адымда гына немецчә сөйләшкән тавышлар ишетелде. Әйе, минем янга немец солдатлары килеп житкәннәр иде! Чиктән тыш караңгы булу аркасында гына без бер-беребезне күрмибез. Алар саклык белән юл буйлап атлыйлар һәм кемнедер үз яннарына чакыралар. Мин кинәт аңыма килдем һәм Тарасенко машинасы киткән юл белән бөтен көчемә йөгерергә тотындым. Шактый озак йөгердем мин. Авызым кибеп, телем аңкавыма ябышты. Шулкадәр арыдым, басып торырлык та хәлем калмады.

Мин йөгергән юл калкулыкка күтәрелә иде. Үрне менгәч бер тракторны куып життем. Ул безнең полк тракторы иде. Аның прицебына ягулык төяп йөртәләр.—Ул елларда хәзерге кебек махсус эшләнгән бензовозлар юк дәрәжәсендә иде.

Трактор ыңгырашкан тавышлар чыгарып акрын гына алга үрмәли. Прицебындагы зур, тимер мичкә ягулык белән тулы булса кирәк, шуңа күрә бик авырлык белән тарта. Мин күп уйлап тормадым, прицепка мендем дә, борт белән мичкә арасындагы бушлыкка сузылып яттым. Яту белән эреп йокыга да киткәнмен. Күпме ятуымны хәтерли алмадым, нидер шартлаган тавышка уянып киттем. Якында гына, трактордан уң якта миналар ярыла иде. Мин прицепның сул ягыннан сикереп төштем һәм бодай кыры буйлап кирегә йөгердем. Биш минут та үтмәгәндер, бер мина прицептагы мичкәгә эләкте һәм андагы бензинга дөрләп ут капты. Мин күзем белән тирә-юньнән трактористны эзләдем. Күренмәде. Миналар шартлый башлагач, тракторын туктатып, миннән элек төшеп йөгергән булса кирәк.

Трактордан шактый ерак киткәч, мин ниндидер басу юлына тап булдым. Шул юл белән бара торгач еракта иксез-чиксез зур су күренде. Мин аны диңгез дип уйлаган идем, ул Буг елгасы булып чыкты. Монда, диңгезгә койган җирендә Буг елгасы шундый киң икән. Николаев шәһәренә кадәр океанда йөрүче корабльләр керә.

Елга кырыена житәрәк жиләк-жимеш бакчалары башланды. Бакчада ниндидер кешеләр йөри иде. Миңа шик төште. Немецлар булса, нишләргә? Ни булса да булыр дип, алга баруымны дәвам иттем. Бакчада йөрүчеләр юлга чыгып уйланып тордылар да, миңа каршы килә башладылар. Мин аларны ут ачып каршы алырга жыендым. Бер түмгәк артына яттым да, мылтыгымны алар килгән якка төзәдем. Әлеге кешеләр үзләренә төзәлгән мылтыкны күреп булса кирәк, кулларын күтәрделәр. Мин бик гажәпкә калдым. Ничек инде унлап кеше бер кызылармеецка әсир төшсен. Бу кешеләр берәр хәйлә кормыйлар микән? Алар кулларын күтәргән килеш үк минем янга килеп життеләр. Карыйм, барысы да безнең кызылармеец формасы кигән кешеләр. Тик пилоткаларында йолдыз гына юк. Күрәсен, алып ташлаганнар. Алар шундый кызганыч кыяфәттә иде, ирексездән кычкырып көлә башладым.

—Нишләвегез бу? Сезгә нәрсә кирәк?—дип сорадым. Алар минем совет солдаты икәнлегемне аңлагач, төкеренделәр дә жиргә утырдылар.

Минем өстемдәге киемнәрем тиргә манчылып, череп бетте һәм киярлеге калмады. Аларны ташлап противогаз сумкасында артык йөк булып йөргән противоипритный костюмны киеп куйдым. Ул куе яшел төстә һәм читтән караганда немец солдатлары өстендәге киемгә бик охшаган иде. Аны ялангач тәнгә киеп йөрерлек тә түгел, ниндидер синтетик материалдан эшләнгән, кытыршы, энәләре белән чәнчеп бөтен тәнне авырттыра. Нишлисең, шәрә йөреп булмый бит, ахыр чиктә ул да ярап тора.

Әлеге сатлык жаннар шул противоипритный костюмның төсенә алданып, мине немец солдаты дип уйлаганнар һәм әсир төшеп ансат кына өйләренә кайтып китәргә жыенганнар булса кирәк.

—Жүләрләнмәгез, әйдәгез, киттек!—дидем мин аларга.

—Юлыңда бул, без үзебезнең авылга кайтып життек,—диде берсе усал гына. Минем алардан башка китәргә исәбем юклыкны күреп:

—Тикай, тикай,—диде икенчесе һәм карабин затворын шалтырата башлады. Миңа юлымны дәвам итүдән башка чара калмады.

Әйе, алар шушы тирәдәге авыллардан мобилизацияләнгән булганнар. Безнең полктан да Кировоград тирәсендәге авыллардан мобилизацияләнгән кешеләр берәм-берәм качып беттеләр.

Мин бакча буйлап бара торгач бер аланлыкка килеп чыктым да, бераз каранып торгач, исем китеп телсез калдым. Нәрсә генә юк иде бу аланлыкта. Пар ат белән тартып йөри торган кыска көпшәле, 152 миллиметрлы полковой туплар дисеңме, тартма-тартма граната, санап бетергесез винтовка һәм карабиннар, хәрби кием-салым, төрле ашамлык, жанын ни тели, барысы да бар! Тик кешеләр генә юк! Боларны кем, кайчан ташлап киткәндер. Һөжүм вакытында кырылып беткәннәрдер дип уйласаң,

бер генә үле сугышчы да күзгә чагылмый. Нишләп бу әйберләр монда аунап яталар? Мин һич тә төшенә алмадым. Хәер, ул турыда уйлап торырга вакытым да юк иде. Әйе, алар, алар... Алар немец танкларын күрү белән асларына җибәргәннәр һәм каршылык күрсәтергә сәләтсез булып калганнар. Үз чиратларында немецлар да бу ташлап калдырылган тупларны кулларына төшерергә өлгермәгәннәр.

Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә ди безнен халык. Бу әйберләр арасында мине иң кызыктырганы карабин иде. Ә Австрия мылтыгын нишләтергә? Бу файдасыз авыр йөкне күтәреп йөрергәме? Аның номеры минем кызылармеец кенәгәсенә язылган. Ул мылтык өчен шул вакыттагы тәртип буенча мин башым белән җавап бирәм. Мине бу Австрия мылтыгы шулкадәр туйдырган иде, бернәрсә белән дә исәпләшмичә, аны тирән бер окоп эченә ыргыттым да, карабин алдым.—Устав буенча артиллеристка карабин бирелергә тиеш.—Аппетит ашаган вакытта ачыла диләр, дөрес икән. Өстемдәге противоипритный костюмны салып, чиста ап-ак күлмәк-ыштан, комсоставка бирелә торган кара сукнодан тегелгән гәләфи, өр-яңа гимнастерка алып киdem. Аягымдагы төбе төшкән ботинкага күзем төшкәч көлеп җибәрдем. Юк, мондый кием кигәч тишек ботинкалар белән йөрергә ярамый!.. Мин тырышып аяк киеме эзли башладым. Актарына торгач бер пар хром итек табып алдым.

Минем тәүлектән артык авызга бер тәгам ризык капканым юк иде инде. Ашаудан да бигрәк үлеп эчәсе килә. Өелеп торган әрҗәләргә күзем төште. Аларга шампанское тутырылган иде. Иң элек бер шешә шампанскоены тын да алмыйча эчеп бетердем. Аның белән генә сусавым басылмагач, башкаларын тартып чыгардым.

Шампанское мине бөтенләй изрәтте. Бары бер банка дуңгыз итеннән эшләнгән тушонка ашагач кына бераз рәткә кердем.

Монда озаклап маташырга ярамый иде, кызу-кызу бакча буйлап алга атладым. Бераздан алда, елга аръягында шәһәр күренде. Димәк, елга аркылы чыгарга туры киләчәк. Монда Буг шундый киң, минем эчем жу итте. Чөнки елга кичү белән таныш идем инде мин. Немец самолетлары кичүдә күпергә кергәнне көтеп кенә торалар...

Кичүгә житәрәк бер танкетка күренде. Аннан ерак түгел машина кузовына беркетелгән зенит пулеметы тора. Алар икесе дә маскировка өчен зур-зур агач ботаклары белән капланганнар. Танкетка янында ике кулына ике маузер тотып бер полковник басып тора. Ул күп сөйләшеп вакыт әрәм итми, килгән бер сугышчыны оборона сызыгына яткыра. Каршы килсәң, атып үтерәчәк. Бөтен килеш-кыяфәте, сөйләшүе шуны сиздереп тора. Адашкан сарык бәрәнедәй аңгыраланган сугышчылар аңа берсүзсез буйсыналар. Мина да шундагы әзер окопка төшеп утырырга туры килде. Частьләреннән аерылып калучылар монда шактый җыелганнар иде инде. Сугышчылар берән-сәрән һаман килеп тора. Бер кырыйда эвакуацияләнгән еврейләр кичүгә керергә чират көтәләр. Күпчелеге хатын-кыз, бала-чага, карт-коры. Алар Молдавиядән үк киләләр. Без алар белән бер очрашабыз, бер аерылышабыз. Менә монда, Николаев янында тагын очраштык. Аларның бөтен мөлкәтләре үзләре белән. Баераклары ат җигеп, әйберләрен арбага төягәннәр. Ә ярлыныкы билгеле—мыжлаган балаларын арбага утыртып, үзе җигелгән. Барысы да юл мәшәкатьләреннән шундый йөдәгәннәр: юл газабы, гүр газабы дип белмичә генә әйтмиләр шул. Эвакуацияләнгән халыкның саны шактый иде. Кайсысы дөрестер, кайберәүләр аны утыз мең, кайберәүләре егерме мең кеше диделәр. Барысы да дүрт күз белән кичү бушаганны көтә. Беренче чиратта аннан чигенүче хәрбиләрне үткәрәләр иде.

Мин окопка кереп утырып хәл алырга өлгермәдем, күктәге кояшны каплап немец самолетлары килеп чыкты. Бүгенгедәй хәтеремдә, бөтенесе егерме җиде данә. Без аларны узып китәрләр дип уйлаган идек. Мондый табыш барында ташлап китәләрме соң? Николаев өстеннән кырт борылдылар да иләктән сипкән кебек бомба ыргытырга тотындылар.

Безнең аларга каршылык күрсәтергә бердән-бер зенитный пулеметтан башка коралыбыз да юк иде. Ул пулемет та бераздан эшләүдән туктады. Алар шундый түбән очалар, кулны сузсаң, кул тиярдәй булып тоелды. Кайберәүләр самолетларга мылтыктан атарга тотынды. Акырыш, кычкырыш. Баш очында йодрыклар уйный! Һәм шартлау!

Немец самолетлары бомбаларын ыргытып бетерделәр, ләкин китәргә исәпләре юк иде әле. Баш очыннан очып, коточкыч сызгыру белән мыскыл итеп йөрергә тотындылар. Баштагы көннәрдә, немец самолетларына махсус куелган сиреналарның улавы сугышчыларга бомба ярылганнан да ныграк тәэсир итә торган иде. Бераздан эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алгач моңа артык әһәмият бирми башладык. Шулай да дошманның бернинди җәзасыз, иркенләп йөрүләре бөтенебезнең дә чиктән тыш ачуын китерде.

Мин дә кызып киттем, тиз генә окоптан чыктым да, ни булса да булыр дип, зенит пулеметы урнашкан газик кузовына сикереп мендем. Андагы сугышчы пулеметка тотынган килеш сыгылып төшкән, чигәсеннән кан ага. Башына самолеттан аткан пуля эләккән булса кирәк. Мин аны әкрен генә бер кырыйга аудардым. Зенитный пулемет минем күргән дә, белгән дә нәрсәм түгел иде. Шулай да тотынып карарга булдым. Пулемет зарарланмаган икән, гашетка кул тиюгә тырылдый башлады. Минем күңел күтәрелеп китте. Баш түбәсеннән очып йөрүче мессерларга ут ачтым. Бала-чагалык! Минем белер-белмәс атуым көлке инде! Көчсезлегемнән иреннәремне тешләп канатып бетердем.

Алар үз эшләрен эшләп өлгергәннәр иде инде. Еврей-качаклары ачык җирдә, калкулык өстендә иделәр. Барысын да кырып бетергәннәр. Понтон күпергә дә бомба эләккән. Ярый инде аны ашык-пошык төзеп өлгерделәр. Мин шуларны күзәтеп торганда кичүгә, гаубицалар өстерәп берничә трактор килеп туктады. Карыйм, безнең полк командиры шунда буталып йөри. Мин зенит пулеметы урнашкан газиктан җиргә сикердем һәм майор Киселев янына барып бастым. Ул миңа гаубица өстенә менеп атланырга боерды. Минем гаубица өстенә менеп утырганны күреп булса кирәк, танкетка янындагы полковник килеп җитте. Ул Киселевка монда оборонада яткан кешеләрдән беркемне дә алмаска боерды. Алар кызып китеп тарткалаша башладылар. Акыралар, ата-аналарының кабер такталарын каһәрлиләр. Полковник кулында уйнаган маузерны күреп минем хуҗа да билендәге каешка тагылган коралга тотынды. Алар шулай тарткалашып торган арада мин менеп атланган гаубицаны тартып баручы трактор понтон күпергә кереп тә китте. Күпернең уртасына да житәргә өлгермәдек, тагын немец самолетлары әйләнеп килделәр.

Мең бәла белән исән-сау елганы кичтек. Ләкин бу якта безнең гаскәрләр күп иде әле. Немец самолетлары ашкынып-ашкынып бомба ташлауларын дәвам иттеләр. Елга кичү көне буена сузылды. Һәлак булучыларның исәбе-хисабы юк иде. Чөнки немецлар кичүгә артиллериядән дә ут ачтылар.

Елганы аркылы чыгу белән безнең гаубицаларны да эшкә куштылар. Алар тиз генә ут сызыгына урнашып, каршы якны көчле утка тотты. Бу атышу ярты төнгә кадәр дәвам итте...

Безнең полк штабы судоверфь янындагы агач йортка урнашкан иде. Без дә шунда җыйналдык.

Верфьта эшләнеп бетмәгән линкор корпусы тора иде. Ул шундый зур, дөрестерме-юктырмы, буе ярты чакрым имеш. Без аны бик гаҗәпләнеп читтән генә карап тордык. Янына барырга ярамый, миналар куелып, шартлатырга әзерләнгән, диделәр.

Безнең полк штабы урнашкан йорттан ерак түгел хәрби диңгез флотының складлары тезелеп киткән иде. Андагы кием-салымны кислота сибеп яндыралар, ашамлыкны халыкка өләшәләр. Безнең взвод командиры ярдәмчесе старшина Усик шундыйларны иснәнеп кенә йөри иде. Ул бөтенебезне җыйнап шул складларга алып кереп китте. Иң элек берничә

әрҗә шампанское күтәреп алып кайттык. Сержант Иван Башкиров үзенең отделениесе белән каяндыр, егерме литрлы шешәләргә тутырылган тройной одеколон ташыды, шулай итеп безнең машина кузовлары җыен юк-бар әйберләр белән тулды, үзебезгә утырырга урын да калмады, ләкин болар белән генә канәгатьләнмәдек, бөтенебез бергә җыйналып кием складына барып кердек. Тау-тау булып өелгән киемнең кислота өске катын гына яндырган иде. Без ул янган киемнәрне читкә алып ыргыттык та үзебезгә кирәкне сайлый башладык. Мин хром куртка, хром чалбар, хром пальто һәм бер пар хром итек сайлап алдым. Калганнар да үзләре күтәрә алган кадәр кием-салым алып кайттылар. Бераз алгарак китеп булса да әйтим, ул киемнәрнең барысын да Днепрның аргы ягына чигенгәч җыеп алдылар.

Бер заман мин моряк булырга хыялланып йөргән идем. Матрос формасын киеп үк йөрергә туры килмәсә дә, кулым белән тотып карарга насыйп булган икән.

Хәзер ачык хәтерләмим, кырыгынчы елның июль азаклары иде бугай, шунысын өзеп әйтә алам: армиягә алынганга бер ай чамасы гына узган иде, безне, бер төркем урта белемле сугышчыларны полк штабына чакырдылар. Анда бер өлкән баталионный комиссар чыгыш ясады. Башта халыкара хәл турында сөйләп алды. Аннан бөтенебезгә хәрби училищега укырга керергә тәкъдим ясады. Мин күп уйлап тормадым, Ленинград югары хәрби дингез инженерлар училищесына китәргә ризалык бирдем.

Бу вакытта безнең полк Краснодардан 60 километр ераклыкта, Саратовская станцасы янында лагерьда тора иде. Лагерь табигатьнең иң матур урынында, таулардан башланган Псикопцы елгасы буена урнашкан иде. Ничек кенә булмасын, мин лагерь тормышына ияләнә алмый идем. Алда нәрсә көткәне билгесез булуга карамастан, кая да булса китәргә ашкындым. Училищега китәргә ризалык бирүгә бәлки шушы ашкыну этәргеч булгандыр да...

Бер көнне миңа Хәмит Кавидан хат килде. Бик аптырап калдым. Чөнки Хәмит абый минем армиягә алынганны белергә тиеш түгел, мин киткәндә ул өйдә юк иде.

Хәмит Кави белән мин Казан финанс-экономика техникумында укыганда таныштым. Ул географиядән укыта иде. Студентлар аның дәресләрен түземсезлек белән көтеп алалар иде. Дәресне шундый кызыклы итеп үткәрә, ике сәгатьнең узганы сизелми дә кала иде. Һәр илнең халкы, тарихы, гореф-гадәтләре, культурасы турында үзе шунда булып кайткан төсле бик белеп, тәпле итеп, ышандырып сөйли иде.

Тиз арада без Хәмит абый белән дуслашып ук киттек. Мөгаен, минем матбугатта шигырьләрем күренү сәбәп булгандыр. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, бер вакытта да ул минем шигырьләрем турында фикерен белдермәде. Күрәсең, ул аларның чын шигырь булмавын яхшы аңлаган һәм минем күңелне төшерергә теләмәгән.

Безнең дуслык көннән-көн ныгыды. Ял көннәрендә мин аның Болак буендагы фатирына барып йөри башладым. Нәрсә белән генә шөгыльләнми иде ул! Өе тулы Советлар Союзының төрле почмагыннан алып кайткан минераллар. Бер елны Франц-Иосиф җиренә ясалган фәнни экспедициядә катнашып, чемодан тулы таш җыеп алып кайтты. Болардан тыш скульптура белән шөгыльләнә иде. Бүлмәсендә гипстан үзе койган К. Насыйри һәм Г. Тукай бюстлары тора. К. Насыйрига аеруча хөрмәте зур иде. Ул үзе дә Ачасырдамы, Шырдандамы туган—аз гына туганлыклары да бар иде бугай. Билгеле булганча, К. Насыйриның үзе исән чагында алынган фотосы юк. Мин әле ул вакытта бу турыда белми идем. Шуңа күрә К. Насыйриның бюстын кемгә охшатып, нинди чыганакка нигезләнеп коелган—кызыксынмадым. Бер нәрсә минем хәтердә бик нык сакланып калган: Хәмит абый да, рәссам Әлменев эшләгән портреттагы төсле, К. Насыйриның башына каракүл бүрек кигерткән иде.

Хәмит абыйның хатыны чыгышы белән Мари АССРның Бәрәңге авылыннан иде. Ул анда җәяүләп кайтып йөреде. Гомумән, ул җәйге

каникул вакытын юлда йөреп үткәрде. Кавказны, Татарстанны аркылыга-буйга җәяү йөреп чыккан.

Мин армиягә киткәч Бәрәңгегә кайтышлый Хәмит абый безнең авылда—Кушлавычта тукталган. Тукталуының сәбәбе шул булырга кирәк, Тукай туган нигезне күрергә теләгәндер.

Безнең йорт шул Тукай туган нигез белән янәшәдә—күршедә. Хәмит абый минем Кушлавыч кешесе икәнемне белә иде. Ул туп-туры безгә барып кергән. Әти белән гәпләре килешкән булса кирәк, бер кич куныпкиткән. Шунда аңа миннән килгән хатны укытканнар булса кирәк.

Хәмит абый минем хәрби училищега китәргә йөрүемне ошатмаган. Хатны уку белән җавап язган. Җавап хаты Кушлавычтан җибәрелгән иде. Ул миңа ашыкмаска киңәш иткән. Безнең халыкта «чит илнең солтаны булудан үз илеңнең олтаны булу артык» дигән мәкаль бар, минемчә, хезмәт срогың тулгач Казанга кайтуың яхшырак булыр дип язган иде. Мин бу киңәш белән берсүзсез килештем. Училищега алуларын сорап биргән гаризамны кире алдым.

Хәмит абый белән сугыш башланганчы хат алышып тордык. Мин сугыштан кайтканда ул дөньяда юк иде инде. Аның фронтта һәлак булуын ишетеп бик кайгырдым. Чын мәгънәсендә гыйлем иясе кеше иде. Әгәр исән булса бик күп файдалы эшләр башкарган булыр иде.

Хәмит Кави тагын берничә мәртәбә Кушлавычка кайтып киткән. Күрәсең, ул анда үзенә азык тапкан.

Кушлавыч зур авыл түгел. Сугыш алдыннан анда 155 йорт бар иде. Хәзерге көндә таралып бетеп бара, барысы 50 ләп хуҗалык калган, күпчелеге карт-коры, яшьләр исә туган төякләрен ташлап өзлексез китә торалар.

Авылның кыл уртасыннан тирән елга ага. Суы язгы ташу вакытында гына була, җәй көне кибә. Сугышка кадәр буа буып суны саклап кала торганнар иде. Буаның суы шактый тирән була торган иде. Җәй көне иртәдән кичкә кадәр шул буада су коена торган идек.

Кушлавыч халкы элек-электән иген игеп көн иткән. Телгә алырлык байлар булмаган. Авылда иң матур бина мәчет иде. Аны узган гасырда Казанда яшәүче ниндидер бер бай салдырган. Утызынчы еллар уртасында ул мәчетне сүттеләр.

Мәчет урамы Олы урам дип атала. Тагын Аргы як, Чүлмәк атавы, Тегәрҗеп дигән урамнар бар иде. Хәзер Тегәрҗеп урамы юк. Чүлмәк атавында да ике-өч кенә йорт калган.

Тегәрҗеп урамы артында зур таллык, шул таллар арасында салкын чишмәләр бар иде. Сугыш елларында талларны кисеп яккач чишмәләр дә юкка чыккан.

Минем әтием: Кушлавыч бик борынгы авыл, халкы Иван Грозный Казанны алгач, качып китеп утырган дип сөйли торган иде. Башта Иске Җәлби белән Яңа Җәлби исемле авыллар арасындагы инеш буенда Мичкә бите дигән урынга куыш казып яшәгәннәр. Базарга баргач, кайсы авылныкы дип сораучы кешегә куышлы авыл дип җавап биргәннәр. Шулай итеп Кушлавыч дигән исем килеп чыккан.

Бу тәгъбир күпмегә дөрестер, анысын әйтә алмыйм, чөнки профессор Г. Саттаров Кушлавыч дигән исемне башкача аңлата. Югары Сәрдә исемле авыл белән ике арада иске зират урыны бар. Ул елга буенда, калкулыкта. Шуннан иген кыры башланса да, ул урынны сукаламыйлар, бүлеп калдыралар. Хәтта анда хайван да кертмиләр. Ул җир изге урын булып исәпләнә. Төптән уйлап карасаң, бу халыкның ерак бабаларыбызны хөрмәт итүе, минемчә. Әгәр шушы иске зиратны казып карасалар, бәлки күп нәрсә ачыкланыр иде.

Хәзер Кушлавыч тирәсендә урманның эзе дә юк. Бабайлар килеп утырганда бу тирәләр калын урманнар белән капланган булган. Авыл тирәсендәге суы кипкән елга исемнәре шуны раслап тора. Үзләрендә хәзер бер генә агач үсмәсә дә, аларны Каенлы елга, Баланлы елга, хәтта

Үгез елгасы дип атап йөртәләр. Имеш, кайчандыр анда кыр үгезләре йөргән.

Безнең авылда имән бүрәнәләрдән салынган йорт бар иде. Аның кайчан салынганын беркем дә белми. Йортка дигән таза, юан имәннәрне безнең урманнан кискәннәр. Яртылаш җиргә сеңгән булуына карамастан, анда һаман Мөкәли Садыйгы дигән кеше гаиләсе белән яши иде әле. Садыйк абзый үлгәч, сугыштан соң бу йортны утынга сүтеп саттылар.

Кушлавычта мулладан башка укымышлы кешеләр булмаган. Мин ишетеп белгән муллаларның барысы да дип әйтерлек,дин башлыгы булу белән бергә хәлфә булып та хезмәт иткәннәр. Мәдрәсә безнең нигезнең түбән башында урнашкан иде. Заманына күрә шактый зур, алты почмаклы бу бинаны минем мулла бабайлар салдырган. Утызынчы еллар башына кадәр бу озын гомерле йорт мәктәп булып хезмәт итте.

Тукайның атасы Мөхәммәтгариф хәзрәт тә балалар укыткан. Ул үз заманында алдынгы фикерле, зур мәгълүматлы кеше булган. Шигырь язу белән дә шөгыльләнгән. Бу турыда минем әнием әтисеннән ишетеп, бик белеп сөйли иде. Аның әтисе, ягъни минем бабай Мөхәммәтгариф хәзрәт белән яхшы ук дус булганнар. Аларның дуслыгы мәдрәсәдә укыганда башланган. Минем бабай Хәбибулла мулла ярлы крестьян гаиләсендә туып, бик кыенлык белән мәдрәсә бетергән. Шуннан аны 50-60 йортлы фәкыйрь генә бер авылга Иске Җәлбигә указлы мулла итеп билгеләгәннәр. Иске Җәлби белән Кушлавыч арасы ярты чакрым да юк, аларны инеш суы гына аерып тора.

Хәбибулла мулланы мин күреп белмим, ул үлгәндә мин бик кечкенә булганмын. Аның йортындагы китапларның күплеге генә исемдә калган. Кулдан язылган калын-калын бу китапларның күбесе Мөхәммәтгариф хәзрәтнеке иде. Ул үлгәч аның йортында аларны сакларлык кеше калмаган. Үзе әйтеп калдыргандырмы, әнием анысын белми иде, китапларны дустына—Хәбибулла хәзрәткә тапшырганнар.

Гадәттә катыргы белән тышланган иске китапларның алдында һәм артында берничә чиста, язылмаган бите була торган иде. Мөхәммәтгариф хәзрәт шигырьләрен китапларның шул буш битләренә яза торган булган. Әнием «кышкы озын төннәрдә күрше кызлары белән бергә шул шигырьләрне җылый-җылый укый идек», дип сөйли торган иде.

Бабайдан калган китапларны егерме тугызынчы елның җәендә ике олауга төяп, бездән унике чакрым ераклыктагы Мулла Иле авылына—волостька алып киттеләр. Анда аларны мичкә якканнар.

Мөхәммәтгариф хәзрәтнең кабере Кушлавыч зиратында. Ул үзеннән соң мулла булып, мең тугыз йөзенче елны үлгән Габделхәер хәзрәт кабереннән ерак түгел канәфер агачы куаклары астында булырга тиеш.

Габделхәер мулла каберендә таш бар. Бу турыда минем кендек әбием, Чөкнә Гарифәсе бик белеп сөйли торган иде. Гарифә әби сиксәнне узып үлде.

Мин Габдулла Тукайдан башка Кушлавычта туган танылган кешеләрне белмим. Хәер, заманында атказанган артистка Оркыя Кушловская бар иде. Бу хатын ни өчен үзенә Кушлавычны псевдоним итеп алган, авылда бу турыда белүче юк...

* * *

Николаев шәһәрендә хәрби диңгез флотының складларыннан матрос киемнәрен алып чыккач, мин иреексездән Хәмит Кавины искә төшердем. Хәзер, ул вакыттан соң бик күп сулар аккач, аның турында яза башлагач, артык озынга китсә дә, туган авылымны искә алмыйча булдыра алмадым.

* * *

Без шулай складларны актарып йөргән вакытта немецлар шәһәргә артиллериядән каты ут ачтылар. Билгеле, безнекеләр җавап бирергә тотынды. Төне буе сугыш барды. Иртә белән кинәт тынлык урнашты. Безгә, штабтагыларга, каравылдан башка хезмәт калмады. Мин дә постка бастым. Минем янга йорт хуҗасы чыгып утырды. Ул шактый олы яшьтәге кеше иде. Маңгаенда тирән җыерчыклар, сакал-мыегы ап-ак. Аның бөтен гомере шушы верфьта эшләп үткән. Унөч яшеннән эшли башлаган. Ул үзе гомерендә Николаев җирендә дошман гаскәрләрен икенче мәртәбә күрә иде инде. Октябрь революциясеннән соң булган француз интервенциясе вакытында аларга каршы яшерен эш алып барган. Сизәм, немецнең монда килеп житүенә жаны-тәне белән әрни. Ләкин бу хәлнең вакытлы гына булуына һич кенә дә шикләнми иде. Без аның белән озак сөйләшеп утырдык. Карт, немецләрнең кинәт һөҗүмне туктатуларына сәерсенеп:

—Бу юкка түгел, нинди булса да этлек эшләргә җыеналар!—диде. Ул ялгышмады. Немец гаскәрләре безне чолганышта калдырып күптән узып киткән булганнар икән инде. Алар һөҗүмне Днепрның теге ягында җәелдереп җибәргәннәр. Безгә Николаевны ташлап китүдән башка чара калмады. Иртән юлга кузгалдык.

Юллар, юллар... Гражданнар сугышы тарихы буенча таныш юллар башланды. Херсон яныннан узып киттек. Сиваш тирәсендә әйләнеп йөрдек. Гомумән, без ерак немец тылында калганбыз. Йөри торгач Аскания Нова дигән җиргә килеп чыктык. Кызык урыннары бар да инде табигатьнең! Минем мондый җирне күрү түгел, ишеткәнем дә юк иде. Тәвә кошлары, кыр атлары, тагын әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән җанварлар очратып шаклар каттым! Монда тыюлык икән. Ул вакытта мин әле тыюлыкның нәрсә икәнен дә белми идем. Бу җирдә хайваннар гына түгел, үсемлекләр дә башка иде. Әйтерсең, Африканың бер почмагын кисеп алып шушында китереп куйганнар!

Монда бераз тукталып торырга туры килде. Каядыр, якында гына немец танклары һөҗүм итә дигән хәбәр алынды. Бөтенебезгә дә яндыргыч тутырылган шешәләр, танкка каршы ата торган гранаталар тоттырдылар. Шулай коралланып, немец танклары һөҗүмгә килергә тиеш дип уйланган юл буенда оборона тота башладык. Көн бик эссе иде. Кояш баш миен пешерә. Минем бик эчәсем килде. Шампанское эчәргә уйлап машиналар янына киттем. Алар санаулы гына калып бара иде инде. Бер башланган шешә бар иде. Мин яңаны башламаска, шуны гына алып эчәргә булдым. Шешәне алып андагы сыекчаны авызыма тидерүем булды, алгы тешләрем камыр кебек йомшардылар. Авыздагы сыекчаны тиз генә җиргә төкердем. Ул арада ике иренем ут кебек янып бөртеп тә чыкты. Төкергәндә сыекчаның бер өлеше өстемдәге гимнастеркага эләккән булган һәм аның алдын яндырып алды. Ярый әле вакытында сизеп өлгергәнмен, авыздагы сыекчаның тамчысын гына йоткан булсам да мәгънәсезгә дөнья белән саубуллашырга туры килер иде.

Шешәгә аккумуляторга салу өчен кирәкле кислота тутырылган булган. Аны Лысенко фамилияле полк командирын йөртүче шофер тутырган. Шушы вакыйгадан соң күп тә үтмәде, Лысенко качты. Машинасына утырып качты. Сөйләүләренә караганда, туган авылына кайтып киткән. Ә ул авыл немецлар кулында иде инде.

Немец танклары безгә һөҗүм итмәде, икенче юнәлешкә китте. Без иген кыры буйлап йөри торгач Каховка янына барып чыктык. Минем уйлавымча без моннан бер адым да чигенергә тиеш түгел идек. Каховка кадәр Каховканы ташлап китәргәме? Юк, бусы була торган хәлме соң?! Ул безнең күнелдә, утызынчы еллардагы совет мәктәбендә тәрбияләнгән яшьләр күңелендә, җиңү символы булып урнашкан исем.

Каховка тирәсендә дошман гаскәре юк иде әле. Тыныч кына Днепрны кичтек. Озак барырга туры килмәде, Токмак дигән шәһәрчеккә

житәрәк шуны белдек: бездән өстәрәк немец гаскәрләре Днепрны күптән кичкән булган. Запорожье, Днепропетровский тирәләрендә каты сугышлар бара икән. Без ашыгыч рәвештә Запорожьега юнәлдек. Шәһәр тирәсендә танкка каршы тирән-тирән окоплар казылган иде. Безнең батареяләр шул әзер окопларга урнаштылар. Немецлар Днепр уртасындагы Хортица утравына бәреп керергә маташалар. Мин хезмәт иткән 268 нче КАП алар белән тигезсез авыр сугыш алып бара. Дошман көне буе бер туктаусыз һавадан һөҗүм итә. Килеп урнашырга өлгермәдек, безне дә һавадан бомбага тоттылар. Сугыш башланганнан бирле үзебезнең самолетларны күргәнебез юк иде. Беренче мәртәбә Запорожье күгендә күрдек. Ләкин шатлыгыбыз озакка бармады, безнең күз алдында бер истрибительне бәреп төшерделәр, калганнары качып котылды.

Сугыш көннән көн кызды. Безнекеләр Хортицаны калдырдылар. Шәһәр әле һаман безнең кулда иде. Никадәр тырышса да дошман безнең оборонаны өзә алмый иде. Артиллеристлар бер нәрсә белән дә исәпләшмичә сугышалар иде. Безнең полкның Харченко фамилияле сугышчысы үзе йөрткән ЧТЗ тракторы белән немец танкасын таранить итте. Танк стройдан чыкты, ә Харченко исән калды. Без барыбыз да бер нәрсәне яхшы сизеп алдык, безнең батареяләр урнашкан ут сызыгына немец танклары якын да килә алмый иделәр. Алар гел безне тылда калдырып, йә уң яктан, йә сул яктан узып китәләр иде. Запорожьедә дә шулай эшләделәр. Без өч йөз километр эчтә калдык, ә алар Дон елгасы буена барып чыктылар.

Запорожьедагы заводлар эвакуацияләнгән иде инде. Домналар шартлатылган. Шунысы гаҗәп: әллә инде алып китәргә өлгермәгәннәр, дәүләт банкысындагы сейфлар, төрле кыйммәтле кәгазьләр, акча белән тулы иде. Ул вакытта мин нәрсә уйлаганмындыр, хәзер хәтерләмим, банктагы ишекләре каерып ташланган сейфлардан бер тиен дә акча алмадым. Теләсәм, күтәрә алган кадәр алып чыгарга була иде. Үз гомеремдә бер мәртәбә дә акчага кызыкмадым. Бәлки ахмаклыктыр, анысын укучым үзе хәл итәр. Күзләре тонган кемнәрдер тыз-быз чабалар, куеннарына, кесәләренә пачка-пачка акча тутыралар иде.

Ниһаять, Запорожьены калдырырга приказ булды. Әллә приказ да көтмичә чигенә башладыкмы? Төнлә кузгалдык. Шәһәрдән чыгып китүе бик кыен булды. Үзебезнекеләр төзегән танкларга каршы корылмалар, урамны иңләп казылган тирән окоплар киртә булдылар.

Шәһәрдән чыгып өлгермәдек, немец самолетлары һөҗүм итте. Олы юллар бар да дошман кулында иде. Анда бертуктаусыз аларның машиналары агыла. Без шулар белән янәшә бодай басуларын изеп-таптап хәрәкәт иттек. Миңа, авыл баласына, бу хәлләрне күрү ифрат читен иде. Немец самолетларының һөҗүме генә җитмәгән, бер көнне үзебезнең штурмовиклар бомбага тоттылар. Дошман гаскәрләре дип уйладылар күрәсең. Еракта, немец тылында йөрүче шактыйга сузылган колоннаны башкача ничек күз алдына китерәсең!

Безнекеләр берничә җирдә кызыл флаг күтәрделәр. Шуннан соң гына эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап штурмовиклар коерыкларын күрсәттеләр. Аларның һөҗүменнән соң үлүчеләр, яралаучылар шактый булды.

Запорожье өлкәсенең бер булган бу җирендә иксез-чиксез иген кырлары бер-берсенә ялганып киткәннәр иде. Ә урманнар юк дәрәҗәсендә булып истә калган. Һәр адымыбыз уч төбендәге кебек немецларга күренеп тора. Шуңа күрә көндезләрен берәр авылда туктап торырга тырыша идек. Ә инде аннан соң төне буе сыпыртабыз, юлда булабыз. Новомосковский исемле зур авылда безгә шактый озак тукталып торырга туры килде. Авылга иртә таң белән килеп кердек. Анда ниндидер немец частьләре тора иде. Авылдан аларны бәреп чыгарыр өчен шактый көч түктек. Никадәр тырышсалар да дошман безнең артиллерия утына түзә алмады, авылны ташлап китәргә мәҗбүр булды. Ләкин алар китеп озак

тормадылар, өстәмә көчләр туплап, кире килеп безне камап алдылар. Камалышта калу безгә бик кыйммәткә төште. Көне буе барган тигезсез көрәштә полк тупларының яртыдан артыгы стройдан чыкты. Үлүче һәм яраланучылар сансыз-исәпсез булды. Ниһаять, без дошман боҗрасын өздек. Октябрь урталарында Донбасста, Алмазный станциясе янында фронт аша узып, үзебезнекеләргә килеп кушылдык. Бу вакытта безнең полкта бары өч гаубица калган иде. Сугышчылар чиктән тыш йончылган, яңадан сафка басар өчен ял кирәк иде. Шулай эшләделәр дә. Безне Ворошиловградтан унсигез километр ераклыктагы Луганский станицасына ялга чыгардылар. Минем язмышым үтә сәер бер якка кереп китте, шактый вакыт полктан аерылып торырга туры килде.

Бер көнне шулай полк штабына чакырдылар. Анда сержант Башкиров һәм тагын ике сугышчы—Макусинский һәм Костенко нидер көтеп утыралар иде. Безнең бөтенебезне бергә полк командиры майор Киселев янына алып керделәр. Киселев янында 12 нче армиянең разведка начальнигы майор Еремеев һәм бөдрә чәчле көяз полковник та бар иде. Без барында тагын бер яһүд майоры килеп керде. Алар безне күздән кичереп нидер серләштеләр дә ияк кагышып бер нәтиҗәгә килделәр. Безне командировкага җибәрәләр икән. Һәркайсыбызның кулына майор Еремеев кул куйган документ тоттырдылар. Шактый ерак юлга чыгарга кирәк иде. Юл Ростов, Краснодар шәһәрләре аркылы Орджоникидзега кадәр сузыла. Безнең командирыбыз итеп сержант Башкиров тәгаенләнгән. Аның кулындагы документка «... аерым әһәмиятле задание белән җибәрелә, урындагы партия һәм совет оешмаларыннан ярдәм итүләре сорала»,— дип язылган иде. Безне Костенко үзе йөрткән полуторкага утыртып алып барачак. Машинаның кузовы каплаулы иде. Аңа бик күп чемоданнар, бүктәрләр төягәннәр. Сержант Башкиров шофер янына утырды. Без Макусинский белән ничек кирәк алай, кузовка, чемоданнар янына кереп сыендык. Бүгенгедәй хәтеремдә, 2 нче ноябрь көнне юлга чыктык. Көн шактый салкын, җиргә кырпак төшкән иде. Без Макусинский белән арканы аркага терәшеп утырдык. Ул миннән шактый олы, чигәләренә чал кергән. Бөтен кеше белән, кем булуына карамастан, фәкать украинча гына сөйләшә. Сүз арасында бик еш «бесовая душа» дип әйтеп куя.

Безнең беренче тукталыш Ростовта булырга тиеш иде. Анда помполтехның хатынын күреп, ире биргән әйберләрне тапшырырга кирәк иде. Ләкин нәкъ без шул юлга чыгарга әзерләнеп йөргән көннәрдә Ростовны немецләр алган булганнар. Кичкә кырын без нindидер станицада туктадык һәм шунда төн үткәрергә булдык. Станица безнең гаскәрләр белән шыгырым тулы иде. Сугышчылар бары да дип әйтерлек кавказлылар. Русча бик начар беләләр. Араларында бер Баку татары бар иде. Фамилиясе—Мөхетдинов. Өч телдә дә: татарча, русча, әзәрбәйҗанча—нәкъ туган телендә сөйләшкән кебек сөйләшә. аның сөйләвенә караганда аларны монда Ираннан китергәннәр. Өс-башлары чиста гына. Тагын шунысы ят тоелды, башларында безнеке кебек пилотка түгел, эшләпә кигәннәр. Мин соңыннан гына белдем, эссе якта хезмәт итүчеләр шулай эшләпә киеп йөриләр икән.

Станицадагы йортлар шушы Ираннан килгән солдатлар белән тулы иде. Шуңа күрә без фатир эзләп маташмадык, ташландык бер бакчада төн үткәрергә булдык.

Сержант Башкиров безне шушы бакчада калдырып каядыр китеп барды. Ул озак йөрмәде, бик күп ризыклар күтәреп әйләнеп тә кайтты. Аңа, безгә таныш булмаган старшина да ияргән иде.

Юлга чыкканда безгә төрле-төрле консервлар биргәннәр иде. Шунадырмы, Макусинский Башкировның азык-төлек алып кайтуын ошатмады.

—Боларын да ашап бетерә торган түгел,—диде, машинадагы әрҗәләргә күрсәтеп.—Нәрсәгә аларны күтәреп йөрисең?

—Алары кара көнгә калсын, хәзергә литерларны бетерергә кирәк,—

диде сержант, һәм серле итеп өстәп куйды:—Юлыбыз ерак, алда әллә ниләр булыр әле!

Эш шунда, ана полкның начпроды бик күп талоннар биреп чыгарган. Ул талоннар белән юлда очраган һәрбер армия складыннан теләгән ашамлыкны алырга була икән. Башкиров үзе күтәреп кайткан ашамлыкларны шул талоннарга алган. Бернечә шешә аракы да бар иде. Ияреп килгән старшина якташы булып чыкты. Ул аны сыйларга алып кайткан. Без бер агач төбенә плащ-палаткалар корып кечкенә генә куыш әзерләдек. Шунда кереп утырдык та бик иркенләп үзебезне үзебез сыйларга тотындык. Сыйлана торгач яхшы ук булып житкәнбез. Мин шунда утырган урында йокыга да китеп барганмын. Макусинскийның «бесовая душа, житәр сиңа, әйдә тор!» дип, кабыргама төртә-төртә уятуына уянып киткәндә көн яктырып килә иде инде. Мин уянганда алар өчесе дә аяк өстендә иделәр. Костенко машинага бензин салып йөри. Башкиров тунган булса кирәк, бик тырышып физзарядка ясап маташкан була. Бераздан Костенко моторны кабызды.

—Ни булса да булыр, Ростовка барабыз,—диде сержант. Алда тагын күз күрер.

Ростов тирәсендә гаскәр мыжлап тора иде. Җәяүле, атлы сугышчылар каядыр юл тота. Красный Аксайга житәрәк «безнекеләр Ростовтан немецны бәреп чыгарганнар икән» дигән хәбәрне ишетеп бик шатландык. Безгә Краснодарга барыр өчен Дон елгасын кичәргә кирәк иде. Аны бары Ростов янында гына кичеп була иде.

Красный Аксай төбәгеннән Ростовка кин асфальт юл алып бара. Без шушы юлда коточкыч күренешкә тап булдык. Монда үлекләрне жыярга өлгермәгәннәр иде әле, бары юлны гына ачканнар. Аксай белән Ростов арасы егерме километрга якын икән. Менә шушы ике арадагы юлда, ике яклап та гәүдәләр өелгән иде. Башта без немецларның кирәген биргәннәр дип уйлаган идек. Күзебезгә ышанмадык, үлекләр арасында немец солдатлары берән-сәрән генә күренәләр иде. Юлның ике ягына өеп куелган үлекләр барысы да дип әйтерлек кызылармеецлар иде. Иң элек бу хикмәткә Макусинский игътибар итте.

—Бесовая душа—диде ул ахылдап,—це ведь усю наше хлопцы. Мехлис халыкны менә кая китереп тыккан. Чебен күк кырылганнар!

Ростов үлекләрдән чистартылган иде инде. Монда да сугыш каты булган. Еш кына снаряд эләгеп яртылаш жимерелгән йортлар очрый башлады. Без шәһәрнен үзәге Энгельс урамында туктап юл сораштык, узган-барган кешеләр белән бераз сөйләшеп тордык.

Немец монда бер-ике генә көн булган да үзенең эзен калдырырга өлгергән иде инде. Сөйләүләренә караганда, «крытый рынок» үлекләр белән тулы иде. Анда шәһәрдән китәргә өлгермәгән коммунистларны, еврейларны семьялары белән бергә жыеп үтергәннәр.

Без Батайский шәһәренә алып чыга торган күпергә юл тоттык. Аны жимертергә өлгермәгәннәр иде әле. Шул күпердән Дон елгасын кичеп, төньяк Кавказга барып кердек. Патрульләр еш кына туктатсалар да Башкиров кулындагы кәгазьләрне укып, артык төпченмәделәр, кузовтагы чемодан-бүктәрләрне актаручы булмады. «Махсус задание үтибез!— диде Башкиров һаваланып.

Ростовтан икейөз километр узгач, кичкырын Павловка дигән зур станицага килеп туктадык. Станица үзенең таш йортлары белән шәһәрне хәтерләтә. Үзәк урамнарга асфальт жәелгән. Сержант машинаны зур бакча эчендәге ике катлы таш йорт янына китереп туктатты. Бу йортта станица советы һәм колхоз идарәсе урнашкан иде. Костенконы машина янында калдырып без өчәү эчкә кердек. Анда каравылчы хатыннан башка беркем дә юк иде. Ул тиз генә барып станица советы рәисен алып килде. Рәис көрәк сакаллы, таза гәүдәле бер казак иде. Ул бик озаклап Башкиров кулындагы таныклык белән танышты. Шул арада бакча янында торган ят машинаны күреп булса кирәк халык жыйнала башлады. Барысы

да дип әйтерлек хатын-кызлар. Алар бездән фронт хәлләрен сорашырга тотындылар. Нинди генә сораулар бирмиләр иде. Кызыл Армиянең туктаусыз чигенүен башларына сыйдыра алмыйлар. Барысы да чын күңелдән әрнеп, чигенүнең сәбәпләрен ачыкларга телиләр. Ләкин беребезнең дә андый сорауларга җавап бирерлек төпле мәгълүматы юк иде.

Кыен хәлдән станица советы рәисе коткарды. Ул безне халыктан аерып, күршедәге йортка алып керде.

—Анфиса, кунакларны кабул итеп ал!—диде ул, ишек алдында нәрсәдер эшләп маташкан хатынга. Анфиса безнең һәркайсыбызны башыннан аягына кадәр карап үткәрде дә, салкын гына:

—Өйгә рәхим итегез!—диде.

—Безгә иң элек машинаны ишек алдына кертергә кирәк,—диде Башкиров, һәм Анфисаның рөхсәтен көтеп тормады, капканы ачты.

Без ишек алдында эшне бетереп өйгә кергәндә лампага ут алынган иде инде.

Анфиса утыз яшьләр тирәсендәге таза гәүдәле, зур күкрәкле зәпзәңгәр күзле чибәр генә хатын иде. Ире фронтта икән. Карт әнисе һәм өч-дүрт яшьлек кызы белән яши. Кызы бөҗыр кебек, бөтен өйне айкап, йөгереп йөри.

Өй эчендә берничә бүлмә. Бары да пөхтә итеп җыештырылган. Залда идәнгә келәм җәелгән, бер почмакта пианино тора.

Хуҗа хатын әнисе белән нәрсәдер пышылдап сөйләшә башлады.

—Мәшәкатьләнмәгез, безнең азык-төлек үзебез белән—диде, Макусинский аларны бүлдереп.

—Сез безгә әзерләп бирсәгез яхшы булыр иде,—диде Башкиров сүзгә кушылып.

Алар шулай сөйләшкән арада Костенко ишек алдына чыгып, машина әрҗәсеннән азык-төлек алып керде.

—Төнлә машинаны ялгыз калдырырга ярамас,—диде, Макусинский.

—Әүвәл ашап-эчик әле,—диде сержант.—Тамак туйгач күз күрер.

—Бер дә борчылмагыз,—диде Анфиса сүзгә кушылып,—безнең капканың биге яхшы, әлегә станицада тынычлык, ул-бу ишетелгәне юк.

Аяк киемнәрен салып, билне буган каешларны ычкындыргач рәхәт булып китте. Сугыш башланганнан соң беренче мәртәбә шулай кешечә иркенләп төн үткәрергә җыендык.

Ул арада ашарга да әзерләп өлгерттеләр. Башкиров Макусинскийга ымлап нәрсәдер аңлатты. Ул теләмичә генә ишек алдына чыгып машинадан ике шешә эчемлек алып керде.

—Бүген башка сорамагыз,—диде ул коры гына. Әйтеп үтәргә кирәк, сержант бу мәсьәләне тулысы белән аның карамагына тапшырган иде. Ул бер вакытта да безне артык кыландырмады.

—Безнекен дә авыз итеп карагыз,—диде Анфиса. Графин белән йөземнән үзләре эшләгән шәрап чыгарып куйды.

Ашап-эчә торгач барыбыз да яхшы ук кыздык. Хуҗаның патефоны бар икән. Пластинкалары да күп. Анфиса белән Башкиров пластинкалар сайлап, шуларны уйнатырга тотындылар. Алай да булмады, патефонга кушылып җырлый ук башладылар. Анфиса да яхшы гына җырлый икән. Җыр артыннан бию китте.

Күңел ачу шактый озак дәвам итте. Мин почмак якта, барыбыз өчен әби идәнгә түшәгән урынга кереп ятканда төн уртасы җитеп килә иде инде. Мендәргә башым тию белән эреп йокыга да киткәнмен. Изелеп, бер нәрсә сизми йоклаганмын. Озак йоклаганмын. Мин уянганда стена сәгате иртәнге унны суга иде. Өйдәгеләр бары да йоклый иде әле. Урын дүрт кешегә әзерләнгән булса да идәндә өчәү генә ята идек. Безнең янда Башкиров юк иде. Мин аны эзләп ишек алдына чыктым. Ул анда да юк иде. Кире өйгә кереп Макусинскийны уяттым.

—Командир каядыр чыгып сызган,—дидем мин аңа шыпырт кына. Ул елмайды да залга ымлады. Мин барып ишекне ачтым. Анда түрдәге

кроватьта алар Анфиса белән бергә анадан тума чишенеп ятканнар, өсләренә дә ябынмаганнар. Тиз генә ишекне ябып куярга мәҗбүр булдым.

Макусинский белән Костенко да торып киенделәр дә без ишек алдына чыктык. Чыгу белән машинаны көйләргә тотындык. Урамга чыгып андагы коедан ике чиләк су алып кердек, бер чиләген Костенко радиаторга салды, икенчесе белән бил тиентен чишенеп үзебез юындык.

Ноябрь башы булса да көн шактый җылы иде. Халык монда әле җәйге киемнәрдән йөри. Без дә бер кат гимнастеркадан гына калдык. Гомумән, үзебезне рәткә китерергә кирәк иде. Шулай эшләдек тә. Гимнастеркага чиста, ак якалар тактык. Аяк киемнәрен көзге кебек итеп ялтыраттык.

Ул арада сержант та йокыдан торып ишек алдына чыкты. Аның бүген моннан китәргә исәбе юк иде. Макусинский белән Костенко аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр.

—Вакыт калса, Анфисаң янына кайтканда керерсең,—диде Макусинский.—Элек өскә йөкләнгән заданиене үтәргә кирәк.

Без тиз генә җыенып юлга чыктык. Анфиса капка төбенә басып, машина күздән югалганчы кул болгап озатып калды.

Станицаны чыгу белән Костенко газикны соңгы тизлек белән куды. Юл буена тезелгән иксез-чиксез станицаларны, вак-вак хуторларны артта калдырып Краснодарга юл тоттык.

Шәһәргә без төн уртасы җитәрәк барып кердек. Башкиров белән миңа монда бар да таныш иде. Без хезмәт иткән 268 нче КАП торган хәрби шәһәрчек кырыннан Карл Маркс урамы башлана иде. Бу урамда бөтенләе белән диярлек үз йортлы кешеләр яшиләр. Безгә старшина Усикның хатыны яшәгән йортны эзләп табарга кирәк иде. Юлга чыкканда: «Краснодарда эшегезне бетергәнче шунда тукталып торырсыз», дигәннәр иде. Хәзер йорт номеры онытылган, ләкин шунысын ачык хәтерлим, так номер иде. Сержантның бу йортта булганы бар икән, шуңа күрә эзләп вакыт әрәм итәргә туры килмәде, туп-туры шулар капка төбенә барып туктадык. Хуҗалар йоклап беткәннәр иде инде. Капканы шакылдата торгач эчтән бер хатын тавышы ишетелде. Без ашыга-ашыга аңа үзебезнең кем икәнлегебезне аңлата башладык. Ләкин ул безнең сүзләргә ышанып бетмәде ахры, өйгә кереп икенче бер хатынны алып чыкты.

—Кем ул болай вакытсыз борчып йөри?

—Безгә Римма Ивановна кирәк,—диде Башкиров.—Сезгә Анатолий Никифоровичтан күчтәнәчләр алып кайттык.

Ниһаять, күп сөйләшә торгач капканы ачтылар. Машинаны ишек алдына керттек. Ишек алды шактый киң иде. Арт якта бакчасы да бар. Йорт кирпечтән салынган, калай түбәле. Верандасы ишек алдына каратып эшләнгән.

Башкиров иң беренче эш итеп Римма Ивановнага ире язган хатны тоттырды. Әлбәттә аңа хәзерге минутта шушы хаттан да кадерле нәрсә юк иде.

—Анда кузовта сезгә тапшырасы чемодан бар,—диде Башкиров,— аны иртәгә көн яктысында карап алырбыз.—Алар икесе бергә өйгә кереп киттеләр. Без машинаны сүндереп капканы яптык та, тын гына веранда кырыена барып утырдык.

—Сез анда нәрсә озакладыгыз, нигә өйгә кермисез,—дип кычкырды сержант өй ишеген ачып.

Өй эче иркен иде. Безне тәрәзәләре бакчага карап торган уң яктагы бүлмәгә алып кереп, икешәр-икешәр караватка яткырдылар.

—Парлап яткач йокы тәмле була,—диде Римма Ивановна шаяртып. Ул кырыкка якынлашып килә торган чибәр генә хатын иде. Чәчләре ясатылган. Бер чакрымга хуш ис аңкып тора. Шомырт кара күзләре бераз татар хатыннарын хәтерләтә. Ул безгә тыныч йокы теләп үз бүлмәсенә чыгып китте.

Иртә белән йокыдан торгач шуны белдек, бу йорт Римма Ивановна-

ның әнисе, Анастасия Семеновнаныкы икән. Әтиләре сугыш алдыннан вафат булган. Анастасия Семеновнаның Надя исемле тагын бер кызы бар. Ул әле кияүгә чыкмаган, әнисе белән бергә шушы йортта яши.

Надя апасына бер дә генә ошамаган. Зәңгәр күзле, ут кебек янып торган кызыл чәчле, битендә бераз сипкеле бар, ягымлы гына сөйләшә.

Безнен полкның начальствосы барысы да дип әйтерлек Краснодар кешеләре иде. Гаиләләре полк Кировоградка күчкәндә бер кая да кузгалмады, шунда калды. Ничек булса да аларның барысын да күрергә, хат һәм күчтәнәчләр тапшырырга кирәк иде. Беренче көнне шушы эшкә багышладык. Безгә унлап адрес биргәннәр иде. Шул адреслар белән йөри торгач бөтен шәһәрне әйләнеп чыктык.

Ул вакытта Краснодар әллә ни зур түгел иде. Күп катлы йортлар бары бер—Красная дип аталган үзәк урамда гына. Телгә алып сөйләрлек завод, фабрикалар да юк иде кебек. Шунысы бик кызык, этләр бик күп иде. Үзләре уйлап чыгарганнардырмы, яки кемнән булса да ишеткәннәрдерме, кызылармеецлар шәһәр турында сүз чыкканда «Краснодар не казачий станица, а собачий столица» дип көлешә торганнар иде.

Чын мәгънәсендә эт куып урамнан урамга йөри торгач, көннен узганын сизми дә калдык.

Шәһәрдә зур чинлы хәрбиләр бик күп иде. Моңа шушында фронт штабының урнашуы сәбәп булгандырмы, адым саен командирлар очрап газап чиктерде. Эш шунда, алар яныннан шома гына узып булмый, честь бирергә кирәк. Минем шул честь биреп, командир турысыннан строевой шаг белән атлап китүдән дә яратмаган нәрсәм юк иде. Честь бирми китсәң, туктатып маңгаеннан кырык тирең чыкканчы «үгетлиләр».

Шәһәргә бертуктаусыз эвакуацияләнгән халык килә. Урамнар кырмыска оясы кебек мыжлап тора. Шулай да тормыш чагыштырмача иркен, кибетләрдә, бигрәк тә базарда азык-төлек тулып ята иде.

Сержант уникенче армиянең разведка начальнигы майор Еремеев биргән пакетны фронт штабына кертеп чыгарга тиеш иде. Ул бу эшне иртәгә калдырып торырга булды. Без арып-талып Карл Маркс урамындагы фатирыбызга кайтып егылдык.

—Озак, озак гулять иттегез,—диде Анастасия Семеновна,—сезне чыгарып җибәрерлек түгел икән.

Хуҗалар безне ашарга әзерләп көтеп торганнар. Миңа барыннан да бигрәк борщ ошады. Бәлки шулай тоелгандыр гына, андый тәмле ашны бер вакытта да ашаганым юк кебек иде.

Без әле полк командирының хатынын күрмәгән идек. Аңа да хат һәм берничә чемодан тапшырырга кирәк иде.

—Бүген үк илтеп бирергә кирәк,—диде Макусинский. Бәладән ераграк торырга кирәк,—минемчә, ул чемоданнарда акча...

Башкировның «тс-с!» дип бармагын иреннәренә аркылы куюыннан ук Макусинскийның сүзе хак икәнлеге аңлашылды. Ул чемоданнарда, Запорожьедан чигенгәндә, дәүләт банкысында ташлап калдырылган акча булуы бик ихтимал иде.

Полк командирының хатыны Красная урамының азагында, ике катлы таш йортта яши иде. Без анда машина белән бардык. Фатиры беренче катта, ишегалды аша керелә. Әйтергә кирәк, бу ишегалды тулысы белән шушы фатир хуҗасы карамагында иде. Раиса Туевна—чын исеме Рахиль, безне бик җылы каршы алды. Ул шундый яшь күренә, әгәр Макс Соломонович белән икесен янәшә бастырсаң, һичшиксез аны кызы дип әйтәчәкләр иде.

Раиса Туевна зифа буйлы, чем кара чәчле, кылыч борынлы. Ак йөзе ничектер грек статуэткаларын хәтерләтә. Шомырт кара күзләре ут кебек янып тора...

—Көтәм сезне, көтәм,—диде ул ягымлы елмаеп.—Кичә генә хат алдым. Ничек килеп җиттегез? Кайда туктарга уйлыйсыз?—дип сорады ул сүзен дәвам итеп.

—Кайда туктарга дип әллә ни маташып булмас,—диде Башкиров.—Безнең барасы жир бик ерак әле, иртәгә фронт штабында эшне бетерсәк, юлга чыгабыз. Юл кешесенең юлда булуы яхшы.

Сизеп торабыз, фронт штабында эшне бетерсәк, дип Башкиров үзенең дәрәҗәсен зурайтып күрсәтергә тырыша, аңа бары бер сургучланган пакет тапшырырга кирәк һәм аны анда беркем тоткарлаячак түгел.

—Ашыкмагыз, мондый командировка теләсә кемгә тәтеми, сезгә дә башка болай чыгып йөрергә туры килмәс,—диде Раиса Туевна.—Моменттан файдаланып калыгыз. Безнең ишегалды бик тыныч, машинагызны шунда кертәбез...—Ул безнең ризалыкны көтеп тормады, капканы ачарга кушты. Сержант белән Костенко серле итеп бер-берсенә карашып алдылар да аның боерыгына сүзсез буйсындылар.

Машинаны кертү белән генә эш бетмәде. Раиса Туевна безне өйгә алып керде. Фатиры иркен иде.

—Миндә эвакуированныйлар тора, берничә көнгә сез дә сыярсыз,—диде ул. Без аңа үзебезнең старшина Усикның хатынында тукталуыбызны әйтергә мәҗбүр булдык.—Бик яхшы,—дип сүзен дәвам итте Раиса Туевна,—шулай да машинагыз безнең ишек алдында калсын, югыйсә төрле хәл килеп чыгуы мөмкин.—Без аннан нинди хәл килеп чыгуы турында сорашып тормадык, үз чиратында ул да безнең машинаны монда калдырырга ризалыкны сизеп, башка бу хакта сүзне озайтмады.

Раиса Туевна шәһәр Советы башкарма комитетында эшли икән. Яңа оештырылган бүлек—эвакуация белән килгән халыкны урнаштыру бүлеге мөдире. «Кирәк булса шалтыратырсыз», дип ул үзенең эш телефонын бирде.

—Кичләрен мин өйдә булам, бер дә тартынып тормагыз, килегез, сез минем кадерле кунагым,—диде ул.

Без кайтканда өйдә Анастасия Семеновна үзе генә иде. Римма Ивановна белән Надя театрга киткәннәр.

—Безгә монда эвакуация белән Ленинградның оперетта театры килде,—диде Анастасия Семеновна,—халык бик яратып йөри, сез дә барыгыз.

Кайту белән иптәшләр йокларга яттылар. Минем нәрсәдер йокы килми иде. Өстәлдә «Нева» журналының революциягә кадәр чыккан төпләмәләре яталар иде. Мин шуларны актара башладым. Кайсы елгы, ничәнче номер икәне истә калмаган, шунысын ачык әйтә алам; егерменче йөзнең беренче елларында чыккан журнал иде, берсендә композитор Моцарт турында зур гына мәкалә таптым. Мин бу мәкаләне бөтен дөньямны онытып укыдым. Композиторның исемен ишеткәнем бар иде, әмма аның нинди кеше булуы турында бер нәрсә дә белми идем. Бар бит дөньяда гаҗәп кешеләр, әйтергә генә ансат—биш яшендә фортепианода уйнаган, музыка язган!

Сәгать ничә булгандыр, кызлар соң гына театрдан кайттылар. Минем журнал укып утырганны күреп, яныма Надя килде. Ул беренче сүз итеп минем нинди милләт кешесе булуым турында сорады.

—Сез, минемчә, рус түгел бугай, нинди милләт кешесе икәнлегегезне белергә мөмкинме?

Мин русчаны бик ватып сөйләшә идем. Чөнки армиягә кадәр бер дә руслар белән аралашырга туры килмәде. Үземнең татар икәнемне әйткәч, «мин татарларны башкача итеп күз алдыма китерә идем»,—диде Надя.

—Ничек итеп?

—Кысык күзле, сары йөзле, карсак гәүдәле...

—Бүгенге көнгә кадәр тарихи бер ялгышлык яшәп килә. Безне монголлар белән бутыйлар. Безнең нәсел исә кайчандыр Идел елгасы буенда барлыкка килгән «Бөек Болгар» иленнән башлана.

Мин Надяга болгар дәүләте турында сөйләп киттем. Аларның Европада беренчеләрдән булып чуен коюлары турында искә төшердем.

Бу дәүләтне монголлар коточкыч ерткычлык белән җимерткәннәр, халкын үтереп бетерергә исәпләгәннәр, ләкин халыкны кырып бетерү мөмкин түгел...

Надя мине бик кызыксынып тыңлады. Мин Краснодарда татарлар шактый булуын, Красная урамындагы татар клубын искә төшердем.

—Чыннан да,—диде Надя,—минем ул клуб турында ишеткәнем бар, ләкин анда йөргән кешеләр белән кызыксынганым булмады.—Без сөйләшә торгач бик тирәнгә кереп киттек. Халыкның гел үзара аралашып торуын да әйттек.

—Руслар белән безнең татарлар кадәр аралашкан халык юктыр,—дидем мин.—Французларда, хәтта мәкаль бар: «урысны чукысаң, татар чыга»,—ди алар. Күп кенә билгеле кешеләрнең нәсел башы татарларга барып ялгана. Мин аңа Тургенев, Карамзин, Денис Давыдов, Бородин һәм башкалар турында әйтеп үттем.

Надяның кәефе яхшы иде. Театрдан күңеле күтәрелеп кайткан. Ленинград артистлары шундый ошаган, мактап бетерә алмый.

—Бармый калмагыз,—диде ул,—бармасагыз гөнаһ булыр. Бер генә спектакльне булса да күреп китегез.

Минем оперетта турында ишеткәнем дә юк иде. Шуңа күрә аны күз алдына да китерә алмый идем. Икенче көнне без барыбыз да Надяга ияреп театрга киттек. Ул көнне «Сильва» бара иде. Беренче пәрдәдән үк бу спектакльнең музыкасы, андагы вакыйгалар һәм артистларның оста уены безне әсир итте. Үзебезне бөтенләй икенче дөньядагы кешеләр кебек хис иттек. Бары да онытылды. Сугыш, андагы елга булып аккан кеше каны, үлә алмый тилмереп ятучы яралылар, тылдагы тел белән әйтеп аңлата алмаслык авыр тормыш бер минутка истән чыгып торды.

Бара торгач безнең эш бөтенләй җайланып китте. Көндез кунакка йөртәләр, кичен театр карыйбыз. Фронттагы ирләреннән, туганнарыннан без хат, күчтәнәч алып кайтып биргән хатыннар чиратлап кунакка чакыралар, бармасаң үпкәлиләр. Кунакта ничек икәне билгеле, эчемлек була, әлбәттә. Бераз төшергәч кызып китәсең. Кызгач—ярты юлда туктап калып булмый, барысына да барасың...

Без Надя белән шундый дуслашып киттек, ике атна буена бер минутка да аерылышмадык. Мин башта үземнең элекке танышымны, татар кызын эзләп караган идем. Барып чыкмады. Клубны япканнар, анда эвакуация белән килгән халыкны кертеп тутырганнар, чыр-чу, бала-чага, ата улны, ана кызны белми. Минем таныш кызым турында ишеткән кеше дә юк.

Китәр алдыннан Раиса Туевнада кунак булдык. Анда аның иптәш хатыннары да бар иде. Күңелле утырдык. Хатыннар барысы да Башкиров тирәсендә әйләнделәр. Сержант үз бәясен белеп эш итте. Әйтеп узганымча, ул сезгә кесәгә керә торганнардан түгел иде. Шомартып сөйләргә көннән-көн остарды. Бездән дә тартынмый башлады. Чынмы, ялганмы—азрак кеше ышанырлык булса сиптерә генә! шулай итеп ул мондагы хатыннар алдында чын геройга әйләнде дә куйды. Мәҗлес таралгач ниндидер сәбәп тапкан булып яшь кенә бер хатын аны үзе белән алып китте. Ул анда куныш кайтты.

Бездә комиссар хатынының адресы юк иде. Аны Орджоникидзе шәһәреннән, анда булмаса шул тирәдәге төбәкләрдән эзләргә кирәк иде.

—Һәрбер шәһәрдә, район үзәкләрендә эвакуация пунктлары оештырылды, кайда гына булсагыз да иң элек шунда керегез,—диде Раиса Туевна.—Аларда эвакуация белән килгән кешенең исем-фамилиясе, адресы була.

Шәһәрдән иртә таң белән чыгып киттек. Юл буе төньяк Кавказның гаҗәп матур табигатенә, берсеннән-берсе бай, төзек станицаларның чисталыгына сокланып бетә алмадым. Тагын шунысына гаҗәпләндем,

кайбер станицаларның исемнәре татарчага бик якын иде. Тимергуево, Мечетинская һәм башкалар. Жирле халык Пятигорскийны да үзенчә, Бештау дип атый икән.

Станицалар үзләренең төзелешләре белән кечерәк шәһәрләрне хәтерләтә. Миңа бигрәк тә таулардан башланган көмеш сулы Лаба елгасы буена урнашкан Лабинский, Усть-Лабинский станицалары ошады.

Шәһәрләр дә безнең яктагыларга охшамаган. Пятигорскийдан тыш Нальчик, Прохладный, Черкесский шәһәрләрен уздык. Ниһаять, бара торгач Төньяк Осетиягә, Терек елгасы кырыена килеп чыктык. Орджоникидзе шәһәренә барып житә алмадык, комиссарның хатынын шуннан ерак түгел Вислан станицасендә эзләп таптык. Ул үзенең сеңлесе белән каяндыр, көнбатыш чик тирәсенә эвакуацияләнеп шунда килеп урнашкан. Сеңлесенең дә ире хәрби хезмәттә икән. Танкист. Өлкән лейтенант. Сөйләүләренә караганда сугышның беренче көненнән үк фронтта, ләкин хәбәре юк.

Комиссар хатыны шактый олы яшьтә иде, ә сеңлесе яшь, күзләре уйнап тора, сугыш алдыннан гына кияүгә чыккан булган. Алар бик тиз Башкиров белән уртак тел таптылар. Беренче төнне үк бергә үткәределәр.

Комиссар хатыны безнең монда озаграк булуыбызны теләде.

—Килгән-килгән, рәхәтләнеп ял итегез,—диде ул, анда сезне көтеп тормыйлар әле.

—Ашыкмагыз, үләргә өлгерерсез!—диде сеңлесе, апасының сүзен җөпләп. Никадәр кыстасалар да без алар әйткәнчә озаклап тора алмадык. Сәфәр артык озакка сузылды, кайтырга кирәк иде.

* * *

И хәйран дөнья! И вәйран дөнья! Ил өстенә ябырылып дошман килә. Авыл, шәһәрләр жимерелә, елгаларда сулар кандай кызарып ага. Иген кырлары өстендә ялкыннар йөгерә. Бөтен халык урыныннан купкан! Ә без урланган акча өләшеп ил гизәбез! Хатыннары белән типтерәбез... Командир, комиссар хатыннары йомылып кына безнең кочакка сеңәләр. Хәзер шул монсу хатирәләрне уйлыйм да... Күз алдыма китерә алмыйм. Акылдан язармын төсле. Ходаем, языкларымны кичер!

Соңгы чемоданнарны комиссар хатынына тапшыргач машина кузовы бөтенләй бушап калды. Без Макусинский белән борт кырыенда буйдан буйга сузылган эскәмиягә басып йокы симертә башладык. Ләкин бу рәхәтлек тә озакка бармады.

Бер көнне һава салкынаеп, кар ява башлаган иде. Атна буе өзә-тәтә гел яуды. Бураннар уйнады. Юлларны калын кар көрте каплады. Урыны-урыны белән карның калынлыгы бер метрга кадәр житә иде. Без юлга кузгалгач та кар мулдан яуын дәвам итте. Машинабыз көрткә кереп батты. Ни алга, ни артка барырга мөмкин түгел иде. Ярый әле станицадан әллә ни ерак китмәгән идек. Башкиров кире кайтып колхоздан пар үгез алып килде. Машинаны пар үгезләр белән тарттырып Тимергуево станицасына көч-хәл белән кайтып кердек. Һаваның мондый хәленнән халык бик аптырашта калган иде. Һәркем үзенчә фикер йөртә. Дингә ышанучылар мондый күренешне Алланың жирдәге бозыклыкка чиктән тыш ачуы чыгу белән бәйлиләр иде. Ничек кенә булмасын, тирә-юньдә яшәүче иң карт кешеләр арасында да бу якларда мондый салкын һаваны, бигрәк тә бу кадәр күп кар яуганны хәтерләүчеләр юк иде.

Атна буе шушы Тимергуево станицасында яшәргә туры килде. безнең монда тукталып торуга нык шатланучылар да бар иде. Ирләргә шул кадәр сусаганнар, кая утыртырга белмиләр. Ни тәртипле Макусинскийны да юлдан яздырдылар. Мин бичара да бозылып беттем.

Нәкъ бер атнадан күк йөзе болытлардан арчылып, көн жылытып

җибәрде. Кар эреп, бөтен дөньяны су басты. Җир тәмам җебеде, аяк баскан саен тез тиңентен бата. Юллар тәмам эштән чыкты. Машина кыймылдый да алмый. Артык монда калырга ярамый иде, ничек булса да кайту ягына таба хәрәкәт итәргә кирәк иде. Машинаны үгезләр белән тарттырып юлга чыктык. Ташбака адымы белән үрмәли торгач ничек кирәк алай Краснодарга кайтып җиттек. Башта без монда тукталып торырга уйламаган идек. Тиз генә Раиса Туевна белән эшне бетереп шәһәрдән чыгып китәргә җыенган идек. Алар безне дүрт күз белән көтеп торалар иде. Китү турында ишетергә дә теләмәделәр. Бер кич кунмыйча бер кая да җибәрмибез дип, Башкировны теге, бер көн йоклап кайткан хатын янына алып киттеләр. Шуннан файдаланып мин дә Надя белән очраштым һәм без театрга бардык.

Аз гына вакыт бергә булсак та, без Надя белән бер-беребезгә ияләшеп җиткән идек инде. Аерылганда ул күз яше белән елап калды. Минем дә күз төпләре дымланды.

Кайтканда без Павловка станицасына кереп вакыт уздырмаска, икенче юл белән китәргә исәпләгән идек. Башкиров үзенекен итте. Әйләнгечне туры итеп, туры юлны хур итеп йөрмик әле, дигән булып Павловка аша китте. Ләкин Анфисаны очрата алмады, аны окоп казырга җибәргәннәр иде. Әби безнең белән бик салкын сөйләште. Шуңа күрә без анда кунып тормадык, азрак тамак ялгап алдык та, юлыбызны дәвам иттек.

Луганский станицасына кайтып кергәндә безнекеләр анда юк иде инде. Фронтка җибәргәннәр. Алдан сөйләшеп куйганча, армия штабына, Ворошиловоградка киттек һәм разведка начальнигы майор Еремеев янына кердек. Юлда озак маташкан өчен шелтәләргә исәбе бар иде, Башкиров юл хәлләрен бик оста итеп аңлатып биргәч, безнең озак йөрү белән килеште тагын, артык ул турыда сүз кузгатмады. Ул безне ничек полкны эзләп табарга өйрәтте. Полк Алмазный һәм Каганович станцияләре арасында, ут сызыгына урнашкан иде. Штабы Калиновка дигән авылда икән. Барасы җир әлләни ерак түгел иде. Майор Еремеев планшетыннан карта алып юлда барганда нинди торак пунктлар аша узарга туры киләчәген билгеләде.

Шулай итеп без Калиновка авылын эзләп киттек. Донбасс тоташ шәһәрләр тезмәсеннән тора. Кая карама, анда шахтер хезмәтеннән барлыкка килгән пирамидалар, зур-зур террикон таулары. Шул күмер калдыклары өемнәре арасында боргаланып-сыргаланып йөри торгач, Калиновка авылына барып җитүебезне сизми дә калдык.

Безне бик җылы каршы алдылар. Полк командирының әмере буенча, икенче көнне ашка берәр порция аракы өстәп бирделәр. Бар да өйләреннән хат алганнар һәм амәнәтләренең исән-сау тапшырылганын белеп бик шатланганнар иде.

Без югында полкка яңа кешеләр китереп тутырганнар. Безнең взводта да берничә яңа кеше бар иде.

Исәпләүчеләр отделениесе авыл уртасында, полк штабы белән янәшә зур гына бер колхозчы йортында урнашкан иде. Йорт хуҗасы кара сакаллы, карлыккан тавышлы, бөкере бер кеше иде. Үзләре белән ике балалы Галя исемле кызлары тора. Кияүләре Ленинград юнәлешендә, фронтта икән. Бер хаты килгән, шуннан соң хәбәре юк.

Галя бөтен килеше белән чегән хатыннарына охшаган. Кап-кара, озын толымнарын күкрәгенә төшереп йөри. Дугаланып килгән кара каш астындагы күзләре сихерле елмаеп ирләрне бер карауда үзенә җәлеп итә. Әнисе аны күзәтеп кенә тора, бер минутка да күзеннән ычкындырмый. Егетләр ничек булса да җаен китереп Галя белән ялгыз калырга тырышалар.

Йорт хуҗасы Константин Петрович—коммунист, колхоз төзүдә башлап йөргән, әле дә җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ул немец килүдән бик курка. Сөйләүләренә караганда, авылның кайбер кешеләре аны тере килеш ашарга тора. Немец килсә аягыннан тотып дарга асачаклар. Күптән, күптән Донбассны, авылын ташлап тылга китәргә әзерләнеп

куйган, бары команда гына көтә. Зур гына үгезе бар. Шул үгезне жигеп, иң кирәк әйберләрен төяп, йөк өстенә онықларын утыртып юлга чыкмакчы була. Шул турыда сүз чыкса кызы белән ике арада тавыш куба. Кызының авылны ташлап китәсе килми.

—Син теләсә нишлә, мин онықларымны алып китәм,—дип кырт кисә карт.—Син өстерәлчеккә бала калдыраммы соң? Әниләренен жирән немец солдаты астына кереп ятуларын күрми торсыннар әле!

Фронт Калиновкадан биш, ун километр чамасы жирдән уза. Анда әлегә тып-гын. Ике як та бер-берсен күзәтә, төннәрен ут сызыгы аша разведчиклар йөреп тора, ара-тирә мылтыктан, автоматтан аткан тавышлар янгырый.

Константин Петрович түземсезлек белән безнекеләрнең һөҗүмгә күчүләрен көтә.

—Көз көне немецне Ростовтан кудылармы, кудылар! Изюм-Барвенково юнәлешендә кирәген бирделәрме, бирделәр!—ди ул горурланып.—Яз житү белән аны Донбасстан куарга тиешләр. Фашистка Донбассны калдырырга ярыймы соң?!—Ул бу сүзләрне шундый итеп сөйли, әйтерсең ана бу хакта каяндыр хәбәр итеп торалар. Без анардан «дядя Костя, син юкка монда әрәм булып ятасың, сине Сталин янына киңәшче итеп жибәрергә кирәк»,—дип көлә торган идек. Ул да үз чиратында югалып калмый торган иде:

—Минме,—ди торган иде бик житди итеп,—әгәр анда утырсам, бөтенләй башкача булыр иде. Кызыл Армияне бер адым да артка чигендермәс идем! Иптәш Ворошилов әйткәнчә, сугыш дошманның үз жирендә барган булыр иде!

Мин бер егет белән бик дуслашып киттем. Аны безнең исәпләүчеләр отделениясенә мин югында китергәннәр. Фамилиясе—Куличенко, исеме—Анатолий. Ул вакытта атасының исемен белми идем. Бер-беребезне исемнәребез белән генә атап йөри идек. Ул яше белән миннән шактый олы иде. Украинлы. Белая церковь шәһәре янында, бер авылда атасы яши. Анатолий әтисе патша армиясендә хезмәт иткәндә Кытайда, Харбин шәһәрендә туган. Әнисен хәтерләп бетерми. Ул шунда, Харбинда үлеп калган. Васыятен үтәп, туган жире—Башкортстанга алып кайтып күмгәннәр.

Анатолийның әтисе гади солдат кына булмаган. Аз-маз укып фельдшер булып хезмәт иткән. Акча туплап, Украинага кайтып жир сатып алырга хыялланган.

—Әти акчаны жыйган жыюын, ләкин аның кирәге булмаган,—ди торган иде Анатолий көлеп.—Октябрь революциясеннән соң аңа жирне түләүсез биргәннәр. Күпме диген әле. Әйтергә генә ансат, ике гектар! Революция булу белән ул авылга кайткан. Башы-аягы белән жиргә чумган. Башка өйләнмәгән, ялгыз яшәгән.

Анатолий югары белемле иде. Сугыш алдыннан гына Ленинградта институт бетергән. Ул бик күп укыган, философия, матур әдәбият белән яхшы таныш. Мин аннан дөнья әдәбияты классиклары турында бик күп яңалыклар ишеттем. Без аның белән һич кенә дә сөйләшеп туя алмый торган идек. Ләкин безгә озак бергә булырга туры килмәде. Алар взвод командиры Голумба белән килешә алмадылар. Мин Краснодардан кайтып ике ай чамасы вакыт узгач аны икенче частькә озаттылар. Гомумән, Голумба взводта үзеннән өстен кешеләрне булдырмаска тырыша иде. Ничек булса да жаен китереп ул аларны озаттыра торган иде.

* * *

Анатолий белән ике ай чамасы гына бергә булуга карамастан, ул минем күңелдә мәңге онытылмаслык булып урын алган иде. Аерылганнан соң бик күп еллар мин аны чын күңелдән юксынып йөрдем. Яшьлегем белән уйлап житкермәгәнмен булса кирәк, адресын

алып калырга башыма да килмәгән. Ә ул минем адресны алган булган икән...

1949 нчы елның сентябрендә миңа авылдан гадәти булмаган бер хат килде. Хат рус телендә, әти исеменә язылган иде. Мин чиктән тыш дулкынланып хатны укый башладым һәм беренче юлдан ук кемнән икәнен аңлап алдым. Хатны Анатолий язган иде. Ул башта үзенең хат язарга уңайсызланып йөргәнен әйтеп үтә. Төзәлеп бара торган ярагызга тоз салырмын дип курыктым, ди. Хәзер үзенең Казанда яшәвен әйткән. Әгәр исән булсам хатны миңа тапшыруларын үтенгән.

Хат миңа эштән кайткач, кич белән тапшырылды. Мин бик арыган булсам да хатны укыгач та, бер нәрсә белән исәпләшмичә, Анатолий янына чыгып йөгердем, хәтта тамак ялгап та тормадым.

Анатолий Казан педагогия институтының Болак буендагы төп бинасы янында, кечкенә генә бер йортта тора иде. Бу тирәләр миңа яхшы таныш. Сугышка кадәр бу йортта педагогия техникумы иде, мин шунда укучы авылдашларым янына барып йөри торган идем. Урам, бигрәк тә адреста күрсәтелгән йортның ишек алды караңгы булса да Анатолий яшәгән фатирны эзләп азапланмадым, туры барып кердем.

Мин барып кергәндә алар кичке ашны ашап утыралар иде. Анатолий мине күтәреп алгандай иттерде. Без аның белән кочаклашып күрештек. Хатыны, ике баласы бар икән. Хатыны үзенә караганда бик күпкә яшь, балалары да әле кечкенәләр. Кызы яңа туган, берничә айлык кына. Анатолий үзе шактый олыгайган, чигәсенә чал кергән. Зәңгәр күзләре генә үзгәрмәгәннәр, элеккечә өздереп карыйлар. Ул мине табынга чакырып тормады, өстен киенергә тотынды.

—Аня, бу минем фронтовик дустым,—диде хатынына,—без аның белән шәһәрдә йөреп кайтабыз...

Аняның йөзендә ризасызлык чагылды. Ул аш яныннан торып кроватьта тиберченеп яткан имчәк баласын алды һәм аны имезергә тотынды. Мин аның чибәрлегенә сокланып куйдым. Ул кылыч борынлы, түгәрәк гәүдәле, мул күкрәкле, житен кебек сары чәчен юан итеп бер толымга үргән, йөзендә ниндидер нур балкып тора. Аня Анатолийның сүзләренә берниндидә жавап кайтармады. Мин киткәндә «исән булыгыз» дигәч тә дәшмәде.

Без Анатолий белән урамга чыктык. Ул мине Бауман урамына таба алып китте. Сугыштан соңгы елларда хәзерге татар ашлары йортынын Бауман урамы ягыннан керә торган иске бинасында ит комбинатының ашханәсе урнашкан иде. Анда үпкә-бавырдан пешерелгән кайнар сумсалар була торган иде. Анатолий Никифорович—шуңа кадәр мин аның атасының исемен белми идем,—мине шул ашханәгә алып керде. Ашханә халык белән тулы иде. Анатолий Никифорович, күрәсең, монда беренче мәртәбә генә түгел, андагы официанткалар белән яхшы таныш икән. Алар безгә бик тиз урын табып бирделәр. Озак көтәргә туры килмәде, өстәлгә графин белән аракы да килеп утырды. Гәпләшеп ашый-эчә башладык. Безнең сүзләр бер утыруда гына сөйләшеп бетә торган түгел иде. Сүзгә мавыгып ашханә ябылыр вакыт житкәнне дә сизми калганбыз. Аннан бик озак урамда йөрдек. Йөри торгач без урамда икәү генә калдык. Транспорт туктады. Бөтен жирдә сәер тынлык урнашты.

Анатолий Никифоровичның фатиры янында аерым ишекле тагын кечкенә генә бер бүлмәсе бар икән. Без шунда кайттык. Чишенеп, икебез бергә аның караватына яттык. Ләкин иртәнгә кадәр күз йомып карамадык. Икенче көнне мин шуннан туп-туры эшкә киттем.

Миннән аерылгач Анатолий Никифорович запасной полкка эләккән. Анда ике айга якын писарь булып хезмәт иткән. Бу хезмәт аңа ошамаган. Ул жаны-тәне белән фронтның алгы сызыгына ыргылган. Күп сорый торгач аның үтенечен канәгатьләндергәннәр. Ул бер артиллерия полкы составында башта Кавказда, аннан Украинада сугышкан. Украинаны немецләрдән азат иткәч аларның полкы Карпат таулары аша Венгриягә

килеп кергән. Җину көнен Венгриядә каршылаганнар.

Анатолий Никифорович армиядән демобилизацияләнгәч Ленинградка кайта һәм Герцен исемендәге педагогия институтының аспирантурасына керә. Шунда диссертация яза һәм аны уңышлы яклап философия фәннәре кандидаты дигән исемгә лаек була. Минем белән очрашканда Казан педагогия институтында доцент, кафедра мөдире булып эшли иде.

—Миңа Ленинградта да калырга була иде, сине эзләп килдем!— диде ул бик житди итеп.

Хатыны Анна Емельяновна Рязань өлкәсендә туган. Алар сугыш вакытында танышкан булганнар. Анатолий Никифоровичка сугыш башлангач, ничектер, Рязань өлкәсендә булырга туры килгән. Ул, әгәр сугышта исән калса, ана өйләнергә вәгъдә биргән. Вәгъдәсен үтәгән. Аспирантурага керү белән аны Ленинградка чакыртып алган. Мин беренче күргәндә Анна Емельяновнага егерме дүрт яшь иде. Ул да югары белемле. Укуны Ленинградта башлап, Казанда тәмамлаган. Педагогия институтын бетергән. Ике баласы булуга карамастан педагог булып эшләргә җыенып йөри иде.

Аня—мин аны үз итеп исеме белән генә атап йөртә идем—үзенекен итте. Ул Хәрби һава көчләренең махсус мәктәбендә укытучы булып эшли башлады. Балаларны карарга авылда яшәүче бер туган апасын чакыртып алды. Аның апасы да Анна исемле иде. Икесен бутамас өчен олы Аннаны Анюта дип йөрттеләр.

Анюта иллегә якынлашып килүче карт кыз иде. Ул кече күңелле, һәр эшне жиренә житкереп эшли. Намуслы, бик гади киенеп йөри. Өстендә ситса күлмәк, кышын-җәен сырма. Башка киемне күрергә дә теләми. Юк, бу пальто алырга хәле житмәгәннән түгел. Яшьтән шулай өйрәнгән. Картаеп барганда тышкы күренешенә үзгәреш кертергә теләми.

Үземнең төп темамнан читкә китеп, бу гаилә турында тәфтишләп язуымның сәбәбе шул: без алар белән шундый дуслашып киттек, хәзерге көнгә кадәр бертуганнар кебек яшибез.

Анатолий Никифорович 1954 нче елның көзенә кадәр педагогия институтында кафедра мөдире булып эшләде. Моннан тыш, кичке Марксизм-ленинизм университетында философиядән дәрес бирде.

Аның белән аралашу мине бик күп нәрсәгә өйрәтте. Ул системалы рәвештә миңа философиядән, сәнгатьтән, матур әдәбияттан китаплар биреп торды. Теләсәм, теләмәсәм дә мин аларны укырга мәжбүр булдым. Чөнки ул аларның эчтәлеген сөйләттерә иде. Тора-бара теге яки бу мәсьәлә буенча бәхәсләр оештыра башладык. Бу аңа бик ошый иде. Ул чын мәгънәсендә зур мәгълүматлы кеше иде. Миңа аның укымаган китабы юктыр төсле тоела иде.

Нигә шулкадәр якын күргәндер? Анатолий Никифорович минем өчен утка керергә әзер кебек тоела иде. Илленче елларның башында мин эшсез калдым. Райфода налог инспекторы булып эшли идем. Үземчә мин бик тырышып эшләгәндәй булдым. Нәтижәдә, мин хезмәт иткән участок районда гына түгел, шәһәрдә дә иң алдынгы санала иде. Шуңа карамастан, «Халык арасында налог сәясәтен үткәрүгә яраксыз элемент», дип таптылар. Ул вакытта горфо мөдиренең урынбасары булып эшләгән Касаткин фамилияле кешенең күрсәтмәсе нигезендә мине «кыскарттылар».

Минем эшсез калуыма Анатолий Никифорович чын күңелдән кайгырды, мине яклап горкомга кадәр барып житте. Әйтеп үтәргә кирәк, ул заманда философиядән дәрес бирүче кеше өчен бу гамәл гаять зур батырлык иде.

Кичке марксизм-ленинизм университетында дәрес биргәнлектән, Анатолий Никифорович горкомда, обкомда эшләгән иптәшләрнең күбесе белән якын таныш иде. Ярым надан, белемгә омтылышлары булмаган агач коммунистлар бу аңлы мөгаллимгә астыртын гына ярарга тырышалар иде.

1954 нче елның жәендә Анатолий Никифорович Казаннан китте.

Хәзерге вакытта Орел шәһәрендә яши. Күптән пенсия яшендә булуга карамастан институтта укыта.

Шулай итеп 1942 нче елны фронтта, Калиновка авылында башланган безнең дуслык гомерлек булды... Анатолий Никифорович безнең полктан киткәч тә, без Калиновкада шактый вакыт оборонада тордык әле.

Вак-төяк атышуларны исәпләмәсән, әллә ни искә алырлык сугыш хәрәкәтләре булмады. Ут сызыгында озакка сузылган тынлык көнелләрдә шик тудыра башлады. Шунадырмы, һәр сугышчы зур киеренкелек белән каршы якны күзәтте. Без инде кичәге маңка сарыклар түгел, барыбыз да тынлыктан соң булачак дәһшәтле давылны күз алдына китерә идек.

Бер көнне шулай, Макусинский белән мине штабка чакырдылар. анда безне бер лейтенант көтеп тора иде. Ул зур борынлы, кара бөдрә чәчле, тәбәнәк, юан гәүдәле, шыксыз бер адәм иде. Лейтенант салкын гына безнең сәламне алды да, «бераз сабыр итеп торыгыз», дип, каядыр чыгып китте.

—Моның кем икәнен беләсеңме?—дип сорады Макусинский.— Нишләмәкче була икән безнең белән.

Мин лейтенантны беренче мәртәбә күрә идем.

—Бесовая душа, шуны да белмисеңме?—диде Макусинский, бик гаҗәпләнеп. Аңа лейтенантның кем икәнен аңлатып торырга туры килмәде, безне ишек алдына чакырып чыгардылар. Анда капка төбенә полуторка килеп туктаган. Аның янында кулларын артка куеп, безнең штабной батарея сугышчылары—ефрейтор Иванов белән Мороз басып торалар иде. Аларның икесенең дә петлицалары ертып алынган, билләрендә каешлары да юк. Мин бик сәерсенеп аларга сүз куша башлаган идем:

—Сөйләшү тыела,—диде лейтенант бик җитди итеп. Бер атна чамасы элегрәк Иванов белән Морозны, бүген нәкъ безне чакырган кебек итеп штабка дәшеп алганнар иде. Шуннан соң алар бүгенгә кадәр беркайда да күренмәделәр. Без аларны башка берәр частькә күчерделәр дип уйлаган идек. Ул вакытта бик еш бераз белеме булган сугышчыларны кыска сроклы курсларга җибәреп, командирлар әзерләп чыгаралар иде. Иванов белән Мороз икесе дә югары белемле иде.

Лейтенант Мороз белән Ивановка машина кузовына менеп чүгәләп утырырга боерды. Аннан безгә мөрәҗәгать итеп:

—Хәзер китәбез. Дивизия штабына җиткәнче бу ике кеше өчен башыгыз белән җавап бирәсең. Әгәр качарга уйласалар, бернинди кисәтүсез атарга!—диде. Ул үзе кабинага кереп утырды. Без кузовка менеп кабина кырыена бастык.

Мороз белән Иванов үзләрен бик тыныч тоталар иде. Кыяфәтләренә караганда лейтенант безне кисәткәнчә качарга, яки нинди дә булса башка безгә каршы берәр начарлык эшләргә җыенмыйлар иде төсле.

—Һич төшенмим, нәрсә булды?—дип сорады Макусинский алардан шыпырт кына.

—Үзебез дә берни аңламыйбыз,—диде Иванов иңбашларын селкетеп.

—Юк гаепне тагарга маташалар. Дивизия штабында тикшерерләр. Тикшергәч бар да аңлашылыр,—диде Мороз зур ышаныч белән.

Хәтерем алдамаса, вакыт апрель азаклары иде. Бакчалар ап-ак чәчәккә күмелгән. Үзәнлектә, кап-кара күмер калдыклары арасында, яшел утрау булып калган Калиновка читтән караганда әкияти сихри авыл булып күренә иде.

Күпме вакыт инде, үлемнең күзенә карап, бергә сугыш кырында йөргән шушы ике иптәшнең мондый хәлгә калуын һич кенә дә башка сыйдырып булмый иде. Тегеләй дә, болай да уйлап бактым, ләкин уйларымның очына чыга алмадым. Ни гаебе бар икән соң бу ике яшь җанның? Ярамый торган берәр эш белән шөгыльләнгәннәрдер дип әйтер идем, һәрвакыт бергә булдык, андый кырын эшләрен сизгәнем булмады. Алар башкалардан шуның белән аерылып торалар, әз генә буш вакытлары булдымы, китап укыйлар иде. Тагын шунысы, һәр сугышчының игътиба-

рын җәлеп итәләр, политзанятиеләрдә бик еш политрук белән бәхәскә керәләр иде. Безнең хурлыклы чигенүләрнең сәбәбен эзләп, талашып китүләрен дә хәтерләдем. Әллә инде...

Террикон таулары арасында боргаланып-сыргаланып йөри торгач без Калиновкадан шактый ерак киттек. Бер калкулыкны узганда бара торган юлга снарядлар ява башлады. Күптән мондый көчле ут астына эләккәнебез юк иде инде. Күрәсең, немецлар бу юлдан чебен дә очырмыйлар иде ахры, (ә без сукыр черкиләр халәтендә) һәрбер узганбарганны каравыллап кына торалар. Снаряд төшеп ярылып, юл бөтенләй актарылып беткән. Чокырларның кайберләре шундый тирән, утыргач кеше күмелә.

Давыллы ут астында юлны дәвам итү ахмаклык булыр иде, әлбәттә. Шофер машинаны туктату белән, без бөтенебез дә машинадан төшеп, кем ничек булдыра ала, шулай, снаряд чокырларына яшерендек.

Артиллерия уты ун минут чамасы дәвам итте. Һаваны кара төтен басты. Дары исе тынны кыса башлады. Ату туктаган арада тирә-юньне каплаган кара төтенгә ышыкланып, тиз генә моннан чыгып ычкынырга кирәк иде. Без барыбыз да шул исәп белән яшеренгән урыннарыбыздан торып машина янына килдек. Көтелмәгән бәла туды. Лейтенантыбыз юкка чыкты. Үлсәң үл, ләкин аны ташлап китәргә ярамый! Аның белән берәр хәл булган булса, ачыкламый һич ярамый, үле гәүдәсен булса да табып алып кайтырга кирәк. Яраланган яки үлгән дип уйлар идек, якын тирәдә аның эзе дә юк.

—Бесовая душа, ул кая да булса, еракка йөгергәндер,—диде Макусинский. Аның сүзләре дөрес булып чыкты.

—Әнә ул,—диде Иванов, кулы белән арткы якка күрсәтеп. Лейтенант һаман әле кыр буйлап йөгерә иде. Шофер аның гадәтен яхшы белә икән.

—Ул монда кире әйләнеп киләчәк түгел, хәзер мин аның каршына чыгам,—диде. Ул кабинага кереп утырды да машинасын кабызып, лейтенантны куа китте. Без бик аптырап бераз басып тордык та, җәяүләп кенә алга атладык.

Без алар янына барып җиткәндә лейтенант хәлдән таеп машинаның уң як канатына утырып тора иде. Йөзе агарган, авызыннан чыккан сүзләрен аңлап булмый. Ул үзенең нишләгәнен белми, куркудан шул кадәр башы әйләнгән, безнең килгәнне күреп, руль артына утырды һәм машинаны кабызырга маташа башлады.

—Бу хайван, әллә безне калдырып китәргә чамалый инде?—диде Макусинский бик аптырап. Машинаның арт көпчәкләрен тикшереп йөргән шофер тиз генә кабина ишеген ачып лейтенантны читкә этәрде һәм рульне үз кулына алды. Без дә кузовка менеп кабина артына бастык. Мин үземнең кулга алынган ике кешене каравыллап баруым турында бөтенләй оныткан идем инде. Алар да хәзер үзләрен тоткын итеп сизмиләр иде булса кирәк. Миңа шулай тоелды. Машина бик кызу бара башлады. Юл чокыр да чакыр булганлыктан безне бик нык селкетеп, кузовның әле бер ягына, әле икенче ягына ыргыта иде. Без бер-беребезгә тотынышып идәнгә чүгәләдек. Мин шунда гына күреп алдым, снаряд ярчыгы тиеп, кузовның ике җиреннән тактасын сындырган. Ярый әле моторга, көпчәкләргә зыян килмәгән. Югыйсә снарядлар бертуктаусыз машина тирәсендә ярылдылар.

Бара торгач, куе булып үскән яшь урман кырыена килеп җиттек һәм шунда кереп туктадык. Урман эче хәрбиләр белән мыжлап тора иде.

Машинадан төшүгә, Иванов белән Морозны ике кызылармеец сак астына алдылар һәм бездән күз күреме җирдә куаклар астына куелган өстәл янына илтеп бастырдылар. Лейтенант та шунда юнәлде.

Иванов белән Морозны алып киткәч безгә бик авыр булды. Тирән уйга чумып, телсез-авазсыз калдык. Шулай ук бер дә тикшерми-нитми, җәзага тартырлар микәнни? Шушы уй туктаусыз безнең баш миен боргычлады.

Лейтенант бик озак торып, үзе генә әйләнеп килде. Ниһаять, Макусинский түзмәде:

—Егетләрне монда калдырабызмыни?—дип сорады. Шул вакыт агачлар арасында мылтыктан залп белән аткан тавыш яңгырады.

—Хәрби трибуналда тиз тоталар. Әнә хөкем карары үтәлде дә...

Лейтенантның тыныч, суык тавыш белән әйткән бу сүзләре безне аяз көндә яшен суккан кебек иттерде.

Шушы вакыйгадан соң күп тә үтмәде, безгә ут сызыгын ташлап китәргә приказ булды. Башта фронтның икенче участогына гына күчеребез дип уйлаган идек. Бактың исә бөтен фронт буйлап тагын чигенү башланган икән. Каядыр, Харьковмы, Славянский тирәсендәме, немецлар безнең оборонаны өзгәннәр. Узган ел көзге һөҗүм вакытында Изюм-Барвенко юнәлешендә барлыкка килгән «капчык»ның авызын япканнар һәм безнең армияләр чолганышта калган. Кыскасы, эшләр хөрти иде! Әйтүләренә караганда, безнең полк Калачкага таба чигенергә тиеш икән. Күп тә үтмәде, анда да чигенергә юл өзелгәнлеге турында хәбәр алынды. Аннан, Сальскийга чигәбез, диделәр. Анда да юл булмады. Йөри торгач Шахтинскийга, аннан Краснодарга барып чыктык. Краснодонда да тукталып торылмады, һаман артка тәгәрәдек. Шуңадырмы, Краснодон минем хәтердә калмаган. Бер рәткә тезелгән, акшарланган төссез бараклар гына күз алдына килеп баса.

Ниһаять, чигенә торгач Дон елгасы кырыена килеп чыктык. Туплар ут сызыгына урнаштылар. Безнең взводка полк штабын саклау бурычы йөкләнде. Иң элек тирән итеп җир казып, шунда штабны йөртә торган машинаны кертеп яшердек. Аннан үзебезгә окоп казыдык.

1940 нчы елда армиядә хезмәт итә башлагач, безнең полк, Кубаньда, Саратовский станицасы янындагы лагерьда торганда көн саен хәрби өйрәнүләр үткәрелә торган иде. Шул хәрби өйрәнүләр вакытында окоп казудан да авыр эш юк иде. Җир шундый каты, берничек тә көрәк кертеп булмый. Өстән бер көрәк кара балчыкны алгач сәер катлам башлана: лом да, балта да керми. Бу җирне казуга караганда таш вату җиңелрәк иде. Соңыннан белдек, бу тирәләр кайчандыр диңгез астында булган икән һәм мең еллар буе дәвам иткән су басымы аны шулай ныгытып калдырган.

Мин монда, Дон буенда да шундый ук, су белән басылган, казып булмый торган җирдер дип курыккан идем. Алай булмады тагын.

Без Макусинский белән икебезгә бер окоп казыдык. Окоп тирәнлеге бил тиңентен булгач, мин көрәкне читкә ыргыттым:

—Җитәр,—дидем,—файдасыз хезмәткә көч әрәм итмик, озак торырга туры килмәс.—Макусинский риза булмады:

—Ялкауланма, казыйк әле, казыйк,—диде. Минем күңел нәрсәгәдер хәвефләнде...

Безне немец танклары эзәрлекли иде. Минут саен аларның килеп чыгулары мөмкин иде. Бөтен полк зур киеренкелек белән танк һөҗүме көтә.

Мона кадәр күрелмәгән һава һөҗүме башланды. Иртәдән кичкә кадәр немец самолетлары баш очында уйныйлар. Шулкадәргә барып житте, хәтта аерым сугышчыны куып йөри башладылар... Күңел өчен ник безнең бер самолет күренсен!

Полк урнашкан урын Донның уң ягында, тигез, ачык җир иде. Маскировка ясарлык агач яки куаклар да юк. Үлемнән бары, тирән итеп җир казып, чокыр эчендә генә сакланырга мөмкин иде.

Бер көнне, һавадан көчле бомбага тотканнан соң, танклар күренделәр. Аларга каршы безнең батареялардан ут ачтылар. Һөҗүм итүче танкларның исәбе-хисабы юк иде. Танклар белән батареялар арасында дуэль озак дәвам итте. Көчләр бер дә тигез түгел иде. Һәрбер батареяга дистәләгән танк һөҗүм итте!

Без дә, штабны саклаучылар да, бар булган корал белән танкларны

каршы алырга җыендык. Коралыбыз—танкка каршы гранат һәм янучы сыекча тутырылган шешәләр. Төш вакыты җитәрәк танклар икенче дивизионның беренче батареясын таптап үттеләр һәм безнең окопка таба юнәлделәр. Мин аларны күреп югалып калдым. Нишләгәнемне белмичә танк гранатасына тотындым һәм аны ыргытырга җыендым. Макусинский мине иң башыма басып окоп төбенә утыртты.

—Бесовая душа, ашыкма!—диде ул тешләрен кысып. Аның ут кебек янган күзләрен күреп мин айнып киттем.—Гранаталарны әрәм итәргә ярыймы соң?! Алар санаулы гына...

Әйе, мин ыргыткан гранат танкларга тиячәк түгел иде. Чөнки алар шактый ерак! Гранат танкка тигән очракта да, ул шартлаганнан аңа бернинди зыян киләчәк түгел. Гранатаны тыныч кан белән, танкның кай җиренә, ничек эләктерергә икәнен белеп ыргытырга кирәк!

Танклар окоп кырыена ук килеп җиттеләр һәм берәм-берәм безнең окопларны изеп уздылар. Яртылаш балчыкка күмелдек. Макусинский җитез генә сикереп торды да безнең өстән узган соңгы танкның артына, мотор турысына янучы сыекча тутырылган шешә тондырды. Секунд эчендә аңа дөрләп ут капты һәм шырпы тартмасы кебек яна башлады. Танк кинәт туктап калды һәм эчендәге кешеләр җиргә сикерделәр. Мин аларга автоматтан ут ачтым. Шул арада икенче танк туптан ата-ата, зур тизлек белән туп-туры безнең окопка юнәлде. Ул килеп тә җитте, безнең окоп өстендә зырылдап әйләнергә дә тотынды: менә кайчан кирәк булды Макусинскийның нәрсә буласын алдан сизеп, окопны тирән итеп казытуы! Әгәр окоп тирән булмаса без коймакка әйләнә идек. Мин җиргә сеңәрлек булып окоп төбенә елыштым. Ләкин никадәр куркыныч булса да үлем турындагы уй башыма да кереп карамады. Гомумән, әйтеп үтәргә кирәк, менә кадәр дә, моннан соң булып узган тагын да куркынычрак хәлләрдә дә мин үлем турында уйламадым. Хәзер шул куркыныч вакытларны күз алдына китерәм дә, ничек исән калуыма ышанмыйм. Мөгаен, монда үлем турында уйламауның да роле булгандыр дип фикер йөртәм. Күрәсең, сугыш кырында батырларча һәлак булган ялкынлы патриот шагыйрь Фатих Кәрим үлем турында уйламауның хәлиткеч ролен шул вакытта ук ачык сизгән булган.

Нәрсә турында гына уйланылмады шул күптонналы танк астында яткан берничә секунд эчендә! Курку шул дәрәҗәгә җиткән: бернәрсә белешмичә уйларымны Макусинскийга сөйли башлаганмын булса кирәк. Ул бик дорфа итеп «заткнись, бесовая душа» дип акырды.

Танк безнең өстән узып, бераз алга китүгә, Макусинский минем кулдагы гранатаны тартып алды. Минем белер-белмәс ыргытып соңгы гранатаны әрәм итүемнән шикләнде ахрысы. Әйе, ул үзе бу җәһәттә нык ук чосланган иде, ыргытуы булды, танкка ут капты.

Тирә-як янган танклар, ватылган туплар, шуларны тартып йөрүче җимерек тракторлар белән тулды. Бертуктаусыз кабатланган шартлаулар колакны тондыра, майлы төтен исе тынны кыса.

Безнең окопка бер кеше сикереп төште. Өстендәге гимнастеркасының иң башлары ертылган, бите кара корымга буялып танырлыгы калмаган. Бу безнең топовзвод командиры инженер-капитан Голумба иде. Ул бик ашыга иде:

—Донның теге ягына чигенәбез, матчастьне чыгарып җибәрдек, җыелу пункты Ольгинская станицасының төньяк кырые,—дип әйтте дә уң яктагы икенче окопка йөгерде.

Без беренче мәртәбә арт ягыбызга борылып карадык. Анда бездән ярты километр чамасы ераклыкта Дон елгасы ага иде. Агым уңаена, бераз бездән түбәнрәк—кичү. Ул тирәдә мәхшәр. Ата улны, ана кызны белә торган түгел. Бары да буталган. Кинәт көчле шартлау ишетелде һәм понтон күпер күккә очты. Күперне безнекеләр шартлатты. Немец танклары килгән кызулык белән елганың теге ягына чыгып китәчәкләр иде.

Без Макусинский белән бер-беребезгә карашып алдык та елга буена

ашыктык. Су өсте аргы якка йөзеп чыгучы кызылармеецлар белән тулган иде. Без дә килгән кызулык белән суга сикердек. Мин йөзә белми идем. Аннан соң да йөзәргә өйрәнгәнем булмады. Дөрес, бала чакта җәй буе инештә су коена торган идек.

Язлыкта авыл халкы җыелып инешне буып куя торганнар иде. Шулай буып язын суны җыеп калмасаң, инеш бөтенләй кибә. Без бала-чага шул буа суында иртәдән кичкә кадәр аунап ята торган идек. Буаның иң киң җире бик күп булса дүрт-биш метр булгандыр. Мин шул дүрт-биш метр араны тончыгып пырхылдый-пырхылдый көчкә йөзеп чыга торган идем. Дөрес, Дон безнең Идел кебек киң елга түгел. Шулай да пароходлар йөри торган елга. Хәзер һич күз алдына китерә алмыйм, Донны йөзеп чыктым бит! Ничек диген әле. Кулда автомат, индә камыт итеп кысып төрелгән шинель. Өстән бертуктаусыз пуля ява. Әлегә кадәр үземә-үзем ышанмыйм, нинди көч мине шул вакытта йөзәргә өйрәткәндер, һич анларлык түгел! Минемчә, бу үлем ачыргысы белән соңгы мөмкинлекне җигеп эшләнгән эш булырга тиеш.

Елга аша йөзгәндә без Макусинский белән аерылганбыз. Икенче якка чыккач күпме эзләсәм дә яр буенда мин аны таба алмадым. Мин агым уңаена йөздем, ул күрәсең турыга сыптырган. Башта әллә берәр хәл булганмы дип шикләнгән идем, шикләнүем юкка булды, соңыннан без аның белән очраштык.

Мин елганы йөзеп чыккач яр кырыенда тукталып тормадым әлбәттә, кая барганымны үзем дә белми әле мүкәләп, әле шуышып алга таба ыргылдым. Бераз баргач тимер юл кырыена килеп чыктым. Шунда ук зур станция башланды. Аны бик каты бомбага тотканнар. Янган, җимерелгән вагоннарның исәбе-хисабы юк.

Минем атна буе рәтләп йоклаганым һәм тамакка җүнле ризык капканым юк иде. Аруым чиктән ашты. Аякларга гер таккан кебек булды, көчкә атлап йөрим. Сөйрәлеп бара торгач кырыйдагы бер вагонга күзем төште. Бу шәһәр яңы пассажир поездларына тагылып йөртелә торган вагон, составтан бер үзе исән калган булырга тиеш. Ник дисәң, шул тирәдә генә шундый ук җимерек вагоннар һәм яртылаш янган паровоз арасында бердәнбер бөтен вагон. Хәзер хәтерләмим, нәрсә уйлаганмындыр, шул вагонга барып кердем. Вагонның урындыклары алынган, буйдан-буйга өстәл куелган. Өстәл өсте тулы ризык. Бу нигъмәтләр кем өчен әзерләнгәндер, кызыксынырга вакыт булмады. Өстәл янында бөтен дөньясын онытып бер сугышчы утыра. Ул алдына шампанское, коньяк шешәләре тезеп куйган. Закускага җаның ни тели, бары да бар! Ни гаҗәп, өстәл янында утыручы сугышчыны мин күрү белән таныдым. Ул—армиядә беренче көннән алып минем белән хезмәт иткән Женя Сухов иде. Хәтта без аның белән икебез бер отделениедә идек. Дус яшәдек. Ул армиягә авылдан алынган. Туган авылы Тамбов өлкәсе, Моршанский районында, Нащукино исемле иде. Сөйләвенә караганда алар авылының бер ягында руслар, икенче ягында татарлар яшиләр икән. Женя бер татар кызын яратып биһуш булып та йөргән. Женя армия хезмәтеннән кайткач, чын-чыннан аңа өйләнергә җыенып йөри иде. Бер дә онытасым юк, ходай гафу итсен, мин аңа бер этлек эшләргә дә өлгердем. Ул миннән бик үтенеп, үзе булып татарча хат язуымны үтенде. Шулай итеп сөйгән кызын шаккатырырга теләде. Мин хатны язуын яздым, Женя Сухов булып яздым. Ахырдан шайтан котырттымы, Иблисме, үземчә бик акыллы кыланып «Женя сине бик ярата, синен белән тормыш корырга тели. Ләкин син бервакытта да үзеңнең татар кызы икәненне онытма. Бергә тора башлагач, балаларыгыз булыр. Балаларыгызга үзебезчә, татарча тәрбия бирергә тырыш!» дип язып куйдым. Кыз җавап хатында минем бу этлек турында Женяга хәбәр итте, әлбәттә. Женя әйбәт егет булып чыкты, миңа һич кенә дә үпкәләмәде.

—Әгәр өйләнешеп бергә торырга туры килсә, үзем татарча өйрәнәм!— диде житди итеп.

Женя да мине күрү белән таныды.

—Касымыч,—дип урыныннан сикереп торды.—Ул мине шулай әтием исеме белән атап йөртә торган иде. Без аның белән кочаклашып күрештек.

—Нинди язмыш монда килеп чыктың?—дип сорады ул.

—Ә үзең монда нишләп утырасың?

Безнең полктан урта белемле берничә егетне кыска сроклы командирлар курсына җибәрделәр. Женя да шулар белән киткән иде. Аларның полктан киткәненә өч ай чамасы бар иде инде. Шуннан бирле безнең аның белән хәбәрләшкәнебез юк иде. Аларның курслары, хәзер төгәл хәтерләмим, кайдадыр фронттан ерак түгел, Харьков тирәсендә кечкенә генә бер шәһәрчектә булган. Немецләрнең язгы һөҗүме башлангач курсларны таратып, курсантларны шул тирәдәге өзеклеккә китереп тыкканнар. Женяның сөйләвенә караганда, аларга җүнле корал да бирмәгәннәр. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан коралланудан алып ташланган иске винтовкалар тоттырганнар. Аннан: «яхшысын дошманнан сугышып алыгыз», дигәннәр.

—Менә шулай коры кул белән немецләргә күрмәгәннәрен күрсәтәбез!—диде ул, күз яше аралаш елмаеп.

Женя Донны кичкәндә иптәшләреннән аерылган. Алар белән кайда очрашасын да белмәгән. Мин аны үзем белән алып китәргә уйлаган идем дә, ул якын да килмәде.

—Бер китеп, бер кайтып йөрүне яратмыйм!—диде горур гына.—Үзебезнең курсантларны эзләп табам.

Мина ашыгырга бик тә кирәк иде. Күзгә ни күренсә, шуны хаптхоп йоткалап, әз-мәз сыйландык. Югыйсә минем дә үзебезнекеләрдән аерылып калу ихтималы бар. Фронтта үз частеңнән аерылып калсаң, авыр хәлгә төшәсеңне көт тә тор!

Суховның күнеле төшенке иде. Минеке дә. Без кочаклашып аерылыштык...

Мин үзебезнекеләрне эзләп шактый озак йөрдем. Ольгинская станицасы хәрбиләр белән тулы иде. Кемнән генә сорама, берсе дә рәтләп җавап бирми. Һәркемнең үз хәле хәл. Бөтенләй өметне өзгән идем инде. Станица кырыендагы ярым җимерек хата янында үзебезнең штаб машинасын күреп алдым. Алар машинаны кабызганнар, китәргә җыенып маташалар иде. Мине күреп Макусинский шундый шатланды, машинага кулдан тартып менгезеп, үзе янына утыртты.

Сөйләүләренә караганда, без монда тагын немец тылында «утырып» калганбыз. Бездән уң якта, алар, кайдадыр, Сталинград тирәсендә һөҗүм итәләр, ә сул якта Ростов аша Донны кичеп Майкопка барып җиткәннәр.

Ольгинскаядан кузгалып китү белән безнең нык сыекланган колоннаны бик каты бомбага тоттылар. Бомбага тоту вакытында берничә сугышчы яраланды, гаубицаларны өстерәп йөрүче ике трактор сафтан чыкты. Безнең эш бик мөшкелләнде. Чөнки йөз егерме ике миллиметрлы озын көпшәле еракка ата торган гаубицаларны бары ЧТЗ тракторлары гына тартып йөри ала иде. Күп маташа торгач каяндыр, немецләрдән трофей итеп алынган тягачлар табып алып килделәр. Шуннан соң гына юлны дәвам иттек.

Беркөнне шактый вакыт Мечетлинская дигән станицада туктап тордык. Урамнарда кешене әйткән дә юк, эт тә күренми иде.

Билгеле булганча, Октябрь революциясеннән соң Кубань казакларының күпчелеге аклар армиясенә ияреп советларга каршы сугышкан. Без колхоз яшьләре мәктәбендә укыганда, тарихтан дәрес бирүче Әнвәр абый Кубаньны икенче төрле итеп, бөек француз революциясе вакытында, революциягә каршы көрәш алып барган Франциянең Вандея өлкәсенә тиңләп, «советская Вандея» дип атый торган иде. Чыннан да, озак вакытлар революцияне кабул итмәгән Вандея халкы кебек, Кубань казакларының да революция тудырган үзгәрешләрне кабул итәсе килми. Бай казаклар ак армия тар-мар ителгәч илләрен ташлап чит илгә китәләр һәм эмиграциядә яшиләр. Кубань халкының бер катламы ашкынып шуларның

кире кайтуын көтә. Шушы халыкның безгә начар күз белән караганы әллә каян сизелеп тора иде. Дөрес, алар ачыктан-ачык безгә дошманлыкларын сиздерергә кыймадылар.

Полк тагын бертуктаусыз артка «тәгәри» башлады. Көне буе күктә немец самолетлары оча. Алар безне шундый эзәрлекли, җир ярылса җир тишегенә кереп яшеренерлек булабыз.

Төньяк Кавказның табигате шундый матур, тел белән генә сөйләп аңлатырлык түгел. Юл буйларында ике яклап җимеш агачлары үсә. Офыкта, томан эчендә, серле булып ак кар каплаган тау башлары күренә. Бер тау калганнарыннан аерылып тора, ул шундый биек, башы болытка тигән. Елгаларда көмеш төсле салкын су ага. Елга кырыеннан башланган болыннарны чәчәк баскан. Нинди генә юк аларның!

Җиләк-җимеш өлгергән вакыт иде. Мин абрикос белән тукланып тора башладым. Чиләк тутырып җыям да, көне буе шуны ашыйм.

Чигенә торгач без Адыгей автономияле өлкәсенә килеп җиттек һәм Майкоптан ерак түгел Кашехабель дигән зур авылда туктадык. Көн кичкә таба иде. Тупларны, машиналарны җиләк-җимеш бакчалары эченә кертеп, агачлар астына яшердек. Немец самолетлары югалып торган арада бераз ял итәргә исәпләп, тиз агышлы тау елгасына ябырылдык. Көне буе, рәхимсез эссе Кавказ кояшы астында пешеп, ахыргы чиккә кадәр талчыккан кызыларамеецлар, кайсы котелек, кайсы пилотка белән су эчәргә тотынды. Су шундый тәмле, эчеп туярлык түгел!

Минем бик күптәннән кырынганым юк иде. Битне баскан тимерчыбык төсле каты, сары сакал чиркандырып, эчне пошыра. Тиргә майланып, тузанга каткан сакалны көч-хәл белән җебетеп кырынырга тотындым, немец козгыннары шуны гына көткәндәй, ыжгырып килеп тә җиттеләр. Берничә минут эчендә авылның асты өскә килде. Күп йортларга ут капты. Тирә-юньне кара төтен басты.

Самолетлар күздән югалуга авылны ташлап китәргә приказ булды. Ниндидер Красный Кот дигән хуторлар янына барып чыктык. Хуторда иксез-чиксез күп машиналар җыйналган иде. Бары да яңалар һәм безнең машиналарга һич тә охшамаганнар, бик зурлар. Аларга яңа төзелгән мотобригада сугышчылары утырган. Шундагы кешеләрдән сорашып белдек, безнекеләр бу машиналарны Америкадан алганнар икән.

Безне йөртә торган топовзвод машинасына полкның партбюро секретаре, батальон комиссары Шилов килеп утырды. Ул шундый йончыган, аягында көчкә басып тора.

Кашехабельдән киткәндә комиссар немецләр кулына эләгә язган. Алар утырып барган машинага фашист разведчиклары һөҗүм иткән. Көтмәгәндә, ике арада башланган сугыш вакытында машиналары янган, шофер һәлак булган. Немецлар да тиешле җәзаларын алганнар, ике солдатлары үтерелгән, калганнары качып котылган. Комиссар үзенең сугышчылары белән частькә җәяүләп кайткан. Аның сөйләвенә караганда без хәзер тагын чолганышта калган идек.

Ул безнең машинага килеп утыргач минем башка бер уй төште. Мин күптәннән партиягә керергә әзерләнеп йөри идем. Әллә кайчан гаризасын да язып куйган идем. Гариза күптәннән минем сумка төбендә йөри иде. Шуны тиешле кешесенә тапшырырга һич уңайлы вакыт туры китереп булмый иде. Мин партбюро секретареның безнең машинага килеп утыруыннан файдаланып калырга булдым. Рекомендацияләрем дә бар иде. Мин аларны Калиновка авылында оборонада яткан вакытта әзерләп куйган идем.

Мин Шилов белән сүзне бик ерактан башлап җибәрдем. Ул заманда барыннан да элек кешенең социаль чыгышы тикшерелә иде. Социаль чыгыш ягы минем яхшыдан түгел иде. Дөрес, минем әти үз гомерендә бервакытта да яллы хезмәтче тотмаган, байлыгы да телгә алып сөйләрлек түгел: бер ат, бер сыер асрап, урта хәлле крестьяннар белән бергә иген иккән. Иген игү белән бергә бөтен гомере буе муллалык вазифасын

үтәгән. 1936 нчы елны безнең семья колхозга керде. Ләкин әти муллалыгын ташламады. Үлгәнче, 1954 нче елга кадәр дин йолаларын үтәп килде.

Мин партбюро секретарена беренче чиратта әтием турында бәйнә-бәйнә сөйләдем. Минем барысын да яшерми сөйләп бирүем ана ошады булса кирәк, ул минем гаризаны бик теләп кабул итте. «Молодец!» дип мактау сүзләре дә әйтеп алды.

Мина гаризамның шуннан соңгы язмышын белергә туры килмәде. Шул төнне пленга эләктем һәм фронтта күргәннәрдән дә яманрак хәлләрне баштан үткәрергә туры килде.

Хәзер исемен хәтерләмим, Красный Кот хуторларыннан ерак түгел зур бер станица бар иде. Төн урталарында шул станица тирәсендә машина гөрләгән бик көчле тавыш ишетелде. Алар билгеле бер вакыт саен фараларын кабызып безнең якка килә торган юлны яктыртып алалар иде. Аларның болай юлны яктыртып торулары барыбызның да күнелендә шик тудырды. Шунда барып аларның кем булуын ачыклап кайтырга кирәк иде. Батальон комиссары безнең топовзводтан өч сугышчы сайлап алды да шуларга мине өлкән итеп билгеләде һәм станицага разведка ясап кайтырга боерды.

Без—дүрт кеше—таш түшәлгән олы юл буйлап станицага таба юнәлдек. Төн шундый караңгы, күзгә төртсәләр дә күренә торган түгел. Станицага барып житәрәк, әллә безнең килгәнне күреп, ракетадан атып баш очына фонарь элеп куйдылар. Шул фонарь янып беткәнче юл буенда канауга ятып, яшеренеп торырга туры килде. Шул вакыт юл буйлап безгә каршы килүче машиналар тавышы ишетелде. Без юлдан шактый читкә чыгып, озын булып үскән кукуруз арасына кереп постык. Машиналар безнең турыга килеп житкәч туктап калдылар. Андагы немец солдатларының сөйләшүләре безгә аермачык ишетелә башлады. Алар русча сөйләшәләр иде.

—Болар безнекеләр бит!—диде Среда фамилияле сугышчы.

—Сөйләшүен безнечә сөйләшәләр үзләре, ләкин машина моторларының гөрләве бер дә безнекеләргә ошамаган,—диде Канапий.

—Бәлки Америкадан килгән машиналардыр,—дидем мин. Аларны кукуруз арасында калдырып машиналар янына киттем. Мин туп-туры алдагы машина янына килдем. Машинаның кузовы брезент белән капланган, андагы кешеләрне күрә торган түгел. Кабина эчендә русча сүгенгән сүзләр ишетелде. Бу сүгенүне ишеткәч сөендем, машинаның безнеке булуында шигем калмады. Кабина ишеген ачтым да:

—Әллә нинди ят машиналарга утырып кеше куркытып йөрисез, үзебезнекеләр икәнсез лә!—дип, аларны табалый башладым. Ләкин сүземне әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр, дәррәү кузовтан сикереп төштеләр дә, кулларымны артка борып бәйләп куйдылар.

—Машинада немецлар! Качыгыз тизрәк!—дип кычкырдым мин бар көчемне жыеп.

Авызга суктылар һәм бернichә кеше аяктан-кулдан тотып арттагы икенче машинаның кузовына ыргытты. Мине кузовка салуга машина кузгалып та китте. Бары да шундый тиз эшләнде, нәрсә булганын аңлап та өлгермәдем. Русча сүгенгәнне үз колагым белән ишеттем бит, аермачык ишеттем! Немец алай чиста русча сөйләшә алмый. Әллә немец армиясендә руслар да бар микән? Мин бу сорауга шактый вакыт үткәч кенә жавап таптым. Машинаны йөртүче шоферлар әсир төшкән руслар булган икән.

Минем авызга каты тондырганнар, иреннәр бүртеп чыкты. Бер тешем дә сынган, авыз эче кан белән тулды. Барыннан да бигрәк шуңа бик гажәпләндем, кузовта мин бер үзем идем. Шундый ачуым кабарды, әгәр мөмкин булса машина белән бергә шартларга әзер идем. Кирәк бит шушы кадәр ахмак булырга! Немец кулына үзен килеп кер инде!

Мин күп уйлап вакыт уздырмадым, соңгы тизлек белән барган машинадан жиргә сикердем. Шуннан соң нәрсә булганын хәтерләмим. Аңыма килгәндә ачык кырда, тирә-ягы чәнечкеле тимер чыбык белән

әйләндереп алынган лагерьда, җирдә ята идем. Башымны күтәреп тирә-якка күземне йөртеп алдым, энә төшәрлек урын да юк, лагерь эче халык белән тулы. Кайсы яткан, кайсы утырып тора. Мин дә торып утырмакчы булдым, ләкин көчем җитмәде. Эчәсе килүдән авыз кибеп, телем аңкавыма ябышкан. Өстәвенә кояш рәхимсез кыздыра. Вакыт август азаклары иде. Кубань җирендә җәйнең бу ае аеруча кызу була.

—Су,—дидем мин ачыргаланып. Миңа җавап бирүче булмады. Тешем-не кысып ыңгырашмаска тырыштым. Су турында онытырга, онытырга кирәк. Монда, ачык кырда үлсәң дә су бирәчәк түгелләр. Ничек соң әле мин бу җиргә килеп эләктем? Ирексездән бала чагымда әниемнән ишеткән мәхшәр көнен күз алдына китердем. Монда нәкъ шул әнием сөйләгән мәхшәр көнендәгечә. Ашарга да, эчәргә дә бирүче юк. Илле градуслы кояш кызуы астында күккә күзне текәп, язмыштан мәрхәмәт көтеп утырырга туры килә.

Бер генә минутка булса да үземне онытып торырга теләп узганнарны күз алдына китерергә тырыштым. Машинадан сикергәч минем белән нәрсә булган—һич тә искә төшерә алмадым. Гоман итүемчә, башым белән ниндидер каты әйбергә бәрелгән булырга тиешмен. Маңгаемда зур шеш бар иде. Аңымны җуеп күпме ятканмын, анысын бер алла белә. Күрәсең, сугыш кырында ятып калган яралыларны җыйганда ниндидер мәрхәмәтлесенә тап булганмын. Яралы сугышчылар белән бергә, мине дә шушы лагерьга алып килгәннәр булса кирәк. Гадәттә, фашистлар авыр хәлдәге сугышчылар белән маташып тормыйлар, шул урында, бер пуля белән эшне бетерәләр иде. Әсир калган кызылармеецларның барысы да дип әйтерлек яралылар иде. Бу минем үземнең монда ничек килеп эләгүем турындагы фикерне раслаучы бер факт иде.

Уң ягымда битен кара сакал баскан бер әсир утырып тора. Чиктән тыш газаплануымны күреп кызганып куйды күрәсең.

—Артыгын бирә алмыйм,—мә, бер генә йот,—диде флягасын авызыма китереп.

Су белән иренемне чылатып алгач миңа җиңел булып китте. Көтмәгәндә күрсәтелгән бу ярдәм бераз күңелемне күтәрде. Шулай итеп, егерме ике яшемдә мин явыз дошман кулында тоткын булып яши башладым.

Тоткындагы тормышым турында 1968 нче елны басылып чыккан «Йолдызлар шаһит» дигән повестьта язылган. Повесть илленче еллар азагында ук язылган иде. Озак вакыт дөнья күрә алмый ятты. Рәхмәт Атилла Расихка, аның ярдәмендә китап укучылар кулына барып керде.

Тоткынлыкта, бернинди кыенлыклар белән исәпләшмичә, мин иҗат эше белән шөгыльләндем. Чүплектән табып алган кәгазь кисәкләренә шигырьләр яздым. Лагерьдан качкан өчен төрмәдә утырганда күбесе юкка чыкты. Шулай да бер өлешен үзем белән Казанга алып кайттым. Төп нөсхәләре әле дә исән. Ул шигырьләрне озак вакыт матбугатта чыгара алмадым.

Дөнья башлыча, яхшы кешеләрдән тора икән. Шулай булмаса тормыш та алга бармас иде. Мәңге онытасым юк: Сибгат Хәким һәм мәрхүм Әнвәр Давыдов ярдәме белән бернична шигырем 1957 нче елны рус телендә чыккан татар совет поэзиясе антологиясенә кертелде. Әсирлектә булуымны сәбәп итеп, антологиянең татарчасына мине якын да китермәделәр.

Әсирлектә язылган шигырьләрем 1958 нче елны «Кыен юл» исеме белән китап итеп чыгарылды. Бу җыентыкның чыгуы өчен мин шагыйрь Хисам Камаловка, бары ана бурычлы. Укучылар тарафыннан җыентык җылы каршы алынды. Уфада чыга торган «Кызыл таң» газетасы аның турында: «Муса Җәлил шигырьләре белән аваздаш» дип язды. Бүгенгә кадәр, әсирлектә язылган шигырьләремнең тулысы белән дөнья күргәне юк. Бәлки, алар белән кем дә булса кызыксыныр әле...

*1980 ел.*

# ШИГЪРИЯТ



## Роберт Әхмәтҗан

### ЮЛДАГЫ КЕШЕЛӘР

❂

Озын-озак юл алдыннан кешеләр,
кошлар кебек, өметләрен барлап,—
канат кагыналар,
зур юллар алдыннан
өметләрен барлап.

Тәвәккәллек—байрак!
Буран-яңгырларда,
циклоннарда,
тугыз баллы дулкын өсләренә
китә кешеләр,
гарасатка...

Парашюты ачылмаган килеш
төшкән десант кебек,
төшә карлар
олы юл өстенә...

Юлдагы кешеләрнең язмышы—юл.
Һәр даим—адым, адым артлы—адым,
уй, өмет, тагын өмет—
гүзәллеге юлдагы кешеләрнең...

Тәвәккәллек—сыйфаты көчлеләрнең.

Адым саен офыкны үзенә тартып,
бара алар.
Юлдагы кешеләр—юлга бирелгән.

Һәр адымга

үзе түли Вакыт.

И, ерак соң моннан унсигез яз,
Шунда шаулый нәни тирәгем...
Әйткән сүзем ишетелми, анда
барып җитә алмый йөрәгем!

Адымнарым—төштә чапкан сыман—
бер урында! Җирне тоймыйлар...
Шул кырларның кыл бер турысында
сагына мине шигъри тойгылар!..

Болыт сыман алар—ява алмый,
күкрәр була—чыкмый тавышы...
Әнә шулай йөри, китә хыял
яшьлек кырларына авышып...

Инде моннан ерак унсигез яз,
тукталсаң да була бер тынга.
Рәхәтләнеп кара: синсез дими,
чәчәк атып ята ул кырлар!

Йотылып карыйм язгы эңгер аша,
карашымны киңлек йотса да.
Өметләрем анда баш чыгара,
хыялларым—утыра тупсага!

Язгы эңгер аша йотылып карыйм
сыек зәңгәр таулар артына:
ашкынулар анда—йөрәк кага,
ярсуларым—утыра акылга!..

Офык артларында унсигез яз—
тукталсаң да ярый бер тынга:
Шушы үрдән генә күренеп калыр—
ераклашкан җырын бер тыңла!

Син—Матурлык, Сөю шаһинәсе,
Җир кызысың—ике аяклы...
Тик күзләрең генә күктән бугай,—
Хәтерләтә йолдыз-маякны.

Кая сыйган диңгез-мәхәббәтең,
Шул күкрәкме аны сыйдырган?
Мәхәббәтең Җәннәт бакчасының
Ал гөлләрен кемгә җыйдырган?

Сөю бакчасына кергән чакта
Алма төште кемнең башына?
Кем дип сайрый синең сандугачлар?
Килүләрең кемнәр каршына?..

Моңсуланып багам эзләреңә
(Ник уяна сәер көнчелек?)
Ходай сине камил яраткан шул,—
Ник салмаган мыскал кимчелек?..

Иреннәрең—кызыл кына! Җирдә
Бармы икән синең тиңнәрең?
Ап-ак муеның—шәфтал хушбуйлары,
Сулышларың—диңгез җилләре!..

Аһ, назлардан инде уздым, ахыры,
Кемдә юктыр андый үкенеч?
Яшел кыякларда чыклар яна,
Син, назлы җан, аккош сөтен эч!

Соңласам да инде туйларыңа,
Йөрәгемне тотык иттең ич!..

Көчле токым! Сезләр ир-егетне
Патша ясый, кирәк тапсалар.
Аргамактан егылып төшкән сыман,
Хатын-кыздан
Очып төшкән күпме патшалар!..

## Ак күкрәү

Озын җылы көздә, ак күкрәүдәй
Шаулап чәчәк атты шомыртлар!
Көньягына очып барган кошлар күлгә төште—
Кыйблаларын, ахыры, оныткан...

Иркенәеп, күккә җәелделәр
җылы сөткә тулыш болытлар!
Туган көнем онытмаган кебек,
Бу көзне мин һич тә онытмам...

Юнәлешен үзгәртте дә җилләр,
Көзем калды кара көз булып.
Ак болытлар сипкән җылы яңгыр
Килеп төште җиргә боз булып.

... Гомер агачында
минем дә көз.
Шомырт чәчәгедәй чәчләрем.
Соңлап килгән мәхәббәттән, ачылып,
Күзләреңә багып яшьнәдем!

Гомернең бу тик мизгеле иде,
чыкты сулар ярдан аркылып...
Мин яшеннәр аша очып үттем,
Күңел кояшыңа тартылып!..

... Менә җирдә инде. Ак һәм кара:
Җир өстендә ап-ак кыш тора.
Бар да—артта...
Алда—синсез генә
Яшәү дигән
бөек эш тора!..

## Борынгы көйгә

Чәчтек тә без бодай, бирде Ходай,
Вак иләкләр кирәк иләргә.
«Заманалар авыр», булыйк сабыр,—
Уйланып ла кирәк сөйләргә.

Кыл күпердән ары чыгасы бар,
Кичәселәр бардыр Сиратны.
Чор болгавыр. Әмма бозмый беркем
Сиратларга барыр чиратны.

## Төсле төш

Сабыйчакны күрдем төшемдә...
Шул төсле төш
һәрчак исемдә...

Имеш, безнең урам—Өчиледән
төшеп килә мичче Мөбәрәк.
И бабам яшь, әле исән икән,
үзе кәләч, йөзе түгәрәк.

Ә артыннан төшә безнең Мохтар,—
әллә чабып, әллә тәгәрәп,
ара-тирә җилгә өргәләп...

—Син авылны, ахыры оныттың, дим,
сукмыйсың син безне санга да.
—Эшләр тыгыз, кызыл балчык мулдан,—
мич чыгарам, олан, анда да...

Вак яңгыр тора сибәләп,
тамак кырып мичче Мөбәрәк,
яшьлегенә кайткан кебек уза
авыл урамына, түргәрәк.

Ул кызмача, имеш, мич чыгарып
кайта керәшеннән, марҗалардан...
Аның хөрмәтенә авылымда
төтен чыга бөтен морҗалардан!

## Сурәтең

Килде ул көн: сине энекәшеңнән
чыгардылар ятлар чакыртып...
Кияү белән кәләш утырган ат
Арт урамнан үтте чаптыртып!

Озак йөрдем чатта, сагышлардан
Булмаганны җирдә таптыртып...
Карар өчен бер сурәтең калды...
Аны да алды... яшен,
яктыртып.

## Бурыч

Рәхмәт, Илем, имин иртәң өчен,
җылы урының, назың-иркәң өчен;

дүрт фасылың, яңгыр-карың өчен,
синдә күргән югың-барың өчен;

табындагы ипи-тозың өчен,
пакъ йолдызың, чак дуңгызың өчен;

өлешемә тигән көмеш өчен
кайгы-шатлык эчкән чүмеч өчен;

өстәлдәге кәгазь-караң өчен,
беренче вә... соңгы чараң өчен;

и, зур бурыч алдым үзем өчен,
санлап әйткән кайнар сүзең өчен—

ишетмәде бугай аны беркем:
«шагыйрь» диден бит син миңа
бер көн!..

❁

Тип, әйдә, заман, оятсыз,
Тулпарым калды тояксыз,
Юл хәвефле, Ил—җыйнаксыз,
Кунак булганнар—тыйнаксыз...

Әтрәк-әләм минде түргә,
Даһиларың
кучә
гүргә...

Сук, әйдә, заман, оятсыз,
Кыр—кузсез, урман—колаксыз...

Чыгу юктыр инкыйлабсыз!

❁

Син дә килдеңме дөньяга,
И, нихәл, энем генәм!
Умырзаялар да котлый
Бәхетле көнең белән.
(Бәхетлеме—кем белгән?)

Син дә килдең ич дөньяга!
Мин синнән алдан килдем.
Мин килеп исем алганда
Син, энем, кайда идең?

Айда идеңме син, бүки,
Син әллә кайда идең.
Син килгәч, әйдә бергәләп—
Миннән бик калма, дидем.

Калышма, нәнә, бирешмә,
Би... и... ик ерак барасы бар.
Көрәшеп, яшәү хакына
Дөньясын аласы бар

❁

Салкынча җил китте кагылып кына—
тупылларга гүя җан иңде:
яфракларда—яшел клавишларда
симфония башлый таң җиле!

❁

Күрше бакчада кем сайрый,—
авазы бик күтәренке?
Песнәк көмеш игәү белән
иги язгы күгәрекне.

❁

Шигырь табыннарда табындыра
Башкисәрне, дусны, туганны...
Шигырь ярата ул, күңелләргә
Мөлдерәмә булып тулганны.

Шигырь—алтын башак. Җил искәндә
Алтын орлык җиргә сибелә.
Бер каләмнән төшкән шигъри дога
Укыла ул, укыла Ил белән!..

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Мансур Вәли**

## МӘХӘББӘТ МАҖАРАЛАРЫ

НОВЕЛЛАЛАР

### Курку

Кыш. Уссури тайгасының алагаем биек булып үскән карагайларын, төн караңгылыгында иләмсез зур карачкы сыман чайкалучы чыршыларын аяктан егарлык булып җил котыра, буран уйный...

Ә зур гына бер алан читендәге землянка эчендә дүрт офицер инде кич буе дөньяларын онытып мәҗлес корып утыра.

—Син, Николай, яшерми-нитми генә миңа шуны әйт әле: хатын-кыздан куркасыңмы син?

Инде әллә ничә сәгать буена эчә-эчә карта уйнаганнан соң, төн уртасы житеп килгәндә, араларындагы иң өлкән офицер капитан Федотов лейтенант Сериковтан шулай дип сорап куйды.

Ә тегесе, һич көтмәгәндә һәм маңгайга тәрәп үк бирелгән мондый сораудан тәмам аптырап китте ахрысы, аның йөзе тиз арада житдиләнде, куллары нишләргә белмәгәннән, алда яткан зур тимер калакны алып, таба төбенә көеп ябышкан бәрәңге телемнәрен кыра башлады.

Капитан Федотовның моңа ачуы килде—ул, лейтенантның кулыннан тотып, әлеге шөгыленнән туктатты.

—Юк, син миңа җавап бир әле! Бәрәңге качмый ул... Әнә, почмакта бер капчык ул!

Чыннан да, землянканың үзләре салкынчарак диеп уйлаган бер почмагында зур арыш капчыгына тутырылган бәрәңге жир идәнгә бастырып куелган иде. Ипи, токмач, консерва ише башка ризыклар исә шундагы такта киштәләрдә өелеп-өелеп тора... Болар—солдатларны кыш көне автоматтан атарга өйрәтү өчен тайга уртасындагы менә шушы полигонга килгән хәрбиләрнең бер атналык азык запасы.

Әле генә аптырап калган Сериков капитанның соңгы сүзләреннән соң кычкырып көлеп үк җибәрде.

---

Әлеге исемдәге новеллалар циклының бер өлеше журналыбызның 1997 елгы 11 санында.

—Вәт син, Иван Данилыч, ә! Төн уртасында нинди мәкерле сорау бирәсең яшь егеткә! Тәмам айнытып җибәрдең бит әле...

—Ха-ха-ха... менә монысын дөрес әйттең бугай, лейтенант! Шулай шул: айный-айный эчәргә кирәк аны, аракыны! Тоташтан эчсәң—тәмен, ләззәтен белмичә каласың ич анын!

Хәзер инде яшь лейтенантнын да кыенсынуы, житдилеге узган—ул уйчан коңгырт күзләрен мөлдерәтеп капитанга текәлгән. Хәтта дусларча, үз кешеләрчә көлемсери дә бугай әле ул.

—Менә мин үзем дә кинәт айнып киттем бит әле, лейтенант... Һәм сиңа әнә шул сорауны бирәсе иттем... Ни өчен дисеңме? Ә? Әйт—«Ни өчен?» диген!

Монысыннан соң Сериковның авызы инде тәмам ерылды. Ләкин ул көч-хәл белән үзен көлүдән тыеп (чөнки капитанның холкын белеп бетереп булмый):

—Ни өчен?—дигән ике сүзне жыеп әйтә алды.

Ләкин капитан көлми иде. Ул үзенең юан-юан бармаклы сул кулы белән Сериковның өстәл өстенә куелган кулын кысып тоткан, ә үзе, күзләре белән ашардай булып аңа кадалган.

—Әнә теге дураклар һаман кәрт суга бирсеннәр (өстәлнең аргырак почмагында капитан Савельев белән өлкән лейтенант Булатов дәшмитынмый гына кәрт уйнап утыра иделәр—капитан башы белән шуларга ымлады), ә мин сиңа, Николай, үзем белән булган бер тарихны сөйлим... Бүген тулы бер ротаны үрә катырып маршировать иттергән капитан Федотовның яшь чагында нинди булганын бел әле менә син!.. Сөйлимме соң? Ә?!

Капитанның шулай дәшү рәвешендә үк нинди җавап ишетергә теләве бик яхшы аңлашыла иде, шуңа күрә Сериков та:

—Рәхәтләнеп тыңлыйм! Сөйлә, Иван Данилыч!—димичә булдыра алмады.

—Сөйлим шул! Ник сөйләмәскә! Әллә син менә шушында—Ерак Көнчыгышның Уссури тайгасы уртасында—аракы эчеп кенә ятар иденме?! Үзең белән бергә тайга уртасында яшәп яткан адәмнәрнең кем икәнлекләрен белергә теләмисеңме син әллә, ә?!!

Хәзер инде Сериков көләргә уйламый да, хәзер инде аның авыз җыелган—ул Иван Данилычның житди нәрсә сөйләргә җыенганын сизеп өлгерде. Шуңа күрә якындагы эскәмиядә яткан өстәл сөртә торган чүпрәкне үрелеп алды да, икесенең дә алларын корытты. Әйтерсең лә аларга менә хәзер яңа бер ризык килергә тиеш! Тәмле ризык!

Әлбәттә, хәзер—төн уртасында—яңа ризык юк иде инде. Өстәлнең бушаган әнә шул чиста өлешенә капитан Федотов ике терсәге белән таянды да, кул учларын бергә тоташтырып, чал керә башлаган чәчле зур башын шул терсәккә салды—ияге белән ике кулына таянды.

...—Хәрби училищега укырга кергәнче ике ел чамасы үзебезнең район үзәгендә, ДОСААФ оешмасында, эшләп йөредем мин. Эш болай кызык иде үзе. Спорт ярышлары оештырасың, авылларга чыгасың, андагы хәлләрне тикшерәсең... Колхоз җитәкчеләре белән талаша-сугыша дигәндәй взнос акчасы җыясың... Күп чагында әнә шул взнос дигәне иң мөһим мәсьәләгә дә әверелеп китә. Чөнки синең үзеңә эш хакы да җыйналган акча булса гына түләнә. Урыннардагы оешмалардан акча җыя алмыйсың икән—авызыңны чөйгә эләргә туры килә! Һәм син моңа үзең гаепле буласың!

Ә инде фатир ягы—Марфа түтидә. Ул—житмешнең югары ягындагы кечерәк кенә буйлы, юка гәүдәле карчык. Аның бер кызы авылда кияүдә, ә икенче кызы гаиләсе белән шушы шәһәрчекнең икенче башында, үз йортлары белән тора. Әниләре әлегә үз аягында булгач, алары да Марфа түти янына бик сирәк, онытканда бер генә килә.

Әйе, тагын бер нәрсәне әйтергә онытa язганмын бит әле. Мин яшәп яткан менә шушы Марфа түтинең өен элеккерәк елларда ерактагы

бер колхозның махсус фатиры итеп тотканнар. Бу хакта ишетеп беләсендер инде: сугыштан соңгы чорда колхозларның әнә шулай район үзәкләрендә үзләренең фатирлары бар иде. Кунакханәләр булмаганга күрә, авылдан район үзәгенә эш белән килгән кешенең берәр борын төртер жире булсын диеп эшләнгән инде ул...

Мин район үзәгендә эшли башлаганда инде кунакханә дә бар иде, билгеле. Ул шактый ук зур, житмәсә әле ике катлы таш бина да булгач, анда кирәк кешегә гел дә диярлек урын табыла иде инде анысы... Әмма, ни өчендер, теге колхоз кешеләре сирәк-мирәк әле һаман да Марфа түтигә сугыла иделәр. Әллә инде аның өенең юл өстендә булуы тегеләргә жайлы тоелды, әллә кунакханә бәясе шактый гына югары иде—ничек булгандыр, монысының серен мин сина әйтә алмыйм—әмма эштән кайтуга зур-зур сакаллы абзыйларның ишек ягындагы бүлмәдә тирләп-пешеп чәй эчеп утырганнарын шактый гына күргәләргә туры килә иде мина. Марфа түтинең әле алардан авыл хәлләрен сорашкалавы да истә калган. Әллә инде ул элегрәк теге авылга кайткалап йөри торган булган, әллә андагы кешеләрне шул үзендә төн кунуларыннан гына хәтерләп калган—монысын да белмим, ләкин үзенең өй эшләрен караштыра-караштыра Марфа түти алардан гел сораштыра иде.

—Степанны хасталап ята дигәннәр иде,тереллеме соң әле?

—Кара әле, Катеринаның кече кызы кияүгә чыккан иде түгелме?

—Иваннар сыерсыз калганнар икән, ә... Ай, мескеннәр... Ай, мескеннәр!

Авылдан килгән әнә шул абзыйларның ишек катында өс киемнәрен дә салыр-салмас дигәндәй ашап-эчеп утырулары (бигрәк тә кыш көннәрендә) минем күз алдында элеккеге тормыш турындагы кино кадрлары сыман булып калган. Ишек янындагы менә шушындый киң агач сәкедә аларның зур-зур толыплары ятыр... Ул толыплар янында шыплап тулган төрле-төрле пичтәрләр, кулеклар булыр... Авылга дигән ипи буханкалары бәләкәй генә тау сымак иттереп өеп куелыр... Ә инде сарыга буялган идәндә көймә хәтле зур резин галош кигезелгән сачинкәләр басып торыр...

Менә боларның һәммәсе хәзер бик матур күренеш булып минем күз алдыма килә. Әйтерсең лә мин бүгенге галәмгә очу, ракеталар заманында түгел, ә бер гасыр элегрәк туганмын. Әнә шул гасыр хатирәләрен күңелемдә саклап калганмын...

Әйе, Марфа түтигә килә торган кунакларның әнә шундыйларына гына күнеккән идем мин. Бүтән төрле кешеләрнең безнен өйдә булуын күз алдына да китерә алмый идем.

Әмма бер көнне... Әмма бер көнне безнең өйдә могжиза булды!

Шулай, гадәти бер көнне эштән кайтып керсәм—бу инде яз айлары, апрель тирәләре иде бугай—өйнең түбән ягындагы өстәл янында минем Марфа түти белән ят бер кыз чәй эчеп утыра! Мин, билгеле, шартын китерергә тырышып исәнләштем инде башта. Кыз да күтәрелеп карар карамас кына: «Исәнмесез...»—диде...

Мин өс киемнәремне сала торам, ә Марфа түти кызып-кызып бу кыз белән таныштыра... Ул авылда китапханәдә эшли икән. Исеме Вера ди... Бирегә эшләр белән килгән икән дә, бүген йомышларын йомышлап бетерә алмаган... Ә мин моңа каршы нәрсә диим инде?

—Ә-ә-ә... Шулаймыни?..

—Ә-ә-ә, алай икән...—дия-дия, кулларымны юам, өс-башны алыштырам. Ә үзем эчтән генә: «Болар тизрәк чәй эчеп бетерсә, мин дә ашарга утырыр идем»,—дип уйлыйм. Әмма болар ашыгырга уйламый да! Марфа түти гадәтенчә авыл хәлләрен сораштыра, Вера исә, әз-мәз генә чемченә-чемченә, аңа иплэп кенә, акрын гына җавап биргәләп утыра. Нәрсәгәдер ул да бик иркенләп сөйләшә алмый сыман—җаваплары бик кыска, артык төгәл. Күрәсең, минем кайтып керү кыенсындырадыр инде аны, диеп уйлыйм эчемнән.

Ул арада Марфа түти мине дә чәйгә кыстый башлады... Нишлисең, утырырга туры килде инде... Кая барасың, ашыйсы килә ич!

Анда инде нәрсәләр ашаганбыздыр: авылдан килгән йомыркалар идеме соң шунда, әллә инде миңа диеп ит белән бәрәнге дә куйдыларммы—кыскасы, ул чагында минем ашавым да ашау булмады, нәрсә ашаганым да истә калмады. Унсигез яшьлек егет белән кыз бер өстәл янында утырса, ашауның ашау булмасы билгеле бит инде ул! Менә шулай булды безнең дә.

Ярый, ничек кирәк алай бу процедураны тәмамладык без...

Шуннан соң инде мин рәхмәт әйтеп түр якка, үземнең почмакка таба кузгалып киттем. Марфа түти белән Вера да акрын-акрын гына өстәл яныннан тора башлады кебек...

Өйдә әлләни эш тә күренеп тормагач, бүтән бер шөгыль дә булмагач—ә тамак тук бит инде хәзер—«бераз һава сулап керим әле», дип уйлап, ишек катына килгән генә идем, шунда Марфа түти мине аяктан егардай сүз әйтмәсенме:

—Син, Ваня, безнең Вераны берәр кинога алып бар инде, яме!

Мин ул чагында, күрәсең, бик сәерсенеп, көтелмәгән бу тәкъдимгә аптырап ук калганмындыр инде—ул шундук усал гына итеп әйтеп тә куйды:

—Ярар, ярар! Үзең дә һәр кичне өйдә ятмассың бит инде болай! Әнә Вера да авылда бик күңелсез, ди! Ичмасам киносы да килми бит аның, ди...

Нишлисең инде мондый чакта?! Риза булмыйча кая барасың инде?! Билгеле, күнәсең инде... Гәрчә мин үзем болай алдан уйланмаган, ниятләмәгән эшкә бик сирәк очракта гына килешәм. Андый-мондый, вак-төяк тәкъдимгә генә мине ризалатуы бик авыр... Ә бу көнне Марфа түти нишләптер мине тиз күндерде.

Шулай итеп без Вера белән икәү кинога дип чыгып киттек.

Әйткәнемчә, апрель башлары иде инде бу... Тышта язның тәмам кызган чагы! Безнең ишегалдында да күп җиргә су җәелгән. Баскыч төбеннән алып капкага хәтле бер-берсенә ялгый-ялгый салынган такталарга гына басып йөрибез... Ә кайчакларда аяк таеп китеп суга да батып алгалыйбыз.

Инде эңгер төшәргә якынлашкан булса да биек колгага беркетеп куелган оясы янында сыерчык өздерә... Үзегез беләсез, яз көннәрендә бит ул иң мәшһүр җырчы була! Җәйге сандугачларны да оныттыра! Чөнки ул кышкы салкыннарны куып, шуларны җиңәргә тырышып сайрый. Кыш буена туңган, өшегән һәм җылыга, назга сусаган күңелләргә дәрт биреп, канат куеп сайрый бит ул! Аны ничек якын күрмисең ди инде! Ничек аны яратмыйсың ди инде!

Урамга чыктык. Безнең ихата коймасына терәлеп үк диярлек өстенә асфальт җәелгән бик әйбәт тротуар үтә. Ул инде кардан ачылып беткән диярлек. Урамда кеше дә әлләни күп түгел, шуңа күрә рәхәтләнеп янәшә барырга да мөмкин... Һәм без бер дә ашыкмыйча гына янәшә атлыйбыз... Ләкин менә... Ләкин менә сөйләшергә сүз генә табып булмый...

Шулай байтак кына атлагач, аптыраганнан гына дигәндәй, Вераны үзебезнең шәһәрчек белән таныштыра башлыйм. «Менә бу ике катлы йортта почта урнашкан...» дигән булам... «Ә-әнә теге озын агач йорт—пионерлар сарае инде ул... Аннан әнә шулай гел дә музыка тавышы ишетелеп тора. Мин узганда гел шулай була... Аларның музыка укытучыларын бик сәләтле кеше, диләр... Көн-төн шунда ята икән ул...»

—Ә без ерак барабызмы соң?—Бусы инде Вераның миннән сорап куюы.

—Безме? Без башта менә шушы урамнан туп-туры барабыз әле... Ә аннан соң сулга борылабыз да, тауга таба күтәрелә башлыйбыз. Безнең шәһәрнең иң шәп кинотеатры шунда урнашкан чөнки!—дим мин моңа шактый ук кыюланып китеп.

Әмма... Әмма без, «кино карыйбыз менә», диеп, бик-бик дәртләнеп килсәк тә, бүгенгә инде билетлар беткән булып чыкты. Минем сөмсерем коелды, билгеле... Ә Вераның исә исе дә китми—миңа караган да елмаеп тик тора, берни булмагандай...

Хәзер нишләргә? Бу бәләкәй шәһәрнең икенче очындарак бер клуб бар-барын, ләкин анда баруы бик ерак шул... Әле анда да билет булырмы-юкмы?

Шулай да бу хакта Верага әйттем мин. Ә ул ике дә уйлап тормады:

—Соң, әйдә алайса, киттек!—кенә диде.

Терек-терек киттек тагын... Әле ярый урам кырыйлап тактадан гына булса да тротуар җәелгән. Югыйсә, мондый язгы пычракта барып житә алмаган булыр идек ул клубка да.

Билетлар бетмәгән иде анысы, ләкин киносы гына юньле булмады. «Дүшәмбегә кадәр яшәргә» дигән яшүсмерләр киносы булып чыкты ул. Нишләптер аның исеме генә истә калган... Әллә инде ятрак тоелган ул чакны, кем белә!

Шулай... Менә бер заман кино да бетте бит инде. Урамга да чыктык... Ә анда, мин сина әйтим, баз караңгылыгы—күзенә китереп төртсәләр дә бер нәрсә шәйләрлек түгел! Әле житмәсә клубның тар ишегеннән чыккан чагында халык арасында уралып бер-беребезне югалта яздык. «Вера!» дип кычкырырга туры килде. Алгарак узган булган икән...

Ярар... Күзне караңгыга ияләндерик диеп шулай бераз басып тордык та, төркем-төркем булып атлаган халык артыннан без дә алга таба кузгалдык инде—анда төн куныл булмый ич караңгы дип куркып!

Район үзәге саналган бу шәһәрчектә инде ярты елдан артык яшәсәм дә, бу почмагында һич кенә дә булганым юк иде әле. Житмәсә әле караңгысы да шундый бит—миңа үч иткәндәй!

Кайтабыз шулай абына-сөртенә... Әмма бераздан шәйлибез: бездән алда кайтучылар эреп юкка чыккандай тарала бара бит! Капка саен диярлек керәләр дә китәләр, керәләр дә китәләр... Боларның барысы да шушы як кешеләре булды, ахрысы... Әле ярый ялгызы гына кайтучы соңгы ир-атны куып житеп, әз-мәз сораштырырга өлгердем. Ә ул миңа юлны ничекләр итеп өйрәтә диген:

—Менә шушы тыкырык белән бара-а-сың да бара-а-асың... Берәр чакрым тирәсе атлагач, зират коймасына килеп төртеләсең. Агачлары да бик биек—анысын күрмичә калмассың! Әнә шул зиратны әйләнеп узсаң, теге якта сезгә кирәкле үзәк урам—зур урам башлана! Ә инде зиратны әйләнеп узасыгыз килмәсә, мәйлегез: зират эченнән туп-туры сукмак та бар—рәхим итегез!

Теге мужикның шундый сүзләрен ишеткәч, Вера бөтенләй курка калды.

—Нишләп монда хәтле килдек соң без...—ди мескен, еламсырап ук. Үзе минем кулны шытырдатып кыскан. Ә мин нишләргә тиеш инде андый чакта? Үзең беләсең: мондый вакытта бераз булса да егетләрчә күренергә кирәк инде! Ничек тә сер бирмәскә кирәк миңа!

—Тукта әле, Вера—мин әйтәм,—нигә дип шул хәтле коелып төштең соң әле син?! Кырыеңда мин бар бит! Ә минем төнлә зират тирәләрендә йөргән бар ул—аннан гына курка торган егет түгел мин!

—Ә нишләп йөредең соң син алай зиратта, төнлә?—дип кызыксына калды Вера да.—Алай-болай өрәк түгелсеңдер бит син?!

Бу сүздән соң үземә дә кызык булып китте. Башта кычкырып көлдем, рәхәтләнеп. Ә аннары әйтеп, аңлатып бирдем инде, билгеле.

—Пристаньга бара торган юл безнең авыл зираты яныннан гына уза иде. Шуңа күрә төнлә пароходтан төшкән кешеләр, телиме-теләмиме, барыбер зират кырыеннан үтәргә мәҗбүр була... Кайтасың инде—нишлисең! Үзең генә калсаң, рәхәтләнеп жырлый-жырлый кайтасың әле ул!

Ул чакны куркудан жырлаганны әйтеп тору юк инде ул Верага! Төнге зират чынлап та бик батыр кешене дә куркыта, шыкайта бит ул!

Аның шомлы тынлыгына, ә кайвакытларда гүяки серле ухылдау-ыңгырашуларына эчендә җаны бар бер генә кеше дә тыныч кала алмый ич—монысын үзең дә беләсең!

Әмма мин тыштан батыр күренергә тырышам. Вераны да тынычландырырга телим.

Шулай итеп, инде зиратка якынлашканчы ук мин Вераны әзерләп куйдым дип уйлаган идем. Күңелем белән үземне хәтта өйгә кайтып җиткән кебек тә сизә башлаган идем инде. Ләкин менә шушы нәгъләт орган тар тыкрык зират коймасына килеп терәлгәч—чын-чыннан шомлы булып китте! Бөтен тәнгә курку йөгерде. Бер мәлгә сүзсез дә калдым бугай әле хәтта. Төн карангысында аеруча биек, аеруча зур күренә торган агачлары синең өстеңә ишеләм-ишеләм дип торган кап-кара куркыныч тау диярсең! Ара-тирә әллә нинди кош авазлары да ишетелеп куя. Алары да бит аның урмандагы кошлар тавышы шикелле түгел—җир астыннан чыккандай: әллә нинди афәтле һәм чиркандыра, тетрәндерә, җирәндерә торган тавыш бирә.

Ярар, хәзер инде өйгә таба кайту юлын карарга кирәк бит!

Уң якка бөтенләй юл юк икән, ә сул яклап үзенчә бер тар гына урам шикеллерәк нәрсә башлана, ахрысы... Борынны төртеп үк диярлек эзләнә торгач, зират коймасындагы теге ир әйткән зур гына тишекне дә шәйләп алдым. Бусы инде ашыккан кеше өчен туры юлның башы була... Әмма Вера моңа килешәме соң?!

—Юк! Юк! Юк!—ди бу миңа, әллә ниткән кызганыч та, бераз усалрак та һәм шактый ук калтыранган да тавыш белән.—Шушындый караңгыда зират хәтле зират эченә керәмме соң?! Юләрме әллә мин?! Әйдә, менә бу яктан киттек тизрәк!—дип мине җиңемнән тарткалый ук башлады бу. Ә минем, киресенчә, ул тарткан саен батырлык арта бара кебек.

—Әйдә инде шушыннан гына,—мәйтәм.—Моннан китсәк, өйгә тизрәк кайтып җитәбез бит! Инде Марфа түти безне көтә-көтә көтек булгандыр.

Юк, Вера һаман бирешми. Ризалашмый гына бит!

Билгеле, аның риза булуын мин үзем дә бик теләмим инде. Мондый куркыныч төндә бөтенләй таныш булмаган зират эченнән кайтырга үзем дә шүрлим инде шүрләвен. Ләкин эчтәге ниндидер бер шайтан һаман котыртып маташкан була бит ул әнә шуның ише чакларда... Кылтаюмы инде ул—кем белсен!

Алай да, бары тик Вера өчен генә риза булган, күнгән кыланып, кыз артыннан атладым инде. Дөресрәге: ул минем кулны бөтенләй дә җибәрми инде хәзер! Кая ул җибәрү! Кап-караңгы төн уртасында зират буенда басып торабыз ич!

Шулай, йөгерә-чаба кайттык инде өйгә. Ә өйалды баскычына менеп ишек шакуга, безгә Марфа түти ташланды:

—Нишләп йөрисез соң сез шул кадәр гомер?! Кеше борчып! Кеше куркытып!—диде ул, ишекне ача-ачышлый ук. Бичара, безне көтә-көтә шуңа хәтле йоклый алмый яткан икән...

Шулай диде дә, капитан Федотов сүздән тукталды. Землянка эчендә тынлык урнашты... Шуннан файдаланып, Сериков сүзгә кушыласы итте:

—Синең курку дигәнең шушы булдымы инде, Иван Данилыч?!

Әмма капитан Федотов моңа каршы бер генә сүз дә әйтмәде. Күтәрелеп тә карамады. Башта сүзсез генә аракы бүлде. Үзенә дә, Сериковка да. Һәм болай диде:

—Бусы әле аның баласы гына, дустым!

Аннары ул бераз кыстауны кирәк тапты бугай:

—Әйдә әле, тамак кибеп китте бит әле! Бераз кабып куйыйк әле бу нәрсәне!

Боларның эчәргә җыенганын күреп, кәрт сугучы офицерлар да аларга таба авышты. Дүртесе дә кулларына стаканнарын тотты. Моңа

кадәр дә сүз дилбегәсе Федотовта булгач, тагын аннан сүз көтеп—аңа текәлделәр. Һәм, чыннан да, Федотов озак көттермәде.

—Мин мона хәтле сөйләгәннәр—алар баласы гына әле, егетләр! Чын курку ул соңрак булды... Соңрак...

—Ничек «соңрак»? Соң сез өегезгә кайтып життегез түгелме соң инде?!—дип, лейтенант Сериков бер саллы гына сүз залпы биреп алды да, зур күзләрен капитанга төбәде.

Ә тегесенең мона исе дә китми. Ул тып-тыныч.

—Әйдәгез, менә бусын күтәреп куйыйк та, аннары мин сезгә чын курку турында сөйлим!

Дәррәү генә тотып куйдылар. Ләкин инде кич буе утыра торгач, өстәл өсте шактый такырайган иде—агач саплы зур табада бераз бәрәңге генә калган—барысы да шуңа ябырылды. Бер мәлгә сүзләр дә онытылды.

—Менә шулай, әфәнделәр! Әле мин сезгә үземнең иң зур куркуым турында сөйләмәдем. Хәзер менә рәхим итеп шунысы хакында тыңлагыз! ... Өйгә кайтып життек, дидем бит инде... Марфа түти сукрана-сукрана булса да, безне өйгә кертте, дидем бит инде...

Шуннан соң үзе озак юанмады ул, түр як почмакка куелган киң агач караватына таба атлады. Бераздан догаларын укый-укый жылы юрганы астына чумды. Олы яктагы утны да сүндерде.

Ишек янындагы бүлмәдә без хәзер Вера белән икәү генә калдык бит инде...

Ә ул—кем күрсен—өстендәге курткасын кай арада салып ташлаган да, жәһәт-жәһәт йомырка кыздырып йөри! Электр плиткәсендә инде...

Минем аңа күз төшә бит инде, шайтан алгыры... Аның йөрешләре, мин сиңа әйтим! Елмаюлары... Нәкъ кирәк дәрәжәдә генә тулырак гәүдәсенең тылсымлы-хикмәтле дулкынланулары... Һәм мине бигрәк тә гажәпләндергәне: аның биредә, беренче мәртәбә булган ят өйдә, шундый да ышанып һәм кыю йөрүе! Ул монда әллә кайчаннан бирле шулай хужабикә булып яши диярсең, билләһи! Ушың китәр!

Ләкин безнең арада сүз юк. Мин үземнең яшьлегем, тәжрибәсезлегем аркасында ничек итеп, каян сүз башларга белмим... Әле генә карап кайткан кино турында сөйләшер идең—ул безгә ошамады. Без анда шул, вакыт уздырып кына утырдык бугай инде... Ә тагын нәрсә турында сөйләшергә мөмкин соң кичке аулак бүлмәдә чибәр кызый белән ялгызың гына калгачтын? Житмәсә әле бүген генә беренче мәртәбә күрешкән кыз белән... Шуның өстенә, минем бит әле сүз капчыгы да бик үк зурдан диеп әйтеп булмый!

Бераздан безнең плиткә өстенә куйган йомырка да кызып житте. Вера аны табасы-ние белән өстәл өстенә күчерде, плиткәгә исә чәйнек утыртып куйды...

Кыскасы шул: без төн уртасында икәү генә калып ашадык, эчтек... Аннары, бер-беребезгә сиздермәскә тырышып кына, берәм-берәм генә ишек алдына да чыгып кердек...

Шуннан соң нәрсә? Инде йокларга ятарга да вакыт житкән икән бит инде! Бик күптәннән житкән икән ич инде ул вакыт...

Чыгып кергәннән соң, тагын бераз нәрсәдер эшләп йөредек тә, бер-беребезгә бик зыялы кешеләр шикелле «тыныч йокы» теләп, урыннарыбызга барып урнаштык...

Мин үземнең түр яктагы караватка, ә Вера шул чәй эчкән бүлмәдәге, кунаклар өчен дип куелган агач сәкегә ятты.

... Менә ут та сүнгән инде... Әби дә гырлый-гырлый йоклый инде. Әмма миндә йокының ичмасам әсәре генә дә юк! Ятам-ятам да борылып куям, аннары—алай түйдыргачтын, тагын бүтәнчә борылып урнашам. Ә үземнең күзләрем дә, бөтен уем да бары тик Вера тарафында гына. Ул да йокламыйдыр кебек, минем үзе янына килгәнемне көтеп ятадыр шикелле тоела бит, шайтан алгыры. Шул хәтле чекерәеп карагач, бер мәлне ул торып утырган да кебек булып китә хәтта. Әмма тагын бер кат ныклабрак

карагач, мин моның хыял гына икәнен аңлап алам... Шуннан соң инде башыма бөтенләй бүтән төрле уйлар килә башлый. Үз-үземә: «Вера көне буена йөреп арыгандыр да, менә хәзер яту белән онытылып йокыга киткәндер,—дим.—Син монда бушка хыялланып кына ятасыңдыр»,—дим.

Ә тагын күпмедер вакыт узуга, Вера яңадан борылып яткан сыман тоела да, мин тагын боргалана, кыбырсый башлыйм. Тынычлык бөтенләй кача. Хәтта кайчакны ул миңа пышылдап дәшкән дә кебек тия. Андый чакта мин үземне ныклап ышандыру өчен, аның тагын бер мәртәбә пышылдаганын көтеп, мендәрдән башымны ук калкытамын—шул хәлдә көтәмен байтак кына.

Әнә шулай ничә мәртәбә генә кабатлангандыр инде ул төнне... Әле тагын шунысы да булды бит: мин Верага таба якынрак килү өчен, өскә пиджакны гына салып, ишек алдына да чыгып кергән булдым. Янәсе, үз, йомышым белән йөрим инде! Һәм керешли, Вера караваты янына килеп, байтак кына басып та тордым әле. Әнә шул вакыттагы дулкынлануны, серле вә рәхәт бер куркуны аңлатып бетерү һич кенә дә мөмкин эш түгел! Моны бары тик үзе кичергән кеше генә аңлый, төшенә ала торгандыр!

Өй эче дөм караңгы бит инде, бары тик тәрәзә шәүләсе генә бераз шәйләнә... Ә мин, сулыш алырга да куркып, Вераның караваты янында басып торам. Шуннан башка бер хәрәкәт ясарга да кыюлык житми, үз-үземне мәжбүр итә алмыйм. Житмәсә әле, шуның өстәвенә, Марфа түти уянып китмәсә генә ярар иде инде дип тә борчылам. Ул тора-нитә калса дип, өстән пиджакны да салмыйм. Янәсе, минем ишегалдына чыккан жирдән кереп килешем генә бу...

Ә Вера исә тып-тын ята бирә... Йоклый да кебек инде... Әмма бер тыңласаң—тын алуы да ишетелми шикелле... Икенче карыйм: тып-тыныч йоклап ята шикелле... Бик тә шуңа ошаган...

Аның янында әнә шулай аптырап-йөдәп бик озак басып торам-торам да, аяклар инде тәмам арыгачтын, бүтән инде түзәр чама калмагачтын—акрын гына, песи кебек кенә басып—яңадан үз урыныма барып ятам. «Юк инде! Юкка борсаланып йөремә инде! Йоклый ич инде Вера!»—дип, үз-үземне тынычландырырга телим. Йокыга китәргә тырышам. Ләкин... Ләкин хет үтер—булмый! Бу минем көчемнән килми! Күзләр шар ачык... Йокының һаман әсәре дә күренми минем тирәдә.

Тагын бик озак газапланам... Аннары яңадан Вера пышылдаган сыман тоела... Моңа ышанырга да ышанмаска да белмичә, яңадан әкертен генә аның караваты янына киләм... Ә ул һаман шул килеш: шым да чыгармыйча ята бирә, аз гына кыймылдамый да... Текәлеп-текәлеп карап торамын да, нишлим, тагын үз ягыма китеп барам инде...

Моның хәтле үз-үзең белән тарткалашу газабын Ходай беркемгә дә күрсәтмәсен! Төн буена диярлек бит бу! Төне буена бит!

... Шулай ничә сәгать үткәндер...

Инде караңгылык сыеклана башлагач кына, юрганымны баштанаяк бөркәнеп, нининдидер саннар саный-саный, шулай үземне мәжбүр итә-итә, көч-хәл белән генә йокыга китә алдым.

Иртән уянгачтын да, күземне ачу белән иң башта, иң элек Вера караваты ягына карыйм. Ул торганмы-юкмы, янәсе!

Юк шул инде ! Аның караваты да пөхтәләп жыйнап куелган, әбием дә өйдән чыгып киткән—мин берүзем йоклап ятамын икән шушы гомер! Өйдә инде беркем дә калмаган!

Минем эчтә исә әллә нинди мәчеләр тырмаша: үкенү дә, үз-үземә ачу килү дә, ниндидер бер газаплы, әрнүле бушлык та—тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр бәгырьне тырный. Дөньяга күзне ачасы килми хәтта! Әмма нишлисең—торырга кирәк... Соңарыбрак булса да эшкә барырга кирәк.

Шулай дип уйлап, торып кына утырган идем, борылганда баш

очымдагы тумбочкага күз төште. Ә аның өстендә кечкенә генә кәгазь кисәге ята. Үзе икегә бөкләнгән. Бик тә сәерсенеп кенә ачтым мин моны. Язу бар, кызлар язуы. Укыйм. Ә анда менә мондый сүзләр: «Куркак булып чыктың бит син!»

Аптырап, кабат-кабат укыйм—шул ук сүзләр бит, шайтан алгыры!

Әйе, сүзләрне, хәрефләрне күзем күрә, әмма аларның мәгънәсе, ни әйтергә теләгәне һич кенә дә башыма барып житми. Нәрсә димәкче булган соң Вера? Аның ни өчендер миңа ачуы килгән түгелме соң?! Неужели... Төнлә үзе янында басып торганны сиздe микәнни? Шуның өчен—төнлә үзен борчырга теләгәнем өчен—ачуланды микәнни ул миңа?!

Шулай диеп уйлыйм бит мин—дивана!

Ул чактагы акылым белән Вера миңа шуның өчен ачуланган дип ышанам... Һәм борынымны салындырып, иртәнге ашны ашап та тормастан, атлар-атламас кына адымнар белән эшкә таба кузгалам...

Ул көнне көне буе да, аннары да, Вера язып киткән әлеге сүзләр бик озак хәтеремнән чыкмады минем... Ләкин мин ул сүзләргә бары тик үзем уйлаган мәгънәне генә сала идем. Бары тик әнә шулай дип кенә кабул иттем ул чагында мин аның сүзләрен.

Тагын күпмедер гомер үтте...

Бер командировкада шул төбәккә юл төшкәч, Вера эшләгән авылга да кереп чыгасы иттем. Аның белән күрешеп сөйләшергә, иркенләп аңлашырга иде исәп. Ни өчендер акланырга,нәрсәнедер аңлатырга теләк бар иде шикелле.

Әйе, көндез иде ул... Минем бәхеткә, авыл китапханәсе ачык иде. Вера анда үзе генә йөри—яңа килгән гәзит-журналларны төпләмәгә тегеп маташа.

Көтмәгәндә-уйламаганда мин килеп кергәч, ул башта бик тә аптырады, билгеле. Ләкин шулай да, исәнләшүен ягымлы гына, матур итеп исәнләште.

—Бу якларга нинди җилләр ташлады?—дигән сыман, гадәти сорауны да биреп алды бугай әле.

Ә аннары ул кинәт кенә ашыга башлады.

—Аһ! Мине бит бүген авыл советына чакырганнар иде!—ди бу, минем күзгә карамаска тырышып кына. Һәм ашыга-ашыга өстенә дә киенә башлый... Мин аны азга гына туктатмакчы булып:

—Вера...—диеп сүз башлыйм, аның кулыннан тотмакчы булам.

Әмма ул ут чыккандай ук кабалана башлый.

—Әйдәгез, әйдә! Мин сонга калам ич!

Ә үзенең иреннәре кысылган, йөзе утә житди. Шул чак миңа чын-чыннан уңайсыз булып китә. Шуңа күрә бик тә кыенсынып кына, үземне көчләп кенә дигәндәй:

—Вера, бүген монда калсам... бәлки бераз сөйләшеп йөри алырбыз...—дип әйтәм, аның артыннан ияреп болдырга чыгышлый гына.

Минем бу сүзләрем аны тагын да ныграк куркыта кебек.

Ул тагын да кызыбрак:

—Юк, юк! Кала күрмәгез! Эшләрем бик күп чак!—ди һәм китеп тә бара... Шактый ара узгач кына, миңа таба борылыр-борылмас кына:

—Хушыгыз!—дип кычкыра, йөгерә-атлый барышлый.

... Менә шул...

Урам уртасында берүзем, бер ялгызым бастым да калдым әнә шулай ят бер авылда. Нишләргә дә, нәрсә дип әйтергә дә белмичә...

Капитан Федотов тынды. Землянка эче тып-тын калды.

Байтак утырдылар алар әнә шулай бер сүз дәшмичә...

Ә аннары өлкән лейтенант Булатовның калын тавышы ишетелде:

—Их син, Иван Данилыч, Иван Данилыч... Син ул чагында үзеңнең нинди зур ахмаклык эшләгәнеңне хет хәзер аңлыйсыңмы соң?! Ә?! Хет хәзер, менә хәзер, үзеңнең әнә шул зур хатаңны беләсеңме?! Син бит... Син бит—хатын-кызны рәнжеткәнсең! Аны аңламагансың, аңа карата

игътибарсыз, битараф булгансың! Син... Син... беләсеңме... хәтта табигатьнең үзен рәнҗеткәнсең син!

Моның ярсуын лейтенант Сериков бүлде:

—Бик зур фәлсәфә китереп чыгардың әле син моннан...

Ләкин Булатовның әле әйтер сүзе бетмәгән икән, шуңа күрә ул теге «молодой»ның авызын тиз томалады:

—Нинди фәлсәфә булсын ди бу сиңа! Гап-гади кешелеклелек турында, кеше хәлен аңлый алу, аңлый белү турында сүз бара бит монда!

Шулай дип бераз тынычланды да, аннары инде акрынрак, сабыррак рәвештә дәвам итте Булатов:

—Ул мескен кыз—Вераны әйтәм—авылда бер җунле җегет күрергә тилмереп яшәгән бит инде! Әнә шуңа күрә, аптыраганнан килгән бит инде ул әлеге шәһәр кисәгенә! Авыл тормышыннан тәмам туеп, мең күз, мең колак контроленнән инде гарык булганга күрә—аз гына булса да җаны теләгәнчә яшәп алу өчен, үзен кеше һәм барыннан да бигрәк хатын-кыз итеп сизеп карау өчен килгән бит инде ул!

Ә син, Иван Данилыч, шул кыз баланың тел белән әйтелмәгән, әйтелә дә алмаган—моны хатын-кыз табигате, аларның Ходай тарафыннан бирелгән һәм үзгәрә алмый торган обьектив рәвештәге табигате кушмый—теләгеn, омтылышын аңлый алмагансың!

Чып-чын мәгънәсезлек, хәтта, әйтер идем, кешелексезлек һәм... Һәм табигатькә каршы бару димичә ни дисең инде моны, әфәнделәр!

Әйе, әйе—һич тә аптырамагыз, мин шулай дип әйтәм:

—Безнең Иван Данилыч үзе дә белмичә әнә шундый бер җинаять кылган!

—Тик син шуны да онытма, Булатов! Монда әле тагын бер мөһим нәрсә барлыгын хәтереңнән чыгарма!—Монысы инде һәрчак ашыкмыйча гына сөйләшә торган капитан Савельев иде.—Ул чагында, әйе, әйе, нәкъ менә шул чагында—ягъни әле яңа гына урта мәктәпне бетереп килгән яшүсмер егет, син теләгәнчә, син уйлаганча эшли ала идеме соң ул?? Ә?! Ул бит сиңа бүгенге Иван Данилыч—рота белән җитәкчелек итә торган капитан Иван Данилыч түгел! Ять-яшь бит әле ул! Нигә син әнә шуны онытасың?!

Сүзен әйтә башлаганчы ук көлә-көлә, тагын Сериков кушылды:

—Соң, кыз үзе дә инде! Иртән безнең Иван Данилычны ачуланып язу калдырырга башы житкән, ә төнлә—ул мескен тилмереп, аптырап, газапланып аның караваты янында басып торган чагында—шунда ичмасам чут кенә кымшанырга, яисә инде аз гына күчебрәк ятырга акылы җитмәгән! Соң, безнең ир-ат халкын батыр-куркусыз итәргә хатын-кызның бер күз карашы, бер ишарәсе дә житә ләбаса!

—Юк, егетләр! Ни генә әйтсәгез дә, барыбер курыктым мин ул чагында, курыктым! Башка бер генә сүз дә туры килми монда! Бары тик курку гына бу... Курку гына.

Капитан Федотовның үз-үзенә карата чыгарылган шушы аяусыз хөкеменнән соң, землянкада уңайсыз тынлык урнаша.

Шулай итеп ике-өч минут чамасы вакыт уза да, алар уфтаныша-уфтаныша урыннарыннан кузгалалар һәм тәмәке тартып керергә тайга аланына чыгалар.

Ә анда әле һаман буран котыра...

Ә анда тулысынча Табигать тантана итә...

Табигать—көчле! Ул—хаким!

Аның кешеләргә һәм аларның үзе турында нәрсә сөйләшүләренә, ни турында баш ватуларына да исе китми. Аның үз тормышы, үз кануннары... Һәм... Һәм үзенең көе, үзенең моңы... Ләкин кешеләр күп чагында Аны аңламыйлар шул... Хәтта аннан куркалар да...

**Жан Ануй**

Мена тагын тайганы карангылык биләп алды... Көн яктысында үзләренең озын мәһабәт буйлары белән соклandырып утырган төп-төз карагайлар, купшы чыршылар, баһадир имәннәр—хәзер инде һәммәсе дә тоташ кара пәрдә булып кына күренә башлады.

Тирән кар белән капланган кышкы полигонда бүгенгә билгеләнгән эшләрен бетергәч, офицерлар иң элек үз солдатларын кечерәк кенә бер казарма шикелле итеп, кат-кат такталардан әмәлләнгән кышкы торакка озатып куйды. Аннары инде тынычланып, үзләре дә берәм-берәм землянкага кайтты.

Бераз кысанрак булса да монда мич җылысы бар, түшәмгә үк элеп куелган ялгыз лампочка да әйбәт кенә якты бирә... Шуңа күрә кайтып тамакны бераз ялгап алуга—шул чагында әзрәк кенә «чылана» да бит инде ул тамак дигәнең!—көне буе билдән кар ерып йөргән офицерларның кәефләре шактый күтәрелеп китте. Телләр дә язылды, авызлар ерылды.

—Егетләр, минем баштан кичкән бер кызыклы хәлне дә беләсегез киләме?—дип алдан ук дәртсенеп тотынды үзенең сүзенә өлкән лейтенант Булатов.

Шушындый озын кышкы кичтә, шәһәрдән еракта, караңгы тайга уртасында тагын нишлисең инде? Вакытны ничек уздырасың?! Әлбәттә, офицерлар бу сүзгә бик тә шат иде. Өстәлдә «ягулык» та бар бит әле...

Гадәттәге урынына аягын бөкләп менеп утырды да, уздына бераз гына елмая-елмая, сөйләп китте Булатов.

—Ул елны мин әле өйләнмәгән егет идем... Яшькә инде бик артык яшь диеп булмый, билгеле. Чөнки институт еллары инде артта калган... Сезгә бик тә билгеле булган К. каласында үземә аерым бүлмә алып яши, эшли башлаган чак бу!

Моңа хәтле биш ел буеңа имтихан арты имтихан биреп йөрүләрдән, кирәк-кирәкмәс әллә нинди күнелсез фәннәрне укырга мәҗбүр итүләрдән, безнең яшь йөрәкләрне элеккеге мәдрәсәләрдәге шикелле аскетлык кысасында тотарга яскынган укытучыларның дәһшәтле кыяфәтләреннән—барысыннан-барысыннан тәмам туелган, гарык булынган!

Кыскасы, җанның иреккә сусаган чагы! Минем—аеруча бунтарь йөрәкле адәмнең—инде бигрәк тә рәхәтләнеп, бәйсезлеккә кинәнгән көннәре!

Шәп, малай! Институтта укыган чагында кая барырга, нәрсәләр күрергә диеп хыялланган булсам, әкрен-әкрен һәммәсен дә чынга ашыра киләм. Әллә нинди затлы-затлы кешеләр йөри торган концертларга барам, симфоник оркестр музыкасы биргән ләззәтне дә алырга тырышам, рәссамнарның яңа күргәзмәләрен дә бер үзем озаклап, рәхәтләнеп карап йөрим. Иркенләп, тәмам иркенәеп!

Җәй башы булгач көннәр аеруча матур инде. Шәһәр урамнарындагы яшь юкәләр бигрәк тә татлы хасияттә утыра кебек. Әнә шул яшь юкәнең бер бөресенә генә дә дөньяның бөтен матурлыгы сыеп беткәндер сыман тоелып китә кай чакларда... Нинди асыл төсләр бит анда! Күпме наз һәм йомшаклык! Гүяки, гүзәллекнең символы, һәйкәле ул бөре.

Менә шушындый дәртле, илһамлы көннәрнең берендә мин шәһәребезнең Үзәк мәйданы тирәсендә вакыт уздырып йөри идем. Ял көне иде бугай әле ул... Әйткәнемчә, көне бик шәп иде.

Безнең шәһәрнең Үзәк мәйданы янында «Балалар дөньясы» дигән бик зур кибет бар. Ул көнне мин, һич тә ашыкмыйча гына әнә шул кибет кырыеннан уздым да, җир асты юлына таба юнәлдем. Һәм менә шул мизгелдә күзем үндүрт катлы биек кунакханә белән әлеге кибет арасындагы мәйданчыкка утыртып куелган кечерәк кенә бер будкага төште.

Хәзер инде төгәл генә хәтерләмим дә: әллә инде аңа хәтле буш торган урында кинәт пәйда булган яңа нәрсә игътибарны үзенә тартты,

әллә мин аңышып житмәгән бүтән бер хикмәт килеп чыкты—кыскасы, ул көнне аякларым үзләреннән үзләре шуңа таба алып китте.

Ярар, бик тиз генә килеп тә життем бит мин бу бәләкәй будка янына. Күрәм—нәкъ минем якка карап торган кечкенә генә, кул сыярлык кына тәрәзәсе дә бар моның һәм... Һәм ни хикмәт диген: ул ачып та куелган!

Адәм баласы шулай тикшерүчән, кызыксынучан бит инде ул. Бигрәк тә минем кебек эшсез йөрегән чагында. Мин дә тәрәзәгә таба иеләм, эчкә күз салам. Янәсе ниләр бар икән бу серле тартма эчендә?

Ә анда, мин сиңа әйтим, ышансагыз ышаныгыз—ышанмасагыз юк—анда озын сары чәчләрен ике якка салындырып бер бик чибәр кызый утыра! Чын менә, әкияттәге бер гүзәл инде! Үзе бик яшь тә күренә.

Минем авыз шундук ерылып китте инде, малай! Бер тылсымчы кулына килеп эләктеммени! Әкият иленә килеп кердеммени?!

Үзеннән үзе телгә әллә нинди сүзләре дә килеп тора бит аның:

—Элекке заманда усал патшалар гүзәл кызларны мичкәгә бикләп суга агызган диләр иде, сез гүзәлне дә бу тартмага бикләп куйдылармы соң әллә?

Шулай дидем дә, үзем авызны һаман җыеп ала алмаган килеш, тегенә күзем белән терәлеп каттым инде...

—Әйе, шул... Бикләделәр шул...—ди бу бик тә мескен, әмма гаҗәеп ягымлы тавышы белән суза төшеп кенә.

—Хәзер нишләрсең микән соң инде, мескенкәй?—дигән булам.

—Менә берәр батыр егетнең килеп, бу тартмадан мине ирекка чыгаруын көтеп утырам инде шулай...

—Ә-ә-ә... Алаймыни... Ә алдыгызда нәрсә соң ул? Сер булмаса? Ниндидер билетлар түгелме соң алар?

—Әйе шул... Коткаручы булмагач, вакыт үтсен диеп билет та саткан булам шунда.

Кыскасы, Мәскәүдән килгән Әдәби театрның билет сату кассасы булып чыкты бу. Уйламаганда-көтмәгәндә әнә шуңа килеп юлыкканмын икән мин! Кешесенә ничек туры килеп тора диген син аны!

Кем күрсен—сүз иярә сүз китте бит безнең икебезнең арада. Ул әле былтыр гына урта мәктәпне бетергән икән. Иптәш кызларының барысы да диярлек институтларга укырга кергән—кеше булачылары килгән. Ә менә Ул, гәрчә мәктәптә яхшы укыса да, инә белән кое казудан тәмам туйган. Аның бүтән укыйсы килмәгән.

—Минем бу сүземне ишеткәч әти белән әнинең йөрәкләре ярыла язды!—диде Ул үзенең кечкенә генә өстәленә капланып диярлек, рәхәтләнеп көлә-көлә.—«Ни өчен? Нишләп?? Бездән кеше көлдерер өченме???» Бу сораулар минем өскә ук булып кына түгел, сөңгеләр сыман очты.

Әмма Ул барыбер үз сүзендә нык торган. «Юк! Укымыйм булгач укымыйм!—дигән. Аннары, тегеләрнең күнелләрен бераз йомшартыйммы диеп шунда: «Әлегә...»—диеп тә өстәгән. «Бераздан күз күрер тагын...» дигән.

Менә шул бер сүз әти-әнисенең зиһенен ачып җибәргән күрәсең—«ярый алайса, бала чынлап та арыгандыр шул, әзрәк ял итсен булмаса...»—диеп, ризалашканнар ахыр чиктә.

Әйе, башкала халкы, ни әйтсәң дә, иркенрәк яши шул инде ул. Бу гаилә дә «баланы кая куярга?» диеп озак баш ватмаган—туган тиешле кешеләре менә шушы театрда түрәләрнең берсе икән, ул аны үз янына эшкә алган.

—Тәки минемчә булды! Бирешмәдем!

Аны хуплап мин дә бер ике сүз әйттем бугай инде. Үз шәхесен яклавын, ирекнең кадерен белүен җупләдем, ахрысы.

Тәрәзәне башта кечкенә генә дигән идем дә, әмма бу кызый белән гәп кора-кора аның бәләкәйлеге бөтенләй күзгә күренми үк башлады.

Икебез ике яктан теттерәбез генә мин сина әйтим!

Шулай байтак кына чүкердәшкәч—ул арада билет алырга килеп китүчеләр өч-дүрт кенә диярлек булды—сүз арасында гына дигәндәй мин моннан сорап та куйдым бит:

—Әле син монда озак утырасыңмы соң?

Ул шундук өстәлендәге кечкенә генә сәгатькә күз салды:

—Минем абзый бик тә тәртип ярата. Дүрткә хәтле утырмыйча ярамый инде...

Аның бу сүзләре мина нәрсәдер вәгъдә итә сыман тоелды һәм шундук болай дип тә сорарга тәвәккәлләдем:

—Ә мин сәгать дүрткә бирегә килимме соң?

Әлбәттә, бу инде турыдан-туры аның белән очрашу билгеләү иде. Мин ул чагында тиз арада әнә шуңа җөрьәт иттем булып чыга!

Кызый әллә ни куркып тормады, риза булды.

—Син миңа үзегезнең шәһәрегезне күрсәтерсең, ярыймы?—диде Ул балаларча беркатлылык белән, минем күзләремә туп-туры карап.

Без сөйләшеп торган бу вакыт төш турлары иде. Аның вәгъдәсен алгач, билгеле мин дә инде озак басып тормадым. Билет сораучылар да күбәеп китте, ахрысы—кыскасы, саубуллашып китеп бардым.

Китүен киттем, ләкин йөрәк бөтенләй Аның янында калды бит, малай! Башыма да һич бүтән нәрсә керми, гел Аның турында гына уйлыйсы килеп тора! Күз алдында да Ул: Аның сары чәчләре, коңгырт күзләре, уртача тулылыктагы назлы иреннәр...

Сәгать дүрткә! Сәгать дүрткә!

Колакта да әнә шул сүзләр яңгырап тора. Юк, яңгырамый—дөресрәге, сихри музыка сыман ишетелә ул сүзләр. Бер тылсымлы аһәң булып бөтен эчке барлыгымны биләгән иде алар.

Әйе—сәгать дүрткә... Ләкин менә шуңа хәтле вакытны ничек итеп үткәреп җибәрергә соң?! Бу—вакыт дигәнең—үлгән кебек бит хәзер, һич кенә дә кыймылдарга теләми.

Ул үшән минутларны, ул ялкау сәгатьләрне тизрәк үткәрү өчен ниләр генә эшләп бетермәдем мин: өйгә дә әллә нинди, гомер күрмәгән урау юллар белән кайттым, озак-озак итеп душта коендым, бер дә ашыкмыйча гына ашап та алдым, җәй көннәрендә бер дә карарга яратмасам да телевизор кабыздым... Дивандагы мендәргә чалкан яткан килеш үзем шул тартманы карыйм кебек, ә бер күзем барыбер диварга элengән сәгатьтә. «Ичмасам өч кенә тулса да ярар иде инде... һич югы өйдән чыгып китәр идем дә, Ана таба бара башлар идем...»

Бөек Пушкинның:

> Как ждет любовник молодой
> Минуты верного свидания!—

дигән юлларын хәтерлисездер—мин бахырыгыз да ул көнне нәкъ әнә шундый татлы да, газаплы да булган көтү, зарыгып көтү халәтендә идем!

Ә инде көндез без сөйләшеп торган ул урынга якынаю мизгелләре... Минем йөрәкнең гомер булмаганча дулый-дулый тибенүе... Гүяки үзенең аранында бер яхшы ат тибенә, ярсып йөренә, эчендәге дәртенә чыдый-чыдаша алмый.

«Дүрт тулганны көтеп тормыйм әле... Бер ун минут булса да алданрак килим...» диеп, теге будкага таба якынайсам—ни күрәм: бу кызый инде үзенең тавык кетәклеге хәтле генә кассасын бикләп, тәрәзәсен япкан да, үзе будка янына, тышка ук чыгып баскан! Аны күргәч, башта бер мәлгә тукталып, күзәтеп тә тордым: шактый кыска итәкле ак күлмәктән, гәүдәсе, буй-сыны шундый килешле—чып-чын фәрештә инде менә! Бер дә Җир затына охшамаган! Юк, һич кенә дә Җир кызы түгелдер бу!

Ул икенче якка таба карап тора, ә мин теге зур кибет ягыннан әкрен генә якынлаштым да, монда җитәргә ике-өч адым кала туктап, көлүемне көч-хәл белән тыя-тыя:

—Күкү!—дидем.

Ялт итеп борылды ул. Һәм шундук минем кулыма да килеп ябышты.

—Әй, синмени әле бу?! Ничек ул яктан килдең соң син?! Киткән чагында менә болайга таба киткән идең түгелме соң син?!

Әйе, әйе—менә шулай тиз-тиз, ашыга-ашыга, бик дәртле итеп, тавышыннан ук сизелеп-бәреп торган хис белән сөйләшә иде ул.

Аның болай сөйләшә башлавы миндәге кыенсыну, тартыну тойгыларын бөтенләй бетерде. Киресенчә, шул арада ул миңа бик тә үз, бик тә якын һәм... Һәм хәтта бик кадерле дә булып күренде.

Күрәсең шуның өчендер, мин аңа озаклап, текәлеп карап тора бирдем. Торган саен икебезнең ара якынайганын тоя-тоя, ниндидер эчке дулкыннар хәрәкәтен сизә-сизә.

Минем мондый үтә җитди карашыма ул да игътибар итте һәм:

—Ә нәрсә булды?—диеп сорады.

Шулай ук озак уйлап тормадым, күңелемдәгене әйттем дә салдым:

—Син... Син миңа бик тә, бик тә кадерле кеше булырсың, ахрысы!

Бу минутларда Аның үзенең дә хәлләре шуңа якынрак идеме, әллә Ул минем сүзләремнең ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген аңлавын, төшенүен сиздерергә теләдеме—нәрсә сәбәп булгандыр—әмма минем әлеге сүзләремә җавап итеп Ул бер дә кыенсынмыйча миңа сыенды... Мин дә кулымны җайлап кына Аның биленә куйдым, бу нәфис гәүдәне бер дә җибәрмәскә теләгән кеше сыман үземә кыстым...

Ләкин көпә-көндез, яныңнан халык ташкыны агылып торганда, алай итеп озак басып тора алмыйсың бит инде, мин дә әкрен генә иелеп, аның колагына гына болай дидем:

—Безнең шәһәрнең иң-иң матур урынын күрсәтимме?

Шунда Ул иреннәрен ачар-ачмас кына кыймылдатып, пышылдап кына:

—Бик тә күрәсем килә...—диде.

... Ә аннары без такси тоттык.

Ямьле урыннар дигәндә күп инде алар бездә! Гел дулкынланып-уйнап торган чал Иделнең яр буйлары дисеңме, бөтен шәһәр буйлатып сузылып киткән, үзе бер сихри диңгез сыман җәйрап яткан Олы күл дисеңме, шәһәребезгә терәлеп үк торган калын урманның җиләкле аланнары дисеңме, Иделнең аргы ягындагы тау битләрендә җимеш бакчалары, андагы аулак-аулак сукмаклар дисеңме...

Безнең машина исә ул көнне шәһәр буйлап Олы күлнең аулаграк урындагы икенче башына таба җилдерде. Исәбем—Аны көймәдә йөретү, бу шәһәр кызын үзем яраткан су дәрьясының, су стихиясенең эченә үк алып керү иде. Мәскәүдә күрмәгәнен бирегә, безнең шәһәргә килгәчтен күрсен әле! Табигать гүзәллегенең өр-яңа төре белән танышсын әле!

Озакламый Олы күлнең теге башына килеп тә җиттек без.

Йа Хода, бу күл бүген тагын да матураеп киткән түгелме соң?!

Әйе, әле бит аның ярларында яшел чирәм дә үсә хәтта. Безнең шикелле килеп йөрүчеләр шактый булса да, әле ул яшеллек һаман бирешми, яши бирә.

Без килгән урамның асфальты бетү белән, тәпиләп сөзәк кенә үрдән төшәсең дә, әнә шул йоп-йомшак чирәмлеккә аяк басасың. Ә яр буе тагын да сөзәгәя бара, син ипләп кенә чирәм өстеннән тәпилисең һәм шулай итеп йомшак келәмнән атлый-атлый Олы күлнең йомшак суына ук килеп терәләсең... Анда инде бөтенләй икенче гүзәллек тантана итәргә тотына. Ярына килеп басу белән үк Олы күл сине үзенә тарта, тагын да эчкәрәк чакыра башлый—син инде аның ярында, аның янында тыныч күңел белән генә басып тора алмыйсың!

—Нинди матурлык! Нинди зур күл!

Ул күл буе чирәменә ялан аяк баскан да, ап-ак туфлиларын уң кулына тоткан килеш, аларны җиргә куярга да онытып, алга—күлнең галәмәт зур, иркен өслегенә текәлгән. Инде Ул да бу күлнең тылсымына

эләккән—хәзер инде Анын өчен дөньядагы бөтен нәрсә югалган, исеннән чыккан!

—Шушы кадәр саф гүзәллек зур шәһәр эчендә ничек саклана алган? Бу күл бит үзе бер диңгез сыман! Сезгә инде «диңгез буена» диеп көньякларга бөтенләй барып йөрергә дә кирәкми икән бит!

Аннары Ул аяк киемнәрен шунда, басып торган җиренә генә ташлады да, әкрен генә атлап, сак кына басып, су эченә кереп китте... Сай су астындагы тыгыз һәм тигез комга баса-баса Анын ашыкмыйча, йөзгән кебек кенә адымнар белән күл эченәрәк керә баруы... Ап-ак күлмәкле зифа буйның бу күл өстендә бер романтик җанлы җилкән кебек күренүе... Менә боларның һәммәсе—чын икәнлегенә ышануы кыен, бик тә кыен булган бер сихри төш кенә шикелле иде ул көнне. Чын төш, минем өндәге төшем иде бу!

Бераздан ул минем янга әйләнеп килде дә, тавышына бик тә иркә төсмерләр чыгарып:

—Нигә соң син су буена киләсебезне әйтмәдең?..—диде.—Мин су кергә торган киемемне алган булыр идем.

Анын шулай диеп әйтәсен мин үзем дә сизенгән идем инде, билгеле. Дөресрәге, машинага утыргач та, исемә төшкән иде ул минем. Ләкин инде бер кузгалгач, янадан кире борыласы килмәгән иде, шуңа күрә ана да әйтеп тормаган идем.

Ләкин минем башта икенче бер уй да бар иде шул.

—Ә беләсеңме без ничек итәбез!—дидем мин аңа һәм Ул аңышканчы шундук кулларыннан да җитәкләдем. Бераз гына арырак агачтан ясап куелган сарай шикелле корылмалар бар, йөреп килү өчен көймә бирергә тиешләр! Без ашыга-ашыга шул тарафка атладык. Көне матур булгач, көймәдә йөрергә теләүчеләр аз түгел иде, әлбәттә, ләкин шулай да әлләни озак көтәргә туры килмәде.

Ачык яшел төскә буялган җип-җинел агач көймәнең чылбырын минем кулга тоттырулары булды—шулчак мин гүяки үземнең бала чагыма әйләндем дә кайттым! Зур су буенда үткән, үзенең биек-биек дулкыннары белән без бала-чаганы куркыткан да һәм эмсендергән дә, әнә шул дулкыннар арасында хәтта чатнап яшен яшьнәп, яңгыр койган караңгы төннәрдә дә йөрегән бала чагыма әйләнеп кайттым мин гүя! Әйтерсең, минем кулыма тылсым иленә алып китәчәк бер сихри чаптарның йөгән тезгенен тоттырдылар! Гүяки, без менә хәзер әнә шул тылсымлы чаптарга атланып, әкияти дөньяга—иң матур хисләр һәм уйлар дөньясына атлыгачакбыз!

Ләкин Анын үз гомерендә бер генә мәртәбә дә көймәгә утырганы юк икән лабаса! Әнә Ул басманың читенә үк килгән дә, чын-чыннан куркып, аяк атларга да кыймый басып тора. Ә күзләре яна үзенең, теләге бик тә бар үзенең!

Нишлисен инде—башта үземә керергә туры килде. Аннары гына, үгетли-үгетли, иплән кенә кулыннан тарта-тарта, төрлечә ымсындыра-ымсындыра, тәки көч-хәл белән көймәгә аяк бастыра алдым мин моны... Көймә үзе дә яшь тай кебек урында тик кенә тора белми: чайкала, як-якка аварга тели, бер урында түзә алмый... Көймә аз гына селкенеп киткән саен минем кызыем да чырыйлап кычкырып кулларын болгый, чәбәләнә башлый... Кыскасы, мин моны көч-хәл белән генә көймә койрыгындагы утыргычка хәтле алып барып утырта алдым. Ә үзем инде, билгеле, ишкәк янындагы урта эскәмиягә урнаштым.

Кызым көймәгә кереп утырса да, әле һаман ушын җыя алмый, ахырысы—ул ике күзен дүрт итеп миңа текәлгән, гүя миннән башка бүтән бер генә нәрсәне дә күрми. Гүяки мин аның өчен бердә берденбер таяныч та, коткаручы да һәм аны бу якты дөньяда саклап алып калучы да.

Ярый, ул шулай итеп миңа текәлгән килеш кымшанырга да куркып утыра, ә мин эчемнән генә «Аллага тапшырдым...» дидем дә, иплән кенә ишеп киттем. Көймә шундый да җинел, анын уенчык кебек матур ишкәкләренен авырлыгы бөтенләй дә сизелми—ә мин авылча каерып-

каерып ишәргә өйрәнгән, шулай күнеккән—бирсдә дә куркып-нитеп тормадым: бер көйгә ныклап торып ишәргә керештем. Ниятем—тизрәк күлнең эченәрәк кереп китү, җәтрәк кешеләрдән, аларның күз карашыннан аерылу, үзебез генә, ялгыз калу.

Тигез генә көйгә шулай байтак ишкәч, көймәбез дә ипле генә баргач, кызыем да тынычлангандай булды, тирә-юньгә караштыра башлады. Аның ягымлы, матур йөзендә борчылу галәмәтләре югалып, алар урынына кызыксыну, соклану билгеләре күренде.

Ярдан шактый ук ераклашкач, үзем дә «уф» дигән булып (гәрчә һич кенә дә арымасам да!) ишкәкләремне өскә күтәрдем, шулай итеп алардан бераз су тамызып торгач, икесен дә эчкә үк алып куйдым.

—Ә моннан ничек күренә? Матурмы?

Ул инде тәмам тынычланып, бу су стихиясенә күнегеп беткән иде, ахрысы—минем сүзләремә җавап итеп иң башта бөтен дөньясын онытып, ихластан, үзенең җан һәм йөз гүзәллеген балкытып елмайды... Берничә секунд эндәшмичә торды, эченнән ниндидер сүзләр эзләде кебек Ул. Аннары гына, ашыкмыйча, бер үтә җитди нәрсә турында сүз алып барган төсле итеп:

—Монда ул сүз генә бик аз бит... Монда бит чын рәссам, бик тә талантлы рәссам булырга кирәк!.. Әле ул чагында да—гаять зур талантлы рәссам ясаса да—бу гүзәллекнең барча төсмерләрен барыбер чагылдырып бетерә алмаячак бит!—диде, үз яшенә һич тә хас булмаган тирән, төпле акыл белән.

Аның мондый ихлас уйлары мине дә ниндидер яңа, кызыклы фикерләргә этәрә иде.

—Ә беләсеңме—миңа бит бу табигать, менә шушы манзара тагын да матуррак күренә... Сиңа исә ул алай ук күренми!

Мондый сәер сүзгә кызыем аптырап калды. Ни уйларга да белмәде, ахрысы. Кешене кимсетергә теләү түгелдер ич инде бу сүз...

Шуңа күрә мин үземнең тел төбен ачыклап бетерергә ашыктым:

—Бу гүзәллек эчендә шундый матур итеп утырган бер чибәр кызны дә күрәм мин чөнки!

Сүзләрем Аның зиһененә шундук барып житте, билгеле. Ул рәхәтләнеп, онытылып көлеп җибәрде.

Әйе, ул көнне безнең Олы күл искиткеч гүзәл иде. Һәм ул—җансыз, аңсыз күл булса да, бүген ул да бик бәхетледер сыман иде. Чөнки ... Чөнки аның кочагында шундый чибәр яшь кыз белән ул гүзәлгә торган саен ныграк гашыйк була баручы яшь егет йөзә бит.

Ул көнне ямьле күл өстендә байтак гомер юандык без. Ә инде кояш түбәнәя башлагач яр буйлары, бигрәк тә аның текәрәк ягы тагын да матуррак, серлерәк булып күренә иде. Андагы кечкенә-кечкенә агач өйләр, күл эченә үк кереп торган тар басмалар, ул басмага бәйләп куелган көймәләр, ә кайсыбер култыкларда күзгә чалынган бәләкәй саллар—алары казык белән генә ярга беркетеп куелганнар—боларның һәммәсе шәһәр җиреннән килгән кеше өчен бик тә тансык булган гүзәл күренешләр иде. Аларга карап күз һич кенә дә туймый, аерыла алмый иде. Ә инде Мәскәү шәһәрендә туып, шунда үскән яшь кызга болар бигрәк тә нык тәэсир итә, бер әкият иле сыман тоела иде булса кирәк.

Юри шулай эшләгән шикелле икебезнең дә сәгатьләребез юк икән. Моны искә төшергәч:

—Бәхетлеләргә сәгать кирәкми шул!—дип көлештек инде...

Ә шулай да кояш баерга җыенгач Ул җитдиләнеп китте һәм:

—Миңа кайтырга кирәк...—диде.

Көймәбезне иплэп кенә ярга таба бордым. Салмак кына, ашыкмыйча гына ишә башладым...

Шәһәр үзегенә, Ул торган кунакханәгә кайтып җиткәндә кояш безнең белән саубуллашып та өлгерде... Ул да ашыга-ашыга кунакханә ишегеннән эчкә кереп китте.

Күл буена икенче көнне дә бардык без. Бу юлы инде икебез дә су коена торган киемнәребезне алган идек. Әмма безгә кичә көймәдә йөрү дә бик ошады, шуңа күрә ул рәхәтлектән дә баш тартасыбыз килмәде — нәкъ кичәгечә күлнең уртасына ук кереп киттек. Кешеләрдән ераклашкач, өсләрдән салып аттык. Аның буй-сыны гына түгел, киган коену костюмы да бик матур иде. Ул үзе дә «күз генә тия күрмәсен... сөбханалла» диеп карарлык иде...

Көймәдә утырган көе байтак кына кояшта кызынгач, су коенасыбыз да килә башлады. Монысы шулай, су керәсе килә — әмма күл уртасындагы як-якка чайкалып торган көймәдән тирән суга кинәт кенә сикереп төшү минем үземә дә шиктый ук йөрәк сорый торган эш булып чыкты. Ә инде Ул бигрәк тә курка иде. Болай итеп су кергәне юк бит әле аның — шәһәр кызы ич ул! Җитмәсә, бик тә яшь бит әле үзе...

«Ничек итәргә соң?» — диеп озак кына баш ваттым мин ул көнне. Көймә кырыена утыр башта, шулай суга акрынлап кер дияр идең — көймә шундук капланырга гына тора... Тәмам башваткыч булды бу миңа... Ахыр чиктә үзе утырып барган арткы урындыктан иплә кенә суга төшерергә булдым кызыйны. Үзем бер кулым белән көймәгә тотындым — мин аста, суда бит инде хәзер — үзем аңа әйтәм:

— Әйдә, кулларың белән мине муеннан кочакла да, шулай итеп әкрен генә суга төш!

Икебез дә шырык-шырык көләбез тагын. Чөнки үз хәлебез кызык тоела, әкәмәт кызык тоела безгә...

Шулай, мин әйткәнчә, башта Ул иплә кенә миңа асылынды. Ә мин, әйткәнемчә, бер кулым белән көймәгә ябышкан — батып китмәс өчен — икенче кулым белән җай гына аны кочаклап алдым... Шулчак үзе дә кызарып китте, минем күзгә карамаска тырыша... Минем дә аны җибәрәсем килми. Хәтта, онытылып китеп, кирәгеннән ныграк та кысып куйдым кебек әле...

Менә шулай итеп су уртасындагы көймәдән тирән суга төшү әмәлен өйрәндек без... Ә минем өчен бу тирән суга төшү генә түгел — ярсу бер ут дәрьясына бату булды, ахрысы. Әйе, әйе — әнә шулай, су уртасында, су эчендә торган чагында икебезгә дә ут капты бугай безнең... Һәм беренче үбешүебез дә әнә шундый бәхетле мизгелләрнең берсендә булды. Ул чагында үбешкәннән соң тыныч кына суга төште дә, көймәнең икенче ягына таба йөзеп китте... Гүяки миннән качуы, читенсенүе, оялуы...

Әнә шулай бер атналап рәхәт чиктек без. Көн саен су коендык, бөтен ләззәтен татып кояшта кызындык, көймәдән дә аерылмадык...

Ә аннары яңгырлар китте. Тоташ яңгырлар... Үзе жылы яңгыр, җәйге яңгыр инде ул — ләкин барыбер андый көнне су буенда йөреп булмый ич инде. Кая барырга? Кинога мазарга һич кенә дә керәсе килми... Җәй өчен театр да бөтенләй батмый... Аңа аяк тартмый, күңел теләми. Нишләргә соң?

— Әйдә соң, миңа барып утырабыз! — дидем мин, берчакны тәвәккәлләп.

Ул башта бер сүз дә дәшмәде. Тып-тыныч кына күзгә карап торды. Аннары гына, суза төшеп:

— Әйдә-ә... — диде.

... Ул чакта мин шәһәр үзәгеннән ерак түгел, әмма тыныч һәм күпмедер дәрәҗәдә борынгылыгы да сакланган, язларын-җәйләрен юкә исенә күмелә торган лейтенант Шмидт урамында — ике катлы агач йортта бер әйбәт кенә бүлмә алып яши идем. Үзебезнең ишек алды, капка төбендәге эскәмияләре, өебез каршында су колонкалары булган бик матур, ягымлы йорт иде инде ул. Минем тәрәзә каршысында гына чия бакчасы да бар иде әле хәтта. Язларын ул бакча ап-ак булып чәчәккә күмелә торган иде... Нәкъ менә яшьлек инде, яшь кешенең йөрәк хисләре инде ул бакча үзе дә!

Бүлмәм эчендә әллә нинди уш китәрдәй җиһазлар юк-югын. Чөнки

минем аның ишегә бик ис китми—элек тә шулай иде, хәзер дә карашларым әлләни үзгәрмәде. Бу хакта бер фикерем дә бар. Минем бүлмәдә минем жаныма рәхәт булырга тиеш! Күңелемә жылы, жайлы, унайлы булырга тиеш минем бүлмәдә! Ә кайсы берәүләр күзләре кызыккан бик «стильный» жиһазлар кертеп тутыра үз бүлмәсенә. Ләкин андый бүлмәләрнең байтагына кергәч ничектер, каяндыр салкын бәрәдер сыман тоела. Күңел үзенә урын таба алмый интегә. Жан өшегән кебек була анда...

Ул керер алдыннан утны да кабызып куйгач, шактый гына яктырып, матураеп китте торагым.

Ул бүлмәне карый, ә мин исә аннан күземне алмыйм. Бүлмәм Аңа ничек тәэсир итәр икән? Башкала кызы бит... Моның ише буйдак кеше бүлмәләрен күргәне булмагандыр әле моңарчы...

Юк, йөзенә ризасызлык чалымы чыкмады Аның. Китап тулы киштәләргә, өеп-өеп куелган грампластинкаларга бигрәк тә кызыксынып, озаклап карады.

Кунак килгәч, мин дә тизрәк музыка куярга ашыктым. Билгеле, ул чагында әле хәзерге шикелле магнитофоннар түгел—гап-гади уйнаткыч иде. Электр белән уйный торганы.

—Үземнең иң яраткан музыкамны куйыйммы?—дип сорыйм.

Ул бүлмә белән танышкан жиреннән миңа таба борылып карый һәм ни өчендер сүзсез генә баш селки. «Мин риза» диюе инде бу.

Мин Аңа, беләсезме, нинди музыка куйдым?

Француз композиторы Морис Ровельның «Болеро»сын куйдым мин Аңа!

Үземнең иң яраткан көем булганга күрә куйдым инде мин аны—монысы билгеле. Ләкин менә хәзер, сезгә сөйләгән чагында, яңадан бер кат уйлап карыйм да, шундый фикергә киләм: чыннан да, бик дөрес булган ич ул чагында әлеге музыканы куюю! Чөнки биредә, бу әсәрдә, Шәрекъ рухының, Шәрекъ жанының бөтен барлыгы, һәммә тирәнлеге, сере һәм балкышы, куанычы һәм фажигасы—барысы-барысы бик тә тәэсирле чагыла бит!

Үзегез дә беләсез инде—бик озак уйнала ул музыка. Дәү пластинканың ике ягын да биләп тора ул. Әллә тагын бер сәгать уйный... Ләкин Ул түрдәге тирән кәнәфигә аякларын бөкләп менеп утырды да, шунда кымшанмыйча музыка дөньясына чумды.

Ә минем өчен инде Ул үзе серле музыка иде. Тере, жанлы Музыка! Шуңа күрә иплләп кенә мин дә Аның янына, Аның янәшәсенә килеп утырдым...

Тәрәзәсе чия бакчасына караган минем ялгыз бүлмәмдә ул көнне Ровель болеросы тагын да моңлырак, тагын да хислерәк булып ишетелеп торды сыман...

Ә аннары без Аның белән япь-яшь юкәләр яфрак ярган, уйдык-уйдык янгыр сулары жыелып торган тып-тыныч урам буйлап шәһәр үзәгенә таба атладык. Бер-беребезгә сыенып... Безнең икебезнең арада урнашкан жылылыкны, якынлыкны югалтырга теләмәгән сыман...

Кунакханәгә житә башлагач:

—Минем абзый өйдәдер бит инде! Мине бик орышыр бит инде ул!—дип борчыла, ашыга башлады, адымнарын кызулатты. Йөзе дә үтә житдиләнеп китте Аның.

Әйе, үзен театрга эшкә алган һәм бирегә ияртеп килгән абзыеннан бик тә шүрли иде Ул. Нишлисең, Аны да аңлап була инде. Чөнки абзый дигәне аңа начальник кына түгел, туган тиешле кеше дә бит әле. Алар гастрольгә китәр алдыннан әти-әниләре, әлбәттә, кат-кат тукыганнардыр инде—«кызыбызга күз-колак бул, зинһар!» дип бер генә мәртәбә әйтмәгәннәрдер.

Шуңа күрә без Аның белән гел яктыда, дөресрәге кичкырын очраша идек. Ләкин тора-бара болай очрашу миңа сәеррәк булып тоела башлады. Һәм көннәрдән бер көнне мин моннан сорадым да:

—Ә кичләрен нишлисең соң син? Вакытыңны ничек уздырасың? Ләкин Аның бу сорауга әлләни исе китмәде. Ул гадәтенчә мөлаем генә итеп елмаеп куйды да, ашыкмыйча, сузыбрак кына:

—Әзрәк телевизор карыйм... Әзрәк китап укыйм...—диде.

—Шулай итеп бөтен кичең үтеп китәме?

Бу сүзем Аны шактый ук җанландырып җибәрде.

—Үтә! Һәм ничек кенә әйбәт үтә әле!

Мин бу җавапны төшенеп үк җитмичә беразга тын калдым. Яшермим, күңелем төбендә аз гына шик тә, хәтта көнләшүгә охшаган начар тойгы да, сизелгәләп ала иде кайчак. «Кичләрен гел үзе генә микәнни соң ул?!»—дигән эчке корт та кымшангалап куя иде күңелнең бер почмагында.

Әллә шуны сизеп, әллә инде үзенең яңа гына башлаган сүзен дәвам итеп:

—Кайберәүләр шикелле ялгызлыктан курыкмыйм бит мин,—диде Ул. Үзем генә калганда да күңелсезләнә белмим мин... Чөнки минем матур-матур уйларым була... Ә аннан соң... Ә аннан соң йокларга да бик яратам мин! Үземнең йомшак мендәремне кочаклыйм да (минем әле монда Мәскәүдән үзем белән алып килгән бәләкәй генә мендәрчегем дә бар) көндез булганнарны янадан күз алдыма китерә-китерә, хыяллана-хыяллана, әкрен генә йокыга да китеп барам.

Ул үзе сөйли, үзалдына елмая, ә үзенең миңа таба борылып алган чакларында чалынып калган күз карашы әллә нинди серле, кинаяле, шаян...—һәм тагын әллә нинди, әллә нинди—һич аңлап, аңлатып бетерерлек түгел! Хатын-кыз күңеле бит ул күп чагында кара урман кебек: ямьле дә ул һәм серле дә, матур да ул һәм куркыныч та, үзенә таба тарта да ул һәм өркетә дә, серләре-табышмаклары белән аптырата-уйландыра да ул... Ләкин табигать Анабыз без ир-атны гел дә әнә шул Серлелеккә тартылып тора торган итеп яраткан шул! Күрәсең, яшәешнең бөек нигезе, башлангычы да, дәвамы да әнә шулдыр инде.

...Шулай итеп без Аның белән икеме-өчме атна буе, көн саен очрашып йөрдек. Аккош күле ягындагы урманга да чыктык, шәһәр урамнарын да байтак кына таптадык, аулак тыкрыкларны да читтә калдырмадык... Ә инде яңгырлырак көн булса, минем бүлмәгә кайтып утырабыз да, хискә, хыялга бирелә6ез. Караган кинолар, укыган китаплар турында сөйләшәбез.

Көннәрдән бер көнне безнең очрашуга кулына әйбер тотып килде Ул. Ап-ак кәгазь белән бик матур, җыйнак кына иттереп төргән. Тыштан караганда кәнфит тартмасы сыманрак күренеп тора. Әмма миңа кәнфит нигә кирәк? Бүлмәгә баргач, чәй эчәргәдер дисәң инде...

Ләкин үзе бу хакта башта ләм-мим, бер сүз дә дәшмәде.

Шулай да мин сорамый булдыра алмадым:

—Әллә тәмле нәрсә дә алгансың инде?..

Ишетте, әмма шактый гына дәшми барды Ул. Бары тик бераздан гына:

—Сиңа барып җиткәч, ачып күрсәтермен, яме...—диде, сабыр гына итеп.

—Я-р-а-а-ар...—дигән булдым мин дә бик аптыраган, сәерсенгән тавыш белән.

Әлбәттә, барып җиткәчтән дә иң беренче сүзебез шул булды инде. Ә менә минем хәтердә аның сүзләре генә түгел, бөтен буй-сыннары да, ничек хәрәкәтләнүләре дә, барча адымы, хәрәкәте дә калган. Минем күңелдәге бер мәңгелек кино кебек ул күренеш...

Менә Ул ашыкмыйча гына туфлиларын сала... Ап-ак нәфис туфлиларын... Аннары аларны иплән кенә бүлмә почмагынарак этеп куя. Шул арада аның тулы матур балтырлары ап-ак туфлилар янәшәсендә яна бер сәнгать әсәре сыман күренеп кала. Озакка хәтергә сеңә...

Шуннан соң Ул бүлмә түренәрәк үтә дә, башта кулындагы әйберне

минем язу өстәленә куя. Мине дә үзе янына чакыра.

Нишлим инде: мин дә Анын кырыена барып басам да, сүзсез генә әлеге әйбергә текәләм. Бер карасаң кызык кына күренеш инде бу, валлаһи!

Шулай берәр минут чамасы вакыт үткәч, Ул әлеге әйберне кулына ала да, иплэп кенә кәгазен сүтә башлый һәм аннан чем кара тышлы ... бер китап килеп чыга! Әйе, әйе—китап!

Тышына язылган сүзләрне укып алам:

—Жан Ануй...

Аптырыйм...Чөнки бу сүзләр миңа бер нәрсә дә аңлатмый, бер генә нәрсә турында да белгертми.

Шуңа күрә байтак кына гомер тып-тын торам. Кыскасы, Аннан нәрсә диеп кенә сорарга да кыймыйм. Үземнең наданлыгымны да сиздерәсе килми. Әмма беләсе килә, аңлыйсы килә! Бу сернең төбенә төшенәсе килә.

—Мине иң нык аңлаган язучы бу!—Күзләремә онытылмаслык итеп карап, шулай диде Ул. Һәм, «минем сүзләремне аңлап җитәсеңме икән син?» дигәндәй, озаклап текәлеп карап торды әле Ул миңа. Бик озак күзен алмады. Мин исә ни өчендер кыенсындым, күземне читкә алырга тырыштым кебек ул чакны... Аннары инде китапка үрелдем.

—Карарга мөмкиндер бит?

Француз драматургы икән бу. Китапны ачып җибәргән иң беренче әсәрнең исемен укыйм—«Биштәрсез сәяхәтче»... Күңелемә шундук романтик тойгылар, күзаллаулар дулкыны кага башлый... Теге көнне, күл буенда, яшел көймәнең чылбырын кулыма алган чактагы хисләр миндә яңадан җанлана... Бераздан алар шактый көчәеп үк китә... Ни өчендер Анын белән әнә шул җиңел матур көймәдә барган чагыбыз күз алдына килә. Үзебез белән бер әйбер дә алмыйча, сәгать ише нәрсәләргә ис тә китмичә йөзгән көн... Дулкыннар стихиясенә бирелгән минутлар.

Сүзсез генә басып торабыз шулай... Чыннан да, әлегә безгә бер генә сүз дә кирәкми шикелле. Барысы да шундый әйбәт һәм үз урынында: әз генә бер хәрәкәт булса да, нинди дер ым гына күренсә дә—әлеге идиллик матурлыкның яме китәр сыман тоела.

Биштәрсез сәяхәтче... Әсәрне укымаган килеш тә мин язучы кешенең бөтен күңелен аңлап алдым кебек. Алай гына да түгел: һәммә романтик җанны иң нык аңлаучы кеше ул минә миндер сыман тоела башлый.

—Бу китапны мин сиңа калдырам.

Ә мин тиле кебек шундук сорап куям:

—Әллә бөтенләйгәме?!

—Юк шул! Минем бердәнбер китабым ул! Үземә дә бик кадерле. Укып чыккач, кайтарырсың инде син аны...

Ул көнне тагын нәрсәләр булгандыр—мин инде аларны хәтерләмим, чөнки калганнары инде миңа кызык түгел.

Шулай тагын күпмедер көн үтте.

Бер көнне исә Ул мине болай диеп сөендерде:

—Бүген кич минем абзый өйдә булмый—мине тикшерә алмый. Әйдә, минем бүлмәдә кич утырабыз!

Чыннан да, инде күпме гомер таныш булып, Анын торган бүлмәсен дә күргәнем юк иде ич әле. Бик теләп риза булдым. Тиз генә гастрономга да кереп чыктым. Тәмле-тәмле әйберләр алдым, бер шампан шәрабе дә эләктердем...

Әйе, ул көнне беренче мәртәбә Анын бүлмәсенә аяк бастым мин. Әле дә исемдә: алтынчы катта, коридорның иң аргы башындагы бер бәләкәй генә, аулак кына бүлмә иде ул. Ә тәрәзәсе исә, юри көйләнгән сыман, нәкъ менә без су кереп йөрегән Олы күлгә таба карап тора иде анын! Мин моңа шаккаттым!

—Кара әле! Без көндез йөрегән җирләрне син кичен күзәтеп ятасың икән ич!

Моңа игътибар итүем Аңа да бик ошады.

—Әйе шул! Без синең белән йөргән сукмакларга бүтән кеше аяк баса күрмәсен дип, саклап торам мин аларны!

Әнә шунда яп-якты тәрәзә янына басып, икебез дә күл өстенә карап тордык... Тып-тын гына калып, озаклап... Әле моннан берничә көн элек кенә булган кадерле күренешләр, суның дулкынланулары, күңелнең дулкынланулары—барысы да менә хәзер якты тәрәзә аша бу бүлмәгә үтеп керә шикелле иде. Без менә хәзер басып торган идән дә гүяки көймә кебек тирбәлә, чайкала сыман иде... Һәм әнә шул тойгы башны да жинелчә генә әйләндерә иде...

Өстәле кечкенә иде Анның. Бар булган ризыкларны әнә шул бәләкәй өстәлгә тездек без. Билгеле инде: табыныбыз түренә патша кебек иттереп шампанны утырттык. Аңа карап байтак кына горурланып та утырдык бугай әле хәтта! Үзебезнең ул бәхетле мизгелләребезнең кадерен тагын да арттырдык бугай әнә шулай итеп.

—Без менә хәзер алтынчы катта утырабыз...—диебрәк башладым мин сүземне, аңа эчке мәгънә бирергә тырышыбрак.—Димәк, бәхетнең жиденче каты да янәшәдә генә, бик якында гына дигән сүз!..

Шампан шәрабе салынган касәләрне әнә шул бәхетле минутлар өчен дип күтәрдек без.

—Нинди тәмле...—дия-дия, бик тә нәзакатле хәрәкәтләр генә ясап, бик тә матур итеп йота-йота, ашыкмыйча гына эчеп утырды Ул шәрабне.

Анның ачык тәрәзә янында утыруы... Тәрәзәдән без йөргән күл буйларының, киң булып жәелгән күл өстенең күренеп торуы... Өстәлебездәге татлы шәраб белән тулган касәләр...—Болар барысы да мина ул чагында гаять тә романтик, кешене бик тә бәхетле итә торган мизгел булып күренде. Мин чыннан да үземне бәхетнең жиденче катында итеп сиздем! Ул чагында инде үзеннән үзе куллар кулга да үрелә иде...

Без әнә шулай—бәхетнең жиденче катына тәмам күтәрелеп житеп, онытылып утыра гына башлаган идек... Мин дә Анның янына килеп сыенган идем инде... Бәхеттән, ләззәттән, мәхәббәттән башка бүтән бер генә нәрсә дә көтелми иде инде бирелә... Бу—бары тик сөю-сөешү, сәгадәт минутлары гына булырга тиеш иде инде!

Әмма... Әмма ул көнне без һич кенә дә көтмәгән, уйламаган хәл булды: безнең өстебезгә ыжгырып Анның абыйсы килеп керде! Ишекне шакымыйча-нитмичә!

Күз алдыгызга китерегез менә. Алагаем юан гәүдәле, буйга да миннән шактый калку, ачудан тәмам йөзләре үзгәргән бер яп-ят адәм синең каршыңа килеп бассын әле! Бу бит әле минем үз кырыемдагы яшь кызыйдан, аннан көтелгән мәхәббәттән, наздан тәмам йомшаган, эрегән, мәрткә киткәндәй онытылып утырган чагында! Әле житмәсә бу адәм урамнан кергән көйгә—өстендәге искерәк фасондагы плащы да, кулындагы шактый ук буаз кара папкасы да кеше куркытырдай... Чып-чын газраил инде менә!

Нишлисең—утырган жиребездә аңа карадык та каттык инде. Бер сүз дә әйтә алмыйбыз. Бер генә хәрәкәт тә кыла алмыйбыз.

Ай-һай каты сүкте ул безне! Үзе дә кызарып бүртенде. Жикеренде, сукранды. Өстәл өстендәге әле яртысы да эчелмәгән шампаныбызны да ачу белән идәнгә атып бәрде. Анның шешәсе ни өчендер ватылмады тагын—әллә пыяласы бик калын иде—шул шешәдән алсу шәрабнең күбекләнеп идәнгә озак кына агып ятуы күз алдында калган...

Нәкъ кан төсле булып агуы...

Мин нишли алам?!

Әлбәттә, шыпан-шыпан гына чыгып тайдым инде...

Өлкән лейтенант Булатов әнә шулай дип сүзен бетерде дә, инде байтактан ук аңа диеп салып куелган ярты стакан ак аракыны бер тында авызына каплады. Өстәлдә әле ризык булса да хәмердән соң кабарга теләмәде. Землянкада үле тынлык урнашты.

Шулай бер-ике минут чамасы вакыт узды. Беркем дәшми иде.

—Өемә кайткач, ул төнне ничек үткәреп җибәрә алганмындыр инде, белмим! Бертуктаусыз ишекле-түрле йөрендем бугай, «нәрсә булды соң инде бу?!»—диеп баш ваттым. Йөрәк чамасыз әрни, җан кая керергә белми газаплана иде. Күзгә бер тамчы йокы кермәде!

Таңны көчкә аттырдым. Ә инде көн бераз яктыру белән, әзрәк тынычланып булмасмы диеп урамга, саф һавага чыктым. Шактый еракка ук китеп әйләнеп килдем.

Аннары инде «Аны күрергә кирәк!» дигән карарга килдем. Сөйләшергә, аңлашырга кирәк! Кичә Анын үзен генә калдырып китүем өчен гафу үтенергә дә туры килер бәлки...

Әйе, Ул анда иде.

Ләкин... Ләкин бу иртәдә минем килеп басуым Аңа албасты күренгәндәй тәэсир итте!

—Кит! Кит, зинһар!—дип кычкырды Ул, инәлеп-инәлеп.—Сине тагын бер күрсә, абзый мине эштән чыгарып, кире Мәскәүгә озатачак! Кит, зинһар!

Ул үзе әнә шул усал, кискен сүзләрне кабатлый, ә үзенең күзләрендә яшь, газап, әрнү.

Ике көн рәттән менә шушы күренеш кабатланды. Чөнки мин «бәлки бүген җуңләп сөйләшеп булыр...» дип, кичке дүртләр тирәсендә икенче көнне дә Анын янына барган идем...

Ә аннары миңа авылдан телеграмма килде. «Әтиең авырый, кайт» диелгән иде анда...

Авылда берәр атна чамасы юанып, кире килгәндә, шәһәребезнең үзәгендәге теге мәйданнан әлеге кечкенә будка юкка чыккан иде инде.

Ул урынга барып текәлеп-текәлеп карап тордым мин—тип-тигез асфальтта бернинди эз әсәре дә юк иде! Аз гына да эз юк иде анда!

Бу хәл минем бик тә ачуны китерде. Анын менә шулай—бернинди эзсез китеп югалуына ачу килә иде минем. Йөрәгендә дә бер эз дә калмагандыр сыман иде Анын.

Ә мин ничә көннәр газапланып йөрдем ул чакта. Әйе, әйе—бу сүз өчен һич тә оялмыйча, кыенсынмыйча әйтәмен! Чынлап та, тилмереп йөрдем мин ул чагында. Шул тирәгә киләм дә, башына әйләнчек булган сарык сымак—тик буталып йөрим. Озак вакытлар шул тирәдән китә алмыйм.

Ләкин күпме генә әйләнсәм-тулгансам да—анда тип-тигез, капкаты, шоп-шома таш кына иде... Асфальт кына иде! Гүяки Ходай үзе ул көннәрдә минем тормышымнан моңарчы булган дулкыннарны, көймәне, суда тирбәлүләрне, алай гына да түгел: көчле хисләрдә тирбәлүләрне алды да, алар урынына әнә шул каты, ныклы, таш язмышы гына калдырды... Һәм мин үзем дә гүяки шул көннәрдә шәһәр уртасындагы бер таш һәйкәлгә әверелдем! Гүяки әнә шул чагында мине яшьлек үзе калдырып, ташлап китте!

Землянка эче яңадан тын калды. Әмма ул озак дәвам итмәде, шырык-шырык көлә-көлә капитан Федотов сорау бирде:

—Син байтак кына сүз сөйләдең, Булатов, ләкин иң мөһимен әйтмәдең: берәр нәрсә булдымы-юкмы сезнең? Шунысын ачык кына аңламадым.

Булатовның башына бу сорау барып җитеп, ул җавап бирергә дип авызын ачарга да өлгермәде, Сериков очып диярлек Федотовка ташланды:

—Анысы мөһиммени соң анын, Иван Данилыч! Нигә син мәсьәләне артык гадиләштерәсең!

Федотовның да бирешәсе килми инде, ул да сүзсез кала алмады:

—Шулаен шулай да, ләкин барыбер беләсе килә бит, шайтан алгыры!

Алар сүз көрәштергәндә Булатов нәрсәдер әйтергә теләгән иде, әмма аңа сүз кыстырырга да ирек куймадылар. Ә тора-бара инде ул үзе дә әлеге уеннан кире кайтты, ахрысы—дәшмичә генә утыра бирде...

Ләкин иң ахырдан бөтенесенә нәтиҗә ясарга уйлады кебек.

—Тагын бер кызыгы шунда анын, егетләр: ул чагында мин Аны никадәр яратып йөредем. Ул киткәч күпме газапландым—ә менә хәзер, сезгә сөйләгән вакытта, исемен дә хәтерли алмадым... Шуна күрә Ул диеп кенә сөйләдем. Ә инде башка бер кызның исемен кушып Анын күнелемдәге хатирәсен кыерсытасым килмәде...

Һәм... һәм мин Аны еллар үткән саен тагын да ныграк сагына барам төсле. Ул көннәр минем гомеремнен иң бәхетле минутлары булгандыр кебек тоела...

Әмма... Әмма нәрсә генә эшли алам сон?! Мин хәзер инде Аны ничек кенә итеп эзләсәм дә таба алмыйм ич! Мин Аны инде һичкайчан да таба алмаячакмын бит!

Анын якты, нурлы истәлеге булып миндә әнә шул Жан Ануй китабы гына калды...

Тагын шунысы бар. Минем күз алдыма еш кына биштәрсез сәяхәтче килеп баса... Ерак һәм тузанлы юлларны үтә-үтә арыса-алҗыса да, бу фани дөнья ваклыкларыннан өстен торган, дөнья ваклыгына бирешмәгән-буялмаган һәм яшьлегендәге шикелле якты омтылышлы, саф күнелле булып калалган, үзенең күнел матурлыгын байрак итеп яшәүче Сәяхәтче сурәте минем күз алдымда тора.

Һәм яшермим: үземнен яшьлегемдә менә шушы якты күренеш булмаган булса, яшьлегемдә Ул очрамаган булса—минем гомерем бик тә ямьсез, хәтта мәгънәсез үткән булыр иде кебек.

Ул очрашу өчен мин үз язмышыма чиксез рәхмәтләр укыйм!

## Ялтада

Кышкы землянка эчендәге мәҗлес бу кичне дә дәвам итте.

Бу кичне дә әңгәмә мәхәббәт хакында, хатын-кыз турында куерды.

—Аларның серен һич кенә дә аңлап бетереп булмый бит ул, егетләр!—диеп башлады сүзен капитан Федотов.—Менә шушы—хәзер без яшәп яткан данлыклы Уссури тайгасы никадәр серле бит инде, әмма хатын-кыз аннан да серлерәк ул, аңа караганда да табышмаграк ул—хатын-кыз! Көтелмәгән нәрсәләрне, булыр диеп һич тә уйламаган, бөтенләй башка да кереп карамаган хәлләрне китереп чыгарып кына тора ул! Шаклар катырсын!

Менә шул турыда бер кыйсса сөйләмәкче булам мин сезгә.

... Бер елны мин шулай, үземнен хәләл җефетемне дә ияртеп, Ялтага ял итәргә бардым... Сез, әлбәттә, ул якны, гүзәл Кырым табигатен бик яхшы беләсез инде: андагы сулап туйгысыз җиләс, шифалы һаваны, оҗмах рәхәтлекләре бирә торган җылы дингез суын, сөзәк тау битләрендә үсә торган төрле-төрле җиләк-җимешне, бүтән һичкайда очрамый торган фирменный шәрабләрне... Боларнын һәммәсен әйтеп, санап кына бетереп буламы сон?!

Ә без килеп урнашкан ял йорты бигрәк тә ямьле урында иде—шактый гына биек бер тауның башында ук диярлек урнашкан иде ул. Тирә-ягында кипарислар, пальмалар, инжирлар, йөзем куаклары: бүлмәннән чыгу белән чын-чыннан тропик урманына килеп керәсен инде менә! Фантастика, хыял бу, төштер бу!—диеп йөрергә генә кала, валлаһи!

Дингез үзе алай ук якын түгел-түгелен—бер ярты сәгать чамасы җәяүләп төшәргә кирәк... Ләкин, анын каруы, безнен болдырдан нинди матур булып күренә ул! Зәп-зәңгәр, шундый да чиста зәңгәр әкият иле инде менә!

Ул тугайланып-тугайланып килгән текә яр буйлары, чиксез зәңгәр су киңлеген ерып баручы ак җилкәнле көймәләр һәм ял итүчеләрне төягән, күнелле музыка авазлары тараткан ап-ак пароходлар...

Менә шуларның барысы да безнең болдырга чыгып басу белән үк синең күзеңне иркәли башлый. Хәтта алай гына да түгел: үзенә тарта, ымсындыра, котырта ул сихри, ул тылсымлы күренешләр!

Һәм без әнә шул гүзәл урыннарның барысын да күрергә, мондагы ямьнең һәммә төреннән авыз итәргә, көньяк җире, көньяк табигате бирә торган ләззәтнең бөтенесен татып калырга тырыштабыз. Көннәр буена диңгезнең вак таш җәелгән пляжында кызынабыз... Йомшак, назлы суының эченә кереп китсәк, аннан чыга алмыйча, аерыла алмыйча рәхәт чигәбез... Аккош шикелле тын гына йөзә торган бәләкәй пароходларга утырып, диңгез буенча сәяхәт итеп кайтабыз... Тау сыртлары арасына сузылган асылмалы юллардан гына югарыга, текә-текә тау башларына хәтле менеп төшәбез...

Кыскасы, үзебезнең якта, без яшәгән шәһәрдә булмаган әллә никадәр могҗиза, яңалык, күңел күтәргечләр күрдек без анда! Һәммәсен дә татып карадык, барысыннан да авыз иттек!

... Ә бер көнне өйлә ашын ашап, аннан соң байларча черем дә итеп алгач—Ялтаның үзен карап кайтырга булдык. Чөнки, ни әйтсәң дә, гәрчә бөтен ил халкының ял итү урыны булса да, Ялта—барыннан да элек шәһәр бит әле ул! Аның бик матур урыннары бар дип әйтәләр.

Безнең ял йортыннан диңгезгә таба борма-борма юл төшә. Аның машина йөри торган өлеше асфальт, ә кырыенда гына җәяүлеләр өчен сукмак та бар. Билгеле, анысын бик үк тигез дип булмый, аңа вак таш кына сибелгән. Шуңа күрә атлавы да җиңел түгел, җитмәсә бит әле, юлыбыз да аска таба төшә—гәүдәң үзе үк алга таба сөрлегеп, атлыгып тора. Карабрак басмасаң, йомгак шикелле тәгәрәп китүең дә бик мөмкин монда.

Ә инде төшеп җиткәчтен, Ялтаның диңгез яры буйлап сузылган бердәнбер үзәк урамыннан атлавы—монысы бөтенләй икенче! Уң кулда иксез-чиксез диңгез киңлеге, ә сул якта исә берсеннән- берсе гүзәлрәк, купшырак таш биналар. Аларның һәркайсы үзенчә, бүтәннәрен кабатламаска тырышып төзелгән. Шуңа күрә ул йортлардан күзне аерып та булмый.

Урамның ул ягында эреле-ваклы кибетләр дә күп инде, билгеле. Ә хатын-кызны сез инде үзегез беләсез: күзенә кибет күренсә, аның яныннан тыныч кына узып китә алмый ул! Аңа, һичшиксез, кибет эченә керергә, анда сәгатьләр буена каранып йөрергә кирәк! Әйбер аламы-юкмы, барыбер, аңа үз күңелен басып, тынычланып чыгарга кирәк!

Ә минем исә аның ише җирдә, чүпрәк-чапрак арасында, җенем чыга башлый. Юк-бар нәрсә күзләп—җитмәсә әле мыжлап торган халык арасында—тыныч кына йөри алмыйм мин! Кибеткә керергә туры килсә дә, мин тиз генә үземә кирәк нәрсәне аламын да, җәтрәк чыгып таю ягын карыйм. Тизрәк аннан котылу җаен эзлим!

Ләкин, эшләпәләр кибете каршына килеп баскач, ул көнне эшләр бераз бүтәнчәрәк килеп чыкты шул.

—Кара әле... Мондагы бөркүлеккә болай гына чыдарлык түгел ләбаса!—диде хатын.—Әйдә әле, миңа бер эшләпә алыйк әле!

«Үзең генә кереп чык инде...»—диеп әйтеп, тизрәк аның яныннан таярга иде дә исәп, ләкин аның ялварулы сүзләренә бу юлы битараф калып булмады шул.

—Әйдә инде, килешәме-юкмы, карарга да кирәк бит. Киңәшергә дә кирәк!—диде ул, минем холыкны яхшы белгәнгә күрә кулдан ук тотып.—Үлмәссең, бәлки әле үзеңә дә берәр әйбер табарбыз.

Килештем, риза булдым инде мин моның сүзе белән.

Уртача гына зурлыктагы, урамнан кергәндә ике-өч баскыч түбән таба төшеп керә торган кибет икән бу. Эчке өлеше тагын икегә бүлеп куелган: бер ягында ирләр эшләпәсе сатыла, ә эчкәрерәк урнашканында, күрәсең инде, хатын-кызларныкы...

—Ярар, бар, үзең сайлый тор! Аннары соң мине чакырырсың!—

диеп эчкә кертеп җибәрдем дә хатынны, үзем бернинди эшләпә дә карамыйча, чөнки андый уйның башыма да килгәне юк иде әле!—шулай тик кенә басып торам кибеттә. Тыштагы эсселектән соң монда рәхәтрәк тә икән үзе... Аскарак урнашкан бит кибет, шунлыктан салкынчадыр диеп уйлыйм.

Күпмедер шулай тордым да, янга табарак тагын бер-ике адым атламакчы гына булган идем, кырыемда гына:

—Исәнме...—дигән бер хатын-кыз тавышы ишетелмәсенме!

Ялт итеп шул якка борылам һәм... Һәм кемне күрәм дисез?!

Альбинаны! Үзем белән бергә университетта укыган, үземнең яшьлек мәхәббәтем булган Альбинаны!

Йа, Хода—өнме бу, әллә төшме?! Бу чынлап та шулаймы, әллә минем хыял гына шулай күрсәтәме?! Шаклар катып, гаҗәпләнеп, ни дип әйтергә дә белмичә, торам шулай басып—каккан казык кебек!

Ә Альбина күрәсең мине алданрак искәргән, шуңа күрә ул үз акылына тизрәк килде:

—Башта «синме соң бу?» диеп торам... «Неужели ул?» димен...

Мин инде билгеле тизрәк хәлне аңлатырга тырыштым:

—Альбина... Мин монда хатын белән бит әле...—дидем.

Минем ул сүзләрем аның аңына тиз генә барып җитмәде күрәсең, ул һаман үзенекен сөйләргә теләде, мине күрү шатлыгын белгертергә ашыкты. Чынлап та, сөенечтән балкый иде ул, очына иде ул әнә шул чагында!

Тагын бер мәртәбә ашыга-ашыга кабатларга туры килде... Ниһаять, бу сүзләр аңа барып җитте бугай... Минем аның шикелле иркенләп шатланырга ашыкмавым да тәэсир итте, ахрысы, бераздан ул миңа карап тын калды. Чибәр йөзенә үпкә, нәүмизлек билгеләре дә чыкты хәтта.

Аннары ул әкрен генә:

—Озаккамы соң?..—диеп сорады.

Мин инде, билгеле, аны тынычландырырга ашыктым:

—Әле килдек кенә...—дидем.

Тагын нәрсә диеп әйтергә? Тагын ни турында сөйләшергә? Әлбәттә, безнең сөйләшер сүзләр күп инде ул, ләкин бит якында гына, моннан биш-алты адымда гына, минем хатын йөри! Ул менә-менә килеп җитәргә мөмкин!

Минем әнә шундый борчулы уйларым күрәсең йөзгә үк чыккан булгандыр инде ул чакны... Күпмедер тын торганнан соң, Альбина:

—Хорошилов урамы, 14 нче йортта минем бүлмә...—диде.

Һәм «килерсеңме?»—диеп тә өстәде. Бераздан тагын бер мәртәбә: «Килерсеңме?»—диде.

Мин ул әйткән адресны кабатладым, «ярый», дидем.

—Сиңа сөйлисе бик күп сүзләрем бар! Кил, яме!—диде Альбина, киткән чагында да үзенең гаҗәеп мөлаем, ягымлы елмаюы белән балкый-балкый.

Менә шушы хәлдән соң эшләпә кибетендә йөреп кара инде син! Күзеңә бер генә нәрсә дә күренмәгән килеш—әйбер караган, эшләпә эзләгән булып кылан инде син! Моның өчен бит никадәр оста артист булырга кирәк! Яисә, киресенчә, дулкынланмый, хисләнми генә яши торган таш йөрәкле адәм булырга кирәк моның өчен! Ә мин менә аларның берсе дә түгел... Мин гап-гади адәм баласы... Ләкин биредә—әллә кайдагы Ялтада—моннан күп еллар элек үзем белән бергә укыган Альбинаны һич уйламаган җирдән очрату ул чагында бөтенләй чыгырдан чыгарды. Дөньямның астын өскә китерде бу очрашу!

... Әйе, безнең самими яшьлек иде шул ул! Авылдан килеп кенә кергән чак... Сезгә билгеле У. каласында әле яңа яши генә башлаган көннәр. Яшел студентлар әле без...

Укуның беренче көннәрендә нәрсә диеп баш ватасың инде?

Әлбәттә, китаплар диеп! Әлбәттә, дәресләкләр өчен борчыласың!

Альбина да тулай торактагы безнең бүлмәгә дәреслек сорап керде. Минем янга түгел, ә үзенең группадашы Гамирны эзләп йөреше иде аның...

Менә хәзер дә күз алдымда әле...

Кич иде ул... Бүлмәдә бер үзем генә калып, ниндидер бер китап укып утыра идем... Шул чакны әкрен генә ишек шакыган тавыш ишетелде. Мин ни өчендер «күрше егетләрдер әле» диеп уйладым—гәрчә аларның ишек шакып йөрмәгәнлеген инде белергә һәм онытмаска тиеш булсам да. Шуңа күрә мендәргә сөялеп укып утырган җиремнән әлләни кымшанмадым—бары тик башымны гына күтәрдем бугай.

Ә ишек акрын гына ачыла бирде, анда таныш түгел бер кызыйның сары чәчле башы күренде...

—Монда кеше бармы соң?..—дигән тавышы ишетелде.

Хәзер инде миңа да кузгалмыйча ярамый иде. Сикереп үк диярлек торып утырдым, аннары инде идәнгә үк төшеп бастым.

—Әйе, әйе! Без өйдә!—дигән аваз да салдым.

Таныш түгел кызый бүлмәнең эченәрәк үтте, үзе ни өчендер кызарды һәм искиткеч матур итеп елмаеп:

—Безнең Гамир өйдә юкмыни?..—диде, сузыбрак кына.

Әнә шул чагында миңа нидер булды: аның «к» авазын ничектер мин әлегә хәтле ишетмәгәнчә аеруча ягымлы итеп, йомшак итеп әйтүе, үзенең оялчан да, шул ук вакытта, серле дә итеп елмаюы, аның зәңгәр күзләренең тутырып багуы, озын күз керфекләренең сирпелеп-сирпелеп китүе—болар барысы да мине, китап дөньясына чумып утырган яшь-яшь авыл малаен бер минут эчендә тылсымлап алды. Мин сүзсез калдым... Бары тик күзләрем генә зур булып ачылып аңа текәлделәр дә, минем исән-сау һәм тере икәнлегем әнә шул күзләремнән генә сизелә иде бугай... Һәм кызардым да мин ул чагында. Әйе, әйе—кызардым да... Һаман аңа текәлеп, сүзсез тора бирдем.

—Нигә алай итеп карыйсың?

Альбинаның икенче соравы әнә шул булды. Ул миңа таба тагын да сихрирәк карап һәм әле һаман елмаюдан туктамыйча, җавап көтә иде.

Ә минем аңа җавап бирерлек сүзем юк әле, шуңа күрә әңгәмәне бүтәнрәк юнәлешкә бормакчы булам:

—Әйдәгез, түргәрәк үтегез... Менә хәзер чәй дә куеп җибәрәм,—дигән сүзләр белән бүлмә почмагындагы чәйнеккә барып тотынган булам... Ул да минем хәлне аңлый бугай аңлавын, ләкин бер-бер сүз әйтелсен диепме инде шунда:

—Ә Гамир тиз кайтыр микән соң?..—дигән була.

Үзе һаман елмая, үзенең карашы һаман миндә... Гипнозлый, каһәр!

Мин аны җитәкләп диярлек түрдәге өстәлебез янына алып килəм, шундагы бердәнбер урындыгыбызны җайлабрак куям да:

—Менә шушында гына утырып тор, яме! Мин хәзер чәй генә куеп керәм!—дип, коридорга чыгам...

Бу сүзләргә каршы берни дип тә әйтми инде ул—үзенең бик тә сөйкемле елмаюы белән бөтен бүлмәне яктыртып, нурландырып елмая гына...

Кире әйләнеп кергәндә мин инде үземне шактый ук кулга алган идем, билгеле. Матур гына сүзләр дә килде телгә. Әнә шунда мин аның исемен белдем, туган ягы, авылы турында ишеттем. Сүзебез бүленеп бер мәлгә тын калган арада «ниләр бар икән» дип, дивардагы бәләкәй радионы ачкан идем, аннан бик тә моңлы булып «Тукай маршы» ишетелә башлады... Ничектер, бу музыка безнең ике арадагы менә хәзерге хәлләргә бик тә туры килә кебек иде—шуңа күрә аны көчәйтебрәк тә җибәрдем...

Хисләрне канатландыра, очындыра торган—адәми затның күңелен җиденче кат күкләргә күтәрә торган менә шушы гүзәл көй шактый озак яңгырады ул кичне безнең бүлмәдә...

Ул музыка икебезне тиң сүзсез дә калдырды...

Ә бераздан мин ана болай дип тә әйттем:

Бүлмәдә—Тукай маршы...
Күзләрдә—барсы, барсы...

Менә шулай итеп, кинәт һәм берьюлы муеннан гашыйк булдым мин ул чагында Альбинага. Ерактагы бер авылдан зур калага укырга, белем алырга дип килгән егетнен дөньясы әнә шуннан соң нык үзгәрде: кичләрен инде аяклар тулай торактагы уку бүлмәсенә түгел, ә бөтенләй икенче якка таба—иптәш кызлары белән Альбина торган бүлмәгә таба тарта иде. Бераздан кыюлык житеп мин аны кинога да чакырдым... Аннары инде нинди дер бер спектакльгә дә бардык... Кичләрен бергәләп һавада йөреп керүләр дә ешайды...

Альбина быел безнең белән укырга кергәнче эшләп тә алган икән, көннәрдән бер көнне ул мине үзенең элек торган тулай торагына—иптәш кызлары янына алып барды.

Анда әйбәт кенә кунак булып, авылдан килгән күчтәнәчләр белән сыйлангач, инде кайтып китәргә дип коридорга чыктык. Шунда кызлар белән саубуллашып торганда узып баручы бер кара мыеклы егет ни өчендер безнең янга туктыйсы итте бит. Алай гына да түгел—Альбинага сүз дә куша бу:

—Син мине онытмагансыңдыр ич!—ди.

Мин аптырап, бер Альбинага, бер тегеңә карыйм. Альбина кызарыбрак да китте кебек—әмма югалып калмады:

—Юк, Сәлим! Исәнме? Хәлләрен ничек?—диде.

Ә тегесе һаман әрсезләнүен белә:

—Сине бер минутка мөмкинме?—ди.

Шул сүз Альбинаны кинәт үзгәртеп жибәрде. Ул минем кулга ике кулы белән тиң тотынды да:

—Әйдә, киттек моннан!—диде, ашыга-ашыга.

Минем дә ачу килә башлады, кан кызып китте. Бу галәмәт йөзгә дә чыккандыр инде, билгеле.

Кыскасы, тагын бераз шулай дәвам иткән булса, зур гына ЧП чыгасы ачык иде инде. Әле ярый, мине Альбина алга сөйрәде, ә теге егетне кызлар үз бүлмәләренә алып кереп китте ул кичне.

Урамга чыктык. Мин әле сүз дәшмим, шулай да эчтә явыз шайтаннар котыра инде. «Нигә генә килдем соң мин монда?!» дигән ачы үкенү дә бар... Ләкин сез шуны белегез, шуны дөрес итеп аңлагыз—ул чагында, ул вакытта әле Альбина әйткәнгә каршы килә ала идемме соң мин?! Юк бит, юк! Ул чагында мин бит аның һәр әйткән сүзен дә үземә зур бәхет санап, тыңлап кына йөри идем. Аның чып-чын бер колы идем! Чөнки ул минем өчен гүзәллек алиһәсе иде! Мин тормышта очраткан беренче Мәхәббәт—минем иң көчле сөюем иде ул!

Миндә бары тик соклану, баш ию, мөкиббән китү генә бар иде. Ә инде аз гына аек акыл, аз гына чама, үлчәп карау дигән нәрсәнең исә тамчысы да булмады!

Тулай тороактан чыккач, күпме ара шулай дәшми, сөйләшми барганбыздыр—анысын хәзер инде әйтә алмыйм. Шул гына истә: беренче булып Альбина телгә килде:

—Каян очрап тора диген син аны!.. Анда яшәгәндә, анда тынгылык бирмәде... Гарык булдым шуннан, билләһи!

Әллә инде аның мине сихерләүче тавышы тәэсир итте, ул чакны балаларчарак сүз әйтеп ташладым:

—Ә нишләп бәйләнә соң ул сиңа?

Ләкин Альбинаның моңа жавабы әзер булып чыкты.

—Бер-ике мәртәбә кинога алып барган иде шунда... Сагыз кебек ябышты аннары...

Ул сүзләр ихлас күңелдән, теге егетне чынлап та яратмыйча әйтелгән

кебек иде. Мин Альбинаның әлеге сүзләренә ышанган идем. Димәк, болар арасында элегрәк нәрсәдер булып алган да, хәзер инде аңа нокта куелган икән диеп уйлаган идем.

Ләкин тора-бара бу эшнең андый гади генә түгел икәнлеге ачыкланды...

Ничек дисенме?.. Хатын-кыздагы үземә аңлашылмаган серлелек, сәерлек белән беренче мәртәбә әнә шунда очраштым мин.

Күрше бүлмә егете Дамир ачты минем күзне. Бер көнне, лекцияләр бетеп тулай торакка кайткач, ул мине коридорда очратты да:

—Әйдә әле, сиңа сүз бар!—дип, аулак почмаккарак алып китте.

Мин аның вак кына нәрсәләр турында да зур-зур фәлсәфә куертырга ярата торган, әмма бик укымышлы егет икәнен белә идем. Кайчакларда аның сүз боткасы пешерүләре минем ачуны да чыгара торган иде. «Бүгенгә житте, Дамир!»—диеп, аның бетмәс-төкәнмәс сүзен ташлап киткән чагым да булды бер көнне... Шуңа күрә бу юлы да: «тагын шул фәлсәфәдер инде моның...» диебрәк кенә атладым аның артыннан.

Алып килде бу мине почмактагы ялгыз тәрәзә янына, үзе исә тәрәзәнең киң итеп эшләнгән төбенә менеп үк утырды. Футболка белән спорт чалбарыннан гына, кулында сигарет. Үзенең күзләре күзлек пыяласы аша шактый катгый, хәтта усал карый. Бик гажәп тоелды бу миңа.

—Әйт әле миңа шуны: син чүпрәкме, әллә түгелме?!

Сүзнең нәрсә турында барганлыгын аңламыйм бит әле. Шуңа күрә мондый көтелмәгән фикергә каршы көлеп жибәрдем инде.

—Юк! Син көлмә, көлмә! Бер дә уен нәрсә әйтмим мин!

«Чынлап та житди нәрсә сөйләмәкче була, ахрысы, бу» диеп, үзем сорау бирдем моңа:

—Аңлатып сөйлә әле син! Нәрсә булган?! Нинди чүпрәк турында сөйлисең син?

Бер мәлгә тын калды бу. Сигаретын суырды, төтенен әллә чыгарды, әллә юк шунда—аннары бик житди генә кыяфәт белән аның көлен какты... Шуннан соң гына:

—Кичә Альбинаның бер егет белән чыгып barганын күрдем!—диде.

Сүзләре башка кинәт кенә барып житми бит... Баштарак: «Тукта әле, нишләп Альбина турында сөйли соң әле бу?»—диеп аптырап калдым. Әнә шул сагайтты. Дус егетләр, иптәшләр белән хатын-кыз заты турында сөйләшергә яратмый идем мин чөнки... Бәлкем нәкъ менә шуның аркасында да «кешелекнең гүзәл яртысын» аңлауда шактый артка да калганмындыр, аларга карата нык ук идеалистик фикердә йөрегәнмендер.

Ә бераздан «чүпрәк» сүзенең мәгънәсе башыма китереп сукмасынмы?! Минем турында әйтә бит ул бу сүзне! Альбинага бәйләп әйтә... Тукта... Димәк... Мин нәрсәнедер белми йөрим... Димәк, Альбинаның тагын кемедер бар...

Ул чагында әнә шул «кемедер» дигән сүз күңелгә килеп керде дә, бөтенесен карага буяды да ташлады. Димәк... Димәк, минем «ул» диеп ашкынып, хыялланып йөрүләрем... Аны бер илаһи зат, фәрештә кебек күрүләрем...

Ләкин бу газаплы, әрнеткеч уйның сизелеп торган азагын телгә китерәсе дә, колак белән ишетәсе дә килми иде...

Әйе, әйе—мин ул чагында әлеге кырыс чынлыкны кинәт кенә аңлап житә алмадым. Әмма Дамирның сүзенә ышанмыйча да булмый иде. Кайчакларда бераз хыялланып, арттырыбрак сөйләргә ятратса да, бүген аның ихластан, чын йөрәктән әйтүе күренеп тора иде. Ул миңа ярдәм итәргә теләп, күземне ачарга теләп сөйли ич...

Мин үзем болай тәмәке тартмый идем, хәмер капкан чакларда гына тарткаладым, ә ул кичне авызымны ачып Дамирга әйткән беренче сүзем шул булды:

—Кая, миңа да берне бир әле!

Сигарет кабы аның арткы кесәсендә икән, ул утырган жиреннән

тормыйча гына бер якка авышыбрак, кыйммәтле сигарет кабын тартып чыгарды, аннары капнын астына гына чиертеп ике-өч сигаретны урыныннан куптарды да «үзең ал» дигән мәгънә белән мина таба сузды.

Тәмәке кабыздым да, тәрәзәгә бактым... Бу—бакча як, тыныч як... Кара әле, агачлар инде яфракларын коеп та бетергәннәр икән ич! Әнә алар шәп-шәрә утыралар... Яп-ялангач... Ә нинди күнелсез икән болай! Ә җәй көне, әле күптән түгел генә, ничек күнелле иде бит дөнья! Әле мона кадәр дә ямьле кебек иде дөнья... Ямьле сыман тоела иде ул... Ә баксаң... Ә баксаң, әнә нинди шәрә, ялангач икән бит бу дөнья! Син генә күрмичә йөргәнсен икән мона хәтле аны.

Дамирга мин теш агартып бер генә сүз дә әйтмәдем ул көнне... Ул да сорамады, мине сөйләштерергә теләмәде.

Авызымдагы сигаретны тартып бетергәчтен, Дамирнын күзенә карамыйча гына:

—Рәхмәт...—дидем дә, ашыга-ашыга бүлмәгә кереп киттем.

Анда кергәч тә, тәрәзә янына барып бастым. Әле ярый бүлмәдә бер кеше дә юк иде, югыйсә сүз кушып, «ник алай», «ник болай» дигән булып ачуны чыгарырлар иде—газапны тагын да арттырырлар иде, үзләре белмичә-чамаламыйча да.

«Нәрсә эшләргә?!» Минем башымда хәзер иң нык бөтерелгән утлы сорау шул.

«Хәзер Альбинаны күрергәме, юкмы?!» Күнелгә килгән тагын бер сорау әнә шундый...—Ә аны күреп мин нәрсә сөйләшә алам?! Хәзер барысы да җимерелде, ишелде бит инде! Безнең арада хәзер барыбер җүнле сүз, җүнле аңлашу булмаячак бит инде!

Һәм, өстемә җинел курткамны гына элдем дә, урамга чыгып киттем.

Безнең тулай торак яныннан гына диярлек шәһәр уртасында калган авыл өйләре башлана иде. Алар минем балачакны искә төшереп, үзләре бер урам кебек булып утыралар. Бүлмәдә укый-укый арыгачтын, мин кайчакларда әнә шул урамда йөрештерәм, авылыма кайтып килгәндәй булам.

Инде шактый ук караңгы булса да, шул урам буйлап киттем... Акны-караны күрмичә, кая басканымны белмичә—бары тик эчтә котырган җен ашкындыруы буенча гына очынып, аптырап, газаплы уйлардан изаланып, бик тә озак йөредем ул кичне. Авыл өйләре беткәч, бер буш урын да бар иде, анда беркем дә комачауламый иде мина... Мин берүзем, берьялгызым гына идем!

Ә инде үз-үземә «җитте!» диеп, кире тулай торакка кайтканда тышкы ишек бикле иде. Тәрәзәләрдә утлар да сирәгәйгән... Ирексездән күзем алар тәрәзәсенә дә төште. Һәм ул... Һәм ул—уч иткән кебек—караңгы иде! Кап-кара иде!

Аяк-куллар белән бөтен көчкә дөбердәтә торгач, эчтәге карчык сукрана-сукрана ишекне ачты инде ачуын. Үзе әллә нинди яман сүзләр әйтеп мине битәрли, ә үзе йозгә күтәрелеп тә карамый—әллә мин мондагы кеше, әллә түгел—анысында гаме юк! Көн саен шулай бимазалаганга ачуы киләме соң инде монын?!

Әмма миндә аның кайгысы түгел иде, дәшми-тынмый гына үземнең катка узып киттем. Бүлмә ачкычы кесәдә—анысы өчен борчыласы юк. Бары тик кереп, чишенеп, инде урынга ятам дигәндә генә, Гамир ягыннан пышылдаган тавыш килә:

—Альбина кергән иде... Мине күрсен әле, диде.

Гамирга җавап биреп тормадым, әлбәттә. Илчегә үлем юк, дигәндәй: ул нәрсә белә дә, нәрсәне җайлый ала соң?! Ул да кабатлап бер сүз дә әйтмәде, шулай итеп, әкрен генә йокы кочагына авыштык...

Әле ярый икенче көнне безнең группаның хәрби дәресләре иде—димәк, көндез лекцияләр арасында Альбина белән очрашу мөмкинлеге юк, димәк, мин бу яктан тыныч була алам дигән сүз. Чыннан да, көнозын басуда, болында йөрдек. Аркаларга автоматлар һәм бүтән кирәк-

яраклар асып, урыны да бик чокыр-чакырлы булганмы—кичкә инде бик арыткан иде, шуңа күрә Альбина белән очрашу, сөйләшү теләге юк иде. Ә инде өченче көнне бүлмәдәшебез Вахитның туган көне иде—ул кичне төн буена безнең бүлмә гүләп торды... Мин дә Альбина турында уйламаска тырыштым. Аның буй-сыны күз алдыма бик еш кына килеп басса да, мин аны чебен кугандай куарга, аннан котылырга тырыштым.

Альбина үзе дә безнең бүлмәдә бүтән күренмәде...

Аннары безнең беренче сессия килеп җитте. Альбина белән сирәк-мирәк күрешкәләсәк тә, бер-беребезне танымаган кешеләр төсле узып киттек... Эчтә утлар янса да...

Шуннан соң... Шуннан соң, мин аның имтиханын бирә алмаганлыгын ишеттем. Альбина тулай торакта да күренми башлады. Ә көннәрдән бер көнне Гамир сүз арасында гына әйткән төсле:

—Альбина кияүгә чыккан икән бит ул!—диде...

Бу вакытта инде Вахит та кайткан иде. Ул да авызын ерып:

—Менә шулай була ул...—дип куйган булды, миңа төрттергән сыман кинаяле итеп. Әмма бүтән егетләр ни өчендер аның бу юморына кушылмады.

Минем эчтә исә ниндидер бер тирән упкын хасил булды да, йөрәгем әнә шул төпсезлеккә чумды, төшеп китте... Мәңге чыга алмаслык бушлыкка...

Ә шулай да, бер җаен туры китереп, Гамирдан сорамыйча түзә алмадым. Ул сабыр, юаш егет—сузып-сузып кына миңа аңлатып бирде:

—Элегрәк йөргән бер егете булган икән аның... Шул бик ялынып-ялварып сораган ди...

Бераздан тагын үз фикерен дә белдереп куюны кирәк тапты:

—Имтиханны да бирә алмады бит инде—анысын беләсең... Шулай эшләве бәлки дөрестер дә аның! Хатын-кызга уку әлләни мөһим дә түгел ич инде ул!

Әйе, бу сүзләр белән килешә идем шул. Моны мин Гамирга телем белән дә әйттем ул көнне:

—Шулайдыр шул!—дидем.

Әлеге сүзләр минем ул мәхәббәтемә нокта да куйды кебек.

Ә сүнеп, суынып өлгермәгән хисләрне кеше күзеннән, һәм үземнең дә йөрәктән эчкәрәк яшердем кебек ул чагында. Тиз генә килеп чыкмаслык, күзгә чалынмаслык итеп... Бу тормышта бүтәннәр кебек гади генә яшәргә комачауламасыннар өчен...

Ярар... Минем каршыда хәзер әнә шул Альбина булып китте бит инде... Ә ничек үзгәргән ул! Элек бераз чандыррак иде, хәзер тулыланып киткән. Болай тагын да матуррак кебек үзе... Ә ире нишләптер күренмәде... Тукта әле—нишләптер ул ире турында бер сүз дә әйтмәде бит! «Мин» диеп кенә сөйләште түгелме соң? Бирегә үзе генә килде микәнни? Ә ни өчен үзе килгән? Шушының кадәр ерак җиргә кыюлыгы җитеп, ничек үзе генә килә алган ул?

Шуның ише сораулар байтак уйландыра башлаган иде, ләкин аларга җавап эзләп торырга вакыт булмады—кибетнең теге як бүлмәсеннән хатын килеп чыкты. Кулында матур гына эшләпә. Мине чакыра. «Тегендә, көзге янында киеп карыйм әле»,—ди...

Артыннан иярдем инде. Башына элде бу җиңел генә яшел эшләпәне, үзе көзгегә текәлде... Ә миндә инде, үзегез беләсез, һич тә эшләпә кайгысы түгел. Шуңа күрә маңгай күзем хатын ягында булса да, күңелемдә бөтенләй бүтән дөнья, бөтенләй икенче нәрсәләр анда.

Телгә килгән беренче сүзләр белән үземнең эчке халәтемне яшерергә дә маташам әле:

—Бик тә килешә бит бу сиңа!—дигән булам.—Әйдә, тизрәк сатып ал син моны!—дим, ашыккан төсле.

Җавап та әзер билгеле. Хатын-кыз сүзсез калмый ич инде ул:

—Сиңа шул тизрәк котылырга гына булсын инде! Тизрәк моннан

чыгып таясың килә инде синең! Шуна күрә ал диюең инде синең...

—Юк, юк! Чынлап та шәп эшләпә ич!—дип, байтак мактау сүзе әйтергә туры килде мина ул көнне.

Ә бит чынлыкта, эшләпәләр сатучы менә шушы кибеткә кирәк иде мәдхия уку! Ничә еллардан соң шушы кибет очраштырды бит безне!

Ярар, шулай итеп, без эшләпәле дә булдык...

Әйе, хатынга куаныч: үзебезнең бүлмәгә кайтып кергәч көзге каршысыннан аерылып китә алмый—тегеләй дә киеп карый, болай да итеп үз-үзенә соклана. Бусы инде аның үзе бер театр, валлаһи!

Ә минем эчкә корт керде бит инде хәзер. Күнелдән һич кенә дә Альбина чыкмый. Дингез буена су коенырга дип төшәбез—минем белән ияреп ул да төшә кебек... Очлары таш кыялы, ә битләре без белмәгән җылы як үсемлекләре белән капланган тауларга йөрибез—тагын ул безгә ияреп юлга чыга... хәтта ял йортының ашханәсендә ашап утырган чагында да ул безнең арттагы өстәлдә генә тукланып утырадыр шикелле тоела да, мин ирексездән шул якка таба борылып карарга мәҗбүр булам.

Менә шулай байтак кына көннәр газапландым. Ни эшләргә дә белмичә йөрдем... Ләкин Ходай адәм баласына әллә ничә төрле сынауларны биреп кенә тора бит ул! Көннәрдән беркөнне ул минем каршыга да шушындый мөмкинлек китереп куйды.

Кыскасы, бу көнне минем хатын күршедәге яңа танышкан ахирәте белән шәһәр читендәге чүпрәк-чапрак базарына диеп китте. Билгеле, киенеп-ясанып инде! Акчалар, сумкалар алып инде—бер дә тиз генә кайтырга ошамыйча...

Ә мин бүлмәдә бер ялгызым калдым... Әмма монда нишлисең, шушы тар бүлмәдә ятып булмый ич инде! Көн саен йөреп дингез буе да бераз туйдыра башлаган инде, анда да хәзер аяк гел тартып тормый... Кыскасы, дөресен генә әйткәндә, күңел хәзер бер яңалык сорый—тормышны төрләндерү сорый...

Ул чагында бик әлләни озак уйлап, баш ватып та торылмады шикелле. «Бер күрешеп, күптән очрашылмаган иске дус белән сөйләшеп кайтуның нәрсәсе начар булсын», диебрәк гоман калдым, ахрысы...

Үзегез беләсез: Ялта инде ул зур шәһәр түгел, аның бөтен транспорты да шул дингез ярыннан сузылган бер үзәк урам буйлап йөри. Мин дә шәһәрнең бердәнбер маршрутлы троллейбусына утырырга ниятлим инде... Ләкин аңа хәтле теге мин барасы урамның кайсы тарафта икәнлеген белешергә кирәк бит әле! Хәер, анысы да әллә ни кыен эш булып чыкмады—бераз акча түләгәч, белешмәләр бюросында аны мина бик яхшы итеп төшендереп бирделәр. Бездән соң дүрт тукталыш кына барасы икән...

Менә, ниһаять, Хорошилов урамын да таптым. Тауга таба менеп китә торган бик тар гына, борылмалы-борылмалы урам икән ул... Өйләрнең аскы катлары гына таштан, икенче-өченче катлары барысыныкы да агачтан салынган... Ләкин шуннан биек йортлар юк, алар зур шәһәрләрдәге кебек күккә ашып, кешене изеп тормыйлар. Авыл җирендәге кебек иркенлек, табигыйлек, табигатькә буйсынганлык сизелеп тора монда.

Урам кырыеннан сузылган вак ташлы сукмак буйлап байтак кына өскә күтәрелдем. Артка борылып карагач, инде дингез өсте дә шактый киң булып күренә башлады. Мин хәзер зәңгәр күк белән зәңгәр дингез арасындагы бер яшел сиртмәдә гүяки... Хәзер гүяки атлап бармыйм, ә әнә шул тылсымлы бишектә акрын гына тирбәләм, иркәләнәм—бөтен дөньясының шушы әкияти гүзәллегенә сокланып, исем китеп, сабый бала сыман күзләремне зур итеп ачып гаҗәпләнеп йөрим...

Әйе, кай якка гына күз салма, нәрсәгә генә бакма—һәммә җирдән монарчы күрелмәгән ямь, нур, яктылык агыла иде ул көнне. Һәм алар барысы да мине очындыра, иләсләндерә, күнелне нечкәрәк, кешелеклерәк, хислерәк, тәэсирләнүчәнрәк итә иде...

Менә ул үндүртенче йорт... Тауга менеп баручы юлның уң ягына,

аз гына уйсурак урынга утырган ул. Үзе урам ягтан яшелгә буялган тимер чыбык челтәр белән уратып алынган. Кечкенә капкасы да бик зәвыклы итеп, бизәкләп, чуклап эшләнгән. Бүтән капкалардагы шикелле «сак булыгыз, усал эт бар!» дигән сүзләр дә котыныны очырып тормый... Ә ишек алды белән бакчасы тоташып ук киткән икән: һәммә җирдә җимеш куаклары, инде өлгереп килүче йөземнәр дә тәлгәш-тәлгәш булып асылынып—бу урынны фани дөньядагы оҗмахка ошатып торалар... Кызык: таралып үскән йөзем куагыннан бер әкәмәт коридор да хасил булган хәтта. Капкадан кереп, өйгә таба барганда аның җимешләре синең баш өстендә үк асылынып, синең баш түбәнә тиям-тиям диеп кала икән... Һәм ымсындыра да алар...

Ә өйнең үзен кайсыдыр ягы белән шәһәрдәге минем ин тәүге фатирым, тәүге почмагым булган яшьлегем йортына охшаттым. Биек-биек булып үскән купшы агачлар, куе-куе куаклар янында аның тыйнак кына, сабыр гына утыруы да—нәкъ мин теләгәнчә, мин яратканча иде.

Бу өйгә, аның янындагы матурлыкка сокланып байтак кына басып торылды, ахрысы... Тимер капка эргәсенә көйләп куелган кыңгырау төймәсенә дә басмаган идем әле... Шул арада өйнең уң ягындагы куаклар арасыннан бер хатын-кызның чыгып, болдырга таба атлавы күренде. Кулына зур гына савыт тоткан, аңа өеп йөзем тутырган... Безнең ара шактый ук ерак, әле тиз генә танып та булмый... Ләкин шулай да... шулай да Альбинага охшаган ич бу! Аның атлавы ич! Ул гына шулай матур итеп басып бара белә бит! Дөньяда бары тик ул гына үзенең йөреше белән дә йөрәкләрне җилкендерә ала ич!

—Альбина!—дип кычкырдым. Ничек түзәсең!

Шундук ишетте, әлбәттә.

—Ой!—диде, миңа таба борылып.—Синмени бу?!

Аның шул чагындагы каушап, аптырап калуы да бер сөйкемле, күңелле күренеш кебек килеп чыкты. Кулында йөзем тулы савыт бит инде—әнә шул савытны кая куярга белмичә байтак кына йөдәде Альбина: өй алды баскычына да куймакчы була, үзе белән миңа таба да алып килергә уйлый һәм бу якка ике-өч адым атлап та ала, аннары тагын кире уйлап, аны ерак түгел куелган бәләкәй өстәлчеккә урнаштыра...

Ә мин елмая биреп торам шулай капканың тышкы ягында. Аңа карыйм, аны күзәтәм!

Өстендә алсу чәчәкләр төшерелгән кимоно гына. Альбина ашыга-ашыга атлаганда анысы да ачылып-ачылып китә дә, минем нинди гүзәл хатын-кыз икәнлегемне менә шушы мизгелдә күреп, бәяләп кала аласыңмы, дигәндәй, күз алдындагы бу сүзсез кино кадрлары бер-бер артлы алышынып тора...

Әйе, Альбина йөгереп үк диярлек миңа таба, капкага таба килә... Ул ачык сары төстәге чәчләрен тагын да озынрак итеп үстергән—алар ашыгып атлаганда җил белән янга ташлана, үзенә аерым бер дулкын хасил итә кебек. Бу дулкынга Альбинаның бераз тулыланып киткән зифа буе дулкынлануы да килеп кушыла да—боларның һәммәсе гүяки мине яңадан диңгез буена, аның йомшак дулкыннары кочагына илтеп сала... Гүяки менә хәзер мин шушы тау битендә түгел, ә астагы зәңгәр диңгез дулкыннары арасында тирбәләм...

Альбина капка янына килеп җитте дә, тукталып калды. Үзе минем күзгә текәлгән, үзе балкып елмая. Чын менә—күктәге кояштан бер дә ким түгел аның балкуы! Ә үзе миңа карап көлә-көлә, беләсезме, ни ди?

—Кертим микән инде сине... Әллә кертмим микән?

Аның шушылай шаяртып торуы миңа элекке заманнардагы ишек бавын сагалап торучы уенчак яшь кызларны искә төшерә. Ничектер, мине ул чакны биләп алган әкияти тылсым көче тагын да арта төшә. Мин үземне чын әкият иленең капкасы янында басып торгандай хис итәм.

Ә инде аның матур тимер капканы шылтыратып ачуы минем тәмам сихерләнгән күңелгә үзе бер музыка сыман ишетелде, ахрысы. Һәрхәлдә,

мина кайбер шылтыравык музыкалардан көчлерәк тәэсир итте ул. Монысына иманым камил!

Сихри капка ачып куелгач, ул чагында инде синең алдыңда балкып елмаеп торган гүзәл бер алиһәгә кагылмау, барып аның кулларыннан гына булса да тотып карамау—бу мөмкин эшме соң?! Мондый вакытта кайсы гына ир-ат тик тора ала икән дә, кем генә үзен түземлек, сабырлык кысасында саклап кала ала икән?!!

Мин үзем генә аны нык сагынганмын диеп уйлаган идем, әмма аның хисләре дә минекеннән ким түгел иде, ахрысы. Ул да мине кочаклап алды, иреннәребез дә тиз генә бер-берсен эзләп тапты... Әнә шул урында, капкабызны да ябып куярга онытып, бөтен дөнья, бөтен кешеләр турында истән чыгарып, озак үбештек. Мин үзем яшьләрнең кеше алдында үбешүләрен ничектер артык кылану, чаманы югалту диебрәк бәяли идем. Ә менә монда исә һич тә андый кыенсыну, оялу кебек тойгы сизелмәде... Хәер, биредә кеше дә күренми иде ич инде! Аннан соң бу урын—урам уртасы түгел бит инде! Киресенчә, табигатьнең иң аулак бер почмагы сыман, яшьләрне ят кешеләр күзеннән саклаучы яшел урман кочагы шикелле ич әле бу урын! Күрәсең әнә шунлыктан инде мин читенсенү сизмәдем.

Ул көнне минем авыздан чыккан беренче сүз нинди булды соң әле? Ә-ә... Исемә төште!

—Кара әле! Нинди матур өй тапкансың бит син!—диеп, үземнең ихластан соклануымны белдердем мин иң башта. Әйткәнемчә, бу урын, бу йорт, аның әйләнә-тирәсендәге агач-куаклар мина инде монда килеп беренче аяк басу белән үк җир шарындагы иң гүзәл, иң ямьле урын булып күренә башлаган иде.

—Әле син әнә андагы бакча эчен күрсә-ә-әң...

Альбина ымлап ишек алды түрендәге куакларга таба күрсәтте.

—Әле син ничек итеп минем йөзем җыюымны күрсә-ә-әң...

Аның бу сүзләренә җавап итеп мин кычкырып көлеп җибәрдем:

—Мин дә шунда барсам, адашмам микән соң?

Ни өчендер кызарып, Альбина башын бераз гына түбән иде. Елмаюы да үзгәребрәк китте шикелле.

Һәм ул минем алдан атлап китте. Хәзер инде бөтенләй бүтәнчә, ашыкмыйча...

Альбина әле генә йөзем җыеп килгән җиренә таба бара... Мин дә сабыр булырга тырышып кына, аның артыннан атлыйм...

Бара торгач чып-чын урман эченә кергәндәй булып китте. Көн яктысы да сүрелгән шикелле тоела башлады, әйтерсең лә эңгер вакыты җиткән дә, шуңа күрә караңгыланыбрак киткән... Ләкин бу эңгер һич тә шикләндерә, шомландыра торган түгел сыман. Бу эңгер—өстәге артык көчле кояш нурларын бераз гына тыючы эңгердер шикелле... Һәм, шул ук вакытта, бу эңгер—йөрәк түрендәге күпме гомер яшереп сакланган хисләргә юл ача торган, хәерле эңгер кебек тә иде... Аерым яшәлгән күп еллар салган богауны чишәргә, алар кигергән тимер калканны салдырырга булыша, ярдәм итә торган эңгер сыман иде бу...

Бер йөзем агачына тәбәнәк кенә баскыч та сөяп куелган икән. Әнә шул йөзем янына килеп җиттек тә, тукталып калдык.

—Хәзер мин менә бу баскычка менеп сиңа йөзем өзәм... Син шунда гына басып тор, яме!

Шулай диде дә Альбина бик тә җайлы гына иттереп баскычка менеп тә китте. Әйтерсең лә, Кырым кызлары шикелле гомере буена биредә йөзем җыеп яшәгән!

Һай, шунын йөзем өзүләре!

Менә сезнең тәбәнәк кенә баскычка басып йөзем җыючы кыз баланы күргәнегез бармы? Юктыр, мөгаен! Андый бәхет бик тә, бик тә сирәк тәти шул ул... Ә менә миңа ул бәхет елмайды. Мин «өнме бу, аллә төшме?» дия-дия, озаклап бу кыз баланың йөзем җыюын күзәттем.

Үземне көч-хәл белән тыя-тыя...

Ул бик тә иплəп кенә, жай белән генә йөзем яфракларын аралый һәм алар арасыннан үзенең ап-ак матур кулын суза... Аның йөземгә кагылган бармаклары үзләре дә иң татлы, иң шифалы, бары тик әкиятләрдә генә очрый торган бер хыялый жимеш шикелле күренә... Алар, ул нәфис бармаклар, йөзем тәлгәшен бик зур саклык белән генә өзеп ала да, әкрен генә учка таба күчерә... Шуннан соң кара кучкыл зәңгәр төстәге туп-тулы йөзем тәлгәше аның кулында бер матур күгәрчен шикелле булып: гүяки гөрләп, гүяки жырлап, гүяки иң матур хисләр-омтылышлар турында әйтергә теләп—ожмах кошы сыман серләр оясы булып—әнә шулай онытылмастай булып, миңа озак гомер күренеп тора...

Юк, алай гына да түгел! Менә бу йөзем куагы үзе дә, аның кочагына сыенган Альбина да, һәм аның кулындагы йөзем тәлгәше дә—болар һәммәсе дә гүяки бер Жимеш кенә! Әйе, әйе—менә шушы Кырым табигате, Кырым һавасы өлгерткән бер татлы жимеш алар!

Шуңа күрә мин инде бүтән түзеп тора алмый башлыйм. Түземсезләнеп:

—Альбина... Миңа йөзем авыз иттер!—дим...

Сүзләремә салынган эчке мәгънә аңа да барып житсен өчен тагын да бер мәртәбә кабатлыйм:

—Альбина... Миңа йөзем авыз иттер!

Ул аңлыймы-юкмы, анысын белмим, әмма шаяруны кабул итә һәм:

—Әй, мескенем! Бик ашыйсың киләмени соң?..—ди.

Мин балаларча елаган тавыш белән:

—Би-и-ик тә, би-и-ик тә!...—дим.

Шуннан соң ул моңа кадәр учында тотып торган йөзем тәлгәшен бик саклык белән генә сабагыннан элəктерə һəм аны, уң кулының өч бармагы белән генә тоткан килеш, бераз югарырак күтәрә дә, мине кызыктырып тора башлый.

Сез менә шушы илаһи күренешне күз алдыгызга китерә аласызмы? Дөньяның иң-иң гүзәле булган кыз үзенең ап-ак нәфис муены буйлап агылып төшкән сап-сары озын чәчләрен тузгытып салган да, йөзем куагы кочагына кереп, үзенең шулай ук шактый тулы күкрәкләре турына ук китереп, йөзем тәлгәше тотып тора. Әйтәм ич, ул чагында аларның һәр икесе—йөземе дә һәм кызы да—иң тәмле һәм иң ымсындыргыч жимешкә, тулаем бер жимешкә әверелеп беткән иде инде. Бер генә тере жан иясе дә бу жимешкә ымсынмый кала алмый иде...

Һәм мин иплəп кенә сузылып аның кулына кагылдым... Шулай итеп аны акрын-акрын гына жиргә, үз яныма төшердем... Ә аннары инде безнең куллар үзләреннән үзләре, йөзем сабагы сыман булып, безне урап, безне кочып алды...

Яшәгән бүлмәсе бик тә бәләкәй иде аның. Көньякка ял итәргә килүчеләрдән мөмкин кадәр күбрәк акча каеру өчен әнә шулай тавык кетәклеге ясап бетерәләр бит инде алар—мондагы хужабикәләр. Альбинаның бүлмәсендә дә бер карават тора да, тагын кечерәк кенә өстәл һәм урындык... Ашау һәм бизәнү әйберләре—һәммәсе бер өстәлдә. Икесе ике башка аерып кына куелган. Алар уртасында уч төбе зурлыгындарак бер көзге ята...

Альбина бүлмәсендә ушка килгәч, бер тын әнә шуларны күзәтеп яттым... Ә Альбина мине күзли икән. Бераздан тавыш та бирде:

—Нигә син берни дә сорамыйсың?

Ә мин тавышыма ис китмәгән төс бирергә тырышам.

—Үзең сөйлим диден ич...

—Шулай шул анысы...

Бер мәлгә тынлык урнаша. Бары тик көньяк чикерткәләренең көчле чикылдаулары гына тәрәзә аша шактый ачык булып ишетелеп тора. Аларның әнә шундый кискен һәм ашыгыч тавышы ничектер уйларны

да бүтәнчәрәк итә, бүтәнрәк агымга көйли...

—Теге вакытта син үпкәләдең бит... Минем янга килми башладың!—Альбинаның тавышында бераз гына әрнү дә, аз гына ачу да һәм мине битәрләү дә бар... Хәтта мине мыскыллау аһәңе дә чагыла сыман. Ә бусы ни өчен икән инде?

—Әнә шул чагында син шып туктамаган булсаң, кулыңа килеп керәм диеп торган кыз өчен аз гына булса да тартышкан булсаң—ул чагында мин синеке була ала идем бит... Ә син бер сүз ишеттергәннәр дә, син инде шуны ишетү белән үк, шалт борылып кирегә чаптың! Барысын, һәммәсен—безнең бөтен матур көннәрне, без кичергән барча бәхетле мизгелләрне ташлап, кире йөгердең син!

—Ну бит, синең ул егет белән янадан йөри башлавың дөрескә чыкты ич инде!—Тагын нәрсә кирәк! Мин дөрес уйлаган, дөрес нәтиҗә ясаган булып чыгам ич!

—Алай түгел шул менә!

—Ничек инде алай түгел?

—Без синең белән элек мин торган тулай торакка бардык ич әле...

—Әйе, бардык!

—Һәм анда безгә Сәлим очрады... Нәрсәдер әйтергә теләде.

—Әйе, анысы да булды!

—Менә шуның икенчеме-өченчеме көнендә ул синең белән мин торган тулай торакка килде. Безнең бүлмәне дә эзләп тапкан. ... Шул... Кызлар барысы да өйдә иде. «Әйдә, мине тукталышка хәтле озатып куй әле»,—диде.

—Син аны озаттыңмы инде?!

—Озаттым, билгеле! Аны үзебезнең бүлмәдә, кызлар каршында утыртмам бит инде!

—Һе...

—Анысы шулай... Мин ул чагында тиз генә озатам да, әйләнеп керәм диеп уйлаган идем... Ә ул юлда әллә ниләр сөйли башлады. Синнән башка яши алмыйм мин, ди... Болай булса бетәм бит мин, ди... Кулымнан тотты да: «Дөньяның бер кызыгын да тапмыйм—шуңа күрә эчәм дә эчәм»,—ди... Мин дә әзрәк йомшаклык күрсәткәнмендер инде, бәлки...

—Бу әнә шул, беренче чыгуында булдымы соң инде синең?

—Шул көнне инде... Егетләр сиңа шуны җиткергән бит инде! Дөрес түгелмени?

Миңа ничектер уңайсыз булып китте. Әйтерсең лә ул түгел, ә мин гаепле?

—Аннары син күренми башладың... Ничек ачу килгәнне белсәң иде шунда! Әллә нинди әшәке сүзләр белән сүктем сине... Ишеткән булсаң, җир тишегенә кереп китәр идең, мөгаен!

—Ала-а-ай...

—Ә иң кызыгы: мин, беләсеңме, нинди нәтиҗә ясадым ул чагында? Минем бик баш ватып торасы килми иде инде, шуңа күрә кыска гына:

—Юк!—дидем.—Белмим!

—Минем өчен яклаучы була алмый икән бу!—дигән нәтиҗә ясадым мин ул чагында...

Аның бу сүзләре минем яңакка чапкандай итте! Йокылы-уяулы яткан җиремнән сискәнеп киттем. Ничек инде алай була?!

—Их сез, егет кисәкләре! Хатын-кызның сездән ни көтүен беләсезмени соң сез?!—Альбина әнә шулай дип минем йөзгә текәлде. Ә үзе терсәгенә таянып, бераз күтәрелгән. Аз гына елмая да, мине өйрәнә дә төсле...

—Шулай инде... Сез хатын-кыз бит серле карурман кебек... Мәңгелек табышмак сыман ич сез...

Кырымның йөзем куаклары белән чорнап алынган кечкенә генә

бүлмәсендәге безнең беренче очрашуыбыз әнә шундыйрак булды... Һәм аның сүзләре мине бик гаҗәпләндерде дә. Бик сәер эш иде бу.

Ә мине озатканда ул чын күңелдән кызгандырып:

—Онытма, яме! Син бит миңа бик кирәк!—диеп калды...—Бер ялгызым ич мин монда!

Баргалап йөрергә туры килде инде...

Тауга алып менә торган юлдагы ул өй, йөзем ботаклары белән урап алынган ул кечкенә бүлмә бик тә тартып, чакырып тора иде шул... Минем еракта калган матур яшьлегем кебек иде ул. Беренче сөюемне һәм ачы әрнүемне үзенә берләштергән сер йомгагы шикелле иде ул Альбина.

Ярар... Ялтада көн артыннан көн үтте... Безне автобусларга төяп, Бакчасарайга да алып бардылар... Алупканы, Алуштаны да күрдек... Биек тау башындагы могҗиза—Кара Күлне дә карап йөредек... Данлыклы Ботаника бакчасын да онытмадык... Антон Павлович Чехов яшәгән йортны, хәзер анда оештырылган музейны да үзем генә барып иркенләп карап, танышып йөрдем.

Юк, аның ише җирләргә Альбинаны алып бармадым мин. Аның үзенең дә мондый теләге сизелмәде. Ул диңгез буенда озаклап була, аннары шәһәрне карап йөрим дия иде...

Китәр көннәр дә якынлашты.

Без, дөнья күреп кайтырбыз, диеп, билетны поездга алырга булдык. Кырымның башкаласы Акмәчеткә килсәң, аннан теләсә кайсы якка китәргә җай табыла бит инде ул.

... Кузгалырга ике-өч көн кала Альбина янында тагын булдым мин. Ул әле генә диңгез буеннан кайткан иде. Юл уңае диеп зур гына бер карбыз да алган. Мин килеп кергәндә тәрәзә янындагы өстәл өстендә әнә шул башланмаган карбыз матур булып күренеп тора, ә Альбина үзе су коенып кайткан киемнәрен урнаштырып йөри иде.

Күрү белән беренче сүзе дә шул булды:

—Әфәндем! Сезгә зур миссия ышанып тапшырыла!—Ул, шаян елмайган хәлдә, карбызга ымлады.—Без фәкыйрегез көч-хәл белән күтәреп кайткан карбызны тип-тигез итеп телгәләү сезгә йөкләнә!

Нишлисең, бу эшкә дә тотынырга туры килде.

Безнең бәхеттән, карбызыбызның эче кып-кызыл, мондый эссе көнне авыз суларын китерердәй дәрәҗәдә кызыктыргыч булып чыкты... Шуның өчен Альбинаны мактап та куйган булдым:

—Ничек чамалый алдың син моны—шундый да шәп карбыз эләктергәнсең!

—Уңган кеше инде мин!... Бары тик бәямне белүче генә юк!

Соңгы мәртәбә очрашабыз бит, диеп, мин бер шәраб та алып килгән идем. Карбыз янына анысы да бик урынлы булды...

... Аннары ул мине йөзем куаклары, йөзем ботаклары белән уралган болдыр баскычына чыгып, озатып калды... Беренче күргән көндәге чәчәкле кимонодан һәм ялан тәпи генә килеш чыккан иде ул озатырга... Бу вакытта инде кояш та батып бара иде. Аның соңгы нурлары бездәге моңсулыкны тагын да арттырды... Юлым таудан түбән таба барса да, адымнарым—акрын, салмак булды...

«Кырымда шушындый бәхетле мизгелләрне бүтән кичереп булмас инде... Беркайчан да бүтән булмас инде андый минутлар...»—диеп уйладым эчемнән ул көнне, таудан төшә-төшә...

Ярар... Шулай итеп, Ялта белән саубуллашыр көн дә килеп җитте. Без яңадан бөтен Кырымны кичеп, ике сәгать буена троллейбуста килдек... Акмәчеткә килдек! Алдан ук билетлар алынган булгач әллә ни озак юанмадык та: юлга тагын бераз азык-төлек өстәдек тә, купеларга кереп урнаштык.

Поезд шактый акрын кайта, шуңа күрә тирә-юньне иркенләп күзәтергә мөмкин. Ерактарак күренеп торган тау башларына, тау битләренә карап уйга, хыялга талырга да була.

Ә минем уйлар исә һаман Альбина турында... Өзеп кенә әйтмәде— ул бирелә озак тора микән соң әле? Әйберләре байтак кына күренде, аны ничек итеп күтәрә алыр инде ул? Ә алда безнең хәлләр ничек булыр?

Үзем тәрәзәдән күренгән тау битләрен күзәтеп барам, ә үземнең башымда әнә шундый уйлар, әнә шундый сораулар кайнаша...

Ул көнне караңгы да төште. Берәм-берәм урыннарга урнаштык. Селкенгәләп баруы бик үк җайлы булмаса да, юлда озак килә-килә шактый арыткан булганлыктан акрынлап йокыга да киттек.

... Уянуын иң алдан, купеда иң беренче булып уяндым мин икенче көнне. Вагоныбызның теге башына барып юынып та килдем, бер үзем генә чәй дә эчеп алдым... Аннары нишлисең инде? Чыгып бастым коридорга—тышка карап барам шулай. Чөнки әле купеда йоклыйлар, анда утырасы да, басып торасы да килми.

Тәрәзә пәрдәсен бер яккарак ачып куйдым да шундагы аркылы тимер таякка тотынып, иплэп кенә барам... Поезд инде хәзер шактый ук тиз элдерә. «Инде без ярты юлны үткән булырга да тиештер...» диеп уйлап тора идем, кемдер вагонның теге башыннан миңа таба үтте дә, узып китмичә артыма килеп туктады... Мин шундук борылдым билгеле. Ә анда... Ә анда кем, дисез?! Ә анда, берни булмагандай елмаеп, Альбина басып тора! Үзе бармагын авызы турына куйган. «Тс-с-с!»—ди миңа.

Баскан урыннан егылып китә яздым ул чак! Төш күрәм диеп торам!

—Син... Син ничек монда??—дия алдым, көч-хәл белән һәм пышылдап кына.

Әмма ул үзе миңа «тс» дисә дә, шактый ук кыю итеп:

—Менә, мин дә кайтырга уйладым әле!—ди, күзгә карап.

Шунда ирексездән елмаеп җибәрдем, ни өчендер курку да бетте. «Чыннан да, мин аңа кайчан кайтырга икәнен әйтә алмыйм ич инде! Кайчан кайтасын, ничек кайтасын үзе хәл итә бит инде ул!»

—Әйдә, мин сиңа үземнең купены күрсәтәм...

Шулай дип, Альбина кулымнан житәкләде.

Ике вагон аша икән аның урыны. Барып керсәк—бер купеда бер үзе бу!

—Ә бүтәннәр кая? Юлдашларың юк идемени?—дип сорыйм моннан, бик тә гажәпләнеп.

—Бар иде... Менә әле яңа гына төшеп калдылар...—ди бу һәм бераздан мут кына елмаеп өсти дә:—Безнең бәхеттән!

Аннары ул ашыкмыйча гына тәрәзә пәрдәләрен төшерде. Ишекне бикләп куйды. Утыргычны күтәреп аның астындагы сумкадан затлы шәраб та чыгарды. Кабымлыклар алып куйды...

—Ялта белән саубуллашу!—дип чәкештек без касәләрне.

Ә икенче бер чәкешкәндә ул:

—Минем иң матур ялым булды бу!—диеп тә өстәде...

... Ул көнне кичкырын безнең шәһәргә килеп життек. Ә Альбина әле ары таба китә иде. Аның вагоны яныннан үткәндә мин сиздермичә генә тәрәзәсенә күз салдым. Ул бер як пәрдәне генә ачкан да, бу якка таба текәлгән. Утырган килеш кенә.

Мин инде, билгеле, аңа озак карап тора алмадым. Ашыга-ашыга трамвайга таба киттек... Без трамвай көткәндә исә Кырымнан килүче поездның кузгалачагын да игълан иттеләр...

Менә шулай булды ул җәйне минем баштан кичкән гажәп хәлләр!—дип сүзен тәгәлләде Федотов.

—Ә аннары? Аннары очраштыгызмы соң?

—Юк шул! Бүтән очрашу насыйп булмады безгә! Телефоннан берике мәртәбә сөйләштек тә... Хәтта мин әле аның шәһәренә барырга да җыенган идем... Ләкин дөнья бит! Анысы килеп чыкмады. Шулай итеп, без аның белән югалтыштык... Хәзер инде гомергәдер, мөгаен...

Әмма, күпме генә гомер үткән булса да, Альбинаның йөзем жимешләре җыйган чагындагы гүзәл сурәте дөньядагы иң-иң матур, иң-иң бөек бер картина сыман һаман-һаман минем күз алдыма килеп баса. Күз алдыма килеп баса да, хатын-кыз дигән бөек һәм илаһи зат турында күңелемдә иң-иң татлы, садә, югары уйлар уята. Тормышның, яшәешнең, табигатьнең бөтен яшәү көчен һәм матурлыгын, серлелеген һәм үлемсезлеген үзенә туплаган гаҗәеп бер зат ул хатын-кыз булуга мин яңадан да бер мәртәбә ышанам... Альбина турындагы бу хатирәм миңа яшәүнең, кеше гомеренең тиңдәшсез бер бөек бәхет икәнлеген тагын бер мәртәбә раслый... Сез, әфәнделәр, ни генә дисәгез дә—әллә нинди әхлак кануннарын искә төшерсәгез дә—яшәешнең бөек фәлсәфәсенә бик тә якын тоелган әнә шул фикеремнән кайтасым юк минем!

—... Әйдәгез, минем менә шушы ныклы ышанычым өчен берне күтәреп куйыйк!

## Көймәдәге төн

*Светлана Юрьевнага багышлана*

—Шул хатын-кыз аркасында күпне күрә инде безнең башлар!—диеп, бераз гына шаярткан төслерәк тотынды үзенең сүзенә өлкән лейтенант Булатов тагын бер кичне.—Менә минем дә яшь чагында баштан кичкән бер хикмәтле вакыйга искә төште бит әле... Хәзер шуны сезгә сөйлисе килеп тәмам тел кычыта, түзәрлек түгел дигәндәй...

Атна буена шушында—калын кар белән капланган кышкы тайга уртасында яшәп яткан бу офицерларның инде ашар азыклары да нык кына такырайган иде: хәзер алар көн саен диярлек токмач белән кәбестә генә кыздыралар. Солдатларның да ризыгы шул чама гына... Ләкин моңа әлләни уфтанучы, бигүк аптыраучы юк—чөнки тиздән барысы да полкка, димәк шәһәргә кайтып китәчәк.

... Ә кәеф күтәргеч «утлы су» һаман табыла тора үзе! Моның серен баштарак яшереп тә маташкан иде капитан Федотов, әмма һәммәсе дә кызып җиткән бер кичне аның үзенә дә сиздермичә телен яздырдылар. Баксаң, моннан егерме чакрымдагы кореялылар яши торган бәләкәй генә бер авылга (ә бу якта андый авыллар шактый очрый) махсус машина куа икән ул! Ике генә сәгатьлек «командировкага» була инде бу, ягъни... Яшерен һәм «үтә мөһим» бурыч йөкләп, ягъни.

Шуңа күрә офицерларның кичләре һаман күңелле үтә. Тар гына, кысан гына землянка эче дә һич туйдырган төсле түгел... Аннары көн саен диярлек кызыклы хикәятләр дә сөйләнә тора бит әле! Һәрберсе эч серен бушата, еллар буена саклап йөреткән гыйбрәтле хатирәсен сөйли.

Бу юлы инде өлкән лейтенант Булатовның авызына текәлделәр.

Ә ул өстәл башындагы үзенең кичәге урынына кереп утырган. Савытындагы «утлы суны» да тотып куйганлыгы сизелә—авыз ерык.

—Бик тә эссе килгән җәй иде ул...—дип сөйләп китте Булатов.—Әнә шул җәйне Агыйдел тамагындагы бер район үзәгендә зур гына семинар үткәрергә булдылар.

Ярар, барыбыз да җыйналдык без бу җиргә. Үзе ямьле генә урын, әмма шәһәр дип тә, авыл дип тә әйтергә тел бармый. Чөнки, авыл дияр иден—сирәк кенә булса да өчәр-дүртәр катлы таш йортлар күтәргәннәр... Инде шушы таш йортларга карап «бу кала бугай бит» дип әйтергә теләр идең—урамында ник бер асфальт, тротуар әсәре булсын!

Кыскасы шул: безне, килгән кунакларны, кунакханә дип аталган дүрт катлы өр-яңа бинаның өченче ярусындагы зур-зур бүлмәләргә урнаштырдылар болар... Менә дигән, әле яңа гына буялып, буяу исе кибеп тә җитмәгән якты матур бүлмәләр иде алар.

Ә тәрәзәсеннән... Ә тәрәзәсеннән шундый ямьле булып Агыйдел тугае күренеп тора! Ярдан ерак түгел бәләкәй генә утраулар да күзгә ташлана. Ул утрауларның өсте тәбәнәк тал куаклары белән капланган, шуңа күрә биредән—кунакханәнең өченче катыннан—караганда алар суда йөзеп йөрүче өер-өер йорт казларын хәтерләтә. Йорт казлары да бит шулай салмак кына, сизелер сизелмәс кенә йөзеп йөри җәйге тыныч су өстендә. Шундый купшы булып, кул белән кагылып иркәлисене китереп, йомшак, назлы күренә бит алар шулай яр буеннан күзәтеп торган чагында...

Әйе, безнең бүлмәнең тәрәзәсе янына килсәң китәрлек түгел иде шул! Тау астындагы авыл өйләре дә уч төбендәгедәй ачык күренә. Әнә, бер ишек алдында өч-дүрт бала-чага нәрсә беләндер мәш килә... Әнә, икенче ихатадан ашыкмыйча гына бер абзый чыгып килә... Кайсыбер ишек алларында яшел чирәм дә күренә икән әле монда. Ерак булса да күзне иркәләп, үзенә ялан тәпи белән басуны көтеп, ымсындырып тора кебек ул.

Шулай... Менә тагын бер җәй үтеп бара диген...

Ә минем инде ничә җәй авылга кайткан юк! Шул—эш дия-дия, мин инде ничәмә ничә җәемне менә шулай читтә уткәрергә мәҗбүр. Командировкалардан кайтып керә алмыйча, зур-зур түрәләр катнашында менә шушындый семинарлар үткәрә-үткәрә, бик тә күнелсез генә уза да китә минем җәйләр...

Быел да кайтып булмас микәнни соң? Анда бит быел Халисә дә кайтам дигән иде бит әле... Инде бер елга якын очрашмаган Халисә дә! Менә хәзер, менә бу көннәрдә, ул авылдадыр бит инде. Рәхәтләнеп ял итеп ятадыр ич инде ул шушындый ямьле көннәрдә.

Бу турыда уйлагач, миңа монда бик тә күнелсез булып китә. Ямансу булып... Моның ише җыелышларның бер кызыгы да калмый. Хәтта ачу да килеп китә. «Кем өчен генә кирәк соң инде бу семинар?!»—дип тә уйлап куямын эчтән генә... Әмма... Әмма җитәкчең әйткәч, ул кушкачтын, эшләмичә ярамый шул! Һич кенә дә ярамый! Чөнки җитәкчеләр алар менә шушының ише ысуллар белән үзләренең эшләрен күрсәтәләр. Бөтен республикага шаулыйлар. Югарыда үзләре турында яхшы фикер тудыралар... Ә бүтәннәргә исә тыңларга, буйсынырга, алар кушканны үтәргә генә кала... Эш өчен, халык өчен кирәкме-юкмы моның ише нәрсәләр—түбәндәгеләр бу хакта уйламаска тиеш!

Әйе, туган авыл ничә ел буе мине көтәдер инде...

Иркенләп кайтып, бер Туктар чишмәләренә төшәсе иде бит! Ялан тәпи йөрисе иде бит әнә шул чишмә янындагы йомшак, назлы чирәмнәрдә! Их, йөрисе иде бит бер кинәнеп, туарылып, дөньяны онытып!

Ә бит чынлыкта минем авыл моннан әлләни ерак та түгел үзе... Бер утыз-кырык чакрымнар чыга микән—турыга гына үлчәсәң...

Ләкин су аркылы шул ул... Иделнең теге ягында ук шул минем авыл... Әле туп-турыга чыгып кына да түгел. Иделне кичкәчтен тагын байтак кына араны түбән таба төшәргә кирәк, агым унаена.

Их дөнья, дөнья! Нигә соң бу адәм балалары гел үзләре теләгәнчә генә яши алмыйлар икән?! Нәрсә мәҗбүр итә соң мине менә шушындый матур җәй көнендә әллә кайларда каңгырап йөрергә? Әллә кемнәрнең көен көйләп йөрергә?! Акчамы?! Бары тик акча гынамы?!

Йа, Хода! Яшь чагында, романтик хыяллар белән ашкынганда, ул акча дигән нәрсә шуның кадәр дә зур кодрәткә ия дип уйлый да алмый идем ич мин! Аны максат итеп куйган кешеләрне чын күнелдән кызгана идем хәтта. Кайберсеннән чиркана да идем кебек әле... Чөнки шул акча дип бик тә түбән төшкән кешеләр дә очрый иде ич...

Ә баксаң... Ә баксаң—үзем дә шул хәлгә төшеп барам түгелме соң мин? Әкрен-әкрен генә... Үзем дә сизмичә генә... Хәер, моны, бу хәлне «күрергә, белергә теләмичә» диеп әйтү дөресрәк булыр кебек. Шунысы төгәлрәк туры киләдер минем очракта.

Бүлмәдә без—дүртәү. Шактый юан һәм тәбәнәк буйлы булса да

терекөмештәй житез йөри торган, йөзендә гел елмаю балкыган Әхәт абыйга инде пенсиягә дә күп калмаган, диләр... Ә анын янәшәсендәге караватка урнашкан Сәлим әфәнде исә әле күпкә яшь, ләкин ул үзен гаять тә житди тотарга күнеккән. Сөйләшүе дә бик салмак, акрын. Юан муены да як-якка сирәк кенә борыла. Сөйләшкән чагында ул сиңа карамаска да, хәтта сүзенне ишетмәмешкә салынырга да мөмкин. Бу кеше белән уен-муен сүз сөйләшү дә ярамый сыман... Ә өченчебез Таһир абый исә—бик ипле, жайлы кеше күренә. Анын зур конгырт күзләреннән сиңа жылы бөркелә. Ул синең пүчтәк кенә сүзенне дә жавапсыз, игътибарсыз калдырмас...

Ярый, шулай итеп безнең бу семинарның беренче көне узып та китте... Ашыкмыйча гына, байларча гына, ашагач-эчкәч берәм-берәм бүлмәләргә кайттык... Әмма анда!.. Анда чыдап булырлык түгел! Шундый эссе, шуның хәтле бөркүлек—һич кенә дә тын алырмын димә! Нишлисең, сукрана-сукрана аз гына басып тордык та, янадан урамга чыгып киттек инде. Бераз йөреп килик алайса, диеп.

Ә су буенда рәхәт ичмасам! Монда яры да сөзәк, комлы—ул, бәләкәй-бәләкәй тугайлар ясый-ясый, еракка ук сузылып китә... Мин түзмим: чалбар балагын өскәрәк күтәреп сызганып куямын да, су эченә үк кереп китәм... Аннары яр буена чыгып, шунда яткан коры кискәгә утырып торам... Киң булып жәелеп яткан шушы дәрьяга карап янадан авылымны уйлыйм... Яр буена утырып Халисә дә менә шулай мине көтәдер кебек тоела башлый.

Инде тәмам караңгы иңгәч, каршы як ярлар бөтенләй дә күренми башлагач кына кайттым мин бүлмәгә.

Анда һаман әле бөркү иде, ләкин бусы инде бераз түзәрлек сыман күренде, аннан соң вакыт та байтак бит инде—шуңа күрә иплэп кенә урыныма барып яттым... Күрәсең, көне буе эсседә йөреп шактый ук арыткандыр, озак та тормастан, онытылып та киткәнмен шунда...

Ләкин озак йоклау насыйп булмады: манма тиргә батып янадан уяндым. Уянгачтын инде юеш урында озак ятып булмый—торып та утырырга туры килде... Шул арада йокы да качты инде.

Ә тегеләр, эсселеккә уфтана-уфтана әйләнгәләп куйсалар да, әле уянырга уйламый, ахрысы. Ята бирәләр.

«Тукта,—мин әйтәм.—Монда кыштырдап маташсам, боларны уятам ич мин. Әйдә, тагын бер мәртәбә һавага чыгып керим әле!»

Өскә жинелчә генә киенәм дә, сандалины кулга тоткан көе аяк очына гына баса-баса, бүлмәдән чыгып та китәмен...

Ә аска, беренче катка төшсәм—менә сиңа мә! Кунакханәнең эчке ишеге ныклап торып бикләп куелган! Хәтта ат башы хәтле йозагы да асылынып тора әле.

Әлбәттә, моны дежур хатын бикләгән инде... Әлбәттә, ул үзе дә каядыр шушында—шушы каттагы бәләкәй-бәләкәй бүлмәләрнең берсендә йоклап ята инде!

Ләкин бу вакытта, жиде төн уртасында, ничек аны уятасың, ди! «Һавага чыгасым килә!»—дисеңмени?!

Шулай дип үземне мыскыллый-мыскыллый басып тора бирәм шушы ят бер кунакханә эчендә.

Ә урамга чыгасы килә, малай! Бик тә килә!

Шул чагында, миңа үч иткән сыман, тышкы яктагы бер куакта сандугач та өздереп жибәрмәсенме, мин сиңа әйтим!

—Әйдә, монда чык! Жанын бармы соң синең?!—ди ул гүяки.—Үзеңнең авыл малае икәненне оныттыңмы әллә?—ди.—Кызлар озаткачтын, таң атканда гына өйгә кайтып керүләренне истән чыгардыңмы әллә бөтенләй?!—ди төсле миңа әлеге сандугач сайравы.

Монда инде хәзер мин—читлектә, ә сандугач иректә кебек. Хәзер инде мин арлы-бирле йөренәм. Аптырыйм, йөдим. Һич кенә дә чыгу жаен таба алмыйм.

Шулай газапланып күпме йөренгәнмендер, белмим, әмма бер мәлне күзем тәрәзәгә төште бит! Беренче каттан икенчесенә менүче шома мәрмәр баскыч янындагы таррак кына бер тәрәзәгә.

—Тукта әле!—мин әйтәм.—Неужели мин моны ача алмам?!

Якын киләм. Карыйм. Зур-зур кадакларны агач рамга какканнар да, яртылаш бөгеп, тәрәзәнең ачыла торган бүлеген шул кадаклар белән бастырып куйганнар. Ә ул кадаклар өстенә калын булып чиста ак буяу каткан. Тырнап карыйм—таш кебек!

Шуннан соң мин нишлим дисен?

Кесәмнән бүлмә ачкычын аламын да, шуның очы белән иң башта кадак янына ябышып каткан буяуны кырамын. Газаплана-газаплана инде! Төзүчеләрне, буяучыларны эчтән генә сүгә-сүгә инде! «Шуның хәтле буявыгызны юкка әрәм итмәсәгез!»—дим эчтән генә тегеләргә. Тетмәләрен тетәм үзләренең!

Маташа торгачтын, тәки зур-зур өч кадакны буяудан арындырдым бит мин, малай! Аннары сон инде аларны кире якка таба борырга тырыша башладым... Ахыр чиктә анысы да булды. Хәзер инде рам ачылырга тиеш иде. Шулай диеп уйлыйм. Ләкин, хәерчегә җил каршы дигәндәй, анысы да, әллә буяуга каткан булды шунда, әллә яңгырга чыланып бүрткән булды—тиз генә ачылырга бер дә ашыкмады әле ул. Тагын байтак кына газапланырга туры килде! Тәрәзә тоткасы бөтенләй суырылып чыга диеп торам!

Менә, ниһаять, булды!

Тәрәзә киереп ачылган—урам яктан бөркелеп диярлек төнге салкынча рәхәт һава керә! Хәзер инде бу якка да кошлар, дөнья, табигать аһәңе агыла.

—Яшибез, димәк!

Шулай дип үземне үзем дәртләндерә-дәртләндерә бераз тын алам да, аннары инде, өй басучы караклар сыман—бөтен гәүдәм белән тәрәзә уемына керәм һәм янагына тотына-тотына җиргә аяк басам.

—Ниһаять, мин—ирекле!—дим көлә-көлә үз-үземә зур горурлык белән.—Мин ирекле!

Менә шулай итеп, ул төнне таш капчык тоткынлыгыннан котыла алдым мин. Бер чыккачтын инде, билгеле, авыл урамында байтак кына йөрелде... Сонга калып өйләренә кайтып баручы мәчеләргә (алар да ата мәчеләр иде бугай ) бик тә сагынган төсле озак кына карап тордым. Тау астындагы урам ягыннан ишетелгән әтәч тавышларына мөкиббән киттем... Кыскасы, ул төнне мин азга булса да сагынуымны баса алдым кебек.

Инде кире керәсе дә бар ич! Ә бүтән юл юк—янадан да шул ук, үзем ачкан тәрәзәгә киләм... Әмма хәзер инде астан күтәрелү өчен минем буй җитми икән шул... Аяк астына куярга бирәр әйбер эзләп китәм. Ерак та түгел кирпеч ватыклары күргәч, аларны сөенә-сөенә аслы-өсле тезәргә тотынам. Шулай итеп үземә керү юлы салам!

Яшь чак—дәртле чак, гәүдә җинел. Кире керүе әлләни кыен булмады миңа... Ләкин: «Инде булды! Инде кереп җиттем!»—дип уйлап кына да бетермәдем... Әле эчтәге баскычка аягымны тидергән генә идем... Әнә шул минутта баскыч буйлап югарыдан төшеп килүче ике адәми зат очрамасынмы! Һич көтмәгәндә, һич уйламаганда!

—Алла!—дим эчемнән генә.—Бу ни була инде бу?!

Каттым да калдым шул баскан җирдә. Тын алырга да куркам.

Әле бит болар кемнәр диген?! Шушы районның түрәсе бит берсе! Арттагысы аны озата чыга, ахрысы... Бер бүлмәдә мәҗлес корып утырган инде болар... Шуңа күрә сонга калган инде бу.

Алларында каккан казык сыман тырпаеп торган кешене күрми мөмкин түгел инде... Минем тәрәзәдән кергәнне дә күрде бугай инде алар... Нәрсә диярләр икән сон?! Әмма үзем бер генә сүз дә дәшмим. Дәшә алмыйм. Тик басып торам шунда. Һәм... кымшанмыйм да... Минем хәл көлке дә... кызганыч та!

Ышанасызмы юкмы: тәки тып-тыныч кына узып киттеләр бит минем кырыйдан... Бер сүз дәшмичә генә.

«Иртән иртүк нәрсә диеп сүгәрләр икән инде?»—диеп шыр жибәргән идем—иртән дә сүз дәшүче булмады тагын... Хәзер инде менә уйлап карыйм да, мондый фикергә киләм: ә бәлки алар үзләре миннән шүрләгәндер әле ул чакны?! Кем белә?! Уйламаганда ят кеше күзенә күренде ич алар!

Үзем ачкан әнә шул «юлдан» тагын бер-ике мәртәбә чыгып кердем әле мин. Әйткәнемчә, төннәре бик бөркү иде бит.

... Ә семинар әйбәт кенә дәвам итә. Якын-тирә авылларга да алып баралар. Утырыш иртәрәк бетсә, жыелышып төшәбез дә су коенабыз. «Көннәр шәп тора ич, үзенә күрә бер курорт ич бу»,—дибез.

Әмма шулай да минем күнел тыныч түгел. Юк! Һич кенә дә тыныч түгел! «Халисә хәзер авылда ич инде!»—дигән уй минем күнелдән бер генә дә чыкмый дияргә була. Ел буена күрмәгән Халисә ич инде ул...

Кичләрен ялгыз калып йөргәндә бигрәк тә борчый бу уй. Ләкин борчылуын борчылсам да, чарасын һич кенә дә таба алмыйм. Дәрт бар—дәрман юк, дигәндәйрәк килеп чыга минем хәлләр... Ничек кенә итеп бер жай табарга соң миңа?!

Шулай көн артыннан көн уза...

Менә бер вакыт:

—Район житәкчелеге кунаклар өчен мәжлес үткәрә!—дигән хәбәр чыкты.

Ярга бәйләп куелган иске дебаркадерда көйләнгән су өсте ресторany бар икән боларның—мәжлес шунда булачак, ди.

Бу хәбәргә галәмәт тә нык сөенештек без! «Бер күнел ачарбыз ичмасам!—диештек.—Мондый эсседә семинарда йөрү мәхшәр бит инде ул. Хет шуның өчен сыйласыннар!»—янәсе.

Ярар, тәмам энгер иңгәч кенә башланып китте безнең бу мәжлес.

Өстәлдәге ризыклар галәмәт шәп, сөйләп кенә бетергесез. Монда әллә ничә төрле балык та бар. Аның уылдыклары да өеп-өеп куелган. Итләрне дә ниләр генә кыландырып әзерләмәгәннәр! Жиләк-жимешнен дә ниндие генә юк! Ә инде шешә ише нәрсәгә килсәк—алары да затлыдан затлы: савытларыннан ук күренеп, һәммәсе: «Мине ачыгыз!»—дип кычкырып тора сыман.

Хужа кеше дә үзен бик матур тота. Барыбызның да күнелен күрергә тели, һәммәбезгә дә елмаерга тырыша. Тостларга да бик оста икән, безнең бер иптәшебез әйткәндәй: банкетларда тәгәрәп үскән, ахрысы, бу! Шуңа охшаган!

Без инде Таһир абый белән бер тирәгәрәк утырган идек, затлырак ризыкларны сыпыртабыз гына. Кем күрсен! Безне «ашагыз, аша» дип кыстыйлар, ә без:

—Ярый безгә, уылдыгы да!—дип анысын урабыз!

Күз кызыгып башта чит илнең атлы шешәләреннән тотынсак та, аннары инде һәрвакыттагыча үзебезнең урыс аракысына әйләнеп кайтырга туры килде. Әрҗәсе-әрҗәсе белән китергәннәр ул хәзинәне... бер мәлне бездән бушаган шешәләрне куяр урын табылмый башлады: өстәл астыннан да, аяк арасыннан да тәгәрәшеп килеп чыга болар—хәтта шуларга абынып егылып та киткәлибез...

Әйе, күп эчелде, күп ашалды ул кичне... Өстәл янындагы һәркем белән дус, бөтенесе белән туган булып бетә язганбыз.

... Ә тышка үз йомышым белән генә чыккан идем мин... «Тиз генә әйләнеп керәмен, бераз һава аламын»,—диеп кенә...

Әмма ул төннең көчле тылсымы мине шундук үз кочагына суырып алды. Менә күз алдыгызга китерегез. Икенче каттан төшеп, ишектән чыгу белән сине тоташ карангылык биләп ала. Ә астан, диңгез сыман жәелеп яткан су дәрьясыннан, рәхәт бер дымлылык, су исе сизелеп тора. Мәжлестәге шау-шудан, тавыштан соң бу тынлык, бу рәхәтлек бик

тә тансык, бик тә кадерле тоела. Ул сине үзенә суыра, үзенә тарта— үзенеке итәргә тели.

Дебаркадер киртәсенә тотынып азрак басып тордым да кызыгып, яр буеннан ук урап килергә иттем.

Төн жылы, бик тә жылы. Хәтта яр буенда да жылы ул. Су өсте дә тыныч. Бары тик анда-санда балыклар гына сикерешеп ала...

Яр буенда кап-караңгы, бер генә ут әсәре дә юк. Бөтен яктан төчкелтем су исе һәм ярга чыгарып ташланган бака ефәге, черек агач исе, тагын әллә нинди исләр килә... Бераз гына сумала исе дә сизелә сыман... Су буенда үткән минем балачакның бик тә таныш, бик тә кадерле исләре инде болар. Шул тансык тәм, тансык исләр букеты инде бу миңа!

Су өстендә шулай ук тоташ караңгылык... Кайсыбер урында күктәге йолдызларның гына суда жемелдәгәне шәйләнә. Кайчагында алар су астында йөзүче алтын балыкка да охшап куя. Менә-менә өскә килеп чыгарлар да:

—Әфәндем! Сиңа бездән ни кирәк? Нәрсә боерасыз?—диеп, түбәнчелек белән сорарлар сыман...

Әйе, әйе—күңел әнә шундый сихергә, әнә шундый тылсымга ышанырга тели иде бүген! Ул кичне минем күңелнең әнә шулай: кечкенә генә очкыннан да дәртләнеп, канатланып китәсе—очынасы, талпынасы килә иде!

Рәхәт миңа менә бу яр буенда, бик тә рәхәт!

Гүяки минем моңа хәтле бик озак вакыт тыным кысылып, буылып торган да, гүяки әле менә хәзер генә сулышым, тыным ачылып киткән. Гүяки мин теге—«Амфибия Кеше» киносындагы Ихтиандр дигән егет! Аның сыман мин дә, әйтерсең лә, су дөньясына, үземнең дөньяма, үземнең стихиямә кайттым! Иркенләп сулый, рәхәтләнеп яши торган—үзем теләгәнчә, үземчә яши торган матур, чын дөньяма кайттым мин гүяки менә шушы минутларда!

Яр буе тип-тигез ком... Аякны басканда ул тыгыз булып тора. Аз гына бата. Мин түзмәдем, аяктагы сандалиемны салдым да, балагымны сызгандым һәм су эченнән яр буйлап әкрен генә бара башладым...

Барам-барам да, туктап эчкә—караңгы су өстенә карыйм. Аннан исә тагын да яңарак, тагын да татлырак дөнья сулышы бөркелә сыман... Анда агым да бардыр, тере дулкыннар да яшидер кебек...

Шулай уйлана-хыяллана яр буйлап атлый идем, кинәт кенә бер каты нәрсәгә килеп төртелдем. Кисәк бәрелүдән тез башымны авырттырдым хәтта! Ә иелеп, әйбәтләбрәк карап баксам... Карап баксам—көймә ич бу... Караңгыда яр буйлап килә-килә мин бер көймәгә килеп төртелгәнмен ич!

Билгеле, уйламаганда-көтмәгәндә бу ят, билгесез көймәгә килеп кагылгач мине шундук гажәпләнү, кызыксыну тойгысы биләп алды. Шуңа күрә сак кына басып көймәнең башына киләм...

—Әһ-һә!—дим шунда үз-үземә.—Моны чылбырлап та куйганнар бит әле, малай!

Әйтерсең, мин әнә шул чагында бер яшь юыртак янына килеп басканмын! Шунын хәтле иләсләндерә, дәртләндерә, кызыктыра бу билгесез көймә мине... Ана озак, бик озак карап торам. Гүяки әнә шул карашым белән аннан үземне каядыр алып китүен үтенәм, каядыр илтүен ялварам... Хәтта аны, әлеге билгесез, яңа көймәне, жанлы әйберне иркәләгән сыман сыйпыйм, назлап дәшәм мин... Әнә шул чагында әйтерсең лә ул мине, мин аны сихерлибез... Безнең арада гүяки бер тылсым күпере, тылсымлы бер бәйләнеш хасил була әнә шул чагында гүяки...

Мин акрын гына килеп, аның чылбырына кагылам. Бу жылы төндә салкынча тоелырга тиешле тимер чылбыр да минем тылсымлы халәтемне бүлә алмый—минем кулларым әлеге чылбыр буйлап һаман ярга таба килә... тукта! Ә болары нәрсә? Агач әйбер түгелме соң болар? Әһә...

Монда ишкәкләр дә бәйләп куелган ич! Шушы бер чылбыр көймәне дә, ике ишкәкне дә бәйдә тота икән ич! Бәйдә, биктә тота икән бер чылбыр! Тимер чылбыр!

Кинәт кенә миндә әллә нинди кыргый омтылыш туды. Шушы чылбырны ничек тә булса ычкындыру, көймәне шушы чылбырдан азат итү, аны ирекле итү теләге...

Һәм мин чылбыр очындагы асылмалы йозакны кулымда әвәрә китерә башладым. Аны тегеләй селкетәмен, болайга тарткалап карыйм... Бераз торамын да йозакның дугасын эчкә батырып куямын һәм янадан тышка таба тарта башлыйм... Ни өчен шулай итәм? Чөнки элегрәк, авылда, минем байтак кына йозакларны әнә шулай селкетә-селкетә ача алганым бар иде. Ни өчендер, миңа бирешә иде күпчелек йозак. Ачыла иде.

Бирерә дә, үзем дә аңышып житмәстән, мин әлеге ят йозакны озак кына вакыт кулымда әвәрә китердем. Әллә нинди бер үжәтлек, кирелек, усаллык белән—ә кайчагында исә киресенчә, йомшаклык күрсәтеп, иркә сүзләр, изге гыйбәрәләр әйтә-әйтә ялындым да мин аңа... Әнә шул, уч төбе зурлыгындагы бер тимер йозакка ул төндә мин үзем белгән барча матур сүзләремне түктем бугай...

—Зинһар өчен диеп сорыйм бит, йозаккаем...—дим мин аңа, сөйгән кызының йомшак колагына пышылдаган гашыйк егетләр тавышы белән инәлә-инәлә...

—Хәлләремне аңлачы минем...—дип сүз башлыймын тагын, аны икенче бер яктан килеп йомшартырга теләп...

—Мин сине беләм бит инде, син тагын бераздан барыбер ачыласың ич инде!—дим, йәнә бүтән бер ысулда, үземнең шушы тимер әңгәмәдәшемә мөрәҗәгать итеп.

Бу дөньядагы бөтен тоткынлыкның, коллыкның дәһшәтле бер патшасы сыман тоелган әлеге тимер йозак белән минем әнә шул рәвештәге төнге әңгәмәм, белмим, күпме гомер дәвам иткәндер—ул вакытта мин инде күптән вакыт исәбен, гомер агышын оныткан идем. Ул чагында мин бары тик бер дәрт, бер омтылыш, бер көчле ашкыну кочагында гына калган идем: ничек тә булса, ничек кенә булса да, нинди генә җай табылса да—теләсә нинди ысул белән менә шушы йозакны ачарга һәм бу көймәне азат итәргә! Миңа ул чагында үзем дә аңлап, төшенеп житмәгән ниндидер бер сихриме, илаһимы көч инде сыман. Ходай мине ниндидер бер тылсымга ия итте шикелле су буендагы әнә шул төнге караңгы мизгелләрдә!

Һәм мин Ходайның булышлыгы белән тәки үз дигәнемә ирештем! Бер мизгелдә кулдагы йозакның дугасы килде дә чыкты бит, малай! Күзләремә ышанырга белмичәрәк, аптырап, шактый гына гомер текәлеп карап тордым әле әнә шул чагында йозакка...

Аннары инде, бик тә күңелем булып:

—Әй, бәгыркәем! Менә рәхмәт, жаныкаем!—дия-дия, әнә шул салкын тимер йозакны үбеп тә куйдым хәтта.

Менә инде мин йозакны чылбырдан салдырам... Менә мин чылбырга кигезеп куелган ике ишкәкне дә берәм-берәм коллыктан азат итәм һәм жайлап кына көймә эченә кертеп куям...

Ә хәзер инде көймә—азат! Хәзер көймә минеке!

Шактый ук комга менеп утырган көймәне аз гына этәмен дә, аның ниһаять су иркендә калганын, ирекле тирбәлүен сизүгә, аякларым белән астагы комнан этелеп үзем дә жәһәт кенә көймә эченә кереп басам...

Беренче мизгелдә әле үземә үзем ышаныргамы-ышанмаскамы белмичәрәк торам. «Бу чын хәлме?—димен.—Алай-болай төш кера күреп ятмыйммы соң мин? Юкмы, алай түгелме?» Чыннан да, болай уйлау бик табигый—чөнки бөтен тирә-юнь кап-караңгы, бары тик дебаркадерның ачык тәрәзәсеннән генә мәжлестәгеләрнең жырлаган тавышы ишетелә һәм су өстенә бераз саргылт яктылык көлтәләре сирпелә.

—Әйе, мин—ирektә! Мин—ирекtә! Мин—көймәдә, ниһаять!

Ишкәкләрнең икесен дә үз урыннарына жайлап кына кертеп урнаштырдым да, киереп торып ишә башладым, мин синәйтим!

—Киттем!—дим шунда мин үз-үземә.—Авылга кайтып киттем мин! Үземә үзем кычкырып әйткән әнә шул сүзләр белән бергә үк күз алдыма Халисә килеп баса. Хәзер инде аңа карап, ана дип эндәшәм:

—Кайтам мин, Халисә! Бүген кайтып житәм мин! Менә күрерсең!

Шулай дигәч дәртләнебрәк китеп тагын да көчлерәк, тагын да кинрәк алдырып ишәргә тотынам... Көймә үзе дә жинел булып чыкты, ул бик тиз арада зур гына тизлек алды—мин аның су өстендә жинелчә генә чупылдаган тавышлар чыгара-чыгара, кап-кара суны бик кыю ярып алга баруын бөтен тәнем, бөтен барлыгым белән сизеп торам. Юк, алай гына да түгел: без хәзер менә бу көймә белән икебез бер жан, бер тән булып беттек сыман—без хәзер икебез дә бер үк дәрт, бер үк ашкыну белән алга омтылабыз сыман! Шунда янадан да әлеге Ихтиандр сурәте күз алдыма килә. Һәм мин үземне әнә шул Ихтиандр кебек су ярып баручы бер гажәеп жан иясе дип уйлыйм, шулай күзаллый башлыйм. Әлеге кинода ул әнә шулай сөйгән кызы янына ашыга иде бит әле—мин дә менә бу төндә үз авылыма, сөйгән кызым Халисә янына кайтырга телим!

Менә инде теге, без мәжлес корып утырган, дебаркадер шактый гына ерактә калды. Әмма аның утлары күренә әле, ә тавышлар калган ул тавышлар, ул тонык саргылт утлар түгел—ә алдымда, ләкин әле бик ерактә янып торган маяк уты кызыктыра.

—Тизрәк әнә шул маякка барып житәргә кирәк!—дим тагын үз-үземә фәрман биргән шактый кырыс ук тавыш белән.

Әйе, әлегә бит әле мин олы бер тугай эченнән генә барам. Безнең теге дебаркадер ул әнә шул тугайга урнашкан иде. Хәзер инде миңа алдагы маякка житәргә кирәк—бу инде Агыйдел белән Иделнең кушылган жире була. Димәк, мин анда хәтле барсам, юлның чирек өлешен узган буламын... Алла бирсә, ул урынга житсәм, миңа инде елга агымы да булыша башлаячак дигән сүз... Идел агымына чыгам дигән сүз!

Яр буйлары тоташ кара шәүлә кебек кенә күренә. Анда инде гел тал куаклары бара торгандыр, шунлыктан яр буе күк фонында дулкын-дулкын булып күренә... Баш очымнан канатлары белән һава кискәндә кыштырдаган-быжылдаган тавышлар чыгара-чыгара, ниндидер кошлар очып үтә. Ишүдән туктап ял иткән араларда, мин аларны күрергә тырышып, өскә күтәрелеп карыйм, ләкин әле төн каранғы—әле аларның бары тик шәүләләре генә шәйләнә һәм канатларның һава кискән тавышлары гына ишетелә...

Күз алдымда гел теге маяк... Әллә ул маяк түгел микән?!

—Әллә маяк түгел микән ул?!—дип, үзем белән үзем кычкырып ук сөйләшә башлыйм.—Әллә әнә шулай Халисә минем каршыга чыкты микән?! Мин кайтасыны белеп, мине каршы алыр өчен чыкканмы әллә ул?!

—Шулайдыр шул! Чыннан да—Халисәдер ул! Болай иртә бүтән беркем дә йөремәс!

Һәм шунда минем күз алдыма моннан өч ел элек булган бер күренеш килә...

Өйалды баскычына аның яланаяк килеш чыгуы...

Мин ишегалды чирәмендә, түбәндәрәк басып торам. Ә ул исә баскычта—югарыдарак, өстәрәк елмаеп тора. Бөтен алсу күлмәкләре белән, бөтен яшьлеге, бар чибәрлеге белән балкып, янып, елмаеп тора ул! Әнә шул илаһи күренеш минем хәтеремә бик озакка сеңеп калган иде, мин аны гел исемә төшерә идем...

Менә хәзер, ерактә су өстендә янып торган маяк уты миңа янадан да Халисәдер кебек тоела башлады. Чын менә, улдыр ул! Мине көтеп торадыр, «нишләп бик тә акрын килә соң?» диеп борчыладыр, аптырыйдыр...

Шундый уйлардан соң кулларның аруы, уч төпләренең инде кабарырга әзер булуы да онытыла—мин өр-яңа көч белән ишәргә тотынам.

Мин маяк янына килеп житкән чагында караңгылык бераз гына сыеклана башлаган иде инде. Шуңа күрә ерактан бик балкып, матур булып күренсә дә, мине дәртләндереп һәм алга ымсындырып торса да—якынлашкач миндә аңа кагыласы, тотып карыйсы килү теләге тумады ни өчендер. Ишүдән тукталып, шул тарафка карап бераз ял иттем дә:

—Инде менә хәзер агымга чыгам, Алла бирсә!—дип үземне дәртләндереп жибәрдем һәм соңгы көчне жыеп, янә дә ишәргә керештем.

—Әй, кызык икән монда!

Идел белән Агыйделнең кушылган жиренә житкән идем, үз авызымнан шундый сүзләрнең чыгып очуын сизми дә калдым!

Чыннан да: шушы ике елганың ике агымы арасында никадәр аерма бит! Берсе—Иделнеке—каракучкыл шомлырак агым булып бара, ә Агыйделнеке исә чыннан да аграк, чистарак, йомшаграк та кебек хәтта... Менә шушылай: нык аерылып торган ике агым булып, шактый араны уза икән алар... Аннары гына кушыла бу ике агым, ике олы елга...

Инде яктырып та бетте дияргә була. Әнә инде ямь-яшел таллар белән капланган тәбәнәк яр буйлары да аерым-ачык күренеп тора. Ә теге як яр... Ә ул яктагы яр бөтенләй күзгә дә чалынмый... Минем алда иртәнге жиңелчә томан белән капланган су өсте, иксез-чиксез су киңлеге генә... Гүяки бер диңгез эчендә мин хәзер бер үзем калганмын...

Әнә шундый чагында үч иткән кебек күңелне иләс-миләс уйлар да били башлый бит әле ул. Хәзер мин дә икеләнебрәк калдым инде.

—Тукта әле...—димен үз-үземә.—Мин кеше көймәсен алып киттем бит инде... Ул кеше иртән үзенең көймәсен эзләячәк бит инде! Ул моңа бик аптыраячак ич инде! Эзләячәк бит ул!

Һәм шулчакны—күңелемнән әлеге «эзләячәк» дигән сүз узып та өлгермәгән иде әле—кинәт кенә бөтенләй бүтән уй миңа аяз көнне яшен суккан шикелле булып, зиһенемә китереп бәрде:

—Мине дә эзләячәкләр бит хәзер!

Шулай дидем дә, үземә үзем шаклар катып, үземә үзем аптырап, чиксез гажәпләнә-гажәпләнә, утырган урынымда тораташ шикелле каттым да калдым!

Бераздан тагын кабатлыйм төш күргән шикеллерәк иттереп:

—Соң... Мин булмагач... алар нәрсә диеп уйларга тиеш соң инде?!

Әнә шунда гына үземнең нинди уйламаган эш эшләвемне—күпме кешене зур хафага салуымны аңлый башладым мин. Ярты юлымны үткәч кенә.

Торам шулай көймә эчендә—утырган килеш селкенмичә дә... Кыймылдарга да куркып... Ә көймә, сизәмен, агым уңаена акрын гына агуын дәвам итә... Агуын дәвам итә... Ага ул, ага...

Минем икеле-микеле халәтемне дә әнә шул агым хәл итте бу моментта. Чөнки ул мине үзеннән-үзе туган авылга, күптән күрелмәгән Халисәгә якынайта иде...

Шуңа күрә күңелдә бераз гына тынычрак уйлар да туа башлады.

—Билгеле, яр буенда көймә булмагачтын, алар әзрәк чамалар инде... Мине берәр кая киткән диеп уйларлар алар...

Үз-үземне шулай дип тынычландырмакчы булам. Кычкырып ук дәшәм инде үземә үзем. Кеше белән сөйләшкән шикелле иттереп. Шулай эшләсәң, фикер дә ачыграк аңлашыла, баш та яхшырак эшли кебек бит ул... Чын менә! Мин моны гел күзәткәнем бар!

—Әмма... Әмма мин нишли алам соң хәзер?! Ни чарам бар минем менә шушы минутларда?!

Артка таба борылып карыйм. Анда да берданбер күз текәр әйбер булып әлеге маяк кына тирбәлеп утыра.

—Их!—мин әйтәм.—Әнә шул маякта берәр төрле хәбәр бирү чарасы булсын иде! Үземнең монда икәнлегемне, нинди матур ният белән юлга чыгуымны аңлатып бирер идем кешеләргә... Анда калган, ярда торып калган кешеләргә!

Тагын бераз торгач, башка бөтенләй бүтән төрле фикерләр дә керә:

—Ә син нигә хафаланасың соң әле бу вакыттан ук?! Әле бит бик иртә! Бөтен кеше тәмле йокыда бит әле! Изрәп-изрәп, тәмле-тәмле төшләр күрә-күрә йоклый ич әле адәм балалары... бары тик син генә ул әллә кайларга дип чыгып киттең! Ахырын уйлап тормыйча...

—Әйе шул...—димен, тагын үземнең икенче «мин»ем белән килешергә мәҗбүр булып.—шулай килеп чыкты шул... Ләкин нишлим соң: йөрәк шундый бит инде! Аны үзгәртеп буламыни соң?!

—Ә акыл, ә баш дигән әйбер кешегә ни өчен бирелгән соң алайса?

—Хисләргә йөгән булыр өчен, билгеле! Аларны бераз тыебрак торыр өчен. Адәм баласын хаталардан саклау, дөресрәк юллардан йөретү өчен...

—Менә... Менә! Үзең телдә дөрес сукалыйсың син, ләкин нигә шуны чынлыкта да саклый алмыйсың?! Нигә?!

—Соң, нигә дип... Бераз гына йөрәкне дә аңларга кирәктер ич инде?! Менә уйлап кына кара: эш диеп йөри-йөри бер ел буена Халисәне күрми торамын ич инде! Ничәмә ничә ел буена туган авылымда Сабан туен күргәнем дә юк! Ә бит ул минем иң яраткан бәйрәмем! Ул көнне безнең авылга бөтен туганнар кайта, мәктәптә бергә укыган классташлар җыела, ерак җирләрдән авылдашлар кайта... Туган авыл үзенчә бер Мәккә кебек бит ул! Ә мин менә инде ничә ел шуны сагына сукмый яшим! Шул хәл дөрес була аламы соң инде?! Моны «дөрес» дип әйтергә, «шулай кирәк» дип әйтергә синең телең барамы соң?!

Әнә шул урында икенче «мин» бирелергә мәҗбүр була. Сүзсез кала. Ул дәшмәгәч, билгеле инде, мин дә сүз катмыйм.

Ә көймә әкрен генә ага бирә...

Уйлар да ипләп кенә үз җаена керә шикелле... Һәм алар янәдән Халисә исеме тирәсенә килеп чыга. Халисәгә барып тоташа.

... Моннан биш ел элек үзебезнең авыл Сабан туенда танышкан идек без аның белән.

Шул, шаян холыклы Рәйсә аркасында инде! Мин—каладан җәйге ялга дип кайткан ябь-яшь егет—ни өчендер берүзем генә калып, мәйдан әйләнеп йөргәндә, үзенең кунак кызы белән каршыга очрады да:

—Мин сине йөгерешкә киткән диеп торам тагы!—диеп, көлә-көлә сүз башлады ул.—Бер дә күзгә башка күренмисең ич!

Сөйли дә сөйли Рәйсә—миңа сүз кыстырырга да ирек куймый!

—Менә сине кунак кызы белән таныштырмакчы идем әле...—ди ул аннары, кырыендагы кызга таба ымлап.

Ә тегесе озын саргылт чәчләрен җилкәсенә үк төшереп салган, үзе мөләем елмаеп тора, үзе шундый да сөйкемле, шайтан! Мин бераз гына кызарып та киттем бугай әле ул чагында.

Моны, әлбәттә, Рәйсә дә чамалап алды инде, шуңадыр ахрысы, ул безне алга таба әйдәде:

—Йөри-йөри безнең аяклар да арып бетте инде,—диде ул, миңа кызгандыргыч карап.—Әйдә, әнә теге чыршы төбенә утырып торыйк әле әзрәк...

—Ярар! Бик хуп!—дим мин, үзем дә моңа шатланып.—Хәзер мин Фәйрүзәападан лимонад кына алып килим инде! Сезне сыйларга кирәк ич инде... Кунак кызы да булгач, бигрәк тә...

Үземә игътибар итүем кунак кызына бик ошый, күрәсең—ул тагын да матуррак итеп елмая. Күзләре дә нурланыбрак, очкынланыбрак киткән сыман тоела... Моны күргәч, мин дә дәртләнә төшәм—автомашина өстенә көйләнгән кибеткә таба чабам.

Сатучы Фәйрүзә апа миңа лимонадны, әлбәттә, чиратсыз гына бирә инде. Рәхмәт аңа! Юк, бүген минем бер кызга гашыйк булачагымны белеп түгел—ә каладан кайткан студент егет булганга күрә шулай эшли ул! Элегрәк, җәй көннәрендә, колхоз машинасында йөкче булып йөргәндә кибеткә бик күп әйберләр ташыган өчен тагын... Һәм, гомумән, бик тә

әйбәт, бик тә кече күңелле кеше ул безнең Фәйрүзә апа!

Мин очына-очына киләм билгеле кызлар янына. Ә килеп житсәм... Килеп житсәм! Без әйткән чыршы төбе бик матур табынга әйләнгән дә куйган, мин сиңа әйтим! Менә сиңа кызлар! Вәт, унган да инде үзләре! Хәтта кыздырылган тавык ите дә бар ич монда...

Күзләремне челт-челт йомгалап, аларны көлдерергә тырышып аз гына басып тордым да—ипләп кенә мин дә чүмәштем инде чыршы төбендәге бу ямьле табынга... Ямь-яшел үлән өстенә җәелгән эскәтердәге табын янына.

Кыскасы, бик тә шәп утырдык без ул көнне. Мин янадан барып бер шешә шәраб тә алып килдем әле... Аннан соң тел тагын да язылып китте инде. Мин дә Халисә белән танышып ук беттем дияргә була. Аның әтисе безнең авылдан икән, ул яшь чагында ук Чайковский шәһәренә киткән дә, Халисә әнә шунда туып үскән. Хәзер менә безнең авылга кайткалап йөриячәк икән инде Халисә... Әтисенең туган авылы аңа бик тә ошый икән...

Мин үз хыялымда әнә шулай үткән көннәрне янартып утырам, ә көймә тыныч кына бер көйгә ага бирә... Хәзер инде ишкәкләрне күтәреп ишәсе дә килми, чөнки төн буена диярлек ишә-ишә тәмам арыткан да, аннан соң болай да—агым көче белән генә дә—мин барыбер авылга таба якынаям ич инде...

Инде кояш та берәр карыш чамасы өскә күтәрелеп, әйбәт кенә җылытырга тотынды... Ул җылыткач, хәзер инде мине йокы да баса башлады—ни әйтсәң дә, мин бит әле бүген төнне йокламаган кеше. Баш төрткән дә юк ич әле минем менә бу төнне!

—Ярар, ни булса булды, әле минем байтак кына агасы бар!—дидем дә, көймәнең аркылы утыргычына сузылып торып яттым. Ул утыргыч билгеле кыска инде, көймә инлеге генә. Шуңа күрә минем аяклар бик тә мәзәк булып көймә кырыеннан асылынып чыгып тора... Әмма бу йокыга һич тә комачау итми икән—бик тиз арада онытылып та киткәнмен...

Шул арада төш тә күрә башладым—Ходайның хикмәте!

Имеш мин пароход белән кайтканмын авылга... әнә, текә яр башында Халисә мине каршы алырга килгән... Пароход яр буена да килеп житә, ләкин мин ни өчендер һаман ярга чыкмый торам... Шунда пароход сузып-сузып кычкырта башлый... Тагын-тагын кычкырта... Ә мин нишләптер баскан урыннан кузгала алмыймын. Гажәп! Бу эшкә бик тә аптырыйм—илереп Халисәгә кычкырмакчы булам. «Ярдәм ит!»—дияргә телим, әмма авыз ачылмый, тел әйләнми. Пароход инде кискен, кискен итеп кычкыра—бик тә сәер итеп, усал иттереп!

Һәм, бер мизгелдә, кемдер миңа китереп төрткәндәй тоела да, мин сикереп торам... Баксаң—көймә эчендә ич мин! Ә миннән унбиш метрлап арада зуп-зур пароход кычкыртыпмы-кычкырта!

—Бәт-тәч!—дим.—Минем өскә килә ич бу!

Ябыш тизрәк ишкәккә! Иш тизрәк янга таба!

Үч иткән сыман көймәсе дә авыр кыймылдый—андый чагында шулай ич ул, нәкъ киресе килеп чыга... Аннары гына, тиз-тиз ишә башлап, байтак гомер узгач кына—хәзер миңа һәр секунды бер ай тоела ич инде!—көймәмнең азмы-күпме читкә тайпылганын сизеп алдым... Мин пароход астында калмаячак идем инде!

Маңгайга тир бәреп чыкты, ул йөрәкнең ничек ярсып тибүен әйткән дә юк инде!

—Тәки исән калдыммыни?!!

Янымнан гына узып баручы тау хәтле ап-ак пароходка карый-карый үз-үземә әнә шулай дип кабатлыйм.

—Тәки исән калдыммыни?!!

Әмма сөенергә иртәрәк булып чыкты—хәзер миңа бик куәтле дулкын китереп бәрәчәк иде! Зиһенемне шул уй яшен сыман яндырып алды.

Нишләргә соң? Әлбәттә, мин монын жаен беләм белүен.

—Борыл тиз генә! Көймәңне дулкынга каршы куй!

Әйе, өлгермәсәм—бетәм мин! Менә шушы урында капланам мин!

—Ах, сабака!

Көймә мина тиз генә буйсыныргә теләми, шуңа күрә жан ачысы белән сүгенеп тә жибәрәм! Идел уртасында, шундый матур хыялга бирелеп кенә кайтып килгәндә, һич тә батасы килми ич инде. Килми!

Шуна күрә ике ишкәк белән берьюлы эшлим: берсен артка таба, икенчесен алга таба тартам—бер урында тиз генә борылу өчен кирәк бу мина! Жәһәт кенә борылу өчен!

Ләкин көймә зур, ул бик тә акрын кыймылдый...

Ә пароход дулкыннары инде килеп тә житте. Әнә мине тирбәтә дә башлады инде анын беренчеләре... Иң биеге, иң куәтлесе килеп кенә ята әлегә. Шуна хәтле өлгерәмме, юкмы??

—Булыш мина, Ходаем! Ярдәм ит бу бәндәңә!

Авылдагы иң зур өй биеклегендәге куәтле кара дулкынга кыеклап менеп китте минем көймә... Бер мизгел эчендә мин көймәм нием белән биек тау башында калдым! Иң биек, иң зур дулкын сыртында! Әнә шул мәгъруур да, гаять куркыныч та секунд әллә никадәр озак, бик тә-бик тә озак тоелды мина... Монда инде һични эшләп булмый! Ике ишкәгем дә һавага асылынып калды... Гүяки алар хәзер канатка әверелде! Әйтерсен лә хәзер мине авылга, Халисә янына көймә түгел, ә кош канатлары алып кайтырга тиеш!

Тешне кыскан көе, йөрәкне учка кыскан килеш—әнә шул олы дулкын сыртында күпме тора алдым, монысын бер Ходай үзе генә белә инде. Бер Тәңрегә генә мәгълүм бу хикмәт...

Әмма, ни гажәп диген: бераз авышлап булса да—әлеге дулкын өстеннән тәки исән-сау гына төшә алдым бит мин! Һәм шул чагында инде көймәмне дулкынга каршы куеп та өлгердем—аларны борын белән каршы алырлык итеп, аларны кисәрлек итеп!

Инде хәзер мина дулкын куркыныч түгел иде...

—Уф!—дидем шунда жаным-тәнемне бушатып.—Котылам бугай ич... Ходаем, коткарасың түгелме соң син мине?!!

Әнә шул чагында бу дөньянын никадәр гүзәл, нихәтле ямьле тоелганын белсәгез иде сез! Анда яшәүнең һәр секунды, һәрбер мизгеле—чиксез, чамасыз, әйтеп-аңлатып бетерә алмастай зур бәхет икән ич анын! Менә мондый кояшлы, аяз, тыныч жәйге көне инде бигрәк тә!

Минем көймәм хәзер йомшак, сабыр дулкыннар арасында тирбәлә. Жанымны жәһәннәмгә озата язган пароход инде күптән узып киткән... Хәзер мин нурлы, йомшак Идел өстендә берүзем, берьялгызым тирбәләм...

Уң як ярдагы биек наратларга карыйм. Бу яктагы текә, ташлы кыялар өстенә менеп басканнар да, алар бөтен дөньясына хужа булып алганнар сыман. Торышлары да шундый горур, шундый мәһабәт аларның—бөтен көрәшчеләрне жиңеп, батыр калган мәйдан пәһлеваны шикелле тоела бу таза наратлар, кояш нурыннан алтынсу кием кигән асыл затлар!

Ә текә яр үзе гүяки бер олуг жан иясенең киселгән ярасы сыман—кып-кызыл булып ачылып ята... Әйтерсең лә аннан әле һаман кан саркып ята... Кемдер килеп дәвалаганны, жылы кулы белән сыйпап иркәләгәнне, яратканны көтә гүяки бу ачык яралы ярлар... Һәм бу ярлар әле яңа гына була язган олы фажига ачысын да үзәгемә үтәрдәй итеп аңлатырга тырыша кебек. Бәхет белән фажиганең арасы ничек якын булуы бик яхшы аңлашыла сыман иде әнә шул кып-кызыл ярга һәм аның өстендәге мәгъруур, бәхетле наратларга багып торганда...

Бу як текә ярлы булгач, монда агым да әйбәт кенә иде. Хәзер инде куллар да ял иткән дияргә була, көймәгә ярдәм итәргә теләп ишеп тә аламын... бераз ишкәч, тагын яр башына, югарыга карыйм: шушындый кызыклы, кыргый урман баскан урыннардан бер үзем генә көймәдә баруыма чиксез горурланып та куям! Бүтән кем тагын шушылай итеп

бер ялгызы йөри ала соң әле,—димен...

—Их, текә ярлар! Текә ярлар!

Бу юлы инде көймәмнең уртасына ук торып басамын да югарыга карап чыдый, түзә алмыйча әнә шулай димен. Әйтерсең лә, мин бер төрле сәхнәгә чыгып басканмын. Гүяки ярлар, наратлар өстә түгел—ә мин үзем, адәм баласы—менә хәзер өстәмен һәм мин менә хәзер гүяки алар турында олуг бер нотык тотмакчы булам.

—Текә ярлы авыл шул безнең авылыбыз да... шуңа күрә үзебезнең табигатебез, холкыбыз да текә ярга охшагандыр инде безнең! Әнә шуңа күрә мин, командировкага килгән җирдә дә, әлеге шома кешеләр шикелле тыныч кына, ашап-эчеп кенә йөри алмаганмындыр инде... Эчтән сина омтылмыйча гына, эчтән ирекә сусамыйча гына түзә алмаганмындыр инде мин, текә яр! Сезнең сыман текә яр баласы булганга күрә әнә шундый табигатьле, шундый ирек сөючән холыклыдыр инде мин...

Әйе, шәһәр кызы Халисәне дә, су керергә нәкъ әнә шундый текә ярлы урынга алып килгән идем бит мин... Безнең аның белән беренче коену иде ул...

Әйе, ул көнне кичке Сабан туенда да өчәү бергә йөрдек без... Аннары мин аларны өйләренә хәтле озатып куйдым. Ә кереп китәр алдыннан иртәгә бергәләп су керергә сөйләштек.

Иртән йокыны тәмам туйдырып кына Рәйсәләргә киләм, ә ул миңа каршы ук чыккан—үзе исә әздән генә еламыйча тора, йөзе бөтенләй бозык моның.

—Әнәй җибәрмәй мине... Халисә белән икегез генә барыгыз инде...

Монысы минем өчен тагын да шәбрәк инде, билгеле—ләкин шулай да, Рәйсә дә кызганыч бит әле. Шуңа күрә мин тыштан гына булса да болай дим:

—Алайса бәлки иртәгә генә барырбыз...

—Юк, юк! Халисә анда бөтенләй җыенып ук беткән ич инде! Сине генә көтеп тора бит инде ул!

Рәйсә шулай диеп әйтеп бетердеме-юкмы, өр-яңа ап-ак такталардан ясалып, әле буялырга да өлгермәгән өйалдыннан Халисә күренде...

Аның яшелле-сарылы чәчәкләр төшкән җәйге җиңел сарафаны, иңнәренә чәчелеп яткан алтынсу сары чәчләре, башындагы челтәр-челтәр үрелгән аксыл эшләпәсе—менә боларның һәммәсе миңа җәйге болыннарда иркәләнеп очып йөри торган матур күбәләкне хәтерләтте. Дөнья гүзәллеген үзенә туплаган әнә шундый бер сихри күбәләк сыман иде ул Халисә! Әле җитмәсә, яланаяк бит әле! Минем белән оялчан гына исәнләшеп алды да—әнә шул яланаяк көе ишегалды чирәменә чыкты да басты ул! Һәм елмаеп, балкып, безгә карап тик тора бирә шул баскан җирендә...

Рәйсә нидер әйтә, нәрсәдер сөйли—ә минем өчен инде Халисәдән башка бүтән берни дә юк бу фани дөньяда! Мин бары тик аны гына күрәм, бары тик аны гына күзәтәм.

Шундый сихерләнгән хәлдә күпме тору да онытылган, Рәйсәнең әнисе өй эченнән ачык тәрәзә аша усал итеп кычкыргач кына, өнгә килдек без. Рәйсәне үзе кушкан эшне эшләргә ашыктыруы икән аның...

—Урам буйлап шушылай бармассың бит инде!

Әрли-әрли, үгетли-үгетли Халисәне аягына кияргә дә күндерделәр.

—Шәһәрдән исәр кыз кайткан икән дисеннәр тагын! Шул гына җитмәгән иде!

Ә безнең моның ише исәрлеккә ис тә китми. Рәхәтләнеп көләбез генә! Халисә дә миңа үзе янында рәхәт икәнен сизә, ахрысы, шуңа күрә ул да бәхетле, ул да гел елмаеп кына тора.

Мин Халисәне ераккарак—Иш буенын текә ярына алып бармакчы булам. Чөнки анда аулаграк та, суы да тирәнрәк, чистарак...

Ләкин Халисәнең үз уе да бар икән әле.

—Менә бу тыкрыктан төшик әле...—ди ул миңа, бераз киту белән, серле генә итеп.

Мин әле эшне аңлап житмим, аның кая барырга теләгәнен белмим. Бары тик сүзсез буйсынам гына. Аның белән булганда теләсә кайда да рәхәт, күңелле булыр шикелле тоела.

Аларның тыкрыгы да гел чирәм генә, ә ике якта талдан үргән читән—анысы да тоташтан алабута, кычыткан, эт эчәгесе белән уралып, тәмам яшел диварга әйләнгән, читән үзе күренми дә диярлек. Без Халисә белән бары тик әкиятләрдә генә була ала торган серле сукмактан, тылсымлы бер тыкрыктан барабыздыр шикелле...

Чыннан да, тылсымлы булып чыкты ул тыкрык! Аның беткән жирендә зур бер чирәмлек, бушлык икән, ә чүт кенә түбәндәрәк елга буе комлыгы башлана. Халисә әкрен генә атлап мине әнә шул комлыкка, аның текә яр белән тоташа торган урынына алып килде... Суга житә язып ук туктап калды.

—Бәләкәй чагында менә шушында уйный идек без Рәйсә белән..

Ул әнә шулай ди, ә мин исә «төш күрәмме соң әллә?» диеп, тәмам аптырап торам. Чөнки... Чөнки... Бу суның теге ягында безнең тыкрык бит! Без дә бәләкәй чагында үзебезнең әнә шул, каршы яктагы тыкрыктан төшеп, менә шушы тирәдә мәш килә идек бит!

—Тукта әле...—димен шунда, күз алдымда ерак балачакны яңартырга теләп.—Мин бит үзебезнең якның яр башыннан сезне күзәтеп утыра идем! Малай кешедә туган тәүге кызыксыну белән, ояла-ояла, сезгә соклана-соклана... Эчтән генә, күңел түреннән генә бик тә сөйләшергә, танышырга тели-тели, эмсенә-эмсенә, шуна бик тә омтыла-омтыла...

Бу сүзләрем Халисәне уйга, истәлеккә чумдыра кебек. Ул эндәшми. Ә бераздан аяк киемен сала да, тыгыз һәм тигез комга баса-баса су эченә үк кереп китә. Гүяки мине дә онытып, бик якындагы текә ярга таба атлый...

—Ә менә монда без өй ясап уйный идек... Яр балчыгын шомартып шуа идек...

Аның йөзендә уйчан, хисле, татлы елмаю... Ә баш очында текә яр карлыгачлары балаларын очарга өйрәтә, чыр-чу килә...

Ул урыннан китеп байтак кына ераклашкач та, ерактагы матур көннәр күз алдыннан китми... Менә хәзер Идел ярына карап барганда да мин ул текә яр буенда һаман Халисәне күрәм. Яр буе карлыгачлары гүя безнең үткән көннәр хатирәсен яңартып, әнә шул көнне без ишеткән ягымлы матур аһәңнәрне янадан ишеттерә. Алар гүяки ул көннәр тавышын янадан яңгырата.

Әйе... Иш суының текә яры янында су кергәндә дә безнең баш очында әнә шул яр карлыгачлары—керәшәләр уйнап йөреде шул. Халисә үзенең искиткеч зифа, матур буе белән балкып әнә шул яр буенда басып торганда мин су эчендә килеш аңа карап ничек соклана идем бит. Һәм бу соклануымны яшереп-нитеп тормыйча, үзенә дә әйтә идем мин аның!

—Күз тидереп бетерәсең инде син миңа!—ди иде ул, үзенең чибәр, матур булу бәхетен шундый ләззәтле итеп татый-татый, минем сүзләремнең ихлас икәнлеген белгәнгә күрә тагын да ныграк сөенә-сөенә, күк йөзендәге әнә шул кояш шикелле яшәү, дөнья һәм шул дөньяны күрү, тою, анда гомер кичерү бәхетен—ин олы бәхетне тулы итеп кичерә-кичерә.

Бүген дә әнә шундый матур көн шул...

Менә инде минем көймә Иш белән Иделнең кушылган жиренә дә килеп житте... Борылып аз гына керәсең дә—анда инде безнең авыл күренә дә башлый.

—Халисә йокыдан уяндымы икән инде?

Кулымда сәгать юк, шуна күрә кояшка карап чамаларга тырышам. Ә ул инде байтак кына күтәрелгән, димәк, уннар чамасы бардыр инде, дим... Кунак кызы булса да, Халисә дә аяк өстендәдер инде... Нишләп йөри икән? Ә бөтенләй өйдә дә булмаса?! Күпме жирдән чиләнә-чиләнә кайтуын әрәмгә чыга бит.

—Ниһаять!

Арыган гәүдәмне көчкә күтәреп алып, ниһаять беренче мәртәбә ярга аяк басам! Халисәләрнең тыкрык башы инде бу... Ул миңа күрсәткән комлык бу... Чыгамын да, шундук комга егылам. Еллар буена жир йөзе күрмичә океан гизгән диңгезче сыман комга чалкан ятамын да, бөтен гәүдәмне таратып ташлап, күзләремне йомам.

—Абый...—дигән йомшак кына тавышка күземне ачсам, каршымда бер малай. Аптырап, нишләргә белмичә, миңа карап каткан, мескен бала!

Торып утырдым инде, бик авырдан гына булса да.

—Үскәнем,—дим мин монда, тәмле теллерәк булырга бик тырыша-тырыша.—Менә шушы тыкрыктан менгәч, Рәйсә апаннар тора бит әле... Әнә шул Рәйсә апаннарда шәһәрдән кайткан кунак кызы булырга тиеш. Шуны гына чакырып төш әле, ә!

Теге малай чаба-чаба китте, ә мин үз кыяфәтемне уйлап, көләргә дә, еларга да белмичә—утырам һаман шунда ком өстендә. Көймәм дә шунда гына, борыны белән аз гына комга кертеп куелган килеш.

—Тукта!—дим бераздан.—Болай утыру ярамый бит! Аякка басарга кирәк... Нык арыткан булса да, ул килгәндә аягүрә булырга!

Ә Халисә инде тыкрыктан төшкән дә, миңа таба карап тора икән.

Аптыравы, аңламавы, нык гажәпләнүе, ахрысы, бу...

—Мин бу, Халисә...—дип тавыш бирәм, үз тавышымны үзем дә танымыйча.—Курыкма, чынлап та мин бу!

Ул һаман дәшми әле. Дөресрәге аңышып житә алмый әле ул, шуңа күрә үзен-үзе кулга алып, сүз эндәшерлек хәлдә түгел әле ул!

Ләкин шулай да миңа таба якыная үзе... Һәм менә Халисә, ниһаять, минем каршымда ук басып тора. Әмма үзе елмаймый да, көлми дә.

—Исәнме, Халисә!—дип аның кулын үз кулыма алам. Ел буена тоелмаган жылылык, кайнар дулкынны яңадан тоям... Шунда гына ул жанланып китә, телгә килә.

—Ничек монда син?!!—ди ул, күзләрен зур итеп ачып.—Син каян килеп чыктың?!

Ә мин сүзсез генә көймәгә ымлыйм... Халисә һаман берни дә аңламый төсле.

—Кем көймәсе соң бу?—ди.—Кичә монда юк иде бит ул... Кичә мин монда йөредем бит. Күренмәде ич ул...

—Шулайдыр, Халисә...—димен, сабыр гына.—Мин сиңа бераздан барысын да сөйләрмен, аңлатырмын... Тик бераздан, яме! Ә хәзер син миңа, зинһар, кәгазь белән карандаш алып төш... Мин монда торам.

Шулай дидем дә комга барып утырдым.

Халисә нәрсәдер әйтмәкче дә иде бугай, ләкин әллә инде минем бик арыган кыяфәт аны кызгандырды, әллә кискенрәк итеп әйтелгән сүзем тәэсир итте—кызый, кызу-кызу атлап, өйләренә таба менеп китте.

Минем күңелдә инде күптән телеграмма тексты әзер. Тегендә калган иптәшләр алачак телеграмма мондый булачак:

—Көймәне мин алып киттем. Ике көннән килеп житәм!

Шул сүзләрне һәм адресны язып, Халисәне почтага жибәрәм.

Чөнки бүтәнчә тынычлана алмыйм. Тегеләр мине югалттылар ич инде. Алар хәзер борчыла бит инде!

Бу хикәятне сөйләп утыручы өлкән лейтенант Булатовның шулай диеп әйтеп бетерүе генә булды:

—Да-а... шулай дисең, ә!.. Тәки акыл дигән нәрсә уянды дисең!—дип, үз эчендәге ярсуын көч-хәл белән тыя-тыя, капитан Федотов телгә килде.—Күпме кешенең төн йокысын качырган да бу адәм, төне буе үзен эзләп йөрергә мәжбүр иткән дә—бер тәүлеккә якын вакыт узгачтын гына, кеше күпме изалангач кына—ниһаять акылына килгән ул! Ниһаять, аның зиһене ачылып киткән! Вот, молодец, ә!!

Беразга тукталып торды Федотов, әмма ачуы моның белән генә басылмады, ахрысы, тагын дәвам итте:

—Беләсенме, ул ахмаклыгың өчен мин сине менә хәзер тукмап ташларга әзер! Менә шушы йодрыкларым белән!

Аның зур йонлач куллары өскә күтәрелде, моны күреп барысы да тын калды. Чөнки бу капитанның холкы бик тиз алышынучан, белеп булмый—юктан гына гауга чыгара күрмәсен тагы!

—Тукта, Иван Данилыч—син алай бик кызма әле!

Монысы инде лейтенант Сериковның сүзгә кушылуы иде.

—Ә менә мин, киресенчә, аны хуплап утырдым... Хәтта ул миңа теге... теге кем әле... Мцырины хәтерләтте! Лермонтовның шундый бер поэмасы бар бит әле—монастырьны ташлап качкан яшь бер монах турында... Аның ничек иреккә сусаган булуы турында... Мәктәп дәреслегендә дә бар инде ул, сез аны барыгыз да беләү... Өлкән лейтенант Булатовның яшь чагында булган бу егетлеген дә мин әнә шуна охшатам. Тегеләр арасында—үтә житди агайлар янында—тәмам изелгән бит инде ул! Житмәсә бит, әле аны сөйгән кызы да көтә!.. Шулар өстәвенә, мәжлес булгач, анда утырганда, шагыйрьләр әйтмешли, «арыслан тотарлык кына» утлы суны да капкан бит әле ул! Билгеле—йөрәк жилкенә, йөрәк талпына инде андый чагында—ничек түзмәк кирәк! Ул ирек, киңлек сорый—хәрәкәт таләп итә! Аны акыл йөгәне белән генә тыеп торып буламыни?!

Ләкин капитан Федотов бирешергә теләмәде:

—Тьфү! Бусы да шуны сукалый!—дип, аты-юлы белән каты итеп сүгенде дә, өстенә бушлатын салып, тышка ук чыгып китте.

Кемгә нәрсә диген, өченче берәүне исә бу хикәятнең ахыры кызыксындыра икән:

—Ә теге көймәне... кирегә ничек итеп алып бара алдың соң? Агымга каршы ишеп бара алмыйсың ич инде син!

Монысына каршы инде Булатов әлләни баш ватып тормады:

—Моторлы көймә ялладым инде, малай!—диде.—Анысына бераз чыгым булды инде... Бәхилләтергә туры килде.

Барысы да өстәл яныннан кузгалды, тайга аланына чыгып тәмәке тартырга жыенды.

—Әмма мин үзем моңа үкенмим!—диде Булатов, алар белән бергә чыга-чыга.—Юк, һич тә үкенмим мин яшьлегемдә булган бу вакыйгага өчен!

Сүзсез генә тәмәке тарталар...

Ә кышкы салкын, караңгы тайга өстендә моннан ике-өч көн элек кенә туган шундый чиста яңа ай тора. Өлкән лейтенант Булатовның әлеге хикәятеннән соң күк йөзендәге әнә шул алтын ай да сихри бер көймә сыман күренә... Һәм ул көймә аларны хыялда гына булса да янадан яшьлек иленә, ихлас һәм көчле хисләр иленә алып барыр кебек тоела...

## Таныш бакчада

—Мин шундый бер әфәндене беләм...—дип үзенең сүзен әкрен генә башлап китте икенче бер кичне өлкән лейтенант Булатов.—Сәеррәк кеше инде ул... Гажәбрәк тип...

Менә хәзер, биредә яшәп ятканда да, аның турында еш кына уйланамын. Ул минем күз алдыма да гел диярлек килә... Кайчакларда, бигрәк тә үзем генә калган вакытларда, онытылып, аның тормышын кино караган шикелле күзәтеп утырам... Әйе, әйе—мин аны бик нык аңлыйм кебек тә: хәтта бөтен уй-кичерешләрен дә тоеп торам сыман мин аның!

... Менә Ул үзенең өеннән ерак булмаган таныш бакчасында йөри. Әллә кайларга кереп киткән борылмалы сукмаклардан, туп-туры сузылган

матур аллеялардан үтә ул... Чынга охшатып (ләкин ярларын таш белән катырып!) ясалган бәләкәй күлләргә килеп чыга... Аларга бик озаклап-озаклап карап тора... Андый чакларда эченнән генә нәрсәдер уйлыймы ул, әллә инде бөтен дөньясын онытып болай гына—кайсы берәүләр әйтмешли, «табигатьтән көч, энергия алу өчен» генә—шулай тукталып торамы—йөзенә, чыраена багып кына анысын һич кенә дә белермен димә!

Шулай байтак кына юангач, ул бакчаның аулак урыннарын калдырып, үзәк аллеяга чыга... «Инде эңгер дә төшеп килә икән, әкренләп кайтырга кирәктер...»,—диеп уйлый, ахрысы. Ләкин үзе адымнарын кызулатмый, моңарчы ничек килгән булса шундый ук ипле, тигез адымнар белән капкага таба юнәлә.

Үзәк аллея буйлап утыртылган биек-биек тупыллар янынннан үткәндә аның төз вә озын гәүдәсе бик тә бәләкәйләнеп кала, куерып килгән кичке эңгер гүяки аны бер бәләкәй шәүләгә генә әйләндерә...

Ул шулай тып-тын гына атлаганда кинәт кенә бакчаны бер ир-ат тавышы яңгырата:

—Зилә!

Тавышының катгыйлыгына караганда, мөгаен, үзенең бәләкәй кызын чакыра бу ир-ат... Ләкин тегесе ишетми, ахрысы, шуна күрә ир каты итеп, кат-кат кычкыра башлый: «Зилә! Зилә!»

Безнең әфәндебезнең башта бу тавышка әлләни исе китми, эченнән генә: «Шуның хәтле дөнья куптармасаң»,—диюдән узмый ул. Үз көенә баруын дәвам итә.

Әмма бу әфәнде байтак кына ераклашса да әлеге тавыш һаман тынмады—кабатланды да кабатланды. Мондый гайре табигый хәл әфәндене сәерсендерде, чөнки бүтән кичләрдә бакча аны тыныч кына озатып кала иде. Тып-тын гына... Аннан соң, ул бакчаны үзе ташлап киткәч тә шулай тыныч кала дип, бүтән беркем дә аңлый алмаган серле караңгылыкка чумып кала дип уйларга тели иде... Әнә шундый ышаныч аңа ничектер бер рәхәтлек бирә кебек иде. Бакча гүя аны озату белән үз эченә йомыла да, икенче көнне, ул килгәч кенә уяна, ачыла сыман иде... Алар бер-берсенә нindидер бер сердәш, ихлас дус кебек иде.

Ә менә бүген алай килеп чыкмады. Аның кадерле, бик тә үз күргән бакчасында кичтән бер ят тавыш яңгырап калды...

Тукта әле! Хәзер дә ишетелә түгелме соң әле теге тавыш?

Бакчадан чыгып, инде әллә нихәтле ара үткәчтәме?

Һаман нинди бетмәгән «Зилә» инде ул...

«Зилә... Зилә...»

Әллә... Әллә бераз таныш та инде бу?... Чынлап та, ничектер таныш исем кебек тоела бит әле бу...

Яисә нәрсәдер кабатлана гынамы? Кайчак шулай, элек булып узган хәл-әхвәлләр яңадан очраштыра бит... Ә ныклап уйласаң, аларның кабатлануы һич кенә дә мөмкин түгел икәненә төшенәсең.

Зилә... Бу исемнең нәрсәсе таныш булсын соң аңа? Ул бит бөтенләй яшьләр исеме дияргә була. Соңгы елларда гына күренә башлаган исем...

Ә шулай да ул исем аның колак төбендә һаман яңгырый бирә. Хәзер инде аны үз тавышы әйтә шикелле, бу исемне ул үзе кабатлый башлаган сыман.

«Менә сиңа кирәк булса... Менә сиңа яңа таныш!»—дип, үзалдына елмаерга тырышты ул. Ләкин... Ләкин аның елмаю чаткылары йөзенә чыгарга өлгерә алмады, ул моңа житешә алмый калды, авызы шундук:

—Зилә!—дип кычкырып жибәрде.—Зилә—Тәнзилә! Менә кем икән син! Менә син агай! Тәнзиләне искә төшерә алма инде!

«Әлбәттә, минем үз тавышым кабатлаган Зилә-Тәнзилә исемен... Күп еллар үткәч очраклы рәвештә генә табып алуына сөенә-сөенә кабатлаган ул аны».

... Бүген кич ул үзенең билгеләнгән сәгатендә йокыга китә алмады.

Иярләнгән тәртип, режим бозылды, күзгә йокы килмәде. Иң мөһиме—аның күптәнге дусты: тынычлык калдырып китте. Ә аның урынына бүлмәгә кунакка күптән күренмәгән тынгысыз кунак—нәрсәгәдер ризасызлык килде...

Тукта әле... Шул бер исем аның тормышының җаен шуның хәтле боза алдымы?

Әйе, әнә шундый беркем дә уйламаган, көтмәгән хәлләр дә килеп чыга икән шул ул яши торгач... Килеп чыгалар икән дә, сине бик тиз генә арада танымаслык итеп үзгәртеп тә куялар икән алар! Бөтен барлыгыңны—үткәнеңне, бүгенгеңне бергә катнаштырып, барысын бергә актарып аталар, һәммәсенең астын-өскә китерәләр икән алар!

Ул кадәрге эчке үзгәрешкә бәлки әлеге исем генә дә сәбәпче булмагандыр? Бәлки аның соңгы еллардагы тормышында моның сәбәпләре күп җыелганнардыр да, менә шулай, бер җае чыккач, алар барысы бергә үз сүзен әйтергә тели торганнардыр?!

Ничек булса да булды—төнлә ул рәтләп йоклый алмады. Ләкин шулай да, урынында әйләнә-тулгана ятса да, барыбер гадәттәге тору сәгате җиткәнче түзде. Исәбе—бүген инде нервыларга бик үк юл куймау, шулай итеп әкренләп кенә элеккеге тынычлыкка, рәхәтлеккә кайтырга теләү иде.

Әмма адәм баласын, тәненнән җаны чыкканчыга кадәр, табышмак түгел дип кем әйтә ала?! Аның белән дә шулай булды: көн саен гадәтенчә бакчада йөреп керү вакыты җиткән иде—шул чагында башына үзе дә шаккатарлык фикер килде:

—Барырга! Аны беренче мәртәбә күргән, әнә шул урынга барырга! Кая, ничек барырга—монысын инде ул бик яхшы белә.

Һәм ул шундый кискен карарга килә алуына үзе дә гаҗәпләнә-гаҗәпләнә җыена башлады... Җыену дигәне дә инде байтак еллар буе кулга тотылмаган зур портфелен тартып чыгарып, аңа бераз азык-төлек салу, өскә шулай ук күптәннән киелмәгән җиңелчә киемнәр эләктерү һәм үзе өйдә югында ул-бу килеп  чыкмасын өчен бүлмәне кат-кат күздән кичерү иде.

Бу эшләрнең һәммәсен башкарган вакытта әгәр дә аның кыяфәтен, йөзенең җитдиләгән күрүче булса, мөгаен: «Бик тә ерак юлга җыена, ахрысы бу»,—дип, аңа хәерле сәфәр теләр, «исән-сау әйләнеп кайт» дип әйтер иде.

Әйе, ул бүген гадәттәгедән дә җитдирәк шул... Бөтен игътибарын һәм дикъкатен бер ноктага туплаган ул. Һәм... Һәм, әле нәрсәгәдер соңару, җитешми калу куркынычы янап торгандай, ашыга да ул.

Дөрес, ашыга ул!

Күңеленә кичә килеп кергән ташкын бүген аны менә шулай сәфәргә кузгатты. Ә күңеле белән инде ул күптәннән юлда... Шуңа күрә бу таш диварлар арасындагы таш бүлмәдән гәүдәсен дә тизрәк алып чыгып китәргә тели ул... Менә хәзер, уйлаган чагында, тизрәк чыгып китә алмаса, бөтен барлыгын биләп алган әлеге эчке ташкын иркенә буйсынмаса—бүтән беркайчан да аның моңа кыюлыгы җитмәс шикелле. Чөнки инде аның күнегеп беткән, тәмам иярләнелгән тормыш кысалары да менә шушы таш диварлар шикелле үк каты һәм нык иде.

Баскычтан төшеп урамга чыккач, ул үзен шушындый җиңелчә киемдә күрүләреннән курыккан сыман кызу-кызу атлап китте. Торган йортыннан байтак ераклашкач кына үз-үзен тыя төшеп, адымнарын бераз акрынайтты. Нindидер бер зур эш эшләгән кебек, җиңел сулап та куйды әле.

Әйе, ул үзенең күптән, бик тә бик тә күптән булмаган җиренә бара... Балачагы һәм яшьлеге үткән урынга—үзләренең элеккеге дачаларына бара ул!

Юк, юлы әлләни ерак та түгел аның. Автобуска утырасын да бер сәгать чамасы вакыт узуга инде килеп тә җиткән буласың.

Ләкин безнең бу әфәндебез өчен менә хәзер, менә бүген алда торган юл—бик ерак юл иде шул... Менә бүген ул үзенең бөтен гомер йомгагын кирегә сүтә кебек... Кичәге көненнән башлап ул янадан еракта калган әлеге матур җәйгә кайта шикелле.

Автобус шәһәрне чыккач, урман эчләтеп байтак кына барды да, «инде арыдым, бераз ял итеп алыйм», дигәндәй, асфальт юлның бер кырыена сыенып туктады. Шактый гына кеше төште. Шулай булмыйча—шәһәр тирәсендәге иң ямьле җир ләбаса бу! Шуңа күрә барысы да монда килә, шушында ял итәргә тели.

Ә бераздан ул тукталышта үзе генә торып калды. Халык таралып бетте, автобус та китеп барды... Аның каршысында хәзер урман гына.

Әйе, шул ук мәгърур наратлар... Аларга карагач, синең дә зуррак буласың, югарырак күтәреләсең килә башлый. Вак-вак бакыр тәңкәләргә төренгән бу матур зифа сыннар берәүне дә битараф калдырмыйдыр мөгаен.

Әнә, наратлар арасыннан эчкәрәк кереп киткән бер юл да бар.

Ул үзенә күптән таныш шушы юл буйлап китте.

Ә инде дачаларга җитәрәк нәрсәдер уйлап, ян сукмакка борылды... Әйе, аңлашылды—ул ни өчен шулай эшләгәнен аңлап алды: менә хәзер килеп җитәчәк бик кадерле урыннар белән болай кисәк кенә, туп-туры килеп кереп кенә, очрашасы килми иде аның. Ул аларны әкренләп, азлап-азлап әзерләнә-әзерләнә, бу татлы очрашуга күнеле, йөрәге белән әзер булгач кына күрергә тели иде... Дөрес, ул бирегә нәкъ менә шушы урыннарны күрү нияте белән килде, шул максат ашыктырды аны... Ләкин, юк—ашыгыч кына ярамый шул... Алай ордым-бәрдем генә кагыла торган нәрсә түгел шул ул истәлекләр—бу урынга бәйле хатирәләр...

Шуңа күрә ул үзенең элеккеге дачасына бөтенләй икенче яктан, аулаграк сукмактан якынайды.

Әйе, ул бәләкәй вакытта салынып, аның яшьлеге үтеп барган елларда үзләренең ерак бер туганнарына сатылган бу дача нык кына искергән, таушалган инде... Әмма, шулай булса да, ул әлләни үзгәрмәгән—аңа кеше кулы тимәгән сыман, ул менә хәзер дә нәкъ элеккечә диярлек тора... Хәтта күптән узып киткән әлеге матур җәйне дә кайтара алырдыр сыман ул.

Дача өе, әлбәттә, бикле булачак иде, шуңа күрә ул ишек янына барып та тормады—туп-туры күрше Миңнегали абзыйларга узды. Чөнки элек үзләре анда-монда китә калсалар, өйләре ачкычын шуларда калдыра иделәр. Хәзер генә бик сирәк очраша башладылар, монда яшәгәндә бу ике гаилә бер-берсеннән чыгып та тормый шикелле иде.

Миңнегали абзыйның карчыгы үзе генә иде. Ул аны бик тиз таныды, шунда ук чәен дә куеп җибәрде. Үзе берөзлексез: «Менә Ходайның бирмеше...» дип кабатлады. Аның бу сүзе иске танышлары күренүгә ихлас сөенүгә дә, көтмәгәндә килеп кергән кешегә гаҗәпләнү хисенә дә һәм үзе өчен нигәдер кыенсыну тойгысына да охшаган иде.

—Алар быел диңгезгә китте шул...—диде ул бер-бер гаебе бар кеше төсле сузыбрак кына.—Рәт барында йөреп калыйк, диләрдер инде...

Күңеле тынычсыз иде, әллә нинди бер ашкынулы иде—шуңа күрә хөрмәт йөзеннән бер генә чынаяк чәй эчте дә кузгалды.

Урыныннан торгач, Миңнегали абзыйның карчыгына шактый таркау, буталчык сүзләр белән биредә бер-икене кунарга нияте барлыгын әйтте. Гәрчә шәһәр кешесе өчен бу эшнең, әллә ни ояты булмаса да, ни өчендер уңайсызланды, кыенсынды... Ә бу кунакның килүен нәрсәгә юрарга да белмичә аптырап утырган карчык исә ачкыч кирәклеген аңлау белән:

—Бирәм, бирәм!.. Сиңа бирмимме соң...—дип шундук икенче бүлмәгә чыгып та китте.

Аны озата да керде әле ул. Бу йортка бөтенләй аяк басмаган кешегә сөйләгәндәй тегесен, монысын күрсәтте, үзенчә барысын аңлаткан булды. Ә кунак исә инде күптәннән бирле аны тыңламый, ул инде байтактан бирле үзенең эчендәге, хыялындагы башка дөньяга киткән иде.

Үзе генә калгач, ул иркенләп, рәхәтләнеп диванга ауды.

Моннан күп еллар элек тә нәкъ менә шушы почмакта, мич янына китереп үк куелган икенче бер шундый ук диванда, уйланып, хыялланып сәгатьләр буена ята торган иде ул. Бу анын биредәге иң яраткан, күңеленә иң хуш килгән почмагы иде. Күп еллар элек нәкъ менә шушында тәү мәртәбә диярлек канат кагынган, талпынган җан бирегә килеп керү белән үк үз оясын бик тиз танып алды.

Кайчандыр ап-ак булган кәгазь ябыштырылган түшәмдә күзгә көчле янгырлар калдырган чуалчык бизәкләргә текәлеп диванда озак ятты ул... Күзләре инде күптән аларны күрми башлагач та, инде бөтенләй игътибары булмаса да—һаман шулай карап ятты ул. Әйтерсең лә, әнә шул урында түшәм бер-бер могҗиза белән ачылып китәчәк тә, аннан җинел генә күтәрелеп икенче бер дөньяга үтеп булачак.

Күпмедер шулай яткач, ул йокыга да китте. Күрәсең көндезге черем итеп алу вакыты да житкән булгандыр...

Йокыдан тиз уянды, шундук торып та басты. Башы чип-чиста, зиһене саф, кәефе әйбәт иде. Ә күңеле, ә күңеле ниндидер бер мөһим очрашуга барасы бар сыман—ашыга, ашкына...

Ә бәлки, чынлап та, очрашудыр бу?

Шулай бугай шул... Дөрестән дә очрашу бугай... Тик менә Анын беләнме? Ул бүген Анын белән очрашырга дип килдеме бирегә? Нәрсәгә дип шулай бирегә бик тә тартты анын күңеле?

Ул өйдән чыгып, веранда баскычыннан җиргә басарга да өлгермичә—тукталып калды. Ишекне ачу белән аны үзенең рәхәт эсселегенә чумдырган гаҗәеп мәрхәмәтле кояш, каршыда һәм бөтен тирә-юньдә шул кояш назлавынын яшел дәвамы булып җәелеп яткан бөтен табигать, анын һәр куагы, агачы, күзгә чалынган барча кош-корты, менә шушы гүзәл дөньяга бик табигый рәвештә кереп утырган дача йортлары—һәммәсе дә менә хәзер, менә бу минутларда бары тик аны гына иркәли, анын өчен генә төзелгән, анын өчен генә яратылган кебек иде! Юк, алай гына да түгелдер—алар һәр кешедә, һәрбер җан иясендә әнә шундый мәрхәмәтле тойгы калдыра алырдай җылыга, нурга бай иделәр!

Әйе, бу—шул ук кояш!

Әйе, бу—шул ук ямьле табигать!

Дөньянын оҗмахы санала алырдай шул ук гүзәл урын!

Баскыч төбеннән үк диярлек башланып киткән шул ук борылмалы сукмак буйлап бара ул... Бара, ләкин бер аерма бар... әлеге җәйдә ул бу сукмактан кояшка сокланып, шул бәхеттән кинәнеп һәм бүтән бер генә нәрсәне дә башына китермичә узган булса, шушы сукмакнын капкага килеп кагылган икенче очында Аны очратасын әз генә дә сизенә алмаган булса—бу юлы инде ул үзенә берьюлы ике кояш тәэсирен сизә кебек. Күктәге һәм үз күнелендәге әнә шул ике кояшнын җылысын тоеп, бу кеше үзенен үткәнендәге иң матур көненә бара...

Менә ул капка.

Менә анын кырыендагы кечкенә генә агач эскәмия.

Ерактагы ул матур җәй көнендә эскәмиядә утыручы кызларны шактый арадан ук искәреп алса да, якынлашкач берсен генә таныган иде ул. Бәләкәй арба тирбәтеп утырганын гына. Биредә ул аны көн саен диярлек күрә һәм исәнләшеп йөри иде. Ә менә янәшәсендә утырган кызны ул танымады, хәер башта аңа артык игътибар да итмәде кебек.

Чөнки дөньянын ул көнге матурлыгына соклана-соклана килеп ул тәмам онытылган, тәмам туарылган иде. Ул чак анын җаны әллә кайда югарыда, менә шушы агач-куакларнын, кош-кортларнын, бөтен табигатьнен бер серле үзәге белән барып тоташкан иде. Әлеге минутларда ул әнә шул агачлар, куаклар сымаграк—югарыдагы мәрхәмәтле кояшнын назын, җылысын гына тоя, ә кешегә хас булырдай һәммә нәрсәдән азат иде.

Шуңа күрә үз алдында кешеләр күргәч, ул ризасызлыкка охшаган

тойгы да кичереп алды әле. Кояш рәхәтлегеннән бер канәгатьсезлек тә.

Эскәмиядәгеләр янына житәрәк, ул тиз генә исәнләшеп алды. Һәм менә шушы арада—бер-ике сүз алышкан вакыт эчендә—ул үзенә тутырып карап торган ике коңгырт күзне күрде. Әйе, әйе—чибәр йөз дә түгел, матур кашлар һәм сөйкемле борын да түгел—бары тик зур булып ачылган ике коңгырт күз генә. Аны үзләренә караткан, үзенә таба суырган ике төпсез тирәнлек кенә.

Юк, аларны күргәчтен дә, тукталып кала алмады ул. Бара бирде.

Ләкин менә хәзер—әлеге күзләрне яңадан менә шушында күрә алса—тукталып озак, бик тә озак карап торыр иде ул. Аларның үзенә гомер буена житәрлек бәхет бирүләрен белер иде. Күпләрнең, бик күпләрнең үз язмышлары буенча әллә ничаклы юл үтеп тә, андый күзләрне таба алмауларын исенә төшерә-төшерә, андый тирән күзләрнең кеше өчен никадәр кадерле икәнен секундлар саен ныграк анлый-анлый басып торыр иде ул әлеге коңгырт күзләр каршысында.

Әмма ул чагында, әмма ул жәйдә, аны кочагына алган табигатьнең үзе кебек уйсыз, тыныч һәм пошынмаучан иде шул ул.

Тәнзилә аның дөньясына әнә шулай килеп керде.

Моңарчы аны очратмаган гына икән... Ул биредә, апаларында, инде атнага якын яшәп, ял итеп ята икән ич... Болары бер-ике көннән соң—алар икенче мәртәбә очрашкач билгеле булды...

Ә очрашу үзе шулай килеп чыкты.

Аның гөмбәдән кайтып килеше иде. Ап-ак каеннарны аралап, борыла-сарыла сузылган тар гына урман юлыннан ул әкренләп дачаларга якынлаша иде. Кулында бер дә үзеннән калдырмый йөртә торган, хәзер инде кибеп, жиңеләеп беткән төз юкә таяк... Ә икенче кулда исә шактый гына гөмбә салынган иске кәрзин. Башында—киң читле матур салам эшләпә... Киноларда күренгән чит ил кешеләренә охшарга тырышып, ул көнне юри шулай киенгән иде ул...

Нәкъ менә шул көнне инде—әлеге ап-ак каенлы юлда ана Тәнзилә очрады. Кечерәк буйлы бер кызны да иярткән иде ул үзенә. Урман юлына йөреп килергә чыккан булганнар, ахрысы.

Монда бер дә кызлар очратып күнекмәгәнгә күрә ул башта бик аптырап калды. Күзләренә ышаныргa-ышанмаска белмичәрәк торды... Тик тагын бераз якыная төшкәч кенә кичәге кыз икәнен танып алды һәм... һәм каушап та китте.

Ләкин өчәү булганда жиңелрәк күрәсең... Биредә дә башта кызларның берсе әйтеп куйды:

—Менә гөмбәче дә очраттык бит әле...

Икенчесе елмая төшеп дәвам итте:

—Таныш гөмбәчегә охшаган әле ул!

Моннан соң инде бик каушаган кешегә дә сүз башлау кыен түгел иде. Кызлар үзләре юл сабып бирделәр ич! Ләкин ул барыбер, кызларны шаккатырып, көтелмәгән нәрсә әйтте:

—Сезнең күзләрне бер күргәч онытып булмый икән...—диде ул, коңгырт күзле кызга карап.

Ә Тәнзилә ул чагында моны шаяруга борды:

—Әллә шулай ук?!—дигән булды, рәхәтләнеп көлә-көлә.

Сүз ялганып китте... Әкренләп танышылды шулай...

Тәнзиләнең шушы шәһәр кызы булуын, хәзер институтта, чит телләр факультетында укуын белде ул... Быел жәй беркая да бармаска, шушы шәһәр тирәсендә генә ял итәргә уйлаган икән Тәнзилә... Ана биредәге урман, якындагы зур-зур күлләр бик тә, бик тә ошый икән... Бу хакта ул ничектер, сәхнәләрдә ишетелгәнчә, дәртләнеп, кайнарланып сөйләде. Вакыт-вакыт сүзен бүлде дә зәңгәр күккә үк ашкан ак каен очларына текәлде... Аларның ап-ак кәүсәләре буйлап аның күз карашы югарыга таба бик тә еш күтәрелде—әйтерсең лә шулай канатланып очып китәргә үк теләде ул.

Каеннар янында басып торган шундый да зифа буйлы Тәнзилә ул чагында ана бөек рәссамнарның атаклы картиналарыннан күчкән кыз сыман тоела иде.

Ә Тәнзилә килгәнче нишләптер каеннарга бу хәтле игътибар биргәне дә булмады шикелле анын... Чынлап та шулай идемени соң?

Булгандыр шул... Бәлки чыннан да шулай булгандыр...

Чөнки күнелен битараф чагында, ул хисләнмәгән, дулкынланмаган вакытта, табигатьне дә тирәннән тоеп, анлап булмый сыман бит ул... Аның белән нечкә ялгану, тоташу килеп чыкмый шикелле үз күнелен салкын чагында.

Әйе, ул җәйне анын күнел күзе ачылып киткән шикелле булды. Шуннан сон инде ул үз тирә-юнендәге гаҗәеп гүзәл дөньяны күрде. Үзенен бихисап күп җан ияләре, матурлык ияләре белән чолганып алынган булуын күрде... Болардан башка үз яшәешенен һич кенә дә тулы һәм матур була алмаячагына төшенде.

Ләкин анын ин зур табышы Тәнзилә иде.

Ул җәйдә Тәнзиләнен ана нихәтле бәхет, шатлык алып килүен мена хәзер сүз белән генә анлатып бетерү дә читен шикелле. Анын белән танышканнан сон һәр көне кояшлы булды, алар һәр көнне диярлек бергә үткәрделәр бит. Табигать балаларына әверелеп, иртәдән кичкә хәтле урманда, су буйларында, серле тау битләрендә һәм тирән чокырларда йөрделәр. Үзләре тапкан әнә шул гүзәл дөньяга, әнә шул көннәргә алар чиксез куандылар, аны—ямьле дөньяны үзләренен шат һәм матур күнелләре белән тагын да кинәйттеләр, тагын да зурайттылар.

Юк, ул җәйнен бер генә көне дә болытлы булмады шикелле. Сонгы көненә хәтле тоташ кояш балкыды сыман ул җәйдә!

Хәтта мена хәзер, ул көннәрне искә төшергән чагында да, шулай тоела ич әле.

Ә тәмамлануын ничегрәк тәмамланды сон әле ул җәй?

Юк бугай, алар аерылышканда җәй ахыры икәне сизелми иде бугай әле... Август һаман кызу тора, көннәр һаман июль аендагыча эссе, кайнар кояшлы иде. Тәнзилә үзе дә каникулы бетеп килү хакында, тиздән уку китәчәге турында бер генә сүз дә әйтмәде... Гомумән, ул турыда уйлавын да сиздермәде. Мена шушы җәй—анын бөтен тормышыдыр сыман иде. Шуннан башка, бүтән урында, башка җирдә аны күз алдына да китереп булмый иде.

Һәм күнелнен сизенүе, чыннан да, дөрескә чыкты шул...

Ул Тәнзиләне бүтән урында очрата, күрә алмады.

Тәнзилә иртәгә бакчадан китәсе көннен кичендә алар сон гына аерылыштылар... Ул кичне ишеткән сүзләр исә колакта һаман да яңгырый кебек. Һаман ишетелә шикелле.

—Минем бу җәем бик матур булды!—дигән иде ул кичне Тәнзилә.— Сина да бик ошады бит ул, әйеме?! Безнен матур җәебез! Мин аны бер дә оныта алмамын кебек... Бүтән бер дә, беркайчан да кабатланмаячагын белгәнгә күрә шулай бу күрәсен...

Сина монарчы әйтми килдем—ә мин бит бер атнадан бик ерак җиргә китеп барам. Бу шәһәрдән бөтенләйгә китәмен. «Кая?»—диярсен син. Әйтсәм, авып китүен дә мөмкин: дөньяда Хабаровски дигән бер шәһәр бар... Җир читендә үк. Документлар әнә шул шәһәрнен институтына күчте инде минем. Бер атнадан үзем дә шунда булачакмын, укыячакмын...

Без синен белән бүтән беркайчан да очрашмаячак инде!

Шуна күрә сина дөресен әйтәм: мин булачак ирем янына барам. Көзен Хабаровскида безнен туй булырга тиеш... Гаҗәпме? Минем үземә дә бик гаҗәп булды шул бу. Көз көне булачак туй һәм синен белән үткәрелгән җәй...

Юк, юк! Мина анда бармый калу турында уйларга да ярамый! Ана сүз бирелгән, килешенгән. Аннан сон—барысы да әзерләнгән дә! Минем әти-әниләр бик көтә ул туйны...

Беләсеңме, тагын нәрсә бар: без синең белән бер тормыш кора алырдай кешеләр түгел бугай... без синең белән артык хыялыйлар бугай... Романтиклар...

Ә мин үземнең азмы-күпме булган тормыш тәҗрибәмнән чыгып шуны беләм—андый кешеләргә бергә яшәү бик авыр. Үзләре искиткеч кешелекле һәм матур җанлы ул кешеләр, башкаларның салкын акыл белән, ә инде күп чагында ерткычларча яшәве аркасында, бик күп яра, җәрәхәт алалар... Алар хәтта корбан да булырга мөмкин бүгенге ерткычлар авызында!

Шуңа күрә... шуңа күрә бер гаиләгә ике романтик күбрәк була бугай ул... Ә бәлки мин ялгышамдыр да? Бәлки алар, киресенчә: җир йөзендәге иң бәхетле гаилә буладыр? Бер-берең өчен бик тә кадерле булу—бәлки иң зур шатлык шулдыр? Кешеләр гомер буена эзли торган бәхет бәлки әнә шулдыр?!

Белмим! Белмим! Әмма ул бәхетнең, андый олы бәхетнең, үземә тәтемәячәген сизәм мин... Аның өчен, бу чиксез зур хәзинәгә ия булу өчен, барыбер минем төсле түгел, ә бүтәнчәрәк кеше булу сорала сыман.

Ләкин миңа хәзер гаилә тотрыклылыгы, гаилә ныклыгы кирәк! Монысын мин яхшы беләм. Миңа аның тынычлыгы һәм мине яклаячак ныклыгы кирәк!

... Соңгы кичтә әнә шуларны сөйләде Тәнзилә.

Үз сүзләренә шуның хәтле мәгънә салып, шундый да җитди итеп сөйли иде ул—бу сүзләр ирексездән диярлек бер олы нәтиҗә, нәрсәгәдер йомгак ясау булып аңлашыла иде. Чыннан да, аңа сөйли-сөйли ул үз тормышының бер чоры, бер баскычы белән саубуллашты сыман бу җәй ахырында.

... Ә безнең әфәндебез исә Тәнзилә тормышының башка яклары турында белә дә, уйлый да алмады. Аның сүзләрендә ишетелгән борчулы авазларның сәбәбен, нилектән икәнлеген дә төшенмәде ул. Аның өчен бары Тәнзиләнең китүе, бик тә еракка китүе—үз тормышыннан югалуы гына бар иде. Ул бары тик шуны гына күрә, шуны гына аңлый иде.

Соңга табарак та, Тәнзиләне искә төшереп уйланган чакларда да, гел шулай булды бугай.

Ул Тәнзилә белән килгән һәм аның белән бергә китеп тә барган үзенең матур җәен генә уйлады. Әйтерсең Тәнзилә «җәй» дигән гаҗәеп бер күренешнең үзәк героинясы булды!

... Менә бүген дә ашыкмый гына шул ук җирләрдән, шул ук сукмаклардан йөри ул. Әкрен-әкрен барысы да хәтергә, күз алдына килә. Хәтта вакыт-вакыт аның тавышы да ишетелеп киткәндәй тоела. Кайчагында ул үзен дә яшь кеше итеп, бөтен гомере әле алда булган кеше итеп хис итә сыман. Андый чакларда—әнә шул изге бер алдануны озаккарак сузарга теләгәндәй—ул күзләрен йома, олы бер могҗиза көткәндәй, тып-тын кала.

Ләкин кызганыч: бик тә көтелгән могҗиза күренми. Һәр нәрсә үз урынында һәм ул да үз яшендә кала.

... Урман уртасындагы зур гына аланлыкта, шактый искергән дача өенең баскыч төбендә бер карт басып тора. Үз гомеренең иң ямьле көннәрен эзләп килгән карт ул. Биредә үзенә бик тә кирәкле бер нәрсәне табарга һәм шуны бүгенге тормышына алып кайтырга тели ул.

Шуңа күрә моннан тиз генә китмәс әле ул. Ашыкмас әле...

Хәзер инде аны ашыктырырдай мөһим ашыгыч эшләр дә калмады бит инде... Ләкин, ләкин менә шунысы гына четерекле мәсьәлә: бик тырышып эзләү белән генә югалган әйберләрнең һәммәсен дә табып була микән? Мәңгелеккә югала торган әйберләр дә юк микән бу дөньяда?..

... Еракта, бик тә еракта калган бер җәй гомернең исәпсез күп хатирәләре арасыннан яп-якты булып күренеп тора...

# ШИГЪРИЯТ



## Сафуан Мулла Гали

### УТКӘННӘР БЕЛӘН СӨЙЛӘШЕП...

**Кое**

Күңел коем төпкеләндә Кояш
Нуры күреп, төпкә төшәмен—
Төшкән саен тирәнәя коем,
Күтәреләә күңел түшәмем...

Күңел коем—телем коесы ич,
Телем төбендәге Кояшны
Күтәрергә көчем җитәр микән?—
Ничек алып таугы куясы...

**Сагындырдың**

Таң сызылып аткан чакта
Тәрәзәмне җил кага.
Җилләр кага—дәрья булып
Күзләремнән моң ага...

Моңнар ага, яшьләр тама,
Күз керфекләрем тала.
Беркемгә дә сөйләмәгән
Серемне сөйлим талга.

...Сагышларымда йөзәмен,
Утлар йотып сулыймын.
Аккош—парын сагынган күк
Сагындырдың, сылуым...

## Ялгышу

Таң беленгән вакыт, ярсый-ярсый
Каршыбызда ага агым су.
Туры юлдан читкә алып китте
Айны кояш диеп ялгышу...

## Канап торган яра

Аерылып яшәүдән дә юктыр
Бу дөньяда авыр көенеч—
Тау кадәрле алтын өеме дә
Бер бөртек тә бирми сөенеч...

...Чирләр китә, тән ярасы бетә,
Кимсеталмый салкын көзләр дә.
Ялгызлык бит канап торган яра—
Ходаем, бир куәт—түзәргә...

## Сандугач

Канатын җәеп кочарлык
Кунарга талы булгач,
Коеныырга күлгә төшкән
Айга карап сандугач:

Сайрый-сайрый төзәтенә,
Күреп үзенең йөзен.
Күзләре шундый матурлар,
Әйтерсең кара йөзем...

Талпына үрелеп айны
Алыр булып куенга,
Күктән яуган ай нурында
Сайрый-сайрый коена...

## Ялкыны кемдә икән?

Көзге кебек түгәрәк күл,
Төбендә алтын икән.
Айның алкасы төшкәндер—
Ала алырмын микән?

Алкасын күреп төшкәндер,
Күл төбендә ай күрәм—
Күк кызына гашыйк бит мин,
Төпсез булса да керәм...

...Алтын алкаларын тагып,
Сәламнәр юллый күктән.
Нурларында үзе йөзә,
Ялкыны кемдә икән?

## Замандашка

Бир әле бир, дустым, кулларыңны,
Бөтерелик икәү буранда.
Буран безне үзе кебек күрә
Чәчләребез карлы булганга...

Буран безнең егетлекне күреп,
Арысланнар булып үкерә...
«Авыр заман авырайтты», диеп,
Өметеңне өзеп бетермә!

...Ат та булдык, арыслан да булыйк—
Икесе дә илгә кирәкле.
Яралансак—халык игътибарлы,
Бәйләр әле, бәйләр йөрәкне...

ПУБЛИЦИСТИКА



# Әгъзам Фәйзрахманов

## ГАСЫР БУСАГАСЫН АТЛАГАНДА...

Юллар, юллар... һәм еллар диген. Җәен соры тузан белән капланган, язын-көзен сыек пычрак диңгезенә әйләнгән Кенәр—Арча юлын без бәләкәй чакларда олы дөньяга алып чыгучы иң олы юлдыр дип исәпли идек. Шушы юл тирәли урнашкан эреле-ваклы дистәләгән авыллардан пәһлевандай ир-егетләр сугышка китеп барды. Аларның күпчелеге олы юлның тузанын ерып кире әйләнеп кайталмады инде...

Сугыштан соңгы елларда бу як авыллары үзенең яшүсмер егет-кызларын әлеге «олы юл»дан Донбасс шахталарына, ФЗӨ мәктәпләренә, бөек төзелешләргә озатты. Бераздан урман кисәргә кызлар юлга чыкты. Шунысы гаҗәп: бу гамәлләр өчен кешеләрдән рөхсәт-фәлән сорап торучы булмады.

Арчага җитәрәк 7—8 чакрым кала Пашкау дигән урман бар иде. Революциягә кадәр ул урыс алпавыты Пашков утары булган, Совет власте урнашкач, алпавыт каядыр чыгып сызган, аннан соң сакланып калган берденбер йортта озак еллар буе бер карт белән карчык гомер кичерде. Юлчылар, гадәттә, Пашкау урманында туктап, кое суы белән юынып кәч-хәл җыеп, тузан-туфракларын кагынып, кайберәүләре хәтта йоклап ял итеп тә алалар иде. Биредәге йортка кайчан гына килеп керсәң дә, өстәл уртасындагы җиз самавырның парларын бөркеп утыруы хәтергә сеңеп калган.

Яңа гасырга кереп барышлый дәүләтчелегебезне торгызу юллары турында уйланып утырганда, балачак хатирәләрем менә шулай кабат яңардылар. Ел дәвамында халык ташкыны агылган Кенәр—Арча юлы күз алдына килеп басты. Мөгаен, мөстәкыйльлек юлы Кенәр—Арча юлыннан да зуррак, узу өчен авыррактыр әле. Шунлыктан «Пашкау урманы» кебек бер тынычрак җирдә бераз тукталып хәл җыеп алу, барыр юлны кабат күзаллау һич кенә дә зыян итмәс кебек. Ачыклыйсы мәсьәләләр, борчыган сораулар күп җыелды. Татар нигә үзенең дәүләтчелеген саклап кала алмаган? Татарның дәүләтле милләт булуы кемнәргә комачаулык тудырган? Татар мөстәкыйль дәүләт төзи алырмы? Ул кайчан төзелер? Кем җитәкчелегендә? Егерменче гасырда дәүләтчелегебезне торгызу буенча ни дәрәҗәдә алга кителде? Татарстанның бүгенге җитәкчеләре суверен дәүләт төзүне ни өчен максат итеп куймыйлар?

Бу сорауларга анык җаваплар хәзергә юк кебек. Хәер, җавап бирергә атлыгып торучы да күренми. Дәүләтчелегебезнең киләчәге турында сүз чыкканда, үзләрен политолог дип санаучылар һәм юристлар төп темадан читләшәләр, конкрет куелган сорауларга гомуми җаваплар белән чикләнергә тырышалар. Татарстан җитәкчеләре суверенлык турында күп сөйләсәләр дә,

аларның ахыр чиктә республиканың киләчәген ничек күзаллауларын аңлап булмый. Бәлки мондый хәл Татарстанның дәүләтчелеген торгызу буенча төп максатның бүгенгә кадәр ачык билгеләнмәвеннән киләдер. Без нинди дәүләт төзергә җыенабыз? Әллә бер нәрсә дә төзергә исәпләмибезме? Бүгенге хәлебездән канәгать булып яшәргә ниятме? Шул ачык түгел.

Максатның тәгәл ачыкланмавы һәр эштә сүлпәнлеккә китерә, ничек эшләсәк тә ярый дигән фикергә җирлек калдыра. Нәтиҗәдә, хәтта дәүләтчелегебезнең киләчәге өчен җаваплы кешеләр дә юк кына уңышларыбызны да кабартып күрсәтәләр, шул рәвешле халыкны тынычландырырга тырышалар, үзләре дә тынычланып калалар.

Бәлки инде ниндидер бөек максатлар куеп, аңа ирешү өчен көчәнүнең хаҗәте дә калмагандыр. Татарстан Конституциясендә республикабызның суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуы ачык күрсәтелгән бит. Өстәвенә, Татарстан Россия белән ассоциациялəшкән дәүләт диелгән. Димәк, Татарстан Россия белән бер үк дәрәҗәдәге, аның белән тигез хокуклы дәүләт.

Әмма теория бер нәрсә булса, чынбарлык икенчерәк шул әле. Көндәлек бәйләнешләрдә Россия Татарстанны һич кенә дә мөстәкыйль дәүләт дип санамый, үзе белән тигез дә күрергә җыенмый. Без аның өчен—субъект. Россия Федерациясе Конституциясендә без Кострома, Орел, Брянск һәм башка шундый өлкәләр кебек үк субъект. Артык та түгел, ким дә түгел. Россия Конституциясендә безнең суверен дәүләт булуыбыз күрсәтелмәгән. Мөгаен, шунлыктандыр Мәскәү республиканың табигый байлыкларын да, җыелган салымнарны да үз кулында тотарга тырыша. Россиянең салым инспекциясе һәм салым полициясе башлыклары да Татарстанда еш кунак булалар. Сез башкаларга караганда салымнарны яхшырак җыясыз дип, мактап китәләр. Күрәсең, салым акчаларын үзләре тотып бетермәгәйләре дип шүрлиләр.

Мәскәү агайлары вакыты-вакыты белән Татарстанның газ торбалары краннарын да боргалап куялар. Күрәсең, профилактика өчен. Онытылып китмәгез, теләсәк без икъдисади блокада ясый алабыз, янәсе. Рәсми сәбәп итеп Татарстанның газ өчен бурычлары алына. Вакытында Татарстан газы да башка төбәкләргә күп китте. Россия хөкүмәте моның өчен нигә түләмәде? Татарстан нефте торбалардан акты, тимер юл составлары белән дә озатылды. Бу долларлар кая? Саный китсәң, кем кемгә бурычлыдыр бит әле. Бәлки ул вакытта безгә нефть краннарын борып куярга кирәк булгандыр. Мәскәү биргән Кучмә кызыл байраклар республиканың икътисади хәлен дә, халык тормышын да яхшырта алмады шул. Республиканың табигатен генә пычратып бетердек. Әле дә нефть шакшысын чистартып бетерә алмыйбыз. Хакыйкать шундый. Татарстан тулы мөстәкыйльлектән бик ерак әле.

Өстәлемдә—«Татарстан АССР тарихы» китабы. 1968 елда 9 мең тираж белән урыс телендә нәшер ителгән. Дәүләтчелегебезгә кагылышлы кайбер сорауларга җавап табу максатыннан инде шактый саргая төшкән китап битләрен актарам. Әлбәттә, ул чор өчен тугыз мең бик бәләкәй тираж инде ул. Партия съездлары материаллары, марксизм-ленинизм классиклары томнары миллионнарча тираж белән чыга иде. Һәр китапханәгә генә түгел, хәреф танучы һәр җан иясенә җитәрлек итеп. Ул китаплар СССР халыкларының барлык телләренә тәрҗемә дә ителде. Рәхәтләнеп укысыннар, коммунизмга бару юлларына ныклап төшенсеннәр, янәсе. Ә менә Татарстан тарихын өйрәнү мәҗбүри итеп куелмады. Хәер, КПСС тарихын өйрәнгәч җитмәгәнмени инде?!

«Татарстан АССР тарихы»ның урыс телендә язылуы һәм нәшер ителүе гаҗәп түгел, билгеле. Кем инде татарга үз тарихын туган телендә язарга рөхсәт бирсен! Әгәр урысның абруена зыян китерерлек мөгез чыгарып куйсалар, аны вакытында кем тотып калыр? Ул чагында татарча аңлаучысы да бөтенләй бетеп бара иде шул. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып йөргәндә безгә ничектер сәерсенеп карадылар. Янәсе, татар филологиясе белгечлеге белән киләчәктә кая барырга җыенасыз, мескеннәр? Ничек тамак туйдырырга уйлыйсыз?

Хәер, уйланырга җирлек тә бар иде шул. Хәтта татарның мәркәзе булган Казанда да татарча сөйләшүчеләр Г. Камал театрында һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, Язучылар Берлегендә генә калган иде бит. Татар мәктәпләре бер-бер артлы ябыла торды. Ярый әле студентларга практика узу өчен 35 нче һәм 89 нчы татар мәктәпләре сакланып калган иде. Тора-бара Галимҗан Ибраһимов исемен йөрткән 89 нчы мәктәп тә ябылды, ә Яңа бистәдәге 35 нче мәктәптә

дәресләр бары урыс телендә генә үткәрелә башлады.

Татар тарихы татар тарафыннан язылган дип расларга тырышу да хакыйкатькә туры килеп бетмәс кебек. «Татарстан АССР тарихы» авторларының да яртысы татар түгел икән бит. Урыслар, яһүдиләр, башка миллләт вәкилләре—Е. Чернышов, Е. Устюжанин, Г. Вульфсон, Ю. Смыков, А. Литвин, Е. Медведев, А. Георгиевская, В. Кузьмин, Н. Корецкая. Әйтерсең лә, һәр татар тарихчысына берәр сак куеп чыкканнар.

Бу китапның Мәскәү тарафыннан кушып яздырылган булуын да истән чыгармаска кирәк. Хәер, ул чорда Мәскәү рөхсәтеннән башка бер нәрсә дә эшләнмәде. 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк комитеты «Татарстан партия оешмасында масса-сәяси һәм идеология эшенең торышы, аны яхшырту чаралары турында» карар кабул итте. Игътибар итегез: Бөек Ватан сугышының иң кызган чоры, Советлар Союзының, гомумән, социализмның язмышы хәл ителгән еллар. Ни өчен әле ВКП(б) «Барысы да җиңү өчен!» дигән лозунгны бераз читкә куеп, идеология белән шөгыльләнергә карар иткән? Бу максат өчен нигә нәкъ менә Татарстан сайланган? Сораулар катлаулы, аларга җавап табу да җиңел түгел. Ләкин шунысы ачык: ныклап уйланып, яхшылап әзерләнеп кылынган гамәл бу. Турысын әйткәндә, Россия җитәкчеләре бер вакытта да Татарстанны игътибарларыннан читтә калдырмадылар, аңа ничектер сагаеп карадылар. Алар өчен Татарстан белән мөнәсәбәтләрнең низагка ук барып җитмәве, татарның буйсынып яшәве мөһим иде. Тарихка игътибар итсәк, төрле чорларда татар халкының дәүләтчелеген торгызуга кискен каршылыкны сиземләү авыр түгел. Әгәр көчәеп китсә, татарның буйсынмый башлавы, мөстәкыйльлек даулавы да бар бит әле. Шунлыктан ВКП(б) Үзәк комитетының әлеге карарын да «Барысы да җиңү өчен!» дигән лозунгның бер өлеше буларак кабул итәргә мөмкиндер. Нәкъ менә җиңү, өстенлеккә ирешү өчен.

Аткан—ук, әйткән—сүз дигәндәй, партия боерыгы Татарстан җирендә тайпылышсыз үтәлде, дәресрәге үтәттеләр. ВКП(б) Үзәк комитеты карары дөнья күргәннән соң озак та үтмәде партиянең Татарстан өлкә комитеты шул ук елның 6 октябрендә «Татарстан Тел, әдәбият, тарих фәнни-тикшеренү институты эшчәнлеге һәм хаталары турында» карар чыгарды. Карарда урыс, татар һәм СССРның башка халыкларының чит ил басмачыларына каршы уртак көрәш тарихын тикшерү һәм яхшыртуга, Совет власте чорында Татарстанны социалистик үзгәртеп кору, татар халкының күренекле эшлеклеләрен, галимнәрен, революцио-нерларын популярлаштыру зарурлыгына аеруча басым ясалды, тарихчылар алдына республиканың «чын фәнни» тарихын язу бурычы куелды.

Ул чагында партия карарларын тайпылышсыз үтәү һәркемнең бурычы иде. Тарихчылар да әлеге карарны турыдан-туры күрсәтмә буларак кабул иттеләр, Татарстан тарихының «марксистик курсын» эшләргә керештеләр. Партия кушкач, алар эшне тиз тоттылар. «Татарстан АССР тарихы»ның ике томлыгы 1955 һәм 1960 елларда басылып та чыкты. Шулар нигезендә бер томлык эшләнде. Ул тулысынча марксизм-ленинизм тәгълиматына, КПССның XXII-XXIII съездлары карарларына нигезләнгән иде. Әмма ике томлык кебек ук ул да тарихи дәреслекне яктыртудан бик ерак торды.

Хәер, Татарстан тарихын чын хакыйкатькә туры китереп язуның бик ук хаҗәте дә булмады. Совет власте елларында мәктәпләрдә СССР тарихы укытылды. Ул нигездә Киев Русе, Мәскәү һәм Петербург тарихыннан гына тора иде. Анда тормыш авырлыгына түзә алмыйча төрле төбәкләрдә күтәрелгән крестиян восстаниеләрен бастыруга, яңа җирләр басып алуга юнәлдерелгән империячел сугышларга зур урын бирелде. Шунысы сәер: аларның барысы да тарихчылар тарафыннан гаделлек өчен көрәш дип бәяләнде.

Бөтен дөньяга сибелеп яшәүче татар халкының, Татарстан дәүләтенең чын тарихы бүгенгә кадәр язылмаган, ул юк әле, диләр. Хәер, бүген юк дигән нәрсә белән кешене шаккатырып булмый. Юк нәрсә чиктән ашты. Ә кайчан булыр соң ул? Аны кем язар? Гомумән, бу эш өчен шәхсән кем җаваплы? Менә шушы сорауларга җавап табып, эшкә керешәсе иде. Төрле дәрәҗәдәге җыелыш-киңәшмәләрдә акыл сатуларны тыңлап утыру туйдырды бит инде.

Беренче карашка хафаланырга җирлек тә юк кебек. Әгәр баш миен әз-мәз эшкә җиксәң, чын тарихны кем язарга тиешлеген дә ачыклау авыр түгел. Җирне крестиян эшкәрткән кебек, тарихны тарихчы язарга тиеш.

Татарстанда тарихчылар аз түгел. Республиканың югары уку йортлары аларны күпләп чыгара. Татарстан Фәннәр Академиясенең Тарих институты оештырылды. Исәпли башласаң, аның чыгымнары да аз түгел. Шунлыктан,

халыкның аннан эш таләп итәргә дә хокукы бар. Чын тарихыбызны язу эшен дә, мөгаен, шушы институт оештырырга тиештер.

Кайбер тарихчылар сәясәт җилләренең юнәлешләренә карап фикерләрен үзгәртеп торалар. Бер тарихчының «хезмәте» Гаяз Исхакыйны халык дошманы дип раслауга корылган иде. Заманалар үзгәреп, Г. Исхакый ватанына әйләнеп кайткач, бу тарихчының да фикере үзгәрде. Ул радио-телевидениедән ясаган чыгышларында Гаяз Исхакыйны «милләтче» дип кенә атый башлады. Әмма диссертациясеннән баш тартмады, хаталары өчен халык алдында гафу да үтенмәде. Мондый тарихчылар халык фикерен бутый, дәүләтчелегебезне ныгытуга зур зыян китерә, билгеле.

Татарның чын тарихын язучыларга, кемнең кем булуына карамастан, академик исемен дә бирергә мөмкин. Хезмәте бар икән—бәяләнсен дә. Югыйсә соңгы вакытларда фән тирәсендә буталып йөрүче һәркем үз фамилиясе артыннан «академик» сүзен өстәп куярга иярләнеп китте. Чын галимнәрдән дә тартынып тормый андый адәмнәр. Хәзер Татарстанда берничә йөз кеше үзен «академик» дип йөртә. Алар арасында фәнни эшчәнлек белән бөтенләй шөгыльләнмәүчеләр дә бар.

Без студент вакытта Татарстанда бары тик аталы-уллы Арбузовлар гына академик иде. Фосфор-органик кушылмалар буенча бөтен дөнья күләмендәге ачышлары белән таң калдырган Арбузовларны бер күрү генә дә безнең өчен бәхет иде. Хәтта исеме легендага әверелгән атаклы галим Гыйлем Камай да академиклыкка дәгъва кылмады, профессор көенә үлеп китте. Ә бүгенге «академиклар»ның ачышларын чит илләрдә түгел, Казанның үзендә дә белмиләр. Үзен гаҗәеп зур галим дип исәпләүче бер «академик» хезмәтләрен, ачыграк әйткәндә, китапларын, сата алмый интегә. Татарстан радиосыннан көн саен берничә тапкыр игълан бирелсә дә, төрле брошюралардан күчергәләп язылган, үзенә ничек тотарга кирәклеген кешенең миенә сеңдерүне максат итеп куйган бу «ачыш» халыкны кызыксындырмый, кибет киштәләрендә тузан җыеп ята бирә. Һәр ялтыраган алтын булмаган кебек, кешене чын академик дәрәҗәсенә күтәрерлек ачышлар көн дә ясалмый шул.

Татарның бик күптәннән дәүләтле миллət булуы яхшы мәгълүм. X-XIV гасырларда Идел буе Болгарстаны Көнчыгыш Европада иң алга киткән дәүләт булып саналган. Европаны Азия белән тоташтыручы мөһим сәүдә юлы аның аша үткән. Урта Азиядә дә, гарәп илләрендә дә, Киев Русенда да, Көнбатыш Европада да абруе зур булган аның. Болгарлар икмәк үстергәннәр, терлек асраганнар. Ул үзенең ювелирлары, алтын осталары белән танылган. Биредә чорына күрә кара металлургия, чүен кою, чүлмәк ясау, тире, агач эшкәртү нык алга киткән. Болгар, Биләр, Сувар шәһәрләре төзеклекләре һәм матурлыклары белән һәркемне сокландырганнар.

Хәтта монголлар золымы астында да Болгарстан мөстәкыйльлеген югалтмаска тырышкан. Баштарак мөстәкыйль үсеш өчен юл куймасалар да, монголлар илнең эчке үзидарә системасын үзгәртмәгәннәр. Кенәзләргә идарә итү өчен махсус ярлыклар биргәннәр. Болгар кенәзләре акча сугу эшен дә дәвам иткәннәр, Болгарстан территориясендә алар 1310 елга кадәр йөргәннәр. Дәүләтнең билгеле дәрәҗәдә мөстәкыйльлеген раслаучы үз акчасы булган.

Болгар халкы илбасарлар йогынтысыннан котылу өчен кат-кат көрәшкә күтәрелгән. Халык ясак түләүдән баш тарта торган булган, башка төбәкләргә күчеп киткән. Басып алынган җирләрдә яшәүчеләрнең ризасызлыгы, феодалларның үзара көрәше, ахыр чиктә, Алтын Урданың таркалуына китергән дә инде.

«Татар милләтенең тарихы гаять катлаулы һәм фаҗигале,—диде Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев 1992 елның 19 июнендә I Бөтендөнья татар конгрессындагы чыгышында.—Гөрләп чәчәк атып утырган Болгар дәүләте һәлакәте—югалтуларның иң әрнүлесе һәм зурысы. Фәкать үзенең түземлеге, мәгърифәтле һәм зирәк булуы аркасында гына халкыбыз исән калды, аякка басты һәм Алтын Урда дәүләтендә лаеклы урын алды. Алтын Урда җимерелеп, Казан, Себер, Әстерхан, Кырым ханлыклары оешкач, үсәр өчен халык үзендә яңадан зур көч тапты».

Язмыштан узмыш юк, диләр. Казан ханлыгының тиз генә тернәкләнеп китүе, Төркия, Кырым белән дуслашуы Мәскәүнең кәефен боза, чыгырдан чыгара. Урысларның Казанны буйсындыру, үз кулларына алу өчен походлары ешаеп китә. Аларның берничәсе котелгән нәтиҗәне бирмәгәч, Иван IV (Грозный) хәлиткеч һөҗүмгә ныклап әзерләнергә, Казан янында гаскәрләрне күпләп туплау өчен терәк-пункт булдырырга карар кыла. Шул рәвешле

Казаннан 30 чакрымлап ераклыкта Свияжск ныгытмасы барлыкка килә. Шуннан соң бервдә көч туплап, 1552 елның июнендә 150 меңле урыс гаскәре Казанга ыргыла.

23 августта Казан камалышта кала. Окоплар, чокырлар, ком тутырылган капчык таулары белән чорнап алына. Камалыштагы татарлар явыз дошманга каршы аяусыз көрәшәләр. Әмма көчләр тигез булмый шул.

2 октябрьдә Казан штурм белән алына. Шәһәрдәге барлык ирләр юк ителә. Татарны миллә буларак җир йөзеннән себереп ташлауга исәп тотыла: кан гөрләвек булып ага, урамнар мәетләр белән тула. Менә ул вәхшилек, чын мәгънәсендәге геноцид!

Кызганыч ки, гасырлар буена «урыс белән гомер кичердек сайрашып» кына яшәп булмаган шул. Шулай да, тарихка күз салсаң, татарларның иң кыен елларда да хакыйкатьнең тантана итәсенә киләчәккә ышанып яшәүләренә инанасың. Миссионер Ильминскийның әйтүенә караганда, татарлар һәрвакыт үзләрен дәүләтле халык итеп тойганнар. Дәүләтчелекне торгызу идеясе татар халкының иҗтимагый аңында беркайчан да үлмәгән. Ул халык җырларында, риваятьләрдә, әкиятләрдә яшәгән. Муса Бигиев, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Садрый Максуди кебек мәшһүр шәхесләр халкыбызның азатлык көрәшенә зур өлеш керткәннәр. Гаяз Исхакый, Мулланур Вахитов, Фуат Туктаров, Мирсәет Солтангалиев кебек социаль-демократлар да дәүләтчелекне торгызу буенча үз юлларын тәкъдим иткәннәр.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң татар халкының милләтпәрвәр уллары дәүләтчелегебезне төзүгә җиң сызганып керештеләр. Берәүләр Идел-Урал штаты төзергә чакырдылар, икенчеләре исә милли-мәдәни автономия белән чикләнергә кирәк, дип чыктылар. Совет власте исеменнән Мулланур Вахитов Татар-Башкорт Республикасы проектын тәкъдим итте. Кызганыч ки, бу идея дә тормышка ашмады.

Тора-бара Татарстан Республикасын төзү планы пәйда булды. 1920 елның 27 маенда, ниһаять, Татарстан АССРны төзү турындагы декретка кул куелды. Тулаем бу вакыйга татар җәмәгатьчелегендә уңай бәяләнсә дә, татарлар күпләп яшәгән шактый төбәкләрнең һичнинди нигезсез күрше республикалар һәм өлкәләр составына кертелүе, нәтиҗәдә, Татар иле—Татарстанның нык кечерәеп калуы канәгатьсезлек, билгеле дәрәҗәдә ризасызлык та тудырды.

Шунысын да әйтергә кирәк, башта республика «союздаш»ларга һәм «автономия»ләргә бүленмәде. Барысы да тигез иде. Автономиягә таянып, тулы хокуклы дәүләтчелек өчен көрәшне дәвам итәргә мөмкин дип уйланылды. Әмма 1922 елның ахырында, СССР төзелгәндә, Татарстанга союздаш республика хокукы бирелмәде, татар икенче сортлы халык булып калды. Милләтләр эше буенча халык комиссары Мирсәет Солтангалиев моңа кискен рәвештә каршы чыкты. Ул Россиягә диктатура килүен беренчеләрдән булып сизәтте. Аның дөньяда сәяси процессларның үсүе, колониаль системаның җимерелүе турындагы фикеренең хаклы булуын тормыш үзе раслады.

1936 елда СССР Конституциясе кабул ителгәндә, Татарстан үзенең хокуклары турындагы мәсьәләне кабат күтәрде. Кирәкле дәлилләр китерелде. Ләкин СССРның «татар барда хәтәр бар» дигән төшенчәне аңнарына нык сеңдергән шовинистик җитәкчеләре Татарстанның тавышын ишетергә теләмәделәр, аның гозерен үтәмәделәр. Татарстан автономия кысаларында кала бирде.

СССРның соңгы Конституциясе (1977) кабул ителгәндә, Татарстан җитәкчеләре республиканың статусын күтәрү мәсьәләсен яңа көн тәртибенә куйдылар. Кызганыч, аңа союздаш республика статусын бирмәделәр. Сүз уңаенда тагын шунысын да искәртү урынлы булыр, төрле чорларда башка кайбер автономияле республикалар да статусларын күтәрү өчен тырыштылар. Мәсәлән, СССРның 1977 елгы Конституциясе кабул ителгәндә Татарстан кебек үк Абхазия дә шундый максатны куйган иде.

Ниһаять, 80 еллар урталарында, демократия җилләре исә башлагач, татар халкының башкалар белән тигез хокук алуына өмете арта төште. Татарстан җитәкчеләре Ново-Огарево сөйләшүләрендә актив катнаштылар. Советлар Союзын яңа принципларда үзгәртеп кору өчен күп көч түктеләр. Союз килешүенә Татарстан Россия делегациясе составында түгел, мөстәкыйль рәвештә имза салуны, шул рәвешле союздаш республика статусына ирешүне максат итеп куйды. Шул ук вакытта сөйләшүләрдә даими катнашкан Минтимер Шәймиев республика позициясенең дөреслегенә бик күпләрне инандыра да алды.

Шәхсән үзем бу чорда мөселман республикалары җитәкчеләре, беренче

чиратта, Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан җитәкчеләре Татарстанга ярдәм кулы сузарлар, аның омтылышын хупларлар дип уйлаган идем. Әмма Үзбәкстан Президенты Ислам Кәримов та, Казакъстан Президенты Нурсолтан Назарбаев та, Кыргызстан Президенты Әскәр Акаев та зур «тыйнаклык» күрсәттеләр, Татарстанны яклау, аңа теләктәшлек күрсәтү юлына басмадылар. Күрәсең, көнләшү чире көчләрәк булып чыкты.

Үзбәкстан Президенты Ислам Кәримов бүген дә үзен бик сәер тота. Татарстан Республикасын һаман да суверен дәүләт дип санамый, Россиянең кечкенә генә бер кисәге дип бәяли. Татарстанның Үзбәкстан Республикасындагы даими вәкиле Үмидә Сабирова депутатлар алдындагы чыгышында күңелгә шом сала торган фактлар китерде. Әйтик, Татарстан Президентының Үзбәкстанга визиты вакытында, алдан килешенгән булса да, аны каршы алганда аэропортка безнең флагны элмәгәннәр. Ике республика Президентлары сөйләшүләре барган бүлмәгә дә Татарстан флагын куярга теләмәгәннәр. Татарстанның бу республика-дагы вәкиллеге дә бик авырлык белән ачылган.

Билгеле булганча, Союз килешүенә кул куелмый калды. ГКЧП килеп чыкты. СССРны таркатып ташладылар. Элеккеге союздаш республикаларның барысы да мөстәкыйль дәүләтләргә әйләнде. Без әйләнгәч, төп кыскара дигәндәй, Татарстан тагын теләгенә ирешә алмады, Россия империясе составында калды, империянең 89 субъектының берсе булып йөри башлады.

Тырышып-тырышып та ярык тагарак алдында калу, бөтен өметләрнең чәлпәрәмә килүе республика өчен көтелмәгән хәл булды. Шунлыктан башта җитәкчеләребез дә югалып калдылар, аңнарына килә алмый йөрделәр. Тора-бара дәүләтчелегебезне торгызу буенча яңа сәясәт булдырырга туры килде.

1990 елның 30 августында Татарстанның дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителде. Декларация Татарстанны суверен дәүләт дип белдерде, үз территориясендә республика законнарының өстенлеге танылды. Җир, табигать хәзинәләре һәм башка ресурслар республиканың күпмилләтле халкы милкәте итеп беркетелде. Бу чара Татарстанда яшәүче милләтләрнең мәнфәгатьләренә тулысынча җавап бирә иде. Декларация республикада милләтара мөнәсәбәтләрне нygытуга китерде.

Язмышыбыз шундыйдыр инде: татарлар һәрвакыт башкаларга юл күрсәтә, башлап йөри. Суверенлык Декларациясен дә Татарстан Россия Федерациясендә беренчеләрдән булып кабул итте. Бу уңайдан Татарстанга Россия үзе үрнәк күрсәтте кебек. 1990 елның июнендә РСФСРның суверенлык Декларациясе игълан ителде. Ләкин мондый чараның ни өчен кирәк булуы гына бик үк аңлашылып җитми, гаҗәпсенү тудыра. Россия болай да суверен иде бит. Ул башкалар басымы астында, коллыкта яшәмәде, киресенчә, милли республикаларның байлыгын суырып, үз кулына туплап ятты. Әмма ничек кенә булмасын, Россиянең суверенлык игълан итүе республикаларның гына түгел, крайларның, өлкәләрнең дә мөстәкыйльлеккә омтылышын көчәйтте.

Декларация кабул ителүгә, Татарстанда суверенлыкны реаль эчтәлек белән тулыландыру буенча күпкырлы эш башланды. Югары Совет икътисадны хуҗалык итүнең яңа алымнарына күчерүгә җиң сызганып керештe. Милекне хосусыйлаштыру һәм башка шуның кебек бик мөһим законнар кабул ителде. Алар базар икътисадына күчүдә хәлиткеч роль уйнадылар. Совет чорында беренче тапкыр буларак, Татарстан мөстәкыйль рәвештә хөкүмәтара килешүләр төзергә керештe. Күп кенә дәүләтләр белән икътисад, фәнни тикшеренүләр, мәдәни хезмәттәшлек буенча килешүләргә кул куелды. Бюджетны формалаштыру, банк эшчәнлеге, салым сәясәте кебек мөһим икътисади мәсьәләләр буенча Россия хөкүмәте белән сөйләшүләр башланды. Чөнки үзара мөнәсәбәтләрне ачыкларга, аларны җайга салырга кирәк иде. Әмма күпчелек очракта уртак тел табылмады, килешүләргә ирешелмәде.

Элеккеге автономияләрнең дәүләт суверенлыгы турында Декларацияләрен кабул итүенә Россия битараф кала алмады, билгеле. Югары Советта, халык депутатларының III съездында җитди сөйләшүләр барды. Ни эшләргә?—дигән сорауга җавап эзләнде. Нәтиҗәдә, Россия Федерациясе Конституциясенә элеккеге автономияләр урынына Россия составында суверен республикалар барлыкка килүе турында үзгәрешләр кертелде. РСФСР халык депутатларының III съезды милләтләрнең суверен хокукларын—шул исәптән үзбилгеләнү, үзенең сәяси статусын урнаштыру, икътисади, социаль һәм мәдәни үсешенә хокукларын тануын, хөрмәт итүен раслады.

Суверенлык Декларациясе кабул ителүне кайберәүләр мөстәкыйльлеккә

ирешү дип аңладылар. Бу хакта матбугатта да шатлыклы хәбәрләр күп басылды. Әмма Декларация—Конституция дә, хәтта закон да түгел, бары тик максатны рәсми төстә белдерү, билгеле дәрәҗәдә барыр юлны ачыклау гына иде. Әйе, Декларация парламент тарафыннан кабул ителде, әмма аны халык сайлаган депутатлар игълан итсә дә, бөтен халык фикере дип раслап булмый иде әле. Халык фикерен тәгәл ачыклау максатыннан 1992 елның 21 мартында референдум үткәрергә туры килде.

Референдумның нинди катлаулы шартларда узуын, республика халкының нинди тупас сәяси басымга дучар булуын бик күпләр яхшы хәтерлидер. Россия Федерациясе Югары Советы Татарстанны сепаратизмда гаепләде. Югыйсә, Татарстан үзенең төп максаты республиканың статусын күтәрү икәнен, вәкаләтләрне чикләү буенча Россия белән килешү төзергә җыелуын яшермәде. Максатын ачыктан-ачык белдерде, Россиягә карата бернинди заговор юлына басмады. Әмма Татарстанның бюджетын мөстәкыйль формалаштырырга, салым сәясәтен үз законнарына нигезләнеп алып барырга омтылуы Россия парламентында да, Татарстан делегациясе белән сөйләшүләр алып баручыларда да яклау тапмады. Дәүләт Думасының тугыз депутаты Россия Конституция судының референдумны тыюын таләп иттеләр. 1992 елның 5 мартында Россия Федерациясе Югары Советы референдумны үткәрмәскә өндәп Татарстан халкына, Югары Советка һәм Президентка мөрәҗәгать белән чыкты.

Бу документ Татарстан Югары Советы Президиумында җентекләп тикшерелде. Президиум Татарстанның Россия составыннан чыгу максатын куймавын, бары тик үзбилгеләнү һәм халыкларның тигез хокуклы булуларыннан чыгып, Россия Федерациясе белән мөнәсәбәтләрен яңача, килешүләр нигезендә алып барырга җыенуын белдерде. Югыйсә, академик Индус Таһировның әйтүенә караганда, Татарстанның Россия составына керүе турында тарихта бернинди документ та юк. Чөнки Татарстанның бу хакта хәтта теләк тә белдергәне юк. Ә кермәгән җирдән чыгып булмый инде ул.

Кайбер сәяси көчләр референдум Татарстандагы татар булмаган милләтләрнең хокукларын кысуга юнәлгән, дип аңлатырга тырыштылар. Россия җитәкчелеге Татарстанга каршы рәсми рәвештә сугыш игълан итмәсә дә, ул— бу була калмасын дип, республикабыз чигендәге Мари урманнарына танклар китереп тутырды. Татарстан Россия гаскәрләре белән чорнап алынды. Хәер, гасырлар буе урыс булмаган милләтләрне көч кулланып изеп килгән Россия империясе башкасына сәләтле дә түгел иде.

1992 елның мартыннан ераклашкан саен көнелдә дистәләрчә сораулар туа. Россия Президентын, Югары Советын, Конституция судын Татарстанның суверенлыкка омтылышы нигә шул кадәр нык борчыды соң? Дәүләт Думасына Татарстаннан сайланган кайбер депутатлар ни өчен үз республикалары мәнфәгатьләренә каршы көрәш җәелдерделәр?

Иртәгә референдум үткәреләсе диган көнне Россия прокуратурасының сайлау участокларын ябарга әмер бирүен аңлап та, аңлатып та булмый. Буйсынмаган очракларда сайлау участоклары рәисләрен җинаять җаваплылыгына тарту белән куркыттылар. Бу халыкара хокук нормаларын тупас бозу түгелме? Татарстанга меңнәрчә данә листовкалар кем акчасына китереп таратылды? Бу акчаны кулланырга башка урын юк идеме әллә? Мондый көнелгә ятышсыз хәлләр тарихка кара тап булып ягылып калды.

Татарстандагы барлык сайлау участоклары да билгеләнгән вакытта ишекләрен ачтылар. Берәү дә тормәгә эләгүдән курыкмады. Хәер, халкыбыз да, республикабыз җитәкчеләре дә моңа юл куймаячаклар иде.

Референдум көнне мин күп кенә участокларда булдым. Тавыш бирү һәр җирдә тыныч, оешкан төстә узды. Төрле илләрдән, төрле партияләрдән, иҗтимагый оешмалардан һәм хәрәкәтләрдән җибәрелгән күп санлы күзәтүчеләр сәяси ныклыгыбызга һәм демократик принципларда эш итүебезгә үз күзләре белән күреп ышандылар. Чит ил күзәтүчеләрендә мондый хәл хәтта гаҗәпсену дә тудырды. Алар референдумның халыкара хокук нормаларына тулысынча туры килүен белдерделәр. Берниге дә карамастан, татарлар гына түгел, Татарстанда яшәүче башка милләт халыклары да сайланган юлга тугры калдылар, суверенлыкны яклап тавыш бирделәр. Халыкны Карабах дәһшәте белән куркытырга, милләтләр арасында ыгы-зыгы тудырырга омтылыш барып чыкмады. Шик-шөбһәләр алып ташланды.

Референдумнан соңгы беренче төнне казанлылар йокысыз үткәрделәр

дисәк тә, әллә ни хата булмастыр. Тәрәзәләрдә утлар сүнмәде, йорт-урамнардан җыр-музыка тавышы ишетелеп торды, бар халык референдумның рәсми нәтиҗәләрен көтте.

Парламент эшчәнлеген, дәүләтчелегебезне ныгыту юлларына кагылышлы вакыйгаларны матбугатта даими яктыртып баручы журналист буларак, таң атуга мин Югары Совет бинасына килдем. Ул умарта оясын хәтерләтеп, гөжләп тора иде. Күп кенә депутатлар, журналистлар референдумның рәсми нәтиҗәләрен көтеп, төнне биредә үткәргәннәр икән. Ишектән керүгә беренче очраган кеше—ул чактагы Татарстан халык депутаты (хәзер мәрхүм инде) Дамир Сираҗиев булды. Режиссер кеше, хисләргә дә тиз бирелүчән булгандыр, ул мине: «Әгъзам, победа, җиңдек!»—дип сәламләде. Аның гаҗәеп зур шатлык кичерүе йөзенә бәреп чыккан иде.

Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтим, Дамир суверенлык идеясенә ихлас күңелдән бирелгән кеше иде. Ул Югары Совет сессияләрендә еш чыгыш ясады. Законнарны бик үк яхшы белмәсә дә, аның йомшак тавышы, эмоциональлеге башка депутатларга нык йогынты ясый иде.

Моңарчы ничектер кирәгеннән артык рәсми, гадәттә кешеләр кычкырып сөйләшергә дә батырчылык итми торган парламент бинасы коридорлары ул чакта кинәт бик нык җанланып киткәндәй тоелды. Ул закон чыгару органы булудан бигрәк, тантаналар, тамашалар урынын хәтерләтте. Кешеләр кычкырып сөйләштеләр, рәхәтләнеп көлештеләр, вакыты-вакыты җырлашып та алдылар.

Көн бераз яктыра төшкәч, Югары Советның кече залында матбугат конференциясе үткәрелде. Хәер, аны матбугат конференциясе дип атау бик үк дөрес тә булмас. Шыгрым тулы залда күпчелекне депутатлар, милли хәрәкәт вәкилләре, референдумга төрле төбәкләрдән килгән күзәтүчеләр тәшкил итте. Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары беренче нәтиҗәләр белән таныштырдылар. **«Татарстан Республикасының суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты, Россия Федерациясе, башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокукый килешүләр нигезендә урнаштыруына Сез ризамы?»—дигән сорауга 1 миллион 309 мең 56 кеше референдумда катнашып, «Әйе» дип җавап бирде. Бу сайлау участокларына килүчеләрнең 61,4 проценты иде. Шулай итеп, республика гражданнарының күпчелеге референдумның төп фикерен—Татарстанның дәүләт статусын күтәрү зарурлыгын яклады. Бу көнне республика халкының активлыгын, исемлеккә кертелгән сайлаучыларның 82 процентының участокларга килүен дә хәтердә яңарту зыян итмәстер.**

Референдум җиңү белән тәмамлангач, халык тантана итте. Казанның Ирек мәйданына кыска гына вакыт эчендә йөзләрчә кеше җыелды. Каяндыр гармунчылар, җырчылар пәйда булды. Күмәк биюләр, уеннар берсен-берсе алыштырды. Югары Советка эшкә барышлый Минтимер Шәймиев тә Ирек мәйданында тукталып, тузан очырып биеп китте.

Референдум нәтиҗәләре суверенлыкны ныгыту буенча активрак эшләү өчен шартлар тудырды. 1992 елның 20 маенда референдум нәтиҗәләренә һәм алда торган бурычларга багышлап махсус сессия үткәрелде. Югары Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин докладында Татарстанның кыйбласыннан тайпылмаячагы ачык күрсәтелде. Дәүләт төзелеше, территория, законнар һәм Конституция кабул итү, аларның үтәлешенә контроль ясау, гражданлык, табигый байлыклардан файдалану, финанс, кредит, таможня, салымнар һәм җыемнар, хәрби җиһазлар һәм техника сату тәртибе, халыкара мөнәсәбәтләр, суд, прокуратура, адвокатура, башка күп кенә мәсьәләләрне Татарстанның мөстәкыйль хәл итәчәге белдерелде. Кызганыч, боларның шактый өлеше бары ният кенә булып калды.

Әлбәттә, халкыбызның дәүләт статусын үзе теләгәнчә билгеләргә тулы хокукы бар. Моның өчен юридик нигез дә салынган. Мин монда, беренче чиратта, бөтендөнья кеше хокуклары Декларациясен, шулай ук гражданлык һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактны күздә тотам. Аларда һәр халыкның үзбилгеләнүгә хокукы булуы күрсәтелә. Шушы хокуклары нигезендә һәр милләт ирекле рәвештә сәяси статусын билгели, икътисади, социаль һәм мәдәни үсешен шулай ук ирекле рәвештә хәл итә. Бу хокук 1975 елда Европада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча Хельсинкидә үткәрелгән киңәшмәнең йомгаклау актында тагын бер кат расланды. Шулай итеп, теге яки бу дәүләтнең статусын аның географик урыны билгеләмәве, ә эчке икътисади, социаль, мәдәни процесслар тиешле сәяси статус таләп итәләр.

«Россиядән аерылып чыгу мәсьәләсе нигә көн тәртибенә куелмый?»— дигән сорауга республикабыз җитәкчеләре теләр-теләмәс кенә җавап бирәләр. Янәсе, без Россиянең кыл уртасында, кая барыйк инде без. Әлбәттә, без Россия коллыгыннан котылу өчен башка җиргә, әйтик, Америкага яки Африкага күчеп китә алмыйбыз. Татарстан—безнең туган йортыбыз. Әмма республиканың географик урыны мөстәкыйльлекне максат итеп куймау өчен сәбәп тә була алмый. Татарстанның мөстәкыйль яшәү өчен бөтен мөмкинлекләре бар. Географик урыны да отышлы, җир асты һәм җир өсте байлыклары да җитәрлек, халкы да эшчән. Элеккеге союздаш республикалар мөстәкыйль дәүләт буларак тыныч кына яшәп яталар бит әле. Европада гигант илләр уртасында калган кеп-кечкенә дәүләтләрне искә алып та тормыйм инде. Аларның берсе генә дә Россиядән хәерчерәк яшәми. Шунлыктан Татарстанга да, академик Әбрар Кәримуллин әйтмешли, Россия арбасына тагылган дегет чиләге кебек йөрүнең хаҗәте юк.

Тагын шунысы да бар: бер генә империя дә мәңгелек түгел. СССР кебек үк Россия империясе дә таркалачак. Аның гомере күп калмады инде. Кавказдагы азатлык сугышлары, төрле төбәкләрдә туктаусыз дәвам итә торган забастовкалар, хөкүмәтнең даими алмашып торуы, Президентның ил белән идарә итәргә сәләтсезлеге бу көнне тагын да якынайтыр кебек. Татарстанга да, телиме ул юкмы, кайчандыр барыбер мөстәкыйль яшәргә туры киләчәк. Моның өчен бүгеннән үк әзерлек чараларын күрү зарур. Югыйсә, нәкъ менә базар шартларына күнегә алмый азапланган кебек, авыр хәлдә калуыбыз бар.

Әлбәттә, Россия җитәкчеләре бер генә төбәккә дә ирек бирергә атлыгып тормый. Чечняның (Ичкерия) бәйсезлеге бүгенгә кадәр танылмады. Россиянең Конституциясендә дә милләтләрнең һәм аерым төбәкләрнең Россиядән аерылып чыгуы каралмаган. Шулай итеп, кеше хокукларын бозуны Россия үзенчә законлаштырып куйган. Татары да, чечены да, ингушы да, башкасы да Россиянеке!

Шулай да республиканың Декларациягә нигезләнеп ясаган беренче адымнары уңай нәтиҗәләр бирде. Татарстан табигый байлыкларының бер өлешеннән мөстәкыйль файдалана башлады. 1991 елда республика үз хаҗәтләре өчен бер миллион тонна нефть сатты. Халык куллану товарларын тулыландыру өчен анысы да ярап куйды. Россия белән сөйләшүләр нәтиҗәсендә 1992 елда 5 миллион тонна нефтьне Татарстанның үз ихтыяҗлары өчен сатуы хакында килешенде. Һәр нәрсәне йодрыгында тотарга гадәтләнгән Россия, шулай итеп, кайбер ташламаларга барырга мәҗбүр булды.

Президентның «Татарстан ССР дәүләт суверенлыгын һәм милеккә хокукын тәэмин итү чаралары турында» 1991 елның 15 августы Указы нигезендә Дәүләт милкен идарә итү комитеты республикада урнашкан предприятиеләр һәм оешмаларны Татарстан юрисдикциясенә күчерүне тизләтә төште. 1992 елның 15 маена 1078 предприятие һәм оешма республика карамагына күчерелде. Аларның төп фондлары 31,6 миллиард сум, ягъни барлык предприятие һәм оешмалар төп фондларының 65,8 процентын тәшкил итте.

1992 елда суверен дәүләт эшчәнлегенең иң мөһим принцибы гамәлгә ашырыла башлады: Татарстан бюджетын мөстәкыйль формалаштыруга кереште. Ул салымнарны үзе җыйды һәм тиешлесен генә Россия Федерациясенә күчерде. Мондый система икътисадны тамырдан үзгәртергә мөмкинлек бирде, социаль хаҗәтләргә акча күбрәк калды.

Милли банк булдыру да мөһим роль уйнады. Татарстан кредит ресурсларын теләгәнчә куллану мөмкинлеген алды, коммерция банклары эшчәнлегенә контроль урнаштырды. Ләкин бу вәкаләтләр генә чын суверенлыкны гамәлгә ашыру өчен җитми иде әле.

СССР таркалып, элеккеге союздаш республикалар мөстәкыйль дәүләтләргә әйләнгәч, икътисади бәйләнешләрне саклап калу өчен зур тырышлык куелды. Чөнки шунсыз күп кенә предприятиеләр элеккеге күләмдә продукция эшләп чыгара алмаячаклар иде. Украина, Беларусь, Казахстан, Молдова, Грузия, Үзбәкстан, Таҗикстан, Россия составында калган республикалар, байтак өлкәләр һәм крайлар белән хөкүмәтара килешүләр төзелде.

Татарстандагы сәяси хәлнең тотрыклылыгы, икътисади, фәнни- техник мөмкинлекләре чит ил фирмаларында, банкларында да билгеле дәрәҗәдә кызыксыну тудырды. Татарстанның үзен дөньяга таныту, чит мәмләкәтләр белән турыдан-туры элемтәләр урнаштыру көн тәртибенә килеп басты. Президент Указы нигезендә, Татарстанның халыкара хокук субъекты булуын

истә торкан хәлдә дөньяның төрле илләрендә, Россия төбәкләрендә вәкилләкләр ачылды. Хәзер алар—13. Шуның белән бергә, Татарстан, килешүләр нигезендә үзендә дә чит төбәкләрнең сәүдә вәкилләкләрен, консуллыкларын булдырды. Бүген бездә Төркия Республикасының генераль консуллыгы, уңышлы эшләп килә. Чечня Республикасы Ичкерия Президентының тулы вәкаләтле вәкиле, Ингушетиянең вәкиллеге бар. Шулай да инвестицияләр бик авырлык белән килә. Чит ил фирмаларын бизнес-планнар кызыксындырса да, Россиядәге тотрыксызлык аларда ниндидер шикләнү уята. Капиталистлар акчаларының җилгә очуыннан шүрлиләр. Шуңа күрә читтән ярдәм көтеп тормыйча, үзебездә җитештерүне арттыра барырга, шул хакта күбрәк уйланырга кирәк. «Үлә башласаң, завод торбасына ябыш» дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул. Кулланучыга кирәкле товар җитештерергә, аны сата да белергә кирәк.

Әлбәттә, суверен дәүләтнең символлары да була. Хәтерлим, Флаг та, Герб та, Гимн да бик авырлык белән кабул ителде. Бу хакта парламентта кискен бәхәсләр барды. «Народовластие» төркеме депутатларының символларны кабул иттермәскә тырышуларының сәбәбенә инде шактый еллар үткәч тә төшенә алмыйм. Күрәсең, алар суверен дәүләтнең формалашу чорын мөмкин кадәр озайтырга омтылганнардыр.

Дәүләт символларын кабул итү республика халкының күпчелеге тарафыннан хуплап каршыланды. Дәүләт Флагы кабул ителгән көн хәтергә нык уелып калган. Төшке ялга тукталыр вакыт җитеп килә иде. Флаг кабул ителгәч, зал баскан көйгә озак алкышлады. Аннары депутатлар идәнгә тезләнеп Флагны үбәргә тотындылар. Бик күпләр кичерешләрен яшерә алмадылар. Мөгаен, хәтта иң гашыйклар да алай шашынып үбешмиләрдер.

Залда халык бераз кими төшкәч, берничә кеше Флагны залдан алып чыгып та китте. Ялгышмасам, флаг сессия утырышларына һәрчак чиккән түбәтәйдән килүче депутат Мөдәррис Шәйхиев кулында иде булса кирәк. «Милләтче» мөһере сугылган берничә депутат флагны Югары Совет бинасы түбәсенә алып менеп киттеләр, аларга милли басмаларның журналистлары, милли хәрәкәт активистлары да иярде. Күрәсең, түбәгә күтәрелү юлын алдан ук күзәтеп куйганнардыр.

Дәүләт Флагы кабул ителү казанлылар өчен зур бәйрәмгә әверелде. Берничә минут үтүгә Ирек мәйданы халык белән тулды. Һәркем парламент түбәсендә җилфердәгән флагка карап торды. Яннарындагылардан һич тә оялмыйча үксеп-үксеп елаучылар да булды. Әмма бу шатлык яшьләре иде.

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә дәүләт Гербы, Флаг һәм Гимн дәүләт суверенлыгын, халкыбызның үзенчәлекләрен һәм традицияләрен чагылдыручы символлар булып торалар. Аларны кайчан, ничек куллану хакында махсус закон эшләнде. Тиздән ул гамәлгә дә керер.

Республиканың бөтенхалык тавыш бирү юлы белән билгеләнгән статусы Татарстанның яңа Конституциясе проектына нигез итеп алынды. Халыкара стандартларга җавап бирә торган Конституция эшләргә тырышылды. Анда халыкара хокук нормалары республика законнарыннан өстен итеп куелды. Конституция проектын әзерләгәндә шәхес хокукын яклауга нык игътибар бирелде. Чөнки дәүләтнең куәте территориясенең зурлыгы яки халкының саны белән түгел, ә гражданның реаль статусы, дәүләт хезмәтенә аның хокукы, демократик институтларның ныклыгы, җәмгыятьнең икътисади, социаль, мәдәни үсеш дәрәҗәсе белән бәяләнә ич. Конституция дәүләт тормышының төп мәсьәләләрен билгеләүче иң югары юридик көчкә ия закон гына түгел, ә бәлки демократик үзгәрешләрнең нигезе дә. Аннары республиканың дәүләт-хокук статусындагы үзгәрешләрне Төп Законга беркетү дә бик мөһим иде.

Дөньяда Конституциянең идеаль модельләре юк, диләр. Һәр дәүләт үзенең традицияләреннән, сәяси, икътисади хәленнән чыгып эш итә. Татарстан Конституциясе дә республикада яшәүче киң катлау халык массалары мәнфәгатьләрен чагылдыруны максат итеп куйды.

Конституция проекты Президент Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге махсус комиссия тарафыннан әзерләнде. Аның эшендә Югары Совет Президиумы әгъзалары, халык депутатлары, күренекле галимнәр катнашты. Проектны чит ил экспертлары анализлады, ул халык депутатларының район һәм шәһәр Советлары сессияләрендә, хезмәт коллективларында, матбугатта тикшерелде.

Югары Совет сессияләрендә Конституциянең иң мөһим маддәләрен кабул иткәндә көймә еш кына комга терәлгәләп алды. «Народовластие» һәм «Татарстан» төркемнәренә берләшкән депутатлар бер үк мәсьәләгә капма-

каршы караштa торалар иде. Андый очракларда килештерү комиссияләре төзелде. Ул комиссияләрнең әгъзалары вакыты-вакыты белән яртышар көн (кайвакыт яртышар төн) бәхәсләшәләр иде. Килештерү комиссияләре карары башка депутатлар өчен язылмаган закон булып исәпләнде. Гадәттә, парламент бу карарларны бертавыштан хуплый иде.

Конституция проекты тикшерелгән көннәрдә Ирек мәйданында күпсанлы плакатлар күтәреп килгән халык диңгезе чайкалды. Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт һәм башка шәһәрләрдән халык бирегә автобусларга төялеп килде. Милли азатлык хәрәкәте оешмалары көне буе митинглар үткәрделәр. Конституцияне тизрәк кабул итүне, суверенлыкны ныгытуны таләп иттеләр.

Хокук саклау органнары хезмәткәрләре дә йоклап ятмады. Яхшы коралланган омончылар, милиционерлар ул көннәрдә парламент бинасы тирәсенә чамадан тыш күп тупланды. Югары Совет бинасына үткәнче документларны кат-кат тикшерделәр. Ул тарихи көннәрдә эчке эшләр органнары хезмәткәрләре өчен Ирек мәйданы, аның белән тоташкан урамнар төп эш урыны булды дисәм, гаделлектән әллә ни ерак тайпылмамдыр дип уйлыйм. Парламент бинасы каршында өсте брезент белән ябылган дистәләрчә машиналар кизү торды. Алардагы кулларына автоматлар тоткан омончылар, беләк буе кып-кызыл телләрен асылындырып торучы, ерткыч бүреләрне хәтерләткән этләр әле дә күз алдымда. Ярый әле автоматлар ходка җибәрелмәде. Этләр дә машиналарда гына утырдылар.

Хәтеремдә, милләтче депутатларның кан дошманы, «Народовластие» депутатлары төркеме лидеры Иван Грачев Ирек мәйданындагы митингны туктатуны, мәйданны халыктан бушатуны таләп итте. Янәсе, урамдагы халык депутатларга эшләргә комачаулык тудыра.

Сессия эшендә тәнәфес игълан итәргә туры килде. Шулай да милиция хезмәткәрләре Ирек мәйданын халыктан бушата алмадылар. Берәү дә мәйданнан китмәде. Шуннан соң бер төркем депутатлар урамга чыгып, халыкны Конституция кабул итүнең ничек барышы белән таныштырдылар, мөмкин булганның барысын да эшләргә вәгъдә бирделәр. Хәзерге халыкның Ирек мәйданыннан китеп торуын сорадылар. Бу сүзләр дә нигездә мәйданны үз кулларында тотучы Чаллыдан килгән «Азатлык» яшьләр оешмасы егетләренә тәэсир итмәде булса кирәк.

—Безгә Марат абый чыгып әйтсен,—диде егетләрнең берсе.—Ул әйтмичә урыннарыбыздан кузгалмаячакбыз.

Чыннан да, халык алдында чыгыш ясаучы депутатлар арасында нигәдер ул вакытта Марат Мөлеков күренмәде. Югыйсә, сессиядә нинди мәсьәләләр каралуы, нинди карарлар кабул ителүе хакында төшке ял вакытында һәм кичләрен халыкка җиткереп баруны үзенең намус эше дип саный иде. Мин аның чыгышларын күп тапкырлар тыңладым. Гомумән, Марат Мөлековның



*Югары Совет бинасы түбәсенә флаг элү күренеше.*

милли хәрәкәттә катнашучылар арасында абруе зур иде. Аны бары тик үзләре лидер булырга омтылучы кайберәүләр генә яратып бетермәде. Өлкә комитеты шпионы, җитәкчеләр белән астыртын эш йөртә дигән һәм башка шундый уйдырмалар уйлап чыгарып, аның исемен пычратырга тырыштылар. Бу—кечелек чире иде.

Ул көнне Марат әфәндене тиз эзләп таптылар. Зур-зур атлап кайдандыр килеп чыкты да, нәрсәнедер хәтеренә төшерергә теләгәндәй, ашыкмыйча гына күзлек пыялаларын сөртеп алды. Аннары калын тавышы белән бөтен мәйданга болай дип мөрәҗәгать итте:

—Иптәшләр, хәл бик җитди. Без тырышырбыз. Хәзергә сез опера һәм балет театры янына китеп торыгыз. Кирәк булсагыз, бик тиз хәбәр итәрбез.

Берничә минуттан мәйдан бушап калды. Сессия эшен дәвам итте...

Конституция кабул ителү, әлбәттә, дәүләтчелегебезне кире кайтару юнәле-шендә гаҗәеп зур вакыйга булды. Хәтта депутатлар да бер-берсен котладылар. Сессия утырышы тәмамлануга бу вакыйганең истәлеге итеп, депутатларга сәгатьләр тапшырылды. Кичен Югары Совет ашханәсендә аш мәҗлесе үткәрелде. «Народов-ластие» депутат төркеме лидерлары гына тантаналарда катнашмадылар. Сессия утырышы бетәр-бетмәс алар кайтып киттеләр. Күрәсең, Конституция кабул ителүгә ризасызлыкларын шул рәвешле белдерделәр. Ничек кенә булмасын, яңа Консти-туциядә Татарстанның хокуклары киңәя төшүе, яңа статусы законлаштырылды.

90 еллар башында: «Татарстан Россия составыннан чыгармы?»—дигән сорау еш бирелде. Әмма Татарстан җитәкчелеге мондый максатны куймады. Конституциядә дә Татарстанның Россиядән чыгуы турында маддә юк, ул үзенең территориясе чикләрен дә үзгәртмәде. Хәер, Татарстанның Россия составына кергәне дә булмады. Халкыбыз тарихында андый факт юк. Татарстан урыс дәүләтенә көчләп кушылган икән—анысы инде икенче нәрсә.

Конституциянең 61 маддәсендә Татарстан Республикасының Россия Федерациясе белән вәкаләтләрен һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы Шартнамә нигезендә ассоциациялəшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуы ассызыклана. Төп Законда гражданлык мәсьәләсе яңача хәл ителгән. Татарстанда яшәүчеләрнең барысы да бер үк вакытта Татарстан һәм Россия гражданлыгына ия. Татар һәм урыс телләре—дәүләт телләре.

Башта Декларация, аннары Конституцияне кабул иткәндә Россия белән бергә, тату яшәү максат итеп куелды. Турысын әйткәндә, тулысынча мөстәкыйль яшәргә Татарстан әзер дә түгел иде әле. Шулай да Татарстан хокукларының Россиянеке белән тигезләгән көн тәртибенә куйды. Моңа аның хакы да бар иде. Чөнки Татарстанның Россия субъекты булганы юк. Субъектлык мәсьәләсе Декларациядә дә, Конституциядә дә күрсәтелмәде. Әгәр Татарстан субъект, ягъни Россиянең бер өлеше булса, аның белән тигез хокуклы Шартнамә төзүне максат итеп куя алмас та иде.

Шартнамәгә кул куелган көннән соң вакыт күбрәк узган саен, бу документның тарихи әһәмияте тагын да ныграк күренә бара. Билгеле булганча, Шартнамә бик авырлык белән туды. Россия җитәкчелеген Татарстан вәкилләре белән бер өстәл янына утырып вәкаләтләр бүлешү хакында сөйләшүләр башлауга күндерү күп көч, ихтыяр ныклыгы таләп итте. Өстәл янына утыргач та, Татарстан делегациясе әгъзаларының законлы таләпләрен ишетергә дә, аларны аңларга да теләмәделәр. Бу хакта миңа Татарстан делегациясе җитәкчесе Василий Лихачевның, аның урынбасары, академик Индус Таһировның, сөйләшүләрдә катнашкан Татарстан халык депутатлары Гелий Кобелевның, Марат Галиевнең, Алексей Колесникның ныклы дәлилләр белән күп тапкырлар сөйләгәннәре бар. Шулай да Татарстан инде үзенең Конституциясендә беркетелеп, яшәү нормасына әйләнеп барган ниятеннән—Россия белән мөнәсәбәтләрен ике яклы Шартнамәгә нигезләнеп корырга җыенуыннан тайпылмады.

Сөйләшүләрнең барышы матбугатта киң яктыртылды, халыкка җиткерелде. Делегация Мәскәүдән кайткан саен журналистлар өчен матбугат конференциясе үткәрелде. Иң четрекле сорауларга да җаваплар алына иде. Бу конференцияләрдә, гадәттә, Президент үзе дә катнашты. Шунысы да игътибарга лаек: Шартнамә тексты бер үк көчкә ия булган татар һәм урыс телләрендә әзерләнде. Мондый хәл, беренчедән, Татарстанда ике дәүләт теленең берсе булган татар теленә хөрмәт буларак кабул ителсә, икенчедән, билгеле дәрәҗәдә Татарстанның Россия белән тигезләгән тану иде.

Делегация Мәскәүгә китәр алдыннан татар хәрефле язу машинкасын бөтен Казан буйлап эзләделәр. «Ватаным Татарстан» газетасе редакциясе машинкасын алып киттеләр. Күрәсең, Мәскәүдә татар машинкасы калмаган булгандыр. Менә ул «бөек» урыс теленә генә игътибарның җимеше! Шартнамә текстын кабат басарга туры килсә-нитсә дип делегация белән бергә машинистка сыйфатында Мәскәүгә «Шәһри Казан» газетасе редакциясе хезмәткәре Сәкинә Алтынбаева барды.

Татарстан Конституциясен Россия рәсми төстә танымады, бу уңайдан Мәскәүдән котлау килмәде. Шартнамә «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының тулы вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә таянып...» диган сүзләр белән башлана. Шулай итеп, Татарстан Конституциясе Шартнамә кабул итепү белән танылды да дип расларга нигез бар. Танылмаган нәрсәгә нигезләнеп булмый бит инде.



*Референдум алды көннәре. Март, 1992 ел.*

Чынлыкта Шартнамә Татарстан һәм Россия Конституцияләрен берләштерүче, алар арасындагы каршылыкларны юкка чыгаручы документ та булып әверелде. Бераз сөеррәк тоелса да, нәкъ менә шуның өчен соңгы вакытларда законнар һәм норматив актлар кабул иткәндә, Шартнамәне хәтта Конституцияләрдән дә өстенрәк куя башладылар. Шартнамәне шулай ук Үзәк белән Татарстан арасында кискен конфликтны бетерүнең цивилизацияле ысулы дип санарга мөмкиндер. Ул һәр мәсьәләне көч кулланып хәл итәргә гадәтләнгән Мәскәү түрәләренә мондый адымга барырга ирек куймады, Россиянең бөтенлегенә дә зыян китермәде. Шунлыктан, халыкара экспертларның республикабызның Үзәк белән мөнәсәбәтләрен «Татарстан моделе» дип атаулары һәм аны дөньяның башка төбәкләрендә дә кулланырга омтылулары очраклы хәл түгел. Чөнки ул кан коюлар урынына үзара татулык тәкъдим итә.

Шартнамә «Татарстан Россия составыннан чыгамы, чыкмыймы?»—дигән сорауга чик куйды. Ул Татарстанның күпмилләтле халкын уртак максатлар тирәсенә туплады. Шартнамә татар халкының гасырлар буена килгән өметен, үз дәүләтен, телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен торгызу турындагы хыялын гәүдәләндерде. Шуның белән бергә, анда республикада яшәүче башка халыкларның да мәнфәгатьләре исәпкә алынды.

Без вәкаләтләребезне Россиягә кирәгеннән артык биреп ташладык, дигән

фикерләр дә булды. Милли хәрәкәтнең кайбер җитәкчеләре хәтта: «Татарстанны Россиягә саттылар»,—дип тә ычкындырдылар. Кайберәүләр исә: «Шартнамәнең беренче проекты бөтенләй башкача иде, аны Лихачев үзгәртеп бетерде»,—дип расларга тырыштылар. Минем бу фикерләрне турыдан-туры Василий Лихачевка да җиткергәнем булды. Ул бу хакта:

—Капма-каршы фикердә торган ике кешене күз алдыгызга китерегез. Әгәр алар бер-берсенә ташламалар ясамасалар, бер вакытта да килешә алмаячаклар. Безгә дә сөйләшүләр барышында кайбер ташламаларга барырга туры килде,—диде Василий Николаевич.—Әгәр кемдер Лихачев үз белдеге белән проектны үзгәртте дип расларга омтыла икән, бусы инде акылсызлык. Билгеле булганча, Шартнамәгә Президент кул куйды. Шунлыктан, аның белән килешмичә бер нәрсә дә эшләнмәде.

Минем В. Лихачев әйткәннәрне шик астына алырлык дәлилләрем юк. Ул вакытларда Василий Николаевич белән даими аралашып яшәүче кеше буларак, шуны гына әйтә алам: ул—дөньякүләм танылган юрист, дипломат. Татарстанның дәүләтчелеген торгызуга, аның абруен күтәрүгә, халыкара масштабта танытуга Василий Николаевич күп көч куйды.

Кайберәүләр Шартнамәне Россияне таркату чыганагы итеп күрсәтергә тырыштылар. Аңа Россиянең Дәүләт Думасында да һөҗүмнәр ясалды, юкка чыгарылуын таләп иттеләр. Ләкин тарих шуны раслады: Шартнамә Россиянең тотрыклылык чыганагына әверелде.

Шартнамәнең аерым маддәләрен тормышка ашыру механизмы сыйфатында хөкүмәтара килешүләр эшләнде. Шул ук вакытта аны эчке законнар белән ныгытасы, башкарма хакимият органнары эшчәнлегендә киңрәк файдаланасы бар әле. Безнең законнар федераль үзәк белән уртак вәкаләтләрне дә ныгытырга тиешләр.

Шартнамә безгә, иң беренче чиратта, үз өебездә хуҗа булып яшәү өчен кирәк иде. Әйтик, килешүләр нигезендә акцизлар үзебездә калды, Мәскәүнең гаҗәеп зур казанына кереп эреп бетмәде. Бу акчалар республикада нефть чыгаруны тотрыкландыру өчен тотылды, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенә салым ташламалары ясалды. Нәтиҗәдә, нефть чыгару дәрәҗәсен елына 25-26 миллион тонна күләмендә саклап калу мөмкин булды. Дистәләгән еллар буе икътисад үсешенең Мәскәү рөхсәте белән алып барылуын, республика мәнфәгатьләренә җавап бирмәвен искә алганда, бу зур җиңү иде. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, ярты гасырдан артык нефть чыгарып, Татарстанның ягулык-майлау материалларына ни өчен һаман да кытлык кичерүен аңлатуы авыр бит.

Банк эше, акча-кредит һәм валюта сәясәте өлкәсендәге килешүгә таянып, Татарстан Милли банкы республика икътисадын үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән мөстәкыйль карарлар кабул итте. 1999 елның 1 гыйнварыннан Милли банкның исәп-хисап-касса үзәкләре әйләнешкә акча чыгаруны мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыралар. Бу исә республикада акча массасы күләменә оперативрак идарә итү мөмкинлеген бирә.

Милек мәсьәләләрендә хөкүмәтара килешүгә нигезләнеп, предприятиеләрнең байтагы Татарстан юрисдикциясенә күчерелде. Хосусыйлаштыру үзебезнең закон һәм норматив база нигезендә гамәлгә ашырылды. Хосусый-лаштырылган предприятиеләр җирлегендә 740 акционерлык җәмгыяте һәм җаваплылыгы чикләнгән 87 җәмгыять булдырылды. Бюджетны формалаштыручы предприятиеләр акцияләренең контроль пакетларын дәүләт үз кулында саклап калды.

Татарстан—Россия хөкүмәтара килешүләре белән халыкны таныштырмадылар. Алар матбугатта да басылмады. Матбугат конференцияләре, шәхси очрашулар вакытында килешүләрнең текстларын бирүләрен сорап Президентка, Премьер-министрга, Дәүләт Советы Рәисенә, бу эшкә катнашы булган башка чиновникларга мөрәҗәгать иттем. Бирмәделәр.

—Башка субъектлар башлыкларының безнең килешүләр белән танышмый торуы хәерле,—диде зур җитәкчеләрнең берсе.

Шәхсән үзем ул килешүләр белән Башкортстан Президенты, Самара губернаторы яки башка төбәкләрнең җитәкчеләре танышмагандыр дип уйламыйм. Татарстан халкын да таныштырырга кирәк иде. Сер итеп сакланган әйбер һәрвакыт кызыксыну тудыра. Мин дә килешү текстларын тапканчы эзләдем. Килешүләр кабул ителүгә үк аларның барысы да инглиз телендәге бер журналда басылган булып чыкты. Бер академик аларны әллә кайчан укыган икән. Мин бу килешү текстларын татарчага тәрҗемә итеп, белгечләрнең аңлатмалары белән ул чагында үзем эшли торган «Шәһри Казан» гәзитәсе

укучыларына тәкъдим иттем. Бу үзенә күрә бер сенсация тудырды.

Хөкүмәтара килешүләрнең барысы да биш елга төзелгән иде. Сөйләшүләр нәтиҗәсендә аларның барысының да гамәлдә булу срогы озайтылды. «Бюджет буенча үзара мөнәсәбәтләр турында»гы килешү зур бәхәс тудырды. Россия җитәкчеләре аны юкка чыгарырга тырыштылар. Татарстанда җыелган салымнарны тулысынча Мәскәүгә күчерергә теләделәр. 13 процент ставка буенча табыш салымы, бер процент ставка буенча физик затлар керемено салым, өстәмә бәяләр салымының 50 проценты, күрәсең, Мәскәү түрәләренә аз тоелгандыр. Татарстан болардан тыш республика территориясендәге федераль программаларны, Россия структураларын финанслау буенча йөкләмә алган берденбер төбәк, югыйсә. Моны да онытмаска иде.

Хәзергә Россиянең Шартнамәләрне ратификацияләү тәртибе эшләнмәгән. Татарстанда да әлегә ул юк. Әмма андый тәртип бик кирәк. Ике яклы мөнәсәбәтләр мәсьәләсендә Татарстанның һәм Россиянең килешенгән сәясәте



*Мәскәү белән Татарстан арасындагы Шартнамәгә кул кую вакытында. Мәскәү, Кремль. 15 февраль, 1994 ел.*

рәвешендә Шартнамәне үтәүне тәэмин итүче гарантияләр бар-барын. Шулай да Шартнамә даими рәвештә ныгытылырга, дөньяның төрле төбәкләрендә үз тарафдарларын күбрәк табарга тиеш. Ул чагында шартнамәләр кирәкме-юкмы дип бәхәсләшергә теләүчеләр булмаячак.

Шартнамәне күзлек киеп, игътибар белән кабат карап чыкканда, кайбер маддәләрнең өлешчә генә үтәлүе күзгә ташлана. Мәсәлән, 8 нче маддә. Анда «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Казан шәһәрендә һәм Мәскәү шәһәрендә вәкаләтле вәкилләкләре бар», диелә. Шартнамәгә кул куелуга алты елга якын вакыт үтеп китсә дә, һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Казанда Россиянең вәкиллеге һаман да ачылмады әле. Моны Россиянең Татарстаннан хеерчерек булуы белән аңлатыргамы, әллә үзен Татарстан белән тигез дип санарга теләмәүме бу?

Яңа типтагы федераль дәүләт төзү принципларын тарихтан да табарга була. Хезмәт ияләре һәм эксплуатацияләнүче халыклар хокуклары декларациясе, Советларның III Бөтенроссия съездының федераль учреждениеләр турындагы резолюциясендә федерациянең гомуми билгеләре генә күрсәтелде, ә анда катнашу-катнашмау республикаларның үз эше дип билгеләнде. Һәр милләт үзенең тулы вәкаләтле съездында федераль хөкүмәттә һәм аның органнарында ни дәрәҗәдә катнашачагын билгеләргә тиеш иде. Федераль һәм җирле хакимиятнең эшчәнлек даирәсен чикләү дә каралды.

Әмма тора-бара боларның барысы да онытылды. Россия тоталитар дәүләт буларак яши бирде. Шулай да заманалар үзгәрә. Бүген без

цивилизация бусагасында торабыз, төрле милләтләр мәнфәгатьләренә җавап бирерлек федерация төзергә телибез. Федератив килешүгә кул куйганда, Башкортстан үзенең бюджет һәм салымнар буенча хокукларын искәртте. Якутия-Саха башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен мөстәкыйль урнаштыра. Хәер, федерация субъектларының чит мәмләкәтләр белән шартнамәләр төзү хокукы бөтен дөнья күләмендә танылган. Әлеге хокукның федераль Конституциядә беркетелүе мәҗбүри дә түгел. Әйтик, Австрия һәм Германия җирләре, Австралия һәм Америка штатлары, Канада провинцияләре, Бельгия общиналары халыкара шартнамәләрне турыдан-туры төзиләр. Моннан үзәк мәнфәгатьләренә һичнинди зыян килми.

Тарихи яктан шулай килеп чыкты ки, җиде миллионлы татарның яртысыннан кимрәк өлеше генә Татарстанда яши. Җир шарына сибелгән милләттәшләребез мәнфәгатен кайгырту өчен Татарстан суверен дәүләт буларак, башкалар белән (шул исәптән Россия белән дә) тигез дәрәҗәдә эш итәргә тиеш. Чөнки хокуклар тигез булганда гына мөһим проблемалар буенча уртак тел табарга була.

Россиянең Юстиция министрлыгы һәм башка ведомстволары төбәкләрнең Конституцияләрен Россиянеке белән яраклаштыруны таләп итәләр. Әмма күпчелек республикаларның Конституцияләре Россиянекеннән алданрак кабул ителде. Шунлыктан, Россиянең 1993 елгы Конституциясе проектын эшләгәндә аларны искә алырга кирәк иде. Әйтик, республикаларның бер өлеше үзләрен суверен дәүләтләр дип игълан иттеләр. Әмма бу Россия Конституциясендә чагылыш тапмады, аларның барысы да субъектлар булып калды. Конституциядә федерациягә керү һәм аннан чыгу ысуллары күрсәтелмәгән. Бу исә БМО уставына һәм 1966 елгы халыкара кеше хокуклары пактына каршы килә. Югыйсә, милләтләрнең тигезлек һәм үзбилгеләнү принципларын хөрмәт итү һәркемнең бурычы. Кыскасы, формаль рәвештә федерация дип аталса да, Россия беркайчан да чын федерация булмады. Татарстан кул куймаган федератив килешү дә республика өчен кирәк булган вәкаләтләр күләменә җавап бирмәде. Үзәк белән мөнәсәбәтләрне чикләү буенча Татарстан тәкъдим иткән юл чын демократик федерациягә күчү механизмын табарга ярдәм итте.

Күпмилләтле Россиянең дәүләт төзелеше мәсьәләсе, мөгаен, барлык сәяси проблемаларның иң катлаулысыдыр. Ул максималь җаваплылык таләп итә. Субъектларның мәнфәгатьләре белән кызыксынмыйча, республикаларны өлкәләр, крайлар белән берләштерергә тәкъдим ясаучылар да булды. Янәсе, субъектларның саны кирәгеннән артык күп, идарә итү өчен авыр. Россия дәүләт төзелеше проектларының кайбер вариантлары матбугатта да басылып чыкты. Премьер-министр булып эшләгән чагында бу идеяне Евгений Примаков та хуплаган, диләр. Ләкин ничек кенә булмасын, суверен дәүләтләр Россиянең империячел сәясәтчеләр идеясен хупламаячаклар, дәүләтчелекләрен югалту белән ризалашмаячаклар. **«Татарстан берьяклы гына тәртиптә үзенең статусын үзгәртергә, республиканы өлкәләр һәм крайлар белән тигезләргә ирек бирмәячәк. Республика—үзенә хас барлык атрибутлары булган дәүләт ул, һәм без бернинди дә «губерналашу»га риза булмаячакбыз. Россия үзенең төбәкләре этник, мәдәни һәм икътисади яктан гаять күптөрле булган үзенчәлекле бик зур ил. Мондый дәүләттә котылгысыз рәвештә ассимитрик федерация барлыкка килә—ул аның халәтенә җавап бирүче бердәнбер форма»**,—диде Президент Минтимер Шәймиев Дәүләт Советына 1999 елгы бюджет юлламасында.

Татарстанны әвелгечә Россия составындагы гап-гади бер автономия сыйфатында сакларга тырышучылар да, Мәскәү белән элемтәләрне тулысынча өзәргә чакыручылар да бар. Бүген карашларның тегесе дә, бусы да кабул ителерлек түгел. Үзара мөнәсәбәтләрдә иң кулай юлны табу зарур. Россиядә миллионлаган милләттәшләребез яшәвен дә истә тотмый булмый. Татарстан аларның мәнфәгатьләрен кайгырту өчен Россиянең милли сәясәтенә җитәрлек дәрәҗәдә йогынты ясарга тиеш. Бу төрле төбәкләр белән килешүләр төзегәндә дә истә тотыла.

Россия җитәкчеләре федерациядә яшәүнең яхшырак булуын, бер милләтнең дә хокукына, милли республикаларның суверенлыгына зыян килмәвен үзләренең эшчәнлекләре белән расларга тиешләр. Хәзергә Россия җитәкчелеге, беренче чиратта Президент, милли республикаларга йөз белән борылмадылар. Аларның суверен дәүләт булулары белән килешергә теләмиләр. **«Донор төбәк буларак, без Финанс министрлыгы коридорында кулыбызны сузып утырмаячакбыз.**

**Без кичә дә алай эшләмәдек. Бүген дә алай эшләмибез. Иртәгә дә алай эшләмәячәкбез,**—диде М. Шәймиев 1998 елның 28 октябрендә Саранскида «Зур Идел» ассоциациясе Советы утырышындагы чыгышында.

Татарстанның суверенлык Декларациясе игълан ителгәннән соң парламент күп кенә законнар кабул итте. Аларның бер өлеше турыдан-туры дәүләтчелегебезне ныгытуга карый. Татарстанның сәяси хокукый системасының нигезен тәшкил итүче структураларны төзү дәвам итә. Соңгы вакытта «Конституция суды турында»гы законга өстәмәләр кертелде. «Иминлек Советы турында» Закон чыкты. «Татарстан Республикасының кеше хокуклары буенча вәкаләтле заты турында» Закон проекты беренче укылыш узды. Болар барысы да республикада реаль демократиянең яңа институтларын торгызуда мөһим уңышлар.

Әмма шунысы да бар: парламент эшчәнлегендә кайбер тискәре күренешләр дә традициягә әйләнеп бара. Әйтик, яңа законнарның бер өлеше Конституциягә каршы килә. Шуңа күрә Төп Законны туктаусыз ботарлыйлар, аңа өстәмәләр, төзәтмәләр кертәләр. Югыйсә, яңа законнар эшләгәндә гамәлдәге Конституциягә нигезләнеп эш иткәндә дә начар булмас иде. Хокукый дәүләтләрнең тәҗрибәсенә күз салу да зыян итмәс кебек. Бу мәкаләне әзерләгәндә мин Америка Кушма Штатлары дәүләтчелегенә кагылышлы кайбер документлар белән танышып чыктым. Әйтик, барлык унөч штат тарафыннан да 1776 елның 4 июлендә кабул ителгән мөстәкыйльлек декларациясе һаман да гамәлдә. Аңа үзгәреш-фәлән кертелмәгән. АКШ Конституциясе 1787 елның 17 сентябрендә кабул ителгән. Шушы вакыт эчендә Конституциягә 5 меңгә якын өстәмә тәкъдим ителгән, әмма аның бары 26 сы гына кабул ителгән. Конституциягә төзәтмәләр кертелгән дип әйтү дә дөреслеккә туры ук килеп бетмәс иде. АКШ Конституциясе үзгәртелмәгән. Өстәмәләр аңа кушымта буларак кына йөри.

Соңгы елларда дәүләтчелегебезне торгызу буенча кайбер адымнар ясалса да, тынычланырга иртә әле. Татарстанның суд, хокук саклау системасы эшләнмәгән. Таможня керемнәре тулысынча Мәскәүгә китә. Гражданлык мәсьәләсе ачыкланмаган. Югыйсә, сессиядә тикшерелгән закон проекты, экспертларның әйтүенчә, халыкара нормаларга тулысынча туры килә. Кесәләребездә һаман да СССР паспортлары. Республикада хокук реформалары үткәрү турында күптән сүз бара. Ләкин сүз реформа түгел шул әле.

Гомумән, соңгы вакытларда республикабыз житәкчеләре Россиядә реформалар үткәрүгә көчләрен дә, вакытларын да артыграк сарыф итәләр кебек. Шунлыктан дәүләтчелегебезне ныгытуга багышланган проблемалар һаман да икенче планга чигерелә. Вакыты-вакыты белән теләкне реаль чынбарлык итеп күрсәтергә омтылыш та сизелә. Әйтик, һәр тантаналарда, зур киңәшмәләрдә, «Без башка төбәкләргә караганда яхшырак яшибез»,—дигән гыйбарә кабатлана. Кемнәрдер яхшырак яшидер дә. Әмма мин республика халкының күпчелеге хәерче хәлендә дигән карашта торам. Чүплектә казынучы пенсионерларны иртән эшкә барганда көн дә очратам. 4-5 йөз сум хезмәт хакы алып эшләүче журналистларны да яхшы яши дияргә тел әйләнми. Минем күрше бер зур берләшмә генераль директорының Идел буендагы коттеджын саклый. Минем бу коттеджда булганым юк. Шулай да иманым камил, бу директор бездән бик күпкә яхшырак яши дип раслый алам.

Иң мөһиме—халык иртәгесе көнгә ышанычын югалтмасын. Дәүләтчелегебезне торгызу юлында кылынган һәр гамәл халык өчен эшләнсен! Һәркемнең шатланып эшләве, шатланып яшәве өчен шартлар тудыру зарур бит.

Мөстәкыйльлек юлы сикәлтәле, авыр. Татарстан бу юлда беренче адымнарын гына ясый әле. Юлның калган өлешен житезрәк үтсәк иде. Кабаттан искәртәм: Татарстан яңа гасырда да, академик Әбрар ага Кәримуллин образлы әйткәнчә, Россия арбасына тагылган дегет чиләге булып йөри алмый бит инде. Килешми. Тарихыбыз татарларның горур халык булуын раслый. Гасыр бусагасын атлаганда шушы хакта тагын бер кат уйланыйк әле.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында җитди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?**

## Сәгыйть Хафизов:

XX гасырдан XXI гасырга күчү иске ызбадан өр-яңа өйгә ташыну сыман бер хәл булсын иде. Шулай булса, мин ике чор арасына таш дивар корып куяр идем. Һәм кешелек, бигрәк тә мескен Рәсәй халкы, бер көн яисә төн эчендә бөтен аһ-зарлардан, шыксыз, ямьсез, караңгы тормыштан араланып яңа мәгыйшәт башлап китәр иде.

Тылсымлы әверелешләр шаһиты булсам, әдәбиятыбызны да читтә калдырмас идем. Ул да мунча кергән сыман сафланып, һәйбәтләнеп яңа гасырга аяк бассын иде. Мөгаен, мин аны иң элек вакыт иллюзиясеннән арындырыр идем. Юк, язучыларыбызның ярты гасыр буена нинди дер ерактагы коммунизм хыялы белән кешеләр башын катырган шаукымны әйтмим. Ул беткән инде. Ә менә вакытның иҗаттагы аерым мәкерлекләре хакында уйланасы да уйланасы әле.

Чынлап та нәрсә ул вакыт? Кеше кулы белән көйләнгән маятник талпынуы дип карарга була аны. Яисә Җирнең көннән-төнгә, төннән-көнгә, фасылдан-фасылга бер көйгә хәрәкәте дип тә аңлатырга була вакытны. Бәни адәм үзе өчен вакытны таяк кебек ике очлы бербөтен санар. Аның бер очы туу булса, икенче очы үлем дип аталыр... Тик шулай да адәм үз күзләре белән күрмәс, куллары белән тотмас вакытны. Нәкъ шундый күз күрмәс, кул тотмас үзлекләре булганга, берәүләр аны милади, ә икенчеләре хиҗри белән санап, исәпләп яталар да бит инде.

Тик битараф вакытны кешеләр үзләре илаһилаштыралар. Ана әллә нинди булган-булмаган үзлекләр, сыйфатлар тагалар. Су кебек өзлексез агуына карамастан, Кара Хәким һәм яраннары аны заман, дәверләргә аерып төрле сәясәтләр коралар һәм бер вакытны хурлап, икенчесен бизәп халык алдыйлар. Вакыт иллюзиясе, вакыт ялганы дигәнем шуннан килеп чыга да инде. Язучылар сукыр рәвештә рәсми, сәяси карашларга ияреләр, идеологик стереотиплар колы булалар.

Сәвит чорындагы әдәби анда Октябрь инкыйлабы тарихтагы төп ызан һәм иң бөек багана булып торды. Шулай ук, кешене тасвирлауда да иң мөһим чик иде ул. Теге якта, капитал хөкем сөргән мохиттә, кеше бәхетсез, аны, куллары богаулы, ә бу якта, азатлык һәм ирек кояшы балкыган илдә, кешегә һәрьяктан бәхет юллары ачык, янәсе...

Әмма Сәвит заманасын бетереп, демократия дигән дәвергә кучеп өлгермәдек, язучыларыбыз Кара Хәким куштаннары булып социализмның үзен каһәрләргә керештеләр. Бу—иң золым-зольмәтле мохит икән. Коммунистлар хакимияте кешене утта яндырып суга салган, ирке жиде кат йозакта булган аның...

Әлбәттә, гөнаһларның олысы мәкерле сәясәт коручыга. Әллә асыл шундый, әллә Ходай каргаган, илгә һаман Кара Хәкимнәр килә. Үз заманаларын көйләп, яхшырту мәшәкатьләренә чуму урынына, нишләптер, гел кешенекен хурлау, корганны вату белән алга барырга җыеналар болар. Ә шул гөнаһлы шөгыльне хуплаган язучылар исә икеләтә гөнаһлы.

Бердән, вакыт иллюзиясенә бирелеп схема кора, шаблон ясый, әмма барыбер Кара Хәким зәвыгына туры килгән әсәр әмәлли язучы. Без, бәни адәмнәр, барыбыз да алсу канлы, бердәй биш тойгылы, саваплар һәм гөнаһлар дәфтәренә ия булсак та, әдипләребез халыктан әллә нинди ижтимагый типлар, аклар-кызыллар, уңнар-суллар, тагын башка өммәтләр ясап, кешене кешегә каршы куйдылар. Бер үк мохит, бер үк ил дошманнар өеренә әйләнгән сыман. Кешегә кешене аңларга, бер-берсенә якынайтырга һәм үзара хөрмәт хисләрен үстерергә тиешле әдәбият шундый буламы соң? Бигрәк тә демократия заманы әдәбияты?

Икенчедән, вакыт иллюзиясенә бирелгән язучы кешене дә вакыт колы ясый түгелме? Әлбәттә, кеше язмышы заманага, шартларга бәйле, аның бәхете мохиттән тора, дип раслаган язучыны гөнаһлы дип санау үзе үк гөнаһ сыман. Чөнки социаль-психологик детерминизм, ягъни кеше холкы һәм фигыленең социаль шартларга бәйле булуын раслау—реалистик иҗатның олы мәртәбәсе. Әмма иң йомшак, иң шифалы саналган суны да тамчылап агыза торсаң, су да таш тишә... Әдәбиятта да киң фронт булып һәм бер үк стильдә фаталь мохит идеясен тәкрарлап торсалар һәм ул катгый формула рәвешендә мигә сеңдерелеп торса, ай-һай, мондый аң зомбилыктан котылырмы? Кеше рухын иркле ясарга Ходай кушкан әдәби иҗат, димәк, күпләребезгә фаталь язмыш колына әйләнергә булыша... Чынлап та, фән-техника могҗизалары ясалган, рухи зынҗырлар коелган заманда яшәсә дә, безнең XX гасыр азагы язучысының фаталь язмыш идеясен илаһилаштырган борынгы әдиптән яисә мистик суфи шагыйрьдән нинди аермасы бар? Ул да тегеләр кебек, әмма катлаулырак психологик нечкәлекләр белән, адәмне матур замана, яхшы патша килүен көтәргә дә, Алла мәрхәмәтенә өмет тотарга чакыра бит... Мондый әдәбиятта Җан бөеклеге, геройлыгы яисә трагедиясе юк. Җан хәрәкәте юк. Ахыр чиктә бәни адәмне алга, яхшы тормышка, матурлыкка дәртләндергән рух, ирекка чакырган мотив юк.

Тоталитар режим белән бергә формалашып, үзенә аның рухын сеңдергән әдәбиятыбыз демократлар кулында да һаман үз асылында кала. Бары тик тормыш материалы, геройларның статусы үзгәрә дә, язучы пафосы алмашына. Ә кеше концепциясе, геройны тасвирлау алымнары һаман да искечә кала әле. Дәресрәге, элеккечә кешене вакыт иллюзиясе, замана, мохит кебек категорияләр томалый, сәяси идеяләр, конъюнктурлык һәм иллюстрацияләр стихиясе күмеп китә.

Нәкъ шуна күрә XXI гасыр әдәбиятын вакыт иллюзиясеннән, аның мәкерлекләреннән арындырыйк, дип чаң сугам да бит мин. Тик ялгыш аңламасыннар, чын, гадел вакыттан һәм реализмны реализм иткән принциплардан, детальләр дөреслегеннән түгел. Әлбәттә, заманалар һәм кешеләр буталып, болгавырлык шаукымы көчәйгән чакта, «Кайда сез, романтиклар?»—дип тә сөрән

саласы килә. Чөнки иркен, хыялый дөньялы романтикларның күзләре үткенрәк, хис-омтылышлары ярсуырак. Замана лаеклы матурлык сынын, геройлар рәвешен дә алар тизрәк табып бирерләр иде. Әмма бүгенге базар заманында Сәгыйть Рәмиев, Һади Такташ, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил кебек романтикларны кайдан табасың?

Вакыт образын бирүдә Кара Хәкимнәр, сәяхәтчеләр артыннан бармыйча, әдәбиятның үз юлын, нечкәлекләрен, мөмкинлекләрен барлау һәм куллану, әлбәттә, камилләшү өчен иң төп юл. Иң мөһиме заманага, кешеләргә калып кидермәскә кирәк. Гомумән, иҗат өчен шаблонлык һәлакәт бит ул. Әдәбиятның башка мөһим категорияләрен, әйтик, хәрәкәт, урынны гәүдәләндергәндә язучылар моңардан сакланалар ласа. Мәсәлән, хәзерге әсәрләрнең кайсыларында бер үк сюжет яисә игезәк пейзаж күргәнегез бар? Боларда үзен ачар өчен язучы әлләникадәр тир түгә. Шулар сыман вакыт сурәте дә һәрчак оригиналь булырга тиеш. Бу—иҗат таләбе. Ә инде заманга карата язучы мөнәсәбәте дә ихласлыкка, шәхси нигезгә корылса, киләчәк иҗат, мөгаен, эчпошыргыч, стандарт вакыт сурәтләреннән бөтенләй арынып иде.

Әдәбиятта мохит концепциясендә дә әзер, каткан схемалардан котылу кирәк. Иҗат практикасында да, галимнәр фикерләвендә дә, нишләптер, һәрчак мохитнең кешегә карата өстенлеге, доминантлыгы ассызыклана. Үз вакытында антиномия күренеше буларак, рус философы Г. В. Плеханов искәрткән: «Карашлар тирәлек белән, тирәлек карашлар белән билгеләнә»... Ягъни мохит кешене формалаштырса да, үз чиратында кеше дә мохиткә йогынты ясый. Чынлап та, кешенең тирәлек, мохиткә карата үзгәртү-кору куәте булмаса, тормышта, тарихта янарыш, алга китеш була алыр идеме? Юк! Әдәбият кешесе өчен бу хакыйкать тә бик кирәк. Һәм, безгә калса, киләчәк әсәрләрдә ул ныграк гәүдәләнеш табачак. Ышаныч тормыштан килә. Язучыларыбыз кешене мохит колы ясап бик еш фахишә, зиначы, эчкече, карак-угры, хәтта үтерүче хәленә төшүен күрсәтергә яратсалар да, халык сын响кка сылтау табып адәмлекләрен югалтканнарны бервакытта да акламады. Халык көчлене, тугрыны олылый, булдыклыны ярата. Ә мондый кеше берчакта да үз фаҗигасендә кешеләрне гаепләү түбәнлегенә төшми. Төп гаепне тугры адәм үзендә, гамәлендә, хәлләрдә күрә. Һәм бары тик эчке, әхлакирухи дөнья мөмкинлекләрен барлау, шуларны эшкә җигү генә кешене камиллеккә, яхшыга, югарылыкка әйди. Кыскасы, шуларны уйлыйсың да, әдәбиятта әхлаки үзәге көчле, кешеләр каршында җаваплылыгы зур, тирәлеген унай якка үзгәртергә сәләтле олпатлы, чын һәм натураль кешеләрне күрү теләге көчәя.

Мәгълүм үзенчәлеккә ия булган геройлар, сөенечкә, милли әдәбиятыбызда бар. Муса Акъегет үзенең 1886 елда чыккан «Хисаметдин Менла» әсәрен «Милли роман» дип билгеләгән. Бер яктан иске Шәрекъ әсәрләренә ияреп кыйссалар язу, икенче яктан рустан тәрҗемәләр кылу гадәтләре ташкын сыман хәрәкәт тәшкил иткән чорда, язучы сәер жанр атамасы белән иҗатының тормышыбызга тоташуын искәрткән. Чынлап та, М. Акъегеткә кадәр татар тормышын милли рух, милли омтылышлар белән сугарып сурәтләгән бөек әсәр юк иде әле. Аның дөньяга чыгуына инде гасырдан артык. Әмма заманаларда никадәр якынлык. Шул ук рухи, социаль торгынлык, хәерчелек, фәкыйрьлек... Тик М. Акъегет геройлары Хисаметдин, Әбүзәр, Гайса, Мохтар һәм Ханифә албасты-мохиткә, аның кануннарына каршы кылычсыз көрәшкә күтәрелгәннәр. «Уйганыңыз, кардәшләр, уйганыңыз!»—дип алар халыкны да искелектән, хорафаттән арындырырга, кәсеп итеп һәм иҗтиһад кылып мәгыйшәтне яңартырга чакыралар. Һәм шул юлда Акъегет геройлары үзләре дә соклангыч ныклык, оешканлык күрсәтәләр.

А. Шамовның 1926 елда язылган «Рәүфә» повесте шул елларның яңгыравык вакыйгаларын, шанлы каһарманнарын сурәтләгән китаплар арасында югалып, кичерәеп калгандыр. Әмма канлы вакыйгалар әһәмиятен җуйды, крепость, калалар алган геройлар онытылды. Ә менә гап-гади татар килене Рәүфә чор герое булып калка бара. Чөнки ул үз мохите, үз дөньясындагы киртәләрне горур атлап үтәрлек, шәхесен расларлык көч-куәт тапкан.

Тыштан зәгыйфь, хәтта шөкәтсез булып күренсә дә, Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» (1957) повестендагы ат караучы Нәби дә үзенең эчке дөнья

ныклыгы, тормыш кануннарына баш имәве белән сокландыра. Бигрәк тә аның «ир язмышы—ил язмышы» дип үз өстенә салган йөкне ыңгырашмый күтәрүе, олы йөрәкле булуы таң калдыра.

Зур принциплар белән яшәгән көчле кеше чагылышын мин янә замандаш язучыбыз Ф. Садриевның «Таң жиле» (1992) романындагы Нуриасмада күрдем. Кешеләр галәмендә синең ныклыгыңны ничек кенә сынамыйлар. Әмма гади, бер сүзгә бәйләнгән «әйе», яки «юк» сынавы шулар арасында иң каһәрлесе, газаплысы... Хатын «юк», дип гадәтләрне кире какса—кага, үзенә нәфрәт җыйса—җыя, әмма мохитеннән барыбер бер башка югары күтәрелә. Хакыйкать хакына, гаделлек хакына, алга атлау хакына күтәрелә ул.

Бүгенге матди һәм рухи көрчеккә терәлгән тормыш кешеләренә сазлыктан, торгынлыктан чыгар өчен көчле, зирәк мәгънәви юлдашлар кирәк. Тормышыбыз финанс инвесторларына гына түгел, мораль-әхлак инвесторларына да кытлык, сусау кичерә.

XXI гасыр тарихта, цивилизация юлында тагын бер баскыч өскә күтәрелеш тәэмин итә алса, киләчәк язучылары зирәгрәк булырлар, М. Акъегет, А. Шамов, Р. Төхфәтуллин, Ф. Садриев геройлары кебек көчле, омтылышлы, иҗтиһадлы каһарманнарны ишәйтерләр.

## РЕДАКЦИЯДӘН:

Соңгы елларда матур бер традиция барлыкка килде—язучыларны һәм киң катлам укучыларны борчыган, уйландырган мәсьәләләр турында журнал битләрендә фикер алышулар, дискуссияләр даими рәвештә үткәрелә башлады. Редакция фикеренчә, мондый алым журналны эчтәлек ягыннан тагын да кызыклырак итеп кенә калмый, ә әдәбиятның һәм тормышыбызның аерым проблемалары хакында объектив бәя, мөнәсәбәт булдыруга да булыша. Димәк, ул чаралар әдәби процессны җанландыруга ярдәм итә, ахыр чиктә тулаем мәдәни үсешебезгә булыша.

Шушы елның гыйнвар аеннан башланып киткән «Туксанынчы еллар әдәбияты» дигән анкета җавапларын да журнал укучыларыбыз әлеге матур традициянең бер чагылышы дип кабул иттеләр. Редакция тарафыннан куелган сораулар язучылар һәм әдәбият галимнәре, әдәби тәнкыйтьчеләр, укучылар арасында җанлылык тудырды, кызыксыну уятты.

«Туксанынчы еллар әдәбияты» дигән сөйләшүдә барлыгы егермегә якын авторның язмасы урнаштырылды. Алар арасында галимнәр, күренекле әдипләр һәм шагыйрьләр, драматурглар, публицистлар, танылган тәнкыйтьчеләр, әдәбият сөючеләр бар иде.

Куелган сорауларга җавап бирергә алынган күп авторлар билгеләп үткәнчә, тормышыбыз һәм аның көзгесе булган татар әдәбияты соңгы елларда, чыннан да, зур үзгәрешләр кичерде.

Үзгәрешләрнең иң җитдие, иң мөһиме, әлбәттә, рухи яшәешкә карый. Һәм ул илебездә озак еллар буена хакимлек иткән рәсми идеологиянең җимерелүе белән бәйләнгән. Анкета сорауларына җавап бирүдә катнашучылар басым ясап әйткәнчә, туксанынчы еллар ахырында һәм яңа мең еллык бусагасында коммунистик идеологиягә шулай ук берьяклы гына карарга ярамый.

Әйе, Совет власте чорында халыкка каршы зур җинаятьләр эшләнде, миллионлаган кешеләр бер гаепсез корбан ителде. Болары—ачы хакыйкать. Ләкин, шул ук елларда күпчелек гади кешеләрнең рухи-мәдәни омтылышлары чыңга ашты, аларның белем алу һәм ил тормышында актив катнашу мөмкинлеге туды. Ул елларда әдипләребез байтак классик әсәрләр тудырдылар. Татар матбугатын һәм татар китабын татарлар яшәгән һәр төбәктә диярлек табып һәм укып була иде. Әдәби журналыбыз «Казан утлары» да йөз меңләгән тираж белән бөтен ил буенча таралды. Сәяси яктан алсак, татар халкының егерменче гасырдагы тәүге дәүләтчелегенә дә нигез, гәрчә автономия рәвешендә генә булса да, әнә шул совет власте елларында салынды.

Соңгы елларда алынган сүз ирегән «Туксанынчы еллар әдәбияты» анкетасына җавап бирүдә катнашучылар ин зур казаныш дип бертавыштан диярлек билгеләделәр. Чыннан да, туксанынчы елларда татар әдипләре үз иҗатлары өчен тулы ирек үк дип әйтеп булмаса да (чөнки басмалар барысы да диярлек дәүләт кулында) элекке еллар белән чагыштыргысыз дәрәҗәдә зуррак мөмкинлек алдылар. Нәтиҗәдә, милләтне һәм аерым шәхесне борчыган бик күп үткен мәсьәләләр әдәбиятта кыю рәвештә яктыртыла башлады. Шулар турында туксанынчы елларда күп санлы әдәби әсәрләр иҗат ителде. Совет чорында тыелган тарихыбызга, милли каһарманнарыбызга багышланган романнар, повестьлар һәм поэмалар язылу факты үзе генә дә соңгы еллар әдәби процессының матур бер казанышы. Мондый әсәрләр барысы бергә халыкны, аеруча яшь буынны, милли рухта тәрбияләүдә алыштыргысыз мөһим роль уйныйлар.

Әмма, кызганычка каршы, соңгы елларда татар әдәбиятын үстерүгә нык комачаулый торган күренешләр дә күбәйде. Журнал битләрендә басылып чыккан җавапларда рухи-әхлакый якка игътибар җитмәү, яшь буынны тәрбияләү эшенең йомшавы, денсезлекнең, имансызлыкның гаять тә көчәюе басым ясап күрсәтелде.

Югарыда әйтелгән фактлар һәм тенденцияләр барысы бергә җыйналып бүгенге татар язучысы яши торган социаль-әхлакый һәм рухи мохитне, климатны бик тә начарайтты. Гап-гади генә итеп әйткәндә, болар язучы кешенең күнелен төшерде, аның иҗатка, язуга карата булган дәртен киметтe, илһамын урлады.

Шул ук вакытта, әлеге объектив сәбәпләр белән бергә, әдәбиятның үз эчендә дә байтак кына киртәләр пәйда булды. Иң беренчедән, традицион татар авылында туып үсеп, зур тормыш тәҗрибәсе туплаганнан соң әдәбиятка килгән өлкән буынның талантлы вәкилләре азайды. Ә бу хәл исә язылган әсәрләрнең телендә һәм эчтәлегендә чагыла. Бигрәк тә проза әсәрләрендә күп төсмерле, сыгылмалы, «җырлап торган» милли тел «сирәк кунак»ка әверелде. Тормышның зур фәлсәфәсен сыйдырган конфликтлар һәм характерлар да әсәрләрдә сирәк очрый.

Боларга өстәп, әдәби китапларны дөньяга чыгаруда да зур кыенлыклар килеп туды. Халыкта рухи ихтыяҗ булса да, укучылар вакытлы матбугатка языла алмас, кибеттә күргән китабын сатып ала алмастай авыр матди хәлгә куелды.

Шул ук матди сәбәпләр аркасында иҗат кешеләренең төрле-төрле төбәкләрендә яшәп ятучы милләттәшләребез белән аралашуы да нык кыенлашты. Элекке елларда гадәти күренеш булган авылга, районга чыгулар да бик сирәгәйде. Болары да, әлбәттә, иҗатка ярдәм итми.

Ләкин, бирелә аталган һәм аталмаган бик күп кыенлыклар булуга да карамастан, татар әдәбияты үз үсешенең төп юлын, барыбер, югалтмады дия алабыз. Милләткә, халыкка хезмәт итү—безнең еллар иҗат кешесенең дә төп максаты булып кала бирә. Намуслы тормыш алып барган кешеләр яшәешенең төрле яклары бүгенге язучыга иҗат һәм илһам чыганагы булып тора.

Яна гасыр һәм яна үр—2000 ел бусагасы алдында яшәвебез бу анкета җавапларына үзенчәлекле яңгыраш бирде. Әдипләр һәм галимнәр шушы гасыр тәҗрибәсеннән чыгып әдәбиятка кагылышлы кайбер гомуми нәтиҗәләр ясарга һәм шул ук вакытта алда торган егерме беренче гасырга күз салырга теләделәр, татар әдәбиятының киләчәк язмышы турында уйландылар, үзләренең фаразлары белән уртаклаштылар, теләкләрен белдерделәр.

Татар әдәбиятының сыналган, калыплашкан, ныклы юлы, бай традицияләре бар. Киләсе гасырда да алар югалмас. Халык белән тыгыз элемтә, рухи якынлык аллагы чорларда да күз карасы кебек сакланырга тиеш. Әдипләр өчен профессиональ осталык һәм талант—төп критерий булып кала.

Әдәбиятның яшәве һәм үсүе барыннан да бигрәк ил, халык өчен кирәк. Шуна күрә аның, һичшиксез, дәүләт кайгыртуында булуы сорала. Татарстан дәүләте җитәкчеләре тарафыннан соңгы берничә елда әдәбиятка күрсәтелә башлаган игътибар һәм аллагы елларга юнәлтелгән вәгъдәләр безнең әдәбиятыбыз киләчәктә дәүләтнең кайгыртучан мөнәсәбәтенә ирешер дигән өмет тудыралар.

*Нәкый Исәнбәтнең тууына 100 ел*

# МӘКАЛЬЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА

## Татар халык мәкальләренең шигъри үзенчәлекләре



Кайчагында бер үк мәкаль шигъри әсәр булган кебек, гади, коры сөйләм, проза да була ала. Әгәр дә мин язгы гөрләвек суы бер чокырга төшкәнен күреп:—Су чокырга жыела дип, бу хакта иптәшләремә хәбәр итәм икән, бу сүз мәкаль булмый, очраклы бер хәлне әйтү генә була. Әгәр дә мин шул ук сүзне байлыкның бер әзерләнгән урынга туплануына мисал итеп әйтсәм, бу мәкаль була. Бу чагында аның очраклы мәгънәсе һәм күренеше үзендә калса да, ул хәзер гомуми бер мәгънә касеп итте һәм аны бу мәгънәсендә тормыштагы күп кенә хәлләргә мисал итеп китерү мөмкинлеге туды. Табигатьтән алынган бер күренеш һәм гомуми мәгънәгә ия буларак, ул хәзер мәкаль һәм шигъри әсәр булды.

Мәкальләр шулай, бер яктан, үгет-хикмәт, икенче яктан, шигъри әсәр булганга, әлегә хәтле аңа карата шундыйрак ике төрле килеш алга сөрелгәне күренә: берләре аны борынгы жәмгыять кумәк (община)ләреннән калган кануннар, хөкем, дәлилләр итеп карарга теләделәр һәм шул ягына беренче дәрәжәдә әһәмият бирделәр (әйтик, урысларда Буслаев, Иллюстров һ. б.). Шуңлыктан аларча мәкаль күбрәген үгет-нәсихәт, гыйбрәтле сүз яки кагыйдә-дәлил булып, кыскасы, дидактик әсәрләр булып анлашылды. Әмма икенчеләр исә, аның ирония, шелтә, хуплау яки хурлау шикелле берәр хиснең тышка бәреп чыккан юралышы, шуның шигъри бер мисалы булып әйтелеше ягыннан әһәмият бирделәр. (Әйтик, урысларда Гоголь.) Гарәпләрдә мәкальләргә, күбесенчә, шигъри бер хис юралышы (тәгъбире) булу ягыннан киләләр. Алар мәкальне зырубе әмсал, ягъни—мисал белән суктыру дип тә йөртәләр һәм төрләрен тәшбиһ, тәмлих, тәүбиһ, тәһәккем (охшатым, жор сүз, шелтә, мыскыл) һәм башка шуның шикелле шигъри мәгънәдә мисал сүз итеп карыйлар. Гарәп мәкальләре, чыннан да, күпчелеге бер-бер вакыйгадан алып кына сөйләнә торган тапкыр мисаллар урынында йөрү анлашыла. Без шуның белән һәр халыкның мәкальләре үз тарихи роленә карап та үзенчәлекле булуын күрәбез. Әйтик, русларда закон-хөкем эшләре күптән язма статья калыбына кереп, чиркәү белән кәнсәләр кулында булганга, мәкальләрнең элекке кумәк жәмгыятьтә (общинада) тоткан канун-кагыйдәчелек рольләре нык кимегән, бәлки шуның белән, күбесенчә, шигъри тапкыр сүз һәм фразеология булу ягы алга сөрелгәндер. Гарәпләрдә дә шулай: язма дин канунчылыгы, Коръән, шәригать хөкемнәре торгызылгач, тормыш өчен һәртөрле хәдисләр, язма хикмәтле сүзләр, афоризмнар урын алгач, мәкальләрнең дә элекке ижтимагый рольләре кимеп, күбесенчә, телбизәк чаралары яки стилистик, фразеологик алымнар дәрәжәсенә калулары гажәп түгел. Шул рәвешле, һәр халыкның үз тарихи тормышы, үз эчке көнкүреш тәртибе, үз язма культурасы һәм шигъри үзенчәлекләренә карап мәкальләрнең ижтимагый рольләре үзгәргән кебек, эчтәлек һәм шигъри алымнары да алмашына, шуның белән аларның берләре телдән төшеп, икенчеләре сакланып, яңа алымнарның тууына, үсүенә сәбәп була.

Бездә дә иске шаманлык урынына язма әдәбиятлы ислам дине керсә дә, аять-хәдисләр гарәп телендә йөртелгәнгә һәм гарәпләрнең кагыйдә-кануннары безнең халык көнкүреш шартларына һәм гореф-гадәтләренә, күбесенчә, туры килмәгәнгә, язма закон яки шәригать китаплары мәкальләрнең ижтимагый ролен бетерә алмаганнар,

шунлыктан безнең мәкальләрнең тормышта кагыйдә һәм дәлил булу көче ныграк сакланган.

Соңга таба мәкальләр бездә күбрәк игенчеләр арасында туган. Алар табигать белән эш иткәнгә, борынгы патриархальлек дөньяга карашларын да озак саклап килгәнгә, безнең мәкальләрнең борынгы калыпларын, табигатькә бәйләнешен, шигъри алымнарын да шактый нык күзәтеп, саклап килә алганнар. Һәм шул алымнар белән үзләре дә мәкаль тудыруны дәвам иткәннәр. Шунын белән безнең мәкальләрнең шигърилегендә хәзер иң төп урында авыл теле, игенченең реалистик дөньяга карашы, көнкүреш һәм күңел сурәтләмәләре нык чагыла. Аннары шул алымнар шәһәр һәм бистә кешеләренә, вак һөнәрчеләргә, эшчеләр теленә җәелеп, тагын да баетыла. Без хәзер түбәндә шул шигъри үзенчәлекләрнең кайбер әһәмиятле якларына тукталабыз.

Күчерек (ривая), лирика һәм диалог әсәр булу ягыннан мәкальләр[1]. Мәкальләрнең кайсын гына алып карама, йә ул тормыш һәм табигатьтән алынган бер хәлне сиңа имеш тә булган бер вакыйга төсендә күчереп мисал итә, йә ул сиңа ирония, ачу, хуплау шикелле бер хис тәгъбир итә, яки сорау, эндәш төсендә сиңа эндәшә, реплика ташлый, шунын белән мәкальләр иң кечкенә әсәр булуларына карамастан, һәрвакытта да, сүз сәнгатенең төп жанрлары булган күчерек, лирика һәм драматик диалог яки реплика алымнарында төзеләләр, шундый күп яклы алымнар да әйтелүләре мәкальләр теленең дә шигъри үткен, җанлы һәм сыгылмалы булуына сәбәп булган. Менә карап, аларны турыдан-туры күчерек, лирика, драма дип атап булмаса да, шул жанрлар элементы буларак үзләрен күрсәтүләре кызыклы.

Мәкальләрнең күчерекчелек (эпик) алымында төзелүенә күз салыйк. Мәкальләр мең еллар буена авыздан-авызга күчереп сакланган булулары, борынгы дастан, мәсәл, хикмәт элементларын асрап килүләре белән, күпчелеге күчерек—ривая әсәр калыбында төзелгәннәр. Җөмлә буларак, аларнын хәбәрләрендә иң күп урын алган сүзләрнең хикәя һәм хәбәр (төрдәш) фигыль (хәзерге грамматикаларда йөртелүенчә сыйфат фигыль)ләрдән торуы үзе үк шуны күрсәтә. Мәсәлән:—Алдырган атасының куенын актарган;—Алабута аш булды, алтын-көмеш таш булды;—Изге кеше Идел кичкән кебекләр. Яки, борынгы күрәзәләрчә бер тонда киләчәктән хәбәр бирү төсендә әйтеләләр:—Арпа чәчкән бодай урмас;—Ашыккан кыз кияүгә барса да мантымас;—Ат аунаган җирдә төк калыр;—Этнең башын табакка салсаң, тәгәрәп төшәр формасында әйтелгән мәкальләр. Кайберләре бер-ике кыска җөмләдән генә торган бөтен бер сюжетлы хикәя төсен алалар:—Ирем үлде, иргә бардым—имгәк алдым;—Бер килен баласын сөйгән, сөйгән дә килегә салып төйгән ди;—Ашамыйм дигән килен алтмыш коймак ашаган;—Килен булдым каенанага ярамадым, каенана булдым киленгә ярамадым;—Ялганчының йорты янган, берәү дә ышанмаган;—Эт, язга чыккач, сөяктән сарай салыр идем,—дип әйтә имеш;—Мәче дә иткә буе җитмәгәч, сөрсегән дип әйтте ди;—Әйрән эчкән котылган, чиләген ялаган тотылган һ. б.

Шул мәкальләргә ныклабрак карасак, кайберләре турыдан-туры сюжетлы бер хикәячек булуын, кайберләре исә нинди дә булса берәр мәсәлнең, хикәя яки мәзәкчәнең кыска гына сөземтәсен яки җимешен алып әйтү икәнен күрербез:—Җиде бажаны бер бүре ашаган:—Бер ат аркасында мең ат су эчкән һ. б. Боларда бер җөмләдә бөтен бер күчерек хикәя әйтелгән кебек, эчләренә салынган хикәянең озынчасын да аерым сөйләп була.

Инде күңел хисен тәгъбир иткән лирик мәкальләргә килсәк, алар да бик күп. Мисаллар:

Җаным дигән ярты сүз, бәгърем дигән каты сүз.
Һәркемнеке үзенә ай күренер күзенә!
Көндез абыем, кич җаныем.

---

[1]Күчерек—эпос сүзе урынына, профессор Габдрахман Сәгъди тарафыннан телебезгә кертелгән атама. Эпос, эпика, эпикачылык кебек әйтелешләр телебезнең табигатенә авыр булып, әлегә хәтле киң кулланмыйча, белгечләр телендә генә йөри. Ул сүз шулай ипкә-сапка килмәгәнгә, революциягә хәтле бер алынса да ташланган иде. Галимҗан Ибраһимов үзенең «Әдәбият кануннары»нда ривая, риваячылык дип ала. Китапчарак булса да, иплелек ягыннан ул да матур. Инде бу күчерек атамасына килгәндә, җиңел аңлашылуы һәм телебезнең төрлечә ялганмасына килеп торганга, халык өчен язганда, мондый байлыктан баш тартып торып булмас, дидем. Күчерек, димәк,—сүзне күчереп, хикәяләп сөйләү формасында хикәя итеп язылган әсәр.

Сөйгәнемнен күнеле өчен сөймәсемне сөямен.
Ир көеге итәктә, бала көеге йөрәктә.
Бай килене булганчы, ярлы кызы булсамчы!
Безнең урамда да бәйрәм булыр әле!
Ач бул, ярлы бул, кулыңда акчаң булсын!
Терсәкне бик тешләр идең дә, житми!
Бәхетең булса, башың таз да булмас иде.
Туйдан соң дөмбергә!
Күп белсәң, тиз картаерсың!
Дәрт бар, дәрман юк!
Күңел ни теләми, язык жибәрми!
Какма кеше капкасын, үз капканны кагарлар!
Ир дип әйтмә, ирене-борыны ерылсын!
Алтыга ал, бишкә сат, атың булсын сәүдәгәр!
Кыз кемгә бармас иде! Егет кемне алмас иде!
Заманасына күрә, дуңгызны да жизни диярсең!
Һәммәсе богъдай—без салам, бар да яхшы—без яман!
Кеше хәлен кеше белми, уклау төште башыма!

Шул мәкальләргә игътибар ителсә, эчләренә салынган мәгънә һәм хисләренә юралыш[1] табып укылса, һәрберсендә күпме әрнү, ачыну, көлү, үкенү, кызгану, үпкә, шелтә кебек хисләр ятканын, аларның тормышта нинди лирик тойгыларны әйтеп бирергә булышканын да сизәрсез. Билгеле, кайчагында бөтенләй күчерек (ривая) характердагы мәкаль дә, кешенең тормышта кичергән хәленә карап, лирик бер хис белән әйтелгәли. Димәк, безгә мәкальләрнең күчерекчелек һәм лирик алымнары хакында сөйләгәндә, аларның әйтелгән урыннарына карап, һәр очракта төрле буяулар өстәвен дә онытмаска кирәк икән әле.

Мәкальләрдә драматик диалог элементлары да аз түгел. Югаргы мисаллардан күренгәнчә, лирик мәкальләр үзләре үк, күбесенчә, үзеңә яки каршыңдагы кемгә дә булса эндәшеп сорау, мөрәжәгатьләр төсендә әйтелгәннәр. Менә шуннан мәкаль төзелешендә драматик реплика, монолог кебек формалар килеп чыга:

Кызы мина ошаса, анасын бүре алсын!
Жил тегермәне икәнен беләм, суы кайдан килә икән дип әйтәм!
Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!
Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?
Тыпырчынма, аптыраганнан гына суям, кәжәкәем!

Тагы да катлаулана төшеп, мондый мәкаль-репликалардан диалоглы мәкальләр төзеләләр:

Балам балам баласы;
Балдан татлы анасы;
Бу да балам баласы,
Кара елан анасы!
Сүз юктан сүз: ата казыгыз йомырка саламы, кодагый?
Кинәндем, куандым, тиле улыма кыз алдым.
Бирдем исә котылдым, синекеннән биш битәр!
—Әжәл, кайда барасын?
—Барның малын чәчәргә,
Юкның артын ачарга.
—Эт, ник өрәсең?
—Бүрене куркытам.
—Ник төчкерәсең?
—Бүредән куркам.

Шул рәвешле, без тел-әдәбият сәнгатендә төп жанрлар булган күчерек, ривая, лирика, драма алымнарын халык, бер тамчы суда чагылдырган кебек, үзенең шул кечкенә, бер-ике жөмләдән торган мәкальләрендә чагылдыра икәнен һәм аларны сөйләмдәге аваз ымлары белән төрлечә баета икәнен күрәбез.

[1]Юралыш сүзе бу урында тәгъбир, тәгъбирчәнлек (выражение, выразительность) мәгънәләрендә алынды.

Шулай итеп, мәкальләрнең кайсын гына алып карама, аларның һәрберсе артында жанлы, хикмәтле һәм үлемсез тарихи халык үзе гәүдәләнә, ул шунда, кайдадыр, синең колак төбеңә генә баскан да мәкаль пышылдый: йә ул сиңа хикмәтле бер кисәтү ясый, йә шелтә, йә үкенеч белдерә; йә аның әйткәне синең телең аша әйтелгән диалог төсендә килеп чыга; йә ул сиңа, кем авызы белән булса да, борынгы тормышта булган бер-бер хәлне яки вакыйганы искә төшерә. Шуның белән берсендә ул кучерек булса, икенчеләрендә лирика да ул, драматик сөйләм дә ул.

Ләкин бу жанр үзенчәлекләре бер безнең мәкальләргә генә хас түгел, алар башка халык мәкальләрендә дә, әлбәттә, бар нәрсә. Дөрес, аларда тел ягыннан аерма бар. Бу урында безгә шундый сораулар килә: безнең мәкальләрнең төп үзенә караган шигъри үзенчәлекләре бармы? Әллә мәкальләр, жанр буларак, һәммә халыкларда да булганга, аларның бу үзенчәлекләре бар да гомуми һәм уртак нәрсәләрме? Әлегә чаклы бездә язылган кайбер мәкаләләрдә яки әдәбият теорияләрендә безнең мәкальләргә күбрәк шул гомуми жанр булу ягыннан карап киленә һәм үзенчәлекләре дигәнгә дә күбесенчә шундый уртак элементлар табу ягыннан карап кына мисаллар эзләнә, әйтик телбизәкләргә (троп һәм фигураларга) яки авазлар нәүбәтләшүенә мәкальләрдән кайбер мисаллар китерү белән чикләнелә һ. б. Шуның кебекләр белән аларның шигъри үзенчәлекләре дә гомуми нәрсәләр итеп каралып килүендә дәвам итә.

Билгеле, башка халыкларның үз мәкальләре буенча язган хезмәтләрендә табылган нәрсәләргә безнең мәкальләребездән дә мисал эзләү, шуның белән андагы әзер фикерләрне тагын бер кат куәтләү, икенче төрле әйткәндә, әзер юрганга аяк сузу яки баштанаяк томаланып ятудан да жиңел эш юк. Ләкин әгәр дә без мәкальләребезне халкыбызның үз ижаты, үз культурасы дибез икән, ул чагында аларның гомуми сыйфатлары булу өстенә, тагын үз хасиятләре дә булырга яки шул ук гомуми сыйфатларның чагылышлары да боларда үзенчә булырга тиешле бит. Мин дә бу мәкальләрне жыйганда һәм төзегәндә күземә чалынган кайбер шундый үзенчәлекләренә бу урында аерым тукталып үтәргә тиеш табам.

**Мәкальләрнең тел-стиль чаралары һәм жөмләлек[1] ягыннан үзенчәлекләре; композициясе**. Мәкальләрнең композициясе турыдан-туры аларның теленә, грамматик төзелешенә бәйле булганлыктан, башта шул якларына кагылып үтик.

Иң элек жөмләләрдә ярдәмлекләр куллану мәсьәләсе. Бу ягы белән мәкаль безнең телчеләр һәм язучылар өчен дә бик гыйбрәтле. Чөнки хәзерге безнең чәчмә яки тезмә телебезне басып алган, аны кирәккә-кирәкмәскә чуарлаган кайбер т е р к ә г е ч, б ә й л е к сүзләре анда бөтенләй кулланылмыйлар. Мәсәлән, хәзерге безнең язучыларда иң күп кулланылган *ә* белән *һәм* теркәгечләре бер дә очрамый. Алай булгач, мәкальләрдә жөмлә ничек төзелә соң? Әллә хәзергедән башка формадамы? Әллә элек бездә хәзергечә каршылыклы яки бәйләнешле жөмлә әйләнеше булмаганмы? Берсе дә түгел. Нәкъ хәзергечә капма-каршы һәм кискен кире мәгънәдә төзелгән контрастлы мәкальләрдә дә *ә* кулланылмый. Мәсәлән:*—Атың яман булса, сатып котылырсың; ага-энең яман булса, качып котылырсың; хатының яман булса, ничек котылырсың?* дигәндә, безнең язучылар әлбәттә инде «ә хатының яман булса...» дип язарлар иде. Хәлбуки, мәкальнең анда һич эше юк. Шул рәвешле, түбәндәге мәкальләрне карагыз:*—Дус биткә карар, дошман аякка карар;—Ирләр күрсә нәгыш, хатыннар күрсә ялгыш;—Ирнең атын хатын чыгарыр, хатынның атын утын чыгарыр;—Ирнең уңмаганы икмәксез булыр, хатынның уңмаганы күлмәксез булыр*. Мондый фразалар хәзерге безнең кайбер редакторлар кулына төшсә, жөмләләр арасында әлбәттә инде ә ләр тезеп чыгар иде, ләкин мәкальләр һич аңа мохтаж түгел, чөнки һичбер ә ләрсез

---

[1] Сарыф, нәхү дигән атамалар искергән кебек, синтаксис, морфология атамалары да тел әйләнешебездә әлегечә киң массада үзләшә алмаганга, алар урынына жиңеллек өчен Насыйри һәм Гыймад Нугайбикләрчә, төрлек, жөмләлек дип кенә алдым. Т ө р л е к—сүз төрләрен өйрәткеч, ж ө м л ә л е к исә жөмләгә төшендергеч мәгънәсендә. Бигрәк тә с и н т а к с и с ә й л ә н м ә, м о р ф о л о г и к а е р ы м л а н у т и п л а р ы дигән кебек сүзләр тел галимнәре өчен генә аңлашылмалы сүз әйләнешләрен киң халык өчен язылган мондый китапка тутырырга бертөрле дә юл тапмадым. Урта яшьтәге укучылар монда сүзнең нәрсә турында барганын шул сүзнең үзеннән ук жиңел аңлаячаклар.

[2] Тукай шигырьләрендә дә каршы кайтарып алып әйтү төсендәге ә бер генә урында очрый бугай? *(Н. И.)*

дә шул ук каршылык мәгънәсе бик яхшы аңлашыла. Бу мәкальләрне хәзерге телчә түгел дип тә, болар бар да архаик тезмәләр генә дип тә әйтә алмыйбыз. Инде мин җыйган күп меңлек мәкальләр арасында бер генә ә нең дә күренмәве татар теленә ул теркәгечнең кирәксә-кирәкмәсә һәр җиргә алынуы башка телләргә автоматча ияреп эшләнгән бер эш кенә булуын бик ачык күрсәтә. Аның язма әдәбиятыбызда да XX йөз башларында гына очрый башлавы шуны дөресли[2].

Һәм белән дә эш шулай тора. Ничә мең мәкаль яки җырны алып карама, бу теркәгеч бер урында да кулланылмый. Инде шуңа да карамастан, кайда да булса *һәм* ле мәкаль очрый калса, аны тәрҗемә яки ясалма дип бел! Тик бик кирәк урында *дә, да*, та лар белән котылалар:—*Кояш та тапсыз түгел;—Тәңре көне тарыдан да күп* һ. б. Шулай ук мәкальләрдә ләкин теркәгече дә юк. Алар аңсыз да бик аңлаешлы әйтеләләр:—*Сер дусы күп булыр*, (ләкин) *серне тоткан бер булыр;—Дусың дус булсын*, (ләкин) *исәбең дөрес булсын* һ. б. Яки монда да шул ук *дә, да* лар белән котылалар:—*Эт симез дә ашарга ярамый*. (Симез, ләкин ашарга ярамый, яки тәрҗемә теленә күчерсәк, «Эт симез, ә шарга ярамый» дигәнне әйтә.)

*Әгәр* белән *гәрчә* теркәгечләре белән дә эш шулай ук. Болар урынына беренчесенә шарт фигыль, икенчесенә шул ук шарт фигыль янына да-дә кую белән мәсьәлә хәл ителә. Мисаллар:—(әгәр) *Атың айгыр булса, ят та кайгыр;*—(әгәр) *Атың ак та булса, утыр да макта;*—(әгәр) *Анаң үги булса, атаң үзеннеке булмас;*—(гәрчә) *Әйләнеч булса да, юл яхшы;*—(гәрчә) *Сукыр булса да, кыз яхшы;*—(гәрчә) *Калын, юан булса да, ялгыз агач өй булмас.*

***

## Мәкальнең әйтемнәр һәм башка фольклор жанрлары белән уртаклык һәм аерымлыклары

Мәкаль авыз иҗатында үзенә бер төрле аерым жанр булса да алардан бөтенләй үк аерылып та калганы юк. Ул үзенең кечкенәлеге белән әкият, җыр, бәет һәм башкаларның аерым өлешләре булып та килә, шигъри әсәр буларак, бизәү чарасы булып та катнаша, хикмәтле сүз буларак мәсәлләрнең, мәзәкчәләрнең төше дә була ала. Мәсәлән, әкиятләрдә:—*Уңга киткән уңгар, сулга киткән туңар;—Хәбеш башмак тузды инде, гомерем зая узды инде* кебекләр.

Мәсәл һәм мәзәкчәләрдә:—*Һәрбер эшнең вакыты бар;—Тумаган тайның билен сындырма;—Төлке дә йөземгә буе җитмәгәч, пешмәгән диган;—Каз җибәрәм, йолкырсыңмы?—Мулла бир дигәнне ишетмәс, мә дигәнне ишетер*—кебек мәкальләр, исемнәреннән үк күрелүенчә, мәсәл, мәзәкчәләргә бәйле яки аларның бөтен эчтәлеген бер җөмлә белән әйтеп бирү төсендә үзләре үк кечкенә бер хикәя, бер мәсәл булып торалар.—*Мәче дә, иткә буе җитмәгәч, сөрсегән* диган мәкаль үзе үк һәм хикәя, һәм мәсәл урынында тора. (Мондый хикәя, мәсәлләрне мәкальләр рәтеннән кара.)

Көйләп әйтелә торган җырлар белән мәкальләр арасында тышкы яктан болай уртаклык юк кебек, шулай булса да мәкальләр җырның да куенына кереп утыра беләләр һәм алар белән бергә дә, аерым да йөриләр:

Аяз булса айга көч,
Болыт булса көнгә көч;
Кая барсаң да бер кояш,
Күбәләктәй газиз җанга көч.

Баш юллары һәм өченче юлы үз алларына мәкаль дә булып әйтеләләр.

Агыладыр болыт агыладыр, Таулардан ла таүга кагыладыр; Кайгырмыек маллар өчен, Баш сау булса маллар табыладыр.

Соңгы юлындагы *«Баш сау булса мал табыла»* дигәне үзалдына мәкаль булып та әйтелә.

Тубылгы агач зур булмас,
Тубылгы үтә юл булмас;

*** Үзе исән чагында автор төзәтмәләр кертмәгән «Мәкальләрнең үлчәме» һәм «Мәкальләрнең рифмалары» дигән бүлекләр төшереп калдырылды.

Кая барсаң да бәхетен булсын,
Бәхетле егет хур булмас.

Шул җырның баштагы ике юлы тубылгы турында мәкаль булса, соңгы юлы бәхет турындагы мәкаль булып тора.

Җир җиләге ачы була
Вакытында пешмәсә,
Кеше хәлен кеше белми
Үз башына төшмәсә.

Өченче юлы мәкаль итеп һәм аерым әйтеп йөртелә. Кайбер мәкальләрнең хәттә җырмы, мәкальме икәнен дә аерып белү читен. Мәсәлән, түбәндәгеләр:

Гыйшык дигән бер чәчкә
Йөрәгенә чорнашыр,
Сөйгәненә каушалмасаң,
Хәсрәт булып урнашыр.

Ат яхшысы арканда,
Ир яхшысы тарханда,
Унган булсаң дус итәрләр,
Кай илләргә барсаң да.

Аяз булса суытыр,
Болыт булса җылытыр,
Туган-үскән җирләрен
Җүләр кеше онытыр.

Болар көй белән әйтелсә—җыр, телдән генә әйтелсә мәкаль була. Бигрәк тә борынгы җырлар тирән хикмәтле мәкальләргә бай. Борынгы чичәннәр мәкальләрне тезмәгә сарын, сарыннар, кобаерлар, тулгауларны үзенә махсус күтәренке һәм «китап әйткән» сыман (көйләп укыган) булуларын хәтергә алсак, борынгыга киткән саен мәкальләрнең җыр белән бергә ныграк үрелгән булуын, аларның синкретизмын ныграк күрербез.

Бу хәл исә татар мәкальләренең аерым музыкаль-ритмик булуларын китереп чыгарган кебек, җырларыбызның да кыскалыкка һәм хикмәтле мәгънәлелеккә омтылуларын китереп чыгарган.

Мәкальләр хәттә табышмаклар элементы булып та китереләләр.

Болары җиңел аңлашыла, ләкин мәкальләрнең бәхәсле ягы әйтемнәр тирәсендә. Әлегә хәтле мәкальләр белән әйтемнәр бер-берсеннән яхшылап аерылмаган яки теориядә аерылса да, гамәлдә бергә буталып, әлегә хәтле дә чишелгәне юк. Безнен татар фольклорчы һәм мәкальчеләрендә дә шул ук хәл.

Минемчә, бездә әйтемнең мәкаль белән буталып йөртелеше иң элек саф техник яктан башланып китә: ягъни, сүзебезнең мәгънәсен урысча уйлап төшенүче кайберәүчеләр тарафыннан, әйтемне урысча поговорка сүзенең тәрҗемәсе дип уйлап, мәкаль мәгънәсенә күчерүдән килеп чыккан хата. Хәлбуки, урысларда поговорка сүзе берничә мәгънәдә йөри, шуның берсе дә пословица мәгънәсе. Бу ике сүзнең ясалышы бер төрдән. Шунлыктан, урыс әдәбиятында да, күбесенчә, бу сүзләр бер-берсеннән аерылмый кулланыла. [...] Урысларда шулай булгач, бездә дә шулай механик рәвештә аермыйча куллану кереп киткән.

Урыс теленең аңлатмалы сүзлеген төзүче В. Даль үзенең мәшһүр мәкальләр җыентыгын «Пословицы русского народа» дип атаган һәм китабына сүз башында поговорканың пословицадан аермасын күрсәтергә тырышкан. Теориядә ул моны, якынча, шактый яхшы аңлатып үткән, ләкин гамәлдә үзе китабында поговоркаларны да табышмак, сынамыш яки башка вак жанрларны да бергә алып бутап йөртә. Бездә дә ул моңар хәтле булган җыентыкларда шулайрак. Мәсәлән, Хуҗа Бәдигъ үз җыентыгын «Мәкальләр» дип атаса да беркадәр әйтемнәрне дә керткән. Үткән елда гына чыккан «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» дигән китапта, исеменнән үк күренгәнчә—мәкальләр белән әйтемнәр аермасыз бергә җыелып, чуалтып бирелгәннәр. Анда сүз башында әйтелүенчә, алар бар да «фразеологик берәмлекләр» дип бергә санала һәм алар турында: «В. Даль сүзлеге үрнәгендә бирелә» диелү бик кирәкле аңлатма булып тора. Шуның белән мәкаль һәм әйтемнәрнең, жанр буларак, бездә дә әлегәчә аерылмыйча килүләре каян килә икәнлеге дә аңлашылса кирәк.

Алай зур мәкальчеләр үзләре дә гамәлдә мәкаль белән әйтемне бергә туплап йөртә торган булгач, исемнәрендә дә зур аерма булмагач ник безгә дә аларны аерырга кирәк соң, чыннан да мәкаль белән әйтемнең бик ул хәтле ни аермасы бар соң? диярләр.

Ләкин теориядә һәм гамәлдә бу аерымсызлыкның бездә жанр буталчыклыгы тудырганын күрүе авыр түгел. Әйтем нәрсә? дигәнгә бездә менә—тәмам булмаган жөмлә, грамматик кисәкчә дигән томанлы булса да якынчарак җаваплар бирелсә дә, шунда ук аны—«шул ук мәкальнең бозып әйтелеше» дип аңлату нык урын алган. (Мәсәлән, Хәсән Гали җыентыгына Маминның язган сүз башында, Галимҗан Сәгъдинең «Әдәбият теориясе»ндә һәм дәреслекләрдә шул «теория»гә мисаллар бирелеп килә.) Болай аңлатудан әйтем дә шул ук мәкальнең үзе, ләкин аның үзгәртелгәне, бозылганы гына булып кала. Ягъни, әйтемнәр телдә үз алларына аерым бер жанр, бер элемент булып яшәмиләр, алар шул ук мәкальләр, аның да бозылганы гына булып чыга. Шул рәвешле, мәкальдән бозылган, азган-тузган мондый сүзләрнең халык иҗатының нинди дә булса бер төре исемен алып йөрергә, китап тышы һәм эчләрендә урын тотарга хаклары бармы соң? Аннары, җитмәсә, ул әйтемнәрне әлегә хәтле фразеологиядән аерып бирә алган беркем дә күренми, ихтимал, моннан соң да андый кеше дөньяга килмәс. Шулай булгач, мондый теорияләр нәтиҗәсендә, ул әйтемнәрне безгә нишләтергә? Йә:—Сез безнең мәкальләр бозгынлыгы булып йөрмәгез!—дип, аларны һәм, димәк ки, бөтен фразеологияне авыз иҗатыннан бөтенләй сызып ташларга яки мәкальнең үзен дә шул ук әйтем—фразеология белән бер итеп карарга да, барын да бергә тупларга кала. Югарыда әйтелгән «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» дигән җыентыкта шушы соңгы юлга басылган. Сүз башында Даль буенча диелсә дә, ләкин монда яна нәрсә бар: ул да булса—фразеология сүзе. Бу нинди хикмәтле сүз, нәрсә аңлата соң?

Фразеология—телдәге тәгъбир (юралышлар), киная, идиомалар, телбизәкләр (троплар) һәм башка шуның ише сурәтләү чаралары буларак жөмләгә кереп-чыгып йөри торган кисәкчәләр. Алай булгач, әйтемнәр нәрсә соң? Әйтемнәр—телдәге тәгъбирләр (юралышлар), киная, идиомалар, телбизәкләр..., кыскасы, әйтемнәр дә шул ук әйберләр. Димәк ки, әйтемнәр шул ук фразеология була. Яки фразеология, безнең телебезчә итеп әйткәндә, әйтемнәр була. Аерма булса, берәүләрнең бу төшенчәне кинрәк, берәүләрнең таррак аңлавында.



*Нәкый Исәнбәт (сулда) Сәгыйть Агиш белән.*

Урысларда поговорка сүзе халыкта күптән яши. Аның төп мәгънәсен урыс сүзлекләре, шул жөмләдән Даль үзе дә, фразеология дип аңлатсалар да, халыктагы өстәмә мәгънәләре белән ул аларда мәкаль дип тә кулланып йөртелүе билгеле. Шунлыктан анда бу сүзләрнең сөйләмдә чуалтылуы жанр чуалчыклыгы тудырса да гаҗәп түгел. Әмма бездә әйтем сүзе 30 елларда гына керә башлый һәм бу сүзнең мәкаль белән дә аваздашлыгы юк... Шунлыктан аны, атама сүз буларак, мәкаль белән фразеология арасында бутап йөртү-йөртмәү безнең үз иркебездә. Бездә дә ул фразеология мәгънәсендә булганга, бары шул атама урынында гына кулланырга тиеш. Инде фразеология сүзе бик ошый икән яки ул әйтемнәрнең киңрәк төшенчәсе дип алына икән, кулланыла бирсен, әмма ләкин, мәкаль сүзе бездә үзенә үзе хуҗа булганга һәм әйтем сүзе ул мәгънәдә була алмаганга, аларны игезәк сүз итеп карарга ярамый. Шулай булгач, мәкаль һәм әйтемнәр дип аларны бер мәгънәдәрәк сөйрәп йөртү табагачка кисәү тагу шикелле бер эш булып, жанрлар чуалчыклыгы тудыруга гына сәбәп булып килә.

Әйтем белән фразеология бер үк нәрсә булып, сүз бары аларның күләмнәрен тәгаенләү хакында барырга мөмкин. Хуш, инде мәкаль белән әйтем аермасына килик. Ни белән бер-берсеннән аерылалар соң?

Төп аерма шунда: мәкаль булса, иң элек, ул гомуми бер хөкем, уртак бер төшенчә була, әйтем булса, ул хосусый бер нәрсәнең билгеле бер ягын әйтү генә

була. Әйтик:—А к а к ч а к а р а к ө н ө ч е н,—дибез икән, бу әйтүебездә, турылык белән табылган акча кешене мохтаҗлыкка төшүдән коткару өчен хезмәт итә, дигән бер фикер ята. Бу сүз һәрбер шундый акчага карата һәркайда, һәр урында, һәркем тарафыннан әйтелә ала. Димәк, бу гомуми бер фикер, уртак бер төшенчә. Димәк, бу—мәкаль. Әмма инде син күпмедер акчанны бүлеп, саклык кассасына салып кайткач, хатыныңа книжканны күрсәтеп:—Моны к а р а к ө н ө ч е н салдым, дисең икән, мондагы «к а р а к ө н ө ч е н» дигән сүзең бер дә гомуми фикер түгел, бу тик синең шул хосусый очракны үзен билгеләү өчен генә әйтелгән сүз, башкалар өчен бу кагыйдә түгел, уртак нәтиҗә итеп йөртерлек әһәмияте дә юк. Шулай да бу, «к а р а к ө н ө ч е н» дигән сүзең гади сүз генә булмады, бәлки синең, м о х т а җ л ы к к а т ө ш м ә с ө ч е н дигән мәгънәне әйткән үз хосусый фикереңне читләтеп әйтүең булды. Димәк, бу—әйтем булды.

*—Һәркемнең бармагы үзенә таба кәкре*: бу—мәкаль; ул гомумиләшкән бер фикер әйтә.—*Аның бармагы үзенә кәкре* дисәң, бу—әйтем. Чөнки бу тик аерым бер кешенең аерым бер үз табигате генә. Монда гомуми төшенчә юк. Хосусый очрак.—*Байдан акмаса да тама—мәкаль.—Гайнулла абзыйдан акмаса да тама* дисәк, мондагы «акмаса да тама»—әйтем. Монысында гомуми фикер юк, бер кешенең, бер Гайнулланың сыйфаты турында хосусый бер фикер генә булып кала.

Шул рәвешле, әйтемнәр, телдә йөргән әзер сурәтләү чаралары буларак, тормыштагы конкрет бер нәрсәне йә бер очракны тасмерләү йөзеннән әйтеләләр. Ләкин менә карап, әйтемнәрне бу очракка ят һәм чит булган, каяндыр алынган абстракт бер мисал дип уйларга ярамый, ул бер конкрет хәлгә карата әйтелдеме, турыдан-туры шул конкрет хәлнең үзен, аның шул очраклы күренешен бер яктан сурәтләп үтмичә калмый (охшату, чагыштыру һ. б. шикелле). Әмма ләкин ул мәкальләр шикелле гомуми бер хөкем, бер төшенчә чыгармый, шуның белән генә чикләнә. Мәсәлән:—Авызы әйткәнне колагы ишетми;—Эт шикелле—хәзер талашалар, хәзер ялашалар һ. б.

Әгәр дә без шул әйтемнәрне:*—Авызың ни әйтсә, колагың шуны ишетер;—Эт талашыр, авызын-борынын ялашыр*—дигән мәкальләр белән чагыштырсак—өлешчә, шул ук сүзләрдән ясалганын күрербез. Ләкин аерма боларда бик ачык: мәкальләрдә тәмам булган гомуми бер төшенчә, уртак бер мәгънә әйтелә. Ягъни:*—Эт талашыр, авызын-борынын ялашыр*—дигәннән, этләрнең хосусый бер хәлләре генә әйтелми, ул башка гомуми бер мәгънәгә типик бер мисал булу йөзеннән әйтелә. Әмма без кайбер кешеләр турында:*—Эт шикелле, хәзер талашалар, хәзер ялашалар* дисәк, шул хосусый бер хәлне генә тәгъбир итәбез. Яки бу кешеләрнең талашуын да теге мәкальнең мисалын раслый торган хосусый бер очрак кебек итеп искә алабыз (бу чагында хосусый очрак мисалга мисал була).

Шул мисаллардан күрелүенчә, димәк, мәкальләр дә шулай ук, күбесенчә, табигать яки кешеләрнең көндәлек тормышыннан аерым очракны бирәләр, ләкин мәкальдә бу очракның үзен әйтү максат түгел, бу тик башка бер гомуми мәгънәгә мисал өчен генә китерелә. Монда ул мисалның үзен түгел, бәлки аның аша әйтелгән гомуми нәтиҗәне аңларга кирәк. Яки аларның мисал мәгънәсе булмаганнары да барыбер безгә гомуми бер әһәмияте булган тәҗрибә яки киңәш бирделәр. Мәкаль, димәк, башта ук әйтелгәнчә, тәгәл һәм гомуми мәгънәне эченә алган мөстәкыйль әсәр, халык хикмәте була. Шунлыктан андагы конкрет күренеш үзе гомуми мәгънә—икесе берлектә бер бөтен юралыш табалар. Һәм, димәк ки, мәкаль мөстәкыйль әсәр булганлыктан, аның гомуми мәгънәсе үзе эчендә. Әйтемнәр мөстәкыйль әсәр булмаганлыктан, аларда гомуми мәгънә һәм конкрет күренеш берсе берсенең тышында ята. Шуның белән әйтемнәр бары тик телдәге сурәтләмә чарасы гына булып калалар һәм алар тормыштагы берәр нәрсә, берәр хәлнең очраклы ягын өлешчә генә тасмерләп үтү белән чикләнәләр:*—Кая, күзен алган кигәвен кебек, кереп барасың?—Ул таш йөрәктән* рәхим көтмә;*—Суйган да каплаган* инде һ. б. Болар әйтемнәр. Күренә ки, алар үзләренә мөстәкыйль һәм тәгәл бер әсәр булмыйча, күбесенчә, җөмлә кисәге генә булып киләләр. Яки җөмлә кисәге булмыйча, үләренә тәмам булган бер җөмлә төсендә әйтелә алганда да, барыбер алар гомуми нәтиҗәгә ия булган бер фикер әйтмичә, хосусый бер очракка карата аның бер ягын тасмерләү белән генә калалар:—*Йомшак түшәп катыга яткыра;—Аның бүресе улый;—Түбәсе тишек;—Ашка таракан төште* һ. б. Шуның шикелле, бер-бер кешегә карата—*тимер кул, таш йөрәк, әрем*

*тел,*—дигән кебек әйтемнәрдә дә кемне дә булса берәр кешене нәрсәгә булса да охшатудан, сыйфатлаудан уза алмыйлар.

Димәк, мәкаль белән әйтемнең төп аермалары түбәндәгеләргә кайтып кала:

1. Мәкальне башлап әйткән кешесе кайдадыр еракта, тарихта калган. Шунлыктан мәкальләрдә әйтелгән конкрет факт белән син аны әйткәндәге конкрет бүгенге тормыш һәм факт икесе ике әйбер. Димәк, мәкаль бер унай белән сүзгә китерелсә дә, аның факт булып та, әсәр булып та үз мөстәкыйль тормышы бар. Әйтем исә, киресенчә: син аның белән хәзерге бер фактның үзен генә тәгъбир итәсең. Әйтик, син ашап утырганда, артык бер кеше килеп керде. Син:—*Ашка таракан төште*, дисең. Бу мәкаль түгел, әйтем. Ни өчен? Чөнки синең таракан дип әйткәнең әллә каян читтән яки тарихтан китерелгән икенче факт түгел, ул шул ук каршыңдагы кеше яки хәзерге бер фактның үзе, тик син аны читләтеп кенә атавың булды. Аны әйтүче дә еракта йә тарихта калмады, ул кеше син үзең, бу әйткәнең дә синең үз фикерең, үз карашың булды. Яки:—Курыкма, аның *кимәсе хәзер комга тералгән инде, син күр дә мин күр*, ерак баралмас,—дигән сүзне алып карыйк. Бу сүздә әйтелгән конкрет факт та каядыр шунда үзе хәзер бар нәрсә. Ләкин мәкальләрдәге:—*Жиле бажаны бер бүре ашаган*, яки: *Арпа чәчкән бодай урмас*—дигәндәге кебек әллә кайчан, әллә кайда булган яки булачак хәл түгел. Димәк, әйтемнәр үзләрендә әйтелгән конкрет факттан өзелмәгәннәр, анысы да каядыр шундук яки шул тирәдә үк. Әйтем үзе дә шул фактның тәгъбире, бер кисәге яки иярчене итеп әйтелә. Шуның белән әйтемнәр хәтта күп вакыт сүздән дә өзелмәгәннәр. Алар мәкаль шикелле аерым җөмлә булып килмичә, синең үз җөмләңдәге бер кисәкчә булалар. (Шул мисаллардан кара.)

2. Димәк, мәкаль тормышка яки кешенең хәленә карата халык әйткән гомуми караша итеп сүзгә читтән китерелә, анда мисал яки дәлиллек көче бар. Шунлыктан ул сүз арасында әйтелгәндә дә аерым җөмлә булуын югалтмый, бөтен җөмлә булып килә. Әйтем исә синең үз сүзең итеп, бер-бер нәрсәгә , йә кешегә карата синең үз искәртмәң, үз төсмерең итеп кенә әйтелә. Шунлыктан, аның сүздә дәлилләү көче юк, ул гомуми бер төшенчәне әйтү булалмый, ул синең үз хосусый искәртмән яки хәтта кереш сүз сыйфатында гына, йә булмаса сүз бизәге итеп кенә сүзгә кыстырып җибәрелә. Шуның белән ул күп вакытта тәмам җөмлә булмыйча, синең үз җөмләңнең бер кисәге булып кына килә (югарыгы мисалны кара).

3. Шул рәвешле, мәкальдә иң элек мәгънә, гомуми бер төшенчә алда тотылганга, анда форма икенче урында тора. Шунлыктан сүзнең ипле-сипле, бизәкле булуы да шул мәгънәгә буйсына. Әйтем исә, күбесенчә, үзе сүз бизәге яки сүз төсмере (характерлау) булганга, анда шул характерлы әйтү яки форма алда тотыла, һәм ул күп вакытта җөмләдә иярчен кисәк итеп ияртеп кенә әйтелгәнгә, төп мәгънәне әйтү дә әйтемдә булмыйча, җөмләнең башка кисәгендә кала.

Җыеп кына әйткәндә, әйтемнәр—сөйләмдә кулланыла торган төрле киная, чагыштыру, охшату шикелле хосусый бер карашны белдергән, һәм башка җөмләгә ияртеп әйтелә торган төрле телбизәк чаралары (троплар, фигуралар), идиомалар, характерлы кереш сүзләр һәм башка шундый шигъри тәгъбирләр була. Алар назлы күбәләкләр шикелле анда-монда очып һәр җөмләгә килеп куна алган һәм шундук тагы икенчесенә очып китә алган шигъри кисәкчәләр (яки аларны *канатлы тәгъбирләр, очанак тасвирлар* диик), шуның белән алар бик күп төрдә булып, барын бергә җыеп әйткәндә ә й т е м булалар. Яки хәзер галимнәр бик кулланырга ярата торган фразеология булалар. Шунлыктан, жанр буларак, аларны мәкальләр белән чуалтып йөртергә бер юл да юк. Әмма инде фразеологияне әйтем мәгънәсендә ни дәрәҗәдә киңәйтеп аңлау башка эш.

Алай да мәкальләрнең әйтемнәр белән бер уртак яклары да юкмыни соң?

Бар. Югарыда күргәнебезчә, мәкальләрнең әкият, җыр, мәсәл, мәзәкләр белән уртак яклары булган кебек, билгеле, әйтемнәр белән дә бар. Халык авыз әсәрләрендә мондый арадашлык, алымнарда уртаклык, катнашлык мөнәсәбәтләре зур. Югарыда без, мәсәлән, җырларның мәкальгә әйләнүен, мәкальләрнең җырга әверелүләрен күреп үткән идек. Инде әйтемнәргә килсәк, монда инде мәкаль белән әйтемнәрнең бер-берсенә катнашу, әйләнү кебек хәлләр тагы да җинелрәк. Чөнки икесе дә иң вак төр фольклор әсәрләре. Берсе аерым җөмлә, берсе кисәкчәләрдән гыйбарәт. Мәкальләр, күбесенчә, сурәтләмәгә бай булганлыктан, әлеге шаян күбәләк, шигъри кисәкчә булган әйтемнәр мәкальнең тасвири бер кисәге булып киләләр дә кераләр. Икенче

төрле әйткәндә, җырлар, бәетләр, әкият һәм башкалар ул шигъри кисәкчәләрдән файдаланган кебек, мәкальләр дә бик оста файдаланалар. Әйтемнәр шуның өчен тудырылганнар икән—нигә файдаланмаска? Аларны мәкальнең катнаш өлешенә нигә әверелдермәскә?

Шулай ук әйтемнәр дә тик ятмыйлар, кирәк чагында, үзләреннән шулхәтле олы булган мәкаль абыйларының вакарен ватып, хикмәтен хикмәттән чыгарып, берәр кисәген алып, үзләре кебек җөмлә кисәгенә әйләндерәләр дә берәр нәрсәнең очраклы *бер ягын гына төсмерләп китәргә кушалар:—Үтермәгән аюның тиресен тунамыйлар,—мәкаль иде, икенче берәү тотты да:—Карагыз әле Гафур абзыйны: колхоз әле уңышны бүләргә өлгермәгән,*—ул инде тегү машинасы алам дип, *үтермәгән аюның тиресен тунап ята!*—дип, җөмлә кисәгенә әйләндерде, аны *әйтемләштерде.* Мондый очраклар азмыни? Шул рәвешле, мәкальләр әйтемгә әйләнгән кебек, әйтемнәр дә мәкальләргә әйләнә алалар. Ләкин мәкальләр шулай ук, югарыда күрелгәнчә, җырга да әйләнә алалар бит! Аңа карап кына мәкаль белән җырны бергә чуалтырга ярамаган кебек, мәкальне дә әйтемнәр белән чуалтырга, яки аера алмыйча бутарга урын юк.

Болардан күрелүенчә, билгеле, әйтемгә бер-ике сүз өстәү белән мәкальгә әйләндереп булган кебек, мәкальләрдән әйтем алу авыр эш түгел. Бу һич гаҗәп нәрсә түгел. Чөнки кешенең акыл белән уйлаганда хосусый нәрсәләрдән гомуми нәтиҗә ясавы яки гомуми бер фикернең хосусый бер очракта раслануын күрүе—бу үзе акылның табигый бер сыйфаты булып тора. Ләкин кеше үзенең кайсы сүзендә халык фикерен, кайсы белән үз фикерен әйтә икәнен аера белергә тиеш булган кебек, кайсы сүзендә гомуми һәм төгәл мәгънәнең әйтелеше булган мәкаль китерә икәнен һәм кайсы җөмләсендә үзенең хосусый карашын үткенәйтү өчен шигъри бизәкләмәләр кыстыра икәнен дә аера белергә тиеш.

Беренчеләре м ә к а л ь булса, икенчеләре ә й т е м була.

**Сынамышлар**. Инде мәкаль белән бер-берсенә бик якын, шулай ук чуалтып йөртелә торган бер жанр бар: халык сынамышлары. Мәкальләрне билгеләгәндә, без аның тормыш, көнкүреш сынаулары белән тыгыз бәйләнештә икәнен әйткән идек. Ләкин халыкта көн, һава үзгәрешләре, метеорология, елның ничек килүе һәм башка шуның кебекләр турында алдан сынап әйтү, прогноз куюлар бар (приметы):—*Эт аунаса, буран була;—Көн аязга батса, иртән аяз була* кебекләр. Болар, шул мисаллардан ук күренүенчә, нинди дә булса бер галәмәт буенча табигатьтәге үзгәрешләрнең ничек



*Казандагы очрашуларның берсендә... Сулдан уңга: Нури Арсланов, Нәкый Исәнбәт, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким.*

буласын алдан сынау була. Игенче тормышында ашлык чәчү, үстерүдә һаваларның торышы, елның корымы, яңгырлымы булачагын алдан белеп эш итү, билгеле, бик мөһим. Халыкның гасырлар буенча табигатьне эш өстендә тәҗрибә итүеннән туган мондый сүзләр эш юктан эш өчен генә әйтелмиләр. Шул ук вакыт алар, билгеле, фәнни прогнозлар да түгел, шунлыктан кайберләрендә хәзерге күзлектән бик сай, хәтта күренеш, үзгәрешләрнең сәбәп-нәтиҗәләрен ниндидер, табигатьтән тыш көчләр хәрәкәтенә бәйләп аңлатулар да очрый:— *Чиләк чиләккә бәрелсә, яңгыр була,*—дигәндәй. Ләкин андыйлары бик сирәк, гадәттә исә бу сынамышлар табигатьнең үзен күреп, сынап, күп тәҗрибә нигезендә әйтелгәнлеге күренеп тора:— *Салават күпере яшькелтрәк булса, яңгыр булыр;—Урганда салам шартлап сынса, яңгыр булыр* h. б. Билгеле ки, мондый сынаучанлыкка ия булган картлар иртәгә көннең ничек буласын гына түгел, алгы җәйнең яңгырлымы, корымы булачагын да күп алдан һәм шактый дөрес чамалый алалар.

Халык мондый эшне: *сынамыш буенча* һавалар шулай булырга яки ел болай килергә тиеш дип сөйли.—Картлар сынамышы туры килә,—диләр. Шунлыктан халык тәҗрибәләрен аңлаткан мондый сүзләрне мин дә с ы н а м ы ш л а р дип, күзәтүнең үзен дә сынау дип алдым. Алар, гадәттә, кыска гына бер-ике җөмләдән торулары һәм шул ук вакыт халыкның тормыш-көнкүреш тәҗрибә җимеше булулары белән мәкальләргә бик якын торалар. Чөнки башта мәкальгә биргән билгеләмәдә аның да бер яктан шул ук көнкүреш сынаулары белән бәйләнештә туган әсәрләр икәне әйтелгән иде. Һәм чынлап та без мәкаль дип йөрткән әсәрләр арасында андый саф прогноз өчен генә булганнары да бар бит. Мәсәлән:— *Иртә аязмаса, кич аязмас, кич аязмаса һич аязмас,*—дибез. Мәкальме бу, сынаумы? Яки:— *Барыс елыны барын чәч, һич булмаса тары чәч,*—диләр. Димәк, барыс елы иген өчен уңышлы, яңгырлары вакытлы килүе алдан сыналган булуы әйтелә. Мәкальме бу, сынаумы? Әллә һәр икеседәме? Аларны бер-берсеннән аерып йөртү шулай читен булса—ник аерып торырга? Мәкаль булса ни дә, сынау булса ни? Югарыда мәкальнең бер яктан көнкүреш сынауларына бәйләнешле рәвештә барлыкка килүе дә әйтелгән булгач, аларны, сынау һәм тәҗрибә сүзләре дип, нигә мәкальдән аерып торырга?

Ләкин өстән караганда шулай әйтергә мөмкин кебек булса да, асылда мәкальләр һәм сынамышлар үзләренең функцияләре белән дә, төзелешләре һәм шигъри әсәр булу-булмаулары белән дә бер-берсеннән аерылалар. Иң элек сынамышлар, халык ышанулары буларак фольклорга керсә дә, тексты белән халык иҗатының мөстәкыйль шигъри әсәрләре түгел, алар бары сынаулар. Ягъни, тәҗрибәне телдән әйтеп бирү генә. Тәҗрибәне исә кем ничек теләсә шундый сүз белән әйтә ала. Моның өчен аның алдан билгеләп куелган бер тексты юк. Мәсәлән, мин:— *Тоз юешләнеп торса, яңгыр булыр,* дип тә:— *Тоз дымланса, яңгырга* дип тә:—*Яңгыр булырга булса, тоз юешләнер* дип тә, кыскасы, бу сынауны алай да, болай да, үземә ничек кирәк шулай әйтә алам. Чөнки монда текст, тәҗрибә белән берлектә, мөстәкыйль һәм үз кыйммәтле сәнгать әсәре булып килми, шунлыктан текстның ничек төзелгән булуы әһәмиятле түгел, монда максат тәҗрибәнең үзе, сынауның үзе. Әмма текстын кем ничек теләсә, шулай әйтә. Димәк, сынауларда текст мәгънәнең формасы итеп эшләнмәгән һәм шуның белән дә аның иҗади бер шигъри әсәр булуы күздә тотылмаган була. Шунлыктан аларда образлар да, ритмик яки рифмалы үлчәмле сөйләм дә юк. Шуның аркасында сынамышларның кайбер бик кыскалары, хәтта текст ягыннан күп вакыт бертөсле әйтелсә дә, ул шигъри бер әсәр дип карала алмый:— *Эт аунаса, буран булыр;—Ат пошкырса, яңгыр явар,* дигән кебекләр. Әмма инде мондый ныгыган текстлы сынамышларны мәкальдән аеру өчен шунсына карарга кирәк: аларның икенчел мәгънәләре бармы, юкмы? Әгәр дә аларның мәкаль шикелле икенчел, ягъни мисал урынында йөри торган өстәмә мәгънәләре булмыйча, коры сынау гына булса, һәм ул сынау сүзе дә шигъри текст итеп эшләнмәгән булса, димәк, ул мәкаль түгел, сынамыш. Әйтик:— *Бер елга куян тиресе дә чыдый* дигән мәкальне алсак, бу да сынау һәм тәҗрибәдән алынган сүз һәм анда бер елга алдан әйтеп кую да бар. Ләкин монда максат куян тиресенең үзенең чыдап-чыдамавын сынау түгел, эш шул тиренең образлы мисал итеп йөртелүендә, сурәтләмә булуында:— *Мәче үзе йокласа да, күзе тычканны күрә*—мәкаль, әмма:—Мәче тырнашса, буран булыр—сынау. Чөнки беренчесе астыртынлыкка мисал, икенчесе буран булачагын сынау гына.

Ләкин мәкальләрнең үзләрендә дә сынау һәм тәҗрибә максаты белән генә

әйтелгәннәре бар бит. Мәсәлән, югарыда китерелгән:—*Иртә аязмаса, кич аязмас, кич аязмаса һич аязмас.* Бу да сынау һәм чыннан да һава сынавына карата гына әйтелә, башка хәлләргә мисал яки үрнәк булып йөрми. Шул ягыннан карап, бу сүз сынамышлар рәтенә язылырга тиешле кебек. Шулай булса да без аны мәкальдән санайбыз. Ни өчен? Чөнки сынамышлар сәнгать әсәре алымнарында эшләнмиләр. Әмма бу исә канунлашкан, шигъри алымнарга ия булган бер текст дәрәҗәсенә күтәрелгән. Аның сөйләме ритмик, рифмалы һәм үлчәмле. Ул эчке мәгънәсенә карата тышкы калыбы белән шигъри гәүдәләнеш тапкан мәкальләр алымында төзелгән һәм ул теләсә ничек әйтелми, бары шул әйтелешендә генә телдә саклана. Сынамышларда исә мондый хасиятләр юк. Шулай булгач, без моны авыз иҗаты әдәби әсәрләреннән булган мәкаль дип атыйбыз. Монда аның кинаяле мәгънәдә әйтелмәвенә карап мәкальлегеннән шикләнергә урын юк. Чөнки мәкальләрнең икенчел мәгънәгә күтәрелмичә беренче дәрәҗәдә, ягъни табигатьне сынау һәм кагыйдә, күзәтмә дәрәҗәсендә калганнары да күп икәнен без югарыда бер күреп үткән идек (башта мәкальгә бирелгән билгеләмәдән кара). Бу китерелгән прогноз-мәкаль дә шундыйларга керә:—*Барыс елны барын чәч, һич булмаса тары чәч;—Аяз булса суытыр, болыт булса жылытыр;—Туган ай дугалы булса, давыл булыр* кебек күзәтмәләр дә, әдәби кыйммәтләре һәм мәкальчә эшләнгән булулары өчен, мәкаль булалар.

Хуш, инде мәкаль белән сынамышның аермасын да белдек, ди. Алай да бу күрше жанрларның бер-берсенә бурычка керүләре бармы? Әйтик, бер үк вакытта жыр да, мәкаль дә була алганнары очраган кебек, бер үк вакытта мәкаль дә, сынамыш та булып йөргәннәре бармы? диярләр.

Дөрес, дөнья булгач бар да булыр дигән кебек, сирәк кенә андыйлары да очрый. Мәсәлән:—*Сукыр тавык юлга чыкса, буран булыр.* Бу сүз турыдан-туры мәгънәсендә әйтелсә, сынау; шомлану катыш булса да һава сынавы, прогноз. Димәк, бу сынамыш була. Әмма кайчагында шул сүзне—бәхетсезлек һаман бер мескен кеше башына килә дигән мәгънәдә әйткәннәрен дә ишетергә туры килә. Димәк, бу инде аны икенчел мәгънәдә, ягъни мисал урынында куллану булды. Монысы хәзер мәкаль булды. Яки:—*Кызарып чыккан кояшны болыт каплый* дигән сүзне—кояш кызарып туса яңгыр булыр дигән мәгънәдә прогноз өчен әйтелсә сынамыш була. Әмма шул ук сүз—бик тиз генә ялтырап исем казанган кешеләрнең даны тиз күздән төшүгә яки бәхетнең карарсыз булуына мисал итеп китерелсә, бу хәзер үзенең сынамыш мәгънәсен югалта, икенчел мәгънә кәсеп итә дә мәкаль була.

Мәкальләр сынамышка якын һәм күбесе үзләре дә сынаудан туганга, болар арасында күршелек хакы бик зур. Шунлыктан кунакка киткәндә үзара йортта калып торулар була икән—моңа артык гаҗәпләнергә ярамый. Кеше тормышта үзенә бикләнеп кенә яши алмый, шуның кебек халык үз иҗатында демократчыл һәм иркле. Ул үзенең сынавын мәкальгә, мәкален җырга әйләндереп яки киресенчә әйтә белә икән,—ник син әле алай әйтәсең,—дип, ил авызына иләк каплап булмый. Монысы да аның үз осталыгы:—*Казанчының ирке бар, кайдан колак чыгарса!*—диләр бит. Дөнья булгач, ике йортка бер кисәү тоткан чаклар да булгалый...

Менә шуннан ике жанрга да хезмәт итә алган кайбер уртак әсәрләр дә килеп чыга ала.

Димәк ки, мәкаль белән сынамышлар бер-берсенә бик охшасалар да, һәм жыр белән мәкальнең яки әйтем белән мәкальнең бер-берсенә әйләнүе кебек хәлләр болар арасында да еш булса да, аларны жанр ягыннан бергә бутап йөртергә ярамый, аерып карарга кирәк була.

## Мәкальләрнең тормыштагы роле һәм әһәмияте

Югарыда мәкальләр турында әйтелгәннәрдән без аның тормыштагы роле һәм гомумән әһәмияте хакында берничә фикер ясый алабыз. Чөнки ике-өч сүздән, күп булса ике авыз җөмләдән торган мәкаль, иҗат әсәре буларак, эчтәлеге һәм формасы буенча шул хәтле бай булгач, аның роле һәм әһәмияте дә кечкенә булмаска тиеш.

Аларны түбәндәгеләргә җыеп әйтеп була:

**Беренче әһәмияте**—мәкальләрнең, авыз иҗаты буларак, аталар сүзе яки халык хикмәте булуы: мәкаль ул—тормышның һәртөрле жил-давыллары эчендә, безне аталарча

кайгырткан өлкән һәм борынгы кинәшчебез; дөньяның әчесен-төчесен күп татыган, безгә дә аны ничек танырга өйрәткән өлкән агабыз; безгә үзебезне һәм кешеләрне ничек сынарга өйрәткән сынаучыбыз; безне хатага төшүдән алдан кисәтүче күрәзәбез; хатага төшсәң, ачы, туры иттереп, ләкин шул ук вакытта гадел һәм җылы рәвештә шелтә бирә белүче остазыбыз; көнкүрештә һәртөрле мөнәсәбәтләрдә безгә булышчы иптәшебез; юлда ышанычлы юлдашыбыз; безне эшкә, көрәшкә, актив булырга, ничек уңышка ирешергә чакырып торучы тәҗрибәле хәкимебез; кинәшен, белем-тәҗрибәсен һич түләүсез чын күңелдән гүзәл мисаллар һәм матур тел белән әйтүче хикмәтле шагыйребез; безне дә үзе кебек дөньядан алданмыйча, озак һәм сәламәт яшәргә, ничек бәхет-моратка ирешергә, үзе кебек яшь белергә чакырган безнең күп гомерле һәм кара акылга бай картыбыз; кыскасы, мәкаль ул—кин җәмәгатьчелек фикере, гомумхалык карашы, уртак акыл. Ул дәлил булып та, хөкем булып та, кафил булып, кисәтүче яки гыйбрәт булып та, типик бер мисал булып та тормышның һәр ягына катышып, дөрес һәм гадел якны табарга, уртак мәслихәткә килергә, безне тоткарлыктан чыгарырга тырыша.

**Икенче әһәмияте**—мәкальнең безне иҗтимагый фикергә ия итүе: мәкаль, югарыдагыча, гомумхалык карашы, гомумхалык ышануы булганга, шул ук вакыт мин аны сиңа әйткәндә, ул минем карашым, син миңа әйткәндә, миңа карата ул синең хосусый карашың да булып тора ала. Кеше шулай мәкальләр әйткәндә, алар аша халыкның тарихи, иҗтимагый фикере белән үз фикере арасында әледән-әле бәйләнеш ясап тора, элемтәгә керә. Ягъни, без мәкальләр әйткәндә, үз күңеле белән дә, уртак гомуми фикер, җәмәгатьчелек фикер белән дә яшибез. Син мәкаль әйткәндә, халкыңнан тел генә алып калмыйсың, акыл-тәҗрибә дә, белем-хикмәт тә аласың. Шуның белән син үзеңнең сүзеңдә күп мәртәбә көчлерәк, фикереңдә тирәнрәк буласың. Әйткән сүзең мәгънәгә куәтле, нык дәлилле һәм ритмик сөйләмле, шигъри кинаяле, тәэсирле булып чыга. Чөнки синең бу сүзеңнең артында күмәкнең көче, халыкның тарихи тәҗрибәсе, хикмәте, акыл һәм иҗат көче тора. Син дә мәкаль әйтүең белән шуңа таянасың.

**Мәкальнең өченче әһәмияте**—тел байлыгы булу ягыннан. Аларның текстында безнең телнең әлегә хәтле өйрәнелмәгән гаять бай сүзлек фонды ята. Мәкальнең киң таралган булуы аның текстындагы сүзнең дә күпчелек өчен уртак булганлыгын күрсәтә һәм бу яктан мәкальләр аерым сүзләрнең кинме, тармы һәм ни мәгънәләрдә кулланылуын яки ул сүз хәзер актив кулланылмаса да, тарихта кулланылган булуын күрсәткән иң кыска һәм анык дәлил булып тора. Мәкальләр аерым сүзләргә паспорт һәм гражданлык бирәләр. Алар мең еллар буе авыздан авызга йөреп саклана алулары һәм тематикалары буенча, тормышның һәммә якларына да кагылулары белән, анда сүзнең төрлелеге, байлыгы да бик зур һәм мәгънәләре аныклануы да бик конкрет, ачык була. Мәкальләр шул яклары белән телчеләр, әдип-шагыйрьләр, матбугат һәм укытучылар өчен бик зур байлык чишмәсе. Бигрәк тә безнең шикелле телебезнең культурасын өйрәнергә соң тотынган халык өчен мәкальләр бик нык җыелып өйрәнелергә тиешле, әһәмиятле чыганак. Ул телнең торык-тотрыгын, грамматик төзелешен һәм сүз байлыгын саклап килгән хәзинә. Җыеп кына әйткәндә, мәкальләр—тел казнасы.

**Дүртенче әһәмияте**—мәкальләрнең хикмәт, тәҗрибә яки сүз материалы булып кына калмыйча, сәнгать әсәре булуында. Мәкальләрнең иң кыска, бер-ике сүз белән ачык кына итеп шулхәтле тирән күп мәгънә әйтә алучанлыклары бик зур язучыларны кызыксындыра килгән һәм язучылар үзләре дә шундый иппе, җыйнак, тапкыр, анык һәм шигъри тирән мәгънәле итеп әйтә-яза белүчелекне идеал иткәннәр.

Мәкальләр шул дәрәҗәдә сәнгать алымнарына бай булулары, аларның кучерекчелек (ривая), лирика алымындагы яки драматик сюжетны бөтен конфликты белән бер җөмләдә хәл итә алулары, алардагы сурәтләмә системнарының һәм чараларының бай төрлелеге, ритмик, симметрик үлчәмлекне, эчке-тышкы рифмаларны, авазлар кабатланышын, рифма, (аллитерация, ассонанс) һәм композиция чараларын яки грамматик төзелешне файдалана белүләре ягыннан, безнең өчен бик кызыклы шигъри сөйләм мәктәбе дә булып торалар. Тормышның каршылыгын чагылдыру ягыннан күп мәкальләрнең диалектик каршылыклар өйрәнү тагын да әһәмиятле. Андагы телбизәкләр яки сатира, юмор, киная, ирония кебек стилистик алымнар, шулай ук теркәгечсез, иясез җөмлә төзү чаралары һәм башка бик күп яклар да үзенә игътибар

сорый. Кыскасы, мәкальләр сәнгать әсәре буларак, тирән мәгънәне анык, кыска, ритмик алымнарда шигъри сурәтләмәле һәм тәэсирле итеп әйтә белүләре ягыннан, язучылар өчен, бигрәк тә шагыйрьләр өчен, бик нык өйрәнелергә тиешле чыганак булып торалар. Ленинның язучыларга мәкальләрдән файдаланырга киңәш иткән сүзләре һәммәбезгә билгеле.

**Бишенче әһәмияте**—мәкальләр халыкның культура һәм иҗтимагый тарихын, этнографиясен өйрәнү ягыннан күп кенә материаллар бирә алалар. Шул яктан карап, Мәрҗани һәм Г. Әхмиров мәкальләргә таяна белүнең юлын ачсалар да, алардан соңгы тарихчыларның мәкальләрне ул яктан өйрәнү һәм файдаланулары бездә күренми. Мәкальләрдә халыкның көнкүреше, материаль культурасы, гадәт, йола, этнографиясе, хокукы һәм башка мөнәсәбәтләре бик конкрет сызыкларда чагыла һәм кайберләре турыдан-туры бирәр тарихи кеше авызыннан әйтелгән булулары яки тарихи вакыйгага бәйләнешле булулары белән халыкның ул вакыйгага мөнәсәбәтен ачу ягыннан да беренче кул материал була ала.

**Алтынчы әһәмияте**—мәкальләрнең халык рухын өйрәнү ягыннан да бик кызыклы һәм әһәмиятле булуы.

Мәкальләр халкыбызның тарихын да, язмышын да, аның табигатькә, җәмгыятькә мөнәсәбәтләрен дә, рухи төзелеше ничек ясалып чыгуын да, ышануларын һәм дөньяга карашларын да, нәрсәне ярату, килештерү яки яратмавын да, акылын-фигылен, характерын, милли зәвегын, теләкләрен, әхлакын һәм башка сыйфатларын да чагылдыралар. Беренче карауга каршылыклы күренгән мәкальләр аша без татар халкының рухи йөзе, психологиясе турында кызыл җеп булып сузылып барган шактый кызыклы һәм эзлекле фикерләр ясый алабыз.Билгеле, моның өчен мәкальләр генә җитми, әлбәттә. Ләкин мәкальләр өстенә тагын әкият, җыр-бәетләр, хорафат һәм ышанулар шикелле, башка жанрлар да шул ноктадан өйрәнелгәндә, татар халкының этнография һәм материаль культурасы хакында гына түгел, рухи йөзе, психикасы турында да бик мөһим бер сурәтләмә хасил итә алабыз. Мәкальләрнең гореф-гадәт, көнкүреш кагыйдәчелеге урынын тотып килүе аның бер өлеше әхлакый норма буларак роль уйнап килүен дә күрсәтә. Әйтүләренчә, кытайларда Куефонг яки Дәүләт әхлакы дигән китапта халык җырлары җыелган булган. Элек Кытай императорлары дәүләтне күзәткәндә, халыкның холкы-фигыле, гадәтләре турында яхшы белеп эш итү өчен, аларны җыйдырган булганнар. Бу ноктадан каралса, мәкальләр бигрәк тә әһәмиятле. Шунлыктан халыкка якын торучы, аның белән яшәүче һәм эш итүче кешегә мәкальләрнең бу ягын да читләтеп үтү мөмкин түгел.

**Җиденче әһәмиятле ягы**—мәкальләрнең (һәм шулай ук әйтемнәрнең дә) фикер оештыручы, трибун булуында. Мәкальләрнең зур бер мәгънәне кыска гына конкрет, ипле һәм тәэсирле рәвештә әйтеп бирә алулары, тиз тарала алучанлыклары бирәр иҗтимагый хәрәкәт башында торучыларның, ораторлар һәм башкаларның игътибарын һәрвакыт үзенә тарткан, алар мәкальләрнең үз фикерләренә хезмәт итәрдәйрәк отышлы булганнарын алып, үз чыгышларында һаман кыстыра килгәннәр һәм шуның белән сүзләренең тагын да тәэсирлерәк, дәлиллерәк, аның һәм көчлерәк булуына ирешкәннәр. Кайбер мәкальләр кайчандыр үзләре дә шул юл белән туган һәм бирәр лозунг урынында йөргән булулары мөмкин. Мәсәлән, Ленин үз чыгышларында мәкальләрне һәм әйтемнәрне политик көрәш коралы урынында еш файдаланган, аның кайбер китап һәм мәкалә башларына хәтле урыс мәкаль һәм әйтемнәрен файдаланып төзелгән булулары да моны раслый[1]. Шул унай белән М. И. Калининның 1943 елда агитатор-фронтовиклар белән булган утырышында биргән шундый бер күрсәтмәсен китерү артык булмас. Ул анда әйтә:

—Агитация эшендә иң кыены тиешенчә сөйләргә өйрәнү. Беренче карауда бу бик җиңел кебек:—монда нәрсә баш ватып торасы, кеше ике яшеннән үк сөйли башлый ич! дигән кебек кенә күренә. Эшнең асылында бу бик зур һәм авыр эш. Кыенлык нәрсәдә соң? Агитатор үзенең фикере нәкъ ул теләгән тәэсирне ясасын

---

[1]. Мәсәлән: «Шаг вперед, два назад», «Лучше поздно, чем никогда», «Поспешишь—людей насмешишь», «Соловья баснями не кормят», «С больной головы на здоровую», «Журавль в небе или синица в руке» һ. б.

[2]. М. И. Калинин. О коммунистическом воспитании.—Изд. 3. М., 1947, 168 б.

өчен, аны ачык итеп әйтеп бирергә тиеш. Ул вакытта сез фикерне кыска сүз белән генә әйтергә тиешсез, чөнки сезнен вакытыгыз тар. Фикер тынлаучылар өчен ачык һәм аларнын һәркайсына да анлаешлы булырга тиеш[2].

Мәкальләр нәкъ шундый хасиятләргә ия булганлыктан, ораторларга гомумән дә сүз белән эш итә торган кешеләргә үз сөйләмнәре өчен мәкаль алымнарыннан күп нәрсә өйрәнергә була. Шулай ук мәкальләрнен турыдан-туры үз чыгышларында ничек файдаланырга кирәклеге дә шул мисаллардан яхшы анлашылыр. Мәкальләрнен гомумән халык фикерен туплау ягыннан трибунлык роле һәм әһәмияте зур булуы шулардан күренсә кирәк.

**Сигезенчесе—тәрбияви әһәмияте.** Мәкаль ул дөнья күргән тәҗрибәле карт, бер вакытта да рухын төшерми, безнен кайгыларны бүлешеп, шатлыкка да бик артык очынмыйча, ис китмичә генә югартынрак торып карарга, тормыш ваклыкларына бик әһәмият бирмәскә, төп кирәкне кулдан ычкындырмаска, тормышка философларча карарга өйрәтә. Бер карасан, ул үзен яраттыра белгән оста педагог шикелле. Ул шат һәм юл куючан; вакыты белән астан шаяртып, безгә карата ирониялар дә җибәргәли, вакыты белән әче иттереп, агаларча каты иттереп тә әйтеп куя. Шулай да аны яратмаска мөмкин түгел. Чөнки анда үч алу, төртү, чәнчү кебек вакчыллыклар юк, андый эгоистлыклардан ул югары. Ачы әйтсә дә хак, чын дусларча әйтә, көлсә дә дусларча кин күнелдән көлә, акыл бирсә дә коры үгет сатмый, ул аны кызыклы һәм тапкыр мисаллар белән мәгънәле иттереп әйтә белә. Үзенең шундый дусларча, агаларча сүзләре һәм кинәше белән ул безнең тормышнын авырлыгын җиңеләйтергә, кайгы-сагышын, мәшәкатьләрен җинәргә, тормышыбызны баерак, күнеллерәк итәргә омтыла, көрәшкә жегәрлек уята һәм бәхеткә, моратка ирешергә, монын өчен нинди холыклар белән холыкланырга өйрәтә.



Анын бу педагоглык сыйфатын балалар бик яхшы беләләр һәм алар бу тапкыр телле хикмәтле картны бик яраталар. Шунын өчен дә балалар мәкаль китапларын бик яратып кат-кат укучан булалар. (Мин моны үземнең балачагымнан да алып әйтүем.) Бу унай белән мәкальләрнен мәктәпләрдә балаларда тел культурасы тәрбия итү ягыннан әһәмияте зур икәнен онытмыйк. Мәкальләр мәнге яшь һәм тирән тормышлы халыкнын үз йөрәгеннән, анын тел очыннан атылып чыккан шигъри хикмәтле, афористик әсәрләр булганга, туган телнен матурлыгын, тирән мәгънәләрне юраучанлык сәләтен балаларга сиздерү, йоктыру өчен, балаларны мәкальләр белән дә тәрбия итәргә кирәк. Мәкальләрне тагын шунын өчен дә яраталар, ул балаларга аваз матурлыгы, ритм сизгерлеге үстерә, поэтик һәм тапкыр образлар сизү зәвыгын уята, тормыш өчен дә кирәк булган кайбер кагыйдәләр үрнәге алырга, сүзенә дәлил һәм мисаллар китерә белергә, ата- баба мирасына хөрмәт белән карарга өйрәтә. Барлык шул нәрсәләр баланын үз акылы-фикере үсүдә үзенә генә бурычлы булмыйча, халыкнын бүгенге һәм үткән тәҗрибәләренә, тел культураларына бурычлы булуын тойдырып, шулар аркылы анарда илгә, Ватанга, халыкка мәхәббәт тойгылары тәрбия ителә. Мәкальләрнен тәрбияви ролен белгән яхшы педагоглар үз дәреслек китапларында әлифбадан ук гүзәл мәкальләр урнаштыра килделәр һәм киләләр.

**Тугызынчы әһәмияте**—мәкальләрнен анны һәм тормышны үзгәртү коралы булуында. Югарыда санап үтелгәнчә, мәкальләр гомумиләштерелгән мәгънә-хикмәт юралышы (тәгъбире) һәм шунын белән бергә халыкнын социал-тарихи тәҗрибәсенен, ышану һәм хыял байлыкларынын шигъри сурәтләмәсе төсендә телдә гомумиләшүе булганга, алар безнен фикер һәм дөньяга карашыбызны үзләренчә көйләп, үзләренчә оештырып һәм калыплап кына калмыйлар, бәлки үзләренен күп мәгънәле һәм мисаллы булулары белән яки трибунлык һәм тәрбияви-әхлакый карашлары белән безгә тормышны да үзебезчә эшкәртергә, төзергә, үзгәртергә корал булып хезмәт итеп

киләләр һәм итәчәкләр. Аларның төп мәгънә һәм хикмәт көчләре тормышта әйтелгән урыннарында ачылганга, төп рольләре дә гамәлдә, иҗтимагый чара һәм корал буларак, кулланышта үзләрен күрсәтәләр.

Кыскасы, мәкаль тормышта актив сөйләм һәм иҗат әсәре буларак, тере бер организм шикелле яши. Шуның аркасында, ул тормыш белән өзлексез мөнәсәбәттә булып торган кебек, аның сурәтләү чаралары да формаль катып калган калыплар түгел. Шунлыктан мәкальләрнең тормыштагы роле һәм әһәмияте болар белән генә чикләнми. Тормышта мәкальнең очраклары бик төрле һәм үзенчәлекле булганлыктан, монда язылган сүзләр, аларның барын да санап чыгу булмыйча, мөһимрәкләрен күрсәтеп китү генә. Шулай ук аларның әһәмиятләренең дәрәҗәсе шул санау тәртибенчә икән дип тә аңлашылмасын. Мәсәлән, монда саналганча, мәкальнең тел байлыгы ягыннан әһәмияте өченче урында икән дип аңларга ярамый, безнең өчен бүген нәкъ шунысы беренче әһәмият казанырга мөмкин. Кыскасы, аның кайсы яктан әһәмиятлерәк булуы вакытына һәм эштә куллануга карап йөри.

Аннары мәкальнең роле һәм әһәмияте хакында монда күбрәк бүгенге күзлектән карап язылды. Әмма ул рольнең үзе тарихи булып, әһәмияте дә төрле заманда төрлечә булганны да бер дә истән чыгарырга ярамый. Онытмыйк, халык тормышында шундый бер заманнар булган ки, анда аның басма китаплары да, газет-журналлары да, радио-телеграфлары да булмаган. Татарның элек заманда бердәнбер закон—шәригать китабы Коръән булса, ул да—гарәп телендә. Шундый заманнарда халык үзенең тормыш-көнкүрешен уртак бер фикергә, кагыйдәгә салып эш итүендә үзенең акыл-тәҗрибә хикмәте булган мәкальләреннән башка нәрсәгә таяна алсын соң? Димәк, мәкальләр, җәмәгать фикере буларак, ул заманнарда безнең халыкның матбугаты да, закон һәм фән китаплары, иҗтимагый учреждениесе дә, Коръәне дә, хикмәте дә булып яшәгән. Шунлыктан мәкальләрнең тормышта тоткан роле дә, аңа әһәмият бирү дә хәзергегә башка булып, аны хөкем, дәлил, йә тезмә шигырь хәлендә төзеп әйтә белүче профессиональ шагыйрь, сынчы-күрәзәләрнең дә әһәмиятләре бик зур булган. Димәк, тормыш һәм заман кебек, мәкальләрнең рольләре, әһәмиятләре дә үзгәрә, алышына. Хәзер алар, югарыда әйткәннәребездән күренүенчә, күбрәк шигъри мисал, хикмәтле сүзләр һәм хис тойгыларның тапкыр тәгъбир табу очраклары төсендә куллану ягына таба баралар.

---

## КОНКУРС!

Әдәби тәнкыйтьне җанландыру максатларында «Казан утлары» журналы редакциясе 2000 елның гыйнвар аеннан иң яхшы рецензияләргә ачык конкурс игълан итә.

Конкурска килгән рецензияләрнең соңгы 3—4 ел эчендә басылып чыккан әдәби китапка яисә әдәби әсәргә (шигырьләр яки хикәяләр бәйләмен дә кертеп) булуы шарт итеп куела. Күләме машинкада 12 биткә кадәр.

Конкурста җиңеп чыгучылар өчен түбәндәге акчалата бүләкләр билгеләнде:

**I урынга—1000 сум.**
**II урынга—750 сум.**
**III урынга—500 сум.**

Конкурска рецензияләрне хат белән җибәрергә яисә редакциянең әдәби тәнкыйть бүлегенә кертеп тапшырырга мөмкин.

Конкурста язучыларны, тәнкыйтьчеләрне һәм әдәбият сөючеләрне актив катнашырга чакырабыз.

*Редакция.*

*Үткен мәсьәлә*



Фәүзия Бәйрәмова

# ДИНИ ТӘРБИЯНЕ КЕМ БИРЕР?

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

Бүгенге көндә ин мөһим, иң авыр, иң кичектергесез нәрсә, ул—кеше тәрбияләү. Бигрәк тә бала тәрбиясе, баланы тормышка әзерләү. Илдәге тәртип тә, милләтнең ныклыгы да, гаиләдәге бәрәкәт-иминлек тә кеше дигән адәми затның әхлагына бәйләнгән. Тәрбия турында сүзнең, идеаль кеше тәрбияләрлек чаралар эзләүнең бер генә гасырда, бер генә чорда да туктап торганы юк. Элегрәк заманнарда бала тәрбиясе белән ата-ана, нәсел-ыру шөгыльләнсә, сонрак бу гаять четерекле, шәхси эшкә җәмәгатьчелек тә тартыла башлады, аннан инде кеше тәрбияләү дәүләт дәрәҗәсенә менгерелде. Кеше тәрбияләү турында алтын хәрефләр белән әхлакый кодекслар язылды, дәүләт программалары, концепцияләр кабул ителде, һәр система, һәр режим адәм баласын үз идеологиясенә туры килерлек итеп, үзенә хезмәт итәрлек итеп тәрбияләргә тырышты. Ул дәүләтләр инде җимерелеп юкка чыкты, ул ясалма системалардан да инде бернәрсә калмады, ул идеологияләр чәлпәрәмә килеп таралып төште. Ә кеше калды. Дөнья куйган меӊ төрле сорау каршында, үткәндәге ялгыш һәм гөнаһлары авырлыгы астында, киләчәкнең хәвефле билгесезлеге алдында кеше бер ялгызы басып калды. Аның тәрбиясе белән, бигрәк тә яшь кеше тәрбияләү белән, бүген кем шөгыльләнергә тиеш? Гаиләме, җәмәгатьчелекме, дәүләтме? Яна оешып яткан дәүләт һәм режимнар дәрәҗәсендә, дәүләте юкларның—җәмгыятьләр югарылыгында—тагын кеше тәрбияләү буенча юллар эзләү, концепция-программалар әзерләү, яна идеология-кануннар тәкъдим итүләр китте. Һәрберсе үзенең фикерен иң дөресе, кеше өчен бердәнбер котылу юлы, тәрбия чарасы итеп күрсәтергә тырышты. Гомерендә бала чырае күрмәгәннәр бала тәрбияләү турында трактатлар яза башладылар, бердәнбер балалары ялгыш юлда йөрүчеләр милләт балаларын коткару турында концепцияләр тәкъдим итәргә тотындылар... Дәүләт машинасы да карап тормады—ул карышмыйча хезмәт итәрлек яна кеше тибы, яна идеология эзләү чараларын күрә башлады... Әмма болар барысы да тагын яна бер система килгәнче, яна режим туганчы эшләп тору өчен вакытлы чаралар гына иде... чөнки, тарихтан гыйбрәт—һәр яна чор яна кеше тәрбияләү, үз системасына унайлы кеше тәрбияләү өчен тырышачак, үз идеологиясен булдырырга омтылачак иде... Кеше тәрбиясе белән дәүләтләр, җәмгыятьләр шөгыльләнә башлаган көннән, кеше теге яки бу системаның идеология корбанына әйләнде. Шулай итеп, гасырлардан килгән нәсел тәрбиясе өзелде, нәсел тәрбиясе өзелү белән, милли тәрбия кулдан китте, милли тәрбия китү белән—Аллаһ онытылды, адәм баласы Аллаһ тәрбиясеннән китеп, үзе кебек үк тотрыксыз, үзгәрүчән бәндәләр тәрбиясенә, алар тудырган идеологияләргә мохтаҗ булып калды...

Бүгенге көндә кеше тәрбияләү, бигрәк тә бала кешене тәрбияләү турында сүз алып барабыз икән, алдыбызда торган ике сорауга бик ачык җавап бирергә тиешбез. Беренчесе—баланы кем тәрбияләргә тиеш? Икенчесе—ул тәрбия нинди нигездә булырга тиеш?

Әлбәттә, Коръән буенча да, борын-борыннан килгән милли яшәешебез буенча да, баланы дөньяга китергән ата-анасы, гаилә тәрбияләргә тиеш. Бу хакта безгә пәйгамбәребез

Мөхәммәт саллаллаһу галәйһиссәламнең әйтеп калдырган васыяте бар: «Балаларыгызны яхшы багыгыз. Аларны яхшы тәрбия кылыгыз». Ата-ана балага яхшы тәрбияне нәрсәгә нигезләнеп, кайдан белеп бирергә тиешләр соң? Моңа да җавап бик ачык, ул Аллаһының китабы булган Коръәни Кәримдә язып калдырган: **«Ибраһим галәйһиссәлам угылларына васыять әйтте һәм әмер бирде:» «Ий угылларым, шиксез, Аллаһ сезгә ислам динен ирекле итте. Дөрес һәм ныклап Аллаһ динен тотыгыз! Динегез була торып, кяфер булмагыз, мөселман булып яшәп, мөселман булып үлегез!»** *(«Бакара» сүрәсе, 132 аять.)* **«Локман угълын вәгазьләп әйтте: «Ий угълым, Аллаһуны бер генә дип бел, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш итмә, Аның тиңдәше юк, мәхлукъны Аллаһ урнына тоту яки Аллаһуның хатыны вә баласы бар дип игътикад итү ышану, әлбәттә, бик олугъ золымдыр»,—дип»**.*( «Локман» сүрәсе, 13 аять.)*

**«Ий угълым, намазларыңны вакытында укы, һәркайда кешеләрне яхшылыкка өндә, вә гөнаһлы эшләрдән тый, вә сиңа ирешкән катылыкка, бәла-казаларга сабыр ит, тәхкыйк бу әйтелгән нәрсәләр Аллаһ фарыз кылган олугъ нәрсәләрдәндер»**. *(«Локман» сүрәсе, 17 аять.)* Димәк, кешегә яхшы тәрбия бирүнең нигезе, дөрес яшәү нигезе—ислам динендә икән! Кешелекнең котылу юлы—Аллаһ юлында булганнар өчен икән, ике дөньяның да бәхет һәм ниґъмәтләре Аллаһы Тәгалә өйрәткәнчә яшәүчеләр өчен ачыла икән... Димәк, кешегә кеше булып калу өчен, һәлакәтләрдән саклау өчен бары тик Аллаһ юлы, Аллаһ кушканча яшәү генә ярдәм итә икән...

**«Коръән белән күрсәткән бу юлым тәхкыйк сезнең өчен туры юлымдыр, шул туры юлга керегез! Вә мин күрсәткән юлдан башка юлга кермәгез, әгәр башка юлларга керсәгез, ул юллар сезне Аллаһ юлыннан аерырлар»**. *(Терлек» сүрәсе 153 аять.)*

Адәм баласы каршында ике юл бар—Аллаһ юлы һәм башка юл... Тәрбия мәсьәләсендә дә ике генә төрле юл бар—Аллаһ күрсәткән тәрбия юлы—Коръән нигезендә тәрбия һәм бәндәләр тәкъдим иткән башка тәрбия... Башка юлга, тәрбиягә Аллаһтан килмәгән, Аллаһныкы булмаган бөтен юллар, алымнар, өйрәтмәләр, күрсәтмәләр керә, кыскасы, бәндә уйлап тапкан бөтен тәрбия чаралары да башка юлга керә. Кеше тәрбияләү, дөрес яшәү буенча бәндәләр уйлап тапкан чаралар нинди генә матур һәм кызыктыргыч кабырчыкка төрелсәләр дә—коммунистик идеологияме ул, демократик принципларммы, диннән читтә булган милли концепцияме—ул кешене Аллаһ юлыннан читкә алып китә торган вакытлыча күренеш, алдау, хәтта һәлакәт тә булып чыгарга мөмкин. Моның мисаллары тарихта күп булды бит инде! Менә шуна күрә Аллаһ безне башка юлдан китүдән катгый рәвештә тыя, һәлакәт белән кисәтә, бәндәләрен бердәнбер дөрес юлга—Үз юлына өнди... Менә шуна күрә һәр чорның идеологиясе җимерелә бара, бер генә заманның, бер генә кавемнең дә идеаль кеше тәрбияли алганы, идеаль җәмгыять төзи алганы юк әле. Вакыт шаһит—бәндә күрсәткән барлык юллар да бетүгә илтә, кешелек тарихы шаһит—Аллаһ күрсәткән бердәнбер юл бәхет-сәгадәткә, мәңгелек җәннәткә илтә...

**«Алла сезгә Коръән белән юл күрсәтеп, шул юлдан барырга әмер кылды, әмма башка юлдан китүдән тыйды, шаять, башка юлга китеп, һәлак булудан сакланырсыз»**. *(«Терлек» сүрәсе, 153 аять.)*

Кеше иман белән туа... Тәрбия һәм мохит аннан мөселман яки кяфер ясый; яхшы, гадел кеше тәрбияли яки азгын, җинаятьче бәндә әзерләп чыгара. Балага дини, дөрес тәрбияне ата-анасы бирә алмый икән, әле ул дини кешеләр арасына эләгеп, шулар тәэсирендә дөрес юлга басарга мөмкин. Шул ук вакытта, өендә дөрес дини тәрбия алмаган бала, бозык кешеләр арасына эләгеп, юлдан язарга, харап булырга да мөмкин. Бүген нәкъ менә соңгысы күзәтелә дә инде. Ата-ана баласын ашата-эчертә, киендерә, кулыннан килгәнчә, дөньяви белем, һөнәр алырга ярдәм итә... һәм көннәрдән бер көнне кадерләп үстергән баласының наркоман, фахишә, эчкече, карак, җинаятьче, хәрам юлда йөрүче бер бәндәгә әверелүен күреп, телсез кала. Бүген ике гаиләнең берсендә—шушы фаҗига, ике баланың берсе—һәлакәт юлында. Моның шулай икәненә ышану өчен үз тормышыгызга күз салыгыз, урамнардагы үсмерләргә карагыз, статистик мәгълүматлар белән танышыгыз. Бу заман—14 яшьлек наркоманнар, 13 яшьлек фахишәләр заманы... Төрмәләр, хастаханәләр инде боларны сыйдырып бетерә алмый, бер җирдә дә эшләмәгән, эшләргә дә теләмәгән бу гарип буын тонган күзләре белән безнең өскә килә... Һәм без аларны да, үзебезне дә кәгазь вәгъдәләр, ялган юллар белән коткарып калырга маташабыз. Өстебезгә килгән шушы афәттән милли чүпрәккә төренеп кенә котылып калмакчы булабыз. Имеш, без бүгеннән татарча сөйләшеп, татарча яши башласак, бу бозыклыкларның берсе дә калмаячак икән... Бездә баш миенең һаман бер кузәнәге генә эшли, бер идея табабыз да, шуна чат ябышабыз, ә Аллаһы Тәгалә бу мәсьәләдә нәрсә әйтә, кайда ялгыштык, бу афәтләр ни сәбәпле икән, дип төптәнрәк уйлап карарга теләмибез, тәкәбберләнәбез...

Сүзем дәлилле булсын өчен, 1999 елның 20 март көнне Чаллы шәһәрендә үткән зур

жыен кабул иткән рәсми кәгазьләргә мөрәҗәгать итәр идем. *(Алар «Тәрбия» газетасының 1999 ел, 3 санында басылып чыкты).* Бу конференция «Милли яшәеш һәм милли белем» дип атала һәм анда Чаллы шәһәренең мәгариф идарәсе, ата-аналар, галимнәр, халык депутатлары катнашкан. Документлардан күренгәнчә, конференциянең төп шигаре-девизы—милли рухны торгызу. «Халыкның тереклек иясе буларак һәм милләт буларак бетүдән сакланып калуы өчен милли рух яшәргә тиеш», диелгән. Жыенда кабул ителгән бөтен мөрәҗәгатьләр дә шул милли рухны торгызуга, булдыруга, саклауга юнәлдерелгән. Бер караганда, бик матур өндәмә бит—яшәсен милли рух! Милли рух... Нәрсә соң ул милли рух? Документлар белән танышып чыккач, бу «милли рух»ның бары тик мәгърифәтчелеккә, татарча сөйләшүгә һәм җыр-биюгә генә кайтып калганын күрәсең. Милләт өчен, дин өчен, дәүләт өчен көрәшә алырлык көчле милли рухлылар турында сүз бармый монда, бу документларда дәүләт бәйсезлеге, милли азатлык көрәше турында бөтенләй дә сүз юк. Әмма күңелгә иң тигәне—бу мөрәҗәгатьләрдә Аллаһ сүзе дә юк! Кеше хәтле кеше тәрбияләүдә ислам диненең роле бөтенләй искә алынмаган, анарга татар мәктәпләрендә генә түгел, гаиләләрдә дә, җәмгыятьтә дә урын каралмаган! Һаман да шул—татарча сөйләшик, һаман да шул—җырлыйк та биик... Мәктәпләрдә ислам диненә урын юк икән, ичмасам гаиләләрдә булса да балаларны Коръән нигезендә тәрбияләргә кирәклеге турында нигә мөрәҗәгать белән чыкмый соң бу зур җыен? Мең кешелек залның күпчелеге ата-аналар булган бит югыйсә, нигә аларга Аллаһ сүзен җиткерү өчен бер генә дин әһеле дә чакырылмаган, бала тәрбияләүдә ислам диненең роле турында бер генә махсус чыгыш-доклад та билгеләнмәгән? Бу җыенны уздыручыларның төп максатлары чыннан да татар милләтен саклап калу булса, алар иң беренче эш итеп шул милләтләрне барлыкка китерүчегә—Аллаһ сүзенә мөрәҗәгать итәрләр иде. Әллә, югыйсә, максат башкадамы—бу җыенны оештыручыларга үзләренең төп эш урыннарын—татар мәктәпләрен генә саклап калу кирәкме? Ул мәктәптән кемнәр чыга—ислам динен, татар милләтен, татар илен саклый алырлык көчле рухлы татарлармы, әллә базарда көнбагыш чиртеп, сату итеп, гайбәт сатып көн күрүче татар хатыннары һәм буынсыз-сәрхүш татар ирләреме? Әллә максат тагы да ераграк яшерелгәнме, тагы да куркынычракмы—милли конфит кәгазенә төреп, милләтне Аллаһ юлыннан читләштерү, ераклаштыру башландымы? Соңгы вакыттагы күзәтүләр шуны күрсәтә—милләт турында сөйләгәндә, ислам динен читләтеп үтә башладылар, «иманга кайтыйк» дигән сүзне дә, мәгънәсенә төшенеп тормыйча, гадәти бер сүз кебек кенә әйтеп узалар... Иманга кайту—башка түбәтәй кию генә түгел бит әле ул, иманга кайту—бөтен тормышыңны Аллаһы Тәгалә кушканча көйләү, яши башлау дигән сүз.

Менә минем кулымда, Аллаһны әйләнеп узып, милләтне коткарырга уйлаган, милли концепция, милли мәсләк эзләгән тагын бер язма. Ул язучы Галимҗан Гыйльмановның 1999 елның 19 мартында «Мәдәни җомга» газетасында басылып чыккан «Милли мәсләгебез кайчан булыр?» дигән язмасы. Менә кадәр сәяси-милли мәсьәләләргә бик үк кагылмаган бу автор да җиң сызганып кисәк кенә «милли идея» эзли башлаган. Автор милләт тормышының күп өлкәләрендә хәлнең гаять аянычлы, фаҗигале икәнен әйтә дә, эшне тагы шул «милли идея»гә китереп тери: «Милли идея булмаса, милләт бетә, сүнә, зәгыйфьләнә, хәлсезләнә, үлә», ди ул. Моны бәндә әйтә, ә шул мескен бәндәне дә, милләтләрне дә, дөньяның үзен дә барлыкка китергән, тоткан һәм теләгән вакытында юкка чыгара алган Аллаһы Тәгалә бөтенләй икенче төрле әйтә:

**«Ий кешеләр! Әгәр Аллаһ теләсә, сезне гөнаһларыгыз сәбәпле бөтен нәселегез белән һәлак итеп, юк кылыр да, сезнең урыныгызга үзенә итәгать итә торган кавемне китерер, Аллаһ бу эшне эшләргә кадир булды».** *(«Хатыннар сүрәсе», 133 аять.)*

**«Әгәр Аллаһ теләсә, Аңа итәгать итмәгәнегез өчен сезне юк итәр дә, сезнең урыныгызга үзе теләгән затларны хуҗа кылыр, үзегезне башка кавем балаларыннан бар иткән кебек».** *(«Терлек» сүрәсе, 133 аять.)*

**«Һәрбер өммәтнең билгеләнгән әҗәле бар, әгәр аларга әҗәлләре килсә, бер сәгать иртә килмәс һәм бер сәгатькә кичекмәс».** *(«Әгъраф» сүрәсе, 34 аять.)*

Милли рух... Нәрсә соң ул—милли рух? Нигә бүгенге татар зыялылары, котылу юлын бары тик милли рухта гына күрәләр, милли рухтан да югарырак, көчлерәк, чистарак илаһи рух барлыгын күреп бетермиләр? Нигә милләтне коткарып калуда әзер ярдәмнән—Аллаһ ярдәменнән файдаланырга теләмиләр? Коръән—бөтен кешелек дөньясын тәрбияләр өчен, дөрес юлга чыгару өчен, коткарып калу өчен җибәрелгән бердәнбер күрсәтмә, иң гадел сүз—Аллаһ сүзе бит югыйсә... Бүген һәр бәндә милләтне коткарып калырга күрсәтмә бирә, һәр милләт үзенең милли рухына, миллилегенә таянып, исән калмакчы була, һәм үзара сугышып, фетнәләшеп, җәһәннәм упкынына якынлашып килә... Димәк, кешегә кеше булып калу өчен,

милләтләргә милләт булып дөрес яшәү өчен милли рух кына житми икән әле, иң беренче, Аллаһыдан килгән ИМАНны сакларга кирәк икән, бөтен тормышыңны Коръән нигезендә, Коръән гыйлеме буенча көйләргә кирәк икән...

Алыйк авыл халкын. Боларда милли рух юк, дип бүген беребез дә әйтә алмый. Авыл халкы бөтенләе белән татарча сөйләшә, булдыра алганча, татарча киенә, милли татар ризыгы— бәлеш-коймак ашый, татарча бер генә концерт, бер генә спектакльне дә калдырмый карап бара... Асыл сыйфатлары да бар—эшчән, ярдәмчел, сабыр. Әмма шушы татарча сөйләшкән, татарча яшәгән эшчән авыл ире үлгәнен-калганын белмичә эчә, татарча өздереп жырлаган, моңлы, унган татар хатыны ире өстеннән йөри, зина кыла... Хәер, болар татар авыллары өчен инде гадәти бозыклыклар, бу хәлләргә хәзер беркем шаккатмый, чөнки милли авылларыбызга азгынлыкның гомердә булмаганнары үтеп керде. Татар авылларында да хәзер гомосексуализм (ирләрнең бер-берләре белән зина кылуы), хайваннар белән яшәү, зират өсләрендә зина кылу, наркоманлык һәм төркем белән зина кылу кебек ата-баба белмәгән азгынлыклар бар. Авылларда бер-берләрен үтерүчеләр, үз-үзләренә кул салучылар, асылынып үлүчеләр коточкыч рәвештә арта бара... Болар барысы да татарлар бит...

Бүген һәр авылда диярлек хан сараедай мәчетләр бар, әмма алар буш тора. Чөнки бәндәнең күңеле буш, жаны буш, андагы иман нуры инде сүнеп бара. Милли мәсләк эзләгәндә, менә шундый татарларны да истә тотарга кирәк. Бүгенге авыл халкы, хәтта яхшы исәптә йөргәне дә, Аллаһны гадәт буенча гына искә ала, әмма мең төрле сәбәп табып, дин тотмыйча гына яшәп ята. Анда дөньяның терәге—аракы, «каты валюта»—аракы, бөтен эшне эшләтүче—аракы, татар тормышының, татар авылының төп символы—аракы. Кунак килсә—аракы, кайгы килсә—аракы, шатлык килсә—аракы, бала туса—аракы, туйлар житсә—аракы... Милли мәсләк эзләүчеләрнең үзләренең дә кулларында еш кына —аракы... Зур жыеннарда жыелып утыручылар бу халыкка нәрсә дип мөрәжәгать итәрләр иде икән? Исерек милләткә, айнып дөньяга карар өчен нинди мәсләк, нинди концепцияләр кирәк? Эзләмәгез, бәндәнең әле бу афәткә каршы да чара таба алганы юк, эчкән кешенең эчүдән туктаганы, котыла алганы юк, әгәр Аллаһы теләмәсә, әгәр бәндә Аллаһы таләп иткәнчә яши башламаса...

**«Аларга бу газап шул сәбәпледер: Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртми, ул кавем үзләрен үзгәрткәнгә чаклы».** *(«Табыш» сүрәсе, 53 аять.)*

Авыл жирендә яхшысы да, яманы да күз алдында булса, шәһәр жирләрендә милләтнең фажигасе тимер ишекләр артында бара. Бигрәк тә, шушындый зур жыеннар үтә торган Чаллы кебек эшчеләр шәһәрендә... Эшсезләр шәһәрендә... Нигездә, авыллардан күчеп килгән, белем ягы уртача булган, гомер буе заводта майга батып кара эштә эшләгән, ярты гомерен коммуналкаларда күршеләр белән торып уздырган бу татар гаиләләре, бу татар ирләре бүген күбесе эшсез. Боларның күбесе, өйләрендә бикләнеп, хатыннары тапкан соңгы акчаларына, хурлыктан һәм чарасызлыктан кара эчү белән эчә башлады. Мондый өйләрдә балаларның тормышы—жәһәннәм. Нәтижәдә, күп очракта, йә баланың да эчә башлавы белән, йә үтерешү-жинаятьләр белән, йә баланың урам кочагына ташлануы белән тәмамлана. Болай эчмәгәннәрендә дә көн саен бер проблема, хәсрәт, гауга, адәм баласына ялгызы гына хәл итәргә бик авыр булган мәсьәләләр... Бу татарларга бүген эш кирәк, балаларын төрмәләрдән һәм империя армиясеннән йолып алып калырга кирәк, укып бетергәч, тамак туярлык урынга булса да урнаштырырга кирәк... Чаллы жыенының эшмәкәрләргә булган мөрәжәгатен укып, мин еларга да, көләргә дә белмәдем. Имеш, әйдәгез, эш урыннарында татарча сөйләшик, татар булыйк! Бүген, йөзәрләгән, меңнәрләгән татарлар, кыскартылып, эштән чыгарылып ташланганда, башка төрлерәк тә мөрәжәгать кирәк иде бит, интеллигент иптәшләр! «Татар житәкчеләре, татар байлары, кул астыгызда эшләүче милләттәшләрегезгә карата гадел булыгыз, эшләгәннәре өчен вакытында һәм гадел итеп түләгез, мондый авыр заманнарда, аларны эшсез калдырып, урамнарга куып чыгармагыз, кяферләрнең ишек төпләрендә йөрергә мәжбүр итмәгез, бер-берегезне ташламагыз, татарлар!» дип мөрәжәгать итәргә дә мөмкин иде һәм кирәк иде! Милли яшәешне бары тик татарча сөйләшүгә генә кайтарып калдыру, ул—мәсьәләне бик тар аңлау, тирәнгәрәк төшеп торырга теләмәү, милләт тормышындагы авыр һәм фажигале якларны күрмәскә тырышу... Милли яшәешнең нигезендә г а д е л л е к ятарга тиеш. Ә гаделлекнең ачкычы—Коръәндә, милләтнең сакланып калу юлы—Коръәндә. Бу сорауларга башка жирдән жавап эзләмәгез, барыбер таба алмассыз, тапсагыз да, ул жаваплар вакытлы гына булыр, ялгыш булыр... **«Коръәнне куеп кая барасыз? Аллаһ китабын ташлап, Аллаһ жәннәтенә ничек барасыз?»** *(«Чорналу» сүрәсе, 26 аять.)*

Күргәнебезчә, бала тәрбияләүне ата-ананың, тәрбиячеләрнең үзләрен тәрбияләүдән башларга кирәк икән. Һәм «татар булыйк» дигән бер яклы, бер күзәнәкле өндәмә белән генә түгел, ә шушы татар гаиләләренә мөселман рухы, ислам динен кертү өчен тырышырга,

көрәшергә кирәк. Югыйсә, күз алдыбызда без милләтебезне югалтып барабыз. Дөньядагы шушы хәтле бозыклыкка, пычраклыкка, явызлыкка каршы татар булып кына көрәшеп булмый, бу бозыклыкларны, бу явызлыкларны бары тик Аллаһы ярдәме белән, Аның юлында булсан гына җиңәргә мөмкин. Әгәр татарның зыялылары һаман шушы хакыйкатьне аңламыйлар икән, милләтнең череп юкка чыгуына алар үзләре үк шаһит булырга мөмкиннәр...

Бүген татар ирен коткарып калу бик авыр булачак. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, үз-үзләренә кул салучыларның, йөрәк һәм башка кисәк үлем белән чагыштырмача яшьтән үлүчеләрнең 80-90 проценты—ир-атлар икән. Җинаять юлында үлүчеләрнең, төрмәләрдә утыручыларның да күбесе ир-атлар. Эчкече, наркоманнарның да 90 проценты—ир-атлар. Бу—безнең милләтнең дә ир-атлары, кемнәрнеңдер уллары, аталары, туганнары... бер татарлык кына бу бәндәләрне коткарып калу өчен җитәрме? Эчкән иреннән җәбер-золымыннан гарык булган, юлдан язып барган улын эзләп төннәр йокламаган анага «милли рух» даруы тоттырып кына, аны бу бәла-казалардан коткарып алып буламы? Нигә әле баласы итәгендә чагында ук без бу ананы Аллаһы Тәгалә кушканча яшәргә чакырмыйбыз, шуна өйрәтмибез? Нигә әйтелергә тиешле иң мөһим сүзне—б а л а л а р ы б ы з н ы  и с л а м  д и н е  н и г е з е н д ә  т ә р б и я л и к, дигән сүзне бүген әйтмибез, шушы зур җыеннарда әйтмибез? Иртәгә бу ана өчен дә, бу бала өчен дә, бу милләт өчен дә инде соң булырга мөмкин бит!!!

Әгәр гаиләдә ата-ана дини булса, алар балаларына дини тәрбия бирүне төп максат итеп куялар, ягъни, иң беренче эш итеп балаларын Аллаһны танырга өйрәтәләр, бу дөньяның безгә Аллаһның бер бүләге икәнлеген, дөньяга да, безнең гомерләребезгә дә Аллаһ хуҗа икәнлеген, безнең бу дөньяда зур сынау—Аллаһ сынавы үтүебезне балаларына яшьтән үк аңлаталар. Андый бала бу нигъмәтләрнең барысы өчен дә Раббысына рәхмәтле булып үсә, шөкерана итә белә, кайгы хәсрәтләрне зур сабырлык белән үткәреп җибәрә белә, бары тик Аллаһның гына колы була, Аллаһның бәддогасыннан курку аны начарлык һәм бозыклыклар эшләүдән һәрвакыт тыеп тора. Балага менә шушындый дини тәрбия, дини гыйлем бирү—ата-ананың иң зур бурычы. Менә шушылай тәрбияләнгән һәм Аллаһы Тәгалә кушканча яшәүче бала—ата-ананың картлык көннәрендә җан тынычлыгы, таянычы, ярдәмчесе. Баланың ата-анага мөнәсәбәте, аларны тәрбия итүе дә Аллаһы Тәгалә кушканча булачак:

**«Без кеше затына ата вә анага изгелек итәргә әмер бирдек».** *(«Урмәкүч» сүрәсе, 8 аять.)*

**«Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһуга гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф»та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә!»** *(«Ягъкуб балалары» сүрәсе, 23 аять.)*

Аллаһы Тәгалә кешеләргә картайган ата-аналарын карауны, аларга изгелек итүне ә м е р итеп әйтә. Әгәр без бүген ислам дине буенча яшәсәк, картлар йортлары да, ятимнәр, балалар йортлары да булмас иде... Аллаһ әмерен үтәмәгән татар баласы ата-анасын, башкаларны тынлар, бүгеннән рәхим-шәфкатькә кайтыр дип әйтеп буламы? Яшьлектә балаңа нинди тәрбия бирсәң, картлыгыңда шуны кайтарып аласың...

Ата-анадан дини тәрбия күрмичә, җәмгыятьтә дини кешеләргә очрап, дин тота башлаган балалар да бар. Менә монда тагын бер проблема килеп туа. Өйдә ата-ана әле диннән ерак, өстәлдә аракы да тора, кунаклар да җыела, җыр-музыка яңгырап тора, намаз юк, харам-хәләлне аеру юк, дин юк... Ә бала инде дин юлында. Аллаһыга чын күңелдән ышанган, Ул кушканча яшәргә омтылган, намазларын вакытында укыган, ураза тоткан бу бала өчен ата-ананың дин тотмавы ничек авыр тәэсир иткәнен аңласагыз иде сез?! Чиста, саф бала инде Бөек Хакыйкатькә барып җиткән, зәгыйфь куллары белән Аллаһының нурына ябышкан, ә аның газиз ата-анасы һаман җырлый-бии, кәеф-сафа кора, дөнья артыннан куа, дөньяның бар мәгънәсен ашап-эчүдә һәм типтереп яшәп калуда гына күрә... Болар, бала күз алдында, үз аяклары белән җәһәннәмгә баралар. Бала бу һәлакәтне аңлый бит, мондый тормышның ялгыш икәнен күрә, чөнки ул инде дин юлында, аның инде күңел күзләре ачык, ул адашып калган ата-анасы өчен өзгәләнә, дингә өндәп карый, җавап булмагач, йомыла, үзенә китә... Баласының тамагын туйдыруны гына максат итеп куйган ата-ана бу нарасыйга да, үзләренә дә иң беренче чиратта, җан азыгы—иман нуры кирәклеген башларына да китермиләр... Шуны беркайчан да онытмыйк: 10-11 яшьлек балаларның әле барысы да диярлек Аллага ышана, аларга вакытында кул суза, бергә-бергә шушы изге юлдан—Аллаһ юлыннан атлап китәргә генә кирәк. Югыйсә, үсә төшкәч, ул балаларның җанына хуҗа булырга теләүчеләр табылачак, ата-ана сузмаган кулны шайтан сузачак, һәм алга таба бу бала ата-ана башына бәла булып әверелергә мөмкин. Әгәр һәр гаилә берәр генә дини, тәртипле бала тәрбияләп үстерсә дә, без инде күптән җир йөзендә җәннәт төзи алган булыр идек. Бер генә мөселман баласы тәрбияләп үстерсәк тә...

Күреп торабыз—бүген татар гаиләләре әле хакыйкый диннән шактый ерак. Мәктәпләребезгә дә дин кертелми—чөнки дин дәүләттән аерылган. Урамнарыбыз һәм шәһәрләребез азгынлык һәм җинаять оясы... Дөньяга якты өмет белән туган бала кайлардан, кемнәрдән алсын ул дини тәрбияне? Аны, кулыннан җитәкләп, кем дөрес юлга алып чыгар? Аның бу дөньяда ялгыз түгел икәнлеген, галәм кинлекләреннән карап һәм күзәтеп торучы Раббысы-яклаучысы барлыгын, бәхетле булу өчен Ул кушканча яшәргә кирәклеген кемнәр аңлатыр бу нарасый балага?! Дөньяның яктылыгын, матурлыгын, тормышның искиткеч гүзәл бер бүләк икәнлеген аңлап, шуңа куанып өлгерерме ул, яки бары каралыкта гына кайнап, кыйналып һәм каргалып, бары тик явызлык күреп һәм үзе дә явызланып, күңелендәге изгелек орлыклары ачылмаган да килеш юкка чыгып, бәхетсез булып бу дөньядан китеп барырмы? Вакытында дөрес юлны күрсәтмәгән өчен ата-аналарына, мөгаллимнәренә, милләттәшләренә рәнҗеп тагы бер татар дөнья белән хушлашырмы?

Бүген балага, татар баласына ярдәм кирәк. Бүген кешегә ярдәм кирәк. Рухи ярдәм, дөрес сүз кирәк, дөрес юл күрсәтү—дөрес дин кирәк. Кемнәр бирә моны балага? Тәрбияне кемнән башлыйк—тәрбиячеләрдәнме, тәрбияләнүчеләрдәнме? Дөрес, милли мәктәпләребез бүген балаларга булдыра алганча дөньяви гыйлем бирергә тырышалар, аларга шуның өчен дә зур рәхмәт. Әмма бу милли мәктәпләребез дә безнең үзебезнеке түгел бит. Безнең балаларыбыз, тәрҗемә дәреслекләр аша, кяфер идеологиясен аңнарына сеңдерәләр, бары тик, элеккедән аермалы буларак, бу эш татар телендә алып барыла. Бу мәктәпләр—Россия дәүләтенеке, алар Россия законнары нигезендә эшлиләр, Россия кайчан тели—шунда аларны яба ала, идеологиясен үзгәртә ала. Без моны үз башыбыздан кичердек бит инде. Шуңа күрә, аз гына булса да форсат булганда, без милли мәктәпләрне дин өчен, милләт өчен, дәүләт өчен көрәшчеләр әзерләүгә файдаланып калырга тиешбез. Милли рух ул татарча сөйләшү, татарча җырлау-бию генә түгел, милли рух ул—шушы милләтең, динең, илең өчен җиһад утларына да керерлек итеп яшь буынны тәрбияләү. Ватанлы, җирле, телле, динле булырга теләгән һәр милләт иң беренче эш итеп көрәшчеләр хәзерли. Ни кызганыч, Чаллы җыенында кабул ителгән мөрәҗәгатьләрдә ни дәүләт бәйсезлеге, ни милли азатлык өчен көрәш турында ник бер сүз булсын! Әйтерсең лә, безнең инде үз мөстәкыйль дәүләтебез бар, әйтерсең, менә бу милләтчеләр ачтырып биргән татар мәктәпләре дә мәңгелек булачак, инде хәзер көрәшеп тормасаң да була икән, бары тик татарча сөйләшергә генә кирәк һәм Россия барысын да алдыбызга китереп салачак икән! Никадәр беркатлылык, никадәр реаль тормыштан аерылу, никадәр саташу! Бүген балаларны татар телендә чукындыру, иманнарыннан яздыру эше алып барыла, сезнең һәм безнең күз алдында, телевизор экраннарыннан, радиодан, Мәскәү язган мәктәп дәреслекләреннән бала күңеленә шовинизм белән кушылган фашизм юшкыны тутырыла, чит диннәр, чит мәсләкләр, чит гадәтләр сеңдерелә. Бүген мәктәпләрдәге һәр татар укытучысы моны яхшы аңларга, милләт, дин, дәүләт өчен көрәшчеләр сафына басарга, көрәшчеләр әзерләргә тиеш. Безнең башка юлыбыз, башка мөмкинлекләребез юк. Менә шушындый вакытта укытучыларның Аллаһ гыйлеме белән коралланган кодрәтле, какшамас булулары, ислам динен белүләре, аны кеше тәрбияләүдә, көрәшче тәрбияләүдә дөрес итеп файдалана белүләре ничек кирәк! Коръәндә бит милләтне саклап калу юллары да, илле, дәүләтле булу өчен нәрсә эшләргә кирәклеге дә, адәми затны ничек Аллаһ кушканча көчле, шәфкатьле, сәламәт итеп тәрбияләү турында да—барысы да бәйнә-бәйнә әйтеп бирелгән. Бүген балалар каршына килеп баскан һәр укытучы аларга Аллаһ гыйлемен тапшыручы, илтеп бирүче булырга тиеш. Безнең бу эшне эшли алырлык башка оешкан көчебез юк. Әмма балаларны ислам дине нигезендә тәрбияләүне гарәп әлифбасын белүгә генә кайтарып калдырырга ярамый. Ислам дине ул хәреф тану гына түгел, ул—синең бөтен яшәү рәвешең, дөньяны кабул итүең, дөньяга бәян. Ислам дине ул—бөтен уйларыңны, гамәлләреңне Аллаһ кушканча тәртипкә салу һәм яшәү, Коръән буенча белгәннәреңне үз тормышыңда куллану һәм бу тәҗрибәне башкаларга да җиткерү. Мәктәпләрдә һәр укытучы үз фәне буенча бу илаһи гыйлемне балаларга җиткерә алыр иде. Өстәмә материаллар, күргәзмә әсбаплар эзләп әллә кайларга барып җитәргә кирәкми, татар телендәге «Коръән тәфсире»н укып карасагыз да, бик күп сорауларга җавап табарга мөмкин. Хәзер дини китаплар бик күп, кайсы телдә телисең—гарәпчәме, татарчамы, төрекчәме, урысчамы—файдалан гына. Аллаһы гыйлеме татар мәктәпләренә һәр укытучы белән, һәр фән белән керергә тиеш. Әйтик, тарих фәнен бүгеннән Коръән аятьләре белән ачыклап, Аллаһының бу хәлләр турында алдан ук кисәтүен әйтеп, кавемнәрнең, илләрнең, дәүләтләрнең, хәтта цивилизацияләрнең юкка чыгу тарихларын Коръән белән дәлилләп, аңлата-укыта башларга мөмкин. Үзе дә дини булган хак мөселман укытучысы шулай эшләр иде дә. Хәтта кяферләр язган тарихны да, Аллаһының гыйлеме белән коралланып, үзебезгә кирәк якка дәлилләп күрсәтергә була. Татар балаларын

милләт өчен, дин, дәүләт өчен көрәшкә әзерләү мәйданы—нәкъ менә тарих дәресләрендә, мөмкинлекләр, дәлилләр, мөгаллимнәр кулында, шушы форсаттан оста һәм нәтиҗәле итеп файдалана белергә генә кирәк. Тарих дәресләге белән бергә «Коръән тәфсире»н генә файдаланса да, укытучы үзе өчен дә, балалар өчен дә дөньяны өр-яңадан ачар иде...

**«Үткән өммәтләрдән күпме өммәтне Без һәлак иттек, алар исә һәлакәт килгәндә кычкырдылар, ялвардылар, аларга ошбу вакыт котылмак, качмак вакыты түгелләр, диелде».** *(«Сад» сурәсе, 3 аять.)*

**«Бу кяферләрнең сыйфаты—фиргавен каваме вә болардан әвәлге кавемнәр кебекләр, ул кавемнәр Аллаһуның аятьләренә ышанмадылар, Аллаһ аларны гөнаһлары өчен газап белән тотты. Тәхкыйк, Аллаһу Тәгалә куәте вә үч алуда каты газаплыдыр».** *(«Табыш» сурәсе, 52 аять.)*

Бүгенге балаларга мәктәпләрдә суны—уттан, атомны—атомнан аерып алырга өйрәтәләр, әмма хакны—ялганнан, хәрамны—хәләлдән аерырга өйрәтә алмыйлар, чөнки аның өчен Аллаһның гыйлемен белергә кирәк. Коръән адәм баласын көферлектән, хәрамнан, зинадан, эчкечелектән, отышлы уеннардан, азгынлыктан тыя, гадел булырга, ихлас, саф күңел белән яшәргә өнди, Аллаһтан башка бер заттан да курыкмаска, кыю булырга, һәр изге эштә җиңеп чыгарга өйрәтә. Шушыларны белмичә, ничек тормышка аяк басарга мөмкин?!

Әдәбият, биология, астрономия, география, химия, физика, анотомия, психология укытучыларына да Коръән иксез-чиксез гыйлем, нигъмәт, файда бирер иде. Бу фәннәрнең күбесенең үзәгендә кеше тора, тереклек дөньясы тора, безне чорнап алган галәм тора... Ул чагында урта мәктәпне тәмамлаучылар һаман «кеше маймылдан килеп чыккан» дип алданып йөрмәсләр иде, бу табигать, ай һәм йолдызлар үзеннән-үзе барлыкка килгән, димәсләр иде. Боларның барысын да барлыкка китерүче һәм саклап торучы Аллаһы Тәгалә икәнлеген мәктәптән үк белеп чыгарлар иде. Ата-аналарның күңел сизгерлегенә таянып әйткән: «Аллаһ бар ул, балам», дигән сүзләрне мәктәп кулында булган фән ачкычлары аша дәлилләп, һәр татар баласына бу Бөек Хакыйкатьне аңлатып чыгарыр иде.

**«Ул тетрәмәсен өчен җир өстенә мәхкәм тауларны ыргытты вә сезгә елгалар бар кылды, җирдә һәм диндә юллар бар итте, шаять Аллаһ күрсәткән туры юлдан китәрсез».** *(«Умарта кортлары» сурәсе, 15 аять).*

Коръәндә йолдызларның, ай, кояшларның төзелеш-тормышыннан алып, табигатьтәге һәр күренеш—искән җилләрдән алып яшен яшьнәү галәмәтләренә кадәр—барысы да тасвирланган, аңлатылган. Елга-суларның хикмәте, көн вә төннәр алышынуы сәбәпләренә хәтле әйтелгән. Коръәндә кеше күңеленең иң тирән яшерелгән сыйфатларына хәтле әйтелә, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеге кисәтелгән, әйтелгән. Боларның барысы хакында да бала күңеленә яшьтән салып калдырырга кирәк, ул Аллаһның кодрәтен, мәрхәмәтен кечкенәдән аңлап-тоеп үссен, Аллаһның җәзасыннан курыксын, нәфесен тыярга өйрәнсен, яхшы белән яманны үзе аера белсен, көферлектән саклансын...

**«Коръән кешегә файдалы һәм зарарлы нәрсәләрнең һәммәсен сөйлидер».** *(«Чытты» сурәсе, 11 аять.)*

**«Ул—Аллаһ сезгә күрсәтәдер һәм сөйләп белдерәдер, һәм дөньяның бөтен хәле белән Үзенең бер генә икәнлеген исбат итәдер».** *(«Чорналу» сурәсе, 13 аять.)*

Күпчелек татар зыялылары кебек, мин дә үз милләтемне яратам, кызганам, аның бәхетле булуын, бай булуын, сәламәт нәсел калдыруын, гыйлемле кавем булуын телим. Әмма кеше булу өчен, милләт булып сакланып калу өчен бу саналганнарның гына житмәгәнлеген дә беләм, мин боларның барысыннан да югарырак, алтын таҗ урынына—ИМАНЛЫ БУЛУ сүзләрен язып куяр идем, татарның, татар халкының, иң беренче чиратта, иманлы булып, Аллаһы Тәгалә кушканча яшәвен теләр идем. «Татар булыйк», дигән сүзләрне әйткәндә, һичшиксез, «Мөселман булыйк», дип тә өстәр идем, «милли рух» янәшәсенә «дини рух» сүзен дә язып куяр идем. Безнең милләт ике канатлы кош кебек—милли һәм дини рух тигез булганда, көчле булганда гына аны бу упкыннан чыгарып, үз биеклегенә күтәреп булачак. Сыңар канат—милли рух белән генә милләт ерак китә алмас, чөнки менә Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте юк:

**«Аллаһ ничек хак юлга күндерсен, иман китергәннән соң кяфер булган кавемне?»** *(«Гимран» сурәсе, 86 аять.)*

Әгәр без, татар балалары, бүгеннән бер гаилә, бер өммәт булып, бер-беребезгә ярдәмләшеп, Коръән кушканча яши башлыйбыз икән, бу дөньяда безне җиңүче булмаячак. Моны да Аллаһы Тәгалә вәгъдә итә:

**«Әгәр Аллаһ сезгә ярдәм итсә, сезне җиңүче булмас».** *(«Гимран» сурәсе, 160 аять.)*

Димәк, тәрбияне дә үзебездән башлыйк, кулга Коръән тотып башлыйк...

*Чаллы,*
*1999, август.*

## *Дәрдмәнднең тууына 140 ел*

# «ТАНЫЛМЫЙДЫР КЕШЕ ТЫШЫННАН...»

Дәрдмәнднең бер шигыре әнә шундый юллар белән тәгәлләнә. Закир (Мөхәммәтзакир) Рәмиевнең, ягъни шагыйрь Дәрдмәнднең бөтен гомер агышын һәм эшчәнлеген чагылдырган бик тә хак сүзләр. Ул да бит аз сөйләгән, әмма, үз халкының киләчәк өметле көннәре өчен дип, байтак кына нәтиҗәле эш-гамәлләр кылырга өлгергән. Татар иҗтимагый халәтенең яңа бер борылышында күпләргә үрнәк булырдай итеп фәкать үзенчә генә балкыган, үзенә генә хас тормыш юлын үткән шәхес.



*Рәмиевләр гаиләсе. Уңнан сулга: Дәрдмәнд, Садри Максуди һәм Камилә Рәмиева—Максуди. Бельгия. Льеж, 1914 ел.*

Язмышы, биографиясе дә аның бик тә үзенчәлекле. Башлыча хәлфә һәм муллалар даирәсеннән булган элгәреге татар зыялыларының берсенә дә охшамаган язмыш иясе. Хәтта шул чор урыс әдипләре, урыс зыялылары арасыннан да биографиясе белән аңа тиң кешене табуы читен. XX гасыр башында урыс зыялыларының да күпчелеге шул ук руханилар яисә урта дәрәҗәле хезмәткәр вә чиновниклар даирәсеннән чыккан. Дәрдмәнд исә шул заман патша Россиясенең эре буржуазиясенә якын торучыларның берсе, кырыклап алтын шахталарының хуҗасы... Әнисе Камилә ягыннан шул нәселдән булган Төркия галимәсе Гадилә Айда әтисенә багышланган «Садрый Максуди Арсал» китабында (1991) Рәмиевләрне «Россиянең алтын корольләре» дип атый.

Әдәбият мәйданына беренче адымнарын атлаган көннәрдән башлап Дәрдмәнд даирәсенә тартылган, җитди әсәрләренең күпчелеген Рәмиевләр басмаханәсенә тәкъдим итүне кулай күргән Галимҗан Ибраһимов аның иҗатын һәм эшчәнлеген бик югары бәяләгән. Шагыйрьнең кинәт вафат булуы хәбәрен алганнан соң бастырган кыскача бер хушлашу мәкаләсендә ул, шәхсән Дәрдмәндне күз алдында тотып: «Болар уяну күгендәге беренче йолдызлардан иде»,— дип яза. Шуннан соң берничә еллар соңрак Төркиядә дөнья күргән тәүге тарихи зур хезмәтендә (1927) мөһаҗир әдип һәм тарихчы Габделбарый Баттал да Дәрдмәнд турында болай дип язган: «Казан төркиләре телендә язучы шагыйрьләр арасында иң өстен шагыйрьләрнең берседер. Иске төрки әдәбияты белән дә җитди шөгыльләнгән, Нәваи, Лотфи, Бабур кебек чыгатай шагыйрьләренең җыентыкларын игътибар белән укыган булуы да ачык билгеле. Шуңа күрә Дәрдмәнд шагыйрьләр арасында иң белемлесе булып саналырга хаклы».

Чынлап та:

Танылмыйдыр кеше гәрчә тышыннан,
Танып була аны кылган эшеннән.

* * *

«Россиянен алтын корольләре»—ике бертуган Шакир вә Закир Рәмиевләрнен халык мәнфәгатен күз унында тотып башкарган хезмәтләре шактый исәпләнә. Үз шахта-прискаларына янәшә авыл һәм бистәләрдә алар мәчетләр, мәдрәсәләр салдыртып, аларны үз исәпләренә тотканнар. Әлегрәк ачылган берничә зур мәдрәсәгә ярдәм итүләре дә мәгълүм.

Башкортстандагы татар авылы Юлык китапханәсендә унтугызынчы елның февралендә китапханәче вазифасы өяз совет хакимияте тарафыннан яшь драматург Мирхәйдәр Фәйзигә йөкләтелә. Әмма күпләр әле Мирхәйдәрнең нигездә Рәмиев байлар исәбенә ачылган һәм тотылган китапханәне революция көннәрендәге талаулардан соң тәртипкә китереп эшли башлавын белмиләр. Чөнки драматургның көндәлек дәфтәрләрендәге андый язмалар сызылган яисә Советлар чорында бастырып чыгарылмаганнар иде.

Хәзерге Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районында зур гына татар авылы бар. 1895 елгача ул тирәләр буш дала булган. Әлеге нигезләнәчәк авылдан өч чакрымдагы нагайбәк атлы казаклары хуторындагы коедан берничә бөртек алтын табылган. Табыш хакында милләттәш Рәмиевләргә хәбәр ителгән. Тиздән буш далада берничә шахта ачыла. Алар тирәсендә бистәләр барлыкка килә. Шул бистә юл-сукмаклары тоташкан урынга Рәмиевләр үз идарә йортларын төзеп куялар. Шулай итеп Балкан авылына нигез салына. Гасыр башында анда ир балалар мәктәбе, 1906 елда кызлар мәктәбе, беркадәр соңрак кул эшләренә өйрәнү бүлмәсе ачыла. Балканда туган һәм Совет хакимияте чоры актив хатын-кызларыннан булган Шәмсенәһар (Кояш) Вәлитова алтмышынчы елларга караган бер истәлек мәкаләсендә гасыр башына нисбәтле вакыйгаларны искә төшереп яза: «Башта малайлар белән укыдым... 1905 елның язында, имтихан алу дәресләрендә Дәрдмәнд үзе катнашты, минем тапкыр җавабымны ишетеп сөенде. Соңыннан Дәрдмәнд белән бергәләп фоторәсемгә төштек».

Шакир белән Закир Рәмиевләр узган гасырның сиксәненче елларыннан башлап үз матбагаларын булдыру турында хыялланалар. Закир Төркиядә яшәгәндә ике бертуганның язышкан хатлары моңа мисал булып тора. Шакир энесенә, андагы матбугат, басмаханәләр эшчәнлеге белән таныш, өйрән, дип яза. Туксанынчы елларда алар үз матбагаларын ачарга талпынып та карыйлар. Ләкин татарларны ничек тә урыс диненә күчерергә хыялланган патша хөкүмәте, патша түрәләре Идел буенда милли матбугат булдыруга каршы көрәшәләр. Исмәгыйль Гаспринский киңәшен тотып, 1900 еллар тирәсендә басмаханә ачарга ниятләгән Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман Кәримовка беренче ярдәм кулын сузучылар да бертуган Рәмиевләр булган. Гыйльман ахун аларның да киңәш-табышы белән Оренбургка барып төпләнә, Гани бай Хөсәеновның да матди ярдәменә таянып, таушалганрак бер рус типографиясен сатып ала. Ә вакытлы матбугат ачу мөмкинлекләре исә татарларга 1905 елгы халык кузгалышларыннан соң гына тудырыла.

Рәмиевләрнең «Вакыт» газетасы 1906 ел башында, айга ике сан чыгучы «Шура» журналы 1908 елның гыйнварыннан милләттәшләр арасында тарала. «Вакыт» китап-журнал басмаханәсе 1909 елның гыйнварыннан заманга яраклы китапларны да бастыра башлый.

Шәриф Камалның беренче хикәяләре һәм хикәя җыентыклары да 1909 елдан башлап Рәмиевләр басмаханәсендә басылып чыгарылганнар. 1910 елдан Шәриф Камал үзе дә «Вакыт» китап ширкәте хезмәткәре.

Гасыр башында Россиядә төрле хәйрия җәмгыятьләре оеша башлый. Оренбургта да шундый берничә җәмгыять барлыкка килә. Шуның татарлар оештырган иң абруйлысы «Белек». 1906 елда оешкан бу җәмгыять иганәчеләре исемлеге башында Рәмиев байлар да бар. «Белек» шул елда ук үз исемендәге «халык китапханәсе»н оештыру карарына килә. Шәһәр уртасында махсус бина арендага алына. 1907 елда ачылган татар китапханәсенә соңрак Исмәгыйль Гаспринский, ә 1919 елдан Хөсәен Ямашев исемнәре бирелгән. Җитмешенче еллар урталарында укучылар өчен җайсызрак бинага күчерелгән ул китапханә эшчәнлеген бүген дә дәвам итә әле. Унынчы елларда Мөхәммәтзакир Рәмиевнең икенче бер хәйрия җәмгыяте рәислегенә сайланганлыгы да мәгълүм.

Шушы урында Рәмиевләр, аеруча Закир Рәмиев белән дистә еллар буена якыннан аралашкан һәм шагыйрьнең иҗтимагый карашларына теләктәш булган әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәримигә сүз бирик. Дәрдмәнд вафатыннан соң, аның 1929 елда чыккан шигырь китабына сүз башында ул болай яза: «Дәрдмәнднең кешелек ягы бик югары булып, ул гадәти татар байларына бер дә охшамаган иде. Ул алдау, хәйлә, риялану, икейөзлелек итү шикелле нәрсәләргә дошман. Аның үзендә андый сыйфатлар юк. Сүзендә, мөгаләмәсендә соң дәрәҗәдә туры. Аның әйткән сүзе, биргән вәгъдәсе һәртөрле документлардан,

вексельләрдән нык. Артык юмарт кеше булмаса да... халык файдасына иганә бирүдән тартынмый. Җәмгыяте хәйриягә, рус мәктәпләрендә укучыларга һәрвакыт матди ярдәм итеп торды. Чит мәмләкәт мәктәпләрендә үз хисабына берничә шәкерт укытты...»

Әлеге сүзләр элекке хуҗаларны һәм байларны хурлау шаукымы чәчәк аткан бер заманда язылган. «Урыс мәктәпләре» дигәндә исә Фатих Кәрими Россиянең югары һәм һөнәри уку йортларын күз алдында тота. Дәрдмәнднең үз балалары да, башлыча, «Хөсәения»нең рөшди өлешен тәмамлаганнан соң, урыс һөнәри мәктәпләрендә һөнәр үзләштергәннәр. Олы улы Искәндәрне ул, җир асты байлыклары белгече итмәкче булып, «Хөсәения»дә рөшдине тәмамлаганнан соң берничә ел Петербург гимназиясендә укыткан. Германиядәге Тау белгечлеге академиясенә җибәрергә ниятләве сәбәпле, немец телен яхшы үзләштерсен өчен, улын үз телләрендә сөйләшүче башкала немецлары гаиләсенә фатирга урнаштырган. Бельгиядә инженерлык дипломы алырга хыялланган улы Гариф та башта һөнәр училищесында укыган.

Фатих Кәрими фикерен Орск төбәге белән Юлык авылы картлары да раслыйлар иде. Алар карашынча да, Мөхәммәтзакир бай гадел хөкемле, ипле-җайлы кеше булган. Үтенеч белән мөрәҗәгать итүчеләргә ничек тә булса ярдәм итәргә тырышкан. Яшьләрнең һөнәр үзләштерүен, укуын хуплаган. Шушы җәһәттән булачак галим Зәки Вәлидине дә искә төшерү ятышлы булыр сыман. Зәки Вәлиди, кайчандыр Мәҗит Гафури да башлангыч белем үзләштергән Үтәш мәдрәсәсеннән соң, Оренбургтагы «Хөсәения»гә барып керә. Ләкин шук шәкертләр ятрак киемле һәм бик үпкәчән холыклы Зәки шәкертне беренче көннәрдән үк ят күрәләр. Дога-намазларны дөрес укымыйсың, дөрес кылмыйсың, дип эзәрлеклиләр. Шуннан соң Зәки, яклавын үтенеп булса кирәк, мәдрәсәнең Тышкы идарәсе әгъзасы Закир әфәнде янына килә. Ул вакытта сөйләшү-киңәшү никадәргә сузылгандыр, мәгълүм түгел. Һәрхәлдә, Закир Рәмиев тәкәббер бу шәкерткә Казанга барып, укуын анда дәвам иттерергә киңәш бирә. Анда бару һәм башлангыч чорда яшәү өчен дип, Зәкигә илле сум акча тоттыра. Болар хакында Зәки Вәлидинең Төркиядә басылган истәлекләрендә язылган.

* * *

Дәрдмәндкә багышланган хатирәләрне мин Орск шәһәрендә эшләү дәверемдә үк тупларга керешкән идем. Моңа 1959 елда ике вакыйга сәбәпче булды. Беренчедән, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы җаваплы сәркәтибе Вил Ганиевтән хат алынды. Хат шәһәрдә 1911 елдан бирле эшләп килүче, революциядән соң Мулланур Вахитов исемен йөртүче татар китапханәсенә юлланган иде. (Китапханә 1962 елдан соң ябылды.) Китапханә мөдире Лина Әбләисова мине әлеге хатның эчтәлеге белән таныштырды. Дәрдмәнд дигән шагыйрь шушы шәһәрдә укыган һәм революциядән соң вафат булган икән. Туганнары бармы? Язма мирасы берәрсендә сакланмыймы? Каберен табып, фотосын Казанга җибәрә алмассызмы? Хат эчтәлеге шулайрак иде.

Шул ук көздә шәһәргә Татар җыр һәм бию ансамбле килде. Хәтерем ялгышмаса, берданбер концерты Иске белән Яңа шәһәрләр урталыгында урнашкан Төзүчеләр мәдәният сараенда узды. Артистлар белән бергә композитор Җәүдәт Фәйзи, шагыйрь Әхмәт Ерикәй дә килгәннәр иде. Икенче көнне очрашып сөйләшкәндә алар да шул ук сүзләрне кабатладылар диярлек. Җәүдәт ага туганнан-туганы Мирхәйдәр Фәйзигә караган истәлек белән кызыксынуын да белдерде. Яңарак кына әле алар икәү Мирхәйдәрнең ераграк торган бер туганыннан чәй мәҗлесеннән кайтканнар иде. Аерылышканда икесе дә кабат Дәрдмәндне искә төшерделәр.

Шул көннәрдә үк без, берничә егет, Орск шәһәренең ике зур зиратындагы кабер ташларын барлап чыктык. Ләкин игътибар итәрдәй нәрсә тапмадык. Шуннан соң шәһәр картларына мөрәҗәгать иттек. Мәгъсум Шәмсетдинов, элекке приказчик, кайчандыр Мирхәйдәр Фәйзи оештырган драма түгәрәге әгъзасы булган кеше, Дәрдмәнднең шәһәрдән читтә җирләнгәнен хәбәр итте. Иске шәһәр Җаек суының Азия ягында, кечерәк тау битләвенә төзелгән. Ләкин шәһәр, үсә-үсә, елга белән тау аралыгындагы инкүлекләргә дә җәелгән. Зиратлар да шул инкүлеккә урнашканнар. Шунлыктан шәһәрнең түбәнге өлешләрен егерме-егерме дүрт ел саен су баса. 1957 елның язында гына шундый афәт кабатланган иде. Иске шәһәрнең элекке үзәк урамнары гына диңгез булып җәелгән Җаекта кечерәк утрау хәлендә калганнар иде. Шуңа күрә шәһәр байларының күпчелеген елга аръягындагы үрдәге авыл зиратына җирли торган булганнар икән. «Мөхәммәтзакир бай да шул Ильяс утары зиратында гүргә иңдерелде»,—диде Мәгъсум карт.

Җаек суыннан өч чакрым өстәрәк урнашкан элекке татар-башкорт атлы казаклары

авылы инде утызынчы еллар башында төзелә башланган Яна шәһәр читендәге бистәгә әверелгән иде. Төзүчеләр бистәсе читендә элекке авылның бер-ике урамы гына шәйләнә. Зират авылдан ярты чакрымда үрдәрәк, Урал-тауның сөзәк итәгенә сыенган булган. Хәзер ул сугыш башлангач төзелгән хәрби завод биләмәсендә калган иде.

Кырык жиденче еллар тирәсендә Мәгъсум карт шул заводның иске коймасы буенда Дәрдмәнд каберен тапкан булган. Бер иптәше белән алар яртылаш җиргә ингән кабер ташын күтәребрәк тә куйганнар. Ләкин алтмышынчы еллар башында инде каберстанның ул чите дә завод биләмәсенә күчкән иде. Биләм-мәйдан тирәли биек таш койма—аның артында ни-нәрсәләр барын күреп тә булмый. Койма янәшәсеннән хәзер асфальт юл, аның ягасыннан тимер юл уза.

* * *

**1918** елның гыйнвар ае азакларында Оренбургны кызыллар беренче мәртәбә сугышып алалар. Шул елның июль башларынача шәһәрдә Совет хакимияте урнаштырыла. Байлар шәхси милекнең табыш китерүче, ялланган эшчеләр тотылучы өлешен яна хакимияткә тапшырырга тиеш булалар. Дәрдмәнд тә иң әүвәл ишегалдындагы аерым бинадагы «Вакыт» басмаханәсен тапшыра. Басмаханәнен табыш алу өчен оештырылмавын, аны тотарга елына ун-унбиш мен чыгым кирәген шәһәр халкы белә. Ләкин таләп шундый—тапшырырга кирәк... Истәлек-хатирәләргә караганда, хәреф җыючылар һәм башка хезмәткәрләр янына Ярулла кияве белән хуҗа үзе дә килгән. Эшчеләргә ике атналык хезмәт хакын һәм, басмаханә ярты ай дәвамында эшләрлек итеп, башка кирәк-яракны бирәләр. «Бай зур төргәк акчаны үз кулы белән тоттырды»,—дип сөйлиләр соңыннан. Кабул итүчеләр төркеме башында элекке «Хөсәения» шәкерте, 1913 елдан «Вакыт» басмаханәсендә эшләүче яшь коммунист Заһид Шәркый-Йосыпов та була. Шәриф Камал шәкерте, соңгы елларда гына корректорлык вазифасын башкара башлаган яшь кеше. Булачак күренекле журналист. Шушы ук типография җирлегендә булса кирәк, тиздән Заһид Шәркый-Йосыпов мөхәррирлегендә шәһәрдә большевистик рухлы икенче татарча газет—«Оренбург мөхбире» борын төртә. Беренчесе—«Урал» ун еллар әүвәл Тимерша Соловьев басмаханәсендә басылган була.

Бу вакыйгалардан берәр ай чамасы алдарак, Оренбург шәһәрендә Бөтенбашкорт корылтае узган көннәрдә, Рәмиевләр гаиләсенең төп милкенә—алтын шахталарына кул сузу омтылышы була инде. Декабрь азакларында корылтайда мөстәкыйль Башкортстан мохтариятын төзү карары кабул ителә. Яна мохтариятның чикләре билгеләнә. Шул чикләр биләмәсендәге җир өсте һәм җир асты байлыклары яна оешкан автономиянең милке дип игълан ителә. Ә ул мәйданда Рәмиевләрнең күпчелек алтын шахталары урнашкан. Барлык прискалардан җыелган алтынны туплау урыннары да шул тирәләрдә. (Алар 1913 елда Баймакта төзелгән бакыр кою заводындагы махсус цехта эретелергә тиешләр.)

Әйе, унсигезенче елның январь ае—Рәмиевләр нәселенә бик күп йокысыз төннәр китерә. Алар ике ут арасында калалар. Һавада төрле тарафтан йөрәк алгыч «экспроприация» сүзе яңгырап тора. Аклары, кызылларга каршы көрәшердәй хәрби көч туплау, корал алу өчен дип, байлар мал-мөлкәтен мәҗбүриләп йолкыйлар. Кулына корал тотардай һәр солдат өчен көненә унар сум түләмәсәләр, окопка төшеп сугышыр кешеләре дә калмаячак. Кызылларның да гамәле шундый ук—гаскәрне киендерү, туендыру һәм коралландыру өчен акча, бигрәк тә алтын кирәк аларга да. Инде менә яна башкорт хөкүмәте үз милли гаскәрен җыярга керешә икән. Гыйнвар урталарында Чиләбедә башкортлар Себер хакимияте белән яшерен килешү төзегәннәр дигән хәбәр ишетелә. Идел-Уралдан башлап Себерне үз кулларында тотучы ак генераллар яңа башкорт хакимиятенә күп күләмдә корал һәм башка кирәк-яракны бирергә вәгъдә иткәннәр, имеш. Алары да бушлай була алмый бит. Димәк, алтын шахталары тирәләрендә капшану-эзләнүләр башланачак. Әлеге дә баягы—«экспроприация».

Менә шундый чарасыз калган көннәрнең берендә Дәрдмәнд белән хатыны Мәхүпҗамал абыстай Орск шәһәренә китәргә җыена башлыйлар. Заманына күрә авыр, бик тә мәшәкатьле сәфәр: өч йөз илле чакрым арада тимер юлы әле төзелә генә башлаган һәм ташланган. Әйләнгеч юлны сайларга туры киләчәк. Шунлыктан үзләре белән зур йөк тә алмый юлаучылар. Баргач кирәк буласы кием-салым гына диярлек. Оренбургтагы йортта барлык нәрсә үз урынында кала: шагыйрь еллар дәвамында туплаган бай китапханә, эш кәгазьләренен тиз арада кирәк булмасының барысы да, хатлар, бүләкләр, фотолар, кием-салым, затлы савыт-саба... Зәйнәп белән Ярулла кияү, аларның ике яшь баласы; тәүге

бәбиләрен кетүче Искәндәр белән Шәрифзадә; кече кызлары Рауза, хезмәткәрләр. Искәндәр белән Шәрифзадә баласын карашыр дип, яңарак кына кабул ителгән чая кыз Минсафа... Әйе, әлегә бу вакытлы гына китеп тору. Тормыш агышы таләбе генә...

* * *

Әлгәреге тыныч елларда шагыйрь гаиләсе иртә яздан башлап кара көз көннәре якынлашканчы диярлек таш калада яшәмәгән. Баштарак, кар сулары төшкәнче үк, ир-ат юлга чыккан, урыннарга барып, шахталарның җәйге сезонга әзерлеген күзәтеп йөргән. Аннары берничә экипажга төялеп, сабантуйга барырга җыенучылар кебек гөрләшә-сайраша, яз башының матур бер көнендә бергәләшеп бөтен гаилә диярлек сәфәргә кузгалган. Көр атлар, тук балалар дигәндәй—һәр сәфәр бәйрәм төсен алган. Табигатьнең теләсә кайсы гүзәл почмагында тукталып, уйнап-көлеп озаклап ял иткәннәр, аш-су әзерләгәннәр...

Орск тарафына атлы юл саф, тонык сулы Җаек елгасы буйлап сузылган. Вакыт-вакыт кына ул Сакмар суына табарак елышкандай. Җаек белән Сакмар буенының урман-әрәмәлекләрендә җәй башында бихисап төрле чәчкәле болыннар, аланнар күп. Анда билдән печән, ә су буйлап тезелешкән каен вә усаклар арасында—җиләктер, карлыгандыр, кызыл һәм кара бөрлегәндер, гөләп җимешедер—һич җыеп бетермәле түгел. Тау битләүләрендәге куаклыкларда әчкелтем кыргый чия, төче дуләнә җимешләре. Әледән-әле кыргый алмагач төркемнәре дә очрап куйгалый. Чын ожмах урыны инде менә!



*Закир Рәмиев-Дәрдмәнд.*
*Гасыр башы сурәте.*

Шул юлдан атларда дистә еллар йөрелгән. Барысы да көйләнгән, җайланган. Кайсы авылда, кемнәргә кереп кунып чыгасы, кайсысында озаккарак тукталасы—алдан сөйләшенгән, кирәк-ярак белән алдан кешеләр җибәрелгән... Һич ялыкмыйча Орскига житеп була... Кайнаталарда берәр атналап кунак булганның соңында шөлдерләрен чылтыратып юлларын дәвам иткәннәр. Туып-үскән Юлык та, Баймак төбәге шахталарын берләштергән Солтан да, кылганлы Оренбург даласының үзенчәлекле саф, үзенә бер хуш исле һавалы Шәйхан да, Балкан авыллары да аларны сагынып көтеп торалар. Җәй әйләнәсендә Рәмиевләр аларның барысын да йөреп чыгачаклар. Кайберләрендә кайта-кайта яшәп алачаклар әле.

Менә Балкан авылы янәшәсендәге нагайбәк казакларының «Восьмой хутор»ына нисбәтле бер күренеш, Мәҗит Гафуриның мәгълүм повестеннан бер өзек. Эшчеләр күл буенда алтын юалар. «Ат башы хәтле алтын» да шул тирә приисктан табылган. Рәсми документларга теркәлгән авырлыгы—24,5 килограмм.

«—Байлар килә,—диделәр.

Без башыбызны күтәреп караганда, теге яшел түбәле өйләр ягыннан байлар белән управляющийлар әкренләп без эшләгән җиргә таба киләләр иде... Байлар икәүсе дә гәүдәгә бертигез, озын һәм пар аргамак кебек килбәтле, таза кешеләр. Аларның зур, куе кара мыеклары тулы битләренә матурлык биреп, байлыкларын күрсәтеп torгандай күренә. Өс киемнәре европача булса да, үзләренең татарлыкларын, икенче төрле әйткәндә, мөселманлыкларын саклар өчен башларына кара түбәтәйләр кигәннәр. Аларның шәм кебек туры булуларыннан һичбер кара эш белән мәшәкать күрмәгәнлекләре беленеп тора...

Шул арада теге яшел түбәле өйләр ягыннан җәйнең эссе көненә карап киенгән, чәчәкләрдән-чәчәкләргә очып йөргән күбәләкләр кебек, сигез-ун яшьләрендә ике кыз йөгереп килделәр... Алар, килү белән назланып һәм иркәлек күрсәтеп, әтиләренең итәкләренә сарылдылар...»

Повесть авторы телгә алган Балкан авылы янәшәсендәге ясалма күл әле дә бар. Ә менә яшел түбәле йорт урынында хәзер ике катлы яңа мәктәп бинасы. Яшел түбәле йорт та, соңрак аның янәшәсендә Шакирның өченче хатынына багышлап төзелгән купшы манаралы затлы өй дә соңгы сугыш елларында янып беткәннәр. Байлар утарындагы нык таш сарай һәм шул тирәне саф суы белән тәэмин итеп торучы тирән артезиан коесы гына калган.

* * *

Шагыйрьнең Орск шәһәре даирәсе... Узган гасыр ахырларында ук Мәскәүдәге фабрикант Морозовлар белән сәүдә элемтәсе тотучы Мостафа карт Борнаев инде вафат. Шәһәрнең иң бай кешеләре исәбендә хәзер аның туганнары, уллары Сөләйман, Габдуллажан, Мәхмүтжаннар. Шәһәрнең үзәк урамында Габдуллажан, Мәхмүтжан һәм ширкәттәшләренең бик зур сәүдә йорты. Шуның аскы катында кибетләр, келәтләр. (Утызынчы—алтмышынчы елларда анда зур ашханә булды). Өске катта Мәхмүтжан гаиләсе яши. Мәхүпжамал апалары белән җизнәләре өчен дип тотылган кунак бүлмәләре дә бар.

Закир белән Мәхүпҗамал бу юлы да шунда урнашачаклар. Җаек суына табарак бер урам аша үз өендә Габдуллажан гаиләсе яши. Аның да өе ике катлы, кибет өлеше тау ташыннан салынган, өсте—бүрәнәдән. Май урталарында ул йортка Искәндәр гаиләсе дә кайтып тупланачак: бер айлык уллары Бәшир белән өчәүләп. Габдуллажаннар янәшәсендәрәк кенә шәһәрнең зур таш мәчете. Ул башлыча шәһәр байлары көче белән узган гасырның соңгы чирегендә салынган һәм җиһазланган. Элек-электән шагыйрь гаиләсе җомга намазларына шушы мәчеткә йөри. Элегрәк шагыйрьнең мәчет каршындагы мәдрәсәгә шәкертләр белән очрашуга да килгәләгәне булган. Бу төбәк, бу тирәләр аның күңеленә бик якын.

Мәхүпжамалның сеңлесе Маһруй шәһәрнең икенче бер байларында кияүдә. Шагыйрьнең бажа-сы Әхмәтжан Рәхмәтуллин монда иң зыялы затлар-дан санала. «Кара Әхмәтжан» тоткан мәдрәсәнең даны тирә-якларга таралган. Унынчы еллар башын-нан бирле Маһруй да кызлар мәктәбе тота, кыз балаларны укыта. Закир белән Мәхүпжамал элекке елларда килүләрендә ул мәктәп белән мәдрәсәдә дә еш булганнар. Кайбер шәкертләрнең еллык имтихан нәтиҗәләре теркәлгән шәһадәтнамәләренә ша-гыйрьнең имза куйган очраклары да булгалый.



*Сулдан-уңга: Мостафа Борнаев (Орск сәүдәгәре, Дәрдмәнднең кайнатасы), Тимофей Саввич Морозов, Шакир Рәмиев.*

Соңгы елдагы буталчыклар башланганчы монда яшьләр һәм зыялырак кешеләр Хәйрия җәмгыяте оештырган «Шәрекъ китапханәсе» белән «Шәрекъ клубы»на җыелалар. Анда драма һәм әдәбият сөючеләр түгәрәкләре гөрләп эшләп тора. Күмәкләшеп Казанда, Оренбургта басылган әдәби әсәрләрне укыйлар, фикер алышалар. «Шәрекъ китапханәсе» иганәсенә кайсы авторның ниндирәк әсәрен бастыру кирәклеге турында бәхәсләшәләр. Әйдәп йөрүчеләре Әхмәт Исхак була. Мирхәйдәр Фәйзи җитәкләгән драма түгәрәге дә бик актив эшли, ел әйләнәсенә өчәр-дүртәр мәртәбә «театр уены» уйныйлар. Узган кыш сәхнәләштерелгән «Галиябану» пьесасында җырланган «Галиябану» көе әле дә һәркемнең күңел түрендә яши диярлек. Хәзер ул җыр башкарылмаган кич утырышлар да, мәҗлесләр дә юктыр, мөгаен.

Дамелла Әхмәтжан гаиләсе дә, элекке муллалар гаиләсенә хас булмаганча, җыр, музыкага гашыйк. Чалманы мәчет, мәдрәсәгә барганда гына киярга мәҗбүр Әхмәтжан мулла, өендә мандолинада үзе дә моңлы, ятышлы итеп уйнап җибәргәли. Җырлы, уенлы төрле мәҗлесләр оештыруга да Маһруй белән икесе бик һәвәсләр. Кызлары Әсма да алардан һич калышмый—кунаклар алдында чатнатып шигырьләр дә сөйли, башкаларга кушылып моңлана да белә.

Тагын бер заманча зыялы гаилә—«Сары Әхмәтжан» гаиләсе. Сары Әхмәтжан 1911 елда шәһәргә беренче булып «синематограф» дигән сихерле тамаша кайтарткан кеше. Үзәк урамнан үрдәрәк булган, соңыннан Пугачев исемен йөртәчәк урам чатына кино күрсәтү йортын төзеткән. (Үзәк урамдагы «Шәрекъ клубы» бинасы җимерелгәч, 1 нче май исемендәге татар клубы Совет хакимияте чорында шушында булачак. Ул да алтмышынчы еллар башында ябылачак.)

1918 елда Орскига килеп яши башлагач, Закир бай элгәреге байлар белән табын

мәжлесләрендә һәм җомга намазларында гына күрешкәләсә, яшьрәк һәм зыялырак Әхмәтҗаннар белән ешрак очрашкан. Аларны үзенә якынрак торучы әнгәмәдәшләр итеп күргәндер, мөгаен. Ә 1920 елның урталарыннан башлап ул яна хакимият вәкиле, элекке Орск өязе биләмәсендәге татар-башкортлар арасында эшләү өчен җибәрелгән яшь комиссар Габдулла Дәүләтшин белән еш кына очрашкан. Габдулла Орск янәшәсендәге Ильяс утары кешесе, мулла-мөгаллим токымыннан. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган һәм берәр ел чамасы шунда укыткан да. Унсигезенче ел башында атаман Дутовка буйсынган татар-башкорт атлы казаклары фетнәсен кузгатып, кызыллар ягына чыгуны оештыручылардан. 1918 елның февраль башларында Башкорт мохтарияты җитәкчеләрен, шул исәптән Зәки Вәлидине дә кулга алып, өч ай чамасы Совет Башкортстаны җитәкчесе булган кеше. 4 апрель иртәсендә ак казаклар баш күтәргән, вәлидичеләрне азат иткәннәр. Совет Башкортстаны җитәкчелеге тиздән куып таратылган. Аклар Оренбургны алган көннәрне инде Габдулла, хыянәтче сыйфатында булса кирәк, большевиклар зинданында каршылаган. (Большевиклар зинданына ул кабат 1943 елда Казанда утыртылачак. Милләтчелектә гаепләнеп.)

Менә шундый катлаулы язмышлы комиссар була Дәүләтшин. 1920-21 елларда Орскида «Ирек йолдызы» газетасын нәшер итә. Атналык, ике битле газета. Беренче битендә татарча рәсми хәбәрләр, Совет дәүләте карарлары тәрҗемәләре яисә аларның аңлатмалары. Икенче биттә төбәк тормышын чагылдырган материаллар һәм «әдәби почмак». Анда, нигездә, Оренбург төбәге әдип-шагыйрьләренең заманга хасрак шигырьләре яисә кечкенә әдәби парчалары урнаштырыла. Мөхәррире «А. Дәүләтшин». Төп хезмәткәрләренең берсе—комиссарның яшь кәләше, Мирхәйдәр Фәйзи агасының кызы Хәлимә. Ул әле февраль революциясе башланыр алдыннан гына монда гимназия тәмамлаган, татарча да укый-яза белә. Ире аңа еш кына урысча хәбәрләрне тәрҗемә итәргә биргәли.

«Мөселман» комиссарның эш урыны да өязнең башка комиссарларыннан аерым—«Шәрекъ клуб»ында урнашкан. Шунлыктан шәһәр халкы аның янына иркен килеп-китеп йөри. Мөселман солдатлары да моннан өзелмиләр—кайчандыр комиссарның Мирхәйдәр кайнише оештырган драма түгәрәге эшләвен дәвам иттерә.

Шагыйрь Дәрдмәнд тә ара-тирә шул «Шәрекъ клубы»на килә, үзәктән һәм Казан, Уфа, Оренбургтан җибәрелгән газет-журналларны караштыргалый. Соңыннан Хәлимә апа сөйләвенчә, комиссар Габдулла белән дә ул шунда озаклап гәпләшеп утыргалаган. Дөнья хәлләрен сөйләшкән-барлашканнардыр, күрәсең.

* * *

Бездә, алтын прискалары хуҗасы булган Дәрдмәнд турында язганда, еш кына, «прискаларын ул Совет хакимиятенә үз кулы белән тапшырган», диләр. Чынлап та, кайбер бай-буржуйлар кебек ул чит илгә качмаган, туплаган байлыгын тулаем ил халкына калдырган диярлек. «Барлык мал-мөлкәтен үз кулы белән Советларга тапшырган», дип язу шагыйрьнең мирасын халкына кире кайтарганда бигрәк тә актуаль булган, әлбәттә. Шулай дип акланмыйча 1927-29 елларда Дәрдмәнднең беренче шигырь китабын туплап чыгару мөмкин дә булмагандыр. Шундый ук хәл 1959 елгы китабына да кагыла. Шул елда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр» чыгарга ике-өч ел кала шагыйрьнең Казанга килгән улын, Совет хакимиятен урнаштыру өчен барган көрәш-бәрелешләрдә катнашкан, шунда бер кулын терсәктән өздереп кайткан Җәгъфәр Рәмиевне әле кайберәүләр «буржуй улы» дип битәрлиләр. Атасына багышлап «буржуй улы» язган калын истәлек язмаларын журналда да, нәшриятта да кабул итмиләр. Шуннан соң Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гомәр Бәширов аңа әдәбият институтына, Мөхәммәт ага Гайнуллинга мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә. Шул хатирә язмалары һәм кайбер өстәмә мәгълүматлар җирлегендә булса кирәк, әлеге «Сайланма әсәрләр» басылып чыга.

Ләкин, халык мәкалендә әйтелгәнчә, мал бирмәк—җан бирмәк. Алтын байлары Рәмиевләр өчен дә ул шулай булган, әлбәттә. Ерак морза бабалары кайчандыр кичергән афәтне—җирсез һәм мал-мөлкәтсез калу афәтен егерменче гасыр Рәмиевләре дә җиңел генә кичермәгәннәрдер. Ерак морза бабалары байлыкларын яшь урыс патшалыгы йотканнан соң инде алар ике-өч гасыр дәвамында әз-әзләп хәл җыйган, баштарак сәүдә, аннан соң җир байлыкларын чыгару белән шөгыльләнеп, ярыйсы ук мал, байлык тупларга өлгергән булганнар. Һәм менә көтелмәгән яңа афәт, яңа түнтәреш.

«Мәгез, алыгыз гасырлар дәвамында туплаганнарыбызны»,—дип бирәү дә атылып чыкмаган, билгеле. Шул исәптән демократ рухлы Рәмиев байлар да. Яшен яшәгән, ашын ашаган карт шагыйрь шулай эшләргә ниятләсә дә, яшьрәк буын, ата-бабадан килгән

мирасның инде төп хуҗалары андый ният белән һич тә килешмәсләр иде. Шакир вафатыннан соң приискалар белән төп җитәкчелек эше аның олы улына кала, икенче зур төбәк—Чиләбе төбәге байлары кияве Сөләйман җилкәсендә булган. («Офыктагы рәшәләр» дигән хезмәтемдә мин, Орск кешеләре хатирәсенә нигезләнеп, ул эшне Искәндәр башкарган дип язган идем. Закир улы Искәндәргә, 1914 елда Германиядә укып кайтканнан соң, Сөләйман җитәкчелегендә төп белгеч вазифасы йөкләнгән икән. Совет чорында да ул «Башкирзолото» трестында баш белгеч вазифаларын башкарган, баш идарәче булмаган.)

1918 елның февраль азакларында Дәрдмәнднең, кинәт җыенып дигәндәй, Орскига китеп баруы да шул гасырлар дәвамында тупланган мал-мөлкәтнең бер өлешен булса да саклап калырга ниятләүдер кебек күзаллана. Баштарак ул монда төпләнеп калырга һич тә уйламаган бит. Оренбургтан соңгы елларда көндәлек тормыш өчен кирәк булган кайбер әйберләрен генә үз янында тоткан. Әмма шунысы хак—Орск шәһәре приискаларга якынрак урнашкан. Моннан аларның теләсә кайсына берничә көндә барып җитеп, яки кирәкле кешене юллап була.

Ни өчен шундый хәвефле эшләрне башкарырга Дәрдмәнд үзе киткән, олы улы Искәндәрне җибәрмәгән соң? (Сөләйман бу вакытларда, мөгаен, Орскидан да көнчыгыштарак урнашкан приискаларның берсендә мирасны саклап калуны оештыру эшләре белән шөгыльләнгәндер. Һәрхәлдә, кайбер эзләр, шул исәптән Балкан авылы янында җиргә күмелгән яртышар потлы ике алтын «кирпече» табылдыгы шуңа ишарәли.) Бердән, Искәндәр тәүге баласын көтә, хатыны авыр хәлдә ята. (Верхнеуральск кызы Шәрифзадә Дашкова барыбер соңрак икенче баласын тудырганда гүр иясе булачак.) Икенчедән, Искәндәр әле яңарак читтән кайткан, прииска кешеләрен дә белеп бетерми. Авыр чакларда кемнәргә таянырга, кемнәргә четереклерәк йомышлар кушарга була—аермый диярлек. Башкалар әле яшь, тәртә арасына керергә өлгермәгән.

Шагыйрьнең Оренбургтан Орскига китүен мин шулайрак күзаллыйм. Ана, һичшиксез, прииска-шахталарына якынрак яшәү тиеш булган. Приискаларын һәм алардан җыелган алтыннарны Зәки Вәлиди оештырган башкорт мохтариятына тапшырасы булса да, Совет хакимиятенә «илтеп бирәсе» булса да—төп хуҗалар ул да Сөләйман энесе бит.

Һәрхәлдә, Оренбургта Совет хакимияте беренче мәртәбә оешкан мәлдә, 1918 елның беренче яртысында әле аңа каныгучылар булмаган диярлек. Китәргә бәрәү дә мәҗбүр итмәгән. Оренбургта әле ул вакытта эшчеләр юк дәрәҗәсендә: тимерюлчылар депосы, «Орлес» агач эшкәртү заводы да берничә вак-төяк күн-тире эшкәртү «фабригы» белән тегермән эшчеләре генә. Патша хакимиятен үзгәртеп корырга теләүчеләрнең иң актив сул канат тарафдарлары да башлыча уртакул хезмәткәр һәм хәлфәләр, учительләр генә. Алар әлегә либераль карашлы, кискен чаралар тарафдарлары түгел. Гражданнар сугышы соңрак аларны, шул исәптән өске катлам «татар революционерларын» да, ил буйлап таратачак. Алар урынына чикләнгәнрәк фикерле, кешеләрне фәкать эшче һәм байларга гына бүлеп караучылар төркеме киләчәк. Мал-мөлкәте ишлерәк булучыларны чын-чынлап эзәрлекләүләр башланачак.

* * *

Орск төбәгендә Совет хакимияте фәкать 1919 елның җәй азакларында гына урнаша. Бер ел дәвамында шәһәр тирәсендә авыр сугыш бара. Шәһәр кулдан-кулга күчкәли. Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләреннән мәгълүм ки, андый вакытларда Дәрдмәнд шәһәрдән киткәләп тә торган. Драматургның кулак ага-братлары көн күргән Җүнәйдә «шагыйрьнең шәһәр өчен барган сугыштан качып яшәве» теркәлгән. Дәрдмәнд бәлки Җүнәйдән дә арырак китеп торгалагандыр, ләкин Юлык, Солтан, Балкан, Шәйханда авылларында, Верхнеуральски янәшәсендәге өч катлы Рәмиев байлар утарлары тирәләрендә икенче бер Мирхәйдәрнең булмавы сәбәпле, ул сәфәрләр әлегә безгә мәгълүм түгелдер, мөгаен.

1920 елның җәендә Орскиның яшь сәүдәгәр Мусиннар гаиләсе берничә елга бер авылда кибет тотарга китәләр. Урамга биш тәрәзәсе карап торган, буйлап салынган бура өйләрен, иркен ишегалды каралтыларын һәм араннарын Дәрдмәндләргә калдырып китәләр. Ул өй хәзер дә исән, фәкать элекке такта түбәсе шиферга гына алыштырылган. Хәзерге Поль Лафарг урамына аркылы булган Поль Лафарг тыкрыгындагы өченче йорт. Ике йорт аша Җаек буе әрәмәлеге башлана. Ул урында Җаек елгасы дугаланып, шәһәр йортларыннан беркадәр читләшә. Шул ике аралыкта, эре-эре топольләр уратып алган зур-зур аланнарда элгәрерәк шәһәр халкы сәхрага чыга торган булган, самоварлар кайна-

тып, шунда чәй мәҗлесләре оештырган. Дәрдмәнд тә элек-электән шунда кайниш-кайнигәләре белән сәхрага чыккалагандыр, мөгаен. Төнбоекларны тибрәтеп аккан ашкын суга карап, хозурланып һәм уйланып утырган чаклары да булгандыр. Инде яшәү урыны да елга буена ук якынлашкач, ялгызы гына да ул әрәмәлек буйларында йөргәндер, шәт.

1921 елның көзендә соңгы юлга да ул шушы йорт бусагасыннан алып чыгылган.

Соңгы гомерләре Мәскәүдә узган оныклары Бәшир белән Кафия бабаларының үлемен болайрак тасвир итәләр. Кафия—шагыйрьнең олы кызы Өммегөлсемнең кече баласы, 1915 елда туган. 1921 елда әле алар Оренбургта яшәгәннәр. Өммегөлсем дә, аның ире Гариф Камалов та шул елның көзендә кинәт авырып китәләр. Тифме, вабамы эләктерәләр дә, озакламыйча бер-бер артлы якты дөнья белән саубуллашалар. Дәрдмәнд бабалары Өммегөлсем хәлсезләнеп, урын өстенә яткач та Оренбурга килгән була. (Махсус килгәнме, әллә башка йомыш белән килгән вакыты булганмы—оныклар хәтерләмиләр.)

Дәрдмәнд олы кызының җеназасын чыгаруда катнаша. Киявенең дә авыруын исәпкә алып, ятим калган дүрт кыз баланы урнаштыру хәстәрен күрә. (Кечерәкләре Суфия белән Кафия соңыннан Искәндәр абыйлары гаиләсендә тәрбияләнәчәкләр. Рәбига белән Галия дә аларда яшәп-яшәп китәләр.) Орскига кайтышлый шагыйрь үзе дә чирли башлый. Актүбә белән Орск арасындагы йөз илле чакрымлы ат юлында өшегән дә булса кирәк. Иртә башланган суык көз булган ул. Гаиләсе янына кайтып, берәр атна торгач үзенең дә йөрәге тибүдән туктый. Шулай итеп, ул гаиләгә берьюлы ике зур хәсрәт килә.

Дәрдмәнд «ачлыктан үлгән» дигән фараз таратучылар да бар. Бер дә ышанычлы фараз түгел. Икенче бер олы яшьтәге журналистыбыз «шагыйрь бер ерак авылда, кемнәрнеңдер кулында, бик фәкыйрьлектә үлгән икән», дип тә язып чыкты. Анысы да нигезсез. Үз гаиләсендә, үз өендә (әлеге Мусин сәүдәгәрләрдән арендага алып торган өйдә) вафат булган ул. Илленче-алтмышынчы елларда әле Орск шәһәрендә шагыйрьне соңгы юлга озатучылар да бар иде. Уртакул сәүдәгәр кызы, иптәш кызлары белән шагыйрь җеназасын Җаек күперенең аргы башына чаклы озата барган Мәрьям апа Бикбова (Муса Җәлилгә яшьтәш, сонрак яшь шагыйрь белән сәхнә уеннарында катнашкан) туксанынчы елларда гына вафат булды.

Алда әйткәнемчә, илленче еллар урталарында Казанга Дәрдмәнднең улы Җәгъфәр килгән. Шуның да истәлек-хатирәләренә таянып 1959 елгы «Сайланма әсәрләр» китабы дөнья күргән. Ул китапны төзүче һәм чыгаручы әдәбият профессоры Мөхәммәт ага Гайнуллин үз хезмәтләрендә Дәрдмәндне «тифтән үлгән» дип яза. Шул бәяләмә бик хак булырга тиеш. Йогышлы авыру кызын гүргә иңдерүдә катнашкан шагыйрь йә шунда, яисә поездда кайтканда тиф авыруын йоктыра һәм шул чир аны теге дөньяга алып киткән булса кирәк.

Димәк, рәсми дөресе болай булыр: татар шигъриятенең күренекле вәкиле Дәрдмәнд (алтын байларының берсе Мөхәммәтзакир Рәмиев) Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында 1859 елның 23 ноябрендә сәүдәгәр гаиләсендә туа. Алтмыш ике яше тулыр-тулмастан, Орск шәһәрендә, 1921 елның 9 октябрендә тиф авыруыннан вафат була.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

*Сәнгать*

# САГЫНДЫРЫП ИСКӘ ТӨШӘ ҺАМАН...

*Габдулла Шамуковның тууына 90 ел*

Һай, бу гомер дигәнең!.. Әле кайчан гына авылда урта мәктәп тәмамлап, Казанга килгән идем... Инде ана да 42 ел вакыт үтеп киткән.

Казанга килгәч, Г. Камал театрында караган беренче спектаклем «Хужа Насретдин» булды. Гаиләбез белән жыелып бардык без анда. Әнкәй, абый, жинги, мин. Хәтеремдә, урыныбыз икенче ярусга, ягъни, бельэтажда. Менә сихри музыка астында пәрдә ачылып китте. Йа, Хода! Нинди тылсымлы дөнья! Ул декорацияләрнең матурлыгы! Күз явыңны алырлык утлар! Сәхнә тулы халык. Ханнар, вәзирләр, биләр, тарханнар, ахуннар... Гүя мин әкияти дөньяга кереп чумдым. Әле исемнәрен, уеннарын радиодан гына тыңлап белгән артистлар—менә бит алар, сәхнәдә, минем күз алдымда. Спектакльнең үзәгендә, әлбәттә, Хужа Насретдин үзе. Аның һәр сүзенә, һәр хәрәкәтенә тамашачы хуплап кул чаба. Ә минем хәтердә, нигәдер, башына зур чалма кигән, уртача буйлы, тулырак гәүдәле, бик тә жинел хәрәкәтле Ахун ныграк сеңеп калган. Программадан карыйм, рольдә—Габдулла Шамуков. Соңыннан бу рольдә мин башка талантлы артистларның уйнаганнарын күрдем, 1990 елгы куелышта үземә дә бу рольдә уйнарга туры килде. Тик минем күз алдымда гел Г. Шамуков Ахуны булды. Үзем уйнаганда ул мине гел күзәтеп, хуплап, сынап тора иде шикелле.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының фойесында мәшһүр артистларыбызның портретлары эленеп тора. Аларның һәрберсе үзләренең талантлы уеннары, ялкынлы иҗатлары белән татар театры тарихында, тамашачыларыбыз хәтерендә тирән эз калдырган бөек артистларыбыз.. Ул галерея турысыннан мин беркайчан да тыныч кына үтеп китә алмыйм. Ә бит язмыш миңа бу корифейларның кайберләрен күреп калу бәхетен бүләк итте. Аларның тиңдәшсез талантлы уеннарына карап сокланырга, алар белән сәхнәдә партнер булырга, хәтта кайберләре белән аралашып та яшәргә насыйп булды. Берсеннән-берсе мәшһүррәк артистлар, легендар шәхесләр...



*Габдулла Шамуков*

Мин, ихтыярсыздан, Габдулла ага Шамуков рәсеме каршында туктап калам, аның йөзендәге бик тә таныш, бик тә якын чалымнарга текәләм... Талантлы актер, тәжрибәле педагог—остаз, тәрҗемәче, нәфис сүз остасы, мәсәлче, әдип... Галиҗәнап Татар артисты! Күңелдә якты сагыш булып хатирәләр яңара...

1961 елда Казан театр училищесына укырга кердем. Училищебызның әле үз бинасы булмаганга күрә безнең дәресләр Камал театрында үтә иде. Бөтенләй яңа дөнья, кызык, серле, тылсымлы дөнья. Үзебез яшьләр, күңелләр күкнең жиденче катында! Көне буе без театрда кайнашабыз. Ә кич белән, әлбәттә, спектакльләр карыйбыз. Безнең иң яратып караган спектакльләребезнең берсе, һичшиксез, «Зифа» спектакле иде. Мин үзем ул спектакльне ничә тапкыр караганымны хәтерләмим. Һәрхәлдә, ун мәртәбә генә булмагандыр. Инде сәхнәдә жиденче сезонын барса да, шаулап-гөрләп бара иде ул. Ә артистлар ансамбле нинди!.. Галия Булатова, Хөсәен Уразиков, Гөлсем Камская, Фуат Халитов, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Фатыйма Камалова... Болар бит һәрберсе театрыбыз сәхнәсенең якты йолдызлары. Әмма Габдулла ага Шамуков шушы йолдызлар арасында да үзенә бер яктылык белән балкып тора иде. Габдулла Шамуков!.. Ул анда архитекторлар идарәсе

башлыгы Илдархан Балтаев ролен башкарды. Һич тә арттырмыйча әйткәндә, бу рольдә ул суга җибәрелгән балык кебек иде. Ул аны шулкадәр бирелеп, шулкадәр яратып, мавыгып уйный, мин аны караган саен таң кала идем. Ничә тапкыр залдан, ничә тапкыр сәхнә артыннан торып карадым, әмма бу сәхнә остасының уенын карап туя алмадым. Кайбер спектакльләргә мин фәкать шул пәрдәне генә карарга киләм, һәм... спектакльне ахырына кадәр карап бетерәм.

Вакыйга Балтаевның эш кабинетында бара. Архитектор Айдар Чураевның гаиләсендә низаг чыккан, хатыны Зифа аерылышу турында судта эш кузгаткан. Әгәр бу хәбәр «өскә» ишетелсә?! Әгәр шелтә чәпәп куйсалар?! Әнә горкомнан шалтыраталар! Принципсызлыкның аргы ягына чыккан бу җитәкченең коты алынган. Ул утлы табага баскан кебек. Ул—әле «бездә барысы да тәртиптә» дип, «өстәгеләрне» тынычландыра, әле талантлы архитекторы Чураевны «тәрбияли». Шелтәли, юата, акыл бирә. Чураевны уйнаучы талантлы актер Ф. Халитов тамашачыга аркасы белән утырган, ул борчыла, газаплана... Балтаев исә аһ-ваһ килеп, өзгәләнеп, Чураевны тынычландырырга тырыша. Йөзенә су бөрки, маңгаена сулы чүпрәк куя... Бу сәхнәдә уен гротеск дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул көнне мин сәхнә артыннан карый идем. Габдулла ага шулкадәр мавыгып китте... Чураевны уйнаучы актер Фуат абый тыела алмыйча көлә башлады... артистларча әйтсәк, «ычкынды».. Үзе көлә, үзе «Җитте инде сиңа, Шамук... Җитте, дим, арттырма»... дип пышылдый. Тамашачы, әлбәттә, берни сизмәгәндер... Минемчә, бу олы мастерның сәхнәдә уенынннан ләззәт алуы, рәхәтлек алуы иде.

Әйе, бүген минем сүзем—яраткан остазым, СССРның халык артисты Габдулла ага Шамуков турында.

Гаҗәеп хәрәкәтчән, яшьләрчә темпераментлы, һәрвакыт иҗат дәрте белән янып яшәүче бу остазга бервакытта да үз яшен биреп булмый иде. Чөнки ул гел хәрәкәттә, үз-үзен тотышы да, уй-фикерләре дә, йөреше-гамәлләре дә гел яшьләрчә.

Мин биредә күренекле артистның һәм әдипнең иҗат һәм тормыш юлына тәфсилләп күзәтү ясарга җыенмыйм. Моңа минем каләмемнең дә көче җитмәс, бу мөмкин дә түгел.

Габдулла аганың тормыш юлы Октябрь инкыйлабыннан соң тормыш сукмагына аяк баскан күп яшьтәшләренеке кебек, гадәти. Ул 1909 елда, Сембер өлкәсе, Кече Кандал районының гүзәл табигатьле Әсән авылында туа. Иптәш малайлары белән бергә башта авыл мәктәбендә укый, аннары Уфада татар мәктәбендә белем ала. Бәләкәй Габдулла авыл мәктәбендә укыганда ук матур әдәбият белән кызыксына, кичәләрдә дәртләнеп шигырьләр сөйли. Әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт уяткан беренче укытучысы Нәби Хәйбуллинны Габдулла ага һәрвакыт зур хөрмәт белән искә ала иде. Аның әдәбиятка булган мәхәббәте нәселдән киләдер, мөгаен. Артистның шәҗәрәсе күренекле татар шагыйре Габделҗаббар Кандалыйга барып тоташа икән, ләбаса!

Ул Уфа сәнгать техникумының театр бүлегенә имтихан тапшыра. Белемгә сусаган авыл егетенә үзенең хыялларын тормышка ашыру өчен бөтен юллар да ачык. Укы, белеменне арттыр, осталыкка өйрән. Бөтен йөрәгең, күңелен салып тырышып укый ул. Ә укытучылары кемнәр, диген?! Актерлык осталыгы буенча аны күренекле театр эшлеклесе Мәкәрим Мәһдиев укыта. Атаклы шәхес. Менә дигән укытучы, олы җанлы, киче күңелле кеше. Яшь егетне сәнгатьнең олы сукмагына чыгаруда остазының ярдәме зур була.

Ул 1930 елда техникумны тәмамлагач, Уфада, Башкорт дәүләт театрында эшли башлый. Талантлы яшь артистны тамашачылар беренче рольләреннән үк яратып өлгерәләр. Театрда аң зур һәм җаваплы рольләрне ышанып тапшыралар. Ул тиз арада театрның әйдәп баручы, йөкне тәпкә җигелеп тартучы артистларның берсенә әверелә. Күп уйный, еш уйный. Осталыгы да рольдән рольгә үсә, чарлана.. Н. Гогольнең «Өйләнү» комедиясендә Подколесин, Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты» спектаклендә Сережа Бруздак, М. Гафуриның «Кара йөзләр»ендә Сәгыйть, Л. Леоновның «Ябырылу»ында доктор Таланов, һ.б. Ул башкарган күп кенә рольләр аның инде артист булып җитлегүен, художник булып формалашуын раслыйлар. Матбугатта артистның исемен мактап телгә алалар. 1939 елда танылган башкорт язучысы Баязит Бикбай үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза. «Габдулла Шамуков—чын мәгънәсе белән актер. Ул ургып торган хисләр чишмәсе кебек тоела. Бай мимика, күз карашлары, максатлы (һәрбер вакыйкларына тикле үлчәнгән) хәрәкәтләре белән тулыландыра ул үзенең тирән хисле образларын. Ул башкаларга үрнәк булырлык нәфис сүз осталыгына

да ия.» Әле утыз гына яшен тутырган артист турында әнә шундый мактау сүзләре әйтелгән.

1940 елда аңа халык шагыйре Тукай роле тапшырыла. «Тукай» драмасында зур һәм җаваплы рольгә артист икеләнебрәк алына. Сөекле шагыйребезнең якты образын халыкка җиткерә алырмынмы? Артистны шул уй борчый. Ул Тукай әсәрләрен кат-кат укый, өйрәнә, эзләнә. «Ул вакытта мин Тукайның бөтен иҗатын диярлек яттан белә идем»,—дип искә төшерә Габдулла ага . Әсәрнең авторы Әхмәт Фәйзи, спектакльне карагач: «Мин сәхнәдә чын Тукайны күрдем»,—ди. Габдулла ага, чыннан да, Тукай иҗатын бик яхшы белә иде. Гомере буе Тукайга мөкиббән булды, Тукай рухы, Тукай иҗаты белән яшәде. Безне, укучыларын да шул рухта тәрбияләргә тырышты.

Шул ук елда Уфа сәхнәсендә Н. Погодинның «Мылтыклы кеше» пьесасы куела. В. И. Ленин образын иҗат итү Г. Шамуковка тапшырыла. Хәзер юлбашчыбызның шәхесенә мөнәсәбәтләр төрлечә булырга мөмкин. Заманалар да үзгәрде, карашлар да... Әмма ул чакта халык аңында мәңгеләшкән образны башкорт сәхнәсендә беренче булып иҗат итү—бик тә җаваплы, бик тә катлаулы эш. Шул кадәресе дә бар, бу рольне уйнау иң талантлы, иң популяр, бер яктан да тел-теш тидермәслек сыйфатларга ия булган артистларга гына рөхсәт ителә иде. Юлбашчының җанлы образын тудыру өчен Ленин турында истәлекләр белән таныша, аның әсәрләрен өйрәнә. Өзлексез эзләнә. Нәтиҗәдә, Габдулла Шамуков бу рольне уңышлы башкарып чыга.

1940 ел, гомумән, истә калырлык ел була. Бер сезонда бер-бер артлы ике роль, һәм нинди рольләр!

1946 елда Башкортстанның атказанган артисты, 37 яшьлек Габдулла Шамуковны Казанга Татар дәүләт академия театрына чакыралар. Казан тамашачысы алдында ул беренче тапкыр Ленин образында чыгыш ясый. Имтихан уңышлы уза. Артист беренче чыгышыннан ук Казан тамашачысының мәхәббәтен, ихтирамын казана.



Артист тормышында яңа чор башлана. Яңа коллектив, яңа иптәшләр, яңа рольләр. Артистның Камал театры сәхнәсендә иҗат иткән образлар галереясын карасаң, хәйран каласың. Алар күптөрле һәм берсенберсе кабатламыйлар. Хлестаков («Ревизор»), Садрый («Козгыннар оясында»), Балтаев («Зифа»), Тукыш («Һиҗрәт»), Хуҗа, Ахун («Хуҗа Насретдин»), Куык Шәпи («Кырлай егете»), Актай («Кол Гали») һ.б. бик күп рольләре талантлы артистның киң диапозоны турында сөйлиләр.

1948 елда театр К. Гольдониның «Ике хуҗаның хезмәтчесе» дигән үлемсез комедиясен сәхнәгә куя. Хезмәтче Труффальдино ролендә Габдулла Шамуков. Үзенә бик тә туры килә торган бу рольне артист зур уңыш белән башкаргандыр, дип уйлыйм. Бу спектакльне минем үземә күрергә туры килмәгәнгә, 1949 елның 2 февралендә чыккан «Советская Татария» газетасына мөрәҗәгать итәм. Мәкалә Труффальдино-Шамуков турында. «Анарда хәйләкәрлек һәм гадилек, астыртынлык һәм беркатлылык сыешып-тынышып яши. Ул яшен тизлеге белән фикер йөртүе аркасында еш кына авыр хәлләрдән дә җиңел котыла. Труффальдино-Шамуковның сәхнәдәге тормышы бизәкләргә чиксез бай. Мәзәк эпизодларны актер аеруча оста башкара, бер үк трюкны икенче тапкыр һич кабатламый һәм шуның нәтиҗәсендә гаҗәеп зур ышандыру көченә ия». Актер уенына бирелгән югары бәя бу.

Габдулла аганың актерлык иҗаты турында күп сөйләргә мөмкин. Менә, мәсәлән, Н. Исәнбәтнең «Муллануp Вахитов» спектаклендә Галимуллин роле. Укымышлы, зыялы, галим кеше. Ләкин ике лагерь арасында буталып, аптырап калган куркак шәхес. Габдулла ага бу рольне үзенә генә хас зур осталык белән башкара иде. 1976 елда спектакльне икенче тапкыр куйганда миңа аның белән бер сәхнәдә уйнарга, аның искиткеч уенын күреп ләззәтләнергә насыйп булды.

1948 елда иҗат ителгән Хлестаков образы (Н. Гоголь, «Ревизор») да артистның иҗат биографиясендә аерым урын алып тора. Матбугат битләрендә артистның талантлы уенын мактап телгә алалар.

1968 елда Н. Исәнбәтнең «Кырлай егете» куелды. Спектакльне сәхнәгә режиссер М. Сәлимҗанов куйды. Әкият искиткеч матур тел белән татар фольклорына нигезләнеп язылган. Куык Шәпи ролендә Габдулла абый. Байлык-дәрәҗә дип күзе тонган, шашынып дәрәҗәгә җиткән бу комсыз кешене Габдулла абый шулкадәр яратып, бирелеп, ял итүне дә белмичә эшләде. Шәпинең саранлыгы, комсызлыгы чиктән ашкан. Байлык өчен бердәнбер кызын шүрәлегә дә, аксак морзага да, шайтанга да бирергә риза... тик байлыгы гына булсын. Репетицияләр тәмамланганда ул тәмам тирләп беткән, еш-еш сулый, күзләр яна, күлмәкләре юеш... Инде репетиция вакыты беткән, ә ул режиссер янына килеп: «Марсель Хәкимович, әйдәгез инде, тагын бер кат үтик, зинһар»,—дип ялварып сорап торганы бүген дә күз алдымда. Ә бит инде бу вакытта артист 60 яшен тутырып килә иде. Ләкин, әйткәнемчә, ул яшьне аңа кем бирсен»! Ыштан балакларын җилфердәтеп сәхнәдә җил кебек бөтерелеп йөгереп йөрүен һич онытып булмый. Режиссер да, артистлар да бу спектакльне яратып-янып эшләделәр. М. Сәлимҗанов ул репетицияләрне хәзер дә сагынып искә ала. Әйбәт спектакль чыкты. Әсәр әйбәт. Артистлар шәп. Тик, кызганыч, спектакль кыска гомерле булып чыкты. Әкият итеп язылса да әсәрдә шул заманга киная-ишарәләр байтак иде шул. Күрәсең, югарыдагы иптәшләргә ошап бетмәгәндер инде...

Габдулла абый тормышта да бик тә ягымлы, җор телле, мәзәкчән, ярдәмчел һәм шул ук вакытта ифрат гадел, туры сүзле кеше иде. Киң эрудицияле, әдәпле, чын мәгънәсендә зыялы шәхес. Әгәр инде берәр нәрсә белән мавыга башласа, мәзәк хәлләргә калганчы мавыга. Бөек кешеләр бераз сәеррәк булалар дигәннәре хактыр инде, күрәсең. Шахмат уйный башласа, дөньясын оныта. Әйтерсең лә дөнья шушы шахмат тактасына килеп терәлгән... Уйный, мавыга... Ә спектакль бара, сәхнәгә чыгар вакыты җиткән. Артистлар исенә төшереп торалар, радиодан режиссер ярдәмчесе чакыра: «Шамук абый, сәхнәгә... Габдулла абый, дим, вакытыгыз җитте... Әйдәгез инде...» Ә ул, әйтерсең пульт янындагы режиссер ярдәмчесе аны ишетә инде... «Хәзер, хәзер... Тагын бер генә ход... Шах кына бирәм»... Сәхнәгә чыгар вакыт җиткән инде, бик җиткән, үтеп тә бара икән... Ярый ла әле ул киенеп куйган булса. Ә бит чалбарының бер балагын кигән, бер балагын кулына тоткан килеш сәхнәгә чыгып барганда артистлар тотып калган чаклар булган дип тә сөйлиләр... кайбер арттырып сөйләргә яратучылар. Яисә, менә кәрт уйнаганда... «Мең дә бер» дигән тиен акчаларга отышлы уен инде ул. Ләкин Габдулла ага никадәр генә зирәк кеше булса да бу уенның нечкәлекләренә төшенеп бетә алмады. Оттыра иде. Ләкин ник оттырганын һич аңламый... Ничек инде ул, шулкадәр акыллы кеше шушы малайлардан оттырырга тиеш. Бер оттыра, ике оттыра... Ахырында:—Мәгез инде алайса, бусы да сезгә булсын, карта даһилары!..,—дип, калган тиеннәрен дә безгә калдырып, балаларча хәтере калып уеннан торып ук китә. Ярты сәгать тә үтми, берни булмагандай, тагын килеп утыра иде үзе. Үпкәләүнең эзе дә юк. «Кая, машинниклар, миңа да өләшегез әле»,—дип, яңадан уйнарга утыра, яңадан оттыра башлый... Бик еш сагынып искә алабыз без ул чакларны.

Яшь аермасы шактый булса да, Габдулла абый белән безнең арада мөнәсәбәтләр җылы, якын иде. Гастрольдә йөргәндә әгәр кичебез буш булса, мин аңа телефоннан шылтыратам: «Шамук абый, бүген кичебез буш, сезгә кич утырырга төшәргә буламы? Аулак өй ясап алыйк...» «Ә-ә, Җәлял, (нигәдер ул бүтәннәр шикелле Җәләл дип түгел, үзенчә сузыбрак Җәля-ал дип әйтә иде.) Әйдә төш, чәй куям, гәпләшеп утырырбыз.» Ә чәйне әзерли белә иде ул! Башта җиренә җиткереп, бөтен шартын китереп пешерә, аннары тастымал белән кат-кат төреп томалый... Өч минут артык та, өч минут ким дә тотарга ярамый икән әле аны, житмәсә... «Дәмләнүен көтәргә кирәк», имеш. Исе дә, тәме дә бөтенләй бүтән була икән. Әнә шундый технологиясе, фәлсәфәсе бар икән аның, тәмле чәй пешерүнең. «Ә буфет аша әйләнеп, урап төшсәм,—дип дәвам итәм мин кыюланыбрак.—Бу мәсьәләгә сезнең карашыгыз ничек?» Аның тавышы тагын да җанланыбрак китә. Көлә: «Соң, Җәлял, бу мәсьәләгә начар карап буламыни?!»

Бу сөйләшүләр күңелле дә, житди дә була иде безнең. Мин аның белеменә, эрудициясенә шаккатып, әллә соң моның дөньяда белмәгән нәрсәсе юк микән, дип куя идем. Борынгы грек трагедияләреме, көнбатыш, дөнья, рус әдәбиятымы—ул барысыннан да хәбәрдар. Бирелеп китеп, яттан сөйли башлый. «Ә-ә, Прометей анда Гефестка шулай дип әйткәч, Гефест аңа болай дип җавап бирә..» Яттан сөйли. Дәрдемәнд, Рәмиев, Бабич... Ничек ялкынланып сөйли ул алар турында! Тукай, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, Такташ, Ә. Еники... Аларның иҗатларына мөкиббән иде ул, һәм

шул мәхәббәт орлыкларын безнең, укучыларының күңелләренә дә сендереп калырга тырышты.

Аннары сүз татар халкының тарихына, Болгар чорына, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорына күчә. «Сезнең буын бәхетсезрәк булды шул, сез татар тарихын да, аның ханнарын да, патшаларын да белмисез. Бәлки, дөньялар үзгәрер әле, гел тарихны яшереп ятмаслар»,—дия иде. Шулай булып чыкты да. Бүген тарих белән кызыксынган кешегә материаллар житәрлек. Ә ул вакытта минем бөтен «багажым» 1922 елда чыккан Һ. Атласиның «Казан ханлыгы» дигән әсәре генә. Ул да гарәп шрифты белән басылган һәм мин аны шактый азапланып «тырмаштырып» чыккан идем.


*Габдулла Шамуков Хуҗа Насретдин ролендә.*

Мәзәк хәлләр дигәннән... Шундый әңгәмәләрнең берсендә мин: «Габдулла абый, имеш, сез Кольцода озак кына трамвай көткәнсез икән. Көттереп кенә трамвай килгәч, сез, өйгә керәм дип уйлап, галошларыгызны асфальтта салып калдырып трамвайга кереп китсәнсез, диләр. Шул сүз дөресме?»—дип сорап куйдым. Башта рәхәтләнеп бер көлде. Аннары: «Шулай дип сөйлиләрмени? Булгандыр инде. Булгандыр... Ул чакта мин Сөембикә манарасының тарихын язып йөргән вакыт иде... Булды бугай шул...»

Ә ул манараның тарихы Габдулла агага шактый кыйммәткә төшкәнен белә идем инде мин. Ул хезмәтен ул байтак мәшәкатьләнеп, изаланып дөньяга чыгарды. Аны бик кыскартып, шомартып бастырганнар. Бик борчылган иде моңа автор. Шунда әңгәмәбезне дәвам итеп, өстәп куйды: «Әле күптән түгел, шул статьямны ботарлап бастырган түрәне очраттым. Берни булмагандай исәнләшә. Хәлемне сорый. «Кәефегез ничек?»—ди. «Әйбәт,—мин әйтәм.—Әле беркөнне сезне төштә күрдем. Имеш, сез минем аякларымны сындырып бетергәнсез дә, авыртмыймы?—дип сорыйсыз икән», дим. Кинаямне аңлады. Азапланып-көчәнеп көлгәндәй итә. «Сез инде, Габдулла абый, мәзәк белән сөйләргә яратасыз»,—дигән була. Мәзәк дип аңлаган... белсә иде ул минем эчтә ниләр кайнаганын...»

Хәтерлим: 1968 елда Камал театрында (хәзерге К. Тинчурин театры) күренекле татар язучысы Фатыйх Хөснинең 60 яшьлек юбилее булды. Бәйрәм, әлбәттә, бик тантаналы булды. Шушы кичәдә без өчәү—А. Арсланов, И. Баһманов һәм мин юбилярның әсәрләрен укыдык. Кичә беткәндә Габдулла абыебыз сәхнә артында бик канәгать булып, кулларын уып тора иде. «Шәп бит бу!.. Карагыз әле, өчесе дә минем укучыларым бит»,—ди, куануы йөзенә чыккан иде. Шулай, үз уңышлары өчен генә түгел, укучылары өчен дә чын күңеленнән шатлана белә иде ул.

Ә 1981 елда без Мәскәүнең данлыклы Моссовет театрында Т. Миңнуллинның «Моңлы бер жыр» спектаклен уйнадык. (Партиянең кайсыдыр съезды уңае белән бугай). Спектакль бик уңышлы узды.. Тамашачылар да, спектакльнең режиссеры М. Сәлимжанов та бик канәгать иде. Каһарман шагыйрь Муса Жәлилнең һәм аның көрәштәшләренең фажигале язмышлары залда берәүне дә битараф калдырмады. Кич белән бик матур гына банкет та оештырылган иде. Мәжлес вакытында кәефләр күтәрелеп, хисләр нечкәреп киткәч, гадәттәгечә, тост әйтүләр, теләк теләүләр башланды. Миңа да сүз бирделәр, мин дә Жәлил турында, спектакль турында күңелемдә булганнарны жыйнак кына итеп әйтеп бирергә тырыштым. Кунакханәгә кайтырга чыккач, Габдулла абый минем беләгемнән килеп тотты. (Ул бу спектакльдә Шәфи Алмазны уйный, һәм искиткеч шәп уйный иде.) «Әйдәле, Жәлял, жәяүләп кенә кайтыйк әле. Бергә кайтыйк. Кәефем шәп. Чүт-чүт кенә «эчтән тун киеп алдым» бит әле. Жылынып та киттем. Э-эх, нинди бәхетле кеше бит мин! Минем бит укучыларым бар. Бүгенге спектакльдә минем күпме укучыларым катнашты. Биктимер, Баһман, Әюп, Сәләх, син... Кирәк урында үз фикерләрен дә житкереп әйтә беләләр. Син, Жәлял, зинһар, мине гаеп итмә инде. Күңелем күтәренке.»

Укучылар мине дөрес аңласыннар. Габдулла абый беркайчан да—кабатлап әйтәм, беркайчан да!—«эчтән тун киюләр» белән мавыкмады. Эчү, тарту кебек гадәтләр аның өчен ят булды. Әмма ул суфый да, әүлия дә, фәрештә дә түгел, жир кешесе, илаһи рухлы жир кешесе иде.

Габдулла ага тормышта күп вакыт киң күнелле, самими, мәзәкчән кеше булса да, кирәк чакта бик җитди дә була белә иде. Әле ничек кенә!... Бер гастрольдә Ульяновск шәһәрендә (елы истә калмаган инде) без Габдулла абый белән кунакханәдә бер бүлмәдә туры килдек. Бер генә кич кундык... Ул икенче көнне Казанга кайтып китәсе. Нигәдер минем кәеф төшенке, күңелдә ниндидер шик, икеләнүләр. Була бит адәм баласында шундый минутлар. Тормыштан да, иҗаттан да канәгатьсезлек, өметсезлек... мавыгып китеп мин артыграк сүз әйтеп ташладым шикелле. Габдулла ага яткан җиреннән торып ук утырды. Йөзе җитди, хәтта ачулы. «Синең алай дип әйтергә хакың юк. Сине укытканнар, белем, һөнәр биргәннәр, син халкыңа хезмәт итәргә тиеш, бу синең бурычың. Бу дөньяның чүп сүзе күп булыр ул, аларны йөрәгеңә якын ала башласаң!.. Кара аны, Җәлял, бүтән мондый сүзләреңне ишетәсе булмыйм!» Әнә шулай, җитди дә, кырыс та, таләпчән дә... усал да була белә иде ул. Шундый онытылмаслык «сабакларны» да бирә иде. Кызганыч, шагыйрь әйтмешли: «җанга якын җаннар китә тора...»

Габдулла абый педагог буларак гаҗәеп иде. Ул 45 елдан артык Уфа, Казан театр училищеларында сәхнә телен укыта, сөйләү техникасын өйрәтә. Бу тәҗрибәле остазда дүрт ел укуымны үземнең бәхетем дип саныйм. Үзе дә менә дигән нәфис сүз остасы безгә сүзнең кадерен белергә, мәгънәсен аңларга, аның җегәрен, кодрәтен, тәмен тоярга өйрәтте. Шигырь, хикәя укырга өйрәтүенә туктап тормыйча, мәсәлләр укырга өйрәтүен генә әйтеп китәсем килә. Үзе дә оста мәсәлче, И. Крылов мәсәлләрен ин шәп тәрҗемә итүче, күрәсең, мәсәл жанрын аерата якын күргәндер ул. Менә ул Ишәк булып сөйли, яки Төлке булып җавап бирә, һәм шунда яраткан остазыбыз күз алдыбызда тышкы кыяфәте, рәвеше, тавышы белән хәйләкәр Төлкегә, Явыз Бүрегә, аңгыра Ишәккә әверелә дә куя. Чын әгәр!.. Аның хәрәкәтләре, йөреше, күз карашлары нәкъ инде менә шушы мәсәлнең персонажлары. Мәсәлгә ул игътибарны да күбрәк бирде. «Мәсәл бит ул—тәмамланган драма әсәре. Аның идеясе дә, композициясе дә, образлары да, конфликты да бар»,—дия иде.

Үзе дә әдәбиятка җаны-тәне белән гашыйк булган Габдулла ага сөйләү техникасы белән бергә бездә, булачак актерларда, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләде, зәвыгыбызны формалаштырды.

Аның тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре турында аерым тукталып сөйләп булыр иде. Рус, Көнбатыш, дөнья классикларының үлмәс әсәрләрен бердәй осталык белән тәрҗемә итте ул. Әлбәттә, тәрҗемәләре—драматургия әсәрләре. Үзе дә сәхнә кешесе булгангамы, каләме шома-йөгерек булгангамы—аның тәрҗемәсе татарчага бик якын, сәхнәдә сөйләргә җайлы, табигый, телгә ятып тора. Аның тәрҗемәләрен без бүген дә сагынабыз.

Әйе, әйткәнемчә, Габдулла ага Шамуков күпкырлы талант иясе иде. Гаҗәеп актер, тәрҗемәче, әдип, педагог, нәфис сүз остасы...

Ләкин, барыннан да элек, ул мәшһүр Актер! Аның рольләрендә самимилек, юмор, көчле темперамент бөркелеп тора. Хезмәте хөкүмәт тарафыннан да югары бәяләнде: аңа СССРның халык артисты дигән иң югары мактаулы исем бирелде, ул елларда хөкүмәтебезнең иң югары бүләкләреннән саналган Ленин ордены белән бүләкләнде. Ләкин аның өчен иң югары бүләк—туган халкының, тамашачыларның эчкерсез олы мәхәббәте булды. Чөнки ул туган халкым дип яшәде, аңа хезмәт итте. Бик үкенеч, моннан унсигез ел элек, 72 яшендә, янып, илһамланып, иҗат итеп йөргән җиреннән яман чир аны безнең арабыздан алып китте...

Ләкин бөекләрнең кылган эшләре мәңгелек. Туган халкы да, яраткан тамашачысы да аны беркайчан да онытмый. «Безнең Шамук абый...» дип сагынып искә ала. Габдулла ага бүген дә безнең арабызда. Үзенең ялкынлы иҗаты белән безне әле дә тәрбияләп, өйрәтеп һәм... кисәтеп тора.

**Хәлим ҖӘЛӘЛЕВ,**
*Татарстанның халык артисты.*

# 1999 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

1999 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. № 5

«Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. № 7

## РӘСМИ ДОКУМЕНТ

Милли-мәдәни мохтәрият *(автономия)* турында Россия Федерациясе Федераль Законы. № 8

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XIII КОРЫЛТАЕ

Татарстан Президенты М. Шәймиев чыгышы. № 9

Халык язучысы Ә. Еники котлавы. № 9

Р. Мөхәммәдиевнең хисап доклады. № 9

## МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Фәйзуллин Р. Гасыр йомгагын төенләгәндә. № 1

Латыйфи Ф. Яңа меңьеллыкка—яңа имла белән. № 12

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ахунов Г. Тимерханның эзләнүләре. *Документаль повесть.* № 2

Әмирханов М. Тәкъдир. *Роман.* № 10, 11

Әхмәдиев Н. Амбирак яки кара каен кыйссасы. № 7

Вәли М. Мәхәббәт маҗаралары. *Новеллалар.* № 12

Гадел Ә. Өзелгән кыллар. *Хикәя.* № 2

Галиев Ә. Чигенгәндә. *Повесть.* № 12

Галиуллин Т. Өйләнү. *Хикәя.* № 4

Гариф Н. Мәмеш Бирде. *Тарихтан бер кыйсса.* № 8

Зәйнуллин З. Агыйделнең аръягында. *Роман-кыйсса.* № 1, 2

Ильясов Ж. Тынлык манарасы. *Хикәят.* № 3

Камалов Б. Дөмбер Даниял. *Повесть.* № 11

Кәримов К. Ком сәгате. *Роман.* № 8, 9

Латыйфи Ф. Ишелеп төшкән бәхет. *Роман.* № 5, 6

Мингалим Р., Яһүдин Э. Ак метеор. *Нәфис фильмга сценарий.* № 4

Моталлапов Ә. Нигез. *Повесть.* №3

Мөхәммәдиев Р. Өчиле базарына сәяхәт. *Хикәя.* № 5

Сафиуллин Ә. Хикәяләр. № 5

Рахман Р. Таунын башын болыт кисә. *Хикәя.* № 5

Фәизов Р. Тәңре хөкеме. *Хыялый повесть.* № 4

Хафизова Р. Парчалар. № 2

Хуҗин И. Тайгадагы фаҗига. *Хикәя.* № 9

Хуҗин М. Ике хикәя. № 6

Хәлим А. Татар вакыты. *Кечкенә роман.* № 3

Шәйхетдин К. Кышлар узар... *Хәрби кеше язмалары.* № 1

Яруллин Ф. Якты сагыш. *Хикәя.* № 1

## ШИГЪРИЯТ

Афзал Г. Әллә кайда оҗмах кошлары бар. *Шигырьләр.* № 1

Әгъләм М. Ярты гасыр гомер акты... *Шигырьләр.* № 4

Әхмәдиев Н. Сагынудан бүтән зарым юк... *Шигырьләр.* № 11

Әхмәтҗан Роберт. Юлдагы кешеләр. *Шигырьләр.* № 12

Булатова К. Яңа шигырьләр. № 6

Вафин М. Әле бары җәй уртасы гына. *Шигырьләр.* № 5

Гайфуллина А. Көзгедә—ят кеше карашы. *Шигырьләр.* № 5

Галиев Ш. Бакырчы җәе. *Шигырьләр.* № 11

Гамбәр Н. Арбада, юлда, дөньяда... *Шигырьләр.* № 10

Гатауллин Рәшит. Җәй белән кыш арасында. *Шигырьләр.* № 10

Гаташ Р. Синең аша—җанкаемнәр эндәшә. *Шигырьләр.* № 3

Гыйләҗев И. Моңым кайтыр басу ягыннан. *Шигырьләр.* № 3

Дәрзаман Ж. Моннар фәрештәсе. *Поэма.* № 2

Закиров М. Ап-ак давыл иңнәренә төшкән. *Шигырьләр.* № 5

Закиров Р. Эзләп таптым моңның алтын тамырын мин... *Шигырьләр.* № 8

Зөлфәт. Җирнең йөрәгенә юллар якын. *Шигырьләр.* № 2

Иделбикә. «Мәхәббәтнең мең фасылы» китабыннан. *Шигырьләр.* № 5

Идиятуллин Р. Шигырьләрем—яшәү хакында. *Шигырьләр.* № 6

Иксанова И. Ә бәхетне... саклау кирәк... *Шигырьләр.* № 10

Исмәгыйлева Ф. Чатыртауның куенында. *Шигырьләр.* № 9

Исхаков Э. Тауларга илтә бу сукмак. *Шигырьләр.* № 7

Латыйп К. Төн күп телле, серле. *Шигырьләр.* № 4

Маннап Ш. Мин дә килдем, дөнья күрдем... *Шигырьләр.* № 2

Мансуров З. Язмышларга өстәп язылганнар... *Шигырьләр.* № 7
Минталим Р. Яна-яна киткән торналар. *Шигъри новелла.* № 10
Мирза М. Без мәңгелек юлында. *Шигырьләр.* № 9
Мулла Гали С. Үткәннәр белән сөйләшеп. *Шигырьләр.* № 12
Нәзиров М. Иннәрендә канат барда. *Шигырьләр.* № 9
Нәҗми Н. Заман бүлмәсенә кергәндә. *Шигырьләр.* № 4
Рафиков Б. Татар тарихы. *Шигырьләр.* № 5
Рәхимова Б. Сайрамачы, кошчык. *Шигырьләр.* № 4
Сабиров И. «Иманым» китабыннан. *Шигырьләр.* № 5
Садә Г. Сүзем—ялкыным. *Шигырьләр* (Н. Гамбәрнең кереш сүзе белән). № 2
Сафина Н. Җанавылда туып-үскән без. *Шигырьләр.* № 3
Сибат Р. Гомернең дүрт фасылы. *Шигырьләр.* № 1
Синугыл Ә. Кырымда. *Шигырьләр.* № 5
Солтан Ф. Мәңгелектә, якты бу аланда... *Шигырьләр.* № 10
Султи Р. Читтә унынчы көй. *Шигырьләр.* № 1
Суфияров Ф. «Язмыш уртак» китабыннан. *Шигырьләр.* № 5
Сәгыйров Г. Торналарым. *Шигырьләр.* № 5
Сөләйман. Бер дөньядан—бер дөньяга. *Шигырьләр.* № 8
Тукай Г. Шагыйрь. *Шигырь.* № 4
Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. № 12
Харис Р. Бүре күзе. *Поэма.* № 5
Хәлим А. Үсегез, үс, ирек пәрвәрләре. *Шигырьләр.* № 9
Чегән җырлары. № 7
Шагыйрьҗан Л. Әй, гомерләр. *Шигырьләр.* № 7
Шәрифуллина Э. Көзләрдә килгән җылым. *Шигырьләр.* № 8
Юзеев И. Йөрәгемә ятып ял иткәч. *Шигырьләр.* № 1
Янсуар Л. Яз түшендә зәңгәр әкият. *Шигырьләр.* № 3
Яруллин Ф. Күкләр сүзсез, күкләр дәшми. *Шигырьләр.* № 5

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Апуш Р. Ак карлардай. *Шигырьләр.* № 4

## ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ —ТУКАЙГА

Әхмәт Ф. Габдулла Тукайга. *Шигырь.* № 4
Зөлфәт. Ялгызлык. *Шигырь.* № 4
Исәнбәт Н. Тукай—остаз. *Шигырь.* № 4
Шабаев М. Таныш моң. *Шигырь.* № 4
Шагыйрьҗан Л. Тагын язлар килде. *Шигырь.* № 4

## УДМУРТИЯДӘ ЯШӘҮЧЕ ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ ИҖАТЫ

Мостафин Ш. Кардәшлеккә чикләр юк. *(Кереш сүз)* № 8
Абдуллин Д., Батталов Р., Биектаулы И., Гайфуллина Ә., Гәрәев Б., Исхакова Г., Комазани Ф., Мурзыев А., Нигъмәтҗанова Э., Садыйков Ш., Шәфи Р. шигырьләре. № 8

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕННӘН

Ибраһимова С. Тәрҗемәчедән. № 4
Ги де Мопассан. Бер асрауның кыйссасы. *Хикәя.* № 4

## ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Сабитов Г. Өч күнел. № 8
Тинчурин К. Дача хикәясе. № 4

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Сәгъди Р. Сынган беләзек. *Мелодрама.* № 6

## ПУБЛИЦИСТИКА

Әйди Т. Үз җырыбыз—үзәктә. № 6
Бохарай Р., Рәхим Г. Татарның үз миссиясе бар. № 2
Борһанов Ә. Коммунизм—«өрәкме»? № 4
Борһанов Ә. Россия җәмгыятенең кризис чыганагы. № 10
Госманов М. Каһирә очрашулары. № 7
Дунай Ф. Безнең Рәис. № 5
Зарипов М. Генерал булу рәхәтме? № 1, 2
Минһаҗева И. Милли музей сәхифәләре. № 7
Фәйзрахманов Ә. Гасыр бусагасын атлаганда... № 12
Юныс В. «Кызыл Кхмер». № 11
Юныс М. Альбатрос язмышы. № 9

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Әдәби тәнкыйтьне ничек «терелтергә?» *(Әдипләребез фикерләре)* № 10
Бәйрәмова Ф. Дини тәрбияне кем бирер? № 12

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Гыйльманов Г. Образ. Символ. Рухи кодлар. № 4
Гыйльманов Г. Күңел офыклары. № 9
Мөхәммәтвәлиева Г. Г. Исхакыйның «Өйгә таба» повесте. № 8
Урманче Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. № 6, 7
Хатыйпов Ф. Иҗат серләре. № 5
Хәсәнова Ф. Лирик сәүдәгәр кем ул? № 10
Шагыйрьҗан Л. Сүзләр, сүзләр... № 3

## ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

*(АНКЕТАГА ҖАВАПЛАР)*

Фәизов Р., Шәрәфиев Р. № 1
Сибат Р., Әйди Т. № 2
Гамбәр Н. № 3
Гаташ Р., Хәлим А. № 4
Миңнуллин Т., Рәшит Ә. № 5
Сверигин Р. № 6
Галимуллин Ф. № 7
Вәли М. № 8
Гыйльманов Г. № 10
Дунай Ф., Фәттахов И. № 11
Хафизов С. № 12
Редакциядән *(йомгак)* № 12

### ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

Фатыйхова М. «Канга батты колларым». № 7

### ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Әхмәтҗанов М. Фатих Кәрими мирасына яңа сәхифәләр. № 6
Зарипова Ч. Сәгыйть Рәмиев һәм Гаяз Исхакый. № 2
Ислам З. Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай. № 9
Мәрданов Р. «Шура» журналында әдәбият мәсьәләләре. № 4
Фәхретдинов Р. Казан ханлыгы. № 10

### КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА

Шабаев М. Бер китап язмышы. № 11

### «ИДЕЛ» ЖУРНАЛЫНА—10 ЯШЬ

Низами Р. Яшьлек урамына чакыру. № 7
Юныс Р. Өзелгән спектакль. № 7
Зәйдулла Р. Йөгез, янә бер дога. № 7
Гыйматдинова Н. «Муса гына гаепле түгел». № 7
Мәзәк хәлләр. № 7

### ЮБИЛЕЙЛАР

#### А. С. ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА 200 ЕЛ

Гаташ Р. «Хәзрәти Пушкин». № 6
Пушкин А. С. Шигырьләр. *(Зөлфәт тәрҗемәсе).* № 6
Сафиуллин Җ. А. С. Пушкин иҗатында Коръән. № 6

#### ДӘРДМӘНДНЕҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

Хәмидуллин Л. «Танылмыйдыр кеше тышыннан...» № 12

#### НӘКЫЙ ИСӘНБӘТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Исәнбәт Н. Мәкальләребез турында. № 10, 11, 12

#### ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Мостафин Р. «Өзелергә житеп сыкрый күңелем...» № 1

#### ӘНВӘР ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Миңлебаев К. Аның шигърияте озак балкыр әле. № 3

#### ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Шәфигуллина Р. Саф йөрәккә пакь дөнья кирәк. № 5

#### ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ 90 ЯШЬ

Олуг әдибебез бар! *(Аның турында замандашлары, каләмдәшләре).* № 3
Еники Ә. Шаяру. *Хикәя.* № 3

#### МОСТАЙ КӘРИМГӘ 80 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Прометей утың сүнмәсен. № 10

#### КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВКА 70 ЯШЬ

Галиуллин Т. Сүз җинәр. № 6

#### ШАМИЛ РӘКЫЙПОВКА 70 ЯШЬ

Вәли М. Кешелеклелекнен дәвамы—батырлык! № 9

#### ФӘНЗАМАН БАТТАЛГА 60 ЯШЬ

Баттал Ф. Сатирик хикәяләр. *(Ш. Маннапның кереш сүзе белән)* № 2

#### ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВКА 60 ЯШЬ

Исламов Р. Галим, мөгаллим һәм остаз. № 4

#### ФЛҮН МУСИНГА 60 ЯШЬ

Ханзафаров Н. Танылган галим. № 2

#### МИРГАЛИМ ХАРИСОВКА 60 ЯШЬ

Камалов Б. Пар канатлар талмасын. № 3

#### РӘШИТ БӘШӘРГӘ 50 ЯШЬ

Әмәк Ф. Күңелдәге кызыл миләшләр. № 10
Бәшәр Р. Мин бит татар егете. *Шигырьләр.* № 10

#### ӘХӘТ ГАФФАРГА 50 ЯШЬ

Гыйльманов Г. Халыкчан иҗат иясе. № 1
Гаффар Ә. Шәҗәрәм ажаганнары. *Хикәят.* № 1

#### РАВИЛ РАХМАНИГА 50 ЯШЬ

Вәли М. Гасырлар ярында. № 5

### ТАРИХ

Газыймҗанов Г. Исхак мулла варислары. № 8
Гайнетдин М. Әдәби телебез төбендә—Алтын Урда теле. № 1
Исхакый Г. Артист Габдулла Кариев. № 11
Кәримова А. Ике йолдыз яктысы. № 11
Мусабәкова Р. «Мин догада» *(Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына 110 ел).* № 8
Рәмиев З. Габдрахман Сәнгати—фоторәсемнәрдә. № 8

### ФӘН

Әмирхан Р. Максатына тугры Максуди. № 5
Гайнетдин М. Тагын бер фараз. № 5
Галләмов Р. Тарихчы үткән юл. *(Сәлам Алишевка 70 яшь тулу уңаеннан)* № 3
Гыйләҗетдинов С. Борынгы риваятьләребезгә бер караш. № 5
Кириллова З. Үткәннәрдән сабак алыйк. № 6
Рәмиев З. Тукай энциклопедиясе төзелсәме? № 6
Хисамов Н. Мөбарәк тәсбихнын бер буыны. № 6

### ФӘН ҺӘМ ДИН

Тимергалин А. Пәйгамбәр. № 2, 3

### ХӘТЕР

Госманов М. Бер күргә ни житә яки бер фоторәсем турында. № 5
Гыйләҗев А. Онытылмас эшләр калдырып китте *(Ш. Хөсәеновның туувына 70 ел)* № 11
Маннапов Ф. Бабаемның тормыш фәлсәфәсе: кеше хакы. Истәлек. *(Ә. Еники кереш сүзе белән)* № 2

Мостафин Р. Шамил Усманов турында өч риваять. № 7
Сафин Ф. Кече Укмаска сәяхәт. № 11
Сибгатуллин К. Басылмаган шигырьләреннән. № 11

## СӘНГАТЬ

Арсланов Г. Халык җырчысы. № 6
Куанычлар да бар, борчулар да җитәрлек *(җырчы З. Сөнгатуллина белән язучы М. Зарипов әңгәмәсе).* № 5
Җәләлов Х. Сагындырып искә төшә һаман *(Г. Шамуковның тууына 90 ел).* № 12
Минлебаев К. Кодрәт иясе (*Рәссам Илдар Зариповка 60 яшь).* № 10
Монасыйпов Ш. Урманченың рухи дөньясы. № 1
Сафиуллин Ю. «Әйләнә сәхнә...» № 11
Фәйзуллин Р. Нарасый хәким. № 6
Хәйруллина З. Опера сәнгате йолдызы. № 5

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Бәйрәмова Г. Шәфкать һәм вәхшәт. № 5
Закирҗанов Ә. Тормыш учагы сүнмәсен. № 7
Зарипова И. Шигърият һәм җыр. № 11
Кәримуллин Ә. Аллалар, фиргавеннәр нинди телдә сөйләшкәннәр? № 9
Кәшфиева Л. «Атларым, колыннарым». № 10
Урманче Ф. Татар халык музыкасы турында җитди хезмәт. № 1
Хәбибрахман Р. *(Фәизов Р.)* Тарихка күпер. № 1
Шәрәфиев Р. Якты сагыш. № 7

## СӘЯХӘТНАМӘ

Даутов Р. Әдипнең җыентыкларына керми калган әсәрләреннән берсе. № 4
Камал Г. Истанбул мәктүбләре. № 4, 6

## МИРАС

Бикташев А. Тәнкыйть тирәсендә. № 7
Ибраһимова Ф. Әдип иҗатына ике караш. № 7
Ибраһимов Г. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналу мөнәсәбәте белән. № 7
Исхакый Г. Г. Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә. № 4
Шамов А. Картлар *(Әсәрдән өзек)* М. Шабаевның кереш сүзе белән. № 9

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Арсланов Г. Гаяз Исхакый һәм татар театры. № 9

## МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

Надиров И. Татарга тугры Төркәр. № 10
Соуккон Т. Швециядән татар тавышлары. № 10

## ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Баттал Ф. Мәзәкләр. № 8
Маннап Ш. Мәзәкләр. № 1
Фәйзрахманов И. Пародияләр. № 2
Шиһапов И. Хикәяләр. № 7

## ХАЛЫК ИҖАТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Мәхмүтов Х. Гыйбарәләр тарихына сәяхәт. № 9
Мишәр әкиятләре (*Л. Җамалетдин кереш сүзе белән)* № 8

## «КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН

Тарихка калган мизгелләр. № 6

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Күренекле мөхәррир һәм тәрҗемәче Яхъя Халитовка 70 яшь. № 8
Фәния Гайнановага 70 яшь. №11
Дамир Гарифуллинга 60 яшь. № 6

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Габдрахман Сәгъдинең тууына 110 ел. № 3
Ринат Рәхимовның тууына 60 ел. № 3

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Вәлиева-Сөләйманова Г. Иҗатка багышланган гомер. №11
Гамбәр Н. Рәссам үткән юл. № 3
Гамбәр Н. Рәсемнәрдә—татар дөньясы. № 4
Мөхәммәди Ә. Казан гербы—татулык тамгасы. № 1
Сибгатуллина Т. Күңелгә нур иңдерүче. № 5
Шаһиева Р. Галәм хисе. № 2
Шаһиева Р. Миләүшә гөлләре. № 7

Укучы сүзе №№ 1, 3, 5, 6, 7, 8, 10

## ЛАТИН ИМЛАСЫНДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

Гарданов С. Әхсән Баяновның «Су өсләрендә пароход» повестен укыгач. № 1
Маннап Ш. Мәзәкләр. № 1
Ханзафаров Н. Танылган галим Флүн Мусинга 60 яшь. № 2
Фәйзрахманов И. Пародияләр. № 2
Габдрахман Сәгъдинең тууына 110 ел. № 3
Ринат Рәхимовның тууына 60 ел. № 3
Тукай Г. Шагыйрь. *Шигырь.* № 4
Шагыйрьләребез—Тукайга. Ә. Фәйзи, Н.Исәнбәт, М. Шабаев, Л. Шагыйрьҗан, Зөлфәт шигырьләре. № 4
Тимершин Р. «Казан утлары»—Башкортстан татарларының яраткан журналы. № 5
Мортазин Ф. Украинада яшәсәк тә, күңелебез белән Татарстанда без. № 5
Ибраһим А. Латин хәрефенә кайту - телебезне, милләтебезне саклап калуда мөһим адым. № 7
Маратова Р. Укучы сүзе. № 8
Хәсәнова Ф. Лирик сәүдәгәр кем ул? № 10
Гарипов Р. Укучы сүзе. № 10
Гыйләҗев А. Онытылмас эшләр калдырып китте... *(Шәриф Хөсәеновның тууына 70 ел).* № 11

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан №№ 1—12

*Иҗтимагый—мәдәни тормышыбыздан*

## НИҺАЯТЬ—ЭНЦИКЛОПЕДИЯ!

3 ноябрь көнне Татар энциклопедия институты бинасында әле яңа гына Лондон каласында басылып Казанга кайтарылган «Татар энциклопедик сүзлеге» белән кин җәмәгатьчелекне таныштыру кичәсе булып узды. Тантананы ТФА президенты М. Хәсәнов ачты. Аннан соң, бу вакыйганы тарихи дип билгеләп, әлеге сүзлекнең татар энциклопедиясенең әзерләнә торган күптомлыкларына ачкыч булачагын искәртеп, Татарстан Президенты М. Шәймиев чыгыш ясады. Ул бу олы хезмәтне чыгаруда катнашкан галимнәрне ихлас күңелдән котлады, киләчәктәге эшләренә уңышлар теләде. Тәкъдим итү кичәсендә, шулай ук, ТР мәгариф министры Ф. Харисов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, тарихчы профессорлар А. Литвин, Б. Солтанбәков, академиклар М. Мәхмүдов, И. Таһиров, Казан мэры К. Исхаковлар чыгыш ясады.

## МИЛЛИ КИТАПХАНӘДӘ ЯҢА ЗАЛ

Вакытлы матбугат бүлеге китапханәдә иң зур бүлекләрдән санала. Бирегә меңнән артык исемдәге газета һәм журналлар алдырыла. Шуларның йөздән артыгын Татарстанда чыга торган басмалар тәшкил итә. Шушы елның 28 сентябрендә ачылган бу яңа залда 1917 елга кадәр чыккан газета-журналлар белән дә танышырга мөмкин. Элек, урын аз булу сәбәпле, әлеге басмалар гомуми фондта саклануган булган, яңа зал җиһазлангач, иске газета-журналларны яхшылап төпләп, билгеле бер тәртипкә китергәннәр. Залда утырып эшләр, кирәкле күчермәләр алу өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган, шулай ук, үзенә кирәк мәгълүматны компьютер аша эзләп алырга була.

Татарстан Милли китапханәсе бүген Республикада дөнья вакытлы матбугат басмаларын чагыштырмача тулы һәм иң күп алдырып торучы бердәнбер китапханә. Татарстан матбугаты залы студентларга, укытучы-профессорларга, гомумән, фән әһелләренә һәм гади укучыларга нык ярдәм итәчәк. Китапханәнең адресы: Казан, К. Маркс урамы, 36 йорт.

## ЖУРНАЛИСТЛАР ГЫЙЛЕМ ЭСТИ

18-20 октябрьдә Татарстан Дәүләт Советында район һәм шәһәр газитләре, гаммәви мәгълүмат чаралары журналистлары өчен «Журналист: һөнәри стандартлар һәм һөнәр этикасы» дигән темага семинар булды. Өч көн дәвамында журналистлар сайлау алды кампаниясен үткәрүдәге нечкәлекләр, бүгенге катлаулы һәм буталчык заманда журналистларның һөнәри әхлагын саклап калу зарурлыгы турында сөйләштеләр.

Быелгы сайлау алды агитациясе Русиянең—дүрт, Татарстанның өч законына таянып уздырылуын исәпкә алсак, журналистларга, чынлап та, кыенга туры киләчәк. Семинарда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов, Президент Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтә һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире И. Терентьева, Татарстанның Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары Л. Гусева, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова чыгыш ясады.

Соңгы көнне журналистлар Татарстан Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин белән очраштылар.

## ЯҢА ЖУРНАЛ

22 октябрьдә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетында «Фән һәм тел» журналын тәкъдирләү булды. Журналны гамәлгә куючылар—Казан хакимияте, Татарстан Фәннәр академиясе, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Казан архитектура-төзелеш академиясе. Бу истәлекле җыелышта журналның баш редакторы, Казан вице-мэры, профессор Фаил Әхмәдиев, академик Индус Таһиров, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Мирфатыйх Зәкиев, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе, шагыйрь Роберт Миңнуллин һәм башкалар чыгыш ясады.

Яңа басманың елга дүрт мәртәбә чыгып, бездәге галим-голамә мөхитендә генә түгел, мәктәп укучылары, укытучылары, киң катлау җәмәгатьчелек, гомумән, дөнья татарлары арасында таралуы фараз ителә.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

* * *

20 октябрьдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы үзенең яңа сезонын башлап җибәрде. Беренче очрашу күренекле язучы һәм галим Зәки Зәйнуллин иҗатына багышланды.

Кичәдә чыгыш ясаган каләмдәшләреннән Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Татарстанның халык язучысы А. Гыйләҗев, Т. Миннуллин, М. Хуҗин, К. Тимбикова, М. Галиев, М. Әмирханов, Р. Низамиев, Ш. Мостафин, Г. Садә, Р. Зәйдулла, Р. Корбан, К. Шәйхетдин, Н. Сафина һ. б. язучының соңгы елларда проза һәм публицистика өлкәсендә гаять актив эшләвен, халкыбыз тормышын чагылдырган дистәләгән повесть, «Ат каралары» белән «Агыйделнең аръягында» романнарын һәм йөзләп хикәя иҗат итүен әдәбиятыбыздагы бер яңалык буларак билгеләп үттеләр. Моннан тыш чыгышларда язучының милли хәрәкәттә актив катнашуы, аны оештыручылардан булуы да хупланып телгә алынды.

Очрашуны Язучылар берлегенең проза һәм публицистика остаханәсе җитәкчесе язучы С. Шәмси алып барды.

* * *

Татарстан Язучылар берлеге каршында оешкан «Шигърият остаханәсе» (җитәкчесе Зиннур Мансуров) үзенең беренче утырышын шагыйрә Фирдәвес Әһлиянең яңа дөнья күргән «Кояш баласы» дигән шигъри җыентыгы белән таныштыруга багышлады. Мәдәният әһелләре мәҗлесендә чыгыш ясаучылардан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, рәис урынбасары, тәнкыйтьче Г. Гыйльманов, Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, шагыйрьләрдән Р. Мингалимов, Ә. Гадел, Р. Низамиев, әдипләрдән М. Маликова, А. Хәсәнов, З. Хөснияр, драматург Д. Салихов, язучы Ш. Мостафин һ. б. шагыйрә иҗатына югары бәя бирделәр.

* * *

21 октябрьдә Татарстан Язучылар берлегенең «Әдәби тәнкыйть остаханәсе» (җитәкчесе Мансур Вәлиев) үзенең эшен башлап җибәрде. Тәнкыйтьчеләр бергәләп киңәшеп, алдагы эшләр планын төзеделәр, бу тармакны җанландыру буенча кызыклы тәкъдимнәр керттеләр. Шул ук утырышта Рәфикъ Шәрәфиев һәм Хәнәфи Бадиков иҗатлары тикшерелде һәм алар Язучылар берлегенә тәкъдим ителде.

* * *

28 октябрьдә Язучылар Берлеге каршындагы Кабул итү коллегиясенең оештыру җыелышы булды. Мәгълүм хакыйкать: Язучылар оешмасының киләчәге—Берлеккә яңа кабул ителгән авторларга бәйле. Аларны язучылар гаиләсенә кабул итү нинди принципларга корылырга тиеш? Яңа заман элек гамәлдә булган тәртипләргә беркадәр үзгәреш кертүне таләп итә. Җыелышта катнашкан—Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Кабул итү коллегиясенең рәисе Р. Фәйзуллин, язучылар М. Хәбибуллин, Г. Зәйнашева, Ә. Гадел, Ж. Дәрзаман, Г. Морат һ. б. Язучылар берлеге әгъзалыгына кабул итүнең Яңа Положениесен эшләргә дип таптылар.

*Тышлыктагы сурәтләр:*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Кышкы мизгел»—фотоэтюд.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь Разим Вәлиуллин.

# БЕЗ ЭНЦИКЛОПЕДИЯЛЕ ХАЛЫК




Халкыбыз рухи тормышында зур вакыйга: күп буыннарның хыялы булган Татар энциклопедик сүзлеге дөнья күрде. Фәннәр Академиясенең Татар энциклопедиясе институты (җитәкчесе Г. Сабиржанов) хезмәткәрләре тарафыннан башкарылган бу басмага татар халкының килеп чыгышы һәм тарихы, Татарстан, аның икътисады һәм иҗтимагый-сәяси хәл-вәзгыяте, табигате, географиясе, татар теле-әдәбияты, мәдәнияте, гореф-гадәте һәм йолалары, күренекле шәхесләре турында 16 меңнән артык белешмә тупланган. 710 биттән торган бу уникаль энциклопедик сүзлек югары полиграфик ысул белән, яхшы сыйфатлы кәгазьдә Лондон шәһәрендә басылган.

Татар энциклопедик сүзлегенең фәнни редакция коллегиясе рәисе— басманың баш редакторы академик М. Хәсәнов.

Индекс 73210



Разим Вәлиуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)